
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1995



## Рашат Низамиев

### Хуш киләсең, Яңа ел!

Көртләр ерып, күр, Яңа ел килә...
Һәм сәгатьләр суга уникене!
Коеп-коеп ак теләкләр ява —
Ватанымның бүген шундый көне.

Картаюны белми торган төсләр
Алып калыйк карлы чыршылардан.
Башланмаган бәхет турындагы
Өр-яңа җыр отыйк җырчылардан!

Карларыннан — аклык, мәхәббәттән
Пакьлек алыйк, дуслар... Һәм аннары:
Ал язларга табан җилдерик без
Ак чанага җигеп бураннарны!

Тыныч йолдыз, тыныч нурлар яусын
Җир шарының һәрбер төбәгеннән.
Фәкать моржалардан чыксын төтен,—
Чыкмасын ул илләр йөрәгеннән!



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**12**

**(878)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

М. ӘГЪЛӘМ. Күз яше без. *Шигырьләр* ..... 3
Ә. БАЯНОВ. Хыялда туган калам. *Автобиографик повесть* ..... 10
А. ХӘЛИМ. Төрле еллардан. *Шигырьләр* .. 64
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Менә шундый мәхәббәт. *Хикәят* ..... 71
С. МУЛЛА ГАЛИ. Нишләр идек. *Шигырьләр* ..... 76
Ә. ГАБИДИ. Сагышлы хушлашу. *Шигырьләр* ..... 79

ДРАМАТУРГИЯ

Д. САЛИХОВ. Алла каргаган йорт. *Драма ике пәрдәдә* ..... 82

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Сугышта жингәч — зинданга... *(70 яше тулу уңаеннан күренекле язучы Гурий Тавлин белән әңгәмә)* ..... 99

ОНЫТЫЛГАН ИСЕМНӘР

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. Шагыйрь Миңлекәй ..... 104
МИҢЛЕКӘЙ. Кирәк түгел миңа... *Шигырьләр* ..... 105

ӘДӘБИ МИРАС

С. МАКСУДИ. Англиягә сәяхәт ..... 107
Ә. КӘРИМУЛЛИН, Р. ДАУТОВ. Сәяхәтнамә авторы турында берничә сүз ..... 152

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Т. ӘЙДИ. Хуҗа Насретдин оныгы ..... 160
Г. НӘСИН. Хикәяләр ..... 165

КИТАП КҮЗӘТҮ

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ. Татарстанда Сталинның канлы эзләре ..... 174

СӘНГАТЬ

К. МИҢЛЕБАЕВ. Сабыр төбе — сары алтын ..... 181
Дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр 181
1995 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,
бухгалтерия — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: автобиографическая повесть А. БАЯНОВА «Город рожденный в мечтах»; рассказ Г. ЗАЙНАШЕВОЙ «Вот такая любовь»; стихи М. АГЛЯМА, А. ХАЛИМА, С. МУЛЛА ГАЛИ, А. ГАБИДИ.
«Драматургия»: драма Д. САЛИХОВА «Богом проклятый дом».
«Литературная критика»: статья посвящена 70-летию писателя Г. Тавлина.
«Забытые имена»: статья Марселя АХМЕТЗЯНОВА «Поэт Миннекай», стихи Миннекая.
«Литературное наследие»: С. МАКСУДИ «Путешествие в Англию»; А. КАРИМУЛЛИН и Р. ДАУТОВ «Несколько слов об авторе».
«Из классики мировой литературы»: статья Т. АЙДИ «Внук Ходжи Насретдина»; рассказы Г. НЕСИНА.
«Книжное обозрение»: Махмут АХМЕТЗЯНОВ рецензирует книгу «Кровавые следы Сталина в Татарстане».
Религиозные праздники и памятные дни.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимние сумерки» — картина М. Рахманкулова; литературный критик, главный редактор журнала «Идель» Ф. Зулькарнаев.

## IN OUR ISSUE

«Prose and poetry»: the autobiographical narrative of A. Bayanov «The Town borning in dreams»; G. Zainasheva's story «A kind of love»; the verses of M. Aglyam; A. Khalim, S. Mulla Gali, A. Gabidi.
«The Drama»: D. Salikhov's drama «The house cursed by god».
«Literary critique»: the article devoted to the 70 th Anniversary of G. Tavlin.
«Lost names»: M. Akhmetzyanov's article «The poet minnekai»; Minnekai's verses.
«Literary heritage»: S. Maksudi's article «The travel through England».
«A. Karimullin and R. Dautov «Several words about an author».
«From world classical literature»: T. Aidi's article «Khadja Nasretdin's grandson»; G. Nesin's stories.
«Bood review»: Makhmut Akhmetzyanov reviews the book «Stalin's murderous Traces in Tatarstan».
«Religious feasts and memorable days».
In our corvers: M. Rakhmankulov's picture «Winter Twilight»; literary critic, an editor in chief of the journal «Idel» Ph. Zulkarnaev.

- Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
- Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
- Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 3.11.95 ел. Басарга кул куелды 13.12.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 8 021. Заказ Д-564.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.



## Мөдәррис Әгъләм

# КҮЗ ЯШЕ БЕЗ

### Ишетәсезме?

Егерме ел әллә кемнәр белән
Бергә яшәп Аккош күлендә
Өйрәнелгән инде сөйләшергә
Шигъри телдә — аккош телендә.

Ә бер төркем һәвәскәрләр килгән:
— Шул шигырьнең серен әйт,— диләр.
Тик үзләре шигырь икәнлекне
Белмиләр шул.
Дөрес әйтмиләр.

Сез сөйләшкән телдә яза алу,—
Аккош теле — сезнең тел, димен.
Сүгенергә өйрәтүче телдән
Кай яклары белән ким, димен.
...Кайда яшәсәң дә ишетүе
Аккош авазына тиң, димен.

Ә-ә-ә... Аккошмы? Күргән бар шул аны.
Күргән идек зоопаркта.
Тик авазын гына ишетмәдек,
Дөнья читләренә барып та.

Җирдә пычрак тулып яткан чакта
Ай, йолдыз да балкый күгендә...

Күрәсезме?
Татар балалары
Сөйләшәләр Аккош теләндә —
Туган теләндә.

*1995, 1 сентябрь*

## Гәптенур җизнинең мәрсиясе

Шундый тимер затлар бар чагында,
Алтын,
Көмеш,
Бакыр,
Җиз нигә?
Уела идем әйтеп,
Коела идем,
Сыена идем кайтып җизнигә.

Ул — шабашник,
Һәм әйтә дә иде:
«Кагы́лмагыз,— диеп,— балтама —
Тота белсәң аны, йомычканың
Һәрбер кисәгеннән бал тама».

Ах итәсең кайчак әйткәненә —
Аннан башка туган тел дә юк!
Без уйлап та чыгарырлык түгел,
Аның сөйләгәне телдә юк.

Юккамыни — ни гомерләр аңа
Яшәдем мин үги ул булып.
Әгәр бүген шигырь язам икән,—
Бу мәрсиям — сөйләү ул булып:

«Ташла Казаныңны,
Баш катырма,
Тинтерәмә анда...
Күч кенә!
Дөрес, син дә хаклы, бер агачтан
Бер агачка күчә күч кенә.

Мин яратам кайнеш кай ягыңны?—
Җилгә каршы бару синдә бар;
Тик шунысы гаҗәп: матурлыкны
Табам дигән җүләр син дә бар!
Кеше җаны, дисәң!—
Син аңарга
Аягыңны атлап кер генә —
Бәлки чистартырга теләвеңдер:
Кер генә шул анда, кер генә!»

...Балта остасы иде. Кирәк булса,
Күтәрә дә йортны, төшерә.
Акчасын да әйбәт, башкасын да
Шактый гына әйбәт төшерә.

Баш авырту хәлен узып киткәч
Тотып ала иде эч мәле.
Тир — тир белән, Чир — чир белән чыга,—
Тустаганлап түгеп эчмәле!

— Хәл яманмы, җизни?
— Һәйбәт түгел,—
Дигән кебек кенә баш кага.
Ходай аңа олы һөнәр биргән,
Багышламагандыр башкага.

Идел-Чулман диеп үлә иде,
Бик тә гашыйк иде суга ул.
Әчтерханга бәрәңге төшереп
Язларында акча суга ул.
Акча аның гомер буе
Дәва да булды шул, яра да.
Эшли иде аны — эш булмаса,
Җинел генә такта яра да.

Аннан башка мин ялангач калдым,
Аякта бар кием,
Башта — юк.
Аннан башка өске өлешем буш —
Кая бүрек?
Хәтта баш та юк!

Корыч бер зат иде.
Аннан башка
Алтын, Көмеш, Бакыр, Җиз нигә?
Ярдай уела идем,
Комдай коела идем —
Кайтып сыена идем җизнигә.

...Имчеләр бирә ят им.
Мин ятим, ансыз ятим.

*1993—1995*

## Диңгез эзли чишмә

Мәсьәләне күпме генә ясама син,
Ясама син,
Чишмә —
Күз алдыңа килеп басар
Акаеп шул Чечня.

Котылмас булсак да күпме
Авыз чайкап кына —
Килеп төртелдек,
Торабыз
Инде байтак кына!

Байтак кына микән инде,
Әйе, байтак гасыр!?!
(Халыкларның хыяллары,
Бәлки, чынга ашыр.)

Алда өмет:
Әмма якты
Өмет түгел — томан...
Өметләнеп карау белән
Ул таралмас сыман.

Җил булып исәргә кирәк,
Таратырга кирәк —
Аның өчен үз халкыңны
Яратырга кирәк.

Төрки якын, гөрҗи, әрмән,
Балтыйк якын җанга.
Һәммәсе дә якын безгә,—
Без — Татарстанга.

Тагын нәрсә алда?

Тыгылмагандыр ул, димен,
Дәүләт дигән чишмә...
Диңгез чишмәсен эзләсә,
Үзен эзли Чечня.

*1995*

## Бер батманнан...

Мин «Идегәй» дастанында тудым,—
Һәм калырмын аның дастанында.
Бәлки бераз калыккан чак булыр,
Калган чак та булыр аста гына.

Ә барыбер шул дастанда тудым,
Югыйсә бит әни тапкан иде...
Син — бер батман,— дисең.
Мин — бер батман,—
Шуңадыр да кереп баткан инде.

Үзләреннән туеп, үз-үзләрен
Үзләреннән әле куачаклар...
Әнә шунда янә бездән килеп,
Шул дастаннан кабат туачаклар.

*1995, октябрь*

## Тартып өзгән кебек

Уйнар булып телләренә басмый
Тартып өзгән кебек күрекне.

Хатын-кызга ирек бирәбез, дип,
Без өзгәнбез икәнирекне.

Богау өзәбез дип өзгәнбез бит —
Үзебезгә юлны өзгәнбез.
Ана,
        апа, сеңел,
                кызым, дигән
Изге сурәтләрдән бизгәнбез...

...Һәм барабыз изге киләчәккә
(Үткәнебез әле килбәтсез...)
Кызым туган телсез Сеңел булды,
Сеңел Апа булды — милләтсез...

Шул милләтсез апаң Ана булыр,
Ә булмыйча кая барасың...
Малае да бер көн нәселен эзләп
Кычкырыр ят телдә:
...Ана-сын!

Богау өзгән кебек өзгәнбез бит
Буын белән буын арасын.

...Һәм барабыз якын киләчәккә,
Күзләр күрми,
                күзләр чагыла:
Алда рәшә... Ә син йөгерәсең
Әнкәй белән балачагыңа,

Басу белән капка keләсенә...
Гәрәбәдәй болдыр сап-сары.
Апаңнарның яшереп егетләргә
Кулъяулыклар чиккән чаклары.

Сәкеләрдә өем түшәк-мендәр —
Атлап керү белән тупсадан.
Әнкәң чиккән сөлге, түрләмәләр —
Шатлыкларыңа юк чик-чама.

Өйдә коймак, бәлеш, токмач исе,
Илнең сабантуйга кереше —
Әби, әни, апа.
                ...Һәм җиңгиләр —
Һәммәсе дә алар кул эше.

...Якты киләчәккә барасы бар
Бу төш кенә, бары төш кенә...
Хатын-кызлар асфальт җәйгән чакта
Ул шатлыклар хәзер кечкенә.

Алар инде бездә тугарылган
Йөк атлары кебек иркле...

Өздек инде
Телләренә басмый
Тартып өзгән кебек күрекне.

*1995*

* * *

*(«Саумы, сәях дустым!..»)*
Зөлфәт.

Илле яшь тә тулып килә икән,
Ни хәлләрең бар соң, Зөлфәт энем!
Минем кебек синең хәл хәленчә —
Хәл хәленчә бүген милләтемнең.

Энем, дигәч, син үпкәли күрмә,
Ара бер аймы соң,
Ике аймы?
Милләт өчен кайгы басты башны —
Шул кайгыдан башлар аңгырайды.

Ә чынлыкта милләт күзендәге —
Ике күзендәге күз яше без,
Күзләреннән яше килә икән —
Милләт яши, димәк, без яшибез.

Безнең язган юллар, күз алмасы
Саклап тора күзне керфекләре...
Теге елларда да
Күз алмасы
Була алдык —
Дөнья өркетмәде.

Ник куркырга, хәзер, иманына
Кайтып барган көне милләтеңнең.
Сиңа илле тулып килә, диләр,
Тагын ел бар әле, Зөлфәт энем...

*1995, сентябрь*

## Югалтканмын икән...

Бүгенге көн иң көйсез көн иде,
Иң юньсез көн иде
Иртәдән үк...
Тәгам шатлык, тәгам елмаю да
Куйган кебек иде киртәләнеп.

Бүгенге көн баш-аягы белән,
Бөтен ягы белән өнсез иде...
Ул, ниһаять...
Башлануы белән
Минсез иде.

Кысыла-кысыла чыктым
Тар кочактан,
Кысыла-кысыла чыктым
Тар ишектән —
Чыгып киткән чакта ишеткәнне
Кем ишеткән?

Кысыла-кысыла кердем трамвайга...
Тән басымы,
җан басымы... тагы
кан басымы...

Мин бакчаның әллә кышка калган,
Өшеп каткан кыргый алмасыны!..

Кинәт... Күрәм...
Алда ана булып
Япь-яшь йөкле хатын утырып бара —
Минем ышанычым ике куллап
Өскә тотынып бара.

...Бүгенге көн иң көйле көн булган,
Иң юньле көн булган,
Иртәдән үк...
Тәгам шатлык, тәгам елмаюны
Югалтканмын икән иркәләнеп.

*1995*

## Кешелеген кайтар бәндәгә

Кеше, барыбер, кеше булып кала:
Ул дөньяга нидер бирә ала
Ике кулы бәйле хәлдә дә;
Авызына чүпрәк тыкканда да,
Кием итеп чайкап сыкканда да
Күз карашы кала бәндәдә.

Кеше, барыбер, кеше булып кала:
Кайчагында кешелеген сала
Эчке кием салган шикелле —
Тимгел-тимгел керле булса булсын —
Кием кере киемендә торсын,
Мохит аны шуңа китерде.

Кеше, барыбер, кеше булып кала:
Ул нәрсәдер сала, нидер ала
Тыкканда да хәтта кысага;
Дантедан да ашкан тәмугъ узып,
Соңгы чиктә аякларын сузып
Кабахәтлекләрдән бушана.

Кеше, барыбер, кеше булып кала.
Хайван итеп йөрткән хәлдә дә,
Кешелеген кайтар бәндәгә син
Кешелеген кайтар бәндәгә!
Кайтар аны хуҗа булгач та —
Шуның өчен синдән «влачь»ка!

*1989*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Әхсән Баянов**

# ХЫЯЛДА ТУГАН КАЛАМ

АВТОБИОГРАФИК ПОВЕСТЬ

*Сез аңларсыз, беләм,*
*Сез аңларсыз мине, Кешеләр!*

Бервакыт, авылга шалтыраткан чакта, телефонистка, ничектер, миннән авылдан кайчан киткәнемне, Казанда күпме вакыт яшәвемне сорады. Мин Казанда гомеремнең дүрттән өч өлешен яшәгәнемне әйткәч:

— Ә-ә, алайса, сез — безнеке түгел икән инде, сез — Казан кешесе,— дип, миңа кирәкле номерны җыярга кереште.

Тана алмыйм, ул чакта (бәлки әле хәзер дә) үземне авылдан, туган-үскән җирләрдән шулай катгый рәвештә аерып куярга, үземне чын Казан кешесе дип әйтергә җөрьәт итмим. Озак еллар калада яшәсәм дә, туган җирләр белән бәйләнеш өзелмәде. Авылны хәзер дә сагынам. Сагынам да шунда кайтам. Һәм... өч-дүрт көннән соң ук Казанны сагына башлыйм. Казанны сагынып кайтам. Аллага шөкер, авылга да, Казанга да кайтам. Китмим...

Казансыз да, авылсыз да миңа тормыш юк. Димәк, телефонистка хаклы дип тә, хаклы түгел дип тә раслый алмыйм.

Димәк ки, кайбер нәрсәләрне ачыклый, фикерли төшәргә, кайбер вакыйгаларны искә төшерергә тиешмен. Һәм менә мин хәтерлим, күз алдына китерәм...

* * *

Авылым, туган җирем, халкым биргән бөтен барлыгымны биштәрләп, ерак офыкларга табан атладым. Офык артында — яңа киңлекләр, ихтыяр, язмыш... Язмышыма табан атлап киттем.

1951 елның яп-якты, ямь-яшел июнь көнендә, Агыйдел буйлап пароход килә. Мин инде аның үзәкне өзә торган ямансу һәм жилкендергеч тавышын ишетәм. Агыйдел буйлап, Кама аша Зур иделгә мине шул пароход — Тукай исемен йөрткән пароход алып китәчәк.

Балачактан бирле күз яшьләре төсле чиста сулары белән җаныма дәрман биргән җырчы чишмә, колачлап-колачлап йөзәргә өйрәткән моңлы суым — Базы елгасы миңа рәнҗемәсләр.

Китәм инде. Ялыкканнан түгел,
Туган җирдән ничек бизәсең!
Тар суларга сыймый ярсу күңел,
Киң суларда килә йөзәсем.

Бу сәфәргә чыгу теләге кайчан туды икән? Үземне белә башлаганда ук дисәм, иң дөресе булыр кебек. Чынлап та, оясыннан очкан кош баласының тәвәккәлләп канат җилпүе — гомер буйлата сәяхәткә китүенең башы бит. Минем дә юлым балачактан башлана. Чемоданымда диясем килми, биштәремдә — шул чаклардан ук туган хыяллар, беренче талпынышлар, истәлекләр...

Базы елгасының аръягында, күрше авылның басу капкасыннан ары, кояш баю ягына борылгач, кояшның үз нурларыннан да яктырак булып, ниндидер якты утлар ялтырый башлый. Утлар шулкадәр матур җемелди, бии, шулкадәр күңелле шаяралар ки, алар күңелдә үзләре төсле якты сөенеч кузгаталар. Бу чакларда кечке табигать үзе дә шушындый ук көчле шатлык белән тула һәм аның шатлыклары музыка булып яңгырый башлагандай тоела. Тавышсыз музыка бу. Ләкин ул җанны тавышлы моңнардан да көчлерәк әсәрләндерә. Шаян матурлык, сихерле сер вәгъдә итеп, сине үз янына чакыра. Һәм син шул якка йөгереп китәрдәй буласың, барып җитеп, вәгъдә ителгән серне кулларың белән тотып, сыйпап карарга телисең. Әмма сиңа — яланаяклы малайга, алай ук ерак китәргә мөмкинлек юк шул әле. Сабыр ит, бераз үсә төш...

Әйе, котәргә, үсә төшәргә туры килә. Һәм син көтәсең. Һәм син ниһаять, бераз үскәч тә, үзенә дәшкән ялтыравыклы матурлыкка таба ашыгасың. Ләкин...

Ләкин анда нәрсә күрдең соң?

Анда — әкияти сарай күрергә өметләнгән җирдә нибары сәмәннән ясалган, ярым җимерек, ташландык ферма гына икән ләбаса... Кичке нурлар шул ферманың ярым ватык тәрәзә пыялаларына төшеп балкыган икән. Кая инде ул сихерле серләр! Шундый кызганыч фәкыйрьлек, хет утыр да ела.

Һәм син, өметләрдән гайрәтең чиккәнен тоеп, алданган, бөлгән, бәхетсез хәлдә, кире өеңә кайтып китәсең.

Ярый әле тормыш шулай корылган, хисләр үзгәрә, хыяллар яңара белә. Һәм берзаман шул ук Базы аръягында, шул ук кырлар артында, тик тагын да ераграк, яңа матурлык пәйда була. Офыкның нәкъ читендә Күк белән Җир кушылган төштә, башын күккә чөйгән пәһлеван ат-аргамак басып тора. Тиз арада кешнәп җибәрәчәк тә, үлчәнмәгән киңлекләр аша, әлегә исеме табылмаган билгесез җирләргә үзенең бар көченә ук шикелле атылачак. Ул ат сине көтә. Үзен йөгәнләгәнне һәм атланып, чабып китәр чагыңны көтә. Вакыты җиткәч, нәкъ шулай булачак. Шулай булачагына ышанып, вакыты килгәч, син, тагын юл аласың.

Әмма тагын бер кабат алданганыңны барып җиткәнче үк төшенеп, туктап каласың. Әнә күр, кара! Арт аякларына басып кешнәгән ат урынында — әйе, бар булганы шул — ат рәвеше барлыкка китереп, өч өянке жуылдап утыра икән.

Юк, әкияттәге атка атланып чабарга язмаган сиңа, бар, җәяү кайтып кит, атла...

Хыялыңа таба күпме мәртәбәләр шулай бардың икән? Исәпсез-сансыз мәртәбә. Дөньяның киңәя баруы бәрабәренә, син гомерең офыкларыңа таба ашыктың, ләкин барып җитә алмадың. Матурлык, хыял, мәхәббәт, берзаман барлыкка килеп, икенче вакыт үзгәрә һәм ... синең хыялыңа хыянәт итә.

Турысын әйтергә мәҗбүрмен, алар мине һәрвакыт диярлек алдый килделәр, ә кайчакларда артык рәхимсез рәвештә...

Яшь өстәлү, тәҗрибә арту бәрабәренә фантазия кимергә тиеш кебек булса да, миндә, нишләптер, арта гына барды ул. Аерым әйберләр һәм тере затлар гына түгел,— шулай дип әйтик,— ә бәлки төрле вакыйгалар, төрле күренешләр, хәтта бер авыл, шәһәрләр, илләр укмаша башладылар.

Нәкъ Казан артында Кырлай дигән, Тамбов урманнары уртасында Сыркыды дигән авыллар бар икән. Алардан соң — күз алдына китерү ысулы белән — Казан исемле кала иҗат ителеп, ул минем хыялымда әкертен-әкертен, әйтергә мөмкиндер, берәр кирпечләп, һәр укылган китап исәбенә төзелә, үсә, зурая килде.

Мин мәктәпкә кадәр үк укый башладым. Түшәмгә, өй диварларына ябыштырылган газеталардан, сурәтләрдән хәрефләр (әйе, шулай мөмкин икән!), сүзләр, җөмләләр җыям. Газета исемнәреннән башланып, эшләр абыйларымның һәм мәктәпкә йөргән күрше малайларның уку китапларына, дәреслекләренә барып җитте.

Ә беренче китап? Ахрысы, ул олыларның наданлыгын бетерү өчен махсус чыгарылган уку китабы иде. Тиз арада мин ул китапны тулысынча ятлап, кычкырып укый идем инде. Ул китап һәр өйдә бар. Шул исәптән, каравыл өендә. Шунда көн саен диярлек барып, ат караучыларга укый идем. Шулай итеп, мәктәпкә инде мин шактый укымышлы малай булып барып кердем. Икенче сыйныфка. Мәктәп елларында дәреслекләр һәм хрестоматияләрдән тыш, башка күптөрле китаплар, мисал өчен, «Мең дә бер кичә», «Корыч ничек чыныкты», (Н. Островский), «Сәгать» (Л. Пантелеев) дигән китаплар аерылмас юлдашларым булдылар. Татар язучылары белән танышлык, билгеле инде, Г. Тукайдан башланды. Аннары — Һ. Такташ, Н. Баян, Ш. Маннур, Г. Кутуй һәм тагын күпләр. Такташның бертомлыгы — кызыл тышлы. Барча шигырьләре үзләреннән-үзләре ятландылар.

Шул ук малайлык елларында миндә А. Пушкинның татарча проза һәм шигырьләреннән торган бертомлыгы булып, аның да барлык шигырьләрен яттан белә идем.

Китапларны санап бетереп булмый. Мин аларны монда тик бер сәбәп белән искә алдым — ул китапларның бөтенесен бер исем берләштерә иде — Казан дигән тылсымлы исем. Әсәрләр аша хыялда бөтен бер кала укмашты. Казан каласы...

Уйлар офыгында күктәге йолдызлар санынча яңа утлар кабынды. Алар кайчандыр елга аръягында ялтыраган кечке нурлардан да яктырак иде бугай һәм мин, ихтимал, үземнең таныш күк аргамагыма атланып, шул калага юл тотарга, барып җитәргә тиешмен.

Тиеш дигән, теләк дигән нәрсә — бер, ә мөмкинлек дигәне бөтенләй икенче төрле шул. Күп вакытлар кичте. Аргамак табылмады, мин юлга чыга алмадым. Менә күпме еллардан соң, ниһаять, хыял чынлыкка ирешергә тиеш. Ләкин бу юлы ничек булыр? Хыял мине бу юлы да алдамас микән?

Күңелем төпкелендәге бер тойгы бу юлы икенче төрле булачагына ишарә итә. Беренче галәмәтләр шуңа ышандыра.

Менә инде мин Агыйдел буенда. Хәтерлим, пристаньга мине бер таныш судья (исем-фамилиясен онытканым өчен ул мине гафу итә күрсен) — Андреевка участогы судьясы (безнең районда шундый авыл бар) тарантаска утыртып китерде. Яшь егеткә кайдан шундый ихтирам дисезме? Сере зур түгел, ул чакта районда мин берләнбер баянчы, ә ул, судья иптәш, музыкага мөкиббән киткән зат. Шул гына.

Менә без ярдан дебаркадерга төшәбез. Ә аннан безне хатын-кыз — икенче судья (Югары Яркәй участогы судьясы) елмаеп каршылый. Ул Казанга үзенең кардәш апасын озата икән. Һәм мине булачак юлдашым белән — Рокыя апа белән таныштырды. Әйтәм бит, хәерле башланды —

Казанда тукталырга фатир эзләп интегергә туры килмәде. Рокыя апа мине үзенең Нариман урамында урнашкан өенә чакырды.

Анда ун көнгә якын торылды. Хәзер дә яхшы хәтерлим, Рокыя апа һәм аның гаиләсе мине үз туганнары төсле күреп кунак иттеләр. Рокыя апа хәтта шул вакыт эчендә керләнеп өлгергән күлмәгемне юып бирде. Ә соңрак танышлары аша: «Ник ул безгә килеп йөрми икән?» — дигән хәбәр җибәрә иделәр. Чынлап та, хискә кагылырлык бит. Бар бит шундый яхшы кешеләр! Һәм шулай булырга тиеш тә — Казан дигән кала бит ул!

Шулай, мин инде өнемдә күрәм, Казан бу. Менә ул — Казан!

Максатым — укырга керү.

Әмма мин, беренче эш итеп, институтка яки университетка барырга тиешле кеше, ни өчендер, Кремльгә, китаплар һәм әни сүзләре аша күптән таныш булган Сөембикә манарасына ашыгам. Аның иң өске ярусына күтәреләм. Карыйм. Тирә-якта ямь-яшел, зәп-зәңгәр киңлек. Идел. Аннан ары — таулар, биек ярлар. Шундый да киң, шундый да матур дөнья!

Сулышлар иркенәеп китте. Кинәт күзләргә яңа дөнья ачылгандай, зиһен яктырып киткәндәй тоелды. Тарихлар буе чит кавемнәрнең бу сахраларга ни өчен кызыгулары, аларны кулга төшерү өчен төрлечә хәйлә корулары, җәнҗәл оештырулары, сугышулары һәм, ниһаять, каланы яулап, аны канга батырулары аңлашылды...

Без башлангыч сыйныфларда укыганда, Казанны канга батырган явыз патшаның хәтта урта гасырлар өчен дә кыргыйлык саналган вәхшилекләрен һәм Казанны саклап сугышкан татарларның каһарманлыгын тарих фәне таный иде. Соңыннан бу сүзләр тыелды. Рәсми рәвештә халыклар дуслыгы, тигезлек, милләтләрнең үзбилгеләнү хокуклары хакында бөтен дөньяга игълан кылган адәмнәр бүтән дәүләтләрне колониягә әйләндерүне прогрессив күренеш дип атый башладылар. Бу хәл үзләрен гуманистик караш тарафдарлары дип зурлаган кешеләрнең чынлыкта вәхши ата-бабалары эшен, баскынчы патшалар сәясәтен дәвам итүче икәнлекләрен күрсәтә иде.

Югарыдан, манара биеклегеннән карап, мин кара тарихның ничек сулаганын тойдым һәм үз уйларымнан хәтта куркыныч булып китте. Җаныма салкынлык иңгәнен сизгән хәлдә, түбәнгә төштем. Анда төшкәч, манараның аскы катында истәлекле тактага карап, кәеф янә бер тапкыр кырылды. Язылганны күрергә күзләр карыша. Мәгәр күрми хәлең дә юк. Шулай, манараны татар осталары төземәгән икән, аны ятлар килеп салганнар...

Ничек була инде? Безнең халык, безнең авыл, минем әни бу һәйкәлгә — баскынчыларга әсир төшмәс өчен, Сөембикә зәңгәр биеклектән ташланып түбәнгә мәңге оча биргән легендалы манарага — юкка гына табынып яшәгән булып чыгамыни? Кыйблага карагандай, карашларын алар ятлар корылмасына төбәгәннәрме?

Нәрсәдер дөрес түгел, ниндидер ялгышлык бар монда.

Кремльдән балачакта тойган таныш алдану хисе белән, әкияттән килгән тылсымлы сарайны һәм күк аргамагымны югалткан чактагыча, күңел төшенкелегенә бирелеп чыгам...

Бу минем күңел кайту, яңача гайрәт чигүләремнең башы түгелме? Шушы рәвешле, минем хыялымнан Казан үзе дә, каядыр китеп, юкка чыкмасмы?

Икенче көнне юридик институтта укыган бер якташымны очраттым. Ул мине Казан кешеләренең яраткан ял урынына — Маркиз ярымутравына чакырды. Ап-аяз, якты көн. Идел, минем күңелдәге ямансу уйларга һәм кичерешләргә игътибар итмәстән, үзенә хас булганча иркен, рәхәт сулап ята. Җиләс, талгын җиле белән җаныма бераз тынычлык иңдерә.

Әмма трамвайда кайтышлый, Казансу үзәнендә ниндидер сәер корылма күреп, шуның нәрсә икәнлеген сорыйм. Якташым аңлатканча, бу —

Казанны алганда һәлак булган урыс сугышчылары каберлегенә салынган һәйкәл икән. Башта ышанасы килмәсә дә, кайбер икеләнүләрдән соң, аңлашыла — тарих белән бәхәсләшү җайсыз. Дөресе шулай, яманлыкның бер яхшы ягы була. Бу һәйкәл, ни әйтсәң дә, хакны күрсәтеп тора: без үз телэгебез белән бирелмәгән, ә мөстәкыйльлекне бирмәс өчен каһарманнарча сугышканбыз. Дошманның явызлыклары аңа җиңел җиңү китермәгән, тантана бушка бирелмәгән...

Дошманга каршылыксыз бирелгән халыклар ихтирамга лаеклы түгелдер. Әйе, шулай булып чыга ки, җиңелүенә карамастан, безнең халкыбыз ихтирамга лаек.

Шуны уйлагач, күңелгә бераз җиңеллек иңеп, Казанга килү максатын искә төшерергә мөмкинлек туа.

Хәзер нихәтле гаҗәп тоелмасын, нәкъ шулай булды: мин әле кайсы ишекне шакырга кирәген белмим икән. Әдәбияттан, бигрәк тә чит илләр әдәбиятыннан укып кайбер зур язучыларның әдәбиятка юриспруденция аша килгәнлеген беләм. Шунлыктан, алар үрнәгенә иярмәкче идем. Шул теләк белән юридик институтка киттем.

Ишек янында кешеләр басып тора. Студентлар. Арада институтны тәмамлап килүчеләр дә бар икән. Алар мине дә студент дип белделәрме, сүзгә катнашуыма гаҗәпләнмәделәр. Әлбәттә инде, мин гәпне үзем теләгән якка борырга тырышам. Соңгы курстагыларның нәрсә уйлауларын, нәрсәгә өметләнүләрен, нәрсә эшләргә җыенуларын белмәкчемен. Йә, ничегрәк соң? Алар үз язмышларының ничек, кай таба борылачагын әйтә алмыйлар. Чөнки бит илдә шундый ныклы тәртип яшәп килә ки, асылда юристларга шөгыль аз калган. Институт тәмамлаучыларның кайберләре, ихтимал бүтән профессиягә күчеп, эшне үзләре эзләргә мәҗбүр булыр. Шул сәбәп белән, югары инстанцияләр, университетта юридик факультет ачып, институтны ябарга җыеналар икән. Ә кайбер студентларга Свердловск институтына күчәргә туры киләчәк. Бу хәл исә минем максатка һич тә туры килми. Мин Казанга килдем, бары тик шушында гына калырга тиешмен.

Күңел тынычлыгы дигәнең, шушы рәвешле, янә бозыла төште. Һәм мин, нишләргә белмичә, күпмедер вакыт Ирек мәйданы буйлап йөргәннән соң, Бауман урамына төшәм. Анда, бәхетемә, үземнең икенче якташымны — Зыя Мансурны очратам. Без моңарчы аның белән хат алышкалый идек һәм ул мине Казанга чакыра иде.

Беренче итеп, минем шигърияттәге эшләрем белән кызыксынды. Үзем белән булган шигырьләрне бирдем. Зыя Мансур, үзенә хас сак әдәп белән, шигырьләрнең бернигә яраксыз икәнлеген аңлатыр өчен кирәкле сүзләрне табачак. Ул, кибет тәрәзәләре янындагы тимер култыксаларга сөялеп укыган чакта, мин шундый уй белән басып торам. Беркемгә кирәге булмаган, сәясәттән ерак лирик шигырьләр язганымны беләм бит. Андый әсәрләргә җәмгыятьтә хаҗәт юк шикелле.

Мәгәр бераз ялгышкан икәнмен. Зыя абыйга шигырьләрем ошады һәм ул мине «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясенә алып керде. Икенче шагыйрь, Гали Хуҗи — газетаның җаваплы редакторы — безне дусларча каршылады. Шигырьләрне шунда ук укып чыккач, якын көннәрдә, мин шәһәрдән киткәнче үк басып чыгарырга вәгъдә итте. Сүзендә торды да. Берничә көннән соң шигырьләрем басылган газета минем кулда иде инде. Бу — республика югарылыгында чыккан беренче басма. Минем шигъри биографиям шуннан башлана. Икеләнүләремне белгәч, шуннан соң З. Мансур миңа катгый рәвештә Казан университетына, тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә киңәш итте. Һәм кабул итү комиссиясе бүлмәсенә минем белән бергә керде. Дөресен әйтергә туры килә, чынлыкта ул мине җитәкләп китерде дияргә була.

Ләкин шушы урында көтелмәгән хата килеп чыкты — минем сәламәтлек турында белешмәм юк икән. Нишләргә? Иң якында урнашкан полик-

линикага киләм. Регистратура бүлмәсендә утыручы кыз: «Яшәгән урыгызыздагы поликлиникагызга барыгыз»,— дип кырт кисте. Паспортымны күрсәтәм. Авылдан киткәнмен, ә монда пропискага керелмәгән әле. Нишләргә мондый хәлдә?

— Берничек тә ярдәм итә алмыйм, тәртип булгач, тәртип.

Аңлыйм инде, төшенәм, бу — минем өчен фаҗига. Чүп дәрәҗәсендәге кәгазь аркасында, тагын бер елымны суга салырмын микәнни?! Болай да күп югалган бит инде!

Әмма шушы вакытта чибәр хатын кыяфәтендә коткаручы фәрештә пәйда булмас диген син. Нәкъ үзе. Кәҗә тояклары белән шак-шок килеп җитте дә, миңа тынычланырга куша, кычкыруның сәбәпләрен сораша. Мин регистратор кызга әйткәннәремне кабатлыйм. Әй, Алла, әй, Тәңрем минем! Мөгаен, миңа игелекле гамәл кылырга дигән уйны бу фәрештә зиһененә син иңдергәнсеңдер. Бар лабаса, казна күрсәтмәләреннән өстен яхшылык бар икән дөньяда. Хатын-кыз мине үз бүлмәсенә алып керә дә, йөрәгемнең ничек типкәнен, күкрәгемнең ничек сулаганын тыңлап карагач, тиз генә белешмә язып та бирә. Бу кәгазь мине ким дигәндә оҗмахка алып керәчәк.

Катгый нәтиҗә: менә нинди шәфкатьле икән ул Казан.

Казан күз яшьләренә ышана!

Мондый кешеләр белән очрашу — үзе бер бәхет, үзе бер уңыш бит ул. Мин аларны кабул итү имтиханнары вакытында да очраттым. Рус теленнән язмадан һәм немец теленнән генә «дүрт»ле, калган фәннәрдән гел «биш»ле куйдылар. Группага староста итеп билгеләделәр һәм, иң мөһиме, тулай торакка урнаштырдылар. Читтән ярдәм алмаган кеше — мин фатир өчен акча түләп тора алмаячак идем. Алдан ук сизенүемчә, бөтенесе хәерле килеп чыкты.

Мин — студент.

Әлбәттә, биш елга сузылган студентлык чоры бик тә шома узды дисәм, арттыру булыр иде. Тормыш — тормыш бит инде. Хаталар, уңышсызлыклар, кәеф кырылулардан гел генә котылып буламыни. Ләкин әйтергә кирәк, бу авырлыклар, шигырь язарга мәҗбүр итүләре белән, хәтта файдалы да булгандыр, бәлки. Блокнотка, мәсәлән, шундыйлардан «Топольләр» исемле шигырь язып куелган:

Өй артында үскән топольләрнең
Яфраклары күптән коелган.
Ботаклары бәсләр авырлыгын
Күтәралмый, җиргә сыгылган.

Өсләрендә вак йолдызлар төсле
Кар җемелди кичке нурларда.
Тукталдым да килеп яннарына,
Биреләдем мин бүген уйларга.

Өй артында тополь агачлары
Баш имиләр ләкин салкынга.
Тирән сулап, алар язны көтә —
Яфрак ярыр айлар якында.

Җирдә яшәү җиңел генәмени,
Күпме була туңу, янулар.
Йөрәкләрдә бетмәс эз калдырган
Борчылулар, хәтер калулар.

Халкым көтә миннән бер көрәшче,
Җиңүемә өметем кимемәс.
Бәхетле мин килер көнем белән,
Юк, һичкайчан башым иелмәс.

Яшьлек үзе биргән өмет, ялкын,
Сүнмәс җилдә, сүнмәс салкында.
Топольләр дә шулай язны көтә —
Яфрак шаулар чаклар якында.

1953 елда язылган бу шигырьгә курсташ дус: «Булачак җыентыгыңда почетлы урыннарның берсен алачак шигырь»,— дип язып куйган.

Алай ук була алмады алуын. Шулай да, истәлек буларак, ул чордан калган язмалар минем өчен әле дә кадерле.

Шунысын өстәргә кирәктер, «Йөрәкләрдә эз калдырган борчылулар һәм хәтер калуларда» Казанның гаебе юк. Мондый хәлләр күбесенчә яшь белмәү, ихтимал, яраклаша белмәүдән киләдер, дип уйлыйм. Шул сәбәпкә бәйле очраклардан, мәсәлән, декан урынбасары Л. Л. Тузов ялга киткәч, аның урынына калып торган Шофман фамилияле укытучы, бер

дәрестә безнең группаның бер студенты лекция язмый утырган өчен, миңа шелтә бирергә азаплана...

Берзаман татар теле әдәбияты кафедрасы мөдире Хатип ага Госман, мин авырып дәрескә килмәгән бер көнне, бөтен группа алдында мине «меченый атом» дип атап: «Кайчан, кайда гына шартлар инде ул»,— дип борчылуын белдергән.

Ә сәбәп кечкенә: әдәбият дәресләренең берсендә мин: «М. Җәлил — безнең чорның иң зур шагыйре, ни өчен аның иҗаты өйрәнелми?»— дип сораган идем. Җавап кыска булды: «Мондый сорауларны органнарга бирегез!»

Аңлашыла ки, мин тиешсез җиргә борын сузмаска тиеш булганмын...

Хәер, агай хаклы булып чыкты бугай. Ахрысы, мин чынлап та еш шартлый торган булдым. Әмма беркемгә дә зыян китермичә, бары тик үземне генә җәрәхәтләп шартлый торган булдым. Ләкин бит, әйтүемчә, вак-төяк күңелсезлекләрдә түгел хикмәт. Иң мөһиме шул: фәкыйрь студент булсам да, тулы канлы тормыш белән яшим, яраткан Казанымда кайныйм. Лекцияләр, сынаулар, имтиханнар күзләрне киңрәк ачарга ярдәм итә. Җанны якты кыйтгалар киңәйтә — бәйрәмнәр, кичәләр, концертлар, спектакльләр — уку башланган көннәрдән үк.

Хәтерлим, иң беренче итеп, Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» пьесасы буенча куелган спектакльгә ашыктым. Аны караганда алган ләззәт әле булса күңелдә саклана.

Опера спектакльләренә аеруча еш йөрелде. Гастроль спектакльләрен дә кушып, бер генә яңа спектакльне дә карамыйча калмаганымны әйтә алам.

Ул елларда Свердловскидагы опера һәм балет театрында эшләгән атаклы җырчы Нияз Даутов еш килә иде. Ул катнашкан бер генә спектакль дә каралмыйча калмады. Бермәлне, «Евгений Онегин» операсын караганнан соң, шигырь язылды.

Син моңсу җыр итеп яңгыраттың
Шашып сөйгән шагыйрь йөрәген.
Сының калды минем күз алдында
Рәсеме булып гүзәл көйләрнең.

Ил күгендә янган йолдызларның
Кайберләре, бәлки, яктырак.
Моңнарны мин инде күп ишеткән,
Синең җырың, никтер, татлырак.

Татлы итеп шулай, чын моңнарны
Йөрәкләргә чәчтең син безнең.
Җәйге таңда искән җил шикелле,
Чайкалдырып хисләр диңгезен.

Пушкинның бит, беләм, булмагандыр,
Мондый уе, мондый өмете —
Белмәгәндер үзенең Ленскиен
Җырлар диеп татар егете.

Син моңсу җыр итеп яңгыраттың
Шашып сөйгән шагыйрь йөрәген.
Гәүдәң калды минем күз алдында,
Рәсеме булып гүзәл көйләрнең.

1954 елның 23 апрелендә язылган шушы шигырьне группадаш бер кыз спектакльдән соң артист янына барган да: «Мин — сезнең поклонницагыз, тик менә миннән дә важныйрак поклонникгыгыз бар»,— дип, Н. Даутовның үзенә тапшырган.

Артистның рәхмәт сүзе башка факультет кызлары аркылы да килеп җитте.

Укуга бөтен көч диярлек сарыф ителсә дә, шигырьләр дә языла һәм басыла тордылар. Татарстан радиосында эшләгән чагында, Зыя Мансур миңа шигырьләр тәрҗемә итәргә биргәли иде. Стипендиягә азмы-күпме өстәмә, дигән сүз.

Яшьләр газетасы белән ара өзелмәде. Университетта үзем әдәби түгәрәк җитәкчесе булган чакта да «Татарстан яшьләре»ндәге түгәрәкнең бер утырышын да калдырмыйча йөри идем.

Активлык әдәбият белән кызыксыну зурлыгы белән генә түгел, түгәрәк утырышларның кызыклы, мәгънәле булуы белән дә бәйләнгән булгандыр.

Ул чакта түгәрәккә шагыйрь Шәрәф Мөдәррис җитәкчелек итте. Жанр үзенчәлекләре, формалар төрлелеге теоретик планда да, тәгаен әсәрләр җирлегендә дә тикшерелә, өйрәнелә иде. Ш. Мөдәррис, әсәрләрне һәм алар хакындагы фикерләрне тыңлаганнан соң, йомгак ясауны чиратлап безгә тапшыра иде. Мөстәкыйль фикерләүгә күнегү өчен бу әңгәмәләрнең файдасы тигәндер дип уйлыйм.

Гамәли яктан да шулай. Кулга алырдай шигырьләрнең чыга килүе белән бергә, күләмле әсәр — «Ташлы сукмаклар» («Ике аккош») исемле поэмам беренче мәртәбә шушы газета битләрендә дөнья күрде.

Шигырь һәм поэмалар уку, үзара тәнкыйтьләшү ярышларында катнашкан дистәләрчә кешеләр арасыннан язучы буларак хәзер дүрт-биш кенә исем калды шикелле. Әмма әдәбиятны, матурлыкны чын мәгънәсендә тоеп, яратып калучылар шактый күптер һәм алар түгәрәк утырышларына йөрүләренә үкенмиләрдер, дип беләм. Әдәбиятка мәхәббәт аларның җаннарын баетмыйча, гомерләрен теге яки бу төсләр белән бизәмичә калмагандыр.

Әйе, шактый еш кабатланган читенлекләргә, студентларга хас фәкыйрьлеккә, интегүләргә карамастан, зур мәгънәләрдә Казан мине алдамады. Хыялдагы аргамагым ярыйсы ук матур тормышка алып килде. Булды, барысы булды — күз яшьләре дә, мәхәббәт тә, илһамлы көннәр дә.

Уңышлар да булмады түгел. Биш ел эчендә барлыгы дүрт кенә «дүрт»ле, ә калган фәннәрдән «биш»ле булды. Һәм... шуннан соң яңа тормыш башланды. Бүтән төрле имтиханнар...

* * *

Эш эзлим.

Ул чакта газетада әдәби сотрудник булып эшләгән шагыйрь Зәет Мәҗитов рекомендациясе белән «Совет Татарстаны» (хәзерге «Ватаным Татарстан») редакциясенә киләм. Буш урын юк. Шулай да, тәртип бозып булса да, мине махсус хәбәрче (разъездной корреспондент) итеп алдылар. Тәртип бозу дигәннәре шунда — бу эштә КПСС әгъзасы гына эшләргә тиеш икән. Партия газетасы бит. Командировкалар вакытында партия җыелышларына, бюро утырышларына партбилетсыз узу кыен.

Хәерле булсын диик, эш табылды. Ләкин яшереп булмый, менә шушында башланды хәсрәт дәрьясын кичүләр!

Гаиләм белән чынлыкта урамда калдым. Фатир эзлим — юк. Урамнар буйлап узам — күпме йорт, күпме тәрәзәләр. Ичмасам, бер генә тәрәзә минеке булса икән! Тәрәзәләрдә күпме утлар балкый. Ичмасам, бер генә тәрәзәдән бер генә лампа минем өчен яктырса икән лә! Юк, юк. Ә бит студент елларында нинди әйбәт иде. Кайда алар? Кайда сез, минем алтын көннәрем?! Кайтыгыз, кире кайтыгыз!

Сорарга, ялварырга, түзәргә туры килде. Ниһаять, өч ел узгач, фатир бирделәр. Баш өстемдә хәзер түшәм бар. Шуңа ия булдым, гәрчә түбәдән су үтә торган булса да...

Мәгәр мондый ваклыкларга гына түзмәслек түгелдер без... Түзәргә дәрман биргән төп мәгънә шунда ки, ниһаять, менә тагын тулы хокуклы Казан кешесемен. Яраткан шәһәрем, яхшымы-яманмы, сыеныр урын биргән, шуның өчен рәхмәт әйтергә кирәген тоеп яшәдем. Аның көндәлек эшләрендә катнашырга тырыштым. Тыйнаксызлык тоелуы ихтимал булган бу фикерне кайбер фактлар белән ныгытып карыйм әле.

Илленче еллар азагында Казан сугыш шартларына тартым хәлдә яшәде. Аңа зур диңгез суы «һөҗүм итә» иде. Илле сигезнең язында хәл куркыныч төс алды — шәһәрнең су астында калуы мөмкин иде. Ул каләргә җитмәсен өчен киеренке эшләр алып барылды. Су басуга —

туфанга каршы көрәштә (сугышта диясе килә) барлык хөкүмәт һәм хуҗалык оешмалары катнашты. Су саклагыч корылмалар төзү буенча эшләр кайнады — дамбалар өелде, канаулар казылды, язгы суларны Иделгә күчерүче насос станцияләре төзелде. Бу станцияләр бер генә сәгатькә дә тукталып тормый, ә туктаган очракта, чын мәгънәсендә тревога куба.

Шундый бер эпизод хәтергә төшсә, хәзер дә тәннәр чымырдап куя. Тимер юл станциясе янында насос станциясе эшләми. Җир астындагы зур торбага чүп тыгылган. Су җыела торган кое тулып, аның өсте озакламый күлгә әйләнәсе. Тыгылган урынны йортларда торбаларны сантехниклар чистарткан ысул белән — тимер аркан төшереп чистартмакчы иделәр. Барып чыкмады. Бер генә юл калды — кемдер бозлы су тулы коега төшәргә тиеш. Кешеләр нишләргә белми — аптыраш. Ләкин бер егет табылды — әлләни уйлап тормастан, эчке киемнәренә хәтле чишенде дә, упкынга чумды. Кулында ни булганын хәтерләмим. Шунысы истә нык калган, егет чумганнан соң ике-өч минут үткәч тә, суы хәрәкәткә килде, бөтерелә башлады һәм егет, бауга тотынып, коедан чыкты. Юеш тәнгә киемнәрен кигән чакта, янда торучылар, шул исәптән мин аңа батырлыгы өчен мактау сүзләре әйтмәкче идек тә, егет кул гына селтәп, тиз арада китеп тә барды.

Мондый эпизодлар байтак булды. Үзләрен кемнәрнеңдер коткаруын кешеләр белми, уйлый да алмыйлар иде. Шәһәр гадәттәгечә хезмәт итә, тыныч йоклый бирде.

Билгеле булганча, сугыш вакытында фронт газеталары чыккан бит. Судан саклану корылмалары төзелешендә шундыйрак махсус бюллетень чыгарылып, аның хәбәрчеләренең берсе мин булдым. Тездән пычракка бата-бата, үзенең мәңгелек ирегеп югалтырга теләмәгән Идел ярларын аркылыга-буйга кичеп йөри идем. Ләкин елга буйсынмыйча булдыра алмады. Ямьле, якты көннәрнең берсендә, язгы стихия шаулап тынганнан соң, кала үзе каршында чайкалган гаҗәеп гүзәл диңгез күреп, аһ итте.

Төзелешне халыкта, шаярыбрак бугай, икенче фронт дип атыйлар. Ә мин монда шаяру күрмим. Уйлыйм ки, нәкъ шулай да ул.

Бик үк гөрләп булмаса да, Казан төзелүдә дәвам итә. Чиратта — икенче гигант төзелеш, органик синтез заводы төзелеше. Газетадагы вазифам буенча, күп чакрымнарга җәелгән төзелеш кырлары буйлап, җәен-кышын, язын-көзен, аркылыга-буйга, мин тагын, бата-чума, пычрак юллар гизәм. Үзебезнең газета өчен очерклар, мәкаләләр язам. «Правда» газетасы өчен коллектив репортажлар, хәбәрләр оештырам. Үзләренең килешүләр буенча кабул иткән йөкләмәләрен үтәсеннәр өчен үзәк газеталарда басылган материалларны союз ведомстволарына юллау җиңелрәк, җайлырак иде. Шундый ысул белән без төзелешкә ничек булса да ярдәм иттек, дип расларга җөрьәт итәм. Сөекле калабыз хакына бер генә түгел, берничә пар аяк киеме тузган икән, бу юкка түгелдер, дип уйлыйм.

Ә анда эшләр төзүчеләр өчен генә түгел, бәлки безнең каләм әһелләре өчен дә куркынычсыз түгел иде, әлбәттә.

Менә мин төзелеп килгән фенол-ацетон цехында. Гадәти йортның бер катыннан биегрәк итеп, стеналар инде салынган. Шушы биеклектә, стеналар буена такта күперләр салынып, алар өстенә өем-өем кирпечләр һәм измә тулы ләгәннәр куелган. Астан, басмалар буйлап шул төшкә кызлар измә һәм кирпеч ташуны дәвам итә. Ташчылар кирпеч тезә. Акбулат Маукаев дигән бригадир белән без, алар янына күтәреләбез. Стена белән кирпеч өемнәре аралыгында кызлар-егетләр белән, бер сәбәпсез диярлек, көлешеп, әңгәмә корабыз. Бер мизгелдә басмалар буйлап, носилка тоткан ике кыз менеп килгәнен шәйлим... Һәм берни дә күрми башлыйм. Мин аңымны җуям, мин — юк. Һушыма килгәч, үземне кирпечләр, такталар өеме астында икәнемне төшенәм. Ишетә дә башлыйм. Әле бая гына хихылдашкан, шаярган кызлар ачыргаланып кычкыра, елашалар. Бригадир абыйларын ярдәмгә чакыралар. Нинди җай

беләндер егылмый калган бригадир, әлбәттә, ашыга, кызларга өем арасыннан чыгарга булыша.

Кызларның берсе катырак яраланган икән, Акбулат аны күтәреп алып китте. Ә мин, нишләргә белмичә, кирпечкә күмелгән хәлдә һаман торам да торам икән. Әйе, миңа да өем эченнән чыгарга кирәк ләбаса. Кузгалам, гүяки, суда йөзәм. Йөзеп чыгам. Һәм адәмчә ике аякта басып торам, гәрчә сул аягым канга манчылган икән. Мәгәр атлап була. Кая икәнен аңышмастан, атлап китәм. Кемнеңдер киңәше белән медпунктка таба атларга кирәклеген чамалыйм. Столбняк дигән авыруга каршы укол алгач, өйгә кайтып китәм. Бюллетень белән атна чамасы өйдә яткан арада, бригадир исеме белән «Акбулат» дигән очерк язылa.

Язылу датасы — 1960 ел.

Бу чакта мин редакциянең промышленность бүлеге хезмәткәре идем. 1960 елның сентябрь аенда (бер уйласаң, кызык кына — минем теге яки бу эшкә керү һәм күчүләр гел сентябрь аена туры килә!) әдәбият-сәнгать бүлегенә күчтем. Башта — әдәби хезмәткәр, аннары бүлек мөдире. Җаваплы редактор Галим Рябков тыныч холыклы, әдәпле кеше иде. Ил корабының чайкалуын һәм шуның газета битләрендә чагылуын исәпләмәгәндә, шәхси мәгънәдә кытыршылыклар булмады. Газета Мәскәүдән телетайп аша килгән докладлар белән тулып чыга. Тәрҗемәчеләр шуларны көн-төн тәрҗемә итә, без җыйнаулашып редакциялибез. Иртәнге сәгать бишләргә чаклы эшләргә туры килгән көннәр күп булды. Иртәнге тугызга, күзләрне уып, тагын эшкә ашыгасың.

Зарланмадык, түздек.

Соңынтын, җаваплы редактор булып Шәмси Хамматов килгәч, хәлләр үзгәрде. Үзхолыклы, тынгысыз кеше. Редакция таяк тыгып кузгатылган кырмыска оясына охшап китте. Мәңге селкенмәстәй тоелган имән кәнәфиләр шыгырдап, олы-олы агайлар, апалар, җил очыргандай, тиз арада китеп бардылар. Редакция шактый яшәрде.

Партия оешмасы составында калганлыктан, бу агайлар җыелышларда һич курыкмыйча тәнкыйть белән шөгыльләнә башлагач, Шәмси Хәбибуллович, аларны учеттан төшереп, йорт идарәләре оешмаларына, торган адреслары белән озатты.

Моның уңай ягы да, тискәре ягы да булгандыр, әлбәттә.

Ничек булса да, минем бу җәһәттән җан тыныч, өстәлләр һәм кәнәфиләр тәмен-кадерен белә алмадым. Бөтенесен эш хәл итә дип уйлый идем. Нинди беркатлылык!

Үзара мөнәсәбәтләр хәл иткәнлекне сизгән дә кебекмен, ләкин икенче төрле була да белмим. Вак-төяк командаларны «ишетмәвем» редакторга ошамый. КПСС өлкә комитетындагы административ күнекмәләрен редакциягә алып килгән җитәкче мөстәкыйльлекне ихтирамсызлык дип бәяли. Ә чынлыкта мин аңа ихтирам белән карый идем.

Ул бигрәк тә шуңа — минем креслога чатырдап ябышмавыма гаҗәпләнә, моны җитдилек җитмәү, малайлык дип атый. Бәлки, чынлап та шулай булгандыр. Әгәр шулай икән, мин гомерем буе малай булып калдым, диярга туры килә.

Менә бит нинди хәл. Гагаринның Галәмгә очкан көне. Бөек вакыйга. Махсус әдәби бит оештырдым. Күпчелек урында — шигырьләр. Берсе — үземнеке. Бит әзер. Үземнең кизү торган көн иде — кул куеп җибәрдем. Хаталарның төзәтелүен тикшерим дип типографиягә менсәм, ни күрим, минем шигырь юкка чыккан. Сәбәбен иптәш Хамматовтан сорыйм. Елмая:

— Үз газетасында үз шигырьләрен чыгара диюләре бар ич.

— Алай ярамыймыни?

— Килешми.

Шуны ишеткәч, тиз арада үз бүлмәмә төшеп, ак кәгазьгә ашыгаашыга сүзләр тезәм. Мәгънә шундый: иҗатка комачау итүе сәбәпле, мине әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире вазифаларыннан азат итүегезне үтенәм.

Сәгать кичке сигезләр булуга карамастан, үз урынында утырган редактор өстәленә гариза китереп куйгач, аның гаҗәпләнүе!

— Җиңел, кара, ничек җиңел!— дип кенә куя алды җитәкчем.

Иртән эшкә килүемә газета бите мин кул куйган рәвештә басылып чыккан иде.

Бүтән сүз булмады. Эш дәвам итте.

* * *

Язучының иҗаты — аның биографиясеннән аерылгысыз бит. Һәркемгә билгеле булган бу хакыйкать мине генә читләтеп узмагандыр, әлбәттә.

«Социалистик Татарстан» газетасында эшләгәндә, сәнгатьнең һәм әдәбиятның төрле күренешләре һәм актуаль мәсьәләләре буенча үз фикерләремне даими әйтә торырга туры килде. Төрле җыелышлардан информацияләр, мәкаләләр, махсус битләр бирү белән беррәттән, газета битләрендә аерым жанрлар буенча бәхәсләр оештырдым. Аерым алганда, бүгенге театр һәм драматургиянең торышы һәм «Татар совет прозасының бүгенгесе һәм проблемалары» дигән темаларга дискуссияләр булды.

Драматургиягә кагылышлы бәхәсне йомгаклау рәвешендә басылган мәкалә турында кешеләрдән уңай фикерләрне күп ишеттем. Бигрәк тә язучы Фатих ага Хөсни сүзләре хәтердә нык саклана.

— Әйбәт мәкалә,— диде ул, кабинетка кереп туп-туры узгач, кул биргән чакта ук. Һәм, мин рәхмәт әйтергә җыенгач кына, башка суккандай итеп — Үзең яздыңмы?— дип өстәде.

Редакция исеменнән чыккан ул мәкаләне, бүлек мөдире буларак, мин әдәби сотрудникка әйтеп торып яздырган идем. Әллә ул да авторлыкка дәгъва итәме, дип уйлап, конкрет һәм житди җавап бирергә тырыштым:

— Үзем... ягъни диктовать иттем. Машинистка басты.

Фатих абый рәхәтләнеп кеткелдәде һәм:

— Ярый, ярый, мин болай гына,— дип, тиз арада чыгып та китте.

Хәтер калгандай булды. Ләкин соңыннан белүемчә, ялгышканмын, аның гадәте шундый — үзенә ошаган әйбер турында шулай шаярта икән. Аның бу сүзләрен моннан ары да ишетергә туры килгәләде. Атап әйткәндә, проза турысындагы бәхәскә багышланган мәкаләне укыгач та, шул сүзләрен кабатлады ул.

Проза турындагы бәхәскә йомгак ясау өчен язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында җыелыш булды. Миңа анда доклад кебегрәк кереш сүз сөйләргә туры килде. Житди фикерләр белән бергә, сәеррәкләре дә хәтердә калган: чыгышта коммунистның әхлак кодексы хакында әйтелгән сүзләр дә бар иде. Бу кодексны уйлап тапкан лидерларның үз әхлак дәрәҗәләре ул чакларда безгә билгеле түгел иде шул әле.

Бәхәсне йомгаклап язылган редакцион мәкаләдә Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» һәм «Мәңгелек кеше», М. Әмирнең «Саф күңел», Ф. Хөснинең «Утызынчы ел» романнарын әдәби казаныш буларак билгеләп үткәнмен. Алар белән беррәттән Г. Ахунов, Ш. Бикчурин, Б. Камалов өметле яшьләр сыйфатында телгә алына. Әмма бүгенге көндә тере классик дип танылган язучыбыз Әмирхан ага Еникигә карата җылы сүз әйтергә ярамаган...

Гомуми караш буларак, теоретик фикернең акрын үсүен күрсәтүче мисаллар китерелә. Әсәрләрнең тематикасын баетуга, катлаулы тормышның күпъяклы сурәтләнүе зарурлыгына басым ясала.

Күрәбез ки, әдәбиятның төп бурычлары үзгәрешсез диярлек кала бирә. Мондый таләпләрне бүгенге көннәрдә дә куярга мөмкин булыр иде.

Әдәби җәмәгатьчелекнең һәм үземнең фикер эволюциясен күзәткәндә, бу чор хакында уйлану минем өчен кызыклы, әһәмиятле тоела.

1962 елның көзе. Минем тормышта көчеш-борылышларның гел сентябрь аена туры килүен әйткән идем бит. Тәкъдир кушуы буенча диярсең, тагын шулай килеп чыкты.

Көннәрдән бер көнне мине Татарстанның һәм Башкортстанның чиктәш районнары буйлап йөрергә һәм сәяхәтнамәләр язу өчен командировкага җибәрделәр. Бурычны үтәп кайтуыма — гаҗәп хәл. Газетада Бадамшин фамилияле бер кешенең татар теле мәсьәләләренә карата үтә дә реакцион мәкаләсе басылган. Гадәттә, безнең бүлек аша чыга торган материал. Шуңа күрә язучылар бу материалны мин чыгарган дип уйладылар бугай. Алар, протест белдереп, өлкә комитетына барып житкәч, гаепле кеше дип, мине күрсәткәннәр булса кирәк. Чынлыкта моңа минем каршы киләчәгемне сизгән редактор ул мәкаләне мин югында ашыгып үзе чыгарган иде. Ә күләгә — минем өскә...

Җайсыз хәл. Югарыда редактор ничегрәк сөйләшкәндер, әйтү кыен. Тик нәтиҗәсе шундый булды — аның белән безнең ара шактый суынды, кискенләште. Сизәм, баш өстемдә болытлар айкала.

Шикләнүләр акланды да. Бер көнне редактор секретарь аша чакырта. Моңарчы турыдан-туры үзе дәшә иде. Билгеле инде, сагаеп керәм. Утырырга тәкъдим итә, утырмыйм. Җитди чырай тагын да карала төшә. Җайсызрак хәлдә булса да, сүз әйтелергә тиеш бит инде. Карандаш-ручкаларын «тәртипкә китереп» алганнан соң, ниһаять, ул минем элекке бүлегемнең промышленность бүлеге икәнлеген искә төшерә. Шунда кире кайтырга тәкъдим итә.

— Сәбәп?

— Промышленность житди тармак, аны энергичный кеше белән ныгытырга кирәк.

Моңарчы үзем дә бүлектән бүлеккә күчүләрне табигый нәрсә дип исәпләсәм дә (редакциядә мин эшләмәгән бүлек калмады да бит инде, дөресен әйткәндә), бу юлы, нишләптер, җенем котырды. Инициатива минем яктан булмаганга күрәме?

Алдарак эштән китү хакында бер гариза биргәнемне әйткән идем. Аннан соң тагын бер кискен вакытта: «Җаваплы редакторның эш принциплары белән килешмәвем сәбәпле», — дип, икенче гариза да калдырган идем. Шуларны искә төшердем:

— Ник ул гаризаларга игътибар итмәгән идегез?

Берничә елдан соң Шәмси Хәбибуллович бу гаризаның үз архивында саклануын берничә мәртәбә хәтергә төшерәчәк. Башка кешеләр аша ни өчен аңа рәсми төс бирмәвен хәбәр итәргә тырышачак. Җаваплы редактор КПСС сәясәтен алып бара, аның принциплары белән килешмәү партия сәясәтенә каршы булу дигән сүз. Әгәр шул нәрсә барып житсә, Ирек мәйданындагы иптәшләр минем баштан сыйпамаслар иде... Шулай итеп, редактор миңа яхшылык эшләгән булып чыга. Ә шуны аңламаган мин, житмәсә, кабат сорап торам:

— Нишләп шул гаризага кул куймадыгыз?

Җилкә җыеру җавап юклыкны аңлата.

Шулай булгач, өченче гариза язылырга тиеш.

Сатулашмыйча гына үз бүлмәмә чыктым да өченчесен язып, җилтерәтеп кенә кертеп тә бирдем. Монысы инде редакциядән бөтенләй китү турында иде.

Кул куймады. Өч мәртәбә яңадан чакырып, калырга үгетләде. Аннары урынбасарлары аша сөйләште. Номенклатурада һәм махсус больницага беркетелгән килеш калуымны аңлаттылар. Әмма карарым катгый иде. Ниһаять, өч-дүрт көннән соң, гаризага кул куелды.

Моннан соң булган бер эпизодны шушы язмалар төгәлләнеп килгән көннәрдә, «Шәһри Казан» газетасының баш редакторы урынбасары Әгъзам Фәйзерахманов өстәде. Гаризама кул куелганны көткән арада һәм

яңа мөдир килгәнче, ун-унбиш көн эчендә бүлеккә килгән хатлар байтак җыелып өлгергән икән. Күбрәк гонорарлы эшне сөйгән әдәби хезмәткәр аларга игътибар итмәгән. Шуны сизгән хатлар бүлеге мөдире, Фазыл Мөбәрәкшин дигән кеше, яңа редактор алдында дәрәҗәсен күтәрмәк булып: «Менә, элекке мөдир хезмәт иярәренең хатларына ничек төкереп караган, аны судка бирергә кирәк!»— дип, гауга куптарган.

Ә. Фәйзрахмановның әйтүенә караганда, хатларга берничә бүлек кешеләре җыйнаулашып җавап язганнар.

Шулай да, моңа карап, Фазыл абзыйның дәрәҗәсе күтәрелеп китмәгән иде. Шул ук көннәрдә, башка яшьтәшләре артыннан, аны да пенсиягә озатканнар. Бермәлне күрәм тегене, каршыма ярты квартал кадәр җирдән елмаеп килә...

Һәр кучеш, бигрәк тә мондый кискен күчеш, нервыга сукмый калмый бит. Рәсми урында эшләмичә, гонорар исәбенә яшәү, профессиональлыкка чыгу ул чакта әле мөмкин түгел. Язучылар союзы идарәсе председателе Мирсәй ага Әмир, Союзга гариза язарга тәкъдим итсә дә, беренчедән, мин әле әгъза итеп алынмаган. Ә иң мөһиме: иҗат эше белән гаиләне матди тәэмин итү мөмкинлеге юк. Газетаны мин шушы хәлдә ташлап киттем... Шуңа күрә, өлкә комитетына барырга мәҗбүрмен.

Идеология секретаре Мөнәвир Закирович Тутаев әйбәт каршылады. Хәлне сөйләп күрсәткәч, гаҗәпләнмәде. Димәк, белә...

— Минем янда иптәш Баянов утыра. Сез нишләдегез анда? Әйе, без бит алай сөйләшмәдек. Андый егетләр белән... разбрасываться итмәскә кирәк иде.

Трубкадан: «Кешене көчләп тотып булмый бит»,— дигән сүзләр ишетелеп куя.

— Хәзер ничегрәк соң? Аңлашылды. Ярый.

Трубканы куйгач та, иптәш Тутаев, елмая төшеп, редактор сүзен җиткерде:

— Ничек, сез күнмәдегезмени?
— Эштән күчерерлек сәбәп күрмәдем.
— Ә Бадамшин мәкаләсе? Нигдирәк?
— Җитди теманы утрировать иткән әйбер.
— Нишләп чыгардыгыз?
— Мин юкта чыккан, нишләптер.
— Ну барыбер принципиальлегегез җитмәгән. Фикер әйтмәдегез бит.
— Эш узгачмы?
— Барыбер.

Тавышына, чыраена карап, сизәм, иптәш секретарь җәза бирергә җыенмый, форма өченрәк тәнкыйтьли. Шуңа күрә түзеп, җавап бирми уздырам. Яңадан ул сүз башлый:

— Хамматов әйбәт сүзләр әйтә, көчле журналист, ди. Башкалардан да ишеткәнем бар иде.

Шуннан соң тагын нинди сүзләр булганын хәтерләмим. Ничек төгәлләнүе онытыла торган түгел:

— Номенклатураның кадерен белмәдегез инде. Ләкин эш табарбыз. Элеккесе кебек үк булыр.

Рәхмәт әйтеп, чыгып киттем.

Конфликт хәл ителде дияргә була. Ләкин, ул чактагы түрәләр әйтергә яратканча, юллар инде аерылды. Бөтенләйгә. Берничә елдан соң Шәмси Хәбибуллович редакциягә яңадан кайтырга чакырса да, моның инде минем өчен кирәге калмаган иде. Мин инде профессиональ язучы. Язылыасы әсәрләр берсен-берсе ашыктыра торган чак. Башымда туган язылысы әсәрләрнең, фикерләрнең чиге күренми. Вакыт та җитмәс иде, тик арып, хәлдән тайгач, туктал торырга туры килә. Иртәгесен эшкә өр-яңадан дигәндәй керешәсең...

Шуңа күрә, Шәмси Хәбибулловичка һич икеләнүсез:

— Редакциядән китү дөрес булды бит?— дим.

Элекке житәкчем үз карашында нык тора:

— Дөрес булмады,— ди ул.

Кабатлап әйтәм, бу сүзләр биш елдан соң — мин инде «Казан утлары» журналында эшләп киткәннән соң әйтеләчәк. Һәркайсыбыз үз теләге белән һәм үз юлы белән китсә дә, аңлашу соңгарак калса да, барыбер, килештек.

Язучылар союзыннан «Коктебель» дигән иҗат йортына юллама алган идем. Тынычланып диярлек, шунда сәфәр чыктым.

Шигырьләр язылды. Берсе — «Карыйм таулар ягына» дигәне турыдан-туры әлеге вакыйгадан килеп чыккан иде:

Ятсам да авырып ышыкта,
Карыйм таулар ягына.
Зур дауга чыгар алдыннан
Ял гына бу, ял гына...

Иҗади ялдан кайтуга, икенче көнне үк, таң-иртә белән дигәндәй, «Совет әдәбияты» журналы редакторы Абдулла Гомәр өйгә үзе керде. КПСС өлкә комитеты мине журналның җаваплы секретаре итеп билгеләгән икән. Минем өчен яңа дәвер башлана, димәк.

Журналга күчкәч күп тә үтмәстән, шагыйрьләр секциясе утырышына чакырдылар. Мине союзга алу мәсьәләсе карала икән.

Утырышны Сибгат ага Хәким алып барды. Көн тәртибенең идарә тәкъдиме белән куелганын әйткәннән соң, минем әсәрләр хакында сөйләде. Арада: «кешелекле поэзия» дигән сүзләре хәтердә калган.

Чыгышларның күбесе уңай яктан иде. Тәнкыйть булмады диярлек. Шуңа күрәдер, тәнәфес вакытында хәтта: «Синең аркаңнан тагын күпме сыйпарбыз икән?» — дип шаяртучылар булды.

Тәнкыйтькә тартым сүз дигәндә, Хәсән ага Туфан: «Союзга алырга кирәк. Без талантсызларны да (исемнәре белән әйтте, ләкин кемнәрнеңдер хәтерен калдырмас өчен, кабатлап тормыйм) алдык. Бу — талантлы егет. Ләкин строфаларны боза, иҗек саннарын санга сукмый. Моны ул киләчәктә истә тотарга тиеш»,— диде.

Утырыш, ниһаять, азагына житеп, Сибгат ага мәсьәләне тавышка куйды. Каршы тавыш бирүче булмады. Хәсән абый да кул күтәрде.

— Секция Ә. Баянны Союз членлыгына бертавыштан тәкъдим итә,— дип, С. Хәким утырышны япты.

Ләкин бу — мәсьәләнең хәл ителүе түгел иде...

Сәбәпме?

Сәбәп — үземдә.

Идарәдә яшь язучыларны Союз членлыгына кабул итү комиссиясе бар бит. Сират күпере. Комиссия председателе Гариф Гобәй дигән кеше иде. Нәкъ шул көннәрдә кечкенә нәрсә белән шуның ачуын кузгаттым.

Журналда Г. Гобәйнең ниндидер әсәре басыла. Тәгаен хәтердә калмаган. А. Гомәр бүлмәсендә утыра бу. Алдагы санга төшә торган әсәрләрне папкасы белән күтәреп кергән идем. Җаваплы редактор Г. Гобәй әсәрен фотосурәте белән чыгарырга тәкъдим итә.

Моңарчы авторларны фото белән бирү гадәте юк иде. Чөнки типографиянең ул чакта мөмкинлекләре чамалы булганга, портрет бирүне өнәмиләр. Өстәвенә, номер инде әзер, бер рәсем өчен тоткарлауның мәгънәсе юк. Шуңа күрә әйтәм:

— Булмас инде, башта уйланылмагач...

Абзыйлар ләм-мим. Редактор ник минем сүзне аста калдырасың дими, автор әфәнде иреннәрен кысып кына куя. Мин чыккач ничегрәк сөйләшкәннәрдер, анысын белмим, әмма бу хәлнең нәтиҗәсе озак көттермәде.

Кабул итү комиссиясендә минем кандидатура каралган. Председатель булган Г. Гобәй, сүз башлаганда ук, тональностьны дип әйтик, үзенчә

билгеләгән: «Талантлы дип әйтәләр. Ләкин бераз иртә, минемчә. Сабыр итә төшсен». Г. Халит исемле тәнкыйтьче шул сүзне куәтләгән: «Талантлы булган өчен генә кешене Союзга алалармы?»

Ярый, болар шулай әйтә алсыннар да, ди. Аларны кичереп тә буладыр. Ә менә Хәсән ага Туфан? Ул да бит шул сүзләрне кабатлаган: «Талантлы булган өчен генә Союзга алырга димәгән. Ижек саннарын вата, строфаларны җимерә. Төзәтсен. Бераз кичектереп торырга кирәк».

Акыллы кешеләр болай әйтмәс, дисезме? Валлаһи, беркетмәгә шулай язылган иде.

Карар шундый: «Киләчәктә яңадан карау шарты белән кичектереп торырга».

Кабул итү комиссиясе секретаре В. Нуруллин беркетмәне күрсәткәч, күзләремә ышанмый торам. Әлеге беркетмә бәлки әле дә исәндер. Исән булмаса, В. Нуруллин раслый ала — акка кара белән язылган әле мин китергән сүзләр. Нинди абсурд!

Г. Гобәйгә түгел, Г. Халиткә дә түгел, Хәсән ага Туфанга хәтерем калды... Соңыннан берни булмагандай сөйләшсә дә, җае килгәндә хәтта аркадан сыйпап калгаласа да, мин аңа бер сүз әйтмәс булдым, хәтта сәламен дә аласым килмәде.

Билгеле, дөрес сәясәт түгел иде бу. Күреп торам лабаса, кешеләр Союзга керергә, яисә бүтән максатларын тормышка ашырырга теләгәндә, бөтенләй икенче төрле кыланалар. Файда эшли алырлык кешеләргә ярарга тырышалар, нинди дә булса яхшылык кылырга җай эзлиләр, табалар. Ләкин минем әдәбиятка караш икенче төрле иде шул. Әдәбиятта кемнәрнеңдер яраклашып ирешкән уңышларына чирканып карый идем...

Бераз алга китеп, шуны да әйтергә ярыйдыр: кичектерү дигәннәре өч елга сузылды. Тагын да сузылуы ихтимал иде, ләкин гайре табигый чара күрелде. Съездан соң биш елга сайланган кабул итү комиссиясен таратып, идарә яңа комиссия төзеде. Союз тарихында мондый очракның булганы юктыр һәм, ихтимал, бүтән булмастыр. Бер кеше өчен бөтен бер комиссия таркатылды!

Бу эшнең инициаторы Мирсәй ага Әмир булгандыр. Чөнки беренче тәкъдим аныкы иде бит. Өч ел элек...

Союзга кабул ителгәч, тагын өч ел чамасы узганнан соң, Хәсән абый белән яңадан дуслаша алдык. Хәзер инде безнең хокуклар тигез, кемнең дә: әйбәт мөнәсәбәттән файдаланып, үзенә ниндидер яхшылык өмет итә,— дия аласы юк. Шул ук вакытта, берничә мәртәбә иҗат йортында бергә яшәгәндә, бер-беребезне тәмам белештек дияргә дә була.

Бервакыт Юрмала шәһәрендәге Дубулты иҗат йортында, минем бүлмәдә озак кына сөйләшеп утырганнан соң, кап-караңгы кичтә, ул гаҗәп сүз әйтә:

— Әйдә әле, теге поселок бакчасындагы клумбадан чәчәк орлыклары урлап кайтыйк әле,— ди.

Нинди урлау инде, гаҗәпләнмәгез, карлы-бозлы көз көнендә өзелми калган гөлләр — теләсә кем җыйсын.

Киттек. Ким дигәндә аркылысы-буе ун метрлы түгәрәк чәчәклек. Хәсән ага, шунда менеп, орлык җыйды. Күтәренке күңелләр тагын да күтәрелә төште. Кайтышлый мин:

— Истәлек язарга туры килсә, шушыннан башлыйм бит, Хәсән абый,— дип шаяртам. Җайсызрак та әйтелгән бугай. Ләкин ул көлде генә...

Болар алгарак китеп әйтелгән сүзләр булды инде. Яңадан редакция эшенә кайтыйк.

Җаваплы редактор булган А. Гомәр үзе көчле дип исәпләгән, сүзе үтә торган язучыларга хезмәт итә. Мондый кешеләр белән минем арада потенциаль конфликт ята. Ходай сакласын...

Көчле шәхесләр әсәр китерергә вәгъдә итсә, А. Гомәр журналны производствога төшермичә тора. Автор, гадәттә, соңга калып китергәнлектән, журнал берәр айга тоткарлана. Мин монда эшли башлаганнан соң озак та үтмәстән, журналга язылу кампаниясенә багышланган җыелышта чыгыш ясап: «Журнал әсәрне көтеп ятарга тиеш түгел, ә әсәр чират көтәргә тиеш»,— дип, редакторга тел тидерергә мәҗбүр булдым.

Җыелышны алып барган М. Әмирнең:

— Монысы кечкенә мәсьәлә,— дигән репликасына:

— Кечкенә, ләкин укучыларда зур ризасызлык тудыра,— дип җавап кайтардым.

Редакторның хәтере калды, мөнәсәбәт кырыслана төште. Тора-бара бу кытыршылык нинди рәвешкә керер иде, әйтү кыен. Әмма тормыш аны үзенчә хәл итте. Язучыларның шул чакка туры килгән съездында А. Гомәр идарә составына узмаганлыктан, редакторлыктан алынды. Җаваплы редактор итеп, яшь язучы Газиз Мөхәммәтшин куелды. Аның белән эшләү җиңел һәм, әйтер идем, хәтта күңелле иде.

Съездан соң булган беренче зур җыелышка өлкә комитеты секретаре М. З. Тутаев килде. Дөнья вакыйгалары хакында сөйләгәннән соң, Язучылар союзындагы хәлләргә күчкәч, журналга карата да кайбер теләкләрен белдереп:

— «Совет әдәбияты» журналында хәзер бик әйбәт кешеләр эшли. Яңа редакторга, алар белән бергәләп, эшне әйбәт итеп оештырасы гына кала,— диде.

Янымда утырган язучылар, шул җөмләдән, А. Расих, бу сүзләрнең кем адресына әйтелгәнен аңлап, минем беләкне кысса, ераграк утырганнар баш кагып елмаештылар. Өлкә комитетының ышаныч белдерүе ул чакта зур әһәмияткә ия иде әле. Шулай да, дөресен әйтим, бу ышанычны аклый алдым, дип булмый шул.

Әйткәнемчә, Газиз белән көйле генә эшләп киттек. Нәтиҗә нинди булды дигәндә, алары — чыгарылган журналлар. Теләгән кеше аларга карап, бәя бирә ала.

Газиз белән икәүләп, «Совет әдәбияты» дигән исемнән баш тартып, аны «Казан утлары» исеме белән чыгара башладык. Журналның сыйфаты, тәэсир куәсе дә үсә төште дип расларга җөрьәт итәм. Тиражның күтәрелә баруы шуның күрсәткече булды, дип уйлыйм. Шул ук вакытта, А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», Ә. Еникинең «Рәшә» повестлары кебек гадәти булмаган әсәрләр чыккач, югарыдан безгә шикләнебрәк карый башладылар. Җитмәсә, аларга минем «Сез аңларсыз мине» дигән поэмам да өстәлде.

Поэманы укучы кабул итте. Шигъри әсәрләргә хас булмаганча, укучылардан күп хатлар килде. Язучыларның да күпчелек өлеше аны таныды. Ләкин сәяси җәһәттән әсәр идарә җитәкчелеген пошаманга төшерде. Журнал чыкканның икенче көнендә үк С. Хәким М. Әмир бүлмәсеннән:

— Абзыйларның мыегы тырпайган,— дигән хәбәр алып керде.

Абзыйларны тыңлыйм. Ул чакта тормышны гел мактап, партияне зурлап кына язулар канга сеңгән бит. Традиция әле үз көчендә. Бу әсәрдә исә, яшь автор бөтенләй киресенчә яза:

> Шундыйларны беләм: алар хыялында
> Махсус машиналар,
> Больницалар,
> Ашханәләр, аерым дачалар
> Һәм башкалар.
> Тик үзләре керә алган
> Махсус ишекләрне
> Ничек алар горур ачалар!
> Алар — миңа дошман!..

Партократия диктатурасы тулы куәтендә булган ул елларда аның мәгърур чиновникларына шулай ташланып кара син!

Мондый юлларның язылуы, ә бигрәк тә басылып чыгуы гайре дә табигый хәл иде, әлбәттә. Әгәр редакциядә үзем эшләмәсәм, чыгасы да булмагандыр.

Югары оешмаларга гына түгел, җитмәсә, аерым шәхесләргә дә ошамаслык юллар бар иде:

Чагалмады мине һичбер елан,
Кайда гына ләкин булсам да.
Үзем белгән бер хам Саматов та,
Төзек җөмлә төзи белмәс «шагыйрь»—
Укучысыз «даһи»
Саламторхан да.
Башкасы да...

Коридорларда кызык итеп сөйләнелгән бу юллардан соңрак баш тарттым.

Беренчедән, дөрес үк түгел иде, дияргә туры килә. Чактылар, ничек кенә! Һәм бер генә мәртәбә дә түгел, кабат-кабат, гомер буе!

Икенчедән, И. Гази әйткәнчә, «казларны котыртмау хәерлерәк» буласы булган. Хискә артыграк бирелүдән котылып булмый шул. Монысын да гомер буе дияргә мәҗбүрмен. Ходай үзе шулай яраткач, нишли аласың соң! Аннан котылу өчен лирик булмаска кирәктер...

Нәкъ көтелгәнчә, ел йомгакларында тиешле кешеләр тиешле сүзләрен әйттеләр. Әмма гаҗәпләнмәдем, артык бирешмәдем, дия алам. Укучылардан да: «Бирешмә, ул кешеләрнең акылдан язып барганнарын онытма!»,— дигән хатлар килүе дә күтәрелеп бәрелмәскә ярдәм итте бугай. Әйе, хаклыгымны тою хисе кимемәде. Шушы поэмадан башланган юнәлеш борылмаларсыз алгы елларда да дәвам итте.

Г. Мөхәммәтшинның әйтүенә караганда, Тутаев аңа: «Поэманы басмаска кирәк булган»,— дип искәрткән. Бу — өлкә комитетының миңа карашы үзгәрде, дигән сүз иде. Тиешле кешеләр моны тиз сизәчәкләр дә, җай чыкса-чыкмаса, мине чукырга, шул ысул белән батырлык күрсәтергә, ә иң мөһиме, үзләрен өстенрәк күрсәтергә мөмкинлек алачаклар.

Аңлаучылардан «аңламаучылар» күбрәк. Бигрәк тә — китап нәшрияты... Әсәрне чыгару хакында сүз кузгаткач, кара коелдылар. Якын да китермиләр. Нишләргә белми йөргән көннәрнең берсендә миңа Сибгат ага Хәким: «Әсәрне сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп, Мәскәүгә җибәрергә кирәк»,— дип, киңәш бирде. Әнвәр Давыдов подстрочник ясагач, шулай эшләдем дә. «Советский писатель» нәшриятына — илнең дәрәҗәле нәшриятына җибәрдем. Озак үк көттермичә, җавап та килде. Үз адресыма гомер буе ишетмәгән мактау сүзләре!

Ул чакта ил күләмендә популяр булган шагыйрә — Аделина Адалис: «Подстрочники Баянова выгодно отличаются от многих других, предлагаемых национальными поэтами...»— дигән, һәм шул рухта дәвам иткән: «Речь его прямодушно-бесстрашна и правдива... Он пишет о чувстве чести, о верности, о любви к Родине, и читатель ему верит. «Вы поймете меня»— это поэтическая исповедь».

Икенче рецензент Анисим Кронгауз: «Это заметное явление не только для татарской, но и для всей многонациональной лирической поэзии»,— дигән.

Нәшриятның ул чакта татар поэзиясен яхшы белгән редакторы Николай Сидоренко шушы фикерләр белән килешеп, әсәрне рус укучысына җиткерү өчен һөнәр осталыгы гына җитмәячәген, ә югары тойгыларга ия тәрҗемәче кирәк булачагы хакында әйткән иде.

Бу хәл 1965 елның җәендә, ягъни, поэма басылганнан соң бер елдан артык вакыт узгач булды. Китап үзе 1968 елда басылып чыкты.

Поэманың Мәскәүдә ничек кабул ителүе ишетелә башлагач, аны аңлаучылар күбәя төште, әлбәттә. Н. С. Хрущевның властьтан китүе дә

бераз җиңеллек китермәде түгел. Чөнки әсәрдәге ятим гаиләне талап качкан «печәнче ир»не кайберәүләр шул кешегә ишарә дип тә кабул иткәннәр иде. Шулай да Татарстан китап нәшриятына тапшырылган җыентыкны поэма исеме белән атарга мөмкин булмады. Өлкә комитеты аны тематик планнан сызмасын өчен үзенә күрә конспирациягә барырга, җыентыкны «Мәңге зәңгәр күгебез» дип, яктыртырга туры килде. Нәшриятның ул чактагы баш редакторы Х. Гобәйдуллинның корыч ихтыяры текст эченә дә яктылыкны шактый өстәргә мәҗбүр итте. Көпшәкләнгән хәлдә булса да, чыгарырга риза булмый хәлең юк. «Советка каршы» әсәр авторы данын күтәреп йөрисе килми бит. Әсәр басылу әз булса да җиңеллек китерергә тиеш иде.

Әмма язучылар арасында бераз сулыш иркенәя төшсә дә, хәлләр җайлана ук алмады шул. Мәскәүдә «Вы поймете меня» дигән исем белән китапның 1968 елда гына чыгуы (кульязманың законлы хәрәкәте шулай сузыла бит) һәм аңа чаклы кайбер бүтән сәбәпләр аркасында, бәйләнүләр дәвам итте. Моның өчен җайны, билгеле инде, үзем дә җитәрлек кадәр бирә килдем.

* * *

**1965** елның май санында, тышлыкның икенче битендә, башка бер сүз дә өстәлмичә, бармак зурлыгы хәрефләр белән белдерү басып чыгардык:

**«Хөрмәтле иптәшләр!**

**1965 елның июнь аеннан «Совет әдәбияты» журналы «Казан утлары» исеме белән чыга башлаячак...**

**Редакция».**

Белдерү язылганчы ниләр генә булмаган бит әле. Исем алмаштыру идеясе әүвәл Газиз белән минем башта туган. Аннары Язучылар союзы идарәсе рәисе М. Әмир белән ничәмә кабат сөйләшенгән. Эш КПСС өлкә комитеты каршында куелган. Аннары КПСС Үзәк комитетының матбугат бүлегенә барып җителгән һәм, карар көтеп, берме, икеме ел вакыт узган.

Исем үзе дә күктән төшмәде. Бишме, алтымы вариант тәкъдим иттек. Исемнәрне үз кулым белән теркәп, үз кулым белән Союз идарәсе диварына элеп куйдым. Язучыларга шундый үтенеч язылган иде: кем кайсы исемне кабул итсә, плюс билгесе куйсын. Үзенә күрә — конкурс. Анда күпчелек билгеләрне «Казан утлары» исеме алды.

Шунысы сәеррәк иде. «Казан утлары» дип чыгарыла башлагач, журналның абруе кинәт күтәрелеп, аңа игътибар көчәеп китте. Аңа беренче булып кем кул куярга лаеклы булуы хакында идарә утырышында кайнар бәхәсләр купты. Х. Туфан тәкъдиме белән, журналның алтынчы санына С. Хәким кул куярга тиеш булды. Җиденче санга, С. Хәким риза булмаганлыктан, кул кую миңа туры килде.

Бөтен булганы — шушы. Ләкин язучы М. Мәһдиев башта үзенең «Казан утлары» журналында чыккан истәлекләрендә, аннары Татарстан радиосы аша, журналның тарихы турында сөйләп: «Баш мөхәррир булып килгәч, Рафаэль Мостафин үз эшен «Совет әдәбияты» журналының исемен алмаштырудан башлады»,— дигән фикер әйтте. М. Мәһдиев язучы гына түгел, галим дә бит әле. Аның фикерләренә башкаларның ышануы ихтимал. Чынлыкта шулай булды да. Р. Мостафин юбилее уңаеннан, М. Мәһдиевнең бу фикерен «Шәһри Казан» газетасы, кабатлап, күпсанлы укучыларына таратты.

Күрәсез ки, М. Мәһдиев теләсә дә, Р. Мостафин «үз эшен журналның исемен алмаштырудан» башлый алмады. Ышанмаган кеше журналның төпләмәсен алып карасын.

Әдәбияттагы «көчле шәхесләрнең» һәм өлкә комитетының журналга бәйләнүе артык та активлашып киткәнлектән, Г. Мөхәммәтшин эштән китәргә мәҗбүр булгач, идарә җитәкчелеге тынычлык урнашыр дип өметләнгән иде. Ләкин киресенчә, хәлләр соң дәрәҗәдә кискенләште генә. Бу чакта өлкә комитетының идеология секретаре булып М. Ф. Вәлиев, культура бүлеге мөдире булып М. М. Мусин эшли башлаган иде. Язучылар союзы партоешмасы секретарьлыгына Г. Гобәй дигән балалар язучысы куелды. Сайлау дигәне формаль рәвештә генә була иде бит, шуңа күрә «куелды» диюем.

Өчесе дә — «яңа себерке яхшы себерә» дигән мәкальне тулысынча акладылар.

Г. Гобәй журналга атаклы «Коръән серләре»н китергән чак. Дингә каршы сугышчан әсәр. Бернинди тикшерүсез, бәхәсләрсез нәфис сәнгать әсәре буларак басыла башлады. Җаваплы секретарь булган килеш, миңа моны журналга салынгач, корректура хәлендә генә укырга мөмкин булды. Укып карыйм, нәфислек сизелми. Гомер буе ата-баба табынган Аллага һәм Мөхәммәт пәйгамбәргә каршы памфлет...

Үземне артык динле кеше дия алмасам да, минем дә ачуны кузгатырлык әсәр булып чыкты бу. Иң принципиаль ягы — сәнгатьчә язылган әсәр түгел. Күп дигәндә, публицистика бүлеге аша чыгарга тиешле.

Шундый нәтиҗәгә килгәнлектән, Р. Мостафин иҗади ялга киткәч, мин ул язманы чынлап та публицистика бүлегенә күчереп бастырдым. Хәрефләр кечерәю белән бергә, авторның гонорары да кимеде, дигән сүз. Ул моны гафу итә алмады. Әйе, «сиздә эшне Шүрәле дә, кычкыра да бакыра». Һәм максатына да ирешә. Р. Мостафин ялдан кайту белән, саннан саннарга сузылучы роман хәтле памфлетны яңадан нәфис әсәрләр бүлегенә — журналның беренче битләренә күчереп куйды.

Шуның белән эш беткәндәй тоелса да, каршылык эчкә яшерелгән булып чыкты.

Давылның чыны «Яшьлегемне эзлим» повесты язылгач купты.

Әсәрне редакциягә 1966 елның көзендә тапшырдым. Җаваплы редактор Р. Мостафин үзенең фикерен бик ачык итеп: «Әсәр протест уята»,— диде. Мәсьәләне бер сүз белән хәл итсә дә, хакы булгандыр. Ләкин ул редколлегиягә куярга булды. Махсус җыелган редколлегия утырышында повестьны ике кеше — Сибгат Хәким белән Әмирхан Еники генә яклап чыкты. Әмирхан аганың бер җөмләсе хәтердә саклана: «Повесть — көйрәп торган утлы күмер, тотып та булмый, ташлап та булмый».

Күпчелек каршы булса да, авторга әсәрне яңадан карап чыгарга, ягъни «утлы кисәүләрне» сүндерә төшәргә тәкъдим ителде. Мин исә, саламга тотынырга мәҗбүр. Мөмкин кадәр «төзәткәннән» соң, Рафаэльгә тапшырып, үзем иҗат йортына киттем. Яңа әсәрләр — шигырьләр язам, имеш. Кая ул! Артымнан ук Рафаэльнең хаты куып җитте: «Син киттең дә котылдың, ә безнең башка бәла калдырдың. Мин повестьның башын яңадан укып чыктым. Син бит аңа бик аз каләм тәрткәнсең. Һәрхәлдә, повестьның бөтен рухы-юнәлеше искечә калган».

Сызыласы кайбер җөмләләр һәм абзацлар китерелгән, аннары иң принципиаль каршылык бәян ителгән: «Әмма иң җитди момент — милиционер Шәйми турында. Ул нәкъ элеккечә язылган — син аны халыкны җәберләүче жандарм итеп күрсәтәсең. Әлбәттә, совет журналында андый карашны үткәреп булмый».

Сүз шушылай катгый булганлыктан, бер генә юл калды — повестьны өчтән бер өлешеннән «коткарырга» ризалык бирергә туры килде. Ләкин алай да үзем котыла алмаган булып чыктым.

Иҗат йортыннан кайтуыма, мине политбюро утырышы көтеп тора. Чыгыш ясаучылар әзерләнгән. Кемгәдер гонорар күбрәк, кемгәдер кимрәк язылган. Җаваплы секретарь — гаепле, ә җаваплы редактор — җавапсыз.

Повесть басылу ихтималын беләләр. Мин үзем шунда эшләгән өчен генә басыла икән. Ник монда бирдең?— Әйтерсең, башка журнал бар...

Редакциядән язга чыккач, май аенда китәргә җыена идем. Ашыга төшәргә, 1967 елның гыйнвар аенда китәргә туры килде.

Утырыштан алынган тәэссорат «Шәрә башлар» дигән шигырьгә әверелде:

Шәрә башлар мәҗлесендә булдым,
Эшләр, әйтим, булды бик җайсыз.
Бер юньсезен чәчсез дигән идем,
Ул башсыз ук икән, имансыз.
Баш урнына хәзрәтләрдән чәлгән
Буш комганны йөртә икән бит...

Ул көннәрдә җыелышларда: «Г. Гобәйнең «Коръән серләре» ачылып бетте»,— дигән сүзләр ишетелеп торды. Ләкин миңа карата булганнары яшертен килеш калды. Давыл тынарга чамаламый иде әле. Редакциянең үзендә дә.

Утызынчы елларда җидегәнчелек җиле тиеп төчкергән агайларның берсе, сәяси сизгерлек күрсәтергә җай күреп, редакторга: «Әгәр ул әсәрне бастырсаң, редколлегиядән чыгам!»,— дип, ультиматум игълан иткән икән. Яңадан редколлегия җыярга мәҗбүр булганнар. Шунда гына, ниһаять, җаваплылыкны үз өстенә алучы табылган. Ибраһим ага Гази: «Мин Советка каршы бер җөмлә дә уздырмам, ышансагыз, бирегез повестьны үземә»,— дигән. Телефон аша Рафаэль миңа шуны хәбәр итә.

— Ибраһим Гɀзига ышанасыңмы?

— Ышанам.

Һәм акланды ышаныч. Укып чыккан да Ибраһим ага, «Советка каршы» бер җөмлә дә тапмыйча, хәтта кыскартмыйча чыгарырга мөмкин дип, кульязманы Рафаэльгә кире кайтарган. Үземне күргәч, сөенче ала:

— Повестьны мактаячаклар!— ди.

— Юк, Ибраһим ага, тиргәячәкләр,— дим мин.

Өлкән иптәшнең гаҗәпләнеп караганы хәтердә.

Кызганыч ки, повесть басылып чыкканнан соң, тиз арада ачыкланганча, артыгы белән хаклы булып чыктым.

1967 елның көзендә — мин өйдә юк чакта — башлангыч партия оешмасы җыелышы. Бюро секретаре Г. Гобәй повестьны сәяси зарарлы дип игълан иткән. Өлкә комитеты секретаре М. В. Вәлиев шуны раслап, мөһер суккан. Һәм... дәвам итте, ягъни, купты бая без әйткән давыл. Өр-яңа көч белән!

Бер яктан, үземә һәм редакциягә кочак-кочак хатлар килә. Икенче яктан, өлкә комитетының басымы көчәя. Тиешле кабинетта баш редакторга эшлекле күрсәтмә: әсәрне дөньяга чыгарган редакция аны үзе үк тар-мар итәргә тиеш. Шуны ишеткәч, Вәлиев исеменә хат җибәрәм. Моның өчен (сер чишкән өчен) баш редакторның башын шактый катырдылар, ул төрле мыскыллауларга дучар ителде. Җыелышларның берсендә Вәлиев Рафаэльне «слюнтяй» дип мыскыллады. БМО өстәлен туфли табаны белән кыйнаган җитәкче үрнәгендә, партиянең башка әһелләренә болай гына кылану ул инде бик тә табигый хәлгә әйләнгән иде. Минем өчен шунысы җайсызрак булды, чынында бит, ак эт бәласе — кара эткә. Мәгәр минем «благоразумиегә чакырып» язган хатым азмы-күпме тәэсир итте, ахрысы. Тар-мар итү бурычы «Казан утлары» өстеннән алынып, «Социалистик Татарстан»га тапшырылган иде. Газетаның тулы бер битен тутырган дилбегә буе мәкаләне күпләр анонимка дип атадылар. Әмма янә шунысы кызганыч, минем аркада тагын башка иптәшләргә дә өлеш мул тигән иде. Бер генә кешегә сәхифә багышлау вакланну төсле тоелгандыр, күрәсең.

Журналда кыскартып чыгарылган әсәрне тулы килеш чыгару өмете белән Татарстан китап нәшриятына биргәч, ташка басылган тематик план өлкә комитеты бюросында тикшерелгән вакытта, минем фамилия кызыл кара белән сызылган иде. Нәшриятның ул чактагы баш редакторы Х. Гобәйдуллин (Гобәйләрдән бәхетем зур, ә?) астыртын гамәлгә рәсми төс бирер өчен редакция советын җыймыш. Анда Х. Госман, Г. Минский, М. Әмир (беркетмә күчермәсеннән күренгәнчә) үзләренә тапшырылган бурычны «намус белән» үтәгәннәр иде.

* * *

Ул еллар КПСС өлкә комитеты коммунистларның сәяси белемен күтәрү буенча, әдәбият-сәнгать әһелләре өчен фәнни яки хуҗалык мәсьәләләренә багышлап, аена бер тапкыр семинар үткәрә иде. Чираттагы семинар Кама буе төзелешләре һәм нефть районнарына сәяхәт рәвешендә оештырылды. Ракетага утырып, юлга чыктык.

Егерме-утыз язучы, утыргычларда тезелеп, тыныч кына барабыз. Юлның яртысы тирәсе узылгандыр, берзаман тыныч кына утырган иптәшләр дәррәү аягүрә басмасынмы. Күтәрелеп карасам, өске каттан бик ыспай гына киенгән — эшләпә һәм затлы плащтан, кырык биш-илле яшьләр тирәсендәге, аксыл зәңгәр чырайлы, уртача зурлыктагы зәңгәр күзле бер кеше төшкән дә, ишек төбендәрәк тукталган. Олы-олы, чал чәчле агайлар, мөмкин кадәр шат елмаешып, буйларын бөгә-сындыра, аның белән исәнләшергә урыннарыннан куптылар. Мин ул кешенең кем икәнен белмим әле. Танымыйм. Танысам да, әгәр ихтирам итәрлек түгел дип исәпләсәм, карар идем әле. Шуңа күрә, урынымнан кузгалмадым. Зур залда үз урынында калган бердәнбер кешене зәңгәр үткен күзләр тиз күреп алдылар, әлбәттә. Күреп алдылар да, гаҗәпләнеп, текәлеп карадылар. Шулай да, мин ул карашка чыдагач, кеше читкә борылырга тиеш булды һәм, шаян сүзләр әйтә-әйтә, агайлар белән гәп кора башлады. Матур гына әңгәмәдән соң, яңадан үз биеклегенә менеп китте. Залда урыннарга утырган агайларның яңадан башланган тыныч әңгәмәләреннән: Мөдәррис Мусинович, Мөдәррис Мусинович, дип тәкрарлавыннан мин теге кешенең кем икәнлеген төшендем. Мусин белән беренче танышуым шулай булды. Беренче һәм ныклы танышуым, дип әйтим. Аннан соңгы очрашулар байтак булса да, ул аларын, әлбәттә, оныткандыр, ә минә беренчесен хәтерендә саклавына иманым камил.

Шулай, ракета су өстеннән очуын дәвам итте.

Беренче тукталыш — Красные ключи пристане. Яр буенда — пионерлар. Район җитәкчеләре. Ипи-тоз. Фанфаралар. Кама өсте шулар шаушуыннан чуарланган төсле. Бөтен гүзәл киңлек быргылар, трубалар тавышы, пионерлар котлаган сүзләр, декламацияләр һәм җырлар белән күмелде. Хәзер онытылган күп сүзләр һәм авазлар арасыннан: «Не пищать, не пищать!»— дигәннәре колак төбендә әле дә яңгырап торадыр кебек. Бу сүзләр миңа әдәбият-сәнгать әһелләренә күрсәтмә һәм кисәтү буларак кычкырыладыр шикелле тоелды. Шунысы гына сәеррәк, нишләп өле алар безгә тантаналы рәвештә пионерлар тарафыннан җиткереләләр?

Моны ишеткәннән соң, тормышка ризасызлык сиздереп кара син!

Район һәм предприятие җитәкчеләре белән көндезге рәсми сөйләшүләрдән соң, кичен — тантаналы очрашу. Шигырьләр укыйбыз. Мин «Дөньяга ялвару» һәм «Сарбайларны яклап» дигән шигырьләр укыдым.

А, Дөнья!..  
...Күрсәтмә син купшы парад, тантаналар.  
Батырларны зурламаган юха фанфаралар  
Тондырмасын колагымны —  
Сакла тиле шау-шулардан.

Шигырьнең икенчесе болай тәгәлләнә:

Этләр өрә, этләр талый, этләр тешли —
Ихтимал ки, дөрес эшли.

«Ясалма юлдашлар» гыйбарәсе шактый кискен ишетелсә дә, юлдашларымның күбесенә шигырьләр ошады. Кул кысучылар булды. Фольклорчы галим Илбарис Надиров сәхнәгә менеп:

— Беренче шигырең әйбәт, тирән, заманча,— дип бәя бирде һәм: — Икенчесе артык турыдан әйтелде, кемнәргәдер туп-туры килеп бәрелде,— дип өстәде.

Мин моны объектив фикер дип кабул иттем. Ул чакта И. Надировны миңа каршы агитацияләп өлгермәгән булганнардыр инде. Соңрак ул миңа карата шактый суынды.

Идарә секретаре Г. Ахунов: «Союз члены булып каласың килсә, икенче тапкыр бу шигырьләрне укыма»,— дип кичтән үк әйтсә, М. Мусин үзенең катгый күрсәтмәсен икенче көнне иртән җиткерде:

— Сезнең басылып чыккан әйбәтрәк шигырьләрегез бар, шуларны укыгыз,— дип боерды.

Аңа да, Гарифка да әлеге шигырьләрдә сәяси хата юклыгын ачык әйткәнлектән, икенче көнне миңа сүз бирмәделәр. Өченче көнне исә, шигырь уку гомумән тукталды. Сәбәп аңлашылса кирәк, мин «пищать» иткән булып чыктым.

«Яшьлегемне эзлим» повестен бастыру юлында ике дистә ел буе йөрешли, КПСС өлкә комитетында М. Мусин белән танышлык тирәнәя барып, булган әңгәмәләрдә, сәяси катылык белән бергә, шәхси мотивлар да сизелә килде дисәм, дөреслеккә хилафлык китермәм, дип беләм.

Шәрехләргә бирелмәстән, бер генә эпизод белән чикләнәм. Очрашуларның берсендә иптәш Мусин, үз көченә нык ышану һәм шуның белән артык рухлану аркасында, минем өскә сәяси гаепләрне шулкадәр күп өйде ки, хәтергә утызынчы еллар килеп, мин, хәтта елмаерга тырышып, аның матур зәңгәр күзләренә бактым:

— Сезнең бу сүзләрегез дөрес булса, мине бит атарга кирәк,— дим.

Аның исә күзләреннән бозлы, күк очкыннар гына сирпелде:

— Хәзергә атмыйбыз!

Шаярырга, әйе, ярамый иде шул. Тарихи шартлар, социаль психология, шәхси мәнфәгатьләр, мөмкинлекләр... азмыни сәбәпләр.

Ул чорда дөньяда «диссидент» дигән куркыныч сүз ишетелә башлаган иде. Аның эчке мәгънәсен һәм авырлыгын миңа үз җилкәмдә күпмедер тоярга, үз җилкәм белән күтәрергә туры килде. Ә кемнәр өчендер ул кызык сүз генә иде.

Ярлык булып тагылган ышанычсызлык тамгасыннан котылырга тырышу фарыз лабаса. Ничек? Нишләргә?

«Сез аңларсыз мине» поэмасы белән салынган таныш юлдан китәргә кирәк булды. Повестьның юлын-юлга ясалган тәрҗемәсен «Советский писатель» нәшриятына җибәрдем. Тагын иң югары дәрәҗәдәге бәяләр.

Минем өчен иң кызыклы фикерләрнең берсе: «К достоинствам книги надо отнести так же то, что характеры героя и всех действующих лиц даны в развитии»,— дигән сүзләр. Безнең татар тәнкыйтендә әсәрнең бу сыйфатына бөтенләй дә игътибар итү юк иде бит.

Нәшрият редакторы биргән гомуми бәядә: «Писателю чуждо упрощенчество, однобокое представление о людях, и это мы хорошо видим на примере героев повести»,— диелгән. Үзебезнең тәнкыйтьтән авыз тутырып әйтелгән мондый сүзләрне әле булса ишеткәнем юк, диясем килә. Менә бит, таныш булмаган кешеләр ничек яза да, мине белгән кешеләр сүзне ничек теш аркылы гына чыгара. Шушыны аңлау миңа азмы-күпме тынычлык китерә, үз-үземә, үз көчемә ышаныч тудыра иде.

Повесть 1969 ел планына тәкъдим ителеп, ул 1970 елда чыгарга тиеш иде. Ләкин 1971 елда гына дөнья күрде.

Сәбәбе болай. Башта тәрҗемәгә Вл. Солоухинга бирмәкчеләр иде. Ләкин, кызганычка, нәшриятта партбюро секретаре булып эшләгән, шигърияткә катнашы булмаган тәрҗемәче, әсәрне бик ошатып, тәрҗемәгә үзе алынмакчы булган. Мин ризалашмыйча торган арада, әсәр икенче ел планына күчерелгән. Риза булмасам, өченче елга да калдырылуы ихтимал булганга, чигенергә мәҗбүрмен. Чыкмавына караганда, сыйфаты кимебрәк булса да чыгуы мөһим әле минем өчен. Үземне сәяси каһәрдән коткарырга тиешмен ләбаса...

1971 елда (май аенда ук) кулга керү белән аны КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусинга үз кулым белән «бүләк» иттем. Аның ничек иреннәрен кысып елмаюын күз алдына китерү кыен түгелдер...

Кабинетында булмавы сәбәпле, М. Ф. Вәлиевкә дигәнен канцеляриядә калдырдым.

Шуннан соң озак та үтмичә, М. Ф. Вәлиев мине С. Хәким аша үз бүлмәсенә чакырды. Дусларча сөйләштек. Укыган. Теге чакта алама сүзләрен доносларга таянып кына тәкрарлаган булгандыр инде. Элеккесе белән чагыштырганда, хәзерге фикерләре — җир белән күк арасы. Татарча чыгарырга вакыт җиткәнен әйткәч, минем алда ук нәшрият директорына — Г. К. Камалиевка шалтыратып: «Өлкә комитетында «Яшьлегемне эзлим» повестына карата булган тискәре фикер юк, әйе, бетә (снимается). Пожалуста, чыгарыгыз».— диде.

Директорга ашыгам. Ачык елмая:

— Булды, сөйләштек, хәл ителде.

Мәгәр өч-дүрт көннән соң керсәм, чырае тагын дөм кара. Уйлыйм инде: Мөҗәһит Фәтхиевич минем алда бер төрле, ә соңыннан икенче төрле әйткән икән. Шул хакта кечкенә хат язып җибәргәч Вәлиев өйгә шалтырата:

— Мин нишләп ике төрле сөйләшим ди? Әйтелгәнчә, үз фикеремдә калам.

— Камалиев тагын киресен сөйли бит. Бүлек каршы, ди.

— Син хәзер Мусинга кер, алайса.

Мусин, гадәтенчә, кырыс.

— Нәрсә, Вәлиев басарга ук дип әйтмәгәндер ич?

— Басарга ук диде. Ышанмасагыз, үзегез сорагыз.

Иреннәрнең кысылып елмайгандай итүе. Таныш бит?

Мин нәшриятка шалтыратуын үтенәм. Ул директорга түгел, ни өчендер баш редакторга, Марс Шабаевка шалтырата:

— Әхсән Баянның «Яшьлегемне эзлим» повестена безнең каршылык юк. Ләкин тиешенчә әйбәтләп редакцияләп чыгарыгыз.

Әйбәтләп дигәне шул булды: повесть табак ярымга кыскартылып, 1975 елда, ягъни ун еллык газаплардан соң гына, ниһаять, татарча да дөнья күрү бәхетенә иреште. Ун ел тартыш, бәхәс, көрәшләр белән узды, дигән сүз. Тынычлык төшкә дә керми иде, ичмасам.

Рухи кысанлыкның төннек-җиллекләре 1969 елда «Һәйкәл» драмасы сәхнәгә куелгач, 1971 елда «Ут һәм Су» романы басылгач ачылып куелгаласа да, дөресен әйтим, артык иркенәеп китәргә барыбер мөмкинлек тумады. М. Мусинның бәйләнүе (каныгуы, диясе килә) кимемәде.

«Һәйкәл» спектаклен Әлмәт шәһәрендә күрсәткән чакта, киң җәмәгатьчелек катнашында әңгәмә үткәрелә. Тамашачы алдында обком кешеләре дә яман сүз әйтергә кыймаган, күрәсең. Мусин да уңай сүз әйтергә тиеш тапкан. Шуңа ышанган инструктор ханым хәтта: «Дөреслек барыбер җинә!»— дип тә җибәргән икән. Әлмәттән кайткач, әңгәмәдә катнашкан башка язучылар, шул исәптән Г. Ахунов, мине котлап, әйтелгән җылы сүзләрне үземә кайтарып җиткерделәр. Рәхмәт аларга.

Әмма күп тә үтмәстән, газетада хәбәр: «Һәйкәл» спектакле Г. Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим ителгән. Режиссер исеме бар, автор исеме төшеп калган. Ни өчен? М. Мусин әмере белән. Машинистка хатасы түгел...

Әле кайчан гына әсәрне мактаган иптәшләр шуннан соң киресен тукылдый башламасыннармы? Идарәдә бухгалтер булып эшләгән Флера ханымның: «Бар бит кешеләр, исләрең китмәле!»— дип аһ оруы хәтердә калган. Чибәр ханым, кешеләрне бик үк белеп бетермәгән булгансың шул әле син!

Мине «аклый» язган «Һәйкәл», ярдәм иткән «Ут һәм Су» романы гидростанция төзелеше күренешләре белән кызыксынудан башланса да, мине Камаз куып җитеп, роман үзем уйламаганча, көтмәгәнчәрәк яңгыраш алды. Өлкә комитеты шуннан соң төрле конференцияләргә, актив җыелышларына чакыра башлады. Бу хәл яңачарак мөнәсәбәт дигәнне аңлата иде. Әсәрне ялындырмыйча диярлек китап итеп тә чыгардылар. Шәхси яктан караганда, монын әһәмияте мина профессионал буларак нужа күрмичә яшәргә мөмкинлек бирүендә иде. Кайчакларда, кайбер язучыларга хәтта әҗәткә акча биреп торырга да туры килгәләде. Шунын шагыйрь Марс Шабаевка бәйле бер мисалы үзем өчен шактый кызыклы тоела.

Аңа, дача салганда, ашыгыч рәвештә акча кирәк булган икән. Элеккеге бәя белән ике йөз сум акча биреп тордым. Тиз арада кайтарды. Зур ярдәм дә түгелдер. Кешеләр арасында андый гына ярдәмләшү бик тә гади нәрсә бит. Әмма шушы кечкенә нәрсәне оныта алмадым. Сәбәбе дә зур түгел, югыйсә.

«Тау ягы повесте» журналда басылгач, (1974 ел), кульязманы нәшриятта баш редактор булган М. Шабаевка укырга бирергә тиеш таптым. Ялындырмый гына укыды, һәм бик уңай, матур фикерләренә өстәп:

— Кульязманы нәшриятка китер. Тешем-тырнагым белән яклаячакмын!— диде.

Күпмедер вакыттан соң китердем. Кульязмага сәяси яктан бик тә сак тәнкыйтьче Хәсән ага Хәйри уңай рецензия язган. Инде баш редактор теше-тырнагы белән яклап, әлбәттә, планга кертәчәк бит. Ышаныч — зур, йөз процентлы. Шундый зур ышаныч белән яшәп, планнар төзелеп беткән бер мәлдә нәшриятка килсәм, исемлектә мин юк. Нишләп?

М. Шабаев күзен дә йоммый. Кәгазьләр күрсәтә. Нәшрияттан кемнәрнең күпме гонорар алганлыгы хакында бухгалтериядән мәгълүмат алган икән.

— Иң күп гонорар алучыларның берсе — син!— ди баш редактор.

— Булса соң?

— Түзеп тора аласың, дигән сүз.

— Соң бит... гонорардан үзең дә баш тартмыйсың.

— Минем кешеләргә бурычка биреп торырлык акчам юк. Ә менә син биреп тора аласың.

Кем әйткәндәй, бер кызардым, бер агардым. «Тешләрең дә, тырнакларың да коелдымыни, нишләп якламыйсың?»— диясем килде. Телем әйләнмәде. Шаккаттым да калдым. Нишләргә белмим, көләргәме, еларгамы? Ул чакта көләсе килмәсә дә, хәзер елмаеп искә алам. Әҗәткә биреп торган өчен рәхмәт әйтү ысулы буларак, шактый мәгънәле сабак бит! Ә?

Нәтиҗәсе шул булды. «Тау ягы повесте» биш елдан соң гына дөнья күрә алды. М. Шабаев хаклы да булып чыкты — түзеп тора алдым, интегүләрсез генә профессионал язучы булып яши бирдем.

Унбер еллык иҗади тормыш гомернең иң матур һәм нәтиҗәле чоры булды, дип саныйм. «Яшен исе», «Ике аккош», «Елларга ышаныгыз», «Сез аңларсыз мине», «Җәй — яшел кош», «Елларга сәяхәт» дигән шигырь китаплары, «Ут һәм Су» романы, «Язмыштан узмыш», «Тау ягы повесте» исемле проза җыентыклары шул фикерне раслый, дип беләм.

Шушы төштә кечкенә генә чигенеш ясап, язган вакытта һәр әсәрнең үзенә генә хас халәт кичергәнем хакында да ике-өч сүз әйтим әле.

Авылдан китәбез дә, аны сагынып яшибез бит. «Яшьлегемне эзлим» сагынуга түзә алмыйча язылды. Язылгач исә, күңел җиңеләеп, тынычландым дияргә була. «Тау ягы повесте»н язганда еш кына күз яшьләре комачау итсә дә, шулай ук күңел бушап, кинәт дөнья яктырып китте. «Аязучан болытлы һава» язылган чакта, ел буе диярлек тәнем кычытты. Хәтта врачлар белән киңәшергә туры килде. Ярдәм итә алмадылар. Әсәр төгәлләнгән генә иде, сырхауны әйтерсең җил очырды. Гел күтәренке хисләр кичерелгән әсәр дигәндә, «Төлке тоту кыен түгел» дигән повестьны, аерым шигырьләрне сагынып искә алам.

Киләчәктә дә шушы темпны саклау мөмкинлеге бар иде. Ләкин көннәрдән бер көнне — 1977 елның җәендә — мине КПСС өлкә комитетының культура бүлегенә чакырдылар. «Тау ягы повесте» буенча өч серияле телеспектакль куелуы минем өчен көйле тормышка нокта куелуы да булды, ахрысы. Тамашачылардан килгән бер папка хат бүләк итеп бирелгәннән соң, бер чор төгәлләнеп, катлаулы да, гыйбрәтле дә булган яңа чор башланды...

* * *

«Казан утлары» журналына баш редактор урынбасары кирәк. Ул чактагы баш редактор, авыруы сәбәпле, күп вакыт иҗат йортларында, санаторийларда була. Түгәрәкләп әйткәндә, елның яртысын читтә үткәрә. Нигездә, аның вазифаларын да башкара торган кеше таләп ителә. Җиңел генә ризалашмадым.

— Язылясы әйберләр бар. Редакциядә эшләү комачау итәчәк бит.

Мөдәррис Мусинович аптырап кала торган кеше түгел, кырт кисте:

— Әнә Нәҗип Җиһанов гомере буе ректор булып эшләде, иҗат активлыгы да кимемәде.

— Язылганнарын да күрсәтергә кирәк бит, эшләгәндә җайлырак булыр,— дип, Гариф Ахунов фикерне үзенчә үстерде.

Ни булса шул, өлкә комитеты тапшырган йомыштан баш тарту ул чакларда мөмкин булмаган хәл диярлек. Озак ялындырмыйча, ризалык бирергә мәҗбүрмен.

Иҗади активлык дигәнебез сизелерлек кимесә дә, үкенәсе килми. «Мәңгелек бәхәс» исемле фәлсәфи повестька материалны бары тик редакциядә эшләү чоры гына бирә ала иде. Үзем өчен бу әсәрнең язылуын әһәмиятле нәрсә дип исәпләгәнлектән, редакциягә бирелгән биш ел гомерне заяга узды диясем килми. «Сине очып барган чакта атып төшерделәр»,— диючеләр булса да. Аннары бит әдәбиятка хезмәт итү үзе генә дә кайбер югалтуларны исәпкә алмаска куша.

Дөрес, югалтулар шактый зур булды, иҗади якны исәпкә алмаганда да, мораль җәһәттән. Редакциядән һәр минут китәргә әзер булуыма карамастан, бу эшкә дәгъва кылучылар, минем уемны белмәгәнлектән, минем җәмәгатьчелектәге дәрәҗәмне төшерү өчен бернинди түбәнлекләрдән дә чирканмадылар. Һөҗүм төрле яклап көчәя торды. Бигрәк тә сыналган, сәяси юнәлештән. Шуларның бер мисалы.— Н. Исәнбәтнең бер мәкаләсе белән бәйләнгән иде.

Нәкый ага Исәнбәткә сиксән яшь тулу уңае белән аның хакында мәкалә яздыру редакциянең тәнкыйть бүлегенә тапшырылды. Нишләптер, яздыра алмадылар. Шуның аркасында язучының үз материалын сорарга туры килде. Авторның тарихи темага язылган мәкаләсе алынды. Редколлегия әгъзасы буларак, Н. Юзиевтән уңай рецензия килде. Бүлек редакциялэп, кул куеп кертте. Бераз бәйләнерлек җөмләләр булса да, өлкән авторга, бигрәк тә галим кешегә артык бәйләнмичә генә, мин дә

кул куеп җибәрдем. Главлиттан да узды. Бер елга якын бернинди шикшөбһә сиздерүче булмады. Бер ел чамасы вакыттан соң, редакциягә КГБ кешесе килеп керде. Журналны даими укып бара алмавын, больницада ятканда күп кенә саннарны әле генә укыганлыгын хәбәр итә ул. Ниндидер зарарлы әсәр чыккан, ахрысы. Тел төбеннән шул аңлашыла. Иллә дә атап әйтми. Мин сорамыйм. Тәки шул килеш китеп барды, җанны пошаманга салып...

Пошынып йөргән көннәрдә, өлкә комитетына чакырдылар. Нәкый Исәнбәт мәкаләсендә икән «коточкыч» нәрсәләр. Бер деталь хәзер дә хәтердә. Ишек бавы дигән сүз. Каян килеп чыккан? Илне Явыз Иван басып алгач, татар өйләрендә бернинди дә металл әйбер калдырмаганнар, чөнки аның коралга әйләнүе бар. Шуңа күрә өйләрдә тимер тотка урынына каешмы, җепме бау куйганнар. Сәяси хатамы? Хатаның да ниндие әле! Бөтен гаеп — минем өскә. Галим рецензент белән, бүлек мөдире белән уртаклашмакчы булам, кая ул! Син, баш редактор буларак кул куйгансың, син гаепле, башка беркем дә түгел. Ярый инде, мин икән, мин. Китешли М. Мусиновичның: «Артык хафаланма, обидага бирмәбез!» — дигән вәгъдәсенә карамастан, җилкәдә сәяси гаеп авырлыгын тоеп, чыгып киттем.

Берничә көннән КГБдан беркөнге иптәш шалтырата — сөйләшүнең ничек узганын сораша.

— Менә шулай инде, каты әйттеләр. Соңыннан гына Мусин йомшарта төште. Сиңа бәйләнүчеләр бар, ләкин без сине в обиду не дадим, дип куйды, дидем.

— Үзегездәге кешеләр куерта,— ди әдәпле иптәш.

Явыз Иван идеясенең бүгенге көндә патшалык итмәскә тиешлеген ул сизгән иде булса кирәк.

— Әйе шул,— дим,— мине монда көчләп үк диярлек куйганнар иде, хәзер көчләп үк диярлек чыгармакчылар.

Аңлашылмас нәрсә юк, хәл ачык. Миңа китәргә кирәк. З. Нури чираттагы ялыннан кайткач, ике айга дип отпуск алам да иҗат йортына китәм. Дубулты дигән җиргә. Күпмедер вакыттан соң М. Мәһдиев килә.

— Редакция тирәсендә әллә нинди сүзләр йөри анда, хәерле бетсен инде,— ди.

Тәгаен нинди сүзләр икәнен мин сорамыйм (чөнки чамалыйм бит), ә ул сөйләми.

Бер ай йөреп кайткач, тагын бер аен өйдә эшләгәч кенә, китү хакында гариза язып бармакчы идем редакциягә, ләкин З. Нури шалтырата:

— Югарыдан кушалар, син эшкә чык инде, соңыннан карарсың,— ди.

Эшкә чыкканның икенче көнендә үк Гарифтан үтенеч: мин аның янына барып, мөһим бер нәрсәне хәл итәргә тиешмен. Эш нәрсәдә?

— Синең редакциядән китәм дигән сүзең бар иде. Ул Мусинга барып җиткән. Мин — аның сүзен генә җиткерүче...

Шулай, 1981 елның гөрләвекле язында, шактый кызыклы һәм сәер рәвештә, редакциядән китәргә туры килде.

Аңлашылып, ачыкланып җитмәгән кайбер нюанслар һәм персонажлар кала биргәнлектән, бу чор хакында җентеклəбрәк язуны киләчәккә калдырып торырга туры килә. Алда тагын күз күрер...

Ягъни дип әйтик, яңадан профессионал язучылык эше башланды. Монысының чиге үземнең гомер озынлыгы белән билгеләнәчәктер. Ә артта калган бишъеллык мәгънәсе дүрт юлга сыя бугай:

Төшәлмәдең җиргә син хаялдан,
Каһәрләрең булды сөю сыман.
Аваз өмет иттең каберләрдән,
Көттең бозык кыздан тапсыз вөҗдан...

Һади Такташка багышланган поэмадан кайбер юллар шулай ук хәзер үземә кайта:

Беләм, беләм,
Казан урамнарын
Мин анынча сөям яратам.
Аңарга да кемдер ташлар аткан,
Кем, сөюен кушып, кар аткан.

Әмма тагын, тагын кабатлый алам, Казан Казан инде ул. «Илдә бер дус калмаса гәр, ил бөтен дошман түгел». Сөю кушып атылган кар йомгакларыннан битәр, ташлар күбрәк булса да, элегрәк язылганча: «Ялалардан, бәлаләрдән мин арып егылмадым.» Ташларның зурысы, бәләкәе бардыр. «Аерма юк, сиңа атылган». Шулай да, сукранмыйча, сызланмыйча гына шуларның кайберләрен күтәреп, сезгә дә күрсәтим әле.

1974 елда урта мәктәп дәреслекләренә өстәмә итеп, «Юлдаш» исемле җыентыкта минем «Ут һәм Су» романыннан өзек бирелгән иде. Үзләре сорагач, ничек каршы киләсең. 1975 елда «Юлдаш»ның шигъри китабына да катнашуымны сорадылар. Ялындырмыйча гына, тапшырдым, әлбәттә. Ләкин шуннан соң нәшриятның яшьләр-балалар әдәбияты бүлегенә кайбер шагыйрьләр көчле басым ясый икән: проза әсәрләре җыентыгында чыкты бит инде, монысында чыкмасын,» — диләр. Редакторлар әйтүенчә, олыгаеп барган шагыйрьләр йөри икән шулай!

1987 елда, минем русча нәшер ителгән шигырь китаплары нигезендә, яшь шагыйрь С. Малышев газетада бик әйбәт мәкалә бастырган иде. Шуның өчен ул күп кенә татар шагыйрьләреннән каты шелтә ишеткән. Икенче юлы, минем бер җыр текстын тәрҗемә итәргә тәкъдим булгач, композиторга:

— Аның дошманнары күп икән, усал кешеләр. Мин аны тәрҗемә итмим. Сиңа да аның шигырен китабыңа кертмәскә киңәш итәм,— дигән.

Тәнкыйтьчеләрне, җәмәгатьчелекне әнә шулай өйрәтә, «акылга утырта» килделәр.

Бер елны бер төркем татар язучылары минем туган районыма — Илешкә әдәби атналык оештырдылар. Кем генә бармады. Ә миңа әйтмәделәр. Авылларда йөргәндә, әдәбият турында сөйләгәндә, мине искә дә алмаганнар. Андый кеше юк. Райондашларым соңыннан, аларга бик рәнҗеп калдык, дип сөйләделәр. Бусы мине рәсми рәвештә кимсетү сәясәте. Сәбәп нәрсәдә?

Мондый ваклыкларның мәгънәсен бер зирәк язучы, яшертен мактау, читләтеп әйтелгән комплимент, дип аңлата. Берзаман, миңа артык каныгуларга игътибар итеп, бер күренекле артист: «Җимешсез агачны селкетмиләр»,— дигән иде.

Кызганыч ки, андый «комплиментлар»ны шактый ишетергә насыйп булды. Булмаса да ярар иде дә бит...

Кемнәргәдер миңа карата «дөрес уйларга» бирелгән күнекмәләр, шәхси мөнәсәбәтләрдән узып һәм җәмәгатьчелек фикеренә әйләнеп, матбугат битләренә күчә торды. Хикмәттер, кичә генә дус булган кешеләр иртәгесен кара чырайлыга әйләнә.

Язучы М. Юныс белән аралар дусларча иде. Аның беренче әсәрләренә бәя бирүче, киләчәгенә юл ачучыларның берсе мин идем. «Ут һәм Су» романы басылгач: «Синең романыңда бер тамчы да су юк, ул гел уттан гына тора»,— дип хат язган иде. Аннары, күпмедер елдан соң, Чаллы темасына язылган романнарның кечкенә бер мәзәктән кайтыш икәнлеген «раслап», матбугатта язып чыкты. Дус кеше «дөрес курска» керде.

Язучылар союзына әгъза булып керергә җыенган В. Юнысов, Мәскәүдә очрашкан чакта: «Әсәрләрегезне с удовольствием укып барам»,—

дисә, күп тә үтмичә, минем әсәрләрнең укылмавы хакында памфлет бастырды.

Хәл шундый ки, еллар буе мин ике фронтта көрәшергә мәҗбүр ителдем. Беренчедән, социалистик реализм кысаларына сыя алмаганлыктан, югары оешмаларның һөҗүмнәренә дучар булсам, икенчедән, шул җайлы ситуациядән файдаланган көндәш төркемнәр куак асларыннан чыгып, өскә ташлана тордылар. Алар күп, ә мин берүзем. Көрәшеп нишлисең? Кәтүгә ияреп йөрү хисе — яхшыдырмы бу, яманлырмы — миндә була алмады. Бердәнбер диярлек шундый ысул калды: аларга түбәнсетеп карау (русча презрение дию дөресрәк кебек) һәм әсәрләр белән җавап бирә тору. Көрәшнең сизелерлек нәтиҗәләр бирмәве шуның белән аңлатылса кирәк.

Шушы җәһәттән, язучы М. Галиев: «Синең имиджың үзеңә бөтенләй туры килми бит, ә үзең син аны төзәтергә тырышмыйсың», — дигән иде. Әйтелгәннәргә шуны өстисе кала: карачкылар белән сугышырга табигатем кушмады бугай...

Беркемне да дошман күрмәдем. Ә үзем, имеш, кемнәрнеңдер дошманымын. Ни өчен? Беркемгә бернинди зыян китергәнем, аяк чалганым булмады, дип игълан итә алам. Мин комачау иткән бер кеше дә юк дип беләм. Андый кешеләр табылмаячак. Дәрәҗә сөйгән кешеләрнең дәрәҗә, бүләк алуларына да риза булып, кул күтәрә килдем, гәрчә минем кандидатура тикшерелә башласа, үзләре каршы килсә дә. Һәм алар миңа таш аталар...

Таш кынамы! Кургаш атарга теләүчеләр дә булган бугай әле. Бер язучы ханымның: «Борынгы заман булса, сине дуэльгә чакырып, үтергән булырлар иде!» — дигән сүзләре хәтердә.

Минем ике томлы проза әсәрләренә кереш сүзендә Әмирхан ага Еники: «Әсәр артыннан әсәре чыкса да, ул обоймага эләкмәде, исеме кирәксә-кирәкмәсә дә тәкрарланып тормады, киресенчә, шактый вакыт ул ничектер бер читтәрәк кала килде. Һәм тагын да гаҗәбрәге шунда, аның моңа бер дә исе китми иде кебек. Югыйсә бит игътибар җитмәү язучыны еш кына рәнҗетә, борчылырга мәҗбүр итә. (Хәер, бу очракта Әхсәннең күңелендәниләр туганын ул үзе генә белә торгандыр инде.») — дип яза.

Менә хәзер «үзем генә белгәнне» язып карадым инде...

Әсәрләремне яклый белмәдем, үз көннәрен үзләре күрсен дигән фәлсәфә белән гомер кичте. Бәлки, бу минем язмышка әйләнгән зур ялгышым булгандыр...

Сәнгать әсәренә карашым шундый булып кала: кемдер чын күңелдән ярата алса, шул җитә. Шунда гына ул яшәргә хаклы. Хаксыз икән, аны ясалма рәвештә яшәтүдән файда юк. Синнән соң ул барыбер тиз арада үләчәк бит. Бәлки бу караш та минем кимчелегем, хатамдыр?

Г. Ахунов та бервакыт: «Әсәрләреңне чыгарырга көч куясың, ә аларны таныту өчен бернәрсә дә эшләмисең», — дигән иде. А. Гыйләҗевнең: «Еламаган балага имчәк бирмиләр», — дигән сүзен берничә кабат ишеттем.

Дөрес сүзгә җавап юк. Елый белмәдем. Әсәрләрем, геройларым гафу итсеннәр. Үзем якламагач, башкалар да якламады. Киресенчә, алдагы мисаллардан күренгәнчә, аларга каршы аяусыз көрәшүчеләр җитәрлек булды.

«Һәйкәл» әсәрен башлап Нәкый ага Исәнбәттән укыткан идем. Шул хакта сөйләшеп утырганда, гадәттә үзенчәлекле әсәрләрнең тәнкыйтькә еш эләкмәве юлыгуы турында сүз чыккач, мин Исәнбәт дигән язучының да гомер-гомергә дигәндәй тиргәлеп килүен хәтерләп:

— Еллар буена сузылган тәнкыйтьне ничегрәк кабул итә идегез? — дип сорадым.

Остаз ихлас елмайды:

— Йөрәккә уклар шул хәтле күп кадалды, алар бер катлам өслеккә әверелеп, бөтәннәре җәрәхәтли алмый башладылар.

Бүгенге көннәрдә мин дә үземне шундыйрак халәттә дип хис итәм.

* * *

«Һәйкәл» дигәннән, миңа болай драма әсәрләре, гомумән, ят булмады. Табигыйдер ки, кеше, үзен белә башлаганнан алып, сәнгать белән яши бит. Үсмер чакта ук төрле спектакльләрдә катнашырга һәм кайчак үземә дә пьесалар язарга туры килгәли иде.

1962 елда Язучылар союзы рәисе Мирсәй ага Әмир:

— Поэма язган кеше, гадәттә, пьеса да яза. Синең язганың юкмы?— дип сорады.— Ниятең юкмы?

Ниятем генә түгел, яза башлаган әсәрем дә бар иде. Күпмедер вакыттан соң, аңа шул әсәрне укырга бирдем. Тагын күпмедер көннәр узгач, янына кердем:

— Укып чыга алмадыгызмы?

— Укыдым.

— Алайса, мин сезнең хөкемегездә.

— Хөкем каты булачак.

Мирсәй абый бу сүзләрне чын җитдилек белән әйтсә дә, минем елмаясым килде. Хәтердә калган хөкем сүзенең төп мәгънәсе әле дә ап-ачык:

— Куела торган әсәр түгел. Социалистик реализм әсәре мондый була алмый. Кешеләрнең җиңеп чыга алмаслык фаҗигаларын сайлагансың.

Шулай булгач, ни әйтә аласың? Бәхәсләшмәдем. Кәефем кырылганын да хәтерләмим. Мирсәй ага гадәттә әдәпле сөйләшә бит, бәлки шуңа күрәдер.

Соңрак, иҗат йортында очрашкач, пьесаны А. Гыйләҗев укып, икенче төрлерәк әйтте. Әсәрне эшләп бетерергә мөмкин икән. Аның киңәше белән, пенсиягә әле генә чыккан режиссер Габдулла Йосыповка күрсәттем. Аның тәкъдимнәрен искә алып, берме, икеме кабат төзәткәч, ул театрга илтергә киңәш бирде.

Академия театрының баш режиссеры Ширияздан ага Сарымсаков, тагын берничә кабат төзәттергәннән соң, пьесаны художество советына чыгарды. Фикерләр, әлеге дә баягы, төзәтү хакында. Киңәшләр, тәкъдимнәр. Галимә апа Ибраһимова репликасын оныта алмыйм. Сирәк очрый торган, мөлаем артистка. Студент елларында шигырьләремне радио аша укыганы бар иде.

Күңелдә сакланган матур күренешне харап итмәсә ярар иде, дип, аңа текәлсәм дә, юк, бозмады сурәтне. Нәкъ әүвәлге хискә туры килгәнчә әйтте сүзен:

— Автор бик әйбәт укымады. Шулай да яхшы аңлашылды. Фаҗигалы язмыш. Героиня үлеме. Ул үзенең иң тирән серен үзе белән алып китте...

Сөйләшүләрнең күпчелеге мондый серләрдән ерак иде.

Әдәби бүлек мөдире Зәмирә Саликова үлемнең ни өчен килеп чыкканын аңламый:

— Айса ник үлә? Во имя чего?!

Таныш шаукым, төп персонаж үлмәскә тиеш. Совет кешесе үлми. Әгәр үлсә, зур идеал хакына, геройларча гына үзен корбан итә ала. Шул какшамас мәзһәбкә каршы килә́м:

— Ә ник тәгаен шундый сорау куясыз? «Во имя чего?» түгел, ә бәлки «Ни өчен?» дигән сорау тиештер?

Оратор өчен бу көтелмәгән сорау булгандыр, күрәсең. Аптырабрак калды.

— Шулаймы? Эһе, бәлки шулайдыр?

Сөйләүләр тәмам.

Директор Рәшидә апа Җиһаншина, тыныч утыруыма гаҗәпләнеп бугай, сөйләүләрне минем ничек кабул итүем белән кысыксынды:

— Ничек соң? Эшлисезме?

— Соң... Кабул итсәгез, эшлим, кабул итмәсәгез, эшләмим.

— Монда бит кабул итмибез дигән сүз булмады. Шулай бит?

— Шулай, шулай,— диештеләр иптәшләр.

— Ярый, договор төзербез. Киләсе сезонга китерерсез.

Бу сөйләшү яз көне булган иде. Көз көне, режиссер белән нык кына эшләгәннән соң, әсәрне директорга тапшырдык. Тагын җыелыш, тагын фикерләр. Бу юлы аларның күбесе — режиссерга. СССРның халык артисты исемен алачак Фуат Халитов хәтта тавышын күтәрә төшеп әйтте:

— Без бит мондый үзгәреш көтмәгән идек. Романтик әсәр иде. Ә хәзер ул җиргә төшкән. Автор синең сүзне тыңлаган.

Рәшидә ханым Җиһаншина да шундый ук сүзләр әйткәч, бәхәсләр тагын кыза, кинәя төште. Шулай да, бераз суына язып, репетицияләргә тотынырга дигән карарга килделәр. Ләкин бу автор тынычлыкта калды, дигән сүз түгел иде әле. Артистлар, очрактан файдаланып, үз мөнәсәбәтләрен дә ачыклыйлар шикелле иде. Чәчрәгән очкыннар миңа да кагыла бирде. Эш азагына житә язганда килеп чыккан, ызгышка тартым бәхәсләр миңа бөтенләй диярлек бәйләнмәгән иде. Героиня характерына дөрес кереп, образны эшләп бетерә язган Нәҗибә Ихсанованы икенче составка күчереп, моңарчы эшкә катнашмаган артистка белән алмаштыру коллективтагы эчке каршылык галәмәте икәнлеге күзгә бәрелеп торды. Бу хәл, Нәҗибәнең кәефен бозу белән чикләнмичә, гомуми үрләлеш китереп чыгаруы белән пьеса язмышына тәэсир итмичә калмады. Генераль репетиция алдыннан гына пьесадан бөтен бер образның, тискәре персонаж булган профсоюз лидерының алынып ташлавын бары тик эчке каршылыклар белән генә аңлатырга мөмкин иде.

Спектакльне тапшыру өчен күрсәткәч — профсоюз җыелышы. Минутларга сузылган, шактый шомлы тынлык. Актан-карадан сүз әйтүче юк. Бераздан гына тынлыкны Габдулла Шамуковның әче тавышы чатнатып чыгарды:

— Кая китте Хатамтаев?! Бөтен бер образны сызып ташларлык булгач, ничек итеп спектакль бөтенлеге турында сөйләшергә мөмкин?

Сорау түшәмдә асылынып калды. Аңлыйм, сүзне сәясәт агына борасылары килми. Тагын аптыраш, тагын сүзсезлек. Җыелышны сәхнә биеклегеннән алып барган профком председателе Гәүһәр Камалова тавышында ихлас борчылу. Мөгаен, аның да Хатамтаевның — профсоюз житәкчесенең тискәре образ булырга тиеш түгеллеген куәтләгәне булган... бәлки кыскартуда катнашкан...

— Йә, нишлибез? Спектакль язмышын хәл итмичә таралышабызмыни?

Ниһаять, кешеләргә җан керде. Кемнең башлап сүз әйтүен, кемнәрнең нинди сүз әйтүен тәгаен хәтерләмим. Мәгънәләре шул: зур эш башкарылган, спектакльне сәхнәгә чыгарырга кирәк. Һәм премьерадан соң җәмәгатьчелек фикерен тыңларга.

Җәмәгатьчелек, чыннан да, җыелды. Күпчелек — язучылар.

Һөҗүмнәр тагын режиссерга. Беренчеләрдән булып, Шәйхи ага Маннур чәчрәп чыкты:

— Пьесаны кискәләп бетергәнсең. Автор талантлы. Күренеп тора, син бозгансың. Әсәр койрыксыз мәче хәленә калган.

Әхмәт ага Исхак:

— Спектакльгә фельетон төсе бирелгән.

— Без шундый кызганыч хәлдә яшибезмени инде? — Монысы Фатих Хөсни чыгышының «йөзек» кашы.

Театр белгече Хәсән Гобәйдуллин:

— Бу — драматургның беренче әсәре. Фатих Хөсни аны үзенең беренче әсәрләре белән чагыштырсын иде.

Профессор Мөхәммәт ага Гайнуллин — тормышның ачысын-төчесен күп күрсә дә, куркусыз:

— Әсәр моңарчы булмаган, әһәмиятле яңалык алып килә. Күрмәскә тырышмасак иде.

Чыгышларга йомгак рәвеше биргән Мирсәй Әмир, үзенә хас әдәплелек белән, минем шагыйрь буларак уңышларымны, үзенчәлекләремне күрсәтүдән башлады.

— Шулай да, анда бунтарьлык көчле. Шул сыйфатын ул пьесасына да алып килгән.

Ишарәсе сәясәткә караса да, «бунтарьлык»ның мәгънәсен ачмады. Әшне тирәнгә җибәрәсе килмәгәндер инде.

Чират Шириязданга ага Сарымсаковка җитте. Гадәтенчә, сабыр, олпат кыяфәт белән, алмая төшеп кенә иптәшләргә үз өлешләрен кайтарды ул.

— Күңелле хәл, Маннур да театрга килгән. Дәвамлы булсын. Ни хәл итәсең, пьесаны кыскарта төшәргә туры килде. Койрыксыз мәче, диделәр. Ләкин койрыксыз мәче бик усал була ул. Калган кадәресе дә җитәрлек икәне аңлашылды бит...

Шулай килеп чыкты ки, фикер алышуга мин нокта куярга тиеш булдым.

— Каты әйткән кешеләргә үзләренчә үк җавап бирәсе килә. Ләкин алай эшләмәскә булдым. Кемнең ни өчен нинди сүз әйткәнен яхшы беләм, контекстны аңлыйм. Дөрес, артыграк үзгәртергә, кыскартырга туры килде. Бу — минем беренче сәхнә әсәрем. Режиссерны, беренче укытучымны тыңларга туры килде. Әйбәт теләктә булганнарга рәхмәт.

Таралышканда, каты сүз әйтүчеләр дә премьера белән котладылар. Алар белән бергә Мирсәй Әмир дә елмаеп кул кыскач, хәтта гаҗәпләнеп куйдым. «Болай әйбәт итеп котларык булгач...» дигәнне уйда гына калдырып:

— Алайса, ник алай әйттегез соң? — дип сорадым.

Ул җавап биргәнче чираттагы кеше кулымны кысып, безне артык сүзләрдән коткарды. Әсәрнең иптәшләрне сагаерга мәҗбүр иткән төп мәгънәсе әйтелмичә, һәркемнең күңелендә китте. Ныклап уйласаң, аларны гаеп итү кыен. Кешеләрне аптырашта калдырган сәбәп — пьесаның үзендә, төпкел мәгънәсендә бит.

Конфликтның чатнаган үзәге баш героиня булган Айса йөрәге аша уза. Диплом эше буларак, аның проекты буенча салынган йорт кап урталай ярылып чыккан. А. Шамуков гыйбарәсе белән әйткәндә, идарә башлыгы Хәмитов, «ярык диплом белән килгән» кызга яхшылык күрсәтеп, аны эшкә ала һәм үзенең сердәшенә әверелдерә. Уртак зур сер — планда каралган бөтен бер йортны салынган дип кабул иттерә алу һәм чынлыкта салмыйча калдыру. Ялган йорт, ялган төзелеш. Моның өчен тиешле документлар Айса кулы белән эшләнә. Ялган йорт урынына матур итеп бакча утыртыла. Ялган бакча. Вакыты җиткәч, ялган фаш ителәчәк. Шул җөмләдән — ялган геройлар. Ләкин алар тормыш үзәгендә калачак...

Сиздекме инде ишарәләрнең нинди «кирәкмәгән» якка юнәлгәнен?

Чынбарлыгыбыз — 1960 еллар уртасы — башлыча ялган төзелешләргә әверелә. Ярык бина, салынмый калган йорт, ялган матур бакча — болар соң нәрсә? Тәгаен вакыйгамы, әллә метафорамы? Автор исәбенчә, метафора. Ләкин җәмәгатьчелек әйтеп бетермәде шикелле. Нинди-дер шикле нәрсә барлыгын сизәләр, ләкин тәгаен нәрсә ул, күренеп, аңлап бетермиләр, атап әйтмиләр. Әгәр дә эш зурга китә калса, ник сүз әйтмәдегез дип бәйләнә калсалар, без фикеребезне әйттек, диярлек дәрәҗәдә генә тәнкыйтьләделәр. Моның өчен иптәшләргә рәхмәт әйтергә кирәктер. Әмма бит минем уем барыбер яхшылыкта иде: ялганны фаш итү, чын әхлаклы җәмгыять төзү, ә шушы юл белән дәвам иткәндә исә,

иҗтимагый корылышның һәлакаткә киләчәген кисәтү... Ләкин, дөресен әйткәндә, мине аңламадылар һәм аңларга да теләмәделәр. Сай җирдә йөзделәр. Әгәр тирәнгәрәк кереп, мәгънәне ачыклаган булсалар? Әйтү янә кыен, бәлки ул чакта әсәр тыелган да булыр иде. Ничек булса булды ки, языла башлаганда «Яшен ташы» дип аталган драма, эш барышында «Күзләре нинди иде...» дигән исем алып, Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә гәүдәләнеш тапты. Ул чакта, тамашачының өчәр, дүртәр пәрдәле пьесаларга күнеккән булуы аркасында, спектакльнең иртәрәк бетүе аерым кешеләрдә ризасызлык тудыруга карамастан, әсәр тулы бер сезон дәвамында уңышлы барды, дия алам. Әгәр Ширияздан ага Сарымсаков театрдан китмәгән булса, тагын берәр сезонга чыдаган булыр иде, дип ышанып әйтәм.

Спектакльдә Хәмитов ролен башкарган күренекле артист, тамашачы аңлап җиткерми дип, ялган өйгә актлар төзүне Айсага кушканда, автор сүзләрен үзгәртеп, ачык текстка күчә. Яңа билгеләнгән баш режиссер М. Сәлимҗанов моны автор кимчелеге дип кабул итте. Шул караш аркасында, икенче сезонда репетицияләрне яңартучы булмау, спектакльнең хуҗасыз калуы сәбәпле, ул икенче ел репертуарына кертелмәде.

Шулай да матбугатта, тәнкыйтьтә аның хакында сүзләр тиз арада гына тукталмады. Истә калган кайбер бәяләрне телгә алу урынлы булыр кебек.

Драматург Т. Миңнуллин («Гүзәлем Әсәл» премьерасын карагач):

— Тулы килеш чыкса, синең әсәр дә шушының кебек яңгырарга тиеш иде.

Драматург Ш. Хөсәенов:

— Шекспир мәктәбенә караган әсәрләр безнең татар тормышында уңыш казана алмый. (Шекспирмыни? Ә. Баяновның дөньяга үз карашы юкмыни?)

Шагыйрә Г. Зәйнашева:

— Спекталь безнең театрда куела торган спектакльләргә охшамаган. Мәскәү театрларындагы кебек.

Театр белгече И. Илялова:

— Һәр театрның үз характеры, үз стиле була. «Күзләре нинди иде...» Г. Камал театры юнәлешенә туры килгән әсәр түгел иде.

Ул чакта «Казан утлары»ның баш редакторы булган Р. Мостафин спектакльне үзе карамаган иде булса кирәк: «Советка каршы әсәр дип сөйлиләр»,— диде. Ләкин укучылардан пьесаның басылып чыгуын сораган хатлар килгәнлектән, аны журналга бирергә тәкъдим итте. Тик басылып чыгуына ышанып бетмәгәнгә күрә, мин әсәрне журналга да, нәшриятка да тәкъдим итмәде.

Дөресен әйтим, әле телгә алынган бәяләрнең барысы белән дә килешәм, диярлек. Әмма театрның асылда бер генә юнәлештә калуы белән беркайчан да килешә алмыйм. Академия театры, әлбәттә, үз исеменә муафыйк рәвештә үсәргә тиеш иде...

Моннан соң «Чалбарлы кыз» исемле пьеса язылып, аньсы да пенсионер режиссер Г. Йосыпов фатихасын алса да, академия театрына күрсәтмәдем. Күчмә театрга биреп караган идем. Режиссер Р. Тумашев: «Сәхнәгә чыгарасы килә»,— дисә дә, ни өчендер озак яткыруын аңламыйча, кире алдым.

Шул ук чорда «Һәйкәл» драмасы язылды. Нәкый ага Исәнбәт фатиха биргәнлектән, аны Г. Камал театрына — М. Сәлимҗановка илттем.

Әсәр аңа ошады. Үзе үк куярга алынмакчы иде. Ләкин тора-бара, икенче төрлерәк сөйләшә башлады. Башымны кискәгә куеп әйтә алам, аның үз сүзендә тормавы кайбер тар күңелле кешеләр йогынтысы аркасында килеп чыкты. Үзе баш тартканнан соң әсәрне Н. Исәнбәткә биргән һәм ул да нигездә уңай фикер әйтеп, әйдә, эшләп бетерик, дигән иде. Очрашу өчен вакыт билгеләдек. Бер мәртәбә, ике мәртәбә. Әйткән вакытында килмәгәнлектән, өченче тапкыр инде мин аның янына бармадым. Үзләре соравы буенча, Минзәлә театрына җибәрдем.

Кабул иттеләр. Ихлас күңел белән, яратып эшләделәр. Әмма анда да шома гына булып чыкмады. Репетицияләр «полный хут» барган бер вакытта, мине чакыртып, драманың финалына үзгәреш кертергә киңәш иттеләр. Мин каршы килгәч, эш өзелә язды. Мәгәр соңыннан кайбер аерым артистларның аерым-аерым килеп киңәш бирүләрен тыңларга, әсәрнең азагын бераз «кызартырга» дучар булдым. Нишлисең бит, вакыты шундый — алда Бөек Октябрьнең кырык еллыгы тора, В. И. Ленинның йөз еллыгы якынлаша...

Академия театрында мондый ультиматум куелмаган булыр иде, дип уйлыйсы килә.

Шулай да театрга үпкәләрлек түгел. Үзләренең төп спектакльләреннән санап, берничә ел буе уйнадылар, Казанга алып килделәр, башка зур шәһәрләргә алып бардылар. Әлеге дә баягы, баш режиссер алмашынгач кына, әсәр сәхнәдән төште.

Спектакль барган араларда яңа әсәр язылы башлап, аның «Зәңгәр күгем кыйпылчыгы» дигән беренче варианты шулай ук театр коллективында тикшерелеп, нигездә уңай фикергә киленгән иде. Баш режиссер алышыну белән, анысы буенча да бәйләнеш өзелде. Шуннан соң пьесаны Академия театрына тапшыргач, тагын коллективка укылды. Фикерләр янә уңай. Күләме озынрак икән, диючеләргә Фуат Халитов минем өчен:

— Озынны кыскартып була,— дип җавап бирде.

Гомуми фикер әйбәт булгач, яраткан әнисе, күренекле артистка Нигъмәтуллина да: «Алырга кирәк, алырга кирәк!» — дип торганда, баш режиссер бер үзе генә каршы сүз әйтә алмый бит инде. Шунлыктандыр дим, ул, минем үзенчәлекле автор булуымны, бу әсәрнең дә үземә хас стиль белән, художникларча язылуын билгеләгәннән соң, шактый оста нәтиҗә ясап:

— Мин бит чабаталы режиссер, мондый романтик әсәрләрне куя белмим,— дип тыйнаклык күрсәтте.

Фуат Халитов тагын җавапсыз калмады:

— Уфадан Исрафиловны чакырырга була...

Шул ният белән таралыштылар. Әлбәттә инде, чакырулар белән мәшәкать чикмәделәр. Кузгалыш сизелмәгәнлектән, ел чамасы вакыт узгач, пьесаны алырга бардым.

— Нишлисең, шулай инде,— дип, кызгану белдергәннән соң, Марсель Хәкимович бигүк ерак ятмаган пьесаны табып бирде.

Егерме елдан соң, әсәр, ниһаять, Татарстан телевидениесендә куелды. «Зәңгәр кыңгыраулар»...

Ярыйсы яңгырады. Күргәнсездер, актуальлеге кимемәгән, киресенчә, бәлки арткандыр әле. Шигъри-музыкаль образы күп кенә шагыйрьләрне рухландырып, җырларга, шигырьләргә күчте. Хәтта шул исем белән аталган җыр ишетелде.

Инде икенче әсәргә күчик.

Драматургия җанрына караган чираттагы әсәр — «Алтын кашбау» трагедиясе. Берничә елга сузылган хезмәт. «Казан утлары» журналында басылды. Аннары Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып чыкты һәм, шул рәвешле, аның да үз биографиясе башланды.

Нәшриятта корректура укыганда, бөтенесе тәртипле иде. Зур хаталар юк, булганнары төзәтелде. Әмма ни хикмәттер, китапта әсәрнең иң үзәк фикерләренең берсен шундый оста итеп бутаганнар, хәйран калмалы. Төп персонажларның берсе булган Алсылуның:

Җыен хәшәрәтне өскә алып чыккан
Дәүләт үзе чыгачактыр юкка,—

дигән сүзләрен хыянәтче Балтамарга «бүләк иткәннәр». Ә Балтамарның үзенең түбән нәселдән булуын таныган «Мул тормышта яши торгач, безнең дәвам булыр юлбарыстай» — дигән сүзләрен Алсылудан әйттерәләр.

Юкка түгелдер, юкка түгелдер, диясе кала. Ләкин әсәрнең тормыш юлы моның белән төгәлләнә алмады, киресенчә, башланды гына әле.

Сөяленә бассалар, сөялеп тора алмассың, дигән халкыбыз. Катырак бассалар, кычкырып җибәрүең дә ихтимал. Хәзер сүз барасы очракта мин шундыйрак хәл тойдым бугай.

Эш ерак Ташкент каласыннан килгән бер хаттан башланды. Хатның авторы — Хәлим Гыйззәтуллин — Татарстан китап нәшриятында басылган «Алтын кашбау» исемле шигъри трагедия хакында яза һәм шуңа бәйләнешле рәвештә кайбер җитди мәсьәләләр кузгата, сораулар бирә, «Идел» журналында (автор яшь кеше, күрәсең) шул әсәр буенча фикер алышырга чакыра. Сораулар, нигездә, шулардан гыйбарәт иде:

— Әсәр опера либреттасы була алыр иде бит. Нишләп аны театрга тәкъдим итмисез? Әллә опера язарлык композиторлар юкмы? Н. Җиһанов үзенә алмашка шундый композиторлар тәрбияли алмаганмыни?

— Нишләп хәзерге композиторларның күбесе рок музыкасы белән генә мавыга? Зур күләмле җитди шигъри әсәрләр популяр түгел. Моның сере нәрсәдә?

Күрәбез ки, сораулар бер әсәргә генә кайтып калмый. Шуңа күрә — иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр куелганга күрә — хат авторының теләген искә алып, аңа «Идел» журналы аркылы ачык хат юллаган идем. Кичерегез, тагын халык сүзенә мөрәҗәгать итәргә туры килә, чөнки нәкъ шулай булды бит:

Хатлар яздым утырып,
Ак кәгазьләр тутырып.
Хатым китте, үзем калдым,
Язган җирдә утырып.

Утырып калуым анысы хак, ә менә хат? Әйе, китә алмады хат, редакция өстәлләрендә айлар ятты, икеме, өчме ел ятты һәм югалды. Укучы хатын да, үземнекен дә кире кайтаруларын үтенеп берничә мәртәбә Фәиз Зөлкарнәевкә мөрәҗәгать итсәм дә, таба алмадылар.

Байтак вакыт узып җиткәч, хатларда кузгатылган фикерләр искергәндер, әһәмиятләрен җуйгандыр дип, үзем дә суына язган идем инде. Ләкин шушы көннәрдә яңадан укып карагач, бөтен нәрсәнең искечә кала бирүе аңлашылды. Тормышыбызны ул хәтле тиз «үзгәртеп кора» алмадык шул әле.

Әллә миңа гына шулай тоеламы? Әллә соң ал да гөлме хәлләребез?

Бисмиллаһир-рахманир-рахим, китап укучыларга язган хатымны бергәләп укып, уйлап карыйк.

*«Хөрмәтле Хәлим иптәш Гыйззәтуллин!*

*Сезгә әйтәсе килгән беренче сүзем, әлбәттә, шул: хатыгыз өчен, әйбәт сүзләрегез өчен зур рәхмәт.*

*Укучы фикерен беләсе килү һәр авторның иң беренче, табигый теләге бит. Язучының иң беренче дусы, киңәшчесе дә, хөкемдары да — укучы. Шуны истә тоткан хәлдә, хатыгызны игътибар белән укыдым. Рәхмәт йөзеннән, теләгегезне үтәргә тырышып карыйм.*

*Дөресен әйткәндә, бу — җиңел эш түгел, чөнки сезнең фикерләрегезгә мин бит тулысынча кушылам. Каршы дәлилләр эзләргә, бәхәсләшергә, үзеңнекен исбат итәргә җәй юк. Фикерләрегезне яклаган хәлдә, аларны дәвам итәргә һәм кайбер мисаллар өстәргә генә мөмкинлек кала.*

*«Алтын кашбау»ның китап басмасына сүз башында әйтелгәнчә, әсәрнең төп чыганагы ерактан — туган җирдән, Агыйдел буйларыннан, балачактан башлана. Бүтән һичбер тәэсир булмаса да, ул барыбер язылган булыр иде. Мәгәр аңа заказ да булмады түгел. Шул ук сез әйткән опера һәм балет театрыннан.*

*Әсәр язылганчы дистә ел чамасы элек театрның әдәби бүлеге җитәкчесе Земфира ханым шушы темага уйлануымны һәм либретто язуымны үтенгән иде. Язарга ук йөкләмә алмасам да, уйланырга вәгъдә биргән идем. Ләкин, күңелдә трагедиянең сюжеты, вакыйгалары, образлары табигый рәвештә укмашканчы байтак вакыт узып, ул арада театрның әдәби бүлек мөдире алмашынып, андый әсәрне кирәксенүче калмады. Башкача аны миннән сораучы булмады.*

*Ләкин әсәр барыбер язылды, театрга бәйле булмаган рәвештә барлыкка килде.*

*Әсәр язылгач, ник үзегез инициатива күрсәтмәдегез, дип сорарга мөмкин. Тик бу очракта җавап бирү җиңел. Сәбәп гади һәм тәгаен — безнең милли музыка тормышында урнашкан тәртипләр, аяныч хәлләр.*

*Сез: «Нәҗип ага Җиһановның бу темага язарлык берәр укучысы калдымы икән, юкмы?» — дип сорыйсыз.*

*Мин андый композиторларны белмим, калмады дип исәплим.*

*Бу, әлбәттә, олы композиторның зур кимчелегедер. Әмма сәбәп бер генә кеше җаваплылыгында түгелдер, ә барыннан бигрәк, иҗтимагый, сәяси хәлләр белән аңлатыладыр.*

*Өстенлек иткән сәясәтнең илдәге халыкларга төрлечә карашы, җитмеш еллык тырышлыгы культурага, аеруча татар культурасына мөнәсәбәте — бөтен нәрсәне асылда әнә шул хәл итте.*

*Милли изелү — безнең борын-борыннан килгән язмышыбыз. Явыз Иван чорында башланган геноцид, Казан — Болгар илен тураклау юлы белән (бүлгәлә һәм хакимлек ит!), көчләп чукындыру, күтәрә алмаслык ясаклар салу, ач үлемгә дучар итү юлы белән тарихи җиңүләргә иреште. Милләтебез халыклар төрмәсенең иң караңгы һәм тынчу почмагында гомер сөрергә мәҗбүр булды. Колонизаторлык миссиясен үз өстенә зур теләк белән кабул иткән интернационализм сәясәте бу юнәлештә аеруча зур казанышлар ялады.*

*Формаль яктан игътибар һәм аталарча кайгырту галәмәтләре күрсәтелеп, чынлыкта исә астыртын рәвештә, ә «җепшетү» һәм торгынлык дәверендә — республикаларны өлкәләргә әйләндерергә азапланган, республикалар конституциясеннән милли телләрне дәүләт теле статусыннан мәхрүм иткән чорда — милләтләрне юкка чыгару өчен көрәш ачыктан-ачык, оятсыз төстә барды. Илне бер генә милләттән торган монолит дәүләт итәргә ашкыну, советлаштыру исеме белән руслаштыру реаль лозунг, партия программасына акка кара белән язылган максат иде. Бу чорда ирешелгән уңышлар патша хөкүмәтенең, барча төр империалист, шовинистларның төшенә дә кермәгәндер. Чөнки патшалар көрәше гел бер төрле — ачыктан-ачык барганлыктан, халыкларның каршылык күрсәтү кирәклеген аңлау дәрәҗәсе зуррак иде. Ә илдәге «халыклар дуслыгы» эмиссарлары озак еллар буе хәйләле тактика белән эш итте — дус булып, кайгырткан булып, яшертен. Шуңа ышану аркасында — яшерен явызлыкны сизмәү сәбәпле — милли организмның чиргә, үлемгә каршы көрәшү иммунитеты бетү дәрәҗәсенә җитте. Организмда иммунитет җитмәүнең нәрсә икәнлегеге хәзер бөтен дөньяга билгеле.*

*Борыннан килгән гадәт белән, татар исемен йөрткән халыкка, аның культурасына, теленә карата аеруча рәхимсез булды.*

*Бөек Ватан сугышына чаклы Казанда булган татар мәктәпләре сугыштан соң тиз арада һичбер каршылыксыз (иммунитет мәсьәләсе!) ябылды, бетте. Ә соңгы елларда бу афәт авылларга да таралды...*

*Культура өлкәсендә дә күптәннән бирле хәлләребез шул чама.*

*Дәүләтнең халыклар культурасын чәчәк аттыруга багышланган хәләл капитал салымнары хисабына (бөек шагыйребез М. Җәлил катнашында) сугыш алды елларында Татар дәүләт опера һәм балет театры ачылган иде. Татар театры. Ләкин сугыш чыгу белән иң талантлы, иң өметле композитор иң беренчеләрдән булып, фронтка озатыла. Чистай шәһәрендә йөзләгән Мәскәү әдипләре ышанычлы ышык*

*тапкан бер вакытта, йөзләрчә, меңнәрчә чиновникка бүләк ителгән бронь дигәннәре бер генә композиторга табылмаган...*

*Сугыштан соң эре жанрда эшли алырлык, карап торырлык бердәнбер Җиһанов кала. Бөтенесен кадрлар хәл итә, ләкин юк кадрлар. Ярый әле Мәскәү бар, ул ярдәм итә — башка милләт әһелләре!*

*Башка милләт әһелләре безгә консерватория һәм музыка училищесы укытучылары буларак ярдәм итәләр. Еллар дәвамында йөзләрчә белгечләр, музыкантлар тәрбияләнә... Тик күпчелек, нишләптер, шул ук башка милләт вәкилләре булып чыга шул. Нәтиҗәдә, училище да, консерватория дә, опера һәм балет театры да үз телен белми — татарча җырлый да, уйный да алмый.*

*Хикмәти хода, театрга инде татарча язылган бик күп жанрлар кирәкми, аеруча — опера, балет...*

*Дөрес, сугыштан соң да опера язарга талантлы композиторлар чыккалады. Хәзер дә күренгәли кебек. Алар бәлки күбрәк һәм әйбәтрәк яза алган булырлар иде. Ләкин зур әсәрләр өчен түләргә культура министрлыгының акчасы җитми. Композиторны язарга үгетлиләр, теге риза да була һәм... Эш башлана дигәндә, гонорар сандыгының буш икәнлеге беленә. Шулай итә-итә, композитор сәбәпләрне ачыкларга керешә, җыелышларга, киңәшмәләргә катнаша, үзен икенче яклап: оратор буларак раслап, сөйли. Сөйли торгач, илһам дигәне сүзгә күчә. Хәзерге көндә опера да, балет та хаҗәт түгел аңа. Җиңелрәк юл бар — эстрада, синтезатор һәм башка төр дөбер-шатыр...*

*Хәер, анысы хакында да җәелеп сөйләргә һәм сөйләшергә мөмкин. Анда да проблемалар җитәрлек. Әйдә, башка очракка калып торсын.*

*Хөрмәтле иптәш Гыйззәтуллин!*

*Бездә ни өчен опера әсәрләре язылмауның, яшь композиторларның, модага ияреп, рок-опералар белән мәшгуль булуының сәбәпләрен сез үзегез дә яхшы сизәсез икән. Ул театрга, композиторларга минем мөрәҗәгать итмәвем шул сәбәпләр белән бәйләнгән.*

*«Алтын кашбау», әдәби әсәр буларак, үз тормышы белән яшәп китте. Язмышы нинди булыр, анысы миннән тормый хәзер. Мин намусым куш-канча эшләдем, акча өчен дә, шөһрәт өчен дә түгел — халыкка нинди дә булса файда эстәүне генә күздә тоттым. Калганын халыкның һәм әдәби җәмәгатьчелекнең мәдәни-әхлакый дәрәҗәсе хәл итәр.*

*Инде килеп, «мондый әсәрләрнең киң халык арасында популяр түгеллеге» хакында.*

*Төп сәбәп, әле генә без искә алганыбызча, милләтнең гомумкультурасына бәйләнгән. Асылда, монысы да — тарихи шарт нәтиҗәсе.*

*Гасырлар буе милләтебезнең акыл көче төрлечә кысрыклаулар, чукындырулар һәм җәйләшү аркасында башка милләтләргә күчеп, кими килгән. Башка милләтләргә, аеруча күп төстә рус мәдәнияте үсешенә хезмәт иткән. Рус милләтенең акыл куәтен — генетик хәзинәсен баеткан. Карамзиннан башлап Булгаковка чаклы татар каны булмаган язучы, мәгърифәтче, фән эшлеклесен табу кыен.*

*Шулай да халыкның үз хәлен яңарта, торгыза алу сәләте Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Дәрдемәнд, Тукайлар мисалында күренә килеп, совет чорында дәвам иткән. Ләкин гасырыбызның утызынчы елларында яңа зур югалту кичерергә туры килгән аңа. Шул вакытлардан башланган рухи бушлык әлегәчә үзен нык сиздерә. Тәгаен әйткәндә, чын галимнәр, чын әдипләр урынын алган кызыл ударникларның холыкларын, гыйльми дәрәҗәләрен формалаштыруда, сәяси шартлар белән бергә, алфавитыбызның ике тапкыр үзгәртелүе дә билгеле роль башкарган, әлбәттә. Аларның эшчәнлеге асылда, законнан тыш булып калган элекке галимнәр фикерен кабатлауга кайтып калды, бер урында таптану килеп чыкты. Үзләре рәтләп укый белмәгәнлектән, элгәрге китапларны таный белгән карчыклардан укытып доктор булган кешеләр дәрәҗәгә менде. Бу галимнәрнең белемсезлеге, аларның куркытылган, өркетелгән булуы шулай ук фәнни сыйфатка*

*тәэсир итмичә калмады. Һәрхәлдә, алардан кыю фикер, әһәмитле яңа ачышлар көтү кыен иде. Уңай яклары дигәндә, шуны әйтер идем: алар арасында агрессив холыклы шәхесләр күп түгел иде. Ә менә яңарак шартларда белемлерәк булып, аларны алмаштырган буын, куркытылмаган буын исә, аларның шушы уңай сыйфатларын да кабул итә алмады. Боларны астыртын эш йөртү, усаллыкның барча төр мөмкинлекләрен файдалана белү белән аерылып торалар.*

*Үзләреннән тирәнрәк фикер йөртә алучыларга юл бирмәү алар өчен кыен эш булмады. Сәләтләрен үстерә алмыйча калу, хәтта Казанны ташлап китү очраклары була торды.*

*Шул рәвешле, безнең рухи тормышыбызда торгынлык чоры дистәләрчә елларны эчен алды.*

*Моның өчен иҗтимагый шартлар әзер: бер үк кеше иң җайлы эшләрне үз кулына эләктерә ала — студентларга дәрес бирә, аспирантлар тәрбияли, югары мәктәп һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр яза, нәшриятта редколлегия әгъзасы, КПСС өлкә комитетында киңәшче булып тора һ. б. һәр урында ул үзенең субъектив карашларын тормышка ашыра. Ә карашлар, принциплар билгеле: алар өстенлек итүче сәясәткә гел дә туры килгән, казна рухы белән сугарылган, сәнгатьчәлеге чамалы булган, җиңел кулдан язылган дус-иш әсәрләрен төрлечә яклау, пропагандалаудан, чор сәясәтенә туры килеп бетмәгән, яки дус-иш булмаган кешеләр иҗат иткән әсәрләрне игътибарсыз калдыра барудан гыйбарәт.*

*Ул тәрбияләгән белгеч аның эшен лаеклы дәвам итә. Яшь белгеч тә бит адәм баласы — фатир кирәк аңа, гыйльми дәрәҗә, мактау, бүләкләр...*

*Бу кешеләрнең төп җинаяте халыкның рухи-мәдәни үсешен тоткарлауда булды. Күп кенә югары сәнгать әсәрләренең халык күңелендә тиешле яңгыраш таба алмаулары (популяр була алмаулары), башлыча, әнә шул тоткарлык белән аңлатыла да.*

*Әдәбиятны чын-чынлап аңлый, тоя торган, киң, объектив фикерли алган, намуслы галимнәр һәм тәнкыйтьчеләрнең юк дәрәҗәсендә аз булуы хәзерге көндә дә зур афәт, явызлык булып кала.*

*Бәхетемә дип әйтимме, минем әсәрләр беркайчан да бу төр тәнкыйтьчеләр яклый торган әсәрләр рәтенә керә алмадылар.*

*Монысы — беренчедән.*

*Икенчедән, популярлык кимәленә жанрның үз хасиятләре дә йогынты ясаганлыкны исегезгә төшерер идем. Алайга китсә, Шекспир, Пушкин трагедияләрен дә халык, шул исәптән рус һәм инглиз халкы да ябырылып укый дия алмыйбыз бит.*

*Борынгыдан килгән традиция буенча, зур күләмле шигъри әсәрнең (поэма, драма, трагедия) нигезен мәңгелек дәвамында дөрес булып кала торган тормыш картинасы тәшкил итә. Мондый әсәрләрдә конфликт чишелеше — хәрәкәт — кеше табигатендәге үзгәрмәс, төпкел сыйфатларны ача.*

*Ихтимал, кеше психикасындагы кайбер шундый сыйфатлар «Алтын кашбау»да да юк түгелдер. Мөнәсәбәтләрдә бер кешенең икенче бер кешене үзеннән талантлырак итеп күрергә ашыкмавы серме әллә? Болгар илендә, мәсәлән, бик күп матур йолалар белән беррәттән, начар гореф-гадәтләр дә хөкем сөргән: башкалар белән чагыштырганда акыллырак икәнлеге беленгән кешеләрне юк итү (куккә озату) йола буларак ныгып урнашкан.*

*Табигатьтән килгән бу тойгы-омтылышларны мин адәм баласының мәңге кала биргән, хәзер дә киң таралган, тагын, тагын дәвам итәчәк кара сыйфаты дип исәплим.*

*Автордан көндәлек тормыш, нәкъ менә бүгенге көнкүреш маҗаралары көткәннәргә, шуңа күнеккән кешеләргә мондый әсәрләр кызыксыз тоелса, гаҗәпләнмәскә мөмкин.*

*Әсәрнең күләмен, уку һәм аңлау өчен җиңел үк түгеллеген шулай ук исәптән чыгармаска туры килә. Мин җитди эш башкарырга тырышканмын икән, укучылардан да шундый ук җитдилек өмет итәргә тиеш булам, укучыдан зиһен хезмәте таләп ителүен аңлап эш итәм.*

*Әйтергә кирәк ки, зур күләмле әсәрләр генә түгел, кечкенә күләмле кайбер әсәрләр дә игътибар зурлыктан бик ук «җәфа чикмиләр». Атап әйтсәк, традицион, җитди лириканың хәле шундыйрак. Классик шагыйребез Дәрдемәнд җыентыгының («Исә җилләр») китап кибетләрендә сатылмыйча еллар буе ятуы — бик тә гыйбрәтле мисал бит, минемчә. Рус классикасыннан А. Блок поэзиясен дә әдәби әзерлеге югары булган укучылар гына кабул итә ала. Мондый мисалларны байтак китерергә мөмкин булыр иде.*

*Бу төр лириканы кабул итү күңел ачудан бигрәк, акыл хезмәте таләп иткәнлектән, күп кенә укучылар, хәтта шагыйрьләр үзләре дә җиңелрәк юл эзлиләр. Соңгы дәверләрдә лириканы гади публицистик әсәрләр кысрыклавы шул мәгънәдә табигый хәл булып калды. Бу жанрны утилитар фикерләүләр рәвешендә кабул итүгә күнегә барабыз.*

*А. Блок, Дәрдемәнд һәм башка шундый юнәлештәге шагыйрьләр лирикасы күрсәткәнчә, шигърият — ул күңел сурәте, хәрәкәттәге тойгылар гәүдәләнеше. Чын лирик әсәрләрдә рухи дөнья халәте — настроение үзгәрешләре тасвирлана. Шигърият — кеше күңеле, кешеләр җанының мәгънәле гармониясе, фикерләр, уйлар яңгырашы, кичерешләр музыкасы. Анда контрапунктлар рәвеше алган каршылыклы омтылышлар, фаҗигале хәлләр, ямьсез күренешләр дә матурлык һәм дөреслек хакына хезмәт итәләр. Анда бөтен нәрсә табигый һәм шул ук вакытта серле, могҗизалы. Акыл белән генә ул әсәрләрнең тирәнлегенә төшеп җиту, әлбәттә, мөмкин түгел. Укучының да автор кебек кичерә алуы шарт. Ә Ходай нечкә зәвык биргән андый укучылар артык күп була алмый шул.*

*Дөреслек дигәннән... Асыл лириканың тагын бер хасиятенә игътибарны юнәлтәсе килә. Тукай әйткәнчә, дөньяда «шагыйрәнә ялган» дигән төшенчә бар бит әле.*

*Сәнгать ич (шул исәптән лирика) тормышны күзгә шикелле төгәл күрсәтә алмый, әмма ул аны күзгәдән төплерәк, мәгънәлерәк итә ала. Фикер һәм сурәтнең чынга (тышкы рәвешенә) охшаш булуы укучыда (тамашачыда) аңа ышану теләге тудыра. Бу теләк шигъри идеягә дөреслек дәрәҗәсе бирә, ягъни — ышандыра. Икенче төрле әйткәндә, автор идеясе белән укучы теләгенең туры килүе (диалектик берлеге) шигъри дөреслекне барлыкка китерә. Димәк ки, ышандыра алу, яки ышандыра алмау шигъриятнең чынлыгын яки ялган икәнлеген күрсәтә торган критерий булып чыга. Күп кенә әсәрләрне укыгач, авторларның бу критерийны сизеп бетермәүләре яки санга сукмаулары күзгә ташлана. Мондый очракта «шагыйрәнә ялган»ның чын ялган икәнлеге, әйтер идем, хәтта ки, авторның әхлакый дәрәҗәсе ачыклана.*

*Кемдер шигъри сурәтләрне гомер сарыф итү бәрабәренә — үзенең кичерешләре, күзәтүләре аркылы тапса, икенче берәү аның әсәрләрендәге детальләрне чүпләп, бераз гына үзгәртә дә үзенеке итә. Кемдер детальләрне тормыштан бөртекләп тапса, икенчесе китап-журналлардан, газеталардан учлап җыя. Һәм җиңел кулдан әсәрләр яза. Ышандыру-ышандырмау хакында уйлау юк. Янәсе, «шагыйрәнә ялган...»*

*Беренче очракта әсәр тормышның үзеннән килсә, икенче очракта ул — суррогат. Беренче очракта — эш, икенчесендә — уен. Яшерен-батырын түгел, бездә ялган (икенчел поэзия) еш кына зуррак уңышларга ирешә, чөнки ул бик җиңел, аны аңлар өчен уйланасы, хезмәт куясы юк.*

*Монысы — мәсьәләнең бер ягы. Аның икенче ягы да бар һәм анысы да шулай ук әхлак дәрәҗәсенә тоташа.*

*Кемдер үз әсәрен күрсәтүгә, пропагандалауга зур көч куйса, икенче берәү моны кирәксенми — әсәрнең үз көчен белергә тели. Бит бервакыт киләчәк, әсәрләр үз көннәрен үзләре күрергә тиеш булачаклар. Яклаучысыннан, хуҗасыннан башка йөрерлек хәле булса, яшәячәк, булмаса — юк. Ләкин кемгәдер уңыш, шөһрәт бүген кирәк. Һәм менә шуннан башлана да инде барча ыгы-зыгы, оештыру, эшчәнлек, кода-кодагыйлык. Җыелышларда, кулуарларда, мәҗлесләрдә шагыйрьлек даулау, чынны юкка чыгару*

*өчен көрәш, аерым җөмләләр, уткен сүзләр табып, күккә чөю ярышлары һ. б. һ. б. галәмәтләр, гадәтләр.*

*Бик тә кызганыч, әхлакка каршы бу гамәлләргә әдәби хәрәкәттәге тәртипләр (дөресрәге — тәртипсезлекләр), структур шартлар булышлык итә. Ә иң беренче чиратта — мәйдан тарлыгы. Бу елларда әдәби журналның һәм нәшриятның бердәнбер булуы, аларга ярдәм итәрлек яки ярыша алырлык бүтән матбугат органнарының юклыгы әсәрләрне дөньяга чыгаруда субъективлыкка, фикер монополиясенә юл калдыра килде. Җайлы һәм хәлиткеч позицияләр алырга тырышу, карьерачылык күренешләре шул хәлләр белән аңлатыла. Нәтиҗәдә, шактый ямьсез көрәш бара, дәвам итә. Үзенә күрә, монысын да борын-борыннан килгән традиция дияргә була. Бөек немец шагыйре Һ. Һейне әйткәнчә, әдәби джунглидә законнар кырыс — кем өлгерә, шул кимерә.*

*Әдәби хулиганнарның күзгә күренгән һәм күренмәгән төркемнәре — шайкалары — матбугат урманнарында һәр куак, һәр яфрак ышыгына посып. Үзләренең лаеклы лидерлары — вожаклары сызгыруын көтеп яталар. Сызгыру ишетелүгә, шайка әгъзалары һөҗүмгә ташлана килде, ташланалар һәм ташланачаклар. Аларның холык-фигыльләрен, аяусызлыкларын минем үземә байтак сынарга һәм татырга туры килде.*

*Алар шулай оешкан төстә үзләренең яшәү мәйданнарын киңәйтәләр. Дуслар макташуы, келәмнәр бүлешү, барча шау-шу урта кул әсәрләрне алгы планга чыгару наменә җәелдерелә.*

*Урта кул әсәрләргә соклану сәнгатьне үстерүгә түгел, үтерүгә хезмәт итә...*

*Җыеп әйткәндә, әсәрләрнең популяр булуы яки булмавына аларның характер һәм эчтәлек үзенчәлекләре, жанрларның үз хасиятләре, шул ук вакытта, тарихи һәм әхлакый факторлар йогынты ясый.*

*Эшләребез уңышлы барсын өчен, беренче чиратта, тормышның үзен рәтле итәргә кирәк. Иң төп мәсьәлә, хәлиткеч гомуми бурыч республикабызның һәм экономик, һәм мәдәни үсешенә, ялгансыз мөстәкыйльлегенә ирешүгә, шул җирлектә принципиаль проблемаларны хәл итүгә кайтып кала.*

*Аерым алганда, музыка мәктәпләрендә, училищеларда, консерваториядә (фәннәргә, предметларга карап) татарча һәм русча тигез дәрәҗәдә укыту опера театрын чынлап та татар театры итәргә мөмкинлек бирер иде. Полиграфия базаларын киңәйтү газета-журналлар чыгаруны юлга салу, махсус әдәби нәшрият булдыру өчен җирлек тудырыр иде. Мәктәпләрдә үз телебездә укытуны яңадан кайтару журналист кадрларны җитәрлек кадәр тәрбияләргә булышыр иде, һ. б.*

*Иң мөһим изге максат — декларатив бәйсезлектән реаль азатлыкка ирешү. Моның өчен чуртан ярдәменә исәп тоту килешмәс.*

*Бәлки, тиз генә барысы да без дигәнчә була алмас. Ләкин дә бит өметсез — шайтан. Гомум халыкка һәм аерым-аерым гражданнарга ышанырга кирәк.*

*Җимерелгән һәм имгәтелгән тормышыбызны аякка бастыруның тиз арада гына хәл ителә алмаслыгын белгәнгә күрә, безнең күзләр бигрәк тә яшьләргә төбәлгән.*

**Март, 1991».**

* * *

Хуш, дип әйтик. Инде килеп, хәлләребез тәмам үзгәрде, төзәлде һәм мондый проблемалар юкка чыкты дип игълан кыла алабызмы соң? Бармы шуңа җай? Ай-һай ла, булса икән!

Укучы белән булган әңгәмә онытылып торган арада үземдә кечкенә булса да бер үзгәреш булды булуын — «Кара кош» исемле тагын бер шигъри трагедия барлыкка килде һәм «Мирас» журналында басылып

чыкты. Анысына карата да аерым хатлар һәм телефон аша безгә инде таныш булган сораулар бирелеп, бер үк мәсьәләләр куелды. Димәк, шәхси яклап та хәлләр бер көе калды. Шулай итеп, әллә өч әсәр: «Һәйкәл», «Алтын кашбау», «Кара кош» — өч трагедия фаҗигале язмышка дучар булды дияргәме?

Әмма әйтергә тел бармый. Укучы күңелендә әсәр ниндидер фикерләр, тойгылар уяткан икән, шуңа канәгать була белергә дә кирәктер ләбаса. Аннары бит бу хәл бер генә язучыга кагыла торган нәрсә түгел. Бу инде традициягә әйләнгән. Традиция Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе»ннән башланган. Нишлик, сәбәпләр бездән көчлерәк. Сәбәпләр, әлеге дә баягы тормышның үзендә.

Тормыш, әлбәттә, үзгәрә тора, әмма да әлегә тискәре якка үзгәрә шул. Бер дә без теләгәнчә, без көткәнчә түгел.

Әйтик, мөстәкыйльлек дип тәкрарларга яратабыз. Шушы иң хәлиткеч мәсьәләдә тынычланырга мөмкинмени? Киресенчә, сагаерга тиешбез. Ник дигәндә, үзебезне халыкара хокуклы дәүләт дип игълан итү белән ниндидер дәрәҗәдә максатыбызга ирештек дигән тойгы туып, канәгатьләнеп калу куркынычы барлыкка килде бит. Эйфория дигән хискә бирелеп, «ассоциацияләнгән» рәвештә, Рәсәй дәүләтенә буйсынып калуыбызны шәйләми калуыбыз бар.

Димәк, тынычлану — үлемгә тиңдәш. Тынычлану — көрәш тойгысы бетте дигән сүз. Организмның каршылык күрсәтү сәләте — иммунитеты — бетте дигән сүз.

Сәяси кыенлыклар аркасында, мәдәният өлкәсендә дә уңышлар шатланырлык (бигрәк тә — мактанырлык) була алмады. Культура әһелләре, шул исәптән язучылар авыр хәлдә яши бирәләр. Әсәрләргә түләү иң түбән дәрәҗәдә. Газеталарда чыккан мәкаләләргә алынган акча, мәсәлән, бер мәртәбә мунчага барырга дә җитәрлек түгел. Югары оешмалардан бирелгән «хәер акчалары» мәсьәләне хәл итә алмаячак. Боларны ваклык дип атыйкмы? Ләкин дөресе шул бит, нишлик соң?

Полиграфик мәйдан мәсьәләсе. Үзгәрдеме? Әйе, начар якка. Нәшриятыбыз мәгълүм сәбәпләр аркасында үзенең китап чыгару күләмен бермә-бер киметергә мәҗбүр булды. «Мәгариф» нәшриятыннан кала, аңа ярдәм итәрлек башка нәшриятлар барлыкка килмәде. Барлыкка килде дигәннәренең бөтен эше болай да барлы-юклы полиграфик базада милли әдәбиятны кысрыклауга, сәнгатьтән ерак торган ыбыр-чыбыр продукция бастырып чыгаруга кайтып калды.

Кысынкы шартларда әхлакый проблемалар көчен җуймады гына түгел, бәлки кискенләшә генә барды һәм шулай дәвам итә.

Агай-эне — ак мыек... әһле әдәбият шул тәртип белән гөр килеп яши бирә.

Тормыш үзе шулай куша дип, акланырга җай бардыр. Димәк, без (әгәр киләчәктә адәмчә яшәргә теләсәк), тормышның, дәвернең үзеннән көчлерәк булырга тиешбез һәм, бәлки, шуңа дучарбыз.

Каршылыкларның җиңелә баруына ышанасы, һич югы өметләнәсе килә.

* * *

Үзең язу белән бергә, сирәк-мирәк, башкаларның язганын да уку кирәк,— дигән акыллы шагыйрьләребезнең берсе.

Дөнья әдәбиятын искә алмастан, газетада һәм журналда эшләгән елларда башкаларның әсәрләрен уку гына түгел, әлбәттә инде редакцияләргә, язмышларын хәл итүгә күп тапкырлар катнашырга туры килде. «Совет әдәбияты»нда Ә. Еникинең «Рәшә», А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестьларын, әгәр дә мин ныклап якламаган булсам, көрәшмәгән булсам, ул вакытта, ай-һай, чыга алган булырлар иде микән, дип уйларга җөрьәт итәм.

1970 еллар азагында «Казан утлары»на яңадан килгәч, чираттагы эшләрне дәвам иткән хәлдә, нинди әсәрләрнең басылмый ятуы, кире кагылуы белән кызыксындым. Шуларның берсе М. Мәһдиевнең «Гомер агышлары» исемле повесте иде. Өлкә комитетындагы иптәшләр вето салган, главлит уздырмаган. Шуны укып, яңадан хәрәкәткә җибәргәч, редакцияләгәч, «Кеше китә — җыры кала» исемле повесть, язучының иң камил дип саналган әсәре дөньяга чыкты. Гәрчә автор әсәрнең язмышын хәл иткән һәм редакцияләгән кешеләрне онытса да — баш редактор урынбасарына һәм проза бүлеге редакторына түгел, ә бөтенләй ул чакта бүтән урында эшләгән иптәшләргә рәхмәт әйтсә дә — бу гамәлне мин әдәбиятыбызга күрсәтелгән игелегемнең бер мисалы буларак хәтергә төшерәм. Мондый мисалларны байтак санарга мөмкин булыр иде, дип уйлыйм. Бу яктан үкенергә туры килгәне юк. Ә менә әсәрләрдән тыш, кешеләр язмышын хәл иткән очракта, хәзергә хәтле уйландырган бер вакыйга булды, дияргә туры килә.

Газетада эшләгән вакытта, мин Татар дәүләт академия театрында художество советы әгъзасы идем. Байтак пьесаларны һәм спектакльләрне кабул иткәндә, шул исәптән Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал», И. Юзеевнең «Янар чәчәк» әсәрләрен кабул иткәндә, чыгыш ясап, нигездә уңай бәя биргәнем хәтердә. Ә үкенүгә якын мисал дикюем болайрак.

Алтмышынчы еллар башында, Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлап, бер төркем яшь артистлар кайтып төште. Буш урыннар җитәрлек түгел. Ә яшьләрне эшкә алырга, театрның киләчәген кайгыртырга кирәк. Шуңа күрә, конкурс үткәрелеп, кайбер артистларны кыскарту мәҗбүри булып чыкты. Мәсьәлә художество советына куелды.

Мин Азнакай ягында чираттагы командировкада идем. Бермәлне район газетасы редакциясенә керсәм, миңа үзебезнең газета редакторына шалтыратырга тиешлегемне әйтәләр. Шалтыратам. Командировканы бүлеп, Казанга кайтырга кушыла. Өлкә комитетыннан шундый әмер бирелгән. Көнендә үк самолет белән очып кайткач, культура бүлеге мөдире Булат Гыйззәтуллинга шалтыратам. Кереш сүзләрсез үк шундый хәбәр:

— Иртәгә театрда худсовет утырышы. Анда сезгә мәҗбүри катнашырга кирәк.— Һәм хәбәрнең азаккы өлеше русча әйтелә: — Там все обговорено.

Аңладым, билгеле. Ләкин уйланырга урын да калган иде. Утырышта — капма-каршы ике фикер. Яшьләрне кабул итәргә. Гәүһәр Камалова һәм Асия Харисова кебек атказанган артисткаларны театрдан мәхрүм итәргә кирәк. Кеше язмышы. Җайсыз хәл. Кешеләр икегә аерылган кебек, күңелдә шундый ук каршылык. Нишләргә?

Баш режиссер (Ш. Сарымсаков) фикер әйтмичә утыра. Сүз әйтергә миңа чират. Чыгышымның бер өлеше: «Баш режиссерның сүз әйтүе кирәк иде. Бәлки безнең карашлар ачыклана төшәр иде». Мин соңыннан сәеррәк фикер әйттем бугай:

— Соңрак, яңа конкурс игълан итеп, ул иптәшләрне театрга кире кайтарырга мөмкин бит?

— Ничек мөмкин булсын?

Сорауга каршы — сорау. Димәк, хәл итү — һәркемнең үз эше. Һәркемнең үз эше тавышка куелды. Бер тавышка өстенлек белән яшьләр кабул ителде.

Бер тавыш белән. Кем тавышы? Күтәрелгән кулларның берсе хәл иткән булып чыга. Алар күбәү. Ләкин икенче көнне Мәскәү вәкиле — кем булып эшләгәнен белмим — минем янга килде. Хатын кеше.

— Баш режиссерның чыгыш ясамавына карата сез дөрес замечание ясадыгыз,— ди,— ләкин... Ялгыш тавыш бирдегез. Әгәр сез икенче төрле тавыш бирсәгез, Камалованы чыгара алмыйлар иде. Әйбәт артистка...

— Икенче төрле тавыш бирсәм, яшьләр кала. Алар белән нишләргә?

Ханым нишләргә икәнен үзе дә әйтә алмый. Аңа бары тик әйбәт артистка кызганыч. Минем өчен дә шулай ләбаса. Сөйләшүдән мәгънә юк. Поезд киткән.

Соңыннан ачыкланганча, яшь артистларның да барысы да бер дәрәҗәдә булмаган икән. Аларның кайберләре, безнең ышанычны аклый алмыйча, театрдан киттеләр. Чыгарылган артисткаларыбыз кире кайттылар. Әмма ишетүемчә, Гәүһәр Камалова да, аның әнисе Фатыйма апа Камалова да миңа нык рәнҗегәннәр, тиргәгәннәр. Асия Харисова, очрашкан чакта, инде ничә дистә елдан соң, үпкәсен һаман сиздерә. Ни өчен тәгаен миңа? Нишләп хәл итүче тәгаен мин булып чыктым икән? Бүтәннәргә түгел, ник миңа рәнҗиләр?

Акланырга мөмкинлек бар, ләкин акланасы килми. Сабак булсын. Бүтән юлы кемнең кем икәнен (бу юлы яшь кешеләрнең мөмкинлекләре нинди булып чыгачагын) алданрак белергә тиешсең. Белмәсәң, катнашма. Сабак булсын...

Сабак онытылмады. Икенче юлы, Татар дәүләт филармониясе художество советы утырышында, шушыңа охшашлы хәлдә үземне дөресрәк тоттым дия алам.

Миңа таныш булмаган артистлар. Гади тел белән әйткәндә, фокусчылар. Филармониянең репетицияләр залына күтәрелгәч тә, бер абый, күптән таныш кеше сыйфатында, кояштан яктырак елмаеп, баш иеп исәнләште дә хәл белән таныштырды. Пенсиягә ике генә ел калган, ә аның штатын кыскартмакчылар. Гомер буе яраган, хәзер килеп яраксызга чыгармакчылар. Сынамак өчен алардан яңа программа әзерләткәннәр дә, хәзер шуны безгә күрсәтәчәкләр икән. Мин, аны-моны уйлап тормастан, катгый рәвештә:

— Пенсиягә чаклы чыгармаска тиешләр,— дигәч, шушы сүзгә абзыйның ничек сөенгәнен күрсәгез! Әйтерсең, бөтенесен мин хәл итәм. Икенчесе — хатын-кыз, маржа апа. Ул да, тыйнаграк булса да, шушындый ук реверанс ясагач, анысына да баягы сүземне кабатладым. Тагын бер-ике артист бар иде шикелле. Истә ныклап калганы — шушы ике кеше. Алар белән сүз беткәннән соң, залга уздым. Художество советының башка әгъзалары белән дә сөйләштеләрме, юкмы, белмим. Әмма шунысы хак, миңа беренче сүз кушкан артист үзенең иллюзион номерларын күрсәткәндә, тамашачылардан ярдәмгә чакырган шаһит сыйфатында мине сайлап, нииндидер әйберләрен минем кесәдән табып алды. Кыюлыгым җитми торса: «Шикләнмәгез, әйбәт булачак!» — дип, тынычландыра иде.

Имтихан концерты тәмам. Утырыш. Аны филармониянең директоры — Первин фамилияле яһүд абзый алып барды. Торып баскач та, үзенчә бик оста рәвештә безне дөрес курска кертергә, юнәлеш бирергә тырышып, ихлас елмайды:

— Болар миңа кирәкми. Булмасалар да юксынмас идем. Бригадаларга да кирәкмиләр.— Шулай дигәч, безнең рәттә утырган Илһам Шакировка елмайды.— Илһам да аларны алмас иде.

Ә мин реплика ташларга ашыктым:

— Анысын инде Илһамның үзеннән сорарга кирәк.

Илһам сүзсез елмайган мәлдә, абзый миңа сагаеп карады. Танышлык чамалы. Бүтән чакта худсовет утырышларында бик катнашмый иде. Ниятемне сизгәч, ул миңа сүз бирергә ашыкмаячак. Әлегечә, репликаларга исәп тотарга кала.

Первин иптәш, утырышның камертонын бигүк уңышлы чиртә алмавына аз гына да борчылу сиздермичә, баштагыча шаян тавыш белән дәвам итте:

— Ярый алайса, фикер алышыйк, уйлашыйк.

Минем янда гына күренекле артисткабыз Зөләйха Хисмәтуллина утыра. Ишетелер-ишетелмәс кенә, татарча: «Пенсиягә хәтле аларга кагылырга ярамый, әлбәттә»,— дип, гүяки үз алдыма сөйләнеп куям. Ә директор шулкадәр сизгер, минем адрессыз үгетне дә бүлдерер өчен:

— Зөләйха Гатаулловна, сезнең сүзегез бар шикелле,— дип, аны ашыктыра.

Ләкин Зөләйха апа, ерактанырак булса да, һәм сынауга куелган артистларның чыгышына мөкиббән китмәвен сиздерсә дә, хәлне төшенгән иде.

— Алар ва-банк бардылар! — дип, томанлырак бәяләрдән соң, нәтиҗә чыгарып: — Шулай да... шулай да, пенсиягә хәтле түзәргә мөмкин,— дип сүзен ачык әйтте.

— Әйе,— дип, җөпләргә ашыктым мин,— түзмәслек түгел, программа хәтта кызыклы бит.

Иптәш Первин миңа бөтенләй илтифатсызга әйләнде, сүземне ишетмәс булды. Мәгәр соң иде. Художество советы әгъзаларына шәфкать тәмам йоккан иде инде. Калганнар да Зөләйха Хисмәтуллина төслерәк сөйләп чыккач, күпчелек тавыш белән: артистларны пенсиягә чаклы штатта калдырырга, дигән карар кабул ителде.

Татарстан радиосының художество советында һәм «Казан утлары» журналы редколлегиясендә озак еллар безгә Сибгат ага Хәким белән янәшә эшләргә туры килде. Катгый сүз әйтергә кирәк чаклар күп булса да, бу оешмаларда кешеләр язмышы хәл ителерлек дәрәҗәдәге каршылыклар очрамады. Татарстан язучылар берлеге идарәсендә 1974 елдан шушы көннәргәчә эшләгән дәвердә дә, үкенерлек гамәлләргә дучар булмадым дия алам. Әмма әдәби фонд идарәсенә килгәндә, алай ук кистереп әйтергә кыенсынам бугай...

Татарстан язучыларының унберенче съездында (17—18 май, 1989 ел) сайланган идарәнең беренче оештыру утырышы алдыннан идарә рәисе Ринат Мөхәммәдиев шалтырата. Гадәттәгечә, хәл-әхвәл сорашу. Эшкә кучәбез. Идарә әгъзаларына вазифалар йөкләнә. Җөмләдән, миңа да шактый җаваплы эш тәкъдим ителә — Әдәби фонд идарәсе рәисе вазифасы. Бераз уйларга вакыт сорыйм.

— Уйла, Әхсән абый, тик баш тартмаска тырыш инде.

Кайбер язучылар белән киңәшкәннән соң, ризалык биреп шалтыраттым. Идарәдә, башка эшләр белән беррәттән, минем вазифа да расланды. Ринат әйткәнчә, хәзер идарә әгъзасы мактаулы исем генә түгел, ә бәлки җитди эш башкаручы.

Әйбәт кенә эшләп киттек. Еллар буе, дияргә кирәк. Әмма дөнья без теләгәнчә генә барса икән лә. Үзгәртеп кору афәтләре үзенең хәтәр зәхмәтләре белән, беренче чиратта дияргә ярыйдыр, язучыларга ташланды бит.

Эшләр җайсызлана башлагач, Әдәби фондта моңарчы көйле генә эшләп килгән Шаһинур Мостафин, 1992 ел азагында директорлыктан китеп (моңа, мөгаен, айлар буе тиешле хезмәт хакын ала алмау һәм йөрәк өянәкләре дә сәбәпче булгандыр), үз урынына Рафис Корбанов дигән яшь шагыйрьне тәкъдим итте. Аның теләге булуын да исәпкә алып.

Яшь иптәш беренче көннәрдән үк үзен яңа тарихи шартларга муафыйк кәсепче итеп күрсәтергә тырышты. Ә без исә, мондый гамәлләрдә — ике кулсыз. Шул сәбәп аркылы, яңа директорның инициативаларына комачау итмәскә, юл бирергә бурычлыбыз.

Ә планнар зурдан. Тиз арада Биектау районында без дистәләрчә еллар буе төзергә хыялланган иҗат йорты салына башлаячак. Директор аның проект сызымнарын үк күрсәткәч, мин, мәсәлән, аһ иттем. Район хакимияте инде җир дә бүлеп биргән икән. Карар — кулыбызда. Өстәвенә, сәүдәгәрлек белән баеп китәчәкбез, имеш. Директор үзенә бу эштә ярдәмгә үзеннән дә зуррак хезмәт хакы белән урынбасар чакырып китерде. Төзелеш эшләре белән матди байлыклар тудыру өчен махсус бригада,

язучыларга юридик ярдәм күрсәтү өчен консультация бүлекчәсе, медицина пункты булдыру... Берсеннән-берсе матур башлангычлар, әйе бит? Мондый эшләр кузгаткан кешегә ничек итеп юл сапмыйсың инде! Ә юл сабу шуннан гыйбарәт булды.

Мәсьәләне хәл итү өчен мин Әдәби фонд идарәсен җыяргә тәкъдим иттем. Мәгәр яшь иптәш, моны кабул итмичә, барлык язучыларны гомуми җыелышка чакырып, хатлар җибәргән.

Җыелыш алдыннан яңа тәкъдим. Яңа башлангычларга киң мәйдан ачылсын өчен яшь иптәшкә директорлык вәкаләтләре тар икән. Икәүдән-икәү очрашкач, ул миңа серен ача:

— Әйдәгез, Әхсән абый, эшләрне алмашыйк, сез директор булыгыз, ә мин — председатель. Сез мине тәкъдим итсәгез... Сезгә дә хезмәт хакы булыр. Бу заманда бушка эшләп булмый бит.

Көтелмәгән тәкъдимнән күңелемдә бераз гына шик туса да, аны шундук җиңеп, киләчәккә булган зур уңышлар хакына ризалык бирдем:

— Бик рәхәтләнеп,— мин әйтәм,— сине председательлеккә тәкъдим итәчәкмен.

Ә конференция җыелды. Язучыларның алтмыш проценты килгән. Кворум җитә.

Җыелышны кереш сүз белән үзем ачтым һәм алып бардым. Сүзнең төп мәгънәсе шуннан гыйбарәт:

— Татарстан язучыларының Әдәби фонды исемсез һәм паспортсыз калды. Ул элек РСФСР язучылары Әдәби фондының Татарстан АССР бүлекчәсе дип йөртелә иде. Татарстан Язучылар союзы идарәсе РСФСР Язучылар союзы белән договор төзегәч, һәм аннан рәсми аерылгач, безнең Әдәби фонд бүлекчәсе дә гамәлдә бүлекчә булудан туктады. Аның мөһере элеккечә калганлыктан, хәзер дәүләт банкы бу исем белән безне кабул итми. Без, димәк, финанс эшләреннән коры калдык. Димәк, Әдәби фондка исем кушарга кирәк.

Статус мәсьәләсе. РСФСР әдәби фондыннан аерылгач, безнең Әдәби фондны мөстәкыйль юридик зат итеп үзгәртү мәсьәләсе куела.

Әдәби фондның уставы искерде. Яңасын тикшереп, кабул итәсе бар.

Әдәби фонд идарәсен яңарту турында тәкъдим бар.

Әдәби фонд Россия әдәби фонды тарафыннан финанслана иде. Бу керемябылгач, безнең фондның хәле авырайды. Аның акчасы штатны сакларга да җитми хәтта. Язучыларга ярдәм итә алмаган оешманың кирәге калмый. Димәк, аңа кәсепчелек белән шөгыльләнерлек вәкаләтләр кирәк. Яңа директор шундый вәкаләтләр сорый.

Шушы мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк. Сездән фикерләр көтәбез.

Көн тәртибе көтелмәгәндә куелган очракта була торган тынлык.

— Нишлибез? Сөйләшмибез дисәгез, таралышырга мөмкин.

Мин шулай дигәч, янымда утырган директор көлеп куйды.

Әгәр дә Әдәби фонд идарәсенең миңа кадәрге председателе — хәзерге идарә әгъзасы Азат Әхмәдуллин:

— Җыелгач, сөйләшергә кирәк! — димәсә, ни булыр иде икән?

Аның кыю авазын кабатлаучылар булды. Әңгәмә башланды.

Чыгыш ясаучыларның берсе минем кереш сүзне үстерде.

Бер кеше еллар буе үгез асрый икән. Шуны җигеп, еллар буе печән ташый. «Үгезне ни өчен асрыйсың?» — дип сорыйлар моннан... «Печән ташырга үгез кирәк бит». «Ә печәнне ни өчен әзерлисең?» «Үгезгә печән кирәк ләбаса».

Фондның мондый хәле белән, әлбәттә, килешү мөмкин түгел. Базар башбаштаклыгында үзенә һәм үз әгъзаларына ярдәм итә алырлык оешма булдыру фикерен куәтләделәр. Тавышка куйгач, күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы язучыларының мөстәкыйль әдәби фонды дигән статус билгеләнде. Яңа устав кабул ителде. Дүрт еллык вәкаләт белән яңа идарә сайланды.

Идарәнең беренче утырышы. Анысын да мин ачтым.

— Җыелышта бу хакта сөйләштек инде. Директорыбыз кәсепчелек һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнү өчен әлеге вәкаләтләр җитәрлек түгел дип саный. Ул идарәнең председателе булырга тели. Мин Рафис Корбановны председатель итеп сайларга тәкъдим итәм. Шуңа кушылуыгызны үтенәм. Сез ризамы?

Идарәгә әле генә сайланган язучы Мәгъсум Хуҗин, минем кебек үк, яңа башлангычларның уңышлы барып чыгачагына ышанган иде булса кирәк, катгый төстә:

— Әйе, без риза,— дип кул күтәрде.

Тавышка кую белән мәсьәлә хәл ителде.

Шушы ук утырышта мине директор һәм председатель урынбасары итеп сайладылар. Фәнзаман Батталның: «Үзе ризамы соң?» — дигән соравына Корбанов: «Без алдан сөйләшкән идек,» — дип җавап бирде. Әйткәнемчә, мин риза, эшләр генә барып чыксын.

Шулай итеп, идарә, базарга кермәк булып, яңарды. Илле дөресен әйтим, күңелдә ышаныч тудыра алырлык гамәлләр күзгә чалынмады шул. Киресенчә, бик тә сәер тормыш башланды. Акча туздыру җәһәтеннән зур эшчәнлек гөрләде. Югары эш хакы белән директорның коммерция буенча урынбасары аркылы сәүдә кызды. Яңа рәисебез идарәдән юридик консультация, медицина пункты, төзелеш бригадасы оештыру хакында карар кабул ителүен сорады. Карардан эш калмаса да, бары тик кәгазьдә генә калды...

Тормыш шулай дәвам итте. Бер көнне Союз идарәсенең киңәйтелгән утырышына чакыралар. Төп мәсьәлә: Әдәби фонд — банкрот. Р. Корбанов эштән китү хакында гариза биргән. Әдәби фонд идарәсенә түгел, үзе аерылып чыккан Союз идарәсенә...

Союз идарәсендә бәхәс тумады. Карар: унбер кешедән торган идарә биш кешегә калдырылып, Әдәби фондны бөтенләй таркатмас өчен бер штатка — бухгалтерга хезмәт хакы табарга вәгъдә итеп, мөмкин булганча эшли торырга кушылды. Союз идарәсе карарына рәсми төс бирер өчен, без Әдәби фонд идарәсен җыярга тиеш булдык.

Утырышны мин алып бардым. Хәлне аңлатканнан соң, беренче сүз:

— Идарә эшләренә бер кешенең — председательнең генә җитәкчелек итүе аркасында, аның эшләре контрольсез калды. Шул сәбәпле зур хаталар килеп чыкты. Нәтиҗә күз алдында, без — банкрот. Корбановның эштән китү турында гаризасы бар. Нишлибез, җибәрәбезме, юкмы?

Ходайның хикмәте, җибәрмибез, диючеләр табылды. Корбанов: «Мин бушка эшләргә җыенмыйм»,— дигәч кенә, җитдиләнделәр. Карар кабул ителде. Чиратта — төп мәсьәлә:

— Әдәби фонд идарәсен саклап калабызмы, әллә үзебезне үзебез таратабызмы?

— Саклап калырга кирәк.

— Алайса, аның председателе булырга тиеш. Кемне сайлыйбыз?

— Идарәнең элекке председателе бар бит, шуны,— диделәр.

Тәкъдимне тавышка З. Мансуров куйды. Ягъни, тагын мине сайладылар. Бернинди финансларсыз тагын яши киттек. Аннан соң ничек көн күрүебез хакында миңа Татарстан язучыларының 12-съездында сөйләргә туры килде. Хәлне кыскарак аңлату нияте белән шул чыгышны хәтергә төшерәм. Кыскарта төшкәндә менә шулар:

*«Әгәр патшалар еш алмашынып торса, моның илдәге хәлләрнең нинди дилеген күрсәтә торган галәмәт икәнен без яхшы беләбез. Фонд директорларының ни өчен китә торуын да шул мәгънәдә аңларга мөмкин. Турысын әйткәндә, хәлебез мактанырлык түгел. Беренче һәм хәлиткеч сәбәп финанс дигән нәрсәгә кайтып кала. Татарстан хөкүмәте безнең Әдәби фондны үз бюджетына сыйдыра алмады. Бүтән килер җир юк. Шул рәвешле, Әдәби фонд фондсыз калды.*

*Съезд алдында информация ясау хакында сүз чыккач, кайбер иптәшләр: «Әдәби фондны ничек итеп таратуыгызны сөйләрсез инде»,— дип, шаяртырга тиеш тапты. Мондый сүзләрнең чынлап әйтелгәннәрен дә ишеткәләгәнгә күрә, моңа җавап бирергә кирәктер. Ә җавап шулдыр: кыргый базар афәтләрен без уйлап чыгармадык. Әдәби фонд идарәсе илдә иң фәкыйрь бәндәләр булып язучылар калсын дип тырышмады.*

*Әйе, элгәрге байтак автономияле, хәтта союздаш республикаларда Әдәби фонд вазифалары язучылар союзлары идарәләренә тапшырылып, фонд булудан туктады. Аңлашылса кирәк, безнең монда катнашыбыз юк. Ә безнең хәл исә, бераз икенчерәк. Рәсми яктан караганда, аны хәтта әйбәт дияргә дә җай юк түгел.*

*Татарстан язучыларының әдәби фонды Халыкара иҗтимагый-әдәби фонды составына кабул ителде. Ягъни, аның статусы элеккеге союздаш республикалар әдәби фондлары статусы белән тигезләште. Иҗат йортларына юлламаларны хәзер шуннан алабыз.*

*Ачыклык өчен шуны да искә төшерергә туры килә. Союз идарәсендә бу яңалыкка каршы кешеләр дә бар иде. Ә без, Халыкара иҗтимагый-әдәби фонд составына керү өчен мөстәкыйль рәвештә документлар әзерләп, идарә әгъзасы булган М. Хәбибуллинга вәкаләт бирдек. Документка мин кул куйдым. Вәкилебез аны Халыкара әдәби фонд идарәсенә тапшыргач, мәсьәлә уңай хәл ителде. Иҗтимагый шартлар шуңа мөмкинлек бирде. Күрәбез ки, бу — бер генә кеше хезмәте түгел.*

*Акча керемнәре тукталганнан соң, Әдәби фонд штатында бердәнбер берәмлек булып, бухгалтер калды. Ул фондның булган мөлкәтен саклаучы да, бүлмәләрне тәртиптә тотучы да, бермә-бер кимегән төп вазифаларны үтәүче дә — үзе.*

*Мөлкәт хәзергә тулысынча исән. Аккош күлендәге дачаларны искә алмаганда. Аккош күлендәге дачалар, Союз идарәсе карары белән, шунда озак яшәгән язучыларга бушлай бирелде.*

*Алдагы көннәр хакында.*

*Мин киләчәкне бөтенләй өметсез димәс идем. Ләкин моның өчен кайбер шартлар кирәк булачак. Татарстанда авторлык хокукларын саклау оешмасы ныклап эшли башларга тиеш. Әдәби фондка аның аша күпмедер акча керә алыр иде.*

*Шул ук вакытта республикада китап басу эшен юлга салу хәлиткеч чараларның иң әһәмиятлесеңдер. Китап басудан килгән күпмедер процентның Әдәби фондка күчүе законлы хәл. Әгәр китап басылмый икән, Әдәби фондның гына түгел, ә гомумән, язучыларның керәге калмый, диғән сүз. Базарга безнең хәзер үк инде керәгебез бик тә чамалы.*

*Базар дигәннән, әлбәттә, Әдәби фондка кәсепчелек тә рөхсәт ителә. Моның белән шөгыльләнсен өчен бермәлне без директор итеп бер яшь иптәшне куеп карадык. Король Лир шикелле, үзебезнең барча вәкаләтләребезне аңа тапшырдык. Ул эшләп тә карады, сату итте, зур-зур планнар корды. Мәгәр кәсеп шундый булып чыкты ки, фондның соңгы тиеннәре, төтенгә әйләнеп, торбадан очты.*

*Әдәби фондка язучыларның үзләреннән өлеш кертү хакында да уйлыйсы бар. Тарихка күз салсак, иң әүвәл кирәк чакта ярдәмләшү өчен фонд язучыларның үз акчаларыннан җыелган бит. Безнең заманда исә, кассадан акчаны алу хакында гына сүз бара. Ахрысы, шундый заман җитте ки, кирәк чакта синең турыңда кайгыртсыннар өчен Әдәби фонд язмышы хакында барыбыз бергәләп һәм берәм-берәм хәзер без кайгыртырга тиеш булабыз...»*

...Чыгыш әнә шулай тәмамлана.

Съездан соң бер ел вакыт узды. Авторлык хокукларын саклау оешмасы эшли башлагач, Әдәби фонд әзме-күпме тернәкләнә башлады, дияргә була. Инде китап басу эшенең җанлануын көтәргә кала.

* * *

Элеккерәк елларда: «Китап — иң әйбәт бүләк!» — дигән сүзләр еш ишетелә иде. Соңгы вакытта онытыла төште. Һәрхәлдә, минем ишеткәнем юк диярлек. Әмма хәзер дә шундый фикер белән яшәп ятам. Китапны бүләк кенә түгел, иң әйбәт бәйрәм дип тә беләм. Бу караш миндә күптәннән бирле ныгып урнашкан.

Өченчеме, дүртенчеме класста укыган чакта, мәктәп китапханәсеннән Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен алып чыккан идем. Китапны сумкага салмадым. Кулда тотып барам. Адым саен дип әйтерлек, күз ташлап, кулдагы бәхетемә сокланам. Аяклар җиргә тими.

Китапның тышында — диңгез сурәте. Болай зур да түгел үзе, кечкенә. Ләкин диңгез диңгез инде ул, дулапмы дулый. Зәңгәр чиксезлектә ак дулкыннар йөгерешә. Китап тышлыгында гына түгел, хыялда гына да түгел, әйтерсең ки, тормышның үзендә, мин атлаган кыр буйлата тезем-тезем булып йөгерешә чал дулкыннар. Алар — минем аяк астында. Шуларга, тезем-тезем дулкыннарга баса-баса, мин дә йөгерәм.

Чалт аяз көн. Кояш нәкъ минем шатлыгым төсле балкый. Җил. Тыгыз февраль җиле. Җәяүле буран. Рәт-рәт булып кыр буйлата агылган, юк, диңгез буйлата чабышкан дулкыннар шул бит инде. Ак дөнья, зәңгәр дөнья минем белән бергә шатлана. Ул көнге шатлыктан ихласрак бәйрәм хисе тоюымны хәтта хәтерләмим дә кебек. Шундый хис белән өйгә кайтып җиткәч, шундый ук сөенеч белән, китапны бер утыруда укып та чыктым. Кояш баеп эңгер төшкәч, соңгы битне яптым. Әсәр үзе дә кичке шәфәкъ төсләре белән тәмамланды. Акчарлаклар тавышы белән...

Мондый күренешләр төгәл генә кабатланмаса да, китап аркасында килгән бәйрәмнәрем күп булды. Шунысын да әйтим, еллар уза торгач, нәүбәте җитеп, үземнең дә утыздан артык китабым басылып чыкты. Әмма ак дулкыннарга баса-баса йөгерерлек үк шатлык тоярга туры килмәде. Шуңа күрә әйтүем, укучы шатлыгы язучы шатлыгыннан зуррак булырга да мөмкин икән...

Нәшрият кешеләре шулай күпме укучыга бәхет тараткан, бәйрәм китергән. Шуннан изгерәк эш хәтта юктыр да сыман.

Басылып чыккан китаплар санынча булмаса да, онытылмас эшләр күп. Җитмеш ел эчендә аларның саны югалгандыр да инде бәлки. Әмма бер нәрсә югала алмас, татар классик әдәбиятын барлыкка китергән әсәрләр — җыентыклар, томнар.

Үсеш сугыш алды елларында, хәтта сугышның үз елларында да тукталмый. Ә менә хәзер, тыныч заманда... Хәлебез шундый ки, Татарстан дәүләте үзенең ике бөртек нәшриятына да тиешенчә ярдәм күрсәтә алмый. Аны кыргый базарга тапшыра. Тагын да уйлый төшик, халыкны әдәбият кебек бөек рухи азык белән тәэмин итә алмаган дәүләт ул нинди дәүләт булыр?

Китап чыгаруның асылда тукталуы язучылар иҗатына, аларның көнкүрешенә тәэсир итмичә калмады. Аларның күпчелеге хезмәт хакыннан мәхрүм калды.

Дөрес, президент фондыннан азмы-күпме ярдәм күрсәтелә килде. Ләкин, беренчедән, бу ярдәм язучыларның тормыш хәлен җиңеләйтә алырлык булмаса, икенчедән, әхлакый яктан кирәкле нәрсә түгел. Эшләмәгән өчен акча алу кешелек дәрәҗәсенә суга. Бушка акча алудан оялмый торган, хәтта шуны алу өчен низаглаша торган адәмнәр барлыкка килде...

Шушы уңайдан, күптәннән бирле хәтердән чыкмый торган, китапка кагылышлы тагын бер очракны искә алыйм әле. Бишенче, алтынчымы класста укыган чак. Сугыш вакыты. Булган китапларның барчасы укылып, ятланып беткән. Яңалары авыл кибетләрендә юк. Китапханәләр ябык. Район үзәгендә «Культмаг» дигән кибеттә бар — рәт-рәт тезеп куелган китаплар. Авылыбыздан унике чакрым ераклыктагы шул кибет-

кә барып йөрим — китапларга карап кына булса да торыр өчен барам. Сатып алырга, билгеле инде, акча юк.

Шулай ничә мәртәбә барганмындыр, әйтә алмыйм. Мәгәр шунысы хәтердә уелган, сатучы апа миңа игътибар итте. Бер көнне елмаеп каршылады. Мин китапларга кызыгып тагын бераз торгач, сүз кушты:

— Складка барып китаплар алып киләсе бар иде. Ярдәм итә алмассыңмы икән?

Мин уйлап тормыйча да риза булгач, кибетне тиз генә бикләде апа. Чама белән ярты сәгать эчендә склад дигән җирдән зур гына төргәк китаплар күтәреп китердем. Эчкә кергәч, апа төргәкне чишеп тә тормастан, киштәләрнең берсеннән мин кызыккан китапларның берсен алып, миңа сузды:

— Сиңа эш хакы түләргә акчам юк. Риза булсаң, менә шушы китапны ал.

Ямь-яшел тышлы «Колхида» исемле китап. Язган кешесенең фамилиясе — Паустовский. Мәктәптә географиядән без үткән темаларның берсе — субтропик зона табигате турында. Һич арттырусыз — кош тоткандай сөенеп кайту белән сукыр лампа яктысында төн буе укыдым. Бигүк мавыктыргыч түгел икән. Шулай да, апа-абзыйларның агачлар, чәчәкләр үстерү, шул яшеллекләр эчендә сөйләшүләре һәм андагы табигать үзе матур хатирә булып күңелемдә саклана. Мәгәр бу очракны искә төшерү максаты сатучы апага карый. Мөгаен, ул миңа китапны бушка бирергә дә теләгәндер. Ләкин мине бушка алырга өйрәтмәс өчен, кешелегемне кимсетмәс өчен ул миңа эш бирде, эш өчен түләде...

Менә бит китап сатучы апалар нинди булган. Ә аны яза торган кешеләр? Лаеклы булмаган хәлдә акча (һәм башка төрле бүләкләр) алу өчен тырышкан, әхлак дәрәҗәсе хакында уйламаган кеше язучы була аламыни? Уйласаң, уңайсыз булып китә...

Әйе, миңа үз гомеремдә утыздан артык китап чыгару насыйп булды. Хыялда туган калам диварларына алар да кирпеч арты кирпеч булып, һич югы минем карашымча, Казан тормышына азмы-күпме рухи байлык өстәгәндер, диясем килә.

Шуның белән бергә, гомумән, татар китабын башка калаларга, башка республикаларга җиткерү эшендә дә, сөйгән калам вәкиле буларак йөргән чакларны искә аласы килә. Шуларның берсе — Башкортстан. Анда Тукай көннәре. Каршымда — зур зал тулы халык. Сүзне, гадәттәгечә, күңелле йоладан, йомыш үтәүдән башлыйм.

— Хөрмәтле иптәшләр, дуслар, кардәшләр!

Үзегез беләсез, татар язучылары Башкортстан турында сүз барганда тыныч кына кала алмыйлар. Бу юлы да шулай: безнең Уфага баруыбызны ишеткәч, телефон аша да, болай күрешкәндә дә үзләренең сәламнәрен әйтергә ашыктылар. Әманәткә хыянәт кылмыйча, бер дә авырсынмыйча, без ул сәламнәрне юлда түкмичә һәм чәчмичә, китереп җиткердек һәм шуларның барчасын ихлас күңелдән сезгә тапшырабыз. (Мондый сүзләрдән соң кул чабу гадәти бит? Шулай булды)...

Тукайның йөз еллыгы уңае белән Казанда гына түгел, илебезнең шагыйрьгә мөнәсәбәте булган күп кенә башка шәһәрләрендә дә Шигырь бәйрәмнәре уздырыла. Без, мәсәлән, Әстерханда узачак бәйрәмгә барырга тиеш идек. Ләкин үзегез күреп торасыз, без Уфа каласында булып чыктык. Һәм бу юлыбыз, ничектер, Тукайның үз юлын хәтерләтеп куйды.

Билгеле булганча, 1912 елның язында Тукай Петербург шәһәренә барырга җыена һәм «юл уңаеннан» Уфага килеп чыга. Казаннан Петербургка Тукайның иң туры юлы Уфа аша уза. (Шушы урында халыкның гөрләп кул чабуы әдәп хакына гына булмагандыр, диясе килә).

Шагыйрьнең бу маршрутын гадәти логика ярдәмендә аңлату, әлбәттә, уңышсыз эш. Әмма аны яхшы белгән кешегә бу шигъри хатаны аңлау кыен түгел. Ник дигәндә, әгәр ныклабрак уйласаң, Тукайның бөтен гомере, язмышы нәкъ шундый юл аркылы узган бит.

Кырлайдан киткәннән соң, Җаек шәһәрендә күпме генә вакыт эчендә үзенең бөек остазлары иҗатын, төрки әдәбияттан тыш, рус һәм Көнчыгыш әдәбиятын, гарәп-фарсы шигъри системаларын үзләштереп өлгергән.

Язмышыннан аңа иҗат өчен нибары җиде ел вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә ул ун мең шигъри юл һәм илле табак проза язып калдырган. Шул вакыт эчендә азатлык һәм мәгърифәткә караган барлык темаларны, шулай ук бөтен жанрларны — лирика, сатира, тәнкыйть, публицистика жанрларын буйсындырырга көч тапкан.

Җиде ел — биш том әсәр!

Могҗиза кебегрәк, ышану кыен шикеллерәк. Мәгәр могҗиза юк. Нәтиҗә күз алдында, без аны үз кулларыбыз белән тотып карый алабыз. Бик яхшы аңлашыла — Тукай бу нәтиҗәгә үзенә иң хас, иң туры юлдан килә алган. Дөреслек аша, хакны әйтә алу батырлыгы аша килгән. Юкка гына халык аны «Туры Тукай» дип атамаган бит.

Теләсә нинди шартларда халык уйлаганны әйтә алу аңа «язар азык» муллыгы биргән. Бу батырлыкны аңа чор һәм халык биргән. Халык аны үзе тәрбияләгән — күңеленә, холкы-фигыленә үз гадәтләрен, үз кичерешләрен, үз рухын салган. Шул юл белән татар халкының тарихи моңы шагыйрьнең әсәрләренә күчкән. Халык язмышы Тукай әсәрләренең төп мәзһәбен, эчтәлеген, музыкасын билгеләгән һәм барлыкка китергән. Бөтен сер шунда — даһилыкка иң туры юл халык йөрәге аша уза.

Иң кыска һәм иң туры юл!

Бу көннәрдә яңа гасырларга, яңа йөзъеллыкларга узып барышлый, Тукай үзенең шул таныш юлыннан тагын бер тапкыр, менә безнең белән Уфага килеп чыкты, дип фаразлыйсы килә. Ныклап уйласаң, шулай да ул. Без сезгә бүләк итеп алып килгән портрет шул·фикернең дәлиле түгелмени?

Бүгенге Тукай үзенең томнарында яши. Без аларны да алып килдек сезгә.

Тукайны аның остазларыннан берсе булган Кол Галидән башка күз алдына китерү кыен. Шуңа күрә без «Йосыф кыйссасы»н да Тукай китапларына кушып алып килдек.

... Бу очрашу 1986 елның 26 апрелендә булды.

Рәсми бүлек тәмамлангач, банкетка тартым кичке аш. Өстәл янында кичәне алып барган шагыйрь Мостай Кәрим, өлкә комитеты секретаре язучы Таһир Ахунҗанов, композитор Заһир Исмәгыйлов, Башкортстан язучылар берлеге рәисе Әсгать Мирзаһитов, шагыйрь һәм галим Гыйлемдар Рамазанов, Башкортстан Министрлар Советы председателе урынбасары Баймурзина (ай-ла, исемен әйтмәделәр), истә калмаган тагын кайбер язучылар, шагыйрьләр, галимнәр.

Минем урын Баймурзина янына туры килде. Икенче яктан үзем белән килгән Рәдиф Гатауллинга урын калдырдым.

— Рәдиф кайда соң? — дип сорый Мостай ага.

Рәдиф бер-ике ел Уфада укыган. Курсташ кызлары белән сөйләшкәнен күргән идем. Шуңа күрә:

— Рәдиф, гадәтенчә, кызлар белән,— дидем.

— Ә сезне кызлар кызыксындырмадымы? — диде бер шаян иптәш.

— Мин дә бит кызлар янында,— дим, янымдагы нык гәүдәле, чибәр ханымга ишарәләп.

— Ул — сезнең Мансур Хәсәнов урыныңдагы кеше.

Министрлар Советы председателе урынбасары дигән сүз инде бу. Зур җитәкче. Шуңа күрә:

— Кем янына утырырга кирәген беләм инде мин,— дигән булам.

— Белмәсәм дә диген,— дип, шаяртып дөресли Мостай ага.

Ризыкка чират җиткәч, (Горбачев «зирәклек» күрсәткән дәвер бит), Таһир Исмәгыйлович гафу үтенгәндәй:

— Банкет аракысыз гына инде,— дип, миңа елмая.
— Эчмәскә өйрәнеп киләбез инде,— дип, кунакка хас тыйнаклык күрсәтәм, янәсе.
Тагын ни?
Ун елга якын арадан соң, истә калганнары шулар.
Г. Рамазанов минем Башкортстаннан аерылмавымны искә ала.
— Әле күптән түгел генә «Аязучан болытлы һава» исемле повесте чыкты. Әйбәт кенә. Безнең Рахмановны Рамазанов дип алып, язган.
Мостай аганың хәмерсез дә кәефе шәп.
— Син аны үзеңә кабул итмәдеңме соң?— ди ул.
— Юк, алай кабул итмәдем.
Тагын нәрсәләр?
Композитор З. Исмәгыйлов безнең татар композиторы Рөстәм Яхинның хәлен сораша:
— Бу арада дөньяга чыкканы күренми, авырмыймы?
— Юктыр,— мин әйтәм.— Берәр зур әсәр язадыр.
Кызганыч ки, ул хаклы булып чыкты...
Аракысыз булса да, чын мәҗлестәге төсле күңелле генә утырдык. Мәҗлестән соң зур гына концерт күрсәттеләр. Анда да Казан темасы — әдәбияты, татар сәнгате үзәктә булды.
Концерт тәгәлләнеп, урамга чыккач, шагыйрь Рафаэль Сафин, минем чыгышны истә тотып:
— Тукайның үз кимәлендә булды,— дип кулымны кысты.
— Әхсән оялгандай гел тыйнак йөри үзе,— диде шулай ук кул кысканда Муса Гали.
Табигатем шундыйдыр инде, дип хисап бирергәмени?
— Эшләр оялырлыктыр инде, күрәсең,— дигән булам.
Уфа урамнары буйлап атлаганда, хатирәләр тагын яңарды. Әлеге дә баягы, Тукайга кагылышлы уйлар. Уфа авиация техникумында укып йөргән чак.
Математика укытучысы Фәхретдинов дигән абый (исеме һәм әтисенең исеме русчага көйләнгән, шуңа күрә микән, истә калмаган) дәрес вакытында төрле темаларга сөйләшеп алырга ярата. Ул кайчандыр Казанда яшәгән.
— Казан матур шәһәрме?— дип сорыйлар малайлар.
— Матур, әйбәт шәһәр.
— Уфадан да матурракмы?
— Уфаның үз өстенлеге — агачлар күп. Казан урамнарында агачлар азрак.
— Сез Тукайны күргәнсез, диләр.
— Дөрес, күрә идем.
— Ул ниндирәк төсле иде?
Бераз уйга калып, барыбызны да күздән кичергәч, абзыйның карашы миндә тукталды:
— Менә, Баяновка охшаган иде ул,— диде.
Валлаһи, билләһи.
Бу вакыт бөтен группаның күзе — миндә. Әңгәмәнең дәвамы да миңа кагылмыйча узмады. Абый киләчәктә кемнең кем булырга хыяллануын сорашты. Күбесе — авиатор, инженер.
— Ә син, Баянов, кем булырга хыялланасың?
Минем инде музыкант, композитор, юрист «булып караганым» бар. Хәзер исә сүз сөрешеннән икенче максат алга чыкты. Бераз элегрәк район газетасында кайбер шигырьләр бастырып өлгергән мин, уйлап тормыйча гына игълан кылам:
— Язучы булырга...
«Хыялланам» дип әйтер идем, тавышым чыкмады.
«Язучы! Язучы!» — дип көлеште малайлар, артык зурдан кубуымнан көнләшепме, гаҗәпләнепме.

Моннан соң күп еллар үткәч, инде мин чынлап та язучы булганнан соң, Баку шәһәрендә дә шундыйрак очрак булган иде. Ашуг Әлиәскәр юбилеена багышланган шигырь бәйрәме азагында, банкетта урыным шагыйрь Рәсүл Рза һәм аның хатыны каршысына туры килгән иде. Бераз сүз дә алмашып өлгергән идек. Алар Муса Җәлил белән таныш булганнар икән. Шулай сөйләшеп утырган бер мәлдә, кайбер башка тостлардан соң, Әзербайҗан Язучылар берлеге рәисе Мирза Ибраһимов татар халкының бөеклеген, Җәлил кебек герой уллары булуын искә алып тост әйткәч, миңа басып сүз әйтергә туры килде. Янымда гына бөек режиссер Сергей Образцов кояштай елмаеп карап тора. Каршыда бая әйткән Рзалар сүз көтә.

— Татар халкына, Җәлилгә карата әйткән олы бәягез өчен бик зур рәхмәт. Мин ул сүзләрне халкыма җиткерергә ысул табармын,— дигәч, Рза хатыны:

— Мәкалә язарсыз,— дип куйды.

Президиум ќебек өстәл янына барып (аларның чакыруын тыңламыйча булмый бит), җитәкчеләр белән рюмка чәкештергәннән соң, үз урыныма утыргач, Рәсүл Рза хатыны:

— Муса Җәлил сезгә охшаган иде,— дип өстәде.

Гаҗәпләнеп куйдым, әлбәттә. Бер үк бәндә ике кешегә охшый аламыни? Мин моны бер генә нәрсәгә юрый алам: мөгаен, Казан кешесе булачагым һәм булуым тумыштан ук минем маңгаема язылган булгандыр инде, дим. Чыраемда сөекле калам чалымныры чагылгандыр...

Төрле хәлләргә юлыкканмын, ачысын-төчесен күргәнмен. Әлбәттә, күбрәк — ачысын. Боегуымны, җиңелеп-югалып калуымны теләүчеләр, шуңа тырышлык куючылар, ихтимал, күп очрагандыр. Әмма юк. Азмыкүпме, булган эшләрем, күзгә күренми торган рәвештә булса да, Казан хәтеренә урнашкандыр, дияргә батырчылык итәм. Гафу итегез.

Хәерле булсын, иң зур хыялың тормышка ашкач, сөйгән Казаныңда яшәгәч, шуны чит җирләрдә дә танучылар очрап торгач, калган нәрсәләр өчен борчылмаска мөмкиндер һәм яшәүне үз мәсләгеңчә дәвам итү дөресрәктер. Шулай бит?

* * *

Барча шатлыкларым Казан белән бәйле, барча кайгыларымның, борчуларымның да иң чыннары һәм зурлары аның өчен, аның хакында.

Үзең турында, дәвамың, киләчәгең турында кайгырту Казан һәм ил турында, дөнья язмышы турында кайгыртуга тоташа.

Беренче карашка бөтенесе бик гади: шәһәрме, авылмы ул, барыннан бигрәк,— йортлар, урамнар. Һәр кешенеке кебек үк, һәр авылның, һәр каланың үз йөзе, үз төсе була. Гәрчә бик тә үзенчәлексез — биографиясезләре дә юк дип булмаса да. Казан андыйлардан түгел. Узып барышлый аны күргән шагыйрь Т. Шевченконың: «Казань городок — Москвы уголок»,— дигән бәясе белән килешү мөмкин түгел. Артык тенденциоз яки чынлыкны күреп җиткермәгән кеше генә шулай әйтә алыр. Казанда Көнчыгыш һәм Көнбатыш культуралары кушылуын күргән бөек мәгърифәтче һәм язучы А. И. Герцен исә үзенең объективрак һәм зирәгрәк икәнлеген күрсәткән.

Якын-тирәдә зурлык ягыннан безнең шәһәрне куып узган өлкә яки хәтта республика башкаласы булган шәһәрләр байтак. Ул шәһәрләрдә яшәүчеләр белән әңгәмәләр вакытында бик тә зыялы дәрәҗәле кешеләр безнең шәһәргә, минемчә, бик тә дөрес бәя бирделәр: «Безнең шәһәрдә метро төзелүгә карамастан, ул барыбер провинциаль булып кала. Ә Казан — метросыз да башкала».

Казан — башкала, чөнки кайчандыр ул мөстәкыйль дәүләтнең мәркәзе булган. Әүвәлдән үк үз теле, үз мәдәнияте, үз Кремле булган.

Казанның, битеннән-чыраеннан борынгылык галәмәтләрен беркемнең сөртә, бетерә аласы юк.

Безнең үсешебезне тоткарларга тырышуларга карамастан, Казан, вакыт агышы аркасында, гәрчә әкренлек белән булса да, төзелә, үсә һәм, уйлыйм ки, яхшы якка үзгәрә килгән. Гәрчә аның үсеше канәгатьлек тойгысы гына түгел, ачы хисләр дә кузгатса да.

Әйе, шундый вакытлар булды, без: «Казан — биш диңгез порты!» — дип горурланып җырладык. Чынлап та, табигый күренешләре сокландыргыч лабаса. Бөтен җирдә шәһәр, бөтен җирдә су. Ләкин Идел үзенең Ходай биргән мәңгелек агышыннан мәхрүм ителгән. Кайберәүләр аны диңгез дип түгел, ә череп килүче сазлык дип атыйлар.

Мин гигант дип мактаган «Оргсинтез» заводы, шәһәребезгә миллионлы кала статусы алырга ярдәм иткән башка зур предприятиеләр белән беррәттән, агулы явым-төшемнәргә сәбәпче булып, күгебезне ыслый, бакча-урманнарыбызны көйдерә.

Калабызның үзәге дияргә мөмкин булган Ирек мәйданы минем күз алдында үз йөзен үзгәртә, алмаштыра килде. Минем күз алдында М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры торып басты. В. И. Ленин һәйкәле пәйда булды. Консерваториянең концерт залы барлыкка килде.

Консерватория дигәннән, шунда бераз тукталып торыйк әле.

Мин Казанга укырга килгән чакта, бу бинага ВКП(б) өлкә комитеты урнашкан иде. Ул КПСС өлкә комитетына әверелгәч, аңа бу йорт кысанга әйләнде. Өлкә комитеты үзенә алты катлы зур пулат төзеде. Ләкин тора-бара, анысына да сыймый башлап, анысыннан өч-дүрт мәртәбә зуррак икенче яңа йорт салып, анысын да үзе биләде. Партия бюрократиясе шундый гөрләп, яшьнәп-күкрәп үсте, чәчәк атты ки, шундый темп белән җәелде ки, әгәр дә хәзерге «демократик» бюрократия тартып алмаган булса, ул, өченче, дүртенче, ә бәлки бишенче биналарын да салып, бөтен кварталны биләп алган булыр иде. Ихлас ышанып әйтәм.

Бер үк вакытта без бу биналар шәһәрнең төсен боза дип тә әйтә алмыйбыз. Шулай ук элекке В. И. Ленин мемориалы, кыяфәте крематорийга тартым булса да, ничек кенә димәсәң, анда барлыкка килгән мәйданга һәм Казансу ярына ямь кертте.

Башка мәйданнарга һәм урамнарга күз салсак, алар да яңара, нигездә — әйбәт якка. Гәрчә тагын да ныграк яхшыру мөмкинлеге калса да.

Ләкин ничек кенә әйтсәк тә — безнең шәһәребез. Үзем турында әйтсәм, бу — иң иртә бала чакларымнан башлап, хыялда барлыкка килгән шәһәрем. Хыялда туган, сөйгән калам.

Белүебезчә, мәхәббәт сагышсыз була алмый.

Югарыда: шәһәр — ул иң башта йортлар, урамнар, дигән идем. Ә бәлки ул иң әүвәл — кешеләрдер?

Кешеләр миллион кыяфәтле. Гәвам миллион тавышлы. Аның да үз холкы булып, анысы да үзгәрә тора. Кызганыч ки, соңгы елларда һич тә яхшы якка үзгәрә дип булмый.

Баштарак телгә алынган сизгер күңеллелек, ярдәмчеллек, вөҗданлык һәм намуслылык кебек сыйфатлар соңгы елларда акыл зәгыйфьлеге булып исәпләнә башлады. Әхлакның базары төште. Пычрак, алама җаннар өскә үрмәлиләр. Иң түбән инстинктлар уянып, шул хисләр белән шашынган алдакчылар, мошенниклар һаман-һаман активрак, оятсызрак эш итә баралар.

Бу төр бәндәләр, шәһәрнең әхлакый дәрәҗәсен төшерү генә түгел, аның тышкы кыяфәтенә дә шомлы төсмер бирәләр.

Шәһәр, әйтик, төрле вак кибетләр һәм коттеджлар белән дыңгычлана. Алар пейзажны матурлыйлармы? Ай-һай. Тирә-юньнәрендә ерткычлыклары төсләренә чыккан молодчиклар кайнаша. Караклыкка, сугышка, үтерешкә гадәти күренеш булып әверелергә мөмкинлек китергән шартлар барлыкка килде. Ямьсез хәлме? Коточкыч хәл!

Әйе, гомер дәвамында, табигый булганча, миңа төрле кешеләр белән очрашырга туры килде. Арада тәрбияле, затлы кешеләр аз түгел. Әмма аралашырга туры килгәндә: «Аһ, фарт килмәде, их, язмыш, ник мине шушындый кабахәтләр белән бәйләнешкә керергә насыйп иттең?!» — дип уфтандырган чаклар да аз булмады шул.

Ничек кенә аяныч булмасын, танырга мәҗбүрмен, хәтта безнең язучы агай-эне арасында да әхлак категориясен бары тик дипломатик хәйләләр өчен генә яраклы дип белгән кешеләр юк түгел.

Казанга диңгез килгән чакта, аңа су басу куркынычы янаганда, без, сусаклагыч корылмалар төзеп, шәһәрне һәлакәттән саклadык. Хәзер кыргый базар дигән болганчык дәрья һөҗүм итә. Безне күмеп китүе ихтимал булган, тагын да куркынычрак, афәтлерәк стихия яңый һәм һөҗүм итә.

Артык соңга калмыйча, нинди дер чаралар күрергә кирәк бит?

Иң әйбәт шәһәрләр арасында безнең Казаныбыз мәгълүм вакытларга кадәр чисталык һәм төзеклек җәһәтеннән әлләни аерылып тора алмады. Шәһәр җитәкчеләре адресына шелтәләр күп әйтелә торды. Бервакыт, шушы темага багышланган шәһәр һәм республика баш архитекторларының әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашуында, аларга күп төрле кискен сорауларга җавап бирергә туры килгән иде. Мин Кабан күле һәм Болак елгасы язмышы хакында сорау бирдем.

Студент елларында без су кергән һәм су спорты белән шөгыльләнгән Кабан күле агуланды. Болакның башы киселде.

Республика баш архитекторы бу сорауга бик сак җавап бирде. Шулай да аның хәлне үзгәртергә вәгъдә бирүен аңларга мөмкин иде. Менә без инде вәгъдә ителгәнне өч ел түгел, ә утыз ел көтәбез. Күлнең сулышы иркенәйми. Болакның кисек башын яңадан ялгый алмадылар. Аның хәле — торба... Шулай диик, чөнки ул Казан-су белән бер торба аша гына тоташа. Баш урынында — цирк. Начар түгел, әйтергә мөмкиндер, хәтта матур кебек. Әмма аның матурлыгын тоярга Болакның ирек таләп итеп тиберченүе комачау итә.

Шулай да без киләчәккә ышанычны югалтмаска тиеш булабыз. Гәрчә белеп торабыз:

Бөекләрнең улый океаннары,
Диңгезләре шаулый зурларның.
Ә минем бар койрыксыз Кабаным,
Башсыз гәрчә, һәм бар Болагым.

Диңгезем юк, әйе, океан ерак.
Алар шаулап торган киңлеккә
Чыгар юлда илләр таптап узмам,—
Иделем бар, миңа шул җитә.

Уңга бәрелмичә, сулга сугылмыйча,
Үз кыйбламa табан барышым.
Юл басмасын катыйль —
Бары шул.

Юл кисәргә теләүчеләр читтә генә түгел, үз өебездә дә яшәп яталар. Әйтерсең, мәңгелек кунаклар.

Бая искә алынган очрашу барышында күренекле әһелләребезгә һәйкәл кую мәсьәләсе дә күтәрелде. Шәһәр баш архитекторының (Солдатов дигән адәм иде) җавабы катгый булды:

— Һәйкәл куярлык кешеләр булса икән!

Ни өчен шушы вакытка чаклы С. Сәйдәшев, И. Шаляпин, Н. Җиһанов кебек күренекле кешеләребезгә һәйкәл куелмавы хәзер бөтенебезгә аңлашыла. Һәйкәлләр барлыкка килсә дә, кайбер очракта аларга уңайлы урын табылмый. Чит кешеләр утарында гүя шулкадәр җайсыз басып яки утырып торалар ки, хәтта аларны кызганып куясың. Ул урыннардан тиз генә китеп барырлар иде дә, тик, авыр постаментка мәңгелеккә ябыштырылып, Ходай тарафыннан мәңгелек җәзага хөкем ителгәнгә күрә, куба, кузгала алмыйлар...

Бик тә ихтимал, бу — минем шәхси тоемымдыр. Ләкин шунысына шигем юк, бу җәһәттән безнең эшләребез, гәрчә сөенерлек җайлар булган

хәлдә дә, әлегә һич тә мактанырлык түгел. Бу сүзне әйткәндә, мин Кремльнең мәһабәт биналары янында үз дәрәҗәсен югалтмаган һәм андагы башка йортлар вә корылмаларны түбәнсетмәгән М. Җәлил һәйкәлен күздә тотам. Мәгънәви-тарихи хакыйкатьне тулыландырып, аңа хәзер күрәштәшләре килеп кушылдылар.

Дәвернең яңа агымнары тәэсирендә, элеккерәк елларда телдән әйтелә дә алмаган проблемалар барлыкка килә. Урам исемнәрен тәртипкә китерү — шуларның берсе. Әйтик, Татарстанга бернинди катнашы булмаган йөзләрчә ят исемнәрнең эре-эре хәрефләр белән күзгә бәрелүе бик тә хәҗәт нәрсәме? Безнең бер үзәк мәйданыбыз татар халкына карата шактый зур явызлык кылган Куйбышев исемен йөртә. Үзен ихтирам иткән нинди халык шушыңа түзеп тора алыр иде икән? Ә шул тирәдә яшәгән, дөнья күләмендә танылган мәгърифәтче галимебез Шиһабетдин Мәрҗани мәйданы юк.

Ике тел — татар һәм рус телләре дәүләт теле итеп игълан ителүгә карамастан, шәһәребез чынлыкта бер генә телле — рус телле генә булып кала бирә.

Шул рәвешле, сораулар җаваплардан күбрәк булып чыга. Аларның кайберләре тулысынча хәл ителерлек, ә күпләрен хәл итү өчен безнең чикләре тарайган мөстәкыйльлегебез мөмкинлек бирә алмас, бәлки. Шулай да, хәл итәргә тырышу — һәр гражданинның намус эше.

Һәркем дигәнебез — ул мин, син. Һәркем үз ысуллары белән, мөмкинлекләренә муафыйк рәвештә үз өлешен кертергә бурычлы, дип әйтик. Моның өчен бер генә шарт таләп ителә — бурычны аңлау, үзебез һәм балаларыбыз хакына хезмәт итү теләге. Аларны ярату. Туган шәһәребезне, халкыбызны ярату. Шул очракта гына үз халкыбыз, үз калабыз дип сөйләшергә мөмкиндер.

Гәрчә монда тумасам да, ерактарак үссәм дә, Казанны үз шәһәрем дип санарга хокуклымын дип беләм.

Бераз элеккерәк елларда, миннән: «Ни өчен туган җиреңнән киттең?» — дип сорыйлар иде. Җавабым үзгәрми: минем туган җиремнән киткәнем юк. Ватанымның тарихын начар белмим, дип уйлыйм. Безнең туган җирләр әлеге дәвердә Татарстанга кермәсә дә, Явыз Иван басып алганга кадәр Болгар дәүләтенә, аннары үзәге Казан булган ханлык территориясенә кергән. Димәк, мин үз тарихи дәүләтем җирендә туганмын, яшәгәнмен һәм яшим. Казан — минем тарихи башкалам. Минем тарихи дәүләтем башкаласы.

Мин үземне Казаннан башка итеп күз алдына китерә алмыйм. Биографиямә кагылышлы, үзем өчен әһәмиятле булган бөтен нәрсә — шатлыкларым, кайгыларым Казан белән бәйләнгән.

Гомерем — тиешенчә яшәлгәнме, юкмы — ул шушында узган.

Казан иң әүвәл минем хыялымда туган калам.

Казан — минем тормышым.

Казан — минем мәхәббәтем.

Язмышым.

*1994—1995.*



**Айдар Хәлим**

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

* * *

Адаштым таныш урында, нык аек булсаң кыен;
Упкыннарга алып керде кемнәрдер таккан уем.

Тауга тезләнгән авыллар, тауга ни ялваралар?
Кысыр болытлар «Бетмибез!» дип микән кабаралар?

Тирбәлә телдә якты сүз, тик нигә өзеп булмый?
Ник җиргә шатланып баксаң, кайгырмый түзеп булмый?

Сине уйласам, и тормыш, җаным җырлар ыргыта;
Тик халкыма сузган чакта кемнәрдер кулдан тота.

Маңгаемнан нур чәчелә — томанда нурлар фидан;
Җиһанның тук базарында сатылып бетте иман.

Мин алла белән бәхәстә, аллалар мине сөйми.
Бу хакта пртакул белә, кеше дә шулай сөйли.

Томан сукырайткан кояш, күрми батышка күчә.
Ул да иртән яктырам, дип, кичен упкынга төшә.

*1986.*

## Ике елга тамагында

*В. га.*

Синең белән авырлык күрмәдек —
Тик сөю газабын кичердек.
Сусаган атларны кичүләрдә
Шәфәкъ дәрьясыннан эчердек.

Әле ике елга тамагында,
Агачлыкта, шаулы агымның
Куркыныч төшендә, кочаклыйсым
Килде сине —
Ярты җанымны...

Яшьнәде күк!.. Изде безне шәүлә:
Агач дисәм — котсыз колгалар!
Яфрак итеп акылын җуйган колга —
Бу кайсыгыз эше, елгалар?!

Нәрсә янап гыжный бу зәкъкүм[1]нәр!
Тарата шом, чыш-пыш, шыр ялган?
Агуыннан череп, авар тиздән —
Сандугач моңыннан болганган.

Кырлы курай сыман утырып корып,
Бөрҗәннән җил чакырып котырган —
Дога кыйлам: елга аеры акмас
Черек кәүсә салган коткыдан.

Дулкынланам, гүя беренче кат
Сине күрергә дип килүем.
Мине мәңге дулкынлансын өчен
Син вакыйга иттең сөюне.

Сине үбәм... Зәкъкум артларыннан
Күзәтәләр — беләм, килешми.
Шартлатыр да идем — бу дөньяга
Минем дулкынлану житешми...

...Төн бик якын. Җәллад өйгә кайтып,
Минем кулъязмамны актара.
Ә без ике елга тамагында
Шәфәкъ эчерәбез атларга...

*3.09.89.*

* * *

Бакчам кышка казылмыйча керде...
Чүп камады — тәмам интектем.
Үткәрәлмәдем ярлы катламнарга
Ләззәтле һавасын иректең.

[1] **Зәкъкум** (гәрәп) — агулы агач. *(Автор).*

Шыбыр-шыбыр гына яңгыр ява,
Чүп-чар янмый — куктән юралган.
Тамчыларның якты илләренә
Кара сачле толым уралган...

Чыш-пыш яткан учакның төтене,
Кагылып китеп, кайчак укшыта.
Чүпләр тартам. Чиксез хокук тойган
Шәхси чүптән вәхши моң шыта...

Әнә, микроб тамчыдай күзгеле
Күзлек киеп, мине бораулый.
Күзгә сыймыйм: димәк, гөлдән түгел,
Чүптән таптатам ди, хыялый...

Зиһенемдә кояш сүнгән сыман
Салкын тамчы төшсә җилкәдән.
Микроб изә, диеп, әллә мин дә
Чыгып олагыймммы илкәйдән?

Микроб энем, даһи явызлыгың
Бердәнбер нан булса тормышка,
Карашымнан очкан зәңгәр уттан
Чайкалмаслар иде офыклар...

...Ярда — шау-шу. Баш төзәтәләрме,
Корылтаймы — күңел сиземли.
Йөз исерек йөрәк кылым тарта,
Кыл бит аркан түгел — өзелми...

*9.1.1990.*

## Ут

Без өшедек. Көне дә кичләде.
Туңып үләбезме далада?
Буран чыкты. Ай ул күптән шадра —
Аны гүя «пәри ялаган»...

Җылыталмыйм сине... Соң үземне
Учак итим мәллә, сөйгәнем?
Синең өчен, ят балдактан үтеп,
Утка ике гомер түләдем...

— Йокым килә... Йоклат, әкият сөйләп! —
Диден дә, син чәнчеп карадың.
Бу дәһшәттән килер бәла тоеп
Чигә чәчем кардай агарды.

Ә давыл котырды... Ашык-пошык
Кораштырган киндер куышның
Бердәнбер казыгын какшатып, җил
Үкчәдән үпкәгә шуышты...

Кайдан бу гамь? Көтмәгәндә җиргә,
Гүя утка сузып кулымны:

— Бу — ут! — дидем. — Кер учакка тизрәк! —
Безнең ут бу... Димәк, борынгы!..

Кар сарылган якты сының белән
Бер бөтен боз булып ул чакта
Тагын да сискәнеп, иелдең син
Мин бар иткән сихри учакка...

Кем күз буды? Күздән нәрсә туды?
Ышаныгыз, канлы кызарып,
Арабызда учак яна иде —
Җирдә исән калган кислород.

Белгән догам укып, ут өстендә
Бармакларын удым кулыңның.
Эреде керфегең... Күзең... Үзең...
Һәм елмайдың:
— Менә, җылындым!..

Без шат идек. Хыялый учакка
Яккач соңгы өмет чималын,
Ниһаять, уянды җанда ач рух —
Ходай Тәгаләсе иманның.

...Дөнья тынды. Ай актаргалады
Пәриләр өерен давылның.
Моңсу төнге күктән карап йөреде
Биләмәсен йөз мең авылның...

*13.1.90.*

* * *

Нишләргә соң? Алар тын алдырмый.
Үлем килми. Ахры, иртәрәк.
Моңдай якты урын эзләп киләм,
Миңа ике аршын җир кирәк.

Нишләргә соң? Инкыйлаб яктысын
Ашап шашкан яңа үрмәкүч
Азатлыкның мәшһүр энҗеләрен
Аулап, оясына күммәкче.

Алар үзен кеше саный. Супер.
Суперталант. Димәк, мөгезле.
Бишектән үк чит имляны танып,
Кешене танымый — бер күзле.

Бер күзлеләр белә кызыл сүздән
Кара аулар кору гыйлемен.
Кара ауның кайнар кочагында
Кан түкереп киләм әле мин.

...Менә бит ул урын — Ялгыз Имән! —
Җылы куйныңнан бир урынны!

Өмет сүнде. Ефәк ауда, шартлап,
Хәнҗәр сынды. Йөрәк суынды.

Их, булмады кешене матурлап!
Бары үзем беттем тапланып.
Җиргә сеңәм тере иҗат өчен
Бер күзледән мең кат тукмалып.

Баш очымда мендәр түгел — меңнәр.
Меңнәр көчле арткы аң белән.
Өязе[1]нең яшь дулкыны, әнә,
Үксеп, шигырь укый таң белән.

Монда ялан якты. Чишмә керсез.
Офык чиксез. Биек һавалар.
Бөртектә ал үзәк — азатлыкның
Шартлаткыч матдәсе ярала.

Монда тыныч. Әнә, һич уфтанмый,
Алтын йөкләп башак угына,
Зәңгәр күзле Ырымбур даласы
Тау-тупсама килеп егыла...

Вөҗданым пакь. Ирегемә тугъры —
Күреп туйдым. Сөеп туймадым.
Гакылым, Имән, күкләреңә сеңсен,
Үлән булып шытсын иманым.

*13.6.86.*

## Дусларга

Хәл сорашып, хат язып тормагыз.
Хәлне күзгә карап белешербез.
Диктатура кайта... Озакламый
«Кирәк урыннар»да күрешербез.

Түздек. Түзәчәкбез. Кемнәр, кайчан
Сөйли алыр безнең түзгәннәрне?
Әмма түзә-түзә булмадыкмы
Бу яктыдан якты карбаздагы
Бәрәңгенең сукыр күзәнәге?

*26.01.91.*

## Укучыга үзем турында

Сиңа дигән йөкне киң җиһанга
Алып чыгам, дисәм — ни баса? —
Мин, ракета, таш баганаларга
Арканланган хәлдә ләбаса!

---

[1] Өязе — елга *(автор)*.

Двигатель эшли, ягулык бар,
Юк йөгемдә хәтәр кораллар.
Омтылам — күз чәчрәп чыгар! — аркан
Өзелмидер. Мең кат уралган.

Сакчылар күп: үзәктән көч алып,
Әле бай, бик байларны күтәргән
Колбиләүче әдип —
Россиян ул —
Мине җырдан читкә этәрә...

Алар миңа махсус тәмуг ясап,
Утын ташыганда учакка,
Мин кузгаткан намазлыкларыннан
Иблисләре тулды кочакка.

Үкенмимен, әгәр кәлам тәмләп,
Йолдызларга иркен үрелсәм,
Шигъри кроликлар утравында
Бер гыйфрит булып күренсәм...

Укучы дус, әйдә, кыйлансыннар.
Килер заман аерып алардан,
Иске йортның ишеген ачкан кебек,
Ачар әле мине яңадан.

Рухның дәһри колбиләүчеләре
Чыбыркыдай череп сүтелер.
Шигърият Иркәмнән Ил, Тел, Нәсел,
Җир алдында гафу үтенер...

Укучы дус, сиңа еллар аша
Килми калмас моңсу бер хәбәр:
Үзем үлсәм — Җабраил[1], диярсең,
Үтерсәләр, әйт: ул — пәйгамбәр.

*19.04.90.*

## Әйбәт кеше

Сөялгән дә кояшлы баганага
Укый китап.
Җитмәсә, шигырь китабы.
Җитмәсә, туган телебездә!
Җитмәсә, көпә-көндез!

Бар икән әле безнең милләттә дә
Мондый әйбәт кеше.

*1986.*

---

[1] Пәйгамбәрләргә китап китерүче фәрештә. *(Автор.)*

## Заман яңа — курку иске

Яңа заман әйтә: батыр бул!
Әмма
Яза гына башлыйм — куркам,
Сыза гына башлыйм — куркам.
Бу шигырьне дә язып тормыйм —
Куркам.

Куркып салдым йортлар —
Яшәрлек түгел.
Куркып салдым төрмәләр —
Ишәрлек түгел.
Курыкмый үстердем корсак —
Тишәрлек түгел.

Юк, Гафури абзыкаем:
Элек рәхәт иде — хәзер кыен ул!

*1986.*

## Татар ахмаклыгы

*(Алты күренештән торган фаҗига)*

Чабата аяклы марҗалар,
Исерек Иван бажалар
Татарстанны басты.
Галиәхмәт, гыйффәтсез Наташаны култыклап,
Дуслык талы артына качты —
Акылдан шашты.

Гөлгәүһәр Әләксәйне җитәклəп,
Гыйффәтен ачты,
Яңа Иваннар үстереп,
Интерсызыкка басты...

*22.09.94.*

* * *

Арыдык без мондый дуслыктан.
Ул бит тигезлек юклыктан.
Булаламы дус — кол һәм колбиләүче?
Тире иләүче һәм кораллы илбиләүче?

Кирәкми дуслык, кирәктер тигезлек.
Безнең дуслык өчен юк һичбер нигезлек.

*22.09.94.*

## Гөлшат Зәйнашева

# МЕНӘ ШУНДЫЙ МӘХӘББӘТ

хикәят

Моннан егерме еллар элек булды бу хәлләр. Халык иҗаты йорты кушуы буенча, һәвәскәрләр концертын карарга дип, Зиреклебаш авылына килеп төштем. Авыл советы секретаре, яшь кенә кыз, гаепле кеше сыман оялып кына:

— Апа, безнең авылда кунак йорты юк, салырга җыенабыз гына әле. Сезне фатирга кертергә туры килә инде,— диде.

— Зарар юк, мин фатирларда күп тордым, бер кичкә кер мичкә дигәндәй, кайда да ярар, урнаштыр әйдә берәр әбигә.

— Әбигә? Әбиләр ни...— дип туктап калды кызыкай.

— Әби булмаса, берәр ялгыз апага,— дим.

— Без Сезгә бер фатир әзерләп торган идек, ялгыз апа түгел, ире бар.

— Ярар алайса, ирле кешеләр уңайсыз димәсәләр.

— Белмим инде, үзегез уңайсыз димәсәгез, ире телсез, чукрак аның.

— Ярар, ярар, әзерләп куйган фатирыгыз булгач, нинди булса да рәхмәт. Телсез, чукрак янында тынычрак булыр.

Кыз авыл советыннан ерак түгел генә бер өйгә ымлап:

— Әнә бакчалары үрмә гөлгә күмелгән алты почмаклы йортны күрәсезме?— диде.

Бакча коймасына үрелеп үскән гөлләр арасыннан калай түбәсе генә күренгән йорт зәңгәр капкалары, капкаларындагы чәчәк бизәкләре белән минем күңелгә шундук якын, үз булып тоелды. Күрше-тирәләреннән үзенең чәчәккә күмелеп утыруы белән аерылып торган бу өйгә тизрәк барасы, хуҗаларын тизрәк күрәсе килде.

Капканы ачып керүгә, борынга алма үләне исе бәрелде. Ишегалды ямь-яшел алма үлән. Капкадан баскычка кадәр таш җәелгән сукмак. Мал асрамыйлардыр дисәм, лапаста кәҗә бәтиләре, сарык бәрәннәре чабышып йөри, бер як киртәгә бәйләп куелган бозау тоз ялый. Авыл җирендә күпчелек ишегалларында бер үлән үсми, аны маллар таптап бетерә. Ә бу хуҗаларның бөтенләй башкача, маллары тыкрык аша лапаска арт капкадан керә икән.

Безне капкага таба йөгереп килеп, ачык чырайлы, таза, чибәр бер апа каршы алды. Чәчәкле күлмәге әле генә энәдән-җептән төшкәндәй өр-яңа, билендә ак алъяпкыч, башына ап-ак батист яулыгын арттан калфаклап бәйләгән, аягында — чигүле чүәкләр.

— Әйдәгез, кунаклар, әйдәгез, түрдән узыгыз, самавырым кайнаган!

Эре нарат бүрәнәләрдән салынган гәрәбәдәй сап-сары бу өйнең саф һавасын хуш исле чәй исе тагы да тәмлерәк иткән. Биек итеп күпертелгән мендәрләре өстенә ап-ак челтәрләр ябылган никельле тимер караваt, хуҗа апаның үзе сыман, мәһабәт, түшәмгә тиям дип тора. Тәрәзәдәге пәрдәләр, челтәрләр күзеңнең явын алырлык ап-ак. Матур чәчәкле ситсыдан тегелгән түрләмәләр, кашагалар, чигүле сөлгеләр элеп, стеналарга чигүле салфеткалар кадаклап бизәлгән бу өй безнең татар авылларында гына була торган ниндидер бер ямьле моңсулык белән күңелне нечкәртә иде.

Без аны-моны сөйләшеп, тегене-моны сораштырып тәмле итеп чәй эчтек. Өстәлдә ни генә юк иде: бер дистәгә якын пешкән йомырка тәлинкәгә өелеп куелган, ак май, каймак, кәрәзле бал, әллә ничә төрле печенье, конфет, варенье, кетердәп торган кабартмалар. Секретарь кыз үз өендәге кебек кече якка чыгып, әле кашык, әле салфетка алып керә, мөгаен, бу апаларда безнең кебек командировкага килүчеләр еш куналардыр, кыз бу өйгә күнегеп беткән. Бик еш килгән кунаклардан туеп бетәргә, аларның барысын да болай бәйрәмчә каршылап арырга, гарык булырга мөмкин, ләкин Мәрьям апаның андый хуҗалардан түгеллеге йөзенә чыккан, ул һәркемне шушылай якты чырае, тәмле табыны белән каршылыйдыр. Колагындагы бөҗра сыман алтын алкалары, бер җыерчыксыз бите очындагы ясмык хәтле генә кара миңе апаны кунак сыйлау өчен генә яратылган ягымлы зат итеп күрсәтә иде.

Секретарь кыз кайтып китте, Мәрьям апа мине әлеге кукраеп торган ап-ак челтәрле караватка ятып ял итәргә димли башлады. Нинди ял ди, күңел ишек алдына, алма үләнгә тарта, шул үләндә яланаяк йөрисе килә. Болдырга чыгып, аяк киемнәремне салдым, ялан тәпи генә алма үләнгә бастым, әмма атлап китәргә уңайсыз, үлән шундый чиста, шундый тигез үскән, мин баскан урында егылып-авып кала. Табан асларын рәхәт назлап кытыкласа да, үләнне таптыйсым килмәде, баскычка килеп утырдым. Мәрьям апа анда чебешләренә бәрәңге боламыгына он кушып болгатып утыра иде.

— Алма үлән сабый чакны хәтерләтә, ятып ауныйсы килә,— дим.

— Ят, матурым, рәхәтләнеп ауна! — ди ул.

— Юк инде, үлән җәл.

Апа җайлап кына нинди эш белән килүемне сораштыра. Авыл апаларына хас бер гадәт буенча, бөтен тормышымны берьюлы белеп бетерергә тырышкандай, сораулар яудыра: кем мин, кайдан, кайда туып үскәнмен, әти-әниләрем бармы, тормыштамы, ирем кем, балаларым бармы, ничәү, үзем ничә яшьтә, кайда укыганмын һәм башкалар. Җавап бирәм, әйдә күңеле булсын апакайның. Минем үземне дә кызыксындырган сораулар бар, мин дә өлешсез калмам, мине аның телсез, чукрак ире кызыксындыра, шушы кадәр матур, төзек, чиста, гөлгә күмелгән йорт-җирле апаның җанашы кайда икән соң әле, ничек телсез калган ул, ничек алар яратышып киткәннәр, хәзер ничек торалар, балалары бармы, алар телләме, телсезме?..

Иң җайлы сораудан башлыйм:

— Апа, кызларыбыз бар дигән идегез, кайда соң әле алар?

— Берсе фермада сыер сава, җәйләүдә кунып-төнеп яталар, икенчесе Казанда заучный укый.

Башка сорауларны бирә алмадым, Мәрьям апа чебеш боткасын күтәреп лапаска таба китте:

— Хәниф абыең кайтты! Әтисе, мә, чебешләрне туйдыр!

Лапаста эш киемнәре кигән бер ир кеше күренде дә шундук әллә кая китте.

Өйдән озак кайнап пешкән тәмле аш исе килә. Мәрьям апа мине аш ашарга чакырды.

— Ә абый? Нигә ашарга керми ул?

— Ә ул ни... ояла... соңыннан ашар, кунак алдында ашарга ояла торган гадәте бар аның. Малларны карый әле ул, чебешләрне ашата.

Без ашап туеп табынны җыйганчы байтак вакыт үтте, мин гәзитләр укып утырганда алгы өйдә юынгыч шакылдаганы ишетелде.

— Әтисе, ашыңны җылыттым, ашап ал,— диде Мәрьям апа. Телсез чукрак дигәннәр иде, ә Мәрьям апа гел телле кешегә дәшкәндәй дәшә дип уйлап куйдым. Бераздан Хәниф абый түр өйгә кереп, мин утырган диванга таба килде. Ул кырынган, чәчләрен әйбәтләп тараган, өстенә күптән үтүкләп сандыкка салып куйганлыктан бөкләнгән урыннары беленеп торган яшел атлас күлмәк, чиста итеп юылган, ләкин оста үтүкләнмәгән чалбар кигән. Аякларында киез чүәкләр.

— Әйдә, әтисе, таныш, Казан кунагы,— дип, Мәрьям апа абзыйны минем янга алып килде. Хәниф абый мин сузган бер кулны көрәктәй ике кулына алып, кысмыйча җайлап кына күреште. Аның кытыршы учы эчендә минем йомшак кечкенә кулларым соскыга салган кош баласы кебек иде. Хәниф абый иплән кенә урындыкка утырды, ничектер чит өйдә кебек, үз оясында үзе уңайсызланып, бу абый ничектер сабый бала кебек бер хәлдә иде.— Концертка кадәр мунча кереп чык, сеңелем,— дип, Мәрьям апа шкафтан миңа чиста сөлгеләр алып бирде.

— Мунча? Әле кай арада мунча ягып өлгерттегез, апа?

— Абыең якты. Кунак килсә, эштән кайту белән аның беренче эше мунча ягу. Әйдә свижий миннекләр белән чабынырсың.

Сары май кебек эретә торган җылысы белән мунча шундый чиста, пөхтә, һәр әйберсе тәртиптә, киенү бүлмәсе дә уңайлы иде. Мин аннан сафланып җиңел бер рәхәтлек белән чыкканда, Хәниф абый гөжләп торган самавырны веранда өстәленә чыгарып Мәрьям апага чәй әзерләшеп йөри иде.

— Әтисе, тана кайтмый бит әле,— дип, Мәрьям апа лапаска таба ымлады. Мәрьям апаның күзенә карап торган җиреннән Хәниф абый иплән кенә атлап чыгып китте.

— Чукрак, телсез кешеләргә сүзне кул белән төрле хәрәкәтләр ясап аңлаталар, сез алай итмисез икән, ничек аңлый соң ул сүзегезне? — дим.

— Әллә тагы, күзгә карап тыңлап тора да аңлый инде шунда. Әнә шулай кул белән сөйләшергә өйрәнергә Казанга чакырганнар иде дә, бармады, оялчан ул, уңайсызлана.

— Оялса да, сөйләшмәсә дә, шундый чибәр апаны ала алган әле...

— Үзем... үзем бардым мин, үзем бармасам, мәңге алмас иде! — дип көлә Мәрьям апа.

Хәниф абый бик матур таза бала булып туган, ләкин бәхетсезлегенә, телсез, чукрак булып дөньяга килгән. Әтисе кулак Харис, бик явыз, саран кеше, ярлы семьядан төшкән Сәрвәр апаны гел кыйнап, җәфалап торган. Хәниф абый авырлы чагында да җәлләмәгән, йодрыкларын гел уйнатып рәхәтләнгән, шул сәбәпле, ахры, бала тормыш шау-шуын ишетмәс, тел тибрәтеп сөйләшмәс булып дөньяга килгән. Хәниф абый белән Мәрьям апа сугыш алды елларында икесе дә буйга җиткән егет белән кыз булалар. Хәниф абый бик оялчан булган, гадәтенчә, беркем белән дә аралашмаган, ә Мәрьям апа шаян, чая кыз икән. Аның тирәсендә авылның иң матур, иң уңган егетләр бөтерелгән. Клубтагы концертлар, спектакльләрнең берсе дә Мәрьям апа катнашыннан башка үтмәгән. Гармунчы Миңнулла исемле егет белән ятатышып матур гына йөри дә башлаган ул, менә өйләнешербез генә дигәндә, сугыш башланып киткән. Миңнулла сугышның беренче көнендә үк солдатка алынган, фронттан бер генә хат язып җибәргән, өч-дүрт айдан аның вафат хәбәре килгән.

Мәрьям апа бу кайгыны бик авыр кичергән. Сугыш бетеп, авылга берничә егет кайткач, арада Мәрьям апаны сораучылар, димләүчеләр булган, ләкин апаның күңеле бер кемгә дә ятмаган, ә каршы йортта гына яшәүче тимерче Хәниф аның уена да килмәгән, телсез, чукрак булганы өчен түгел, кечкенәдән бергә уйнап үскән күрше егетенә ничек гашыйк булырга мөмкин. Ул бит инде бер туганың кебек. Югыйсә, очраган саен кызарып күзгә мөлдерәп карап торган егет күңелендә нинди кайнар мәхәббәт саклануын тоймыйча мөмкин булмас иде. Башкаларның савыт-сабасын ямап биргәләгән тимерче Хәниф Мәрьям апаның чиләген төп-ләп кенә калмаган, матур итеп буяп, төрле чәчәкләр ясап бизәп тә биргән. Әнисе белән генә торган, ир-ат заты булмаган Мәрьям апаның авып барган капкаларын төзәтеп, мичләрен чыгарып, бәрәңге бакчаларын сөреп биргән егет барысын да күршелек хакы өчен генә эшлиме, бу турыда Мәрьям апа уйлап та карамаган. Шулай шул, адәм баласы мәхәббәтне тел белән сөйләп аңлатуга гына күнеккән. Бер вакыйга булмаса, шулай күпме еллар үтәр иде. Бервакыт Ташкент якларыннан кайткан бер егет Мәрьям апаны күреп гашыйк булган, тәкъдим ясаган, инде утызга җитеп килгән кыз ялындырып тормаган, ризалык биргән. Бер атна дигәндә, болар язылышып Ташкентка китәргә җыенганнар. Иртәгә язылышабыз дигән көнне Мәрьям апа ни колагы белән ишетсен, әлеге егет язылышмыйча-нитмичә күрше авылдан кибетче кызны ияртеп Ташкентына китеп барган. Язылышалар дигән хәбәре бөтен авылга таралып өлгергән булмаса бер хәл иде, Мәрьям апа хурланган, кимсенгән, халыктан оялган, шул хурлыкны күтәрә алмас кебек тоелып суга ташланырга җыенган, бер кичне үксеп елаган-елаган да буага таба йөгергән. Суга таба иелеп үскән бер карт өянке янына килеп, буаның иң тирән җиренә сикермәкче булып туктап калган. Шул минутта кемдер килеп көчле куллары белән арттан тотып алган. Әйләнеп караса, яшьле күзләрен мөлдерәтеп аңа Хәниф текәлгән. Мәрьям апа, үксеп, егетнең көчле күкрәгенә капланган.

— Хәниф ал мине үзеңә, синең мәңге тугры тормыш юлдашың булыйм! — дигән кыз егеткә. Егет аны кочаклап күтәреп су буеннан өенә алып кайткан. Менә шул көннән алып Мәрьям апаның һәр сүзен күзенә карап аңлый икән бу абый. Хәниф абый гомер буе чәчәк ярата икән. Коймаларга үрелеп үскән гөлләрне үзе үстерә икән. Авыл читендәге тимерчелектән арып кайткан чакта болынга сугылып, җәй буе көн саен Мәрьям апага чәчәк җыеп кайта икән. Егерме елга якын яшәп чыраен җимереп тә рәнҗетмәгән ул хатынын.

Кояш баюын күзләп баскыч төбендә утырабыз. Хәниф абый кайтты. Кулында зәңгәр кыр чәчәкләре. Миңа суза. Минем аның белән сөйләшәсем килә дә, ул мине аңламас дип икеләнәм. Шулай да ымлый-ымлый сүз башлыйм:

— Хәниф абый, танагыз кайда соң?

Ул күзләрен зур ачып карап тора, аңламый.

— Танагыз?..— дим, ике кулымны мөгез кебек итеп маңгаема куеп.— Му-му!..— дип кабатлыйм. Хәниф абый елмайды, аңлый алды. Ындыр артындагы тугайлыкка ымлады. Шунда ашап йөри булса кирәк.

— Төнгә шунда калдымыни? Бүре ашар бит!..— дим. Хәниф абый күзләрен зур ачып миңа караган килеш елмая, аңламый, ахрысы. Мин «ам-ам» дип беләгемне тешләп күрсәтәм, янәсе бүре «ам-ам» итсә!.. Хәниф абый кулларын сузып бер күзен кысып мылтык аткан сыман хәрәкәт ясады. Кулын селтәп елмаеп куйды. Димәк, бүреләрне атып бетергәннәр. Хәйран сөйләшеп була икән, мин әйтәм, күңелләр, күзләр сөйләшкәндә, дип уйлыйм.

Кич җитте. Клуб тулы халык. Бик матур концерт булды. Мәрьям апа белән Хәниф абый иң алгы рәттә иңне-иңгә куеп утырып концерт тыңладылар. Ишетмим дип тормый, бер кино, спектакльне, концертны калдырмый, хатынын култыклап, иң алгы рәткә кереп утыра икән Хәниф

абзыкай. Тимерчелектә дә, эше буенча да беркем белән бәйләнешми, беркемне рәнҗетми икән. Авылда аның кебек әйбәт холыклы башка кем бар икән, диләр идарәдә. Эчеп-исереп йөрү түгел, исереп кибет тирәсендә кайнашкан ир-ат төркемен дә читләтеп уза, исерекләр сугышып киткәнне күрсә, күзләрен зур ачып ерактан карап тора икән дә китеп бара икән. Кайвакыт аны гаепләүчеләр дә табыла икән, имеш, шундый таза кеше, сукса җиргә сеңдерерлек беләкләре белән сугышучыларны араламый да ичмасам, катышмыйча китеп бара бит дип, үпкәләүчеләр дә була икән. Мәрьям апа андыйларга: «Колагы ишетмәгәч, кем гаепле, кем хаклы икәнен белмәгән килеш, ничек инде катышсын. Телле кешеләр сугышсын, телле кешеләр талашсын!» — дип җавап бирә икән. Иң матур, иң үрнәк гаилә дип алар турында район газитенә зур гына мәкалә дә язып бастырганнар. Идарә янындагы Мактау тактасында Хәниф абыйның фоторәсеме иң беренче урында тора.

Икенче көнне бу авылдан китеп бардым. Хәниф абый мине мотоциклына утыртып, автобус тукталышына кадәр озатып куйды. Хушлашканда аның көрәктәй кулларына кош баласыдай кечкенә кулларымны салдым да:

— Рәхмәт Сезгә! Рәхмәт! Шулай бәхетле, матур яшәгез! Озак яшәгез, сәламәт булыгыз! — дидем. Хәниф абый түгәрәк таза битен тагын да түгәрәкләндереп, елмаеп кул болгады.

Шуннан соң мин аларны бүтән күрмәдем. Ләкин бер гаҗәп хәбәр ишетеп шаккатып калдым. Күптән түгел Казанда очрап әлеге секретарь кыз миңа менә нәрсәләр сөйләде: гомергә беркемгә авыр сүз әйтмәгән, беркемне рәнҗетмәгән, сугышу түгел, сугышучыларны читләтеп үтә торган Хәниф абый берәүне бик каты кыйнап ташлаган. «Ничек кыйнаган, ни өчен кыйнаган, ышанмыйм», дип секретарь кыз үзе сөйләгән күңелсез сүзләрдән үзе дә уңайсызланды. Егерме ел кайтмаган теге Ташкент кунагы кайтып төшкән. Хатыны белән әллә аерылышканнар, әллә татулыклары юк, бер ялгызы кайткан. Аръяктагы туганнарында кунак булып сыйланып, ашап-эчеп бер атна яткан. Көннәрдән бер көнне Мәрьям апалардан ерак түгел кибеткә килеп аракы алган, аракы алганда мактанып сөйләнеп торган, имеш, тели икән, ул Мәрьямне бүген үк Ташкентка алып китә!.. Шапырынма, дигәннәр аңа. Ә ул шапырына биргән, бер генә сүз әйтәм, любой хатын минем аягыма егыла, ди икән. Чынлап та, кичкә таба шактый исерек килеш Мәрьям апаларга килеп керә бу. Мәрьям апа бакчада карлыган җыя икән. Әлеге оятсыз кеше шыпырт кына килеп, Мәрьям апаны кочаклап ала, Мәрьям апа кычкырып җибәрә, бу исерек кочагыннан чыгарга тырышып чәбәләнә. Шул вакыт тимерчелектән, гадәтенчә, кулына чәчәк тотып Хәниф абый кайтып керә. Хатынының бер күз карашыннан барсын аңлап алган Хәниф абый чәчәген Мәрьям апага тоттыра да Ташкент кунагына ташлана. Кунакны шул кадәр сыйлый ки, ике кабыргасы, бер теше сынган килеш аны район шифаханәсенә алып китәләр. Оятсыз кунак анда Хәниф абыйны судка бирәм, төрмәгә утыртам, дип җәнҗал чыгарып маташа, билгеле. Хәниф абыйны авыл советына чакырып нык кына ачуланалар, әмма шуннан кырысрак җәзаны бирергә берәү дә уйламый.

Менә шундый мәхәббәт белән яшәүче Мәрьям апа белән Хәниф абый турында сөйлисем килде сезгә.

# Шигърият

## Сафуан Мулла Гали



### Нишләр идек?

Һәр чишмәнең үз аһәңе була:
Бәрелгән күк көмеш көмешкә —
Татар җыры сыман, челтер-челтер,
Үлемсез су ага инештә...

Моңлы инеш туа чишмәләрдән,
Инешләрдән туа елгалар,
Яз-җәйләрдән — яшел,
Кыштан — ак нур
Алып, туа безнең йолалар...

Безнең йола — ак-яшел нур белән
Җаныбызны юа яңартып —
Бер-берен, дим, шуңа сөяр татар,
Бер-берен гел яшәр яратып...

Безнең йола — җырның чыганагы
Табыннарда җырлар кирәктә —
Моң түгелә татар күңеленнән,
Халык җыры туа йөрәктә.

...Һәр милләтнең туа моңлы җыры —
Үз илендә иркен суласа...
Нишләр идең мең кайгылы татар,
Йөрәгеңдә моң-җыр булмаса?
Нишләр идек?!

### И бала чак!

Үз иттең талын бабамның,
Тирәкләр сорамадың.

Онытылып тыңлый идең
Сыерчык сайрауларын...

Яшь аралаш, хәсрәтләнеп,
Авыл зарын тыңладың.
Тик син сыерчык моңнарын
Тыңлап кына тынмадың:
Кычкырып җырлап җибәрдең,
Серләрең ачылдылар —
Җырыңда аккан сагышта
Коллыкның ачысы бар...

...Бүген дә китми ачысы,
Китми йөрәк ярасы...
Яраларның өсти кемнәр
Төзелмәслек яңасын?!

Һаман без — моң баласы...

## Көн бирәсе иде кешегә

Тәндә җан барында,
И туган җир,
Гаделсезлеккә ник тезләним —
Алдадылар синдә,
Алдадылар безне —
Бу хурлыкка башка түзәлмим...

...Гаделлекне күтәрергә вакыт,
Көн бирергә вакыт кешегә —
Күз алдында шиңә кызларыбыз,
Егетләрнең рухы күшегә...
И туган җир! —
Көн бирәсе иде кешегә...

## Рәхмәтем зур

Өегездә җырлаган җырыгыз
Зәңгәр күккә аша ургылып.
Талларыңнан тама моң тамчысы —
Бабайлардан калган җыр булып...

Былбылларың — кызларың күк моңлы,
Кызларың да, гүя, былбыллар —
Өйләнгән бер — үз бәхетен тапты,
Иң бәхетле ата булдылар...

Оныкларың — нәфис чәчәк сыман,
Ак-пакьлеге җанны тетрәтә.
Сине уйлап, авылым,
Иркен сулыш алам —
Кайнаса да кайгым күкрәктә...

Йөрәгемнең, синең ялкыныңда
Янмый калган көнен күрмәдем.
Беркайчан да сезне
Ташлап, авылдашлар,
Ят ишекне ачып кермәмен...

...Ык буйларын синең —
Эчке дөньям минем,
Анда — Ыкта йөзәм әле дә.
Рәхмәтем зур минем
Нигез ташын
Салган бабам, Муллагалигә...

## Кулларыма килә күтәрәсем...

Гүзәлләрнең карыйм күзләренә,
Күзләрендә күрәм үземне.
Үбә-үбә алсу иреннәрен,
Йөзләренә куеп йөземне,
Кысып-кысып билләреннән кочып,
Бүләк итеп чәчәк көлтәсен,
Кулларыма килә күтәрәсем
Милләтемнең гүзәл иркәсен...

...Иман нуры тула күкрәкләргә
Камышлы күл сыман күзләрдән —
Һәр татарның тусын өй түрендә —
Ун оныгы тусын гүзәлдән...
Иманлы кыз-уллар тудырсыннар —
Үстерсен татар өендә!
Шундый көннәр килер —
Килми калмас,
Диеп минем күңел сөенә...

Үссен халкым,
Үссен-үрчесен ул,
Татар җирен иңләп үрчесен —
Дус халыкка кулын биреп үссен,
Акыл белән җиңсен үчлесен...
Үссен-үрчесен!

...Кысып-кысып билләреннән кочып,
Бүләк итеп чәчәк көлтәсен,—
Кулларыма килә күтәрәсем
Милләтемнең гүзәл иркәсен!..

## Ярый әле син бар

Синең йөрәк белән минем йөрәк,
Ике йөрәк тибә бер булып.
Җаныбыз да бер җан кебек безнең,
Сулга түгел — уңга борылып,
Кыйблага ага ургылып...

Икебез дә моңлы Иделдән без,
Карашлар да безнең бер кебек —
Көннәремне яктырталар минем
Күзләреңнән нурлар бөркелеп...

...Тыңлаганда синең җырларыңны,
Күтәреләм кебек кыяга:
Ярый әле син бар, Җирдә, җаным,
Биеклеккә башны куярга...



# Әзһәр Габиди

## САГЫШЛЫ ХУШЛАШУ

### Язлар көлгәндә

Язлар килә,
Гөлләр көлә,
Тирбәлә зәңгәр рәшә
Таңнан торып бакчаларда
Сандугачлар серләшә.

Язлар килә,
Гөлләр көлә,
Шаярып җилләр исә;
Чәчкә чаллар кунган саен
Яшь чаклар искә төшә.

Язлар килә,
Гөлләр көлә,
Җәелә кичке эңгер;
Яшьнәп яшисе иде дә
Кыска шул, кыска гомер...

Шул кыска гына гомердә
Без яна, шаулый белдек;
Хыял белән үрләрнең дә
Иң биегенә мендек.

Биек үрләрдә уелып
Калды якты эзебез;
Ул-кызларыбыз алдында
Кызармаслык йөзебез!

### Әле кайчан гына җәй иде

Кайчан җәй иде дә,
Кайчан гына
Көз кызлары килеп җиткәннәр?
Җәй сылуның яшел яулыкларын
Сары ефәк белән чиккәннәр.

Кайчан җәй иде дә,
Кайчан гына
Көз кызлары килеп җиткәннәр,
Кылганнарны чыңлы кыллар итеп
/Көз маршын уйнап киткәннәр.

Кайчан җәй иде дә,
Кайчан гына
Көз кызлары килеп җиткәннәр:
Янып торган шомырт чәчләремә
Ап-ак итеп карлар сипкәннәр.

Җиргә төшкән карлар язын эрер,
Гөлчәчәкләр күмәр тугайны,
Чәчтәгесе эремәс шул инде:
Ерак очкан яшьлек тургае.

Күпме чакырсам да килмәс инде,
Килмәс инде яшьлек тургае;
Әйдә, көлеп торсын һәм мул булсын
Без яшәгән алтын көз ае!

## Шаулый урман

Шаулый урман,
Гөрли урман,
Көчле җилләр искәндә;
Без дә урмандай шауладык
Һәм гөрләдек үскәндә.

Шаулый урман,
Гөрли урман,
Һаман — җилләр искәндә;
Юксыну баса күңелне
Яшьлек искә төшкәндә.

Шаулый урман,
Гөрли урман,
Ник мин шауламыйм микән?
Шаулы урманнар шикелле
Яшь чакларыммы үткән?!

Тик, ник әле моңаерга? —
Шауладык шаулар чакта;
Төкле эзләр җәйрәп ята,
Һәйкәлдәй, безнең артта!

## Кичер мине, кичер Болгарым

Әллә инде үзем акрын булдым,
Әллә тотып торды сырхавым,
Моңа кадәр сиңа киләлмәдем
Кичер мине, кичер Болгарым.

Уяу әле Синең ул-кызларың,
Озын йокыларга китмәдек,
Исән әле гадәт-йолабыз да
Тоташ манкортланып бетмәдек.

Көтү генә йөргән зиратларны
Тәртипләп киләбез тоташтан,
Яңа мәчетләрне калкытабыз
Нигезләрен салып нык таштан.

Сибелсә дә татар, чәчелсә дә
Хур булганы юк бит бер җирдә,
Син бит безнең рухи кыйблабыз,
Син бит безгә Мәккә-Мәдинә.

Рәнҗемәче, зинһар рәнҗемәче
Шулай кичегүче улыңа.
Изге туфрагыңа башны иеп
Сәҗдә кылам синең рухыңа.

## Зарланмыйкчы

Зарланмыйкчы татар йоклаган дип,
Инкыйраз дип сукмыйк сөрән дә,
Йокламаган татар һәм йокламас,
Тамырлары аның тирәндә.

Сибелсә дә халкым, чәчелсә дә
Онытмаган телен, йоласын;
Эшен башлый бисмилласын әйтеп,
Юлга чыга укып догасын.

Язларында гөрли Сабан туе,
Күзләрендә казлар өмәсе,
(Ат ялында уйный чиккән сөлге,
Көянтәдә казлар түшкәсе.)

Ир-атлары төзи, чәчә, ура,
Гөл үстерә хатын дигәне;
Нәрсә тотса шуны коеп куя
Кыз-кыркыны, егет-җиләне.

Сокланырлык корган авыллары
Төзгән йорты аның чын сәнгать;
Тышы балкый аның пайтәхеттәй,
Эче тулы аның бәрәкәт.



Данил
Салихов

# АЛЛА КАРГАГАН ЙОРТ

**Драма 2 пәрдәдә**

**Данил Салихов — соңгы елларда театр дөньясында шактый танылган яшь драматургларыбыздан берсе.**

**Ул 1958 елда Актаныш районында туган. Урта мәктәптән соң өч ел Казан музыка училищесында укый, аннары театр училищесының актерлар әзерли торган бүлегенә күчә; училищены тәмамлап чыккач, әүвәл Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия, аннары К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма театрларында артист була. Хәзерге вакытта ул — «Салават күпере» журналында баш мөхәррир урынбасары.**

**Беренче сәхнә әсәреннән «Туй күлмәгем — соңгы бүләгем» драмасы 1988 елда К. Тинчурин исемендәге театрда куела. Аннары шул ук театрда «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (1989) драмасы, «Бәйрәмгалинең сыер тышавы» сатирик комедиясе (1990), Минзәлә татар дәүләт драмасы театрында «Никүләй дәдәйнең бөер ташы» комедиясе (1992) сәхнә күрә. Ә «Хатын түгел — аждаһа» пьесасы Әлмәт (1992), Минзәлә (1993), Оренбург (1994) театрларында куелды. Күптән түгел авторның яңа әсәре, «Әти кызына өйләнәм» комедиясе Әлмәт театрында сәхнәләштерелде.**

**Бу санда укучыларыбызга тәкъдим ителә торган «Алла каргаган йорт» драмасы Әлмәт театрында куелып (1991 елда), 200 мәртәбә уйналды.**

**Данил Салихов — 1992 елдан Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.**

Катнашалар:
Риваль Якубович — **баш врач, 50—55 яшьләр тирәсендә.**
Айрат Харисович Галин — **Генеральный директор, 50—55 яшьләр тирәсендә.**
Зилә Саматовна — **Айрат Харисовичның яшь хатыны, 28 яшьтә.**
Ләйсән Гомәровна — **медсестра, 27 яшьтә.**
Кадыйр — **шәхес культы еллары следователе, 60—65 яшьләр тирәсендә**
Исмай карт — **сабый акылы чыкмаган.**
Садрый — **сугыш инвалиды, 70—75 яшьләр тирәсендә.**
Нәгыймә әби — **70—75 яшьләр тирәсендә.**
Дубинкалы адәм — **тәртип саклаучы.**

**Вакыйга бүгенге көннәрдә бара.**

Беренче пәрдә

**Психбольницаның баш врачы Риваль Якубович кабинеты. Уртада «Т» хәрефе ясалган өстәл. Өстәл өстендә берничә телефон, селектор журналлар. Сул як стена буена китап шкафы, ә уң якка күперен торган диван куелган. Хужа утыра торган креслоның артында, диварда Бехтерев портреты.**

Риваль Якубович *(телефоннан сөйләшә)*. Рәхмәт, рәхмәт... Рәхмәтне соңыннан әйтерсез, Нәжип Айтуганович! Үзегез беләсез, хәзер аптекада анальгинны да дуслык белән генә табып була. Ә сез миннән Америка производствосы чыгара торган дефицит препарат сорыйсыз! Нәрсә? Ә, да да. Юк ла. Ул препаратны только обком аша гына алып була. Кирәкми! Кирәкми дим. Аларны борчымагыз! Сез нәрсә, Нәжип Айтуганович, мин сезне түбән слой кешеләрдән санамыйм. Үзегез беләсез, без сезнең белән обкомда утырмасак та, төшеп калган егетләр түгел. Андый уколлар безнең өчен дә кайта торгандыр дип уйлыйм. Үпкәләмәгез инде. Борчылмагыз. Борчыл-ма-гыз, дим. Эшлим дигәч, эшлибез инде. Разве сезнең кебек дусларны рәнҗетергә ярый. Нәрсә, нәрсә дисез? Такта?! Ну инде, Нәжип Айтуганович, ничек кирәкмәсен. Минем кеч-кенә, төпчек малайның дачасы юк бит әле. Әлбәттә, кирәк, сүз дә юк. Менә нәрсә, Нәжип Айтуганович, кызганмагыз биш минутыгызны, кереп чыгыгыз минем янга. Бирегә барысын да сөйләшербез. Яхшы, хушыгыз. Сәламәтлек телим. *(Ишек шакыйлар.)* Да, да, керегез! *(Ишек бусагасында Айрат Харисович күренә.)* О-о-о, Айрат Харисович, рәхим итегез, менә бирегә диванга утырыгыз. *(Айрат Харисович өстәл аркылы кул сузып күрешә дә, бер урындыкны алып, аның уң ягына килеп утыра.)* Хәлләрегез ничек?

Айрат Харисович. Әбиеңнеке кебек. Нигә сорап торырга, беләсең ич инде.

Риваль Якубович. Алай ук бетеренмәгез, барысы да җайланыр.

Айрат Харисович. Беләм инде, беләм... Әнә тегеләр дә *(бармагы белән өскә төртеп күрсәтеп)*, өстәгеләр, кулымда байлык барында, төнлә йокларга ирек бирмиләр иде, тегене сорап, моны сарап. Ә хәзер шушы хәл килеп чыккач, җир йоттымени үзләрен, ялгышып та шалтыратмыйлар.

Риваль Якубович. Үзегез генәме, әллә бичәгез беләнме?

Айрат Харисович. Риваль Якубович, әгәр ялгышмасам, без синең белән дуслар идек, ахрысы...

Риваль Якубович. Әлбәттә, шулай...

Айрат Харисович. Дуслар булсак, утырган креслодан төшеп «сез»дән-«без»дән «сиңа-миңа»га күчик әле. Без бит өйдә үзара калганда «атом-матом» белән сөйләшергә яратабыз.

Риваль Якубович: Да, дөрес әйтәсең. Нишлисең, канга сеңгән. *(Телефон шалтырый. Риваль трубканы ала.)* Да, да, тыңлыйм! Кем? Ә, Софья Тимергалиевна. Сәлам, сәлам! Хәлләр... Хәлләр ярыйсы. Менә авырулар белән көрәшәбез, дөресрәге җеннәрен куабыз. Үзегез беләсез, миндә бит җенле авырулар. Нәрсә? Спецклиникага салырга иде?.. Кемне?.. Сез нәрсә, Софья Тимергалиевна, сизәсезме, перестройкадан артта калгансыз, дөньядан артта калгансыз, дим. Андый сүз юк бит хәзер. Нийди?.. Спецполиклиника дигән сүз! Күптән ул сүзне үзгәрттеләр. Нәрсә, нәрсә дисез? Ха-ха-ха!.. Үзегез ничек уйлыйсыз соң? Дөнья белән идарә иткән акыллы адәмнәр, көтүче Гыймадилар белән бер палатада аларның эчәк исен иснәп ятырлар дип уйлыйсызмы? Шулай булгач, билгеле юк. Исеме үзгәрде, ә ятучылары, авырулары шулар ук. Да, да, ишек янындагы алтын белән карага язылган язу гына үзгәрде. Кем соң ул, сезнең клиентны әйтәм?.. Ресторанда завпроизводство булып эшли? Кирәк кеше икән... кирәк кеше икән, дим! Яхшы, барсы да сез уйлаганча булыр. Первый ята торган палатага салырбыз. Софья Тимергалиевна, сезне мин кайчан күрә алырмын? Сезнең теге погонлы адәмнәр белән связь каты иде бугай. Үзегез беләсез, алар бит мине теге вакытта бик рәнҗеттеләр. Нәрсә хакында сөйләвемне аңлыйсыздыр дип уйлыйм. Ә хәзер малай, төпчек малай үзләреннән башын алалмый, тагын эләккән. Нәрсә, кайда булсын инде! Аның бер җир бит инде, милициягә. Нишләсен. Бер егеткә үзенең көчен күрсәткән. Шулаймени, ай рәхмәт. Хәзер, хәзер сабыр итегез... *(Өстәлдәге блокнотын актара.)* Менә, менә, аның эшен Петр Николаевич Суслов дигән следовательгә тапшырганнар. Ай рәхмәт, алайса минем барып йөрисе калмады. Ярый хушыгыз! *(Трубканы куя)*. Менә бит, шушы кешеләрсез яшәп кара инде син, бүгенге дөньяда.

Айрат Харисович. Риваль Якубович, йә нишлибез?

Риваль Якубович. Нишлисең, ничек сөйләштек, шулай эшлибез.

Айрат Харисович. Күпмеләп яткырырга уйлыйсыз инде сез мине бирегә?

Риваль Якубович. Күпме телисең шул хәтле. Обстановка ничек килеп чыга бит.

Айрат Харисович. Минем бирегә бер сәгать түгел, бер минут та торасым килми.

Риваль Якубович. Анысын үзегез карыйсыз инде. Йөрәгегез ничек куша. Көчләп яткырмыйм. Сезне яткырганга баштан сыйпамаслар.

Айрат Харисович. Ярар инде, үзеңне минем урынга куеп кара. Нишләр идең...

Риваль Якубович. Нәрсә? Әллә һавасы кысамы? Ә менә минем бөтен гомерем шушында үтте. Ә шулай да үкенмим. Җиде ел шушы кресло өчен ачлы-туклы укыдым. Үз теләгемә ирештем.

Айрат Харисович. Да, креслоны без барыбыз да яратабыз. Тик җайлап утырырга гына ирек бирмиләр... Кем уйлаган аны, миннән башлырак булыр дип. Карап торуга бер селәгәй генә бит, бер селәгәй, адәм көлкесе.

Риваль Якубович. Кайгырма, дус кеше, без синең койрыгыңны өчәүләп яшерербез. Син һәм дә мин, өченчебез әнә теге кеше. *(Бехтерев портретына ымлый.)*

Айрат Харисович. Ярый әле ул кеше булган. Без акыллы дураклар кая илтеп башыбызны яшерер идек.

Риваль Якубович. Кешелек барысын да үз файдасына җайлый. Даже дураклар йорты да кайчакта акыллыларга ярдәм итеп куя. Йә, ярый, эшкә күчик. Нидән башлыйбыз?

Айрат Харисович *(ишеккә ымлап)*. Биклә. *(Айрат барып ишекләрне бикли. Риваль акчаларга карап.)* Аңлап җиткермим.

Айрат Харисович. Монда яртысы, ә яртысы мин моннан исән-сау чыккан минутта сезнең кулыгызда булыр. Сөйләшкәнчә инде, алты ай — алты пачка.

Риваль Якубович. Куркасыз? Чыгарсыз! Бирелән теле озыннар, күпне белгәннәр генә чыгалмый. Сез андыйлар рәтенә кермисез. Үз сөягебез. Да... Алты ай... Азрак инде, конешно.

Айрат Харисович. Мин хәзер үк бу «алла каргаган йорттан» чыгып качар идем. Зинһар алты айдан артык тотмагыз инде мине биредә.

Риваль Якубович. Ничек тотмагыз инде? Тотма инде, диген. Культурный кылаunion киттең. Тегеләрне, тикшерүчеләрне ышандырып булырмы дип шикләнәм. Ярый, тырышырмын. Но, только синең үзеңә дә тырышырга туры киләчәк. Кирәксә, мин әйтәм икән, коридор буйлап ыштансыз-трусиксыз, анадан тума шәрә килеш тә йөрергә туры киләчәк.

Айрат Харисович. Күрәселәрем алда икән әле...

Риваль Якубович. Шулай инде, нишлисең. Дөньяның бер рәхәте, бер михнәте, башың эшләмәсә, аягыңа көч килер, дигәннәрме әле? Ә хәзер менә бу акчаларны менә монда *(өстәл тартмасын тартып чыгара)* үз кулларың белән төртеп төшер. Үзең беләсең, бу акчаларга миңа орынырга ярамый. *(Айрат акчаларны тартмага сала. Риваль тартманы бикли.)* Синең башка шушы сволочьлар җитте бит. Син кайгырма, алар хәзер пленда *(кычкырып көлә.)*. Бар иде, хәзер юк. Кызык бу дөнья. Кичә алар синдә иде, бүген миндә. Иртәгә кемдә булыр, этем белсен. Бар, ишекне ач! *(Айрат ишекне ача.)* Хәзер мин медсестраны чакырам. Образга керә тор. Чибәр кыз, күкрәкләренә, арт санына үрелсәң дә рөхсәт итәм. Хотя сине өйрәтәсе юк. Синең хәзергесе дә егерме биш яшьлек түгелме соң?

Айрат Харисович. Дуракка акыл кирәкме? Үз башыма өйләндем. Менә хәзер туйдырып кара син аны. Өскә менеп мыскыл итә.

Риваль Якубович. Ничего, кайгырма. Сине озакламый тынычлыкта калдырачак ул. Син нигә кирәк аңа, шәлперәйгән карт.

Айрат Харисович. Син нәрсә, мине бөтенләй үтерергә уйлыйсыңмы?

Риваль Якубович. Ярый инде, шаяртканны аңла. Үзе өйдә калдымы? Ярата ул сине...

Айрат Харисович. Коридорда көтә.

Риваль Якубович. *(селектор кнопкасына баса)*: Сеңлем, Ләйсән, бирегә кер әле. *(Айратка.)* Ярый каушама, барысы да тәртиптә булыр. *(Бүлмәгә медсестра Ләйсән Гомәровна керә.)* Сеңлем, менә бу авыруны җиденче палатага озат. Аннары минем янга керерсең. *(Айрат Харисович белән Ләйсән Гомәровна чыгып китәләр. Риваль Якубович телефоннан номер җыя.)* Алло, алло! Бу сезме, Равиль Садриевич? Мин әле бу, Якубович. Яхшы, яхшы. Үзеңдә ни хәлләр бар? Яшь хатын борчымыйммы? Аерылдым? Кайчан? *(Көлә.)* Әллә картайдыммы? Әллә картайдымы, дим? Кайчан аердың? Бер ай элек? Ну, үзең өлгер дә. Тагын өйләнергә җыенмыйсыңмы? Тагын кайчан өйләнәсең дим. Заочно?.. Ярый торган эш. *(Кычкырыбрак.)* Ярый торган эш димен! Йомыш бар иде. Бер чибәркәйгә мутон тун кирәк иде. Әйе инде, әйе, шуңа. Теге синең дачага алып барганга. Ярый алайса, шоферың кертеп чыгар әле, йәме. Чебеш бит инде ул, 46 нчы размер, ахрысы. Әйе, төсе кара булсын, кара дим! Ял көне... Ял көнне кабан атарга чакырдылар. Шулар инде, үзебезнекеләр. Вакытың булса безгә кил. Бергәләп барырбыз. Юк инде, вертолет белән. Ярый, көтәбез. Хуш! *(Бүлмәгә Ләйсән керә.)*

Ләйсән. Тыңлыйм сезне, Риваль Якубович.

Риваль Якубович. Урнаштырдыгызмы?

Ләйсән. Урнаштырдым.

Риваль Якубович. Яхшы булган. Менә нәрсә, сеңлем, менә аның амбулаторный карточкасы. Аны дәвалау белән мин үзем шөгыльләнәчәкмен. Андагы персоналларга аңлатып куярга кирәк. Ул авыру үзенә өч тапкыр кул салган. Кайчакларда нәрсә эшләгәнен белештермичә, төрле кирәкмәгән эшләр эшләп ташлавы бар. Лезвия, электробритва, тимер кисәкләре, бау ише әйберләрне анардан ераграк тотыгыз. Передачаны бары тик минем рөхсәт белән генә алыгыз. Ә, онытып торам, аны озата килгән кеше киткәнме әле?

Ләйсән. Юк. Сезнең кабул итүне сорады.

Риваль Якубович. Керсен! *(Ләйсән чыгып китә. Бүлмәгә Зилә Саматовна килеп керә.)* Рәхим итегез, шәһәребезнең бердәнбер курчагы. Сезне күрүемә мин бик шатмын, Зилә Саматовна.

Зилә. Рәхмәт, Риваль абый.

Риваль Якубович. Кем дисез? Сез мине кимсетәсез. Риваль абый, имеш. Мин сезнең Айрат Харисовичыгыздан яшьрәк бугай.

Зилә. Гафу итегез, Риваль Якубович.

Риваль Якубович. Риваль Якубович! Сез нәрсә... Риваль. Менә монысы миңа ошый. *(Барып ишекне бикли.)* Зилә... Нинди матур исем. Бу минутта минем йөрәгем үзенә урын табалмый. *(Зиләнең кулын тота.)* Нинди нәфис йомшак куллар!

Зилә. (кулын тартып алмакчы була.) Сез нәрсә, Риваль Якубович, шаярмагыз?!

Риваль Якубович. Нинди шаяру ди ул. Бу олы хис, олы тойгы. Тыңлагыз әле йөрәгемне. *(Зиләнең кулын үзенең йөрәк турысына куя.)* Ишетәсезме? Ул бу минутларда бары тик сезнең өчен генә тибә.

Зилә. Җибәрегез, Риваль Якубович! Сез мине уңайсыз хәлгә куясыз. Җибәрегез! Кычкырам!

Риваль Якубович *(ишекне ача.)*

Ярый, мин сезнең сүзегезгә каршы килә алмыйм. Мин сезнең әсирегез. *(Көлә.)* Ә мөнә ирегез минем әсирем. *(Көлә.)*

Зилә. Риваль Якубович, ул биредә озак ятачакмы?

Риваль Якубович. Барысы да сездән тора.

Зилә. Риваль Якубович, мин аңардан курка ук башладым. Анда көчле апатия. Үз-үзенә кул салам ди. Төнлә саташып уяна. Сез аны ныклап дәваламыйча чыгармагыз инде. Аның сәламәтлеге, гаилә өчен дә, үзе өчен дә бик мөһим.

Риваль Якубович. Мин сездән шундый сүз көткән идем дә. Бары тик сездәй яхшы хатыннар, ир өчен яшәүче хатыннар гына бу сүзне әйтә ала. Теләгегезгә каршы килмим.

Зилә. Рәхмәт сезгә.

Риваль Якубович. Мин сезнең батырлыгыгызга һич шикләнми идем. Шундый чибәр, яшь кызның олы яшьтәге ирне үз куенына алуы үзе батырлык.

Зилә. Риваль Якубович, моны ничек аңларга, шаярумы, әллә мыскыл итү дипме?

Риваль Якубович. Сез нәрсә... Мин чынлап. Тик мин генә ялгыз.

Зилә. Нигә алай дисез? Сезнең бит тормыш иптәшегез бар?..

Риваль Якубович. Тормыш иптәшем генә шул. Ә миңа хатын кирәк. Тәнемне җылытырдай синдәй гүзәл хатын кирәк, нәкъ синдәй.

Зилә. Аңламыйм. Минем уйлавымча, тормыш иптәше хатын була түгелме соң инде ул?

Риваль Якубович. Юк шул, акыллым, икесе ике нәрсә. Менә сезнең ирегез миңа тормыш иптәше, менә биредә хезмәттәшләрем минем тормышымдагы иптәшләрем дип аталса, ә хатын бүтән нәрсә. Хатын — тән җылытучы, нәфесне басучы була ул.

Зилә. Менә ничек...

Риваль Якубович. Шулай шул. Алтмышны куган хатынның нинди тән җылысы булсын ди инде. Менә шуңа күрә мин аны үземнең хатынга санамыйм. Их, Зилә, сезнең пешергән камыр ашларыгыз бүген дә күз алдымда торалар, бүген дә авыз суларын китерәләр. Тагын шуларны авыз итеп булырмы, белмим.

Зилә. Нигә булмасын...

Риваль Якубович. Шулаймы... Булырмы? Тик кайчан?

Зилә. Менә Айрат Харисович кына терелеп чыксын.

Риваль Якубович. Гафу итегез, Зилә Саматовна, сөеклем, әле аңа ятарга да ятарга... Ә минем түкатем калмады.

Зилә. Ярый, мин сезне чакырырмын.

Риваль Якубович. Менә шулай, рәнҗетмә карт абыеңны!

Зилә. Риваль Якубович, миңа передачалар алып килергә рөхсәттер бит? Кабул итәрләр дип уйлыйм.

Риваль Якубович. Бездә яхшы ашаталар. Борчылып йөрмәгез. Аннары Айрат Харисовичның аркылысы буйга өйләнә башлаган. Аңа бераз гына диета мешать итмәс дип уйлыйм. Кинога, театрга, рестораннга баргалабыз һәм башка җирләргә... Культурно ял итәргә диюем. Борчылмагыз, мин сезгә скучать итәргә ирек бирмәм. Бары тик бер утырып күзгә-күз карашып камыр ашы гына ашыйк. Барысы да җайланыр.

Зилә. Ярый, хушыгыз. Мин китим.

Риваль Якубович. Туктагыз, мин хәзер машина чакыртам.

Зилә. Юк, рәхмәт сезгә. Мин «Жигули» белән.

Риваль Якубович. Сез рульдә?!

Зилә. Әйе.

Риваль Якубович. Яхшы, яхшы. Бәлки, мине дә катать иттерерсез әле. Сездәй ханым белән бергә-бергә табигать кочагыннан бер әйләнеп кайту үзе ни тора!

Зилә. Обязательно! Хушыгыз!

Риваль Якубович. Мин сезне көтәм, өзелеп көтәм. Менә сезгә минем визиткам, шалтыратсагыз, мин бик шат булыр идем. Айрат Харисович өчен борчылмагыз. Ял итегез.

Зилә. Хушыгыз. *(Чыгып китә.)*

Риваль Якубович. Чибәр шул, кабахәт. Үзе авызга өзелеп төшәргә тора. Сынатма, Риваль Якубович, сынатма! Син сыната торган егетләрдән түгел!

**Ут сүнә.**

**Палата. Каршыда рәшәткәләнгән ике тәрәзә. Стенаның ике ягында икешәр кровать. Кроватьлар янында тумбочкалар. Түрдәге кроватьларның өчесендә, буйлы полосатый киемнәрдән төрле позаларда өч авыру утыра. Садрый, Исмай, Кадыйр. Алар тормәдәге тоткыннарны хәтерләтәләр. Ә, бәлки, образларын яхшы ачыклау, баету йөзеннән, аларда әлек кемлекләрен ачыклаучы элементлар сакланганлыр. Бүлмәдә шундый ук киемнән Айрат Харисович һәм олы гына гәүдәле, ак халатлы, 30—35 яшьләр тирәсендәге алыптай адәм килеп керә. Аның кулында дубинка.**

Адәм *(дубинкасы белән буш кроватька төртеп күрсәтеп)*. Урнаш!

Айрат Харисович *(бүлмә эчен күзәтеп)*. Кая килеп каптым... Төрмә дисәң дә төрмә.

Кадыйр *(утырган җиреннән сөзәргә җыенган үгез кебек Айратка карап торганнан соң.)*. Враг народа! *(Икенче кроватьта утырган Садрыйга кычкыра.)* Немедленно кулга алырга! Допрос!

Садрый *(утырган урыныннан сикереп торып Айрат Харисович өстенә ташлана)*. За Сталина! Уничтожать врага! Урра!!! *(Ул арада Кадыйр егылган Айрат Харисовичның кулларын артка каерып сөлге белән бәйли дә, икесе ике яктан күтәреп алып, тумбочкага утырталар.)*

Кадыйр. Попался, гад! Миннән ычкынмакчы идеңме?! Кемнәргә хезмәт итәсең? Чит ил агентларынамы? Синнән сорыйлар, гад! Кемгә хезмәт итәсең? Дәшмисең? Ничего, әйттерермен. Синең кебекләр минем кулдан меңәрләп үттеләр. Тел яшерәсең? Илне сатмакчы идеңме? Падла! Халыкны сатмакчы идеңме, паразит?! Враг народа! На, получай! *(Айрат Харисовичның яңагына китереп суга.)* Дәшмисең? Яхшы, тешкәк телеңне тешләп теге дөньяга озатканны көтәсең? Маңгаеңа бер пуля утыртканны көтәсең, да?! *(Яңагына суга.)*

Айрат Харисович *(утырган урыныннан сикереп төшә)*. Нишлисең җир бит, уволю! Тфү, суям!

Кадыйр. Ах, син шулай! Совет тәртип саклаучыларына, безгә, тавыш күтәрәсең?! Кемгә-кемгә, безгә, партиянең тугры улларына. Мә, гад! Мә, падла! *(Яңаклый.)*

Айрат Харисович. Үтерәләр, үтерәләр, коткарыгыз!..

**Бүлмәгә дубинкалы адәм килеп керә дә, Кадыйр белән Садрыйның җилкәләренә суга. Алар икесе ике якка йөгереп качалар.**

Кадыйр. Виноват, товарищ начальник! Действовал не по уставу, виноват! Больше не буду! *(Аягын бөкләп кроватька менеп утыра.)*

Адәм *(Айрат Харисовичның кулын чишә-чишә)*. Ә син нәрсә карап торасың, катырак сдача бирсәң, бүтән синең янга якын да килмиләр алар.

Айрат Харисович. Зинһар, мине бүтән палатага күчерегез.

Адәм. Синең өчен махсус люкс әзерләп куйганнар. Утыр, тының чыкмасын! Маңгаеңа сугармын, җелегең атылып чыгар. Кеше рәхәтләндергән кешегә охшамагансың, корсагың бик мул күренә. *(Чыгып китә.)*

Исмай карт. *(Айдар Харисовичның алдына килеп тезләнә)*. Абый?! *(Айрат Харисович дәшми.)* Абый!

Айрат Харисович *(кырт кисеп)*. Нәрсә? Син тагын нинди асыл кош?

Исмай карт. Абый...

Айрат Харисович *(ачуы чыгып)*. Нәрсә?!

Исмай карт. Абый, минем әтине күрмәдеңме син?

Айрат Харисович. Күрдем.

Исмай карт. Кайда?

Айрат Харисович *(кукиш ясап, Исмайның борынына төртә)*. Менә монда!

Исмай карт. Ә-ә-ә, алдашма, анда кеше булмый, мин беләм. Абый, кайда күрдең, әйт инде тизрәк!

Айрат Харисович. Юк, күрмәдем!

Исмай карт. Кайтмый да кайтмый. Төнлә ишек шакыдылар, ишек ачарга дип чыгып киткән иде, шул китүдән юк та юк. Әни тары боткасы пешергән иде, суынып бетте инде, һаман кайтмый.

Айрат Харисович. Кайтыр әле, көт! Исмай карт. Кайтыр бит, әйеме, абый? Кайтыр да мине килеп алыр. Минем бик өйгә кайтасым килә, абый. Мин монда озак булдым инде. Врач ападан кайтырга сораган идем дә, әтиең кайткач кайтарып җибәрербез ди. Хәзер әни дә килми, элек еш килә иде, хәзер югалды. Әтине эзләп йөри торгандыр инде ул, әйеме, абый?

Айрат Харисович. Әйе, әйе, эзлидер. *(Кадыйр кулы белән Садрыйга ымлый да, икесе ике яктан Айратка килә башлыйлар. Айрат Харисович моны сизеп стенага сылана.)*

Садрый. Буам, Гитлер калдыгы, буам! За Сталина!

Айрат Харисович. Коткарыгыз, на помощь, үтерәләр! *(Йөгереп чыгып китә. Бераздан дубиналы адәмне ияртеп керә.)*

Адәм. *(Садрый картны тибеп очыра.)* Кит әле, күз көеге булып утырма. Йә бәреп үтерермен! Әй, сез әрәмтамаклар, ипи черткечләр. Ишетсен колагыгыз! Тагын бер генә тапкыр тәртип бозсагыз, икегезне дә кроватька бәйләп салам, ишеттеңме, «За Сталина»!

Садрый *(үрә катып честь бирә)*. Служу Сталину!

Кадыйр *(аның шүсәсенә тигезләнеп)*. Виноват, товарищ начальник. Действовал не по уставу! *(Честь бирә.)*

Адәм. Вольно! Хәзер үк бүлмәгезне җиләтегез!

Кадыйр, Садрый *(берьюлы үрә катып)*. Есть! *(Икесе берьюлы кабалана-кабалана кроватька басып форточканы ачалар. Адәм чыгып китә, ачык ишектә бер кулына швабра, икенче кулына чиләк тоткан Нәгыймә әби килеп керә.)*

Нәгыймә әби. Исәнмесез, балалар.

Кадыйр *(аның каршына килеп баса)*. Син нәрсә, нинди мин синең балаң булыйм. Син минем кабинетымны җыештыручы.

Нәгыймә әби *(кеткелдәп көлә)*. Синеке инде, синеке. *(Кадыйрның аркасыннан сөя.)* Менә шуның өчен дә синең кровать астыңны беренче юам.

Кадыйр. Действуй так, как положено по уставу. Идәндә бер кан табы да калмасын!! Аңладыңмы?

Садрый *(Кадыйрга кычкыра)*. Син нәрсә, нишләп синеке булсын ди ул. Ул безнең частьның медсестрасы. *(Барып Нәгыймә әбинең битеннән үбеп ала.)* Сугыш кына бетсен, мин сине үзем белән Рәсәйгә алып кайтып китәм. Күп итеп миңа балалар табарсың.

Нәгыймә әби *(кеткелдәп көлә)*. Табармын, Садрый, табармын.

Садрый. Әй, мин сиңа әйтәм, карт карга. Әйбәтләп юасыңмы син, юкмы? Кан исе килә.

Нәгыймә әби. Бер-ике сәгатьтән тагын юармын. *(Айрат Харисовичка карап.)* Менә арабызга тагын берәү килеп кушылган. Кемнең бәхетсез баласы син? *(Айрат Харисович дәшми.)* Яшьли язмыш каргаган сине, улым, бик яшьли.

Айрат Харисович. Әби, идәнеңне тизрәк ю да, олак күз алдымнан.

Нәгыймә әби. Юам, улым, юам. Мин аны гомерем буе юам инде.

Айрат Харисович. Нәфсеңне басалмасаң, акча артыннан кусаң, шул швабраңны кочаклап теге дөньяга да китәрсең әле.

Нәгыймә әби. И улым, улым, бик китәр идем дә, күрәсең, без тиләләр анда да кирәк түгелләр. Төннәр буе, көннәр буе әҗәл көтеп йөрсәм дә, килми. Япь-яшь егетләрнең, кызларның гомерләрен ала, ә безгә килми.

Айрат Харисович *(Кадыйрга күрсәтеп)*. Әнә бит, газраил, аңа мөрәҗәгать ит.

Кадыйр. Ах син, сволочь. Дин белән халыкның аңын томаламакчы буласыңмы? Хәзер күрсәтәм мин сиңа газраилнең ничек булганын. *(Айрат Харисовичка таба ике бармагын алга сузып килә башлый. Нәгыймә әби швабрасы белән мал куган кебек аны кроватенә куып утырта.)*

Кадыйр. Мулла калдыгы. Аңлашылды... Син раскулачивание вакытында Гер-

манияга чыгып качтың да... Хәзер шпион булып кире безгә кайттың да, какшамас көчле Совет илен дин белән агуларга? Аңлашылды.

Нәгыймә әби. Кадыйр энем, иманына кил! Тел тидермә-ул илаһи затка. Безнең әрвахларны бары тик бу ачы кайгыдан ул гына коткара ала.

Кадыйр. Алламы?.. Син нәрсә? Мәхлук! Юк алла, юк! Сезне бары тик без генә коткара алабыз. Аңладыңмы, надан? Алла да юк, газраил да, фәрештәләр дә, мулла да. Беттеләр алар. Төбе-тамыры белән йолкып ташладык без аларны.

Исмай карт. Кадыйр абый, өй иясе бар, әйе бит. Минем үземнең күргәнем бар.

Садрый. Өй иясе бар, анысы хак. Ә газраил юк. Точка.

Кадыйр. Ә ул мине газраил диме?..

Нәгыймә әби. Газраил ул бөек зат. Син дә бөек зат, Кадыйр энем. Ул шуңа сине газраил белән тиңләде дә. Ә син юкка үпкәлисең.

Кадыйр. Шулай дисәгез генә.

Исмай карт. Әби, минем әти килмәгәнме?

Нәгыймә әби. Юк шул, энем Исмәгыйль, юк.

Исмай карт. Бик озаклады.

Нәгыймә әби *(чәченнән сыйпап)*. Көт, Исмәгыйль энем, көт! Кайтыр ул! Гомереңбуе көткәнне, азга гына түз! Күп көтәсең калмагандыр. Бәлки, теге дөнья булса, ахирәттә кавышырсыз. Синең кебек, минем кебек авыруларның гөнаһлары булмый диләр бит. Атаң да изге җан булгандыр, иншалла. Оҗмахта исән-сау тән белән кавышырга насыйп итсен ходай. Синең белән безгә бары тик ул дөньяда гына тынычлык, җан рәхәте насыйп итәр ходай тәгалә.

Айрат Харисович. Әби, картайгансың бит инде, нигә эшлисең? Балаларың юкмени?

Нәгыймә әби. Йортым да шушы, балаларым да шушы. Бөтен гомерем шушында үтте. *(Булмәгә, дарулар күтәреп, медсестра Ләйсән Гомәровна белән дубинкалы адәм килеп керәләр.)*

Ләйсән. Нәгыймә әби, исәнме! Исмай энем, нихәл?

Исмай карт. Әйбәт, апа, синең хәерфатихаңда.

Нәгыймә әби. Исәнме, кызым! Бүген син дежурить иткәч, йортыбыз нурлы. Гел син генә дежурить итсәң иде ул.

Ләйсән. Рәхмәт әби.

Адәм. Көн дә монда сезнең янга килергә алла сакласын. Үзеңнең дуракка өйләнүеңне көт тә тор.

Ләйсән. Нәгыймә әби, син чыгып тор, соңрак юарсың.

Нәгыймә әби. Ярый, кызым, ярый. Минем вакытым күп.

Адәм *(Кадыйрга)*. Әй син, палач, бирегә кил!

Кадыйр *(строевой басып килә дә, дубинкалы адәмнең каршысына килеп үрә ката)*. К вашему приказанию военный исполнитель Кадыйр Нигматуллин прибыл. *(Авызын зур итеп ача. Ләйсән аның авызына таблеткалар сала. Адәм подностан сулы стаканны Кадыйрга суза. Кадыйр суны эчә дә, авызын зур итеп ачып, Адәмгә күрсәтә.)*

Адәм. Вольно!

Кадыйр. Можно удалиться? *(Үзенә-үзе командовать итеп.)* Направо. *(Уңга борыла.)* Шагом марш! Раз, два, раз, два. *(Китеп бара.)*

Адәм. Сталин, монда кил!

Садрый. *(Ул да шул рәвешле дубинкалы каршына килә.)* К вашему приказанию рядовой, сапер Гыйлфанов Садрый прибыл. *(Таблетка эчә дә.)* Служу за Родину, за Сталина! *(Китеп бара.)*

Адәм *(Бармагы белән Исмай картны чакыра)*. Әй син, мальчик, иди ка сюда, конфетом угощу. *(Үзе шаркылдап көлә.)*

Исмай карт *(медсестра янына килеп)*. Апа, мине өйгә кайтарганда миңа бер-ике дару бирерсең әле? Теге конфет кебек тәмлеләрне. Юкса минем әтигә бүләгем юк.

Ләйсән. Бирермен, Исмай бабай, бирермен. Ә менә боларын хәзер үзең эч.

Исмай карт. Әтигә саклыйм, ә апа?

Ләйсән. Юк, боларын үзең эч. Әтиең кайткач, мин аңар күп итеп тәмлеләрен бирермен әле.

Исмай карт *(даруларны эчә)*. Апа, нигә син миңа бабай дисең? Мин бит әле малай гына.

Адәм *(шаркылдап көлә)*. Әйе, нигә бабай дисең?.. Әле үзенә өйләнеп тә куймасын. Ха-ха-ха... *(Кинәт җитдиләнеп, Исмай картка кычкыра.)* Югал күземнән. Йә бармак белән басып сытармын! Бет, холера! Укол биреп үтерәсе нәрсәләр.

Ләйсән. Сез сүзегезне чамалап сөйләгез. Алар бит авырулар.

Адәм. Ипи корткычлары, әрәмтамаклар! *(Исмай картка.)* Сиңа әйтәм, ычкын күз алдымнан. Туйдым мин сездән. Өрәк булып төшемә керәсез.

Исмай карт. Китәм, абый. Мин озакламый бөтенләйгә китәм инде. Сагынырсың әле мине, әйеме, апа?!

Ләйсән. Әйе, әйе.

Адәм *(чыгырыннан чыгып)*. Их, рөхсәт итсәләр, коридорда тезеп бастырып, барыгызга агу кадап чыгар идем. Күземә җен булып күренәсез.

Айрат Харисович. Спирт азрак эч, кеше итеп күрә башларсың.

Адәм. Ах син аны, кара нинди акыл иясе. Ярый... Мин сине авызлыклармын әле. Кил әле бирегә, асыл кош! *(Мыскыл итеп.)* Чеп-чеп-чеп. Ти-ти-ти. Нәрсә, күзле бүкән кебек карап каттың? Кил монда! *(Айрат дәшми.)* Сиңа әйтәләр! Хәзер үзем барам бит яныңа. *(Дубинасын күтәрә.)*

Ләйсән *(Дубинкага үрелә)*. Орынасы булма. Хәзер үк Риваль Якубовичны чакырам. Күпме авырулар өстеннән көлергә була. Син тагын эчкәнсең.

Адәм. Кем эчкән! Минме? Мә! *(Ләйсәннең битенә өрә.)* Бармы миндә ис?!

Ләйсән. Юк, ләкин син нормаль кеше түгел, күзең атылып чыгам дип тора.

Адәм. Болар белән бәбәгең атылып чыгар. Шулай инде, җанкисәгем. Син таблетка, укол белән лечить итсәң, минем уколым дубинка. Бар, нигә Риваль Якубовичны чакырмыйсың?! Бар, бар! Куркасың, әйеме? Куркасың... әгәр телим икән, иртәгә үк мин

сине биредән сәрдерәм. Монда мин главный *(Айратка.)*. Сиңа әйтәм!

Айрат Харисович. Мин дару эчмим.

Исмай карт. Бар, абый, эч. Алайса кыйный ул. Тәмле генә ул дару.

Адәм. Бәлки сиңа спирт кирәктер?

Айрат Харисович. Мин авыру түгел.

Адәм. Синнән сораган кеше юк. Син авыру түгел, дөресрәге тинтәк, ягъни чынбарлыгың белән дурак, чокнутый.

Исмай карт *(ялварып).* Бар инде, абый, бар. Синең аркада безне йоклатмаячак ул. Коридорда бастырып тотачак.

Кадыйр. Уставка буйсынмыйсың... Разрешите, товарищ начальник.

Садрый. Беләм мин синең кебекләрне. Окоптан кулларын күтәреп, ранен булып, өйләренә кайтырга маташканнарны. Окопка барасың килми дә, сволочь, предатель, тереләсең килми... Буам сатлык жанны. Буам, за Сталину!

Ләйсән. Кил, абый, жаным, кил. Син үзеңнең авыру икәнлегеңне үзең белмисең. Авыру түгел кеше биредә ятмый. Без бит сиңа яхшы булсын дибез.

Айрат Харисович. Главврачны чакыртыгыз!

Адәм. Бәлки сәламәтлек саклау министрын чакыртыргадыр?!

Айрат Харисович. Мин ул даруларны эчмим.

Адәм. Эчми кая барасың, мәхлук?

Кадыйр. Заставим, товарищ начальник.

Садрый. Трибунал сиңа, гад! Полевой суд һәм маңгаеңа пух!

Исмай карт. Барыбер эчертәләр, абый, эч!

Кадыйр. Әйтәм бит, халык дошманы дип. Совет даруын эчүдән чиркана.

Айрат Харисович. Мин ашаудан баш тартам.

Адәм. Бик дөрес эшлисең, хәзергесе минутта дуракларга түгел, акыллыларга да ашарга юк. Талон! «Гестапо», «За Сталина!» ә ну ка, кулларын тотыгыз. *(Тегеләр икесе ике яктан килеп Айрат Харисовичның кулларын артка каерып тоталар.)*

Кадыйр. Враг народаның соңгы сәгате, соңгы минуты!

Садрый. Уничтожать предательне, сатлык жанны. *(Адәм каерып авызын ача. Ләйсән таблеткалар каптыра. Айрат Харисович үксеп мендәргә ава.)*

Исмай карт *(Үксеп-үксеп елап аның янына тезләнә.)* Абый, абый, җылама, зинһар, җылама.

**Кабат баш врачның кабинеты.**

Риваль Якубович *(телефоннан номер җыя.).* Алло, алло, аптечный управлениеме? Бу кем әле? Кем? Валентина Сергеевна... Мин андый кешене белмим. Шулай диегез, Валюта. Алло, алло, Валентина Сергеевна, исәнмесез. Бу мин әле, «Доллор» абыең. Эшкә күчик. Тегеләрне озаттым. Сөйләшкәнчә, ампуласын элекке бәядән. Тагын заказлар бар. Хушыгыз! *(Ишекне шакыйлар.)* Занято. *(Муены белән битен кульяулыгы белән сөртә. Ишекне чак кына ачып. Зилә Саматовна башын күрсәтә.)*

Зилә. Риваль Якубович, бәлки бер генә минутка кабул итәрсез...

Риваль Якубович. Сорап торасыз. Рәхим итегез, түргә, менә монда *(диванга күрсәтә).* Рәхим итегез, Зилә Саматовна. Ниһаять, сезне дә күрер көннәр булыр икән. Шалтыратмыйсыз да, өегездә дә тормыйсыз. Үзегез кунакка чакырдыгыз, үзегез миннән качып йөрисез.

Зилә. Зинһар, гафу итегез, Риваль Якубович. Мин әниләргә, туган ягыма кайтып килдем. Айрат Харисович белән кушылганнан бирле беренче кайтуым. Үзегез беләсез, Айрат Харисович яшь кеше түгел. Үзен генә калдырып китү уңайсыз. Үзенә игътибарны күп сорый.

Риваль Якубович. Зилә Саматовна, сез бу дөньяда гүзәлләрнең гүзәле булганга күрә, сүзегездә хаклык булмаса да, мин сезгә ышанырга мәжбүрмен.

Зилә. Минем сүзләремдә һич шигегез булырга мөмкин түгел... Мин...

Риваль Якубович. Анысы шулай. Әмма ләкин, минем бер кешем сезнең подъездны ярты ай саклады. Ухажерыгыз белән икегезне... Сез нәрсә, Риваль Якубович! Нинди ухожор турында сүз алып барасыз?

Риваль Якубович. Сездә куныш йөри торган.

Зилә. Сез ялгышасыз, миндә һичкемнең дә кунганы юк. Сез, мөгаен, подъездны бутагансыздыр.

Риваль Якубович. Белмим шул. Әлегә кадәр хәтерем яхшы иде. Бер күргән жирне икенче күргәнче онытканым юк иде. Әгәр дә бер үк йортта 78 нче квартира икәү булса, зинһар, мине гафу итә күрегез. Ярый инде алайса, Зилә, сеңлем, нишлисең, ул яшь симпатичный иптәшне бирегә, безгә больницага салырга туры килер.

Зилә. Берни аңламыйм...

Риваль Якубович. Шулай. Ул иптәш бик яшьли саташа башлаган булып чыга. Киң белән килеп, «Волга»сын үз йорты янына йә булмаса хөкүмәт гаражына куймыйча сезнең тәрәзә төбенә куеп киткәч, тагын ул кешедән ни көтәргә...

Зилә. Ә, Ул... ул... Айрат Харисовичның личный шоферы иде... Исемә төште.

Риваль Якубович. Менә шулай, бергәләп уйлагач, күрәсең, исеңә дә төшердек. Юк... мин сезне гаепләргә җыенмыйм. Минем хакым юк. Сез яле яшь, чибәр, чәчәк аткан вакытыгыз. Табигать биргән хисне, нәфесне яшереп калу мөмкин түгел.

Зилә. Риваль Якубович, зинһар, бу эшне Айрат Харисович сизмәсен иде.

Риваль Якубович. Сездән тора инде, сездән. Бер тапкыр камыр ашы пешереп үземне чакырсагыз...

Зилә. Яхшы... Болай булгач, турыдантуры сөйләшүгә күчик. Мин сезнең тәкъдимегезне кабул итәм. Тик бер условие куям.

Риваль Якубович. Тыңлап карыйк.

Зилә. Мин бер айга Сочига ял итәргә китәм. Минем белән тагын бер кеше барырга тиеш.

Риваль Якубович. Шуннан?

Зилә. Сез ул кешенең кем икәнен төшенәсездер дип уйлыйм.

Риваль Якубович. Дәвам итегез.

Зилә. Шул кешегә өч атнага больничный эшлисез. Һәм хәзер үк минем алда Айрат Харисовичка әйтәсез. Янәсе, бер ай аның янында мина күренергә ярамый.

Риваль Якубович. Сез миңа бик кыйммәткә төшәсез түгелме? Ә кая гарантия?

Зилә. Гарантия шул: әгәр дә мин сезнең ышанычыгызны акламасам, сез Айрат Харисовичка картаны ачып саласыз. Тузлар сезнең кулыгызда.

Риваль Якубович. Сез яшь кенә булсагыз да шактый шомаргансыз.

Зилә. Айрат Харисович школасы. Сөйләшү шул, Риваль Якубович. Мин Сочидан кайткач, сезне камыр ашы пешереп, постель җәеп кабул итәрмен.

Риваль Якубович. Яхшы. Мин сезнең таләпләрегезне кабул итәм. Тик кисәтеп куям. Сез мине яхшы беләсез. Минем белән шаяру куркыныч.

Зилә. Риваль Якубович, сез ничек уйлыйсыз, берничә кич сезнең күнелегезне күрү миңа берни тормый. Минем карт кешене ничек иркәләвемдә сезнең шигегез юктыр дип уйлыйм. Анардан минем бер җирем, кәгазь кадәр дә, юкармый.

Риваль Якубович *(көлә)*. Шәп әйтелде. Хәзер сез ачуланмасагыз, мин сезгә соңгы соравымны бирәм.

Зилә. Тыңлап карыйк, Риваль Якубович.

Риваль Якубович. Менә сез яшь кенә булсагыз да, дөньяның түмен, ләззәтен татыган, кулыгызга байлык тотып караган хатын. Ә инде якынрак килсәк... Нәрсәсен таптыгыз сез ул майга каткан, простой егетнең? Беренчедән положениесе,икенчедән...

Зилә. Риваль Якубович, сез хатыныгыз бар аркылы яшь кызларга үрелгәндә, нәрсә, үзегә әйтмешли, минем нәфесем юкмени? Тән җылысы, сөягемне җылытырдай кеше миңа да кирәктер дип уйлыйм.

Риваль Якубович. Аңлашылды. Сүзем бетте. Мин бирелэм. Сез дөньяда ничек яшәргә кирәк икәнлеген, безгә караганда, яхшырак беләсез. Бәхәсләшмим. Зилә Саматовна, сезнең Айрат Харисович белән монда, ул бирелә ятканнан бирле очрашканыгыз юк, ахрысы.

Зилә. Юк шул. Вакыт юк. Дөнья, мәшәкать. Үзенә ни дип җавап бирермен.

Риваль Якубович. Борчылмагыз. Бу юлы да мин сезгә ярдәмгә килермен. Аның өчен миңа...

Зилә. Аның өчен сезгә... Белмим инде...

Риваль Якубович. Бер поцелуй! *(Зиләне куеньна ала. Зилә аның иңенә кулларын сала, үбешәләр. Зиләнең хис белән пышылдаган тавышы ишетелә.)*

Зилә. Чакырт үзен. Чакырт, бәгырем! Чакырт Айрат Харисовичны...

*Пәрдә*

## Икенче пәрдә

**Риваль Якубович белән Зилә Саматовна үбешеп торалар. Ишек шакыйлар. Алар берберенннән аерылалар. Зилә чәчләрен, итәкләрен рәтли, бүлмәгә сакалы үскән Айрат Харисович белән дубинкалы Адәм керәләр. Зилә Айрат Харисовичның муеныннан кочаклап ала.**

Риваль Якубович. Әй сез, бераз гына сабыр итегез.

Адәм. Миңа чыгаргамы?

Риваль Якубович *(Адәмгә)*. Берсекөнгә заказлар кил. Минем янга бераздан кереп чыгарсыз. Чакырырмын! *(Дубинкалы Адәм чыгып китә.)* Менә очраштыгыз да. Күрәсезме, Айрат Харисович, сезне уйлап, Зилә Саматовна чыбыкка калган. Күзләре генә утырып калган. Сезнең белән очрашуны сорап, көн саен колак итемне ашады. Менә вакыт җитте, очраштыгыз. Һәр әйбернең үз вакыты бар. Мин сезне калдырып торам, тик озакка түгел. Сезгә ун минут.

Айрат Харисович *(Ривальгә)*. Сезгә сүзем бар.

Риваль Якубович. Соңыннан, кисәтеп куям, Зилә Саматовна, бары ун минут! *(Чыгып китә.)*

Зилә *(Айрат Харисовичның яңагыннан үбә, чәчен сыйпый)*. Нишләттеләр сине?

Айрат Харисович. Кая югалдың син?

Зилә. Сөеклем минем, үзең ишеттең бит. Передачаны алмыйлар, очрашырга рөхсәт бирмиләр. Акылдан шашам бит инде. Көннәр буе шушы больницаның бусагасын саклыйм. Салкын тидереп бетердем бит.

Айрат Харисович. Әйе... Рәхмәт аңа. Шәп җиргә урнаштырды ул мине, прямо җәннәт. Пальмалары гына юк. Маймыллары җитәрлек.

Зилә. Кемгә рәхмәт?

Айрат Харисович. Кемгә булсын, менә бу Якубович дигән ябалакка. Күпме ятып мин аны беренче тапкыр күрәм.

Зилә. Алай димә инде, акыллым. Әгәр ул булмаса, бүтән җирдә утыра идең бит, янган идең, чабуыңа ут капкан иде. Ярый әле ул булды.

Айрат Харисович. Төрмәдә дә очрашырга рөхсәт бирәләр.

Зилә. Түз, түз, бәгърем, озакламый чыгарсың.

Айрат Харисович. Анда ниләр сөйлиләр?

Зилә. Өйгә килделәр, обыска ясадылар.

Айрат Харисович. Берни дә тапмадылармы?

Зилә. Юк.

Айрат Харисович. Шиш аларга. Ниләр сорыйлар?

Зилә. Элек авыртканы бар идеме, диләр.

Айрат Харисович. Элек авырганы бар идеме... Дурак иде инде, кайтып сезне суймасын, диясең калган.

Зилә. Бер-ике тапкыр сәер эшләр эшләгәне бар иде, дилем. Нинди сәер эшләр, диләр.

Айрат Харисович. Нәрсә диден?

Зилә. Минме, мин...

Айрат Харисович. Әйе, син...

Зилә. Күкрәгенә бюстгальтер киеп, иренен кызартып, дамский сумка тотып иртә белән эшкә чыгып барган җиреннән туктатып калдым. Ул көнне эшкә бара алмады.

Кинәт башын тотып идәнгә ауды. Көне буе идәндә аунады. Икенче бер тапкыр шундый хәл булды. Мин эштән кайтуга стенага кукиш рәсемнәре ясап бөтен стенаны тутырган иде, дидем.

Айрат Харисович. Арттыргансың. Нигә именно кукиш рәсеме? Әгәр алар моңа мәгънә салсалар?.

Зилә. Нәрсә башыма килсә, шуны сөйләдем инде.

Айрат Харисович. Алар синең янга тагын килерләр, йә булмаса үзләренә чакыртырлар. Азаплап бетерерләр. Аларга сөйләгән бу сүзләреңне арттырма да, киметмә дә. Алар шундый халык, аларга кабереңякын булмасын. Һәр әйткән сүзеңне уйлап, нәтиҗә ясап сөйлә. Ничего, исән-сау биредән генә чыгыйм, мин ул кукишларны аларның стеналарына, күз кашларына эләм әле. Шалтыратучылар юкмы?

Зилә. Юк.

Айрат Харисович. Ничего, алайболай әземә төшсәләр, мин аларның үзләрен дә яндырам. Тыныч кына креслоларында утыра алмаслар. Бергә икән, бергә... Сагындым мин сине, кошчыгым. Кил әле, кил яныма, үбим әле үзеңне.

Зилә. Син нәрсә, кыяфәтеңә кара, үзең әйтмешли, маймылга охшап калгансың бит.

Айрат Харисович. Маймыл дисең инде... Дурак белән үбешергә чирканасың.

Зилә. Чирканмыйм. Мин сине үлеп сагындым. Тик урыны түгел. Моннан чыккач, иркенләп, йомшак постельдә.

Айрат Харисович. Күреп булырмы ул көннәрне, белмим.

Зилә. Күреп булырмы... Иректә чагында кадеремне белергә иде аны. Айга бер тапкыр кочакларга, назларга түгел, көн саен...

Айрат Харисович. Нишлим соң. Дөньяда бер генә тапкыр яшибез. Рәхәтен күреп каласы килә. Аңла мине, Зилә. Миңа бала табып арыган, имчәге асылынган хатын кирәкми. Минем әлләни яшисем калмагандыр. Ә синә яшисе дә яшисе әле. Мин үлгәч тә сине иркәләүчеләр күп булыр. Байлык ул әллә нинди яшь егетләрне сындыра. Син яшьлегеңдә мине иркәләсәң, миннән калган байлык карт көнеңдә сине иркәләр. Көт мине. Исәнсау чыгыйм гына, байлыгымны синең исемгә күчерәм. Мин үземне сизәм, сүнеп барам.

Зилә. Нигә синең байлыгың миңа? Нигә бар кешене дә үз бизмәнеңә салып үлчисең. Байлык имеш. Син үзең минем өчен байлык. Яратам мин сине (Айрат Харисовичны кочаклап елый).

Айрат Харисович *(юатып)*. Булды инде, булды, акыллым. Рәхмәт, рәхмәт сиңа. Әгәр бу җир йөзендә син булмасаң, үзүземә күптән кул сала идем инде.

Зилә *(кулъяулыгын алып күз төпләрен сөртә)*. Ничек соң монда?

Айрат Харисович. Сорама. Җылап җибәрәм. Алла каргаган йорт бу. Кешеләр түгел, зверьләр монда.

Зилә. Түз, бәгырем.

Айрат Харисович. Түзми кая барасың. Асылынырга бау да табып булмый. Арттан ун күз күзәтә.

Зилә. Айрат, сиңа әйтер сүзем бар. Белмим, син минем бу эшемне кабул итәрсеңме, юкмы — анысы синең эш. Әмма...

Айрат Харисович. Сөендерерлек булса гына сөйлә. Көенеч булса, билеңдәге каешыңны салып миңа калдыр.

Зилә. Минем яшем бара, ялгыз утырып каласым килми. Мин авырлы. Калганын сиңа решать итәргә.

Айрат Харисович. Син авырлы?

Зилә. Миңа бала кирәк. Синең өчен күп яшәдем. Җитте. Күкрәк торгызып, фигура саклап кына яшәү туйдырды. Киләчәгебез турында уйларга вакыт.

Айрат Харисович. Соң бит мин сиңа сакланырга куша идем. Соң бит мин сине үзем гинекологка алып барып...

Зилә. Алып барсаң, син бит минем белән врач янында утырмадың.

Айрат Харисович. Димәк...

Зилә. Әйе, мин син теләгән әйберне куйдырмадым. Сине өзелеп яратканга мин ул эшкә бармадым. Мин беләм синең чәчәктән чәчәккә кунарга яратуыңны. Син бит чәчәк кебек хатыныңны, ике балаңны миңа алыштырдың. Мин тирәнтен фикер йөрттем. Уйладым, үлчәдем. Минем яшь гомеремне үз файдаңа җигәсең дә, кирәгем калмагач ташлап китәсең, дип...

Айрат Харисович *(шатланып)*. Син авырлы?! Рәхмәт сиңа, рәхмәт акыллым! Син дөрес эшләгәнсең...

Зилә. Ә мин сиңа бу турыда әйтергә курыккан идем.

Айрат Харисович. Дөрес, Зилә, без ир-атлар тормышка җиңел акыл белән карарга, үзебезгә игътибар иткәннәрне күбрәк яратабыз. Миннән туган бала — ул минем дәвамым. Шулай булгач, ничек инде мин сиңа ачуланыйм. Минем бөтен курыкканым — син. Бары тик син. Әйе, әйе, мин сине югалтудан курыккан кебек, үлемнән дә курыкмыйм. Син миңа гулять итәсең кебек тоела иде. Зинһар, үзеңне, туачак балабызны сакла. Нинди уйлар сине бу эшкә этәрде? Чынлап, мине яратыпмы? Чынлапмы, Зилә?!

Зилә. Бала тугач, теге хатыннарың кебек ташлап китмәсәң ярый инде.

Айрат Харисович. Мыскыл итмә инде, Зилә. Нигә алай миннән көләсең... Карт булгангамы? Мин бит сине кулымнан килгәнчә тәрбиялим. Кара ул өс-башыңны. Алтынга күмдем бит мин сине. Ә ул — безнең туачак балабыз бәхетле булачак. Әйе, һичшиксез, бәхетле булачак...

Зилә. Белмим инде, хәзер аның атасы генеральный директор була алмас. Белмим, ничек бәхетле итәргә уйлыйсыңдыр.

Айрат Харисович. Директор булмасам, бүген җылы урын табылмас дип уйлыйсыңмы?

Зилә. Белмим шул, бу больница биргән справка белән кешене заводка простой эшче итеп тә алмаулары бар. Исеңә төшер. Син андыйларның күбесен кире бордың. Хәтерлисеңме, мин синдә секретарь булып эшләгәндә, шушында яткан бер олы корсакны приемга керткән идем. Син бит аны бик тиз борып чыгардың. Өстәвенә ул чыгып киткәч, мин үзем дә синең кебек шулер дип, артыннан көлеп калдым.

Айрат Харисович. Еллары башка иде. Әмма ләкин ул бүгенгесе көндә буй

житмәслек урында утыра. Ничего, чыгыйм гына, дуслар житәрлек.

Зилә. Дуслар алар үзең югарыда утырганда гына дуслар. Тәгәрәп төшсәң... Әнә берсе дә сәлам бирми, хәтта шалтыратмыйлар да.

Айрат Харисович. Мин ул справканы тиз югалтырмын.

Зилә. Менә бит ахирәтеңдә кунакта ятасың, рәхәтме соң?

Айрат Харисович. Булды, житте! Хватит! Туйдырды! Тыңлыйсым килми. Алып ташла бу кирәкмәгән мәгънәсез уйларыңны. Син киләчәгебез, туачак балабыз турында уйла. Ул туарга һәм бәхетле булырга тиеш.

Зилә. Белмим шул.

Айрат Харисович. Нәрсә белмисең? Кемнән туачагын беләсеңдер ич? Шулай булгач, миннән туган баланың бәхетле булырга хакы бар. Тормыш законы шулай. Генерал баласы — генерал, көтүче баласы көтүче булып үләргә тиеш. Шулай булганда гына тормыш без теләгән юлдан атлаячак. Менә шул. Мин сиңа гарантия бирәм. Ул тумаган баланың хәзергесе минутта үзе картаеп үлгәнче яшәрлек байлыгы бар. Тап кына. Мин аның тормышын, яшәешен алдан ук күреп, алдан ук кайгыртып куйдым. Синнән бары тик бер нәрсә сорала. Аны табу, бары тик аны табу!

Зилә. Кызма, Әти булачак кеше. Сиңа кирәк бала миңа да кирәкмимени? Тырышырмын. Көчемнән килгәнчә барысын да эшләрмен. Тик...

Айрат Харисович. Нәрсә тик?..

Зилә. Анализларым начар...

Айрат Харисович. Ничек начар?..

Зилә. Каның начар диләр.

Айрат Харисович. Ә мин ничек итеп ярдәм итәргә тиеш?

Зилә. Диңгез буена барырга тәкъдим иттеләр. Җиләк-җимеш, яшелчә ашарга, саф һавада, диңгездә коенырга...

Айрат Харисович. Ә мин нишләргә тиеш. Путевка табаргамы?

Зилә. Син нәрсә? Сиңа аны хәзер кем бирсен.

Айрат Харисович. Шулай шул. Хәтта минем хәлемне белүче дә юк.

Зилә. Миңа путевка обещать иттеләр.

Айрат Харисович. Соң, шулай булгач, тагын ни кирәк?

Зилә. Син монда ят, мин берүзем анда ял итеп ятыйм. Син мине кемгә саныйсың?

Айрат Харисович. Минем турыда уйлама син, иң мөһиме — безнең уртак туачак балабыз турында уйла. Мин үземнең йокысыз, маңгай тирем белән тапкан байлыгымны кемгәдер калдырасым килми. Ул байлык синеке һәм минем дәвамым булып дөньяга киләсе баламныкы булырга тиеш. Акчаң бармы әле?

Зилә. Юк шул. Бетте дияргә була.

Айрат Харисович. Ничек бетте, шул арадамы? Соң бит мин сиңа ике кисәк калдырдым.

Зилә. Шулай инде, нишләтәсең. Син юкта мин көн саен туган-тумачамны, дусишләремне жыеп, банкет оештырып яттым бит. Синең белән яши башлаганнан бирле, хәтта анамны да күргәнем юк.

Айрат Харисович. Ярар инде, ярар. Мин гаепле! Барысына да мин гаепле. Әйе, алтмышны куган карт, кызы кебек яшь кешегә өйләнгәч, билгеле, мин гаепле. Әниең шуңа гарьләнә бит. Килсен, кунак булсын, үзебездә торсын. Күпме чакырдым, күпме ялынырга була. Үзе бит, үзе килми, киресенә каткан. Ярдәм итмим түгел инде, ай саен жибәреп торабыз.

Зилә *(елый)*: Мин сиңа ярдәм итмисең димим. Акча саный башладың. Яратмыйм ирләрнең хатын-кыз эшенә тыгылуларын. Кайчакта чүпрәккә әйләнәсез. Мин сиңа шул деловой булганыңа кызыгып кияүгә чыктым да. Яшермим, көннән-көн яратуым көчәйгәннән-көчәя генә бара.

Айрат Харисович *(аның күзләрен сөртә)*. Ярый булды, барысын да жайларбыз.

Зилә. Хәтта иптәш кызларым белән дә очраша алмыйм. Урамда очрасалар да читкә карап, күрмәмешкә салынып узам. Янәсе, мин жүләр, янәсе, ахмак: бабайга кияүгә чыкканмын.

Айрат Харисович. Чыкса, яшәп карасыннар алар синең кебек. Аңларлар. Шул үз яшьтәшләренә кияүгә чыкканга күрә ирләре белән озак яшиләр дә инде. Атна тулуга аерылышалар. Алар да безнең кебекләргә чыгарлар иде дә, шәһәрдә безнең кебек генеральныйлар аз шул. Бармак белән генә санарлык. Аларны да яшь белә торган акыллы хатын-кызлар эләктереп бетергән.

Зилә. Миңа нишләргә кушасың?!

Айрат Харисович. Кассадан снимать итәргә туры килә.

Зилә. Ә ничек? Синең книжкадагы акчаны миңа кем бирсен.

Айрат Харисович. Картаям ахрысы, онытып жибәргәнмен. Минем каян килеп книжкада акчам булсын ди.

Зилә. Алдашма! Килешми! Күзләрең сата! Нәрсә, беренче хатының, йә булмаса балаларың исеменә күчердеңмени?

Айрат Харисович. Син нәрсә уйлап чыгарасың, Зилә! Мин аларны күргәнем, белгәнем дә юк.

Зилә. Күрергә синең хакың да юк. Сине алардан закон аерды. Мин түгел, үз теләгең белән, гариза язып *(үзенең эченә төртеп күрсәтеп)*. Менә синең балаң, киләчәгең кайда! Менә монда. Ә аның дөньяга тууына да мин төп рольне башкарам. Киләчәгең, картлык көнебез турында уйласаң, син инде боргаланма!

Айрат Харисович. Ярый, Зилә, үз гомеремдә синнән яшерен бер эш эшләдем, дөресен сөйлим. Бу эш килеп чыккач, мин ул акчаларны бер исерек исеменә күчердем. Курыкма, ул акчаларны мин моннан чыккач, дөньялар тынычлангач синең исемеңә күчерермен.

Зилә. Ә нигә башта ук минем исемгә күчермәдең?

Айрат Харисович. Син үз акылыңдамы? Дөньябыз болганган. Сиңа ул хәтле акча каян килсен. ОБХСС тикшерә калса, синең акча — минем акча, минем акча — синең акча! Ә ул исерекне тикшерү түгел, хәтта ул аны үзе дә белми. Әгәр белсә, бүгенгесе минутта аннан да бәхетле кеше булмас иде.

Зилә. Ул исерек кем һәм аның исеменә күпме акча салынган?

Айрат Харисович. Ә менә анысын мин биредән чыкмыйча белә алмассың. Нигә ул сиңа? Тамагың тукмы? Өстең бөтенме — тыныч кына яши бир, мин чыкканчы. Карап карап торам да, син...

Зилә. Әйттем исә кайттым. Синең алдыңда шул исерек, сәрхүш хәтле дә дәрәҗәм юклыгын гына аңладым, бары тик шул гына. Рәхмәт.

Айрат Харисович. Син Зилә, үз туксаныңны тугылама. Шулай кирәк.

Зилә. Димәк, миңа санаторийга бармаска?

Айрат Харисович. Бар, әлбәттә, бар! Мин сиңа монда керер алдыннан күпме аңлаттым, «Жигулины» сат, дидем! Нәрсә, тегеләр килеп алганны көтәсеңмени? Менә шул, машинаны сат та бар! Мин моннан чыккач яңасын алып бирермен.

**Ишек шакыйлар, бүлмәгә Риваль Якубович керә.**

Риваль Якубович: Ярый, дуслар, әңгәмә тәмам. Сезгә, Зилә Саматовна, китәргә мөмкин.

Зилә *(ирен үбеп елый.)*. Үзеңне сакла. Безнең турыда кайгырма, Айрат, без бары тик синең өчен генә яшибез.

Айрат Харисович. Исән-сау йөреп кайт. Үзеңне сакла, ишетсен колагың! Миңа яман хәбәр алып кайтма!

**Зилә чыгып китә.**

Риваль Якубович. Синең өчен генә яшибез диме? *(Кычкырып көлә, бераздан)* Да, молодец син, Айрат Харисович.

Айрат Харисович. Нигә, әйтсә... Бик кызык булдымени?

Риваль Якубович. Юк ла, шундый яшь хатынны үзеңә каратып тора алгач, димәк, әле таушалмагансың.

Айрат Харисович. Риваль Якубович, син мине шушы атна эчендә моннан чыгарырга тиешсең.

Риваль Якубович. Нәрсә дисең? Шушы атнада? Син нәрсә, медсестра биргән бөтен таблеткаларны да әллә йотып барасыңмы? Ул дарулар синең өчен анти. Алмашына башлагансың түгелме?

Айрат Харисович. Риваль Якубович, мин бирредә ятсам да, дурак түгел, акылымда. Куркам мин ул җилбәзәк кыздан, куркам. Төп башына утыртып китмәсен дип куркам. Аңа бит хәзер мин кирәк түгел, аңа минем байлык кирәк.

Риваль Якубович. Да, друг, ты мой любезный, сине тормыш өркеткән. Шул сабыйдан да курыккач, сиңа дальше яшәү авыр булачак.

Айрат Харисович. Дөрес, куркам мин! Без барыбыз да куркып яшибез. Әйт әле, син еш төш күрәсеңме?

Риваль Якубович. Шуннан? Табигый...

Айрат Харисович. Төшеңдә наручниклар шалтырамыймы? *(Риваль Якубович кесәсеннән кулъяулыгын алып, муенын, битен сөртә.)* Нигә тирләп чыктың? Шалтырыйлар да... Менә шуңа күрә син минем хәлне аңла инде. Тизрәк чыгар мине. Чыдар хәлем калмады.

Риваль Якубович. Тегендә керәсең калган аны, төшеңдә түгел, өнеңдә тыңлар иден.

Айрат Харисович. Моның да аннан артык җире юк. Анда ичмасам синең белән үз акылыңдагы башкисәрләр идарә итсә, ә монда тилеләр командовать итә. Аерма зур.

Риваль Якубович. Сүзеңне чамалап сөйләш. Кайда утырганыңны онытма. Озын колаклар тыңлап тормасын.

Айрат Харисович. Әдәм көлкесе бит, позор! Шул синең итек олтанына, тырнак очына да тормаган адәм актыклары, тинтәкләр синнән издеваться итсеннәр инде. Враг народа, имеш...

Риваль Якубович. Ничего, дураклар теленнән чыгуына шатлана гына, акыллылар шул сүзне әйтмәсеннәр.

Айрат Харисович. Шул җүләрләр, кемнән-кемнән, миннән көлсеннәр инде. Ничә мең кеше белән идарә иткән, крупный заводны җитәкләгән Айрат Харисовичтан... Адәм көлкесе бит бу, позор!

Риваль Якубович. Ә менә әлеге дә баягы тегеләр янына эләксәң, бу куркаклыгың аркасында, алар синнән әллә кайчан «зона әнкәсе» ясыйлар иде инде. Ә хәзер син минем башымны себер илтеп тыкмакчы буласың. Ярый да син минем аркада булырбулмас акчаң белән үзеңә убежище таптың. Ә мин нишләрмен? Мин бит җүләргә сабыша алмаячакмын. Миңа берәү дә ышанмаячак.

Айрат Харисович. Миңа, бәлки, үз гаебемне таныырга кирәк булгандыр. Утырып чыгар идем дә котылыр идем.

Риваль Якубович. Исән чыгалсаң... Сине бирредә бөтенләйгә калдырырга теләүчеләр дә юк түгел.

Айрат Харисович. Кемнәр?

Риваль Якубович. Кемнәр белән эш йөрттең соң?

Айрат Харисович. Планнары барып чыкмас. Кисеп ташламакчы булалар.

Риваль Якубович. Уйланырлыгың бар.

Айрат Харисович. Риваль Якубович, бар ышанычым синдә! Коткар?! Өстим! Күпме сорыйсың, шул хәтле өстим!

Риваль Якубович. Син бүгенге акчаның кыйммәтен яхшы беләсең, дорогой. Акча бүгенге көндә кәгазь ул! Ул өч пачкаңны синең эшең өчен өләшә торгач, минем үземә күп калгандыр дип уйлыйсыңмы?

Айрат Харисович. Күпме телисең, өстим, чыгар гына.

Риваль Якубович. Әле теге өчесе кулга кергәне юк. Акча нәрсә соң ул... Акчадамы хикмәт. Шикләнмим, өстәрсең. Тик...

Айрат Харисович. Сора, нәрсә кирәк?

Риваль Якубович. Акча урынына бирәр атнага безелдәвегеңне миңа бүләк итәргә туры килер дип уйлыйм.

Айрат Харисович. Син нәрсә, акылыңдамы? Син нәрсә сөйлисең? Хәзер үк шушы бүлмәңдә буам үзеңне, җүләргә закон юк!

Риваль Якубович. Бар, бар, Айрат Харисович. Бары тик бер кечкенә генә укол. Аннары гомергә бирредә каласың.

Айрат Харисович. Мин сине болай ук дип уйламаган идем. Куркыныч кеше икәнсең ләбаса син.

Риваль Якубович. Без икебез дә куркыныч кешеләр. Бу дөньяда, бигрәк тә бүгенге көндә, безнең кебекләр генә яши ала. Ә тегеләр — (идәнгә төртеп күрсәтә) ике аяклылар, алар яшәми, алар хәрәкәт итәләр. Безнең кушуыбыз буенча.

Айрат Харисович. Аңа кагыласы булма!

Риваль Якубович. Ул да хәрәкәт итүче ике аяклы, акчага, ягъни байлыкка сатып алынган кол, ягъни безелдәвекләр ничек атала әле, ә, жария. Менә шул, Айрат Харисович: коллар, жарияләр элек-электән үк сатылганнар.

Айрат Харисович. Ул жария — минем хатыным. Аңлыйсыңмы, хатыным, ул авырлы.

Риваль Якубович. Менә ни өчен чыгасың килә икән. Хатын кайнарланган дисең инде, ә? Ә син шулай да уйла, уйла, Айрат Харисович. Минем бит бусагамны көн аралаш тегеләр, җилкәнле иптәшләр таптый. Ярар, дапустим, мин сине чыгардым, ди. Син бит өеңдә бер кич тә йоклый алмаячаксың. Сине бит өеңә кайтарып тормаячаклар, туп-туры рәшәткәле машина белән тегендә озатачаклар. Йә булмаса, җан дусларың... Калганы сиңа ачык.

Айрат Харисович. Зинһар, аңа кагылма. Безнең балабыз туарга тора. Черт с тобой, бала тугач уйлашырбыз. Ничек түзәргә, ничек?

Риваль Якубович. Молча.

Айрат Харисович. Шул «палач» дигәненең күзеннән куркам. Гел төнлә белән яныма килеп буар төсле. Төннәрен тиргә батып, саташып уянам.

Риваль Якубович. Буар да. Мин аңа ышанам. Ул бывший Сталин заманнарындагы НКВДның исполнителе, ягъни палачы булып хезмәт иткән, күп шәхесләрнең гомерен өзгән, ягъни теге дөньяга озаткан. Бүгенгесе көндә күкрәгенә өч совет орденын таккан, ихтирамга лаек кеше. Син аның өчен ноль. Ярый, җебемә. Мин тәртип саклаучыларга кисәтеп куярмын. Алар сине сакларлар.

Айрат Харисович. Зинһар, Риваль Якубович.

Риваль Якубович *(селектордан)*. Дежурный, бирегә керегез! (Бүлмәгә дубинкалы адәм керә.) Хәзер бу авыруны озатыгыз да, аннары минем янга керерсез!

Адәм. Яхшы. *(Чыгып китә.)*

Риваль Якубович *(бүлмә буйлап йөри)*. Ничего, синең яшергән ялтыравыкларыңнан бераз өлеше булса да минем кулга күчәргә тиеш. Безелдәвегеннән дә авыз иттерерсең. Бала көтә картлач. Картайган көнендә личный шоферының малаен, я булмаса кызын карап чәчен агартасын аңламый. Синең өчен яшибез диме, әллә йоклыйбыз диме *(шаркылдап көләргә тотына, бүлмәгә дубинкалы Адәм килеп керә)*.

Адәм. Озаттым үзен, Риваль Якубович.

Риваль Якубович *(көлә-көлә яшьләнгән күзен сөртә)*. Яхшы булган. Ул анда үзен ничек хис итә?

Адәм. Ничек итеп әйтим, палач белән Сталин күрмәгәнен күрсәтәләр аңа.

Риваль Якубович. Сизәсеңме, Сталинны хурлаган булалар. Ә ул бүгенге көндә дә армый-талмый кеше тәрбияли. *(Тагын шаркылдап көлә.)* Син анда палачны аңа каршы ныграк өстер әле. Шулай кирәк, нервларын тикшереп карыйсы килә. Арытырга кирәк андыйларны. Аннары инде үз телен үзенә чәйнәткәч, безгә кирәк әйберне ул үзе көчләп бирә башлый. Тормыш законы. Ха-ха-ха... *(Тынычлангач, җитди кыяфәттә.)* Анда сиңа тагын товар китерделәр. Билгеләнгән урыннан барып ал. Тик сак эш ит. Аннары менә нәрсә, соңгы вакытта мин сине ялтыраган күзен белән күрә башладым. Син мине беләсең, сирәгәйт ул эшеңне. Мин сиңа ике бүлмәле фатир әзерләдем, күченергә әзерлән.

Адәм. Рәхмәт, Риваль Якубович, рәхмәт. Йә, үзегездә нинди яңалыклар? Фәнни эшегез уңышлы барамы?

Риваль Якубович. Опыт ясарга, тәҗрибә үткәрергә маймыл бирмиләр.

Адәм. Нигә сезгә маймыл! Үз кулыгызда бит маймыллар, больница тулы.

Риваль Якубович *(елмаеп)*. Шулай дисеңме? Берәрсен эшкә җигәрбез ахрысы. *(Телефон шалтырый, трубканы ала. Адәмгә.)* Бар, эшеңдә бул! *(Адәм чыгып китә.)* Да, да, мин әле бу, Риваль Якубович. Кем? Кем шалтырата дим?! Ишетмим. Киредән шалтыратыгыз. *(Трубканы куя да, бүлмә буйлап йөренә. Күзе Бехтерев портретына төшә.)* Әйбәт кеше син, картлач. Безгә уңай юл сызып калдыргансың. Рәхмәт, рәхәт яши Риваль Якубович! Балда, майда йөзә. Кирәк әйберләрен кулына китереп тоттыралар. Мең дуракның берсен дәвалый алмасак та, юлын табабыз. Акыллыларны кертәбез, акыл биреп чыгарабыз. *(Телефон шалтырый.)* Да, да, мин, Риваль Якубович. Кем, Иосиф Исакович? Югалдыгыз, югалдыгыз, Иосиф Исакович. Шулай инде, билгеле, без бит вак кешеләр. Кемнәндер зависимыйлар. Юк ла инде, шаяртам, аңлыйм, аңлыйм сезнең эш кешесе икәнлегегезне. Саламәтлек? Сәламәтлек имәндәй нык. Үзегез ничек? Авырмыйсызмы? Яхшы, бирешмәгез! Тыңлыйм сезне, Иосиф Исакович. Нинди справка? Баласы учетта тора дип? Кемнең? Малаегызның? Ә, аңлашылды. Сезнең улыгызга квартира алу өчен аның баласы бездә учетта тора дигән справка кирәк, шулаймы? Ну инде, Иосиф Исакович, сезнең эш приказ бирү, ә минеке аны үтәү. Болайрак эшләрбез, мин хәзер машина белән бер кешемне җибәрәм, сез аңа барлык данныйларны бирерсез. Кирәкми, борчылып тормагыз. Кичкә әзер булачак, өегезгә илттерермен. Яхшы. Егерме өч ел инде. Мин Иосиф Исакович, шушыннан пенсиягә китәрмен инде. Шушы бүлмәдән, шушы креслодан. Нишлисең, безнең татар егетләре болайрак дип җырлыйлар иде. Сезнең халык ничек җырлыйдыр:

Ай югары, ай югары,
Айга менә кәтүче,
Без дә айга менәр идек,
Булса арттан этүче, — дип.

Надеемся инде, Сездә көч, Иосиф Исакович.

Хушыгыз. Сәламәтлек телим!

**Авырулар палатасы. Кадыйр белән Садрый әүмәкләшә-әүмәкләшә якалашалар. Алар янында елый-елый Исмай карт йөгереп йөри.**

Кадыйр. Син падла, Сталин артына качып халык дошманын качыргансың. Үтерәм мин сине.

Садрый. Кем падла? Минме? Мин Сталин солдаты. Мин синең өчен, синең балаларың өчен, киләчәк буын өчен сугышып йөрдем. Минем өчен халык дошманы юк. Ул татар, немес түгел. Шулай булгач, ул — безнең Сталин солдаты.

Кадыйр. Юк, ул дошман.

Садрый. Юк, ул дошман түгел. Немес кына дошман була ала. Татарлар, урыслар, марилар — алар безнекеләр.

Кадыйр. Әһә, сез бергә эшлисез. Син аңа сатылдың?! Син дә ил дошманы, сатлык җан!

Садрый. Күрсәтермен мин сиңа, сатлык җанны! Мин рядовой, сапер Гыйлфанов Садрый, беркайчан да туган илемне сатканым юк. Мин Сталинның үзенә ант биргән карт солдат. Син үзең сатлык җан! Сугыштан качып монда ятасың.

Кадыйр. Син дә монда ятасың...

Садрый. Мин яралы. Мин бүген төнлә өч немес «Тигрын» шартлатым кайттым. Шунда яраландым. *(Күлмәген күкрәк турыннан умырып төшерә. Йөрәк турысындагы ярасына төртеп.)* Менә минем ранам! Ә синеке кая?

Кадыйр *(тумбочкага менеп, больница чалбарын тартып төшерә. Трусиктан гына калып, бер алдын, бер артын күрсәтә)*: Менә минем ранам! Күрдеңме? Сугышта йөрергә мин дуракмы?! Күрдеңме? Күрсәң шул... *(Шулвакыт бүлмәгә Адәм Айрат Харисовичны алып керә.)*

Адәм. Күтәр, тиз бул. Хәзер үзенә сульфазин кадыйм. *(Кадыйр кан йөгергән үгездәй күзләрен Айратка төбәп, теләр-теләмәс кенә штанын күтәрә)*. Алла бар икән, әгәр мин сине качырган булсам, иртәгә минем үземне аталар иде.

Адәм. Урманнан тотып алып кайттым. Рациядән сөйләшеп ята иде.

Кадыйр. Да, что говоришь? Рациядән?.. Әйттем бит мин аны агент дип *(Адәмгә)*. Сез аннан сорау алып бетердегезме? Бетерсәгез, сез азат, аны минем хөкемгә калдырыгыз. Хәзер мин аны...

Адәм. Начальник, син аның белән чамалап. Әле ул безгә кирәк.

Кадыйр. Яхшы. *(Адәм чыгып китә. Кадыйр бармагын изәп Айрат Харисовичны үз янына чакыра.)* Кил әле монда! *(Айрат акрын гына кроватенә килеп утыра.)*

Садрый. Кемгә әйтәләр, тиз бул!

Кадыйр. Трн ягына, арт санына утыртканны кютә ул.

Исмай. Барма, абый, кач. Кыйный алар сине.

Садрый. Ах син, Исмай, тоже сатылдың, шулаймы?

Исмай. Юк, абый, мин сугыш уены яратмыйм, мин сугыштан вупчем куркам.

Кадыйр *(Айрат Харисович каршына килеп баса да, Садрыйга ишек төбенә төртеп күрсәтә)*. Урыныгызга!

Садрый. Есть *(Ишек төбенә барып, үрә ката.)*

*Айрат Харисович (әкрен генә тора)*. Син, иптәш, кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме?

Кадыйр. Нәрсә?

Айрат Харисович. Синең каршыңда кем басып торганын чамалыйсыңмы?

Кадыйр. Враг народа!

Садрый. Немес!

Айрат Харисович. Мин НКВД полковнигы Айрат Харисович Галин. Смирно! *(Кадыйр үрә ката. Бераздан буылып кола башлый.)* Смирно!

Кадыйр. Да, сине разведуправлениедә алдашырга яхшы өйрәткәннәр, подонок. Үтерәм! *(Айрат Харисовичның муеныннан буып ала.)*

Исмай. Абыйлар, абыйлар, сугышмагыз! *(Елый. Бүлмәгә Нәгыймә әби белән дубинкалы адәм килеп керәләр.)* Абый, нәрсә карап торасың, үтерә бит!

Адәм *(ишек катында елмаеп, билләренә таянган халәттә)*. Ничего, бернәрсә дә булмый. Дурак — дурак ул, живучий народ.

Нәгыймә әби. Оятсыз син! Безнең чирне, безнең язмышны ходай тәгалә сиңа насыйп итсен! *(Швабрасы белән Кадыйрга китереп суга.)* Кит дим мин сиңа! Нишлисең, җир бит! Ул да синең кебек кеше бит. *(Кадыйр кроватена кача. Үзенең буарга әзерләнгән кулына карап, шашынган халдә.)*

Кадыйр. Кан кирәк миңа, адәм каны. Мин ансыз яши алмыйм. Ишетәсезме, кан кирәк?! *(Елый башлый.)* Китерегез миңа берәр адәмне! Мин аның җанына рәхәтләнеп өрәм! Китерегез! Китерегез! *(Кроватен йодрыгы белән кыйный-кыйный елый да, арып мендәренә каплана.)*

Адәм. Кеше... Ялгышма, әби. *(Кадыйрга күрсәтеп.)* Әнә бүгенге көннең льготаларыннан файдаланып яшәүче бер кешегез! Әйе, ул кеше, аңа яхшы дару, аңа яхшы условия, затлы ризык, чиратсыз! Ә сез... Сез нинди кеше буласыз ди. Әле безне кеше рәтенә кертмиләр. Сез бәхетле: сезгә яшәү рәхәт. Ә менә безгә, безгә авыр. Ай, безгә яшәү авыр. Сезгә рәхәт. Сезгә берни турында да уйларга кирәкми. Ә безгә, үзең әйткәнчә, ходай тәгалә уй дигән, акыл дигән кабахәт нәрсәне биргән. Ничек яшәргә, иртә-таң атса кем синең намусыңны салып таптар да, кем сине мыскыл итәр... Каян ашарга табарга да, ничек киенергә?

Нәгыймә әби. Бар кешене дә аның белән чагыштырма, ул шуның өчен дә берәү генә.

Адәм. Биредә берәү, ә чынбарлыкта, алар меңләгән. Миллионлаган халыкны, нәрсә, Кадыйр гына буып үтергәнмени? Алар безнең арада, безнең белән яшиләр, без сулаган һаваны сулыйлар. Чиратсыз ашыйлар, чиратсыз киенәләр. Ә син, үзеңне кешегә саныйсың.

Нәгыймә әби. Үзебез кеше булып калыйк.

Адәм. Мөмкин түгел. Дөньясы мәхшәр. Дөньясының тиләләр йортыннан аермасы юк. Безне алдыйлар, мәҗбүр итәләр, ә без бары тик буйсынучылар.

Нәгыймә әби. Алла бар, Алла барысын да күрә.

Адәм. Әйе, Алла бар. Элек безнең ише җан ияләрен оҗмахта яшәрсез дип алдадылар, хәзер балаларыгыз оҗмахта яшәр дип алдыйлар. Сүзен дә уйлап тапканнар: киләчәк буын өчен... Ә без кайчан үзебез өчен яшәрбез соң? Кеше, җан иясе дөньяга бер генә тапкыр туа. Аның да үзе өчен яшәргә хакы бар. Ә алар үзләре дә оҗмахта яши, балалары да, ягъни киләчәк буыннары да оҗмахта яшәячәкләр.

Нәгыймә әби. Язмыштан узып булмый улым. Чир агач башыннан йөрми.

Адәм. Ахмак син, әби. Мин бирелә егерме елга якын эшлим. Бер генә олы түрәнең дә баласы бирелә, бездә ятканын хәтерләмим. Алардан җүләрләр тумый, тусалар да бик тиз үләләр. Менә шул. Бәгырь каткан, әби. Җыела, менә монда, йөрәккә җыела. Гасырлар буе адәм йөрәгенә җыелса да, тишелеп чыгардай көч табалмый. Эшлисең, эшлисең, теләгенә ирешә алмыйсың. Ә кемдер эшләми дә, ә шулай да синнән яхшырак яши, синең өстән командовать итә. Синең башың хәтле, какой, чыпчык башы хәтле мие юк. Шул синең өстән командовать итә. Итеп кенә калса ярый, намусыңны салып таптый. Кешелегеңне бетерә. Ә мин кемнән ким, син кемнән ким? Бездән көләләр икән, без дә кемнәндер үчебезне алырга тиеш. *(Чыгып китә.)*

Нәгыймә әби. Миңа тормыштан күп нәрсә кирәкми. Бары тик намазлык җәеп, намаз укырлык бер кечкенә генә почмак. Гомер буе эшләп тә шуңа да ирешә алма инде. Сукыр тычкан булып, сукыр тычкан да үзенә оя кора. Ә минем анысы да юк. Үлгәч торергә кәфенлегең дә булмасын инде. Алла каршына ничек барырсың.

Айрат Харисович. Кайгырма, әби, үлгәч кәфенлеге дә, күмүчесе дә табыла аның. Берәүнең дә җир өстендә ятканы юк.

Нәгыймә әби *(барып Кадыйрның чәчен сыпыра)*. Нишләвең бу синең, Кадыйр? Нигә тиясең син аңа? Ул да бит синең кебек, минем кебек язмыш хөкеменә дучар ителгән.

Кадыйр. Нишлим соң? Мин тимәс тә идем. Әнә бит *(арткы планда салмак кына, Сталин, Берия, Жданов портретлары күтәрелә. Алар арасында тагын портретлар, әмма ул портретларның кемнәр икәнен танып булмый, алар томан арасында кебек)* алар боера. Әнә, әнә, күрәсезме, бармак яныйлар. Әле сез белмисез, алар болар гына түгел, алар күпләр. Мин куркам, әби, ай, мин куркам. Минем кулдан йөзләгән язмыш узды. Алар, әйе, алар миңа боердылар. Мин гаепле булып калдым. Әнә, әнә күрәсезме, качалар, йөзләренә кара ябып качалар. Аларны сез таный алмыйсыз. Алар кача. Ә менә минем кулдан узган язмышлар төрле яктан килеп мине кысалар, үртиләр, үчеклиләр, куркыталар. Әнә, тагын киләләр. Әби, әби җаным, коткар мине! *(Нәгыймә әбигә елыша.)* Алар мине үтерергә киләләр. Әнә тәрәзәдән, ишектән керәләр. Коткарыгыз! Коткарыгыз! *(Тәрәзәгә сикерә, тәрәзә рәшәткәсен куллары белән кысып тота. Тамашачыга карап.)* Мин түгел, мин гаепле түгел. Мин алар боерыгын үтәүче генә. Коткарыгыз, коткарыгыз, минем яшисем килә!

Айрат Харисович *(Садрыйга кычкыра)*. Нәрсә карап каттың. Бар, дубинкалы палачны чакыр. Бәйләп атсын үзен!

Нәгыймә әби. Кирәкми, Садрый. Чакырма! Ул хәзер тынычлана.

Исмай карт. Әби, чакыртыйк теге абыйны. Ул юеш простыняга төреп салгач, Кадыйр абый тынычлана иде. Атна буе кроватьтан тормыйча тыныч кына ята иде. Чакыртыйк. Безгә дә тыныч булыр.

Нәгыймә әби. Кирәкми, Исмәгыйль. Шул юеш простыня аны теге дөньяга алып китә бугай инде. Төш, энем Кадыйр, төш. *(Кулларыннан тотып төшерә.)* Ят, ял ит. Яшисең, яшисең әле.

Исмай карт. Барыбыз да яшибез әле.

Садрый. Ә мин беркайчан да үлмәячәкмен! Мин живучий! Шуңа күрә дә мин дошманнан курыкмыйм. Терелəм дә тагын сугышка керәм. Гитлерны Сталинга тотып бирмичә мин тынычланмыйм. Сталин Гитлерны нишләтергә кирәклеген үзе белер иде инде. Аннары, сине Нәгыймә апа, кияүгә Рәсәйгә алып кайтып китәм.

Нәгыймә әби. Ярый, Садрый, ярый, шулай эшләрсең.

Исмай карт. Ә мин сез утырган атның кучеры булырмын.

Садрый. Булырсың. Өч җирән ат җигәрбез, яме? Исмәгыйль, күңелле булачак бит, әйеме?

Айрат Харисович. Искитмәле, бик күңелле экипаж булачак. Зинһар, җирән атларыгызны җигегез дә, тизрәк олагыгыз.

Исмай карт. Ә син гармунчы булырсың. Минем янымa утырып, гармун тартырсың.

Айрат Харисович. Юк инде, гармуныгызны үзегез генә тартырсыз. Мин әле сезнең белән гармун тартып җирән атка утырырга яшьрәк. Әнә, Кадыйрны алыгыз.

Садрый. Безнең якта кызны шулай алып кайталар, күңелле бит, Нәгыймә әби? Нинди күңелле!

Нәгыймә әби. Бик күңелле булыр...

Садрый. Ә син мин сугыштан кайтканчы, туй күлмәге тектереп куярсың, йәме?

Нәгыймә әби. Минем күлмәгем әзер, Садрый. Кияргә генә насыйп булмады. Туй көнен көтеп, сандыгымда саргайды. Яраттым мин аны, ай, яраттым. Һаман да булса яратам. Һаман да булса сагынам. Әллә ничек кенә булды. Без аерылышкан таң, ай тотылган төнне хәтерләтеп, минем гомеремне, йөрәгемне яралап кына калмады, мәңгелек бәхетсез итте. Минем серемне, йөрәк зарымны сөйләрлек кешем бу дөньяда юк. Тыңласагыз бары тик сез. Сездән гайре минем бер кешем дә юк. Үндүрт яшьтән ятим калып, ир назы күрергә насыйп итмәде. Ә мин аны көттем. Минутлар санап, сәгатьләр... Еллар буе көттем. Көттем. Һаман да көтәм. Бүтән аны күрмәсемне дә беләм. Ә шулай да көтәм. Ул хәзер исән булса, бабайдыр инде. Оныклары бардыр. Бәхетледер. Күптән мине оныткандыр. Ә шулай да мин аны көтәм. Аның белән вәгъдәләр куешып, туй күлмәге тектергәч, инде бергә булырбыз дигәндә генә, минем шул кечкенә, без очраша торган карама төбендә беренче

тапкыр приступым килде. Шул минуттан минем бөтен яшьлегем, тормышым җимерелде, чәлпәрәмә килде. Шул көннән ул минем янга килмәс булды. Без бер-беребезне ярата идек бит, ярата идек. Ә юллар, сукмаклар бергә булмады. Безне рәхимсез язмыш аерды. Ә шулай да мин аны көтәм. Көн саен, туй күлмәгемне актарып карыйм да, яшьлегемә кире кайтам. Бергә йөргән юлларымны, сукмакларымны сагынам. Язмыш каһәрләде мине, балалар, ай каһәрләде. Беркемне дә рәнҗетмәдем, беркемгә дә начарлыгым тимәде, заводта эшләдем, тулай торакта яшәдем. Ә инде приступларым көчәеп, ешайгач, группа алгач, моннан соңгы тапкыр кайтуыма, әйберләремне җыеп камера хранениягә тапшырган иделәр. Туй күлмәге белән, берничә күлмәгемне генә алдым да, кире биреггә килдем. Рәхмәт Риваль Якубовичка, урамда калдырмады. Ә ул әйтә, кешелеклелек, намус бетте, ди. Бар, бар алар Риваль Якубович кебек намуслы кешеләр. Ялгышмаска кирәк, гаделлек бар һәм беркайчан да бетмәячәк. Кешене ходай яраткан кебек, гаделлекне, намусны да ходай үзе яраткан. Әмма аны, намусны, кешегә булган хөрмәтне, үзеңнән читләштерергә генә ярамый. Ул синең белән бергә яшәргә тиеш.

**Ут сүнә. Кабат шул палата. Авырулар йоклап яталар. Вакыт иртә белән. Палатага Риваль Якубович, дубинкалы адәм һәм кулына папка белән ручка тоткан Ләйсән Гомәровна керәләр.**

Адәм. Авырулар, торыгыз! Хәзер сезнең белән Риваль Якубович сөйләшәчәк.

Риваль Якубович. Сез, Ләйсән, папкагызны *(Адәмгә күрсәтеп)* аңарга бирегез дә, үзегез эшегездә булыгыз. Болай да эшегез күп.

Ләйсән. Мин өлгерәм.

Адәм. Әйткәннәр икән эшләгез. *(Папканы тартып ала. Ләйсән чыгып китә.)*

Риваль Якубович *(Кадыйр янына килеп утыра)*. Йә, синең хәлләр?.. Тереләсеңме?

Кадыйр. Мин терелдем, минем бер җирем дә авыртмый.

Риваль Якубович *(Адәмгә)*. Бер атна элек бу имгәкнең хатыны үлгән. Балалары моны бездән алырга баш тарталар. Документ тутырып, тегендә, мәңгелеккә, үз ишләре янына озатырга кирәк булыр.

Адәм. Күптән вакыт.

Риваль Якубович *(Садрый янына килеп)*. Йә, герой, хәлләр ничек?

Садрый *(сикереп тора да үрә ката)*. Так точно, товарищ военврач! Жив-здоров! Фронт өчен, Сталин өчен сугышка керергә рядовой сапер Гыйлфанов Садрый әзер.

Риваль Якубович. Утыр имгәк! Синең сугышка керүең кемгә хаҗәт. Сугышып йөреп нәрсә майтардыгыз. Иректә яшәгәннәрегез әллә кайчан дөмегеп бетте сезнең. *(Адәмгә.)* Алдагы атнада мунча керергә өенә кайтарырсыз, юкса үзеннән сасыган йомырка исе килә.

Адәм. Ярар, килеп алучы булса... Безгә кирәкмәгән кебек, ул үз семьясына да кирәкми ахрысы...

Риваль Якубович *(Исмайны үз янына чакырып)*. Кил әле монда, егет! Йә, нишлибез синең белән, ә?

Исмай. Әти килгәч, кайтып китәм мин, абый.

Риваль Якубович. Кичә әтиең килеп, үз янына чакырып китте сине.

Исмай *(сикереп тора)*. Килдеме, абый, әти килдеме? Минә әйттем бит мин сезгә. Әти киләчәк дип. Мин аны бүген төнлә төшемдә күрдем. Җирән атка утыртып алып китте ул мине. Мин хәзер, врач абый, Ләйсән ападан бер-ике дару гына әтигә күчтәнәчкә алам да, сезнең белән әти янына барам.

Риваль Якубович. Урыныңа утыр, кич менә бу абыең кереп алыр үзеңне.

Исмай. Кич? Ярый, абый, мин көтәм. Урра, кич мине әти янына озаталар...

Риваль Якубович. Менә шушы кешедә тукталабыз. Сүзнең нәрсә турында икәнен аңладыңмы? Врачлар кайтып киткәч, син аны теге бүлмәгә алып керерсең. Белмәссең, бәлки Риваль абыеңа бәхет елмаеп куяр.

Адәм. Бирсен ходай!

Риваль Якубович *(Айрат Харисович янына килеп утыра)*. Ну, сезнең хәлегез ничек?

Айрат Харисович. Яхшы.

Риваль Якубович. Аппетитыгыз?

Айрат Харисович. Яхшы.

Риваль Якубович *(Адәмгә)*. Яз! Иртәгә иртәнге якта миңа приемга кертерсең. Озакламый без сезне биредән чыгарабыз. Бар әйберләр дә тәртипкә кереп бара, только соңгы бер заключениегә берәүдән кул куйдырырга кирәк. Кулы бик кыйммәт тора.

Айрат Харисович. Риваль Якубович, минем...

Риваль Якубович. Сорау бирмәгез, урыны түгел.

Айрат Харисович. Рәхмәт.

Риваль Якубович *(ачулы)*. Рәхмәтең белән хатыныңны рәтләт. *(Адәмгә)*. Ярый, мин киттем. Бүлмәләрен җилләтегез! *(Чыгып китә.)*

Адәм. Хәзер урыннарыгызны җыегыз да, форточканы ачып, үзегез коридорга чыгыгыз!

Исмай *(шатланып)*. Абыйлар, җаныйлар, минем әтием килгән. Мин бөтенләйгә китәм инде. Исән булыгыз, исән торыгыз! Мин анда чыккач, әниләрегезгә әйтермен, алар да сезне килеп алырлар.

Айрат Харисович. Кил әле монда, Исмәгыйль абзый. Янында утыр *(Кулын Исмайның иңсәсенә куя.)*. Хуш, Исмәгыйль абзый, бәхил бул. Рәнҗеткән булсам, кичер.

Исмай. Нигә рәнҗим ди. Син бит әйбәт кеше. Ошадың син миңа. Мин бит синең дустың.

Айрат Харисович. Синең өчен моннан китү, үзең өчен, бәлки, яхшырактыр да. Их Исмәгыйль, Исмай, син минем әтигә килеп ал дип әйтә күрмә инде. Миңа әти янына барырга иртәрәк әле. Дөньяда яшисем килә әле минем, Исмәгыйль абзый.

Исмай. Кара моны, дус дигәч тә, абзый да, абзый, нинди абзаң булыйм ди мин. Атаң түгелме?

**Айрат Харисович.** Юк ла инде, малый инде син, малай!

**Исмай.** Тутыккан калай *(кеткелдәп көлеп җибәрә.)*

**Айрат Харисович** *(уйчан)*. Мин дә тутыгам микәнни? Яшисе иде бит әле, жир жимертеп яшисе иде.

**Кадыйр.** Исән бул, Исмай. Син анда үзеңнең күргән кешеләреңә минем турыда сөйләмә. Мин алардан куркам. Шуның өчен дә менә шушы паласатый киемнәрне киеп йөрим дә мин. Тагын күпме киеп йөрергә язгандыр.

**Айрат Харисович** *(Кадыйрга карап)*. Да, каты чикләвек.

**Кадыйр.** А как думал...

**Садрый.** Ә минем дуслар бар анда. Әйт үзләренә, тиздән рядовой сапер Гыйлфанов Садрый сезнең сафка керә. Күп итеп махорка алып килермен дип әйтте диген.

**Исмай.** Ярый, абыйлар, аманәтләрегезне түкми-чәчми житкерермен.

**Ут сүнә. Риваль Якубович кабинеты. Зилә Саматовна белән Риваль Якубович керәләр.**

**Риваль Якубович.** Да, Зилә Саматовна, сез тагын да тазарып, чибәрләнеп киткәнсез, дингез. Сочи загары килешеп тора үзегезгә.

**Зилә.** Бер ай сизелми дә үтте.

**Риваль Якубович.** Яшь иптәш үзегезне яхшы тәрбияләгән, күренеп тора.

**Зилә.** Яшь иптәш — яшь иптәш инде, Риваль Якубович, игътибарсыз калдырмады. Җәннәттә яшәтте.

**Риваль Якубович.** Менә озакламый Айрат Харисовичны да чыгарабыз. Мин аның эшен тиз арада йомдым. Йә, Зилә, сөеклем, инде нишлибез?

**Зилә.** Нишлибез, бирегә үзен чакыртабыз.

**Риваль Якубович.** Ашыкмагыз. Безнең алда сөйләшкән уртак эшебез бар иде ахрысы.

**Зилә.** Нигәдер мин хәтерләмим.

**Риваль Якубович.** Сез мине яхшы беләсез. Бик тиз исегезгә төшерермен.

**Зилә.** Тыңлыйм, төшереп карагыз.

**Риваль Якубович.** Шаяртмагыз инде, Зилә Саматовна. Сезгә килешми.

**Зилә.** Берни аңламыйм.

**Риваль Якубович.** Камыр ашы...

**Зилә.** Алып куйган оным юк. Үзем дә ресторанда гына ашыйм.

**Риваль Якубович.** Ә, шулаймыни? Яхшы, ярый алайса, үзегезгә үпкәләгез! Ресторан ашы тамагыгызга аркылы килергә дә бик может бит.

**Зилә.** Без медицинаның куйган таләпләренә буйсынып, үз сәламәтлегебезне, ашказаныбызны саклау йөзеннән, озак итеп чәйнәп ашарга өйрәндек инде.

**Риваль Якубович.** Мин Айрат Харисовичка карталарны ачсам ни диярсез.

**Зилә.** Рәхмәт диярмен. Именно шуның өчен килдем дә. Чакырыгыз үзен!

**Риваль Якубович.** Уйлагыз, азагы начар булып бетмәсен.

**Зилә.** Уйланган, Риваль Якубович!

**Риваль Якубович.** Яхшы. Кәкре каенга тәрәттем димәкче буласың инде, шулаймы? Ашыкма, ныклап уйла. Без бит күпләр. Шушы минутта үзеңне югалтып куюыбыз бар.

**Зилә.** Барып чыкмас дип уйлыйм.

**Риваль Якубович.** Зилә, акыллым, сезнең белән без, ягъни мин бер кич бергә булуга Айрат Харисович та каршы түгел. Бер кичтән сез бер әйбер дә югалтмыйсыз. Әйдәгез, әйткән сүзегездә торыгыз.

**Зилә.** Нет! Сказала, нет! Слишком стары сез миңа!

**Риваль Якубович.** Сасы көзән, нәрсә сөйләгән була бит...

**Зилә.** Сез, вонючая поганка, сүзләрегезне чамалап сөйләгез!

**Риваль Якубович.** Стерва! Күрсәтәм мин сиңа хәзер күрмәгәнеңне! *(Селектордан кычкыра.)* Әй син, дежурный! Галин дигән тинтәкне бирегә алып кер! *(Зиләгә.)* Сиңа бүгеннән крышка, тәти кош! Мин сиңа тинтәк, дурак Айрат түгел, мине Риваль Якубович диләр. Покажу мин сиңа күрмәгәнеңне!

**Зилә.** Карап карарбыз. (Бүлмәгә Адәм белән Айрат Харисович керәләр.)

**Риваль Якубович** *(Адәмгә)*. Бүлмәгә бер кеше дә кертмә, үзең гел ишек төбендә бул.

**Адәм.** Яхшы. *(Чыгып китә.)*

**Айрат Харисович.** Зилә! Зилә бәгырькәем, кайттыңмы? *(Зиләгә якын килә.)*

**Зилә.** Якын киләсе булма!!!

**Айрат Харисович.** Нишләвең бу синең?

**Риваль Якубович.** Нишләсен. Сочида кызынып миен, мазгасын киптергән.

**Зилә.** Мине күпмегә саттың?

**Айрат Харисович.** Син нәрсә, Зилә? Нәрсә сөйлисең? Нишләп мин сине сатыйм? Кем әйтте?!

**Зилә.** Иң якын дустың. Әнә үзе карап тора.

**Айрат Харисович.** Аһ, син паразит! Монда әҗәл ролен уйнап яту белән генә чикләнмичә, хәзер минем тормышымны җимермәкче буласың?!

**Риваль Якубович.** Җимерәсе калмаган, ул сезнең әллә кайчан җимерелгән инде, ахмак!

**Айрат Харисович.** Аз иде сиңа опыт ясарга дураклар. Хәзер мин кирәк. Үтерәм мин сине! *(Ривальга килә башлый. Риваль Якубович өстәлдәге звонок төймәсенә баса. Адәм керә.)*

**Риваль Якубович.** Ал бу авыруны, әнә теге почмакка сыла үзен. Өянәге килә башлады. *(Айрат Харисовичның итәгеннән өскә күтәреп.)* Телисеңме, хәзер синең күз алдыңда, хатыныңа опыт ясыйм. Юан, шәхси уколым белән!

**Адәм.** Китәргә мөмкинме?

**Риваль Якубович.** Кузгалма! Урыныңда тор! Монда банда, медицинага хезмәт итәргә ант биргән Риваль Якубовичны сатып алмакчы булалар.

**Зилә.** Хәзер мин сезнең кем икәнлегегезне ачып салам. Әгәр дә үзегезнең кем икәнлегегезне бөтен кеше белмәсен дисәгез, чыгарып җибәрегез бу кешегезне!

**Риваль Якубович.** Минем аннан яшерен эшем юк!

Айрат Харисович. Зилә, син нәрсә? Мин сине нишләп сатыйм ди?! Күрәлмыйм мин аны. Моннан гына чыгыйм, бар эшен ачып салачакмын. Ул... Ул кеше белән кроличий опыт ясаучы фашист, наркоман! Әйе, әйе, беләм мин сине, син кеше үтерүче!

Риваль Якубович. Янама! Син бит мәче авызындагы тычкан!

Айрат Харисович. Күрәсеңме, нинди куркыныч кеше ул. Әйе, әйе, ул мине үтерәчәк. Мин аңа ышанам. Бүген алар икесе бер картка газраил булып килделәр инде.

Риваль Якубович. Иртәгә синә килергә дип уйлап торабыз.

Адәм. Дөрестән дә, Риваль Якубович, бу бәндә үз акылында түгел. Сез аны бер атнага чыгарырга дисез, нинди бер атна,— гомерлеккә, особыйлар ята торганына... Берәр ай «попросту сера» белән «аминазин» кадасак, какрас, бүгенге көн кешесенә әйләнә дә кала.

Айрат Харисович. Калдырма мине, Зилә, кызган. Мин бит начармы, яманмы — синең ирең!

Зилә. Ялгышма, син минем ирем түгел! Син мине үз интересың өчен саткансың. Ә мин, синең личный шоферың Федоренко белән Сочида язылышып кайттым. Минем ирем Федоренко.

Риваль Якубович. Бажаң — Федоренко... Теге сине утыртып йөргән, хәерче, майга каткан малай, бывший кучерың...

Айрат Харисович. Ә безнең туачак балабыз?

Зилә. Син нәрсә? Үз акылыңдамы? Нишләп мин шәлперәйгән карттан бала табыйм. Саташмаган ич мин...

Айрат Харисович. Ах, себерке! Син мине шуңа алыштырдың? Син бездән ычкына алмассың...

Риваль Якубович. Әйдә, сайрасын! Ул үзе безнең тозакта! Бүтән ул бу йорттан чыкмаячак. Үз аягы белән килеп керде.

Зилә. Шулаймы? Яшерә алмассыз, көчегез җитми.

Адәм. Карап карарбыз, чибәркәй!

Зилә. Син, син мине егерме яшем дә тулмаган килеш, үз кабинетыңда мыскыл иттең. Минем чәчәктәй яшь гомеремне ялтыравык күлмәк, кием-салым белән мәсхәрәләдең. Сигез ел мин сине, карт иблисне постельдә назладым. Назларга мәҗбүр иттең. Түздем. Тешне кысып түздем. Сигез ел син мине үзең өчен яшәттең. Ә гомер, наз бушка бирелми. Вакыт җитте. Мин узган сигез елымны синнән бүген сатып алырга килдем.

Адәм. Нәрсә мораль тынлыйсыз, Риваль Якубович, үзен кайсы палатага озатыйм?

Зилә *(Адәмгә)*. Дәшмә, мескен! Нәрсә, сине күпмегә сатып алдылар? Иреккә чыгасың киләме? Килсә булышам, минем көчем җитәрлек.

Адәм. Точно, монысы да ычкынган. Чибәркәй, тынычлан! Сыталар алар сине, бармак белән басып сыталар.

Риваль Якубович. Сөйләп калсын.

Айрат Харисович. Ахмак икәнсең. Рәхәтеңә чыдый алмадың да...

Зилә. Ахмак — син ул. Рәхәтлек, наз — яшьләр куенында. *(Сумкасыннан ачкыч алып өстәлгә куя.)* Ал! Бүлмәңне бушаттым! Җиһазларыңны саттым!

Айрат Харисович. Ничего, җиһаз акчасы белән ерак китә алмассың, тиз бетәр ул.

Зилә. Исерек исеменә салган акчаларың да минем кулда!

Айрат Харисович. Эзләп таптың, сволочь! Аһ, ялгыштым. Каян чыкты ул исерек сүзе минем авыздан. Шул вакытта ук сизгән идем бит, сизгән идем. Син гаепле, барысына да син гаепле, Якубович. Әгәр шул вакытта чыгарган булсаң... Сизәсеңме, Зилә, бетеп барганыңны? Без бит сине биредән чыгармыйбыз?!

Зилә *(сәгатенә карый)*. Чыгарырсыз! Өч минуттан минем телохранительләрем бирегә бәреп керәчәкләр. Менә сезгә касета. Бу касетада сезнең безнең квартирада сөйләшкән планнарыгыз. Тыңлап карагыз да, уйлагыз. Бу касетаның берсе ышанычлы кулларда. Ә инде, Риваль Якубович, мин сезнең белән сөйләшкән сүзләрне яздырган кассетаны алып килмәдем. Ә менә бүгенгесен туктатырга вакыт җиткәндер. *(Сумкасындагы кечкенә магнитофонның кнопкасына баса.)* Менә шул, егетләр, әгәр дә минем белән берәр нәрсә булса, ул кассета үз урынын эзләп табачак.

Риваль Якубович. Да, син простой кош булып чыкмадың, молодец.

Зилә. Шулай инде. Кайбер кызлар үзләренә проститутка исемен алып, кичләрен үзләрен йөз-йөз иллегә сатсалар, мин үземне ничәдер дистә меңгә сатарга хакым бардыр дип уйлыйм. Мин дә бит чибәрләр рәтендә йөрим. Карагыз *(итәген өскә кадәр күтәрә)* минем бу фигурамны, бу ботларымны, меңнәргә торырдай бит. Хушыгыз! Кабат очрашырга насыйп булмас дип уйлыйм.

Айрат Харисович. Чыгармагыз! Чыгармагыз, Риваль Якубович, сезнең көчтән килә! *(Адәм ишеккә ташлана.)*

Риваль Якубович. Тотмагыз! Карагыз әле сез, бу язмалар күпме тора?!

Зилә. Күп тора. Әмма ләкин сатылмый. Бу кассеталарда минем гомерем. Менә шул, сез минем озак яшәвемне аллаган ялварып сорарга тиеш буласыз. Любой, хәтта очраклы үлемем сезгә шатлык китермәячәк. Хушыгыз! *(Ишек ачылып китә, ишекнең ике ягында милиция формасында ике таза егет басып тора.)* Киттек егетләр!

Риваль Якубович. Бәдрәфханә, әйбәт каптырган! *(Айрат Харисовичка.)* Синең аркада, подонок! Бутадың башымны!

Айрат Харисович. Миңа нишләргә?

Риваль Якубович. Нишлисең? *(Адәмгә)* Кич җиткәч, үзенә галстук бирерсең. Бездән булсын изгелек.

Айрат Харисович *(Риваль Якубовичның аягына егыла)*. Риваль Якубович минем яшисем килә! Яшисем килә!..

*Пәрдә.*

*1990. Казан.*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ



# СУГЫШТА ҖИҢГӘЧ — ЗИНДАНГА...

70 ЯШЕ ТУЛУ УҢАЕННАН
КҮРЕНЕКЛЕ ЯЗУЧЫ
ГУРИЙ ТАВЛИН
БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

*— Гурий ага, Сез — зур тормыш юлы үтеп, олы тәҗрибә туплаган, Бөек Ватан сугышы мәхшәрен үз башыннан кичергән хөрмәтле язучы. Үзегезнең 70 яшегезне нindirәк уй-фикерләр белән каршылыйсыз? Аерым алганда: соңгы еллар тормышында Сезгәниләр ошый, ә нәрсәләр ошамый? Һәм ни өчен?*

— 1917 елгы Октябрь түнтәрешеннән соң элекке Бөек Рәсәй җирлегендә барлыкка килгән СССР территориясендәге халыклар ялган идеяләргә нигезләнгән алдакчылар Ватанында, коллар хәлендә яшәделәр.

Минем бала чагым да беренче бишьеллыклар чорына — агач Рәсәйне тимер Рәсәйгә әверелдерү, вак крестьян хуҗалыкларын күмәкләштереп — гади каеклардан куәтле крейсерлар корамалау, кулакларны сыйныф буларак юк итү чорына туры килде. Крестьяннарның иң тырыш, иң эшчән, иң булдыклы катламы иде кулаклар. Партиянең «зирәк» житәкчелеге астында аларны эшлексез, ялкау люмпен авылдашлары йорт-җирләреннән мәхрүм итеп, мал-мөлкәтләрен талап, үзләрен «Макар бозаулар да көтәргә базмаган төбәкләргә» сөрүләренең шаһиты булдым. Илдәге утызынчы еллар башындагы ачлык та хәтеремә тирән уелып калды. Бөек Советлар Союзы составына кушылырга теләк белдергән Балтыйк буе илләрен, Көнбатыш Украинаны, Көнбатыш Белоруссияне, Буковина һәм Бессарабияне Кызыл Армиянең ничек басып алганы, аларны «азатлыкка» ирештерүебезгә ничек шатланганыбыз да исемдә.

1934 елның 1 декабрендә С. М. Киров үтерелгәннән соң илдә иң күренекле шәхесләрдән алып гади колхозчыларга һәм эшчеләргә кадәр, корткычлыкта гаепләп тоташ репрессияләр башланды. Бик күп хәрби начальниклар чит илләр разведкаларына хезмәт итүдә гаепләнеп кулга алындылар һәм, хөкемгә тартылып, атылдылар.

1939 елның ноябрендә фин сугышы башланды. Дүрт ай чамасына сузылган ул сугыш мактаулы Кызыл Армиябезнең дошман белән житди көрәшкә бөтенләй әзер булмавын, зәгыйфь коралланган икәнен, командирлар составының хәрби стратегия һәм тактикада үтә томаналыгын күрсәтте.

Аннары немец фашистлары, сугыш игълан итеп тә тормыйча, искәрмәстән илебезгә басып керделәр һәм 1418 тәүлеккә сузылган, тарихта анарчы тиңдәше булмаган Бөек Ватан сугышы башланды. Сугыш вакытында да, гадәттәгечә, ялган өстенә ялган өстәлә барды.

Совет солдаты дошманга әсир төшмәскә, әсир төшү куркынычы туса, ул үзен үзе үтерергә тиеш, дигән ахмак таләп бар иде. «Бөек юлбашчыбыз» катыйл Сталин немецларга әсир төшкән миллионлаган совет сугышчыларын әсирләр дип танымады, аларның барысын да тик хыянәтчеләр итеп кенә күрде. Башка

илләр әсир төшкән үз солдатларына Кызыл хач җәмгыяте аша ярдәм иткәндә, безнең әсирлеккә эләккән сугышчыларыбызны бар дип тә белүче, аларга ярдәм кулы сузарга уйлаучы кеше табылмады. Безнең әсирләр, язмыш иркенә бирелеп, ачлыктан һәм авырулардан чебен урынына кырылдылар. Күбесе фашист лагерьларында могҗиза белән исән калып, илгә әйләнеп кайткач, ГУЛАГ тоткынлыгына тарыды.

Октябрь түнтәрешеннән соңгы чор эчендә күпме милләтләр, милли традицияләр, телләр, мәдәни хәзинәләр, гореф-гадәтләр, йолалар юкка чыкты, яшәүдән туктады, җимерелде. Әйе, совет халкы, чын мәгънәсендә, кол һәм хайван хәлендә иде. Ул әле бүген дә шул хәлдәрәк кала килә. Аны кешелексезлек, мәсхәрә чокырыннан арындыру, чын ирекле итү җиңел булмаячак. Без үз гомеребездә алдаудан башка нәрсә күрмичә, үзебез дә алдарга өйрәндек һәм, нәтиҗәдә, ялган белән чынны аера алмас хәлгә килдек.

Соңгы еллар тормышында миңа бушсүзлелек, артык олыдан кубып тел белән тегермән тартырга тырышу, булган кимчелек-җитешсезлекләребезне үзебез түгел, читтән кемнеңдер килеп бетерүен, хәл итүен көтү, үзебезнең әйләнә-тирәбездәге мөхиткә (яхшымы ул, начармы икәнен тикшереп тормый) яраклашырга тырышуыбыз ошамый. Аннары урынлы-урынсызга үзебезнең мәнсезлегебездә, денсезлегебездә урысларны гына гаепләвебез саруны кайната. Дөресен, әйткәндә, телебезне без үз иркебез белән, руслардан бер карышка да артта калмаска тырышып, үз-үзебезне хөрмәт итмәү, санга сукмау аркасында оныттык. Әнә, инде мең еллар безнең арабызда гомер кичерүче ассириялеләр үткәннәреннән дә ваз кичмиләр, руслашмыйлар да, татарлашмыйлар да — үз телләрен онытмыйлар бит. Югыйсә, аларның үз телләрендәге мәктәпләре генә түгел, инде биш былтыр гражданлыклары да юк! Без, татарлар, үз үзебезгә үзебез төкерергә гадәтләнгәнбез, телебезне үз иркебез белән оныттык, мәчетләребезне рус Васькалар, рус Мишкалар җимермәде — үз Галиләребез, үз Вәлиләребез җимерделәр. Бәйсезлек яулавыбызга да инде менә алтынчы ел китте, ә парламентыбыз һаман да әле туган телебезне санга сукмый. Туган телне тик урам теленә генә санап, ватып-сындырып русча пупалыйбыз һәм моның якын арадагы чиге дә, ахыры да төсмерләнми. «Балык башыннан чери», дию дөрес ул. Тел нормаларыбызга туры килә торган алфабитыбызны булдыруда да кемнеңдер булышлыгын көтәбез кебек. Ә бит инде үз Фәннәр академиябез, анда галим исеме йөртүче күпме галимнәребез бар. Миндә «Фәннәр академиябез дә, анда чалбар төбе ышкып утыручы «эрудицияле» фән әһелләребез дә кәгазьдә генә түгелләр микән?» — дигән шик яши. Милли яңарышыбызны, Алла түземен югалтып ярдәм итмәсә, безгә әле озак, бик озак көтәргә туры килер кебек.

*— Соңгы елларда безнең журналда сезнең өч әсәрегез басылып чыкты. Аларда үзегезнең авыр тормышыгыз чагылды. Ул әсәрләрне укучы яратып кабул итте. Ә хәзер нәрсәләр язасыз — Сезнең кебек зур тормыш тәҗрибәсе туплаган кешенең иҗат ялкыны тиз генә сүрелми бит ул.*

— Минем инде күптән язылып, соңгы ноктасы куелган берничә зур әйберем бар. Аларны дөньяга чыгару турында бүгенге болгавыр заманда уйларлык та түгел. Соңгы елларда татар матбугатында керәшеннәр турында ярыйсы ук бәхәсле материаллар басылды. Аларда берәүләр керәшеннәрне милләт итеп күрергә тырыштылар, икенчеләре аларны халыкка гына санадылар. Шуннан соң миндә керәшеннәр турында роман язу теләге туды. Үзем дә керәшен булганлыктан, мин алар турында нык кызыксына, аларның асылына төшенергә омтыла идем. Керәшеннәр — дискриминацияләнүче, кимсетелүче, кыерсытылучы халык. Алар — диннәре христиан дине булса да, руслар тарафыннан да, телләре татар теле булса да, татарлар тарафыннан да өнәлмәделәр. Татарстан Дәүләт советы депутатлары һәм республикабыз районнары хакимият башлыклары арасында бер генә керәшеннең булмавы да моны кире каккысыз итеп дәлилли.

Керәшеннәрнең ерак гасырлардан сакланып килгән үз гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш рәвешләре, үзләренә генә хас киеме-салымнары, бизәнү әйберләре, фольклорлары, үзгә культуралары, тел, моң үзенчәлекләре бар. Аларның сөйләм телләренең татар сөйләм теленә якынлыгы гына «керәшеннәр — чукындырылган татарлар алар», диярга нигез була алмый. Башкортларның да, балкарларның да телләре татар теленә якын бит, нигә соң алар да татарлар саналмыйлар, ә аерым милләт исәпләнәләр? Кайбер иптәшләр матбугатта хәтта керәшеннәргә керәшен булуларына хурланырга киңәш бирүдән дә тартынмадылар. Бу — акылга сыймаслык мәгънәсезлек бит! Болгар дәүләтендә яшәгән, тарихта эзләре кая китеп югалганы билгесез бортаслар, бәләнҗерләр булганы билгеле. Алар кемнәр — моны тәгаен генә берәү дә әйтә алмый. Кем белә, бәлки алар керәшеннәрнең ерак бабаларыдыр? Явыз Иванның Идел буе халыкларын көчләп чукындыру сәясәте үткәрүенә генә таянып,

«керәшеннәр элек чеп-чи татарлар булганнар» дип кистереп әйтү, минем карашымча, зур ялгышлыктыр.

— *Хәзер әдәби әсәрләр укырга вакытыгыз каламы? Татар әдипләреннән кемнәрнең әсәрләрен яратып, тәм табып укыйсыз?*

— Рус әдәбиятындагы яңалыкларны да, татар әдәбиятындагы яңалыкларны да даими карап барырга тырышам. «Новый мир», «Октябрь», «Дружба народов», «Казан утлары», «Идел», «Аргамак» журналларының яңа саннары һәрвакыт минем кул астымда. «Роман-газета»ны да укымый калганым юк. Мин Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәгъсүм Хуҗин, Фоат Садриев, Нәбирә Гыйматдинова, Айдар Хәлим, Тәүфикъ Әйди, Рашат Низамиев әсәрләрен күтәп алып һәм зур кызыксыну белән укыйм. Аларда фикер тирәнлеге, милли аһәң, күңелгә уелып истә калырлык образлар, чын татар рухы гәүдәләнә.

— *«Афәт» исемле роман-трилогиягездә байтак кына каһарманнар тормышта булганча һәм күбесе үз исемнәре белән алынган иде. Ул басылып чыккач, укучылардан борчулы хисә бүтән төрле хатлар булдымы?*

— «Афәт» романын мин 1967 елда башлап, 1970 елда язып бетердем. Ул үзем өчен генә язылган иде. Аның кайчандыр басылып, укучылар кулына керәчәген мин башыма да китермәдем. Шуңа күрә андагы образлар күбесе үз исемнәре, үз төс-кыяфәтләре белән бирелделәр. Журналга басканда аларның кайберләренең исемнәре үзгәртелде.

1988 елда «Казан утлары» журналында Казагыстанда яшәүче, үз вакытында ГУЛАГ әсире булган өлкән әдип Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» исемле романы дөнья күрде. Шуннан соң мин дә, бәлки, «Афәт» тә кемгәдер ошап куяр дип аны «Казан утлары» журналына илттем. Трилогиямне журнал редколлегиясе ошатты һәм 1990 елда журналда аның беренче кисәге, 1991 елда икенче кисәге, 1994 елда өченче кисәге дөнья күрде. Укучылар әйберемне җылы кабул иттеләр, матбугатта аңа караган уңай рецензияләр басылды. Ул хәзер урта мәктәп программасына кертелде. Ә үзем мин триллогиямнән канәгать түгел. Ул таркау, сыек килеп чыккан. Мин аны инде башкача, киңрәк тә, тирәнрәк тә, образлырак та, саллырак та итеп язарга тырышыр идем. Ләкин инде соң — поезд китте, аны кул болгап озатудан гайре чара юк.

— *Сез кайчан каләм тибрәтә башладыгыз, бәлки шуны да искә төшереп үтәрсез?*

— Фикер-тойгыларымны кәгазьгә күчерә башлавыма күп гомер инде. Тәүге тапкыр мин фамилиямне ташка басылган итеп 1936 елда «Яшь ленинчы» газетасында чыккан «Галстуклар юк» дип исемләнгән кечкенә генә мәкаләм астында күрдем. Ләкин анда исемемнең баш хәрефе каты латин Г сы белән язылган, фамилиям Танлин дип басылган, мәктәбебезнең адресы исә буталмаган, дөрес күрсәтелгән иде. Әмма мәкаләне мин язганны берәү дә белмәде. Газета килеп берничә көн үткәч, миңа конверт тышына кызыл белән нәкъ газета башындагыча матур итеп «Яшь ленинчы» дип язылган хат килеп төште. Конвертны ачып хатны укыгач, өнсез калдым. Ул газетада чыккан мәкаләм астындагы исемем һәм фамилиямнең хата белән чыккан өчен газета исеменнән түбәнчелек белән гафу үтенеп, хата җибәрүдә гаепле кешеләрнең инде тиешле җәза алуларын әйтеп, «Яшь ленинчы» белән урнашкан элемтәне киләчәктә дә дәвам итүемне сорап Абдулла абый Алиш тарафыннан язылган иде! Тагын бер атнадан мәктәбебезгә посылка да килде. Ул посылкада пионер оешмабызга кемдер 30 галстук җибәргән иде. Бу мәктәбебез өчен зур сөенеч булды.

«Җәйге кич» исемле тәүге шигырем дә «Яшь ленинчы»да чыкты.

— *Сез вакытлы матбугат битләрендә еш күренәсез. Үткен-үткен әсәрләр, мәкаләләр бастырасыз... Үзегез дә газетада эшләп алдыгыз. Ә менә милли матбугатның хәзерге хәлен ничек бәялисез: аңа бигрәк тә нәрсә җитешми икән?*

— Милли матбугатның хәле, турысын әйткәндә, мактанырлык түгел. Республикабызда газеталар хәзер күп чыга, әмма аларда дөнья күргән материалларның күбесенең сыйфатлары гафу итмәслек дәрәҗәдә түбән, эчтәлекләре кызыксыз, сыек, бәян ителешләре күпсүзле, телләре шапшак, бизәлешләре ярлы, күңел кайтаргыч зәвыксыз. Аларның барысында да диярлек проблемалы мәкаләләрне бик сирәк күреп була. Бу, бәлки, аларда эшләүче журналист кадрларның әзерлекле булмауларыннан, үз өсләрендә эшләргә иренүләреннән, башка газеталарда эшләүче каләмдәшләренең язганнарына күз дә төшермәүләреннән киләдер?! Соңгы вакытларда милли газеталарыбызда истә калырлык, йөрәккә үтеп кереп, күңелне кузгатырлык, уйландырырлык мәкаләләр бик сирәк басыла. Шуңадыр, газеталарыбыз халыкка бик авыр тарала. 7 миллионлы татар халкына 10—15 мең тираж белән чыккан милли газеталарыбыз — диңгездән бер тамчы гына бит югыйсә! Газеталарыбызның таралмавын халыкның

акчасызлыгына кайтарып калдыруны аңламыйм мин. Әнә, русларның «Аргументы и факты», «Комсомольская правда», «Труд» газеталары миллионлаган тиражлар белән чыксалар да, безнең кайбер ике-өч мең тиражлы газеталарыбыз кебек киоскларда сатылмыйча, тузан җыеп ятмыйлар, килү белән дәррәү сатылып бетәләр бит. Минемчә, безнең газеталарның кызыксызлыгыннан алардагы хезмәткәрләрне еш кына алмаштыру, аларда конкуренция барлыкка китерү белән котылырга, газеталарга торымнан-торымга «яңа кан» җибәрү юлы кулланырга мөмкин кебек. Торгынлык — инициатива дошманы, торгынлыктан котылып кына яңага барып була.

— *Соңгы елларда керәшеннәрнең мөселман диненә кайту очраклары күзәтеләме? Сез үзегез моңа ничек карыйсыз?*

— Мин былтыр туган төбәгемә кайткач, Зәй районының Туңылҗа авылында яшәүче әтием белән бертуган апамның оныгының татар кызына өйләнеп Валерийдан Вәлигә әверелүен һәм ислам динен кабул итүен ишеттем. Аның бу гамәле мине шатландырмады да, пошындырмады да. Аек акыл белән эш иткән кеше үз язмышына үзе хуҗа. Мин үзем дин тотмыйм, минем өчен христиан дине дә, ислам дине дә бер үк төсле, алар арасында аерма күрмим. Аллага ышанучыларга, дин тотучыларга хөрмәт белән карыйм.

— *Сезнең исемегез һәм фамилиягез дә серле бит. Ул псевдоним түгелме? Чын исем булса, аларның бераз тарихын әйтмәссезме икән?*

— Исемем дә, фамилиям дә псевдоним түгел, үземнеке. Зәй районының мин туган Урта Баграж авылында тагын башка беркайда да очрамый торган Ботаков, Титәров, Тазов, Кандрабаев фамилияләре дә бар. Фамилиям минем Тау иле (Зеленодол ягы) төшенчәсеннән туган булырга тиеш. Чөнки хәзер Зеленодол районына кергән Күгәй авылы советындагы Тау иле авылы хәзер дә русча Тавлино дип йөртелә. Ерак бабаларымның Зәй төбәгенә шул авылдан күчеп килгән булулары мөмкин. Нәсел шәҗәрәм җиде бабама кадәр билгеле: әтием Иван, бабам — Филипп, бабамның әтисе Степан, Степанның әтисе Василий (аны әнием: ул бабаңны «тугыз уллы Бәчүкәй дип йөрткәннәр», дип сөйли иде), аның әтисе Фома, Фоманың әтисе Евстигней (Сигный), Сигныйның әтисе Платон, Платонның әтисе Федор (Пидыр), Федорның әтисе Тихон булган. Фома исемле бабам мин туып-үскән Урта Баграж авылына XVII гасыр урталарында күчеп төпләнгән булырга тиеш. Исемем Явыз Иван Казан ханлыгын тар-мар иткәч, ханлыктагы җирле халыкны христиан диненә дүндерергә килгән Варсонофий, Герман, Гурий атлы миссионерларның берсен ядлау рәвешендә миңа тагылган. Гурий борынгы яһүд телендә «яшь арслан» дигән мәгънәне аңлата. Христиан чиркәве алда телгә алынган өч миссионерның дин юлында кылган уңышлы гамәлләрен искә алып, аларның өчесен дә Казан епархиясенең изгеләре итеп игълан итә. Аларның мәетләренең калдыклары Октябрь түнтәрелешенә кадәр Казан тирәсендәге монастырьларда сакланган була.

— *Әйтеп үткәнебезчә, Сез Ватан сугышын үз башыннан кичергән язучы. Ул сугышка карата хәзер төрле фикерләр ишетелә. Сез нинди фикердә торасыз һәм ни өчен шулай?*

— Бөек Ватан сугышында совет халкы ныклык, фидакарьлек, гражданлык сынавы үтте. Көндәлек тормышта очраган нинди генә коллизияләргә дә карамастан, ул патриотлык, Ватанга бирелгәнлек рухында тәрбияләнгән иде. Фашистлар сугышның беренче көннәреннән үк үзләрен чын вәхшиләр итеп таныттылар. Бер гаепсез бала-чагаларны, хатын-кызларны, картларны, карчыкларны ничек теләсәләр шулай мәсхәрәләделәр, ничек туры килсә шулай каһәрләделәр, аттылар, астылар. Аларның Одесса университеты таш идәннәренә башта олы хаҗәтләрен башкаруы, аннары шуны профессорлардан телләре белән ялатып юдырулары, үзләренең бу хайванлыкларына һәм адәм ышанмаслык этлекләренә чиксез шатланып, фән әһелләренең телләре белән шакшы идәнне ялауларын киноэкранда күргән кем дә генә фашист мөртәтләргә каршы нәфрәт уты дөрләтмәде икән... Фашистларның кешелек дөньясына һәлакәт алып килүләре берәүгә дә сер түгел иде. Шуңа күрә совет сугышчылары, җиңелгән тәкъдирдә үзләрен нәрсә көткәнен тирәнтен аңлап, фашистлар табаны астында калуга караганда үлемне артыграк күрде һәм алларына ил куйган изге бурычны икеләнүсез үтәделәр. Кайберәүләрнең хәзер «сугышта фашистлар җиңгән булсалар, без бу көнгә калмас идек», дип акыл сатуларын мин чын ахмаклык дип кенә атар идем. Бу сугышта шәһит киткән туганнарыбыз, кардәшләребез, якыннарыбыз истәлегенә турыдан-туры кара ягу, узган сугыш турында «үзенчәлекле фикер йөртәбез», дип мөгез чыгару гына.

Мин сугышта катнашуыма үкенмим, ил алдында гражданлык бурычымны намус белән үтәвемә чын күңелдән горурланам.

— *Сез сугыш темасын гына үзәккә алып, аерым әсәр язмадыгыз шикелле... Ә бит хәзер сугышны кичергән кешеләр аз калды. Әсәр яза калсагыз, ул кызыклы килеп чыгар иде бит... Бу хакта ни уйлыйсыз икән?*

— Былтыр мин, Бөек Җиңүнең 50 еллыгына багышлап, «Үлем дәрьясы» дигән повесть яздым. Анда 1943 елның сентябрендә совет сугышчыларының Днепрны кичү фаҗигасе сурәтләнде. Повесть үзем теләгәнчә килеп чыкмаганга, мин аны берәүгә дә күрсәтмәдем. Вакыт табылу белән аны ничек тә «кондициягә китерергә» утырачакмын. Мин үзем катнашкан ул коточкыч дәһшәтне тыныч күңел белән хәтеремдә яңарта алмыйм. Сугыш турында язу авыр, бик авыр...

— *Сезне «СССРның бер зур бүләгеннән баш тарткан икән» дип сөйлиләр. Шуның сәбәпләрен әйтеп бирә алмассызмы?*

— Булды андый хәл, ләкин аны чиктән тыш вакыйга дип санау кирәкме икән? Ул болай булды: 1975 елның 15 декабрендә мине Вахитов районы хәрби комиссариатына чакырдылар. Бардым. Чакыруда күрсәтелгән 18 нче бүлмәдә утыручы подполковник Терехов янына кердем. Ул: «Хәзер үк республика хәрби комиссариатына барыгыз, сезне анда зур бүләк тапшырырга көтәләр», диде. «Нинди бүләк?» дидем. «Зур орден,— диде подполковник киң елмаеп,— котлыйм». «Мин аласы орденнарымны сугыш вакытында ук алган идем инде, башка бернинди орден да көтмим», дидем. «Юк, бу ордынны сез алмаган булгансыз. Барыгыз республика хәрби комиссариатына, чабыгыз тизрәк». «Туй узгач, итекләрем тузгач, миңа бернинди бүләк тә кирәкми инде». «Нишләп?».. «Миңа иң олы «бүләкне» 1950 нче елда бирделәр, шуннан соң әле һаман акылыма килә алганым юк!» «Берни аңламыйм, нәрсә булды?» «Макар бозауларын да көтмәгән җирләргә» сөрелдем, Себер киңлекләрен күрсәтеп, акны карадан, караны актан аерырга өйрәтеп кайтардылар. Мәсхәрәләндем, житәр, тагын да мәсхәрәләнәсем килми». «Бүләктән баш тартасызмы әллә?..» «Аны мине нахакка түбәнсеткән, мыскыллаган бәндәләр таксыннар!» «Орденыгызны алырга бармыйсызмыни?» «Бармыйм, аның миңа кирәге юк! Әле күптән түгел генә каторжан номеры йөргән түшемә бөек даһи сурәте төшерелгән бүләкне кимсетеп, тагып йөрисем килми!»

Шулай итеп, мин республика хәрби комиссариатына бармадым.

1976 елның 3 мартында подполковник Терехов мине хәрби комиссариатка тагын чакыртты. Баргач, сүз озайтып тормады, машинага утыртып, республика хәрби комиссариатына алып китте. Анда комиссариатның бүләкләр бүлеген житәкләүче Устинов дигән кеше янына кердек. Мин шунда зур бүләктән баш тартуым турында нинди дер кәгазьгә имзамны салдым. Аннан соң инде мине, орден ал, дип бүтән борчучы булмады. Менә шул.

— *Соңгы еллар тормышында өметсез, кара тенденцияләр бик тә күбәйде. Кешеләрне өметсезлек тә били бара сыман... Ә сез киләчәкне (илле ел чамасы дип алсак) ничегрәк итеп күзаллыйсыз? Татар әдәбиятының шулай ук илле елдан соң булачак киләчәген ничегрәк итеп күрәсез?*

— Кара төнне һәрвакыт якты көн алмаштыра. Мин бу аңлаешсыз болгавыр заманның да озак елларга сузылмый үтеп, арттa каласына шикләнмим. Тормышны шөкәтсез спектакльгә әверелдергән бүгенге «дерьмократлар»ның соңгы сәгатьләре инде күп көттермәс, шәт. Ул йолкышлар тик үзләре турында гына кайгыртып, киләчәкләреннән мәхрүм калдылар бит инде! Туасы буыннар без тарыган, без кичергән бу болагай дәверне тарихтан өйрәнгәндә гаҗәпләнми калмаслар, әлбәттә. Аларны мин бездән күпкә бәхетлерәк булырлар дип уйлыйм. Әдәбиятыбыз да илле елдан соң шаулап чәчәк аткан булыр. Оныкларыбызны мин бездән күпкә акыллырак, зирәгрәк булырлар, тамырлары мең еллар тирәнлегенә киткән үзенчәлекле әдәбиятыбызны корытмаслар, дим. Татар барда — хәтәр бар. Милләтебез алга тәраккый итәр, димәк хәтер юкка чыкмас. Ул туачак буыннарның иҗат дәртен сүндермәс, яшәтер.

— *Соңгы елларда яшьләр әдәбиятка чагыштырмача азрак килә. Сез моны дөрес дип саныйсызмы? Алар күбрәк килсен өчен нәрсәләр эшләү кирәк икән?*

— Татар әдәбияты утызынчы елларда, аннары сугыш чорында уннарча әдипләрен, шагыйрьләрен югалтты. Әмма, финикс шикелле, тиз арада яңадан тернәкләнде. Халкыбыз — сәләтле. Язучылар сафларын тулыландырасы яшьләр, әдәбиятка буш кул белән килмәс өчен, бүген түл җыялар. Үзләре яшәгән буталчыклы тормышны тәмам аңлап, аны ничегрәк сурәтләү-гәүдәләндерү турында баш ваталар. Аларның әдәбиятта урын алырга ашыкмауларына борчылмаска кирәк дип саныйм.

Әңгәмәне **Мансур ВӘЛИ** үткәрде.



# ШАГЫЙРЬ МИҢЛЕКӘЙ

Бүгенге татар укучысына
аз билгеле,
әдәбиятыбыз тарихы
китапларына кермәгән
шагыйрьләребез арасында
**Сәхаутдин МИҢЛЕКӘЙ**
исеме дә бар.
Шушы елның
7 декабрендә
аның тууына йөз ел тула.

Сәхаутдин Кашшафетдин улы Миңлекәй Татарстанның Баулы төбәгенә карый торган Акбаш авылында игенче гаиләсендә туган.

Башлангыч белемне үз авылларында алгач, Сәхаутдинне 1906 елны атаклы Бәйрәкә мәдрәсәсенә бирәләр. 1913 елны ул Добрино авылындагы ике класслы урыс мәктәбенә кереп укый башлый. Шул ук елда туган авылында кызлар мәктәбе ачып, укыту эшенә керешә. 1915 елны Сәхаутдинне патша армиясенә солдат итеп алалар. Укыйяза белгән бу егет солдатлар арасында абруй казана, 1917 елны февраль революциясе булгач, аны солдат комитетларына сайлыйлар.

Сәхаутдин 1913 елдан яза башлый. Солдатта вакытта аның шигырьләре фронтта татарлар өчен чыгарыла торган «Безнең тавыш» (Псков) һәм «Сугыш хатирәләре» исемле газеталарда, шулай ук Гаяз Исхакый тарафыннан чыгарылган атаклы «Ил» дә басыла.

1918 елны аны армиядән демобилизовать итәләр. Ул ватанына кайтып, укытучылык эшенә керешә. 1919 елда Самара шәһәрендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү курсларында укый; Зәй Каратай, Әлмәт, Чәшеле (Югары һәм Түбән Чыршылы авыллары), Әпсәләм авылларында тарихта беренче мәртәбә татар балалар бакчалары оештырып җибәрә. 1920 елда ул Бөгелмә шәһәрендә дә беренче балалар бакчасы оештыра. 1921 елны ачлык вакытында бу балалар йортлары күп ятимнәрне ач үлемнән алып кала.

1926—1929 елларда Ленинградта өч еллык югары кооператив курсларында укый. 1929—1932 елларда Казанда кооператив техникумында статистика фәне укыта. 1932 елны яңадан Бөгелмәгә кайтып, андагы сәүдә һәм кооператив мәктәбендә эшли. 1942—1946 елларда хәрби хезмәттә була. 1950 елда Уфа шәһәренә күчеп килә һәм шунда, 1954 елның 14 гыйнварenda, авырып үлеп китә.

Сәхаутдин Минлекәй шигырьләрендә авыл тормышы, табигать һәм хезмәт кешесе, империалистик сугышта авыр солдат хәле тасвирлана. Шагыйрь Октябрь революциясен шатлык белән каршылый, ләкин үзенең алданганлыгын гражданнар сугышы һәм аннан соңгы сәясәттә ачык күрә башлый... Педагог буларак, шигырьләренә мәктәп, тәрбия, балалар темасы да ят түгел. Яшьтән үк татар фольклоры белән кызыксыну аның шигырьләренә дә халыкчанлык төсмере бирә. С. Миңлекәй дистәләрчә әкият, мәзәк, текстлары туплаnып, аларны шагыйрь үзе исән чагында Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырган булган: татар халкының күп томлы фольклор җыелмасы хәзерләгәндә галимнәребез С. Миңлекәй хезмәтләрен дә искә алганнар һәм томнарга керткәннәр.

Шагыйрь һәм фольклорчы Сәхаутдин Минлекәй — берничә китап авторы. 1925 елны аның фольклор материаллары нигезендә язылган «Җырлы

уеннар», 1927 елны Казанда «Кояшка таба», 1931 елда үз иҗатын эченә алган, балалар өчен «Тезмә сүзләр» җыентыгы һәм урысчадан тәрҗемә шигырь, проза китаплары дөнья күрә. 1951 елда ул Уфада «Авыл кооператив кибетләрендә исәп-хисап йөртү» һәм 1952 елда «Сельпо хуҗалыгында акча, товар һәм башка бәялекләрне барлау» исемле уку әсбаплары язып бастыра... Аның архивын Уфада яшәүче кызы, пенсиядәге врач Чәчкә ханым Тукаева Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсенә китереп тапшырды. Архивта әдипнең басылмаган хикәяләре, «Акбаш авылы үткәне» язмасы, «Гөлбикә» поэмасы, «Качкыннар» драмасы, басылмаган шигырьләре һ. б. бар.

Шунсы игътибарга лаек ки, Сәхаутдин Миңлекәй үзенең бер шигырь җыентыгын нәшриятка төзеп биргәч, рецензент Кави Нәҗми: «Бу китапта бер генә урында да социализм, Сталин кебек сүзләр юк, аларны басарга ярамый»,— дип каршы төшкән булган. Әнә шуңа аның иҗаты 1930 еллардан соң күренми, басыла алмый кала... С. Миңлекәйнең әдәби мирасы һичшиксез өйрәнелүгә һәм кабат басылуга лаек. Түбәндә без аның шигърияттеннән берничә үрнәк китерәбез.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# Миңлекәй

## Кирәк түгел миңа...

Кирәк түгел миңа алтын сарай,
Зур исемнәр, таҗлар, тәхетләр.
Кирәк түгел миңа байлык, дан, шөһрәтләр,
Кирәк түгел андый бәхетләр!

Кирәк түгел миңа матур кызлар,
Тәмле эчемлекләр, шәраплар.
Кирәк түгел бричка, тарантаслар,
Кареталар, юлга шәп атлар!

Кирәк булса сезгә — булсын барсы,
Миңа кирәк ирек, киң ялан,
Кайда хуш ис гөлләр, күбәләкләр,
Кошлар сайрый,— шуңа шатланам!

*1917*

## Сабанда

Мин яшь идем әле ул чагында,
Әткәй, абзый киттек ялангa.
Ат атланып, тырма, сабан салып,
Җир сөрергә язгы сабанда.

Яз кояшы жылы нурлар коя,
Илне сөя, күктән тургайлар —
Канатларын кагып, киң яланны,
Тырыш илне мактап җырлыйлар.
Киң сәхрәдә халык кырмыскадай,
Әрле-бирле кайный, шау килә.
«Һай, малкайлар!» диләр, ат каулыйлар,
Ат кешәнни, җырлар ишетелә.
«Эшләр уңсын»,— диләр үтүчеләр,
«Яхшы сүзгә рәхмәт!» «Һайт!», диләр.
Шау-гөр килгән тавыш арасында
Сабаннар да сызып җырлыйлар...
Барып җиткәч җиргә эш башладык,
Әткәй тубал асты муйнына.
Чәчү чәчә, абзый сабан сөрә,
Тырма тырмалыймын мин менә!..
Егет-җилән, малай-салай, карт-коры,
Барысы да шат, нинди ямьле кыр!
Тукта, тукта, әнә берәү җырлый,
Ялан тына, халык тыңлый җыр:
«Атларымны атлатып, сабан сөрәм басуда,
Сабан сөрәмен, җырлыймын,
Яшь күңелем ярсуга...
Бодай чәчәм уңсын дип,
Буразнасы тулсын дип,
Зур башаклы эре бодай,
Көзгә насыйп булсын дип.
Иген уңса көз көне,
Куанырбыз ил белән,
Яшь егетләр туй итәрбез,
Кавышып нечкә бил белән».
Егет-җилән шунда сулыгып алды,
Малай-салай бары да көлделәр.
Карт-корылар шунда, башын селкеп,
«Әйттерә бит егет!» — диделәр.

*1923*



## Садретдин Максуди

# АНГЛИЯГӘ СӘЯХӘТ [1]

### XV

**Лондонда өченче көн. Британия музәханәсе. Көтебханә вә бунының зурлыгы. Ике миллион китап. Мисыр вә Ассурия мәдәнияте. Бунлар хакындагы төшенчәләр. Заманы хазир [2] мәдәниятенә иртибат [3]**

Бу көн иртә торгач ук автомобильләр илән янә шул күрсәтүче әфәнделәр илән Лондонның мәшһүр Британия музәханәсене карарга бардык. Британия музәханәсе музәханә генә түгел. Бу көндә бу бина дахилендә һәм бер музәханә, һәм бер көтебханә мәүҗүддер [4]. Һәм музәханәсе, һәм көтебханәсе дөньяның бу кеби мөәссәләренең [5] бик зурларыннандыр, хосусән бу музәханә дөньяның иң зур вә бай музәханәседер. Бундагы кадәр асәре гатыйка [6], эшъйаи тарихийә [7] һичбер җирдә юк имеш.

Иң әүвәл безне көтебханә залларыннан беренә алып керделәр. Бу Томас Гренвилл (Thomas Grenvill) дигән кеше тарафыннан һәдия ителгән көтебханә имеш. Бу бүлмәдә 20000 нән зиядә китап бар. Диварда шүрлекләрдәге китаплардан башка, әллә никадәр язмалар өстәлләрдәге шкафларда күренеп тора иде. Буннан узып, язма әсәр бүлмәсе дигән бүлмәгә чыктык. Бу даирәдә тезелгән пыяла ящикләр эчендә дөньяда мәшһүр кешеләрнең куллары илән язылган асәр тулган. Мәшһүр Лютер, Кальвин, хәким Бэкон, хыяли бер Даррахот, утопия фараз итеп язган Томас Мор мәшһүр француз хәким вә әдипләреннән Вольтерларның язуларына дикъкать итдек. Бунардан башка һәм бик күп язмалар мәүҗүд иде. Буннан соң бер шкафта Англия падишаһларының язулары иде. Башка бер шкафта мәшһүр хөкүмәт әсхабының язулары иде. Холясан, бу бүлмә мәшһүр кешеләрнең язулары илә тулган иде.

Буннан башка бер китап бүлмәсенә килеп чыктык. Бу Король көтебханәсе дип атала икән. Югарыдагы бүлмәне Томас биргән кеби, бу бүлмәдәге китапларны Англия падишаһларыннан Жорж Салис [8] һәдия иткән икән. Бу бүлмәдә сиксән мең китап бар имеш. Буннан узып көтебханәнең Кыйраәт бүлмәсе [9] дигән уку залына килеп җиттек. Уку залы беренче катта. Бу зал бер зур түгәрәк зал. Бу залның катары[10] 43 метр имеш. Биеклеге 32 метр (аршин) чамасында имеш. 360

---

[1] Ахыры. Башы 11 санда.

[2] *Заманы хазир* — хәзерге заман.
[3] *Иртибат* — мөнәсәбәт, бәйләнеш.
[4] *Мәүҗүддер* — бардыр.
[5] *Мөәссә* — учреждение.
[6] *Асаре гатыйка* — борынгы әсәрләр.
[7] *Әшъйаи тарихийә* — тарихи әйберләр (предметлар).
[8] *Салис* — Өченче.
[9] *Кыйраәт бүлмәсе* — уку бүлмәсе.
[10] *Катар (кыйтар)* — озынлык.

кеше рәхәтләнеп урнашып укырга урындыклар хазир. Көтебханә назыйрының өстәле уртал, күтәрелеп ясалган бер җирдә. Аның әтрафында көтебханәдә булган китапларның фиһристе — каталогы тезелгән.

Бу каталог үзе генә ике мең җилд буладыр. Шуннан чамалап, бу көтепханәдә нә кадәр китап булганыны белергә мөмкин булыр.

Бу залның үзендә 21 000 чамасында иң мөстәгъмәл [1] китаплар тора икән. Моннан калган китапларны да сораган кешегә бик тиз табып китерәләр, ди. Китап саклана торган складларга төшмәдек.

Бу көтебханәдә бары нә кадәр китап булганы кеше ышанырлык түгел: бары ике миллион китап бар имеш! Ике миллион җилд түгел, ике миллион әсәр! Һәр с ә моннан башка 30 000 чамасында китап артып тора имеш. Алай булса да, бу көтебханә французларның «Көтебханәи миллия» дигән көтебханәләреннән кечрәк имеш. Французларның көтебханәләрендә китапларның гадәде [2] моннан дәхи артык. Бер вакыт Парижның Көтебханәи миллиясендә ислам китапдары кыйсемене зиярәт итеп, гарәп, фарсы вә төрек — өч ислам телендә утыз меңнән зиядә китап вә язма булганына хәйран булган идем. Британия музәханәсендәге көтебханәдән истифадә итү вә анда барып-йөреп тәдкыйкать ясау [3] һәркемгә мөмкиндер.

Уку залына кереп укырга изен [4] алу өчен егерме бер яшьтә булырга кирәк, баш көтебханә мөдиренә бер гариза язып сорау кирәк. Көтебханә кешеләреннән бер-бер кеше тарафыннан тәкъдим ителү лязем була имеш. Бу шартлар булганда сораучыга бер карточка биреләдер. Бу карточкага малик булган кешегә һәр көн барып уку залында уку, теләгән бер китапны сорап алып истифадә итү, теләгән кадәр тәдкы: кате гыйльмия ясау мөмкиндер. Моннан башка шул ук карточка илән гәзитәләр залына һәм керергә мөмкин буладыр.

Без, кереп, бу уку залыны карап йөргәндә байтак кеше укып утыра иде. Бу укучыларның һәрберенең алдында берничә китап, дәфтәрләр, һәрбере китапка чумган, кайсы укый — укый да ара-тирә дәфтәренә бер нәрсә кайд итеп [5] ала. Без өстәлләр арасыннан узып киткәндә күбесе күтәрелеп тә карамый. Кайсылары күтәрелеп карап, һич илтифатсыз, бәгыйд [6] бер нәзар илән безне тегәлиләр иде. Гүя карап та безне күрмиләр. Фикерләре, кувәи димагыйәләре [7] укыдыклары китапларының анларча ачдыкы галәмнең мәхәвиренә багъланган икәне заһир иде [8]. Анларның у анда булындыклары афак фикерияләрендә нә без, нә көтебханә, бәлки нә дә Лондон бар иде. Бу нәзарлар фәүкыльгадә муҗиб [9] хөрмәт нәзарлары иде.

Укучылар һәрбере житди кешеләр булырга тиеш, күбесе яшь кешеләр. Июнь аеның эссе көнләрендә көтебханәләрдә утырмак бөек бер җиддият, зур бер хөббе гыйлем[10] булуына шәһадәт бирәдер. Шул укып утырган кешеләр арасында байтак яшь егет, байтак хатын вә кызлар бар иде. Боларда һәм гайн җиддият, гайн иһтимам[11]. Хәтеремә кичә күргән Һайд Парктагы бизәнгән хатыннар, мәгънәсез мактанчык д малар килеп төште. Фикрән бу житди, простой, мөхибе гыйлем[12] хатыннарны, исраф вә тәләззезаттан[13] башка бер шәйдән хәбәре булмаган, Һайд Паркта матур арабаларда купшыланучы хатыннарга кыяс итә[14] идем. Бу чагыштырудан соң көтебханәдәгеләренә хөрмәтем никадәр артса, Һайд Парктагыларына гъәдем-рәгъбәтем[15] шул дәрәҗәдә куәтләнә иде.

Бу залдан чыгып, һәйкәлләр залларына килдек. Бунда күргән Юнан вә Рума тарихына мө эгалликъ[16] бөтен һәйкәлләр вә статуяларны тәгърифенә керешмим, бу скульптура кыйсеме дөньяның иң зәнгин[17] бер коллексионы имеш.

---

[1] *Мөстәгъмәл* — файдалана (кулга бирелә) торган.

[2] *Гадәде* — саны.

[3] *Тәдкыйкать ясау* — җентекләп (өйрәнү).

[4] *Изен* — рәхсәт.

[5] *Кайд ит* — теркәү, язып алу.

[6] *Бәгыйд* — ерак.

[7] *Кувәи димагыйәләре* — ми (уйлау) куәтләре.

[8] *Заһир иде* — күренә иде.

[9] *Фәукыльгадә муҗиб хөрмәт* — гадәттән тыш сәбәптән барлыкка килгән кадерле.

[10] *Хөббе гыйлем* — гыйлемне ярату, сөю.

[11] *Гайн җиддият, гайн иһтимам* — шул житдилек, шул тырышлык.

[12] *Мөхибе гыйлем* — гыйлем сөюче.

[13] *Исраф вә тәләззезаттан* — акча туздыру һәм ләззәттән.

[14] *Кыяс итә* — чагыштыра.

[15] *Гъәдем-рәгъбәтем* — дошманлыгым-чиркануым.

[16] *Мөтәгалликъ* — бәйле.

[17] *Зәнгин* — бай.

Чөнки бундагы һәйкәлләр берсе береннән мөһим, бере береннән искедер. Һәрбере хакында, тарихына ашна [1] булганда, бер чук мәгълүмате мөфидә [2] чыгармак мөмкиндер. Юнан вә Рума тарихларына ашна буласы килгән кешегә бу музәханәне зиярәт — бу юлда иң кулай васиталардан [3] бередер. Юнан вә Рума мәдәниятләре хакында китаплардан алынган мәгълүмат бу музәханәне зиярәтдән соң бер дәрәҗә күз алдына килгән кеби булачагында һич шөбһә юк.

Мисыр, Ассурия тарихына гаид залларда һәм гайн хәл. Гүя Мисыр, Ассурия тарихы күз алдына китерелгән кеби буладыр. Бу Мисыр тарихына гаид нәрсәләрнең күплеге һич гаҗәпкә калмаслык түгел. Безгә бу залларны күрсәтеп йөрүче профессор Мисыр фиргавеннәренең һәрберене исемнәре белән атап, һәр нәрсәнең кайсы фиргавен заманыннан калган икәнене бәян итә. Бу күрсәтүче фиргавеннәрнең исемнәрене, кай вакыт яшәгәннәрене шундый тиз җиңеллек белән сөйли ки, гүя алар берлән шәхсән таныш булган диярсең. Бу залларда тарих миладидән өч мең сәнә әүвәл булган әхваль вә кешеләргә гаид асәр бик күп иде. Бу кадәр тәсәлсел сәнәвият [4] гакылларны хәйрәттә [5] калдыра иде.

Ассурия мәдәниятенә гаид шәйләрдән һәм бик дикъкатемезе җәлеп иткән нәрсәләр күп иде. Бунда иң хәтеремдә калган — Ассурия падишаһларыннан Сарданапал дигән падишаһ көтебханәседер. Мәгълүмеңез, бу халык торган заманда хәзерге язу булмаган һәм кәгазь дә булмаган. Ассурия вә Ниневия халкы кирпечләргә әллә нинди тешле-тешле галәмәтләр илән язалар икән. Бу язуга русча клинообазные письмена диләр. Бу язу әллә нинди чөйләргә охшыйдыр. Бу көндә бу чөйләрнең нинди хәреф вә сүзгә ишарә икәнене Яурупа голәмәсе иҗтиһад итеп кәшеф иттеләр. Мисыр язуы иероглифлар кәшеф ителгәне кеби, бу язу вә һәм бу көндә укылган.

Менә хәзер күз алдымыздагы бу кирпечләрдәге сызыкларның һәм мәгънәсе укылган, мәзмуны [6] бу көнгә инглиз теленә тәрҗемә ителгән. Бу китапларның (кирпечләренең) күбрәгендә тарихи вакыйга язылган имеш. Калганнында догалык вә мөнәҗәтләр имеш. Һәр халыкның догасы вә мөнәҗәте бар. Бәни бәшәрне [7] теләсәң генә кайсы гасырда ал, теләсәң кайсы икълимдә булсын, бунын үзенә махсус дини догалары вә мөнәҗәте булмый калмыйдыр. Бәни бәшәрдә хис дини табигый булган кеби, галәме сәмавәт [8] илән үзенең мөнәсәбәте руханиясен идракь дә җибиллидер [9]. Дөньяда бәни бәшәр булган мөддәтдә дога да вә тәзаррыгъ[10] да, тезләнеп рухыны галәме сәмавәткә күтәргән кеше дә һәрвакыт булыр. Бәни бәшәрнең хәятына рух биргән инсанны үзене үзе кашында[11] күтәргәндә, тәкъдис идән[12] бер шәй булса — бу да диндарлыктыр. Бер милләт никадәр рухан мөтәгали[13] исә, у кадәр дә диндарлык хисе һәм куәтле буладыр. Шөбһә юк ки, бу күз алдымыздагы кирпечкә язган вакытта асур халкының да бунларны үгрәткән кешеләре, әгәр тәгъбир җаиз исә[14], үзләренчә мөршид вә нәбиләре[15] булгандыр.

Буннан соң янә Мисыр вә Ассурия мәдәниятенә берничә даирәне карагач, кайтырга вакыт, диделәр. Чыктык. Өч сәгать чамасында дәвам иткән бу мөшаһәдәте тарихия[16] һәр каюымызның фикерләрене тарихның иң ерактагы дәверләренә чигергән иде. Фикерләремез Сарданапал вә Бәхтәнсар, фиргавеннәр, Юнанстан вә Рума әхвальләре тирәсендә әйләнә иде. Бездән ничә мең сәнәләр әүвәл инсаннарның яшәгәне, аларның үзләренә махсус нинди зур мәдәниятләр тәэсис иткәнлекләре, бу мәдәниятләр һәрберсе, бере артыннан бере егылып, бу кавемнәр һәрбере югалып, бунларның җиренә хәзерге галәм, хәзерге мәдәният,

---

[1] *Ашна* — танышлык, белешлек.

[2] *Мәгълүмате мөфидә* — әһәмиятле, файдалы мәгълүмат.

[3] *Васита* — чара.

[4] *Тәсәлсел сәнәвият* — тоташ еллар.

[5] *Хәйрәттә* — аптырашта.

[6] *Мәзмуны* — мәгънәсе, эчтәлеге.

[7] *Бәни бәшәр* — адәм балалары.

[8] *Галәме сәмавәт* — күк йөзе (дөньясы).

[9] *Идракь дә җибиллидер* — аңлау да тумыштандыр (табигыйлер).

[10] *Тәзаррыгъ* — үтенү, ялвару.

[11] *Кашында* — каршында.

[12] *Тәкъдис идән* — изгегә санаган.

[13] *Мөтәгали* — бөек, югары.

[14] *Тәгъбир җаиз исә* — әйтергә яраса.

[15] *Мөршид вә нәбиләре* — туры юл күрсәтүче һәм пәйгамбәрләре.

[16] *Мөшаһәдәте тарихия* — тарихны күз белән күрү.

хәзерге бәшәрият [1] вөҗүдкә чыкканы инсанны бик кызык уйларга төшерә иде. Кем белсен, бүген дөньяның бик һаваланган мәдәният вә культурасы да — бер көн болар шулай ук тарихи булып калыр. Безгә бүген Юнан хорафаты, мәгъбүдләре [2] нә кадәр кызык тоелса, бу Ассурия кирпечләрендәге язулар нә кадәр артта калган кеби булса, безнең мәдәният тә истикъбальдәге яңа бәни бәшәргә шулай ук аңламаслык, шулай ук артта, мәдәниятсез кеби тоелыр. Безгә Юнан вә Рума мәдәниятләренең күп җәһәте көлке, аңланмаслык вә нәмәгъкуль кеби күренсә, безнең бүгенге мәдәниятнең һәм күп җәһәте истикъбаль кешеләренә у кадәр көлке, нәмәгъкуль вә артта булып күренер.

Һәрберемезнең фикерләремез галәме тарихта иде. Күз алдымызда әһрамнар вә бу әһрамнарны [3] бина иттергән Мисыр кадимнең фиргавеннәре, Ассурия әһалисе, Юнан кадим вә бу гали иске Юнан кавеменең шигырь илә тулы мәдәнияте, чиксез мәгъбүдләре, нәфис гыйбадәтханәләре, хосусән Партәнүн (Парфенон) нам мәгъбәдләренең мигъмари нәфасәте [4], румалылар вә боларның салкынрак, ләкин куәтлерәк мәдәнияте, бу бөек румалыларның бөтен галәмне тәхет икътидарына күчергән куәи фатиханәсе, җәсүр [5] гаскәрләре, маһир сәргаскәрләре [6] бере артыннан бере күз алдымызга килә иде. Һәрбере хакында әллә никадәр, тәгъбир итү кабил булмаган [7], хөзен [8] тарихы илә мөләүвән [9] төшенчәләр баштан үтә иде. Өч-дүрт сәгать эчендә берничә төрле асәрене вә бәкайасене [10] мөшаһәдә иткән, ике-өч мең сәнәлек бер мөсафаи заманиядә [11] бер сөргате шәдидә [12] илән очкан идек. Һәрберемез тарихи еллар тәсәлсе [13] эчендә хәйрәттә идек.

Вакыт җитте. Британия музәханәсеннән чыктык. Музәханәнең зур баскычларыннан төшә идек. Минем алдымда бер-береннән ерак түгел Хомяков илән Гучков вә уң тарафымда Милюков һәм баскычтан төшәләр иде. Милюковның кадетларның рәисе булуы, Хомяковның октябристләр рәисе булуы кинәттән хәтеремә төште. Бу дәкыйкадә бу кешенең рәкабәтләре [14], программаларының фәрекы [15], бер беренә каршы булган тәгассыблары [16] фәукыльгадә кызык бер тәэсир итә иде. Аңланмаслык бер кечкенәлек, бик лөзүмсез [17] бер тәгассыб кеби күренә иде. Бу тарихият һавасы башларымызны тулдырган булудан иде.

Тизрәк музәханәдән чыгып, галәме хәкыйкыйга имтизаҗ итәргә [18] ихтыяҗымыз куәтле иде. Чыктык. Лондонның шау-шулары, гөрелдәве янадан ишетелә башлады. Көтеп торган автомобильләргә утырып, Лондонның бик күп кешеле урамнарыннан узып, миһманханәмезгә юнәлдек. Һава яхшы иде. Урамнарда матур мәгазәләр ялтырый иде. Узып киткәндә мәһабәт Трафальгар мәйданы, анда Нельсон дигән адмиралның озын бер колон өстендәге мәһабәт һәйкәле һәйбәт күренә иде.

Һотелгә кайтып җиткәндә инглиз милләтенең мәдәният хазирәсенең куәте, Лондонның кайнап торган хәяты башымыздан тарихи улмыш мәдәниятләрнең тәлкыйн итдеге хөзен [19] вә җәдиде тарихияне чыгара язган иде. Нә кадәр башка мәдәниятләргә философанә мәхәббәт итсәк тә, бөтен тамырларымыз белән хәяте хазирәгә, мәдәнияте гасрыйәгә багъланган икәнемезне хис иттек.

---

[1] *Бәшәрият* — кешелек (дөньясы).
[2] *Мәгъбүдләре* — мәҗүси аллалары.
[3] *Әһрамнар* — пирамидалар.
[4] *Мигъмари нәфасәте* — төзелешенең (архитектурасының) нәфислеге.
[5] *Җәсүр* — батыр.
[6] *Сәргаскәр* — гаскәр башлыгы.
[7] *Кабил булмаган* — көч җитмәгән.
[8] *Хөзен* — көенечле.
[9] *Мөләүвән* — төрле төстәге.
[10] *Бәкайасене* — калдык әйберләрен.
[11] *Мөсафаи заманиядә* — заман юлында.
[12] *Сөргате шәдидә* — каты, көчле, тизлек.
[13] *Тәсәлсе* — чылбыры.
[14] *Рәкабәтләре* — көндәшләре.
[15] *Фәрекы* — аермасы.
[16] *Тәгассыблары* — теләк-омтылышлары.
[17] *Лөзүмсез* — кирәксез.
[18] *Имтизаҗ итәргә* — кушылырга.
[19] *Тәлкыйн итдеге хөзен* — көенечле тәэсирен.

## XVI

### Лорд Райның ханәсендә өйлә тәгамы. Һиндстан мөселманнарының сәяси мәүкыйгы[1] хакында сөйләшүләр

Бүген өйлә тәгамына ике жиргә чакырылган идек. Бере лорд Рай дигән бер лорд ханәсенә иде. Икенчесе Лондонның тәҗҗарлар[2] җәмгыяте тарафыннан ясалган мәҗлескә иде. Мин лорд Рай ханәсенә баручыларга кушылдым. Мөдәббирләр[3] шулай тәдбир иткәннәр иде. Лорд Райның ханәсе Лондонның кибарлар ханәсе илән тулган бер жирендә, тәмиз-пакь бер урамда кечкенә сарай кеби бер ханә иде. Автомобильләр илән килеп життек. Минем илән һаман граф Бобринский утырган иде. Буннан башка бу ханәдә безнең илән Хомяков, Стахович, Глебов бар иде. Ханәнең керә торган жире (парадный ходы) юнан кадим мәгъбәдләренең[4] алды кеби озын-зур мәрмәрле баганалар илән ясалган иде. Ханә эче дә тышына муафикъ иде. Киемнәремезне түбән салып, беренче катка мендек. Лорд Рай үзе беренче кат салонда безне кабул итеп алды. Үзе кабул итеп алгач, салонның түр тарафына алып барып, мадам Райга (хатынына) тәкъдим итте. Һәркем берәр кеше илән сөйләшә башлады. Мин Маккинз Уоллес дигән, Русия хакында бер зур әсәр язган публицист илән таныштым. Бу кеше мөкәммәл, һич косурсыз русча сөйләшә иде. Русиядә байтак сәнәләр утырган (торган — *ред.*) икән. Ахырдан сорашып белдем: бу кеше Англиянең мөгътәбәр вә мөхтәрәм язучыларыннан имеш. Вә буннан башка бер хасыйяте: бүгенге Англия короле Эдуард VII илән шәхси дуст имеш.

Бу кеше белән сөйләшеп туктагач, салонның мәфрушатына[5] дикъкать иттем. Бу ханә Беренче палата рәисенең ханәсенә һичбер охшамый иде. Рәис ханәсенең зиннәтләрендә вә матурлыгында һәр нә кадәр булса бер рәсмият бар иде. Хәлбуки бу ханәдә бер нәүгъ тәгъриф кабил булмаган[6] мәргубият[7], бер мәгънәви җайлылык бар иде. Салон бик биек түгел иде. Һава кояшлы булганга, тәрәзәләренең пәрсияннәре төшерелгән иде. Бу исә салонга бер нәүгъ шигъри ярты күләгә бирә иде. Салонның идәне Һиндстанда эшләнгән зур, фәүкыльгадә кыйммәтле бер палас белән капланган иде.

Диварларыны зиннәтләгән картиналарга дикъкать иттем. Һәрбере шөбһәсез иң мәшһүр рәссамнәр әсәре икәне рәвешеннән мәгълүм иде. Арадан берене таныдым, ханә сахибәсенең рәсеме иде.

Салон зур булмаса да, берничә жирдә диван иде. Вә бик күп зур урындыклары (кресло). Диваннар һәм урындыклар һәрбере эре бөртекле плюш рәвешендә бер ефәк материя илән капланган иде. Бу материалның чәчәкләре зур булуы дикъкатемне җәлеп итте. Бу чәчәкләрнең болай зур вә күзгә бәрелүе бик килешмәгән кеби тоела иде.

Һәр диванда, һәр урындыкта берничә, вак-вак тутырылган ефәк мендәрләр иде. Берничә жирдә зур багана кеби зур төпле лампалар иде. Берничә жирдә вак, консул дигән өстәлләр. Камин үзәрендә (мич буенда) бик күп төрле вак-төяк хатирә вә зиннәтләр. Буннан башка салонның кергәч үк тарафында берничә вак шкафта кыйммәтдар нәрсәләр. Һәр шәйдә кыйммәтлелек заһир иде. Диваннар вә урындыклар, Англиядә һәр жирдәге кеби, бу ханәдә һәм тәбәнәк, киң, җәелеп утырырга уңай.

Инглизләрнең уңгайлыкны яратулары һәр шәйдә, һәр жирдә күренеп торадыр. Бу ханәдә һәр шәйдә иң әүвәл күрелгән зиннәт вә кыйммәтлектән һәм әйтеп булмаган бер кибарлыктан башка, инглизләрнең комфорт дип атаганнары — бер рәхәтлек тоела иде; русча уютность дип аталган бер сыйфаттыр. Бундай ханәне күргәч, эчендә торырга бер арзу[8] хасил буладыр. Байлыгы җәһәтеннән түгел, күңеллелеге җәһәтеннән. Эчендә тору арзусыны кузгату бай ханәләргә генә махсус түгел. Буннан соң күргән бай вә уртача һәр ханәгә дикъкать иттем:

---

[1] *Мәүкыйгы* — урыны.
[2] *Тәҗҗар* — сәүдәгәрләр.
[3] *Мөдәббирләр* — эш башкаручылар, житәкчеләр.
[4] *Мәгъбәд* — гыйбадәтханә.
[5] *Мәфрушатына* — жиһазына.
[6] *Тәгъриф кабил булмаган* — аңлатып булмаган.
[7] *Мәргубият* — күңелгә ятышлылык.
[8] *Арзу* — теләк, омтылыш.

комфорт вә уңгайлылык эчендә торуны теләттерә торган бер хәл һәрберенә гам [1]. Инглизләр хәкыйкатән «ханә», «учак» хасиятене яхшы аңлыйлар. Мескеннәрене хәятка күңел куя торган хәлгә китерә беләләр.

Салонда бераз күрешкәч, йимәк булмәсенә кичтек. Минем урыным ханә сахибе лорд Рай илән Лондонның «Дейли телеграф» дигән зур гәзитәсенең баш мөхәррире арасында иде. Лорд минем мөселман икәнемне белде. Русия мөселманнары хакында берничә нәрсә сорады. Лорд Рай үзе яшь заманында Һиндстанда, мөселман булган мәмләкәтләрдә зур мәэмүриятләрдә [2] булган икән. Соң мәэмүрияте Бомбей вилайәтенең валисе мәнсабы [3] булган. Һиндстан әхваленә вакыйф [4] булган кеби, Һиндстан мөселманнарының хәле хакында һәм байтак мәгълүматы бар икән. Инглетерә [5] өчен Һиндстан идарәсенең бик читеп булуыннан бәхәс итте. Һиндстан халкының бер генә төрле гонсырдан [6] булмавы бер җәһәттән идарәгә уңгайлык бирсә дә, дигәр [7] тарафтан бик күп мәшәкатьләрне дә муҗиб [8] булганны аңлатты.

— Мәҗүс һиндлеләр илән мөселман һиндлеләр бер-берене бер дә сөймиләр. Бер-беренә дошман,— диде.— Бинаән галәйһи [9] Англия хөкүмәте бер генә төрле сәясәт йөретә алмыйдыр. Бу ике гонсырның һәр икесенә бердән яклап булмыйдыр. Берсене якласаң, икенчесе хөкүмәткә дошманлык эшли башлыйдыр. Хөкүмәт буңа кадәр нәүбәт илән бер-ике гонсырның әле берсене, әле берсене яклабрак килде, бу соң заманда хөкүмәтнең күбрәк сөйгән, яклабрак тоткан халкы — мөселманнар,— диде.— Бунын сәбәбе — боларның садыйк[10] булулары; боларда Англия хөкүмәтенә каршы дошманлык күренмәве,— диде.— Боларда хөррият, мөсавәт, хокук-фәләч кеби юк-бар фикерләр дә акрын тарала,— диде.— Һиндстан мөселманнары Һиндстанның хәле хазиренең бәкасы[11] вә Англия хакимиятенең дәвамы өчен файдалы бер әһалидер,— диде.— Шунын өчен бу соң заманнарда безнең хөкүмәт мөселманнарга байтак ярдәмнәр итте. Вак-төяк имтиязлар бирде,— диде.— Бундай мәмләкәтләрдә халыкны кулда тотарга теләсәң, иң әүвәл аларның зурларыны үзеңгә каратырга, дустландырырга кирәк,— диде.— Шуның өчен без хосусән иске ханнарга, зур голәмага хәер-хуаһлык күрсәтәмез,— диде.— Гомумән, мөселманнар садыйк,— диде.— Ләкин алай булса да, бу соң унбиш-егерме елдан бирле мөселманнар арасында безнең хөкүмәт тарафыннан ясалган мәктәпләрдә укып чыккан бәгъзы яшь егетләр зоһур итә башлады. Болар да мәҗүс һиндлеләргә ияреп, хөррият, мөсавәт хокукы-фәләннән бәхәс иткән була башладылар,— диде.— Боларга кадәр мәэмүриятләргә керү, мәнсабларда булырга мәел туа башлады,— диде.— Әгәр мөселманнар арасында бу хәл тәрәкъкый итә калса, бу Англия өчен бер хәтәрле хәлләрдән булачактыр,— диде.

Буннан соң монын сул тарафындагы «Дейли телеграф» гәзитәсенең мөхәррире илән сөйләштем. Ул миңа һотелгә Русия мөселманнары хакында сөйләшер өчен үзенең язучыларыннан берсене җибәрергә рөхсәт сорады. Минем Русия мөселманнары хакында бу сохбәтемне үзенең гәзитәсендә дәреҗ итәчәк[12] булды. Яшерә торган хәлләремез булмаганга, сораган сөальләргә җавап бирергә хәзер икәнемне бәян иттем.

Кайтырга чыктык. Автомобильдә граф Бобринскийдан сорадым:

— Бу ханәдә кунакта булудан нә кеби тәэсир алдыңыз? — дидем.

— Байлык, роскошь, нинди аристократлык! Тәхсин![13] — диде.— Мин бер Австралиядә вали булып торган лорд илән сөйләштем. Сез кем белән сөйләштеңез? — диде.

Мин:

— Өй сахибе иске Бомбей валие илән сөйләштем,— дидем.

---

[1] *Гам* — гомуми, уртак.
[2] *Мәэмүрият* — дәүләт идарәханәсе.
[3] *Вали мәнсабы* — губернатор урыны, вазифасы.
[4] *Вакыйф* — белүче, хәбәрдар.
[5] *Инглетерә* — Англия.
[6] *Гонсыр* — токым, элемент.
[7] *Дигәр* — башка, бүтән.
[8] *Муҗиб* — сәбәп.
[9] *Бинаән галәйһи* — шуның өчен.
[10] *Садыйк* — туры, эчкерсез.
[11] *Бәкасы* — яшәеше.
[12] *Дәреҗ итәчәк* — бастырып чыгарачак.
[13] *Тәхсин!* — Мактау булсын!

— Бу инглизләр хәкыйкатән миңа иске румалыларны хәтерләтәләр,— диде.— Кайсы иске Бомбей валисе, кайсы Австралия губернаторы, кайсы Һиндстан валисе, короле. Болар һәрбере Руманың проконсуллары кеби, һәрбере Англиянең мөтәгаддид[1] зур мөстәмләкәләрендә[2] падишаһ булып торган кешеләр,— диде.

Минем дә башымда һәм моңар охшашлы фикерләр кайный иде. Аркадашымның румалыларга тәшбия[3] җәһәтене тәсдикъ итсәм дә, хәтеремә бер сәаль килә иде.

— Югарыда тәхсин иткән аристократлык нә бәһагә төшәдер?— дия идем.

— Бунын бәһасене түләүче бөтен Англиянең кара халкы, колониянең хокуктан мәхрүм, сөтле сыгыр хәленә төшкән бичаралары түгелме!? — дия идем.

Өйгә кайттык.

## XVII

### Поло уены. Русия сәфарәтханәсендә[4] кичке кабул. Анда танышулар. Барклай.

Бүген, өйләдән соң, поло (Polo) уены мәраклыларының[5] клубы тарафыннан бу уенны карарга, соңра бу клубның даирәләрендә ахшам тәгамына чакырылган идек. Бардык. Иң әүвәл кыска гына бу уенны тәгъриф итү лязем булса кирәк.

Поло уены — махсус ясалган зур бер тигез чирәмлектә атка атланып уйналган шар-таяк уеныдыр. (Безнең дахили[6] Русия мөселманнарыннан шар-таяк уенын белмәгән кеше булмаса кирәк.)

Җәяүле шар-таяк уенындагы кеби, уйнаучылар икегә бүленеп, бер кыйсеме шарны уңга өстерәп китәргә тырышса, икенче тарафы сулга тәгәрәтергә иҗтиһад итәдер.

Шарга озын таяк илән ат өстеннән бәрәләр. Атлар, әлбәттә, буңа үгрәтелгән атлардыр. Һәр тарафта уйнаучы казаклар унлап бар иде. Уйнаучылар — уңга тартучылары кызыл, сулга өстерәүчеләре күк киемнәр кигәннәр иде. Уен отыштан, отышның сумасы байтак зур имеш. Бу уенны карарга клуб әгъзасы булган һәрбер кибарлар килә имеш.

Лондон кибарлары арасында бу клубның әгъзасы булмаган кеше сирәк имеш. Клуб Лондонның тышында, авылда; берничә чакрым җирне әйләндереп алып, бер кыйсемене — яшел болыннар, бер кыйсемене парк хәленә китергәннәр. Клуб әгъзаларына бу җир йөрергә унгай.

Уен була торган мәйдан махсус тәбәнәк киртә белән әйләндерелеп алынган. Ярты чакрымнан артыграк булыр. Уен вакытында бу киртәнең һәр тарафында ясалган урындык, эскәмияләр карап торучы халык илән тулы була икән. Хосусән карарга килгән дамаларның чиге юк. Бу да, Һайд Парк кеби, Лондонның эшсез хатыннарының бер килә торган җирләре икән.

Бер нәүгъ сабан туе. Безне халык карап тора торган җирдә ясалган махсус бер матур павильонга кертеп утырттылар. Короличә Виктория бу уенны карарга килгән вакытта без утырган павильоннан карап тора икән. Уен башланганчы клубның назыйр вә мөдире безнең илән килеп күреште, безгә бәгъзы лязем мәгълүматны бирде.

Көн бик матур, кояшлы иде. (Безнең бәхеткә каршы, көннәр матур булды, бу исә Лондонда бик сирәк бер хәлдер.) Бездән ерак түгел башка бер павильонда музыка уйный иде. Без кереп утырып урнашкач, безнең Русия гимнын уйнадылар.

Буннан озакламый чәй китерделәр. Һава саф, кояш якты, музыка гүзәл, алдымызда яшел чирәмлек. Еракта матур парк, һәр тарафымызда бик төрле төстәге күбәләкләр кеби матур туалетларда дамалар иде.

Бая гына граф Бобринскийнын әйткән сүзе искә төшә иде. Һәр җирдә гайн тәэсир[7]: байлык, роскошь вә аристократлык; һәр беремезнең кәефе яхшы иде. Төрлемез төрлечә уен-көлке сөйли иде.

---

[1] *Мөтәгаддид* — күп санлы.
[2] *Мөстәмләкә* — колония.
[3] *Тәшбия* — охшату.
[4] *Сәфарәтханә* — илчелек.
[5] *Мәраклылар* — һәвәсләр, сөючеләр.
[6] *Дахили* — эчке.
[7] *Гайн тәэсир* — шул ук тәэсир.

Уен башланды. Уен башланыр-башланмас без кызыллар тарафында булдык. Кызылларның һәм атлары да остарак, үзләре дә җиңелрәк тоела иде. Ике сәгать кадәр уеннан соң кызыллар җиңде. Бу ике сәгать бик тиз үтте. Уенга һәркем әһәмият бирә иде.

Уен тәмам булгач, клуб урманыны, паркларны карап йөрдек. Һәр җирдә матур юллар, зур агачлар, чәчәклекләр, вак гөлләр. Һәм бер агым су. Бу зиннәт һәрбере клуб кешеләренең рәхәте өчен ясалган. Агачлар хакында безнең арадагы алпавытлар байтак җир сахибләренә муафикъ мөхакәмәләрдә булындылар.

Буннан соң клуб йортының даирәләрене карап йөрдек. Кәнә бер язу бүлмәсе бар. Бер уку бүлмәсе, бер биллиард бүлмәсе бар. Иң мөһим бүлмәсе концерт бүлмәсе иде. Бунда һәр кичә, поло уены беткәч, халык йимәк йигәннән соң, музыка тыңлыйлар икән. Күрәсенез, һәр клуб мөстәкыйль. Клубта әгъза булган кеше, һич бүтән җиргә барырга ихтыяҗы булмаенча, бөтен көнене рәхәтләнеп уздыра аладыр.

Сәгать җиде ярымнарга килгәндә йимәк бүлмәсенә кичке тәгамга дәгъвәт иттеләр. Бу клубның буфеты кеби матур буфет булмас, гомуми җирдә аз булыр.

Бер падишаһ сараеның тәгам бүлмәсе зан идәрсең[1]. Безгә махсус куелган зур өстәлләрдә клуб әгъзасы булган кешеләр вә бунларның хатыннары тулы иде. Бу хатыннар әлбисәсенең[2] зиннәтене, бриллиантлар вә энҗеләренең күплегене тәгърифкә керешсәм дә, тәгъриф итеп бетерә алмам. Һәр тарафтан күзләр безгә тегәлгән иде. Һәркем Русия парламенты әгъзаларыны күрергә тырыша иде. Чөнки һәркем Лондон гәзитәләреннән безнең бүген кайларда булачагымызны белә иде. Бүген бу клубта кичке тәгамда булачагымыз һәм мәгълүм иде. Фәүкыльгадә надир вә мөтәгаддид йимәкләрдән мөрәккәб[3] бу тәгамны һәм тәгъриф итмим. Йимәктән соң, Инглетерә короле вә безнең падишаһның саулыгына тостлар күтәргәннән соң, автомобильләр илән кайтырга чыктык. Бераз шәһәр харижында[4] рәхәт тапканнан соң, Лондонга кердек. Кич илән Лондонга килеп керү, җәйнең матур бер көнендә яктыртылган Лондон шәһәренең, зур урамнарының, зур мәгазәләренең, һәр җирдәге зыяның[5], бу миллионнар хәятыны шамил шәһәрнең тавышы безгә нә кеби тәэсир иткәнене тасвир итүне укучының үзенә тапшырам. Болар бөтен гомергә онытылмаслык зур-тирән тәэссорат иде. Англиянең төрле тарафларыны күргән саен бу кавемнең сәрвәт вә куәтене идрәк вә мәдәниятене тәкъдир итә бара идек. Ләкин минем башымнан һич югарыда әйткән сөаль чыкмый иде; бу зур табәканең бу сәрвәтене, бу аристократлыкыны, бу рәхәтене кем түлидер? Шөбһәсез, түбәндәге изелгән табәка дип җавап бирәсем килә иде. Ләкин гайн заманда бу җавап бик садә, бәлки бөтенләй тугъры түгел икәнене дә хис итә идем. Укучы, мин бу яздыкларымда күз алдымнан вә фикеремнән ниләр кичкән, шуны язам. Нәтиҗәләр чыгармыйм. Әлбәттә, бу сәяхәтем беткәч, бу күргәннәремнән гомуми бер фикер, Англия мәдәниятенә бер шәхси нәзарым булыр. Ләкин сезгә ул нәзарымнан бәхәс итмәй, нәтиҗә чыгаруны үзегезгә калдырам. Шул сүрәттә язмага тырышам ки, бу язганнарымнан сезгә үзенезгә бер фикер алу, бер нәзар ясау мөмкин булсын. Бунларны укыгач, сезнең Англия мәдәнияте хакында ясаган фикеренез минекеннән башка булырга да мөмкиндер.

Мәгълүменез, бүген кич сәгать унда сәфарәтханәгә дәгъвәтле идек. Һотелгә кайтып җитеп, бары сюртюкләремезне алыштырып, фрак киеп кенә өлгердек, янәдән кунакка киттек. Һәрбер пайтәхет шәһәрләрдә, сәфарәтханәләрдә «кунак кабул» мәҗлесләре — шәһәр кибарының бик яратып бара торган җирләредер. Зур шәһәрнең кунаклык хәятында сәфарәтханәләр бик зур бер урын аладыр. Пайтәхетләрдә һичбер зур мәҗлес булмыйдыр ки, һәр мәмләкәтнең сәфирләре[6] анда чакырылган булмасын. Хөласән, зур пайтәхетләрдә сәфарәт галәме иң кибари бер галәмдер. Бинаән галәйһи һәркаюымыз безнең Русия сәфиренең кабул мәҗлесенең ничек икәнене күрергә мәраклы[7] идек. Әксәремез[8] Петербургта башка мәмләкәт сәфирләренең кабулларында булгалаган идек. Шуның өчен Петербург-

---

[1] *Зан идәрсең* — дип уйларсың.
[2] *Әлбисә* — киемнәр.
[3] *Надир вә мөтәгаддид йимәкләрдән мөрәккәб* — сирәк очрый торган һәм күп санлы ашамлыклардан җыелган.
[4] *Харижында* — тышында.
[5] *Зыя* — яктылык.
[6] *Сәфирләр* — илчеләр.
[7] *Мәраклы* — теләүче, һәвәсле.
[8] *Әксәремез* — күпчелегебез.

та башка мәмләкәт сәфирләренен кабул мәҗлесләре кадәр үк безнең Русия сәфиренең кабулы мәһабәт вә кибаримы икән дип мәрак итә идек. Арамызда сәфарәт кабул мәҗлесләрендә бер дә булмаган кеше бер генә дә юк иде. Бәндәнез Петербургта Франция сәфарәтханәсе кабул мәҗлесләренә дәгъвәт ителгәнем бар иде.

Сәфарәтханәгә барып җиттек. Сәфарәтханә урамына кергәндә үк арбалар (экипаж) тулган иде. Арбалардан узып барып җиттек. Автомобильләрдән төштек. Англия модасы буенча киенгән лакейлар каршы алдылар.

Пальтоларымызны калдырып, зур баскычтан мендек. Баскыч вә ход һәрбере сарай сымак иде. Баскычтан менеп җиткәч, сәфир могавине[1] каршы алды. Ул арада сәфир дә килде. Сәфирнең кызы вә хатыны һәм килделәр. Һәрберемез сәфирнең хатыны, кызы илән һәм таныштык.

Буннан соң беренче залга бардык. Халык тулган иде. Икенче залга чыктык, анда һәм халык тулы; аннан дәхи өченче зур залга чыктык. Анда һәм халык аяк үзрә торып та көчкә залга сыя иде. Заллар һәркаюсы зур, электрик кандилләр (люстра) илән бик каты яктыртылган иде.

Һәр тарафтан сөйләшүләр, тәгаҗҗебләр, көлүләр ишетелә иде. Берничә минут аркадашларымнан аерылып ялгыз йөрдем, бер кешене танымаганга, рәхәтләнеп һәр шәйгә дикъкать итеп йөрдем. Сөйләшүләр күп җирдә французча иде. Йөри торгач, бер яктан бер якка йөргән ханә сахибе сәфиремез граф Бенкендорфка очрадым. «Күрәсенезме, залларымыз кечкенә, кунаклар сыймыйдыр»,— диде. Моны зарланган кеби итеп әйтә. Буннан узып киткәндә беркөн уенда кунак булган Беренче палата рәисенең хатынына тәсадеф иттем[2]. Мадам үзе күрешергә теләде.

Инглизләрнең адабе могашәрәтләренчә[3], бер җирдә таныган дама очраганда иң әүвәл хатыннар күрешә башларга тиеш икән, ирләр барып «исәнме» дияргә килешмидер. Мин бу әдәптән хәбәрдар идем. Бу Франциядәгенең вә Русиядәге гадәтнең бөтенләй гакеседер[4]. Франциядә вә Русиядә ирләр килеп «гыйззе ихтирам»[5] итәргә тиешледер. Хәлбуки, Англиядә әүвәл хатыннар «изһаре илтфат»[6] итү лязем икән. Бу ике гадәтнең кайсы яхшырак икәнлеге хакында күп бәхәс итәргә теләмим.

Рәис хатыны:

— Сезне берәр кеше илән таныштырыйммы?— диде, якынымызда торган бер дамага тәкъдим итте.

Бу дама Лондонда зур сәяси гәзитәләреннән «Остминистр газет» дигән бер гәзитә хуҗасының хатыны булып чыкты. Французча бик начар сөйләшә иде; сохбәтемез[7] озак дәвам итмәде. Ул арада сәфир хатыны графиня каршыма чыкты:

— Эченез пошмыймы, кем белән танышасыңыз килә, тәкъдим итим,— диде.— Залларымыз кечкенә, бик уңгайсыз, йөрер дә хәл юк. Чакырырга тиешле кешенең чиге юк. Әүвәл заманнарда, сәфарәт кабуллары бик зур булмаган вакытта, бу заллар җиткәндер, ләкин хәзер бик уңгайсыз,— диде.

Графиня:

— Сез французларны яратасыз кеби, сезне бер француженкага тәкъдим итим,— диде дә, Лондонның «Дейли телеграф» дигән зур бер гәзитә сахибенең хатынына тәкъдим итте.

Бу хатын асылы француз булып, инглизгә кияүгә чыккан икән. Бу хатын илән бераз француз мәдәнияте илән инглиз мәдәниятене кыяс итеп сөйләштек. Нә кадәр булса да асыл ватаны улан Франциягә мәхәббәте бик кызу икәне сөйләшүеннән тоела иде.

— Лондонда мокыйм[8] французлар күпмедер?— дидем.

— Байтак бар,— диде.

Ул арада Франция сәфарәтеннән бәхәс иттек.

— Франция сәфире хатыны илән таныштырыйммы?— диде.

Эзләдек, таба алмадык. Ләкин эзләгәндә аның ирене таптык. Мин буның илән бүген лорд Рай ханәсендә бергә өйлә тәгамында булган идем.

---

[1] *Могавине* — ярдәмчесе.
[2] *Тәсадеф иттем* — очрадым.
[3] *Адабе могашәрәтләренчә* — дустанә әдәп кагыйдәләренчә.
[4] *Гакеседер* — киреседер.
[5] *«Гыйззе ихтирам»* — «олылау ихтирамы».
[6] *«Изһаре илтифат»* — «илтифат күрсәтү».
[7] *Сохбәтемез* — әңгәмәбез.
[8] *Мокыйм* — җирләшкән, урынлашкан.

Аркадашларымнан Ефремов очрап, княгиня Долгорукий илән таныштырды. Княгиня вә кенәз Долгорукийлар фәүкыльгадә бер зәнгин[1] руслар булып, Лондонда яшиләр икән.

Лондонның бөтен кибар галәмендә боларга очрадык. Үзләре дә бер көнне сәгать биш чәенә чакырдылар.

Княгиня берничә кеше илән таныштырды. Голландия сәфире вә аның хатыны илән бераз сөйләштем, буннан соң — русияле бер хатын белән (фамилиясене оныттым). Бу хатын мине мадмуазель Элиссон дигән инглиз кызы илән таныштырды. Мадмуазель Элиссон — miss Elisson — яңа гына Төркиядән кайткан икән, минем мөселман икәнемне белгәч, Төркиядән бәхәс итәргә башлады.

Истанбулда Хилми паша ханәсендә (кунагында) утырган. Хилми пашаның кызлары, балалары илән һәм танышкан. Төркиянең буннан башка бик күп кибарларының ханәләрендә булган. Бу кыз, Англиянең бер кибар гаиләсеннән булуыннан башка, үзе бәгъзы хатыннар журналында харижи сәясәт хакында һәм яза икән. Төркиядә сәяхәте хакында һәм бер китап язарга хәзерләнә икән. Кызның хәрәкәт вә әтъварында[2] дикъкатемне җәлеп иткән нәрсә — фәүкыльгадә простойлыгы, аз гына да кокетлыгы булмавы иде.

Бу хәл инглиз кызларына махсус бер хәлдер. Кыйланып оялган булган булып маташмыйлар, һәр шәйдән ирләр кеби простой вә җәсүр бер тарызда[3] бәхәс итәләр. Кыз мотлакан[4] мине үзенең гамуҗәсенә[5] таныштырырга теләде. Гамуҗәсене эзләп таптык. Лондонның дәгъва вәкилләреннән мистер Томас Барклай дип таныштырды.

— Мин, месье Барклай, сезне таныйм, хәтта Парижда нинди танышларыңыз булганына кадәр беләм,— дидем.

Буңа Барклай гаҗәпсенде:

— Ничек?! — диде.

— Берәр танышыңызны саныйммы? — дидем.— Сез Парижда мадам Дюбратс илән танышсыңыз,— дидем.— Мин сезне мадам Дюбратс салонында күргән вә сезгә тәкъдим ителгән идем,— дидем.

Хәтеренә төшерде. Ләкин кыяфәтем хәтерендә калмаган икән.

Кыз гамуҗәсе илән таныш булып чыгуыма бик кәефләнде, гамуҗәсе илән бәрабәр, җомга көн сәгать биштә кабул мәҗлесенә килергә вә чәйдән соң ахшам тәгамына калырга үтенде.

— Бу җомга мөмкин түгел, киләсенә буш була алсам, килермен,— дидем.

Барклай рус депутатлары илән танышырга тели икән. Ефремов илән вә Крюднер-Струве илән таныштырдым. Шул арада Стахович яныма килеп:

— Сезнең илән Мисырда бөек комиссар булып торган лорд Крумер бик танышасы килгән иде,— диде.

Ул арада лорд Крумер югалган иде.

— Англиянең харижия назыйре Эдвар Грей илән танышмысыз? — диде.

— Юк,— дидем.

Алып барып таныштырды. Ләкин бу министр илән бүген озак сөйләшеп булмады. Әмма буннан бер атна соңрак янадан бер җирдә очрашып, байтак сөйләштем.

Бу әснада[6] халык киткәли башлаган иде; безгә дә вакыт диештек. Безнең иптәшләрдән һәм берничәсе киткән иде. Сәфир хатыны Бенкендорф илән күрешеп китәргә уйладык. Мадам Бенкендорф һәркөн, өйлә тәгамына килсәк, тәрилкәләремез хәзер булачагыны тәкрар итте. Мадам Бенкендорф хәкыйкатән җайлы, яхшы, симпатияни, мөҗиб[7] бер хатын. Безгә каршы күрсәткән кунак пәрвәрлекләре Русиядән рәсми кунак булганга, рәсми нәзакәт кенә булмай, чыннан эченнән ватаны кешеләренә, ватаны мәҗлесе мәбгусан әгъзасына хәер-хуаһлык вә ихтирамы булганыны белгертә иде.

Гайн хәлне сәфир хакында һәм әйтергә мөмкин. Бөтен Лондонда булган мөддәтемездә сәфир һәр вакытта безнең илән бәрабәр булып, һәрвакыт бер идарәи мәшруталы мәмләкәтнең сәфире, мәмләкәтнең «канун төзүче» милләт мәҗлесе әгъзаларына каршы нинди нәзакәт вә хөрмәттә булырга тиеш булса, безнең Лондон сәфире дә безгә һәрвакыт шул вазгыйәттә булды. Сәфарәтханәдә

---

[1] *Зәнгин* — бай, дәүләт иясе.
[2] *Әтъварында* — килеш-кыланышында.
[3] *Җәсүр бер тарызда* — кыю бер рәвештә.
[4] *Мотлакан* — шиксез, бернигә карамастан.
[5] *Гамуҗә* — атасы белән бертуган абыйсы.
[6] *Әснада* — арада, моментта.
[7] *Мөҗиб* — җавапчан.

кабул рәвешләреннән һәрберемез мәмнүн булып, Русия сәфире Лондонда үзүзене бик яхшы тота белүенә бер нәүгъ ифтихар [1] хисе илә мићманханәмезгә кайттык. Бик арыган идек. Иртәгесен Лондонга якын Кембридж шәһәренә барасы булганга, бераз безгә махсус салонда җыелып сөйләшкәннән соң, һәрберемез бүлмәләремезгә чикелдек.

## XVIII

### Лондонда дүртенче көн. Англиянең мәшһүр дарелфөнүннәреннән Кембридж шәһәре дарелфөнүне [2]. Англия гали мәктәпләре хакында берничә сүз

Бүген Лондоннан берничә сәгатьлек җирдә Кембридж шәһәренә бардык. Кембридж шәһәре кечкенә генә шәһәр булса да, шөһрәте бөтен галәмгә мәшһүрдер. Кембридж илән Оксфорд шәһәрләренең дарелфөнүннәре Англиянең иң зур дарелфөнүннәредер. Англиянең фәлсәфә вә әдәбият бабында галәмгә чыгарган зур кешеләренең күбесе бу ике мәһде мәгърифәт вә мәнбәгы гыйлемнең мәхсулларыдыр [3].

Кембридж шәһәре кечкенә, матур бер шәһәр, бөтен әтрафы яшеллек, болынлык. Шәһәрнең уртасыннан һәр әтрафы агачлар илән күмелгән Кәм нәһере [4] узып китәдер. Урамнар пакь, йортлар матур, бакчалар бик күп, һәрбере тәртипле. Кечкенә шәһәрнең рәвеше безнең Русия җәнүбендәге [5] бер тәгътыйль [6] үткәрә торган дача җиренә, курортка охшыйдыр.

Дарелфөнүнгә барып җиттек. Дарелфөнүн бинасыны тәгъриф итүдән әүвәл бу югарыда тәгъриф ителгән ике дарелфөнүн хакында берничә мәгълүмат бирмәк кирәк булыр. Бу дарелфөнүннәр безнең Русиядәге һәм Франциядәге кеби көндез килеп, дәрес ишетеп кенә китә торган җирләр түгел. Бу ике дарелфөнүн һәр икесе ләйләдер [7]; ягъни студентлар дарелфөнүн ханәсендә һәм кунып торадыр. Бу бер хосусият. Икенче фәрекъ [8]: Русиядә һәр шәһәрнең дарелфөнүне бер идарәгә мәркәзләнгән буладыр. Хәлбуки Кембридж шәһәрендәге дарелфөнүн уннан зиядә [9] — доходы, идарәсе, уставы, рәисе башка «коллеж» дигән мәдрәсәләрдән мөрәккәбтер. Һәр коллежның үзендә мөдир вә берничә мөгаллим вә мөкәррирләре мәүҗүддер[10].

Бу аерым коллежлардан башкабер дә һәр коллежга гам[11] профессорлар мәүҗүддер. Бу профессорлар һичбер коллежга мөтәгалликъ[12] булмай, мөстәкыйль бер һәйәт тәшкил итәләр.

Оксфорд вә Кембридж дарелфөнүннәре — Англиянең бай табәкасенә[13] махсус мөәссәләрдер. Бунда һәркем тәхсыйль итәргә мөмкин түгел. Иң азы сәнәви[14] ике мең рубля чамасында мәсъраф итәргә лязем имеш. Коллежлар һәрбере бик бай, һәрберенең доходы бик зур имеш. Тәкърибән[15] һәрбер коллежның 150 мең рубля доходы бар имеш. Бу доход каян киләдер? — Һәрбер коллежның искедән калган әразыйсы[16], вәкыфләре бар икән. Вә варидәт[17] шул җирләрдән килә икән. Бу җәһәттән Англиянең коллежлары безнең ислам мәмләкәтләрендәге мәдрәсәләргә бик охшыйлар.

---

[1] *Ифтихар* — горурлану.
[2] *Дарелфөнүн* — университет.
[3] *Мәһде мәгърифәт вә мәнбәгы гыйлемнең мәхсулларыдыр* — мәгърифәт бишеге һәм гыйлем чыганагының нәтиҗәләредер.
[4] *Нәһере* — елгасы.
[5] *Җәнүб* — көньяк.
[6] *Тәгътыйль* — ял вакыты, каникул.
[7] *Ләйләдер* — кичкедер.
[8] *Фәрекъ* — аерма.
[9] *Зиядә* — артык.
[10] *Мөкәррирләре мәүҗүддер* — өйрәтүчеләр, репетиторлары бардыр.
[11] *Гам* — гомуми.
[12] *Мөтәгалликъ* — бәйле.
[13] *Табәкасына* — катлавына.
[14] *Сәнәви* — еллык.
[15] *Тәкърибән* — якынча.
[16] *Әразыйсы* — җирләре.
[17] *Варидәт* — керемнәр.

Бу доходтан мөдир әфәнде, мөгаллимнәр вә мөкәррирләр файдалана. Укучылар буннан файдаланмыйлар. Укучылар, билгакес, үзләре бик зур акчалар түләргә кирәк буладыр. Доход күп булганга, мөдир вә мөгаллимнәр бик зур мәгашләр [1] алалар. Иң фәкыйрь коллежның мөдире 20 мең рубля кадәр мәгаш ала имеш. Баерак, вәкыфе күбрәк коллеж мөдиренең мәгашы алтмыш мең сумга кадәр бара имеш.

Коллежларны карап йөредек. Коллежлар һәрбере бер-беренә охшыйлар. Һәрберенең бинасы бик иске заман бинасы. Иң искесе буннан алты гасыр мөкаддәм бина ителгән имеш.

Югарыда бу коллежлар безнең мәдрәсәләргә охшыйлар дигән идем. Бу мөшабәһәт [2] вәкыф җәһәтеннән генә түгел, коллежларның бинадары һәм безнең ислам мәдрәсәләренә бер җәһәттән охшыйдыр. Хөҗрәләргә бүленгән. Бинаның уртасында, там [3] Истанбул мәдрәсәләрендәге кеби, бер холл (мәйдан) бар. Тәгърифләргә бинаән [4], Бохара мәдрәсәләре һәм шул рәвештә ясалган имеш [5]. Затән мәдрәсәләрнең бу рәвештә ясалуы гарәп тарзы мигъмарисыдыр [6] дип беләм. Бөтен ислам галәме мәдрәсәләрне бу рәвештә ясаган кеби, мәдәниятне гарәпләрдән алган европалылар да гарәп тарзы мигъмарисыны кабул иткәннәрдер дип уйлыйм. Ләкин Европа халкының әһалисе һәр шәйне кабул итеп канәгатләнмәй, һәр шәйдә ислях тарафыны һәм караган. Менә бу күземез алдындагы коллежларга карыйк. Бу коллежлар да, Истанбул мәдрәсәләре кеби, коруне вөстадан [7], искедән калган биналардыр. Харижи рәвешләре бер булса да, нә кадәр Шәрекъ кавеме илән Гареб [8] кавеме арасында фәрекъ! Иң әүвәлге фәрекъ — биналарның зурлыгы. Колледжлар һәрбере падишаһ сарайлары кеби зурдыр. Һәр хөҗрә бер генә бүлмәдән мөрәккәб булмай, берничә бүлмәдән мөрәккәбтер. Һәр шәкерднең ашханәсе хөҗрәсендә булмай, һәркемгә гомуми ашханә мәүҗүд. Бу хәл шулай искедән калган. Буннан башка фәрекъләр: Европа галәмендә сәнаигы нәфисә әүвәлдән игътибарда булганга, коллежларның харижи вә дахили [9] диварлары әллә никадәр рәсемнәр, кечкенә һәйкәлләр илән тулыдыр; эчендә, дәресханәләренең вә йимәк бүлмәләренең дивар вә түшәмнәрендә бизәк вә хәтта искедән калма рәсемнәр һәм бар. Бу коллежның безгә өйлә тәгамы тәкъдим иткән бүлмәсенең диварлар вә түшәменең матурлыгы тәгърифеннән хариждер. Осуле ислам мәдәниятене иҗад иткән гарәпләрдә байтак тәрәккъый иткән хис нәфасәт булса да (буңа Кортобаның әлхәмралары шаһитдер), бу мәдәниятне кабул иткән без төрек гонсырында[10] хис нәфасәт бик мөтәрәккъый түгел. Буны агыр булса да игътираф итик[11]. Фәкыйрь бер гарәп бәдәвиенең[12] нәзафәт вә нәфасәткә[13] булган мәел вә мәхәббәте илән бер төркинең, бер кыргызның шакшылыгы кыяс ителмәз. Хәлбуки: хөббе нәзафәт вә хис нәфасәт бик зур мизане мәдәниятдер[14].

Бер кешенең кәмаләт рухиясене, дәрәҗәи мәдәниятене беләсең килсә, аның тора торган җирене, өсте-башыны кара. Инсанның мәскән[15] вә әлбисәсе илән рухы арасында фәүкыльгадә зур бер мөнәсәбәт мәүҗүддер. Шәхесләр хакындагы мөнәсәбәт милләтләр хакында һәм ярыйдыр. Хөббе нәзафәт вә хис нәфасәт тәрәккъыйга вә мәдәнияткә сәвекъ итә[16] торган гамилләрдәндер. Нә исә, мин Европа халкының тиз заманда гарәпләрдән алган мәдәниятне бу кадәр алга җибәрүләренә зур сәбәпләрдән берсе — Европа халкының рухында хис нәфасәт безнең әкъваме төркиядәгедән[17] артыграк булуы дип уйлыйм.

Кембридж шәһәрендә һәр коллеж гаять зур бер парк, яхуд бакча эчендә. Паркның һәр тарафында зур яшел чирәмлекләр, зур, матур, яфраклар илән түгәрәкләнгән агачлар вә матур юллар; бу чирәмлекләрдән Кәм нәһере бор-

---

[1] *Мәгаш* — хезмәт хакы.
[2] *Мөшабәһәт* — охшашлык.
[3] *Там* — нәкъ, тәмам.
[4] *Тәгърифләргә бинаән* — сөйләүләргә караганда.
[5] Шулай ясалган. Англия сәяхәтеннән бер сәнә соң барып күрдем *(С. Максуди искәрмәсе)*.
[6] *Тарзы мигъмарисыдыр* — архитектура стиледер.
[7] *Коруне вөста* — Урта гасыр.
[8] *Гареб* — Көнбатыш.
[9] *Харижи вә дахили* — тышкы вә эчке.
[10] *Гонсырында* — токымында.
[11] *Игътираф итик* — таныйк.
[12] *Бәдәви* — күчмә тормышлы.
[13] *Нәзафәт вә нәфасәт* — пакьлек вә нәфислек.
[14] *Мизане мәдәният* — мәдәният (дәрәҗәсенең) үлчәве.
[15] *Мәскән* — тору урыны.
[16] *Сәвекъ иту* — алга этәрү.
[17] *Әкъваме төркия* — төрки кавемнәр.

галанып агадыр. Ара-тирә чирәмлекләр өстендә түтәлләп ясалган чәчәклекләр. Бу вакыт тәгътыйль вакыты булса да, студентлар һәрбере ватанына кайтып бетмәгән икән.

Бакчада йөргәндә ара-тирә студентларга очрый идек. Кайсы кулында бер китап илән бакча юлларында йөри иде. Кайсылары Кәм нәһерендә көймәдә йөриләр иде. Кайсы су эчендә көймәсене бер күләгәле җирдә туктаткан, гитара уйнап утыра иде. Һава бик матур, кояш җылы иде. Шәһәр кечкенә булганга, тавыш юк, тыныч иде.

Без дә бер көймәгә утырып Кәм нәһерендә йөрдек (Кембридж — «Кәм нәһере күпере» дигән сүз). Безнең көймәдә Милюков, Ефремов иде. Һәрберебез коллежларның байлыгына, бакчаларының матурлыгына хәйран кала идек. Стахович башка бер көймәдә су өстендә безгә очрап: «Максудов, сезгә бу Кама (Кәм) нәһере мәгълүм булса кирәк»,— диде. Көлдек, бик көлке булмаса да, кәефләребез гаять җирендә булганга, һәр шәй тәбәссемне муҗиб була[1] иде. Көймәләрдән чыккач, Кәм нәһере буеннан бер матур юл белән Тринита коллеж дигән мәдрәсәгә таба бара идек. Бер ягымызда су иде, суда гитара уйнаган тавыш ишетелә иде; икенче ягымызда зур яшел чирәмлек иде. Бу чирәмлектә, бер махсус теннис уены мәйданында, берничә студент уйный иде. Алдымызда байтак еракта кояш белән ялтырап коруне вөстави коллеж күренә иде. Коллеж алдында зур бер чәчәклек иде. Һавада ара-тирә күбәләкләр очып китә иде.

Граф Бобринский үзенең һәрвакыт җәһрә уйлый торган[2] ачык табигате белән диде:

— Бундай бер җирдә (мөхит эчендә) тәхсыйль иткәндә забастовка фикерләре башны зиярәт итү ихтималы юк.

Граф Олсуфиев диде:

— Безнең студентлар илән бу инглизнең инсафлы таләбәсе арасында нинди зур фәрекъ!

Мин дидем:

— Англиядә ни генә шаян тәхсин[3] бер шәй күрсәңез, бу хәлне вөҗүдкә китергән сәбәпләрнең иң тирәне хөррият икәнен, хөррияте шәхсияне ихтирам икәнен мин көннән-көн канәгать хасил итәм,— дидем.

Буңа каршы граф Олсуфиев диде:

— Мин башка бер нәтиҗә чыгарам; мин уйлыйм ки, Англиянең бу мәдәнияте инглиз халкының, мәмләкәтенең кибарына хөрмәте сәясәтендә генә мөмкиндер. Күрәсеңез, бу коллеж бер дарелфөнүн түгел, җәннәткә охшыйдыр,— диде.— Бу ничек мөмкин? Чөнки бунда бары кибар баласы, байлар гына укыйдыр. Бундый бер җир ясап карасаң, Русиядә бөтен студентлар кычкырыр иде, бездә бер тиен акчасы булмаган һәрбере укырга тырышкан буладыр,— диде.

Граф миннән яше зур кеше булганга, бердән сәяхәттә булганга, бу фикерләрне тирәнгә кереп ибталь итәргә[4] лязем юк иде. Алай булса да, дустанә бер тарызда гына дидем:

— Хәер, безнең Русиядә һәм бу кеби задәкянга[5] махсус дарелгөлүм[6] бар: бере — Императорский лицей, икенчесе Петербургтагы хокук мәктәбе,— дидем.— Бу мәктәпләр Русиягә нинди зур кешеләр чыгарды. Минем хәтеремә килмидер. Анчак бер Пушкин төшәдер. Әгәр Пушкин да бу лицейдән тизрәк чыкмаган булса, аның дәһасы да мәйданга, бәлки, чыга алмас иде,— дидем.

Граф миңа карап көлеп:

— Теләсәңез нә кадәр демократ булып маташыңыз, Англиядә күргән хәлләр демократлыкка шәһадәт бирми, бәлки аристократлык күрсәтә,— диде.

Буңа каршы мин дидем:

— Бунын сәбәбе, бәлки, будыр: безне чакыручыларның аристократ табәкадан булуыдыр. Граф, һич онытмыйк, без Англиянең өсте катыны гына күрәмез; әгәр вакытымыз булып, асты катларыны яхшырак үгрәнергә тырышсак, сез чыгарырга тырышкан, аристократлык файдасына булган нәтиҗәләргә башка нәтиҗәләр чыгарыр идек,— дидем.— Аннан соң, хәтеремә килгәндә, моны да онытмыйк,— дидем.— Һәр кавемнең аристократлары, бәлки, милләтенә күрсәткән хезмәте дәрәҗәсендә хөрмәт ителәдер. Беләсеңез, Англия аристократлары

---

[1] *Тәбәсемне муҗиб була* — елмаерга сәбәп була.
[2] *Җәһрә уйлый торган* — уен ачыктан-ачык, кычкырып әйтә торган.
[3] *Шаян тәхсин* — бик яхшы, мактаулы.
[4] *Ибталь итәргә* — юкка чыгарырга.
[5] *Задәкян* — аксөяк, аристократлар.
[6] *Дарелгөлүм* — гыйлем йорты.

Англия мәдәнияте, дәүләтене, куәтене хәлыкъ итүдә [1] шөбһәсез зур роль уйнадылар. Нә кадәр үзләренең мәел табигатьләренә [2] хилаф булса да, лязем булганда халык (народ) мәнфәгатенә мөнасиб [3] ислях ясаудан качмадылар. Лязем булганда әһали файдасына күрә сәясәт йөретә белделәр. Үзләрене һичбер вакыт исляхат вә халык гакъсендә итеп [4] игълан итмәделәр. Шуның өчен инглиз халкы үзләренең аристократларыны (әшрафларны) бераз хөрмәт итәргә дә урын бар,— дидем.— Минә безнең ватанымызда яңа бер тормыш ачыладыр, ватанымыз хәятының һәр тарафы исляхка, тәҗдидкә [5] мохтаҗ, алдымызда бик күп хезмәт күренәдер. Һәйдәңез, азрак үзеңезнең интересларыңызны онытып, халыкның күтәрелүенә, аякка басуына, исляхларның тәмамән иҗра ителүенә [6] ярдәм итеңез, халык сезне хөрмәт итәр,— дидем.

Соңра көлеп, дидем:

— Бунда шәхесләрдән бәхәс итмим. Табигый, тарихи бер мөхакәмә ясарга тырышам. Бер хәкыйкать алга чыгарырга телим; бинаән галәйһи [7] Русиядә дворяннарның хезмәтсезлекләре хакындагы фикеремнән тулаи сохбәттәшемнең [8] кәефе китмәячәге табигый,— дидем.

Граф көлеп:

— Яшь кешедә мин бу кеби фикерләр булуына бер дә гаҗәпсенмим,— диде.

— Миндә бу фикерләрнең булуы минем яшь булуымнан дип уйламыйм, бәлки халыкны якыннан белүемнән, халыкның ихтыяҗларыны, җәфаларыны бала вакытымнан, эченнән күргәнемнән дип уйлыймын,— дидем.

Бу сохбәт шулай тәмам булды. Юлдан барып җитеп Тренита коллеж ашханәсенә килдек. Йимәктән соң зур коллежның мөдире илән бәрабәр көтебханәне карадык. Китап фәүкыльгадә күп, укырга уңгай; һәр җирдә иркенлек, пакьлек, яктылык. Хөҗрәләрнең нә рәвештә икәнене күрсәтер өчен бер хөҗрәгә алып керделәр. Хөҗрә өч бүлмәдән гыйбарәт иде. Берсе алда, киемнәр сала торган бүлмә. Икенчесе иҗтиһад бүлмәсе. Өченчесе ятак бүлмәсе. Һәрбере гаять пакь, матур, бизәкле диварларда рәсемнәр, шүрлекләрендә гаять матур төпләнгән китаплар. Китапларга дикъкать иттем, мәшһүр Яурупа лисаннарының һәрберендә китаплар күренә иде. Уку бүлмәсендә бердән пианино бар иде. Күренә ки, укудан арыгач, музыка уйнап, шәкертләр рәхәт итәләр икән. Бундый бер хөҗрә, тышта бер бакча — бу бер җәннәт! Бу бүлмәдә бер искелек исе дә бар. Бүлмәгә кереп карый башлагач ук, күрсәтүче мөгаллим бу бүлмәгә алып килүенең сәбәбене сөйләде:

— Бу бүлмәдә инглизләрнең мәшһүр әдипләреннән Байрон (Вугоn) шәкерт вакытында торган,— диде.

## XIX

### Байрон вә аның тарихтагы роле. Докторлык дәрәҗәсе бирү мәрасиме [9] һәм Дарвинның тууына йөз сәнәлек бәйрәм

Бу җирдә Байронның хөҗрәсене зиярәт иткәннән соң, Байрон хакында берничә фикер язу вазыйфам дип беләм. Бундай бөтен галәмне шау китергән мөҗаһиде хөрриятнең[10], зур шагыйрьнең тәрбия күргән мәдрәсәсене, мәһде тәхсыйлене[11] күрдек; инде буннан соң аз гына бу кеби матур мөхит эчендә тәхсыйльдән соң нә кеби даһилар дөньяга чыкканыны мөшаһәдә итәргә тырышыйк.

Байрон Англия әдипләре арасында иң мәшһүредер. Буның бу кадәр шөһрәтенә иң зур сәбәп — язган әсәрләренең, шигырьләренең әһәмияте әдәбиясе

[1] *Хәлыкъ итүдә* — барлыкка китерүдә.
[2] *Мәел табигатьләренә* — күңел куйган холык-табигатьләренә.
[3] *Мөнасиб* — ярашлы, кирәкле.
[4] *Гакъсендә итеп* — капма-каршы итеп.
[5] *Тәҗдид* — яңарту, үзгәртү.
[6] *Иҗра ителүенә* — гамәлгә ашырылуына.
[7] *Бинаән галәйһи* — шуның өчен.
[8] *Тулаи сохбәттәш* — тирән белемле әңгәмәдәш.
[9] *Мәрасим* — рәсми мәҗлес, җыелыш.
[10] *Мөҗаһиде хөррият* — хөррият көрәшчесе.
[11] *Мәһде тәхсыйлене* — укыган (белем алган) бишеген.

булса да, икенче җәһәттән, шөбһәсез, хәятының вакыйгалар илә тулы булуы да бу шөһрәткә бик ярдәм иткән.

Байрон әсәрләре һәрбере шигырь илән язылгандыр. Байрон 1788 сәнәсендә дөньяга килгән иде (1788—1834).

Мәгълүмеңез, унтугызынчы гасырның башында бәни бәшәрнең хәяте иҗтимагыйәсе вә әфкяре бик зур тәхвилатка [1] очрады. Машиналар ихтирагы [2] бәни бәшәрнең хәяте иҗтимагыйәсене үзгәрткән кеби, фәннәрнең тәрәккыйәсе, хосусән голуме табигыйәдәге кәшфият [3] христиан галәмендә әүвәлдән кабул ителеп, тәнкыйтьсез ышанылып килгән бер такым шәйләрне җимерә вә байтак әфкяре җарияне [4] һәдем вә тәхриб итә [5] иде. Бу хәл ул заманның тәрбияле, нечкә рухлы, хәссас [6] инсаннарында тәгъбир мөмкин булмаган бер кайгулылыкка сәбәп була иде.

Бу дәвердә иске идеалларның акрынлап җимерелүе, хәят вә истикъбале бәшәрияткә [7] бер яңа нәзар ясалмаганлыгы, гали рухлы, мөштакъ [8] идеал кешеләрдә, бер җәһәттән, мәдәнияте хазиргә истихкарны [9], икенче тарафтан, гайре могыйнь[10] бер хәят бәшәрияи фикриягә моңлы бер гыйшыкны муҗиб[11] була иде. Бу хәлне безнең әдәбиятка алышмаган лисанымызда тәгъриф читен. Бу рәвештәге халәте руханиягә тарих-әдәбиятта җиһани мәхзүният — Мировая скорбь — исемене бирделәр.

Менә бу Байрон — бу халәте руханияне иң парлакъ[12] тәгъбир итүчеләрдән бередер. Бинаән галәйһи бу халәте руханияне бәгъзан байронизм диләр, ягъни байронылык димәктер. Бу байронылык ул заманда Байронга, яхуд Англиягә махсус түгел, бөтен Европаның зыялы табәкаләрендә буңа охшашлы бер хәл мәүҗүд иде. Байронның язган әсәрләренең бөтен дөнья лисаннарына тәрҗемә ителүеннән унтугызынчы гасыр ибтидасында бөтен Европага байронизм сирайәт иткән[13] иде.

Франция әдәбияты Байронга мокабил Шатобрианны мәйданга чыгарган кеби, безнең Русия әдәбияты һәм Лермонтовны вөҗүдкә китергән иде. Лермонтов асәренә вакыйф кешеләргә байронизм нәдән гыйбарәт икәнене белергә уңгайдыр. Һәр шәйдә моңлы бер шигырь күрү вә бу хәзин[14] шигърияте әшгар[15] илән язудыр дисәк, байронизм хакында бер дәрәҗә якын фикер биргән булырмыз.

Байрон бер җәһәттән дөньяга нә кадәр күңелсезләнеп караса да, гашыйкы хөррият иде. Кол милләтләрне тәхрир вә игътакъ итәргә[16], әсарәтне тәрзил итәргә[17] шигырьләр язу илән генә канәгатьләнмәй, үз хәятыны фида итәргә дә хәзер иде. Буны һәм исбат итте. Румларның Төркиягә каршы истикълял гыйсъянында[18] Байрон, гасыйларга катышып, төрекләр илән сугышты. Аның фикерендә төрекләр залимнәр иде. Бу безнең мөселман нәзарында бөтенләй тугъры булмаса да, искедәге төрек валиләренең, төрек пашаларының золымнарыны бөтенләй инкяр итү тәгассыб[19] булса кирәк.

Бинаән галәйһи Байронның искедә Сократ хәкимнәрне, Әфләтун, Арстуларны тугъдырган юнан милләтене сөюе вә бу кеби якты бер мазыйга[20] малик милләтне гадәләтсез төрек пашаларының золымыннан коткарырга тырышуыны аңларга тиешмез. Әхвале галәмгә һәрвакыт үз даирәң офыгыннан гына карау мәгъкуль түгел. Бераз башка офыклардан карарга тырышырга тиештер.

---

[1] *Тәхвилат* — үзгәреш, алмашу.
[2] *Ихтирагъ* — уйлап табу (чыгару).
[3] *Голуме табигыйәдәге кәшфият* — табигать фәннәрендәге ачышлар.
[4] *Әфкяре җарияне* — фикерләр агышын.
[5] *Һәдем вә тәхриб итә* — вата һәм хәрап итә.
[6] *Хәссас* — сизгер.
[7] *Истикъбале бәшәриятка* — кешелекнең киләчәгенә.
[8] *Мөштакъ* — омтылучан.
[9] *Мәдәнияте хазиргә истихкарны* — хәзерге мәдәниятне хурлауны.
[10] *Могыйнь* — баетучы.
[11] *Муҗиб* — сәбәпче.
[12] *Парлакъ* — якты, ачык.
[13] *Сирайәт иткән* — йоккан, таралган.
[14] *Хәзин* — хәсрәтле.
[15] *Әшгар* — шигырьләр.
[16] *Тәхрир вә игътакъ итәргә* — азат итәргә.
[17] *Әсарәтне тәрзил итәргә* — коллыкны, әсирлекне тәнкыйтьләргә.
[18] *Истикълял гыйсъянында* — бәйсезлек өчен баш күтәрүендә.
[19] *Тәгассыб* — артык омтылу, фанатиклык.
[20] *Мазый* — үткән заман.

Байронның язган әсәрләреннән бере — «Шильон әсире» («Шильонский узник») дигән әсәрдер. Бу әсәр русчага мәшһүр Жуковский тарафыннан тәрҗемә ителгән. Хөләсасе: Швейцариядә Бонивард исемендә бер мөҗаһиде хөрриятнең алты сәнә кадәр Шильон шатусында [1] мәхбүс ятуыны кызганычлы итеп тәгъриф итүдер. Шильон шатусы Швейцариядә Ләман күле буенда Монтре-Тәрита дигән бер кечкенә шәһәр янындадыр.

Бәндәңез буны язган вакытта бу Монтре шәһәре өстендә бер кышлактагы авылдан Шильон шатусыны күрәмен. Кем белсен, шул күз алдымдагы Шильон шатусындагы алты сәнәлек бер әсарәтне ямьсезләп тәгъриф вә тасвир итү, бәлки, берничә зур мәмләкәтләрдә икътидар әсхабене хөрриятә сәвекъ иткәндер [2]. Золым, тәзийкъ [3] вә җәбердән җирәндергәндер. Бунда һич шөбһә юк. «Шильон әсире» дигән шигырьләрнең тарихе хөррияттә зур бер әһәмияте булганыны һич инкяр итү мөмкин түгел.

Менә, укучым, әле генә сезгә тәгъриф иткән бүлмә — әүвәлдә шул Байронның иҗтиһад гяһе [4] булган бер бүлмәдер. Менә, бу бөтен дөньяга хаәте рухиясене тәгъмим иттерерлек [5] куәтле бер рухка малик, берничә милләтне рәкабәт вә әсарәттән [6] котылдырырлык кадәр кувәи каләмиягә [7] малик бу даһи шушы бүлмәдә тәхсыйль иткән, тәрбия күргән, рухыны шушы бүлмәдә тәрбияләгән, үстергән.

Бүлмәнең пакь-тәмиз матурлыгыннан бәхәс иткән идем. Бу бүлмәнең пакьлеге, коллежның бая гына тәгъриф итдекем бакча вә чәчәкләр эчендә булуы Байрон кеби бер гали рухның мәйданга чыгуына дәхеле [8] юк дип беләсеңезме? Һич шөбһәсез, бу коллежларның тәмиз сарайлары булуы бунда тәхсыйльдә булган кешеләрнең тәшкиле руханияләренә бик зур бер тәэсире бардыр. Тәкрар әйтәм, хис нәфасәт бөек бер муҗибе тәгали вә фагыйле тәрәккъкыйдер [9].

Бүген безне Кембриджга чакыруга сәбәп — Кембриджда бүген Англиянең бөтен дөньяга мәшһүр галиме Дарвин туганына йөз сәнә булу бәйрәменә хазир булу иде. Бәйрәм мәрасиме буннан гыйбарәт булды: бер коллежның зур бер театр кеби сәндерәләр илән ясалган залында халык тулган иде. Түрдә профессорлар вә бөтен коллежларның башында мөнтәхәб[10] рәис (шансиләр) өчен урыннар хәзерләнгән иде. Вә буннан башка Европаның һәр ноктасыннан килгән галимнәргә урын куелган иде. Бу галимнәр һәрбере голүме табигыйәдә, хосусән[11] Дарвин кәшеф иткән мәсьәләләргә мөтәгалликъ китаплар, әсәрләр язган кешеләр иде. Бүген Дарвин туганына йөз сәнә булу бәйрәме мөнәсәбәтилә бу галимнәргә һәрберенә Кембридж дарелфөнүне шәрәфле докторлык дәрәҗәсе өләшә иде. Европаның һәр мәмләкәтеннән берәр профессор Кембридж дарелфөнүнендә докторлык дәрәҗәсе алды. Бу докторлык дәрәҗәсе бирү мәрасиме ошбу рәвештә икән: иң әүвәл Кембридж профессорларыннан берсе дәрәҗә алачак галимне мактап бер нотык сөйли. Буннан соң бөтен коллежларның мөнтәхәб рәисе (декан) бер-ике сүз әйтеп, докторлык шәһадәтнамәсене яңа шәрәфле докторның кулына бирәдер. Яңа доктор бер-ике сүз әйтеп тәшәккер[12] итәдер. Буннан соң безнең кеби карарга килгән кешеләр кул чабалар. Шулай итеп, Кембридж дарелфөнүненең фәхри[13] докторы булалар икән. (Мәгълүменез, доктор бу урында табиб дигән сүз түгел, галим дигән сүз.)

Безнең руслардан мәшһүр профессор Тимирязев һәм докторлык дәрәҗәсе алды. Бу Тимирязевнең хәзер сәламәт бер кеше булуы миңа кызык тоелды. Буннан ун сәнә мөкаддәм Казан учительский школасында өченче класста вакытымда бу кешенең Дарвинның кәшеф иткән нәзарияи гыйльмиясе («Происхождение видов») хакындагы китабыны укыган идем. Бундай китапларны бик каты фикерне ача дип безгә читенлек белән бирәләр иде. Ләкин мин, надзирательләр-

---

[1] *Шату* — крепость-төрмә, замок.
[2] *Сәвекъ иткәндер* — этәргәндер.
[3] *Тәзийкъ* — кысу-тыгызлау.
[4] *Гяһе* — вакыты.
[5] *Тәгъмим иттерерлек* — киң таратырлык.
[6] *Рәкабәт вә әсарәттән* — көндәшлек һәм әсирлектән.
[7] *Кувәи каләмия* — каләм (язу) куәте-кодрәте.
[8] *Дәхеле* — йогынтысы, тәэсире, катышы.
[9] *Муҗибе тәгали вә фагыйле тәрәккъкыйдер* — бөеклек сәбәпчесе һәм тәрәккъыйне башкаручы.
[10] *Мөнтәхәб* — сайланган.
[11] *Хосусән* — бигрәк тә.
[12] *Тәшәккер* — рәхмәт әйтү.
[13] *Фәхри* — мактаулы (почетлы).

дән үтенеп, байтак, башкаларга мәмнугъ[1] китапларны укыган идем. Бу сәнә школада вакытым бик күп укыган сәнәмдер. Дүртенче класста, ибтидаи мәктәптә, тәгълим ысулы белән мәшгуль булганга, бу кадәр укып булмаганы школада булган кешеләргә мәгълүмдер. Школаның өченче классында һәр школьник байтак укыйдыр, мәгаттәәссеф, күбесе романнарга һәм юк-бар вә мәгънәсез романнарга вакыт сарыф итәләр. Мин, иптәшләремә караганда бераз яшем зуррак булганга, тәҗрибә вә һәвәсе гыйльмем[2] һәм артыграк иде. Хосусән тарихи вә фәлсәфәи китапларга мәелем зиядә иде. Француз әдипләреннән мәшһүр Руссо әсәрләре кулыма төшеп, аерыла алмый укыганым халән[3] хәтеремдәдер. Француз лисаныны беләсем килүем дә шул вакыт ук туган иде. Бу рәвештә бер яктан Руссо кеби фәлсәфи әсәрләргә һәвәс иткән кеби, икенче яктан голүме табигыйәгә дә мәракъ[4] итә идем. Ул вакытта фикерле аталган кешеләремез арасында фән белән диннең ижтимагыйәсе мөмкин булуы хакында фикер йөртү бик мода иде, мин дә русча әсәрләрдән дин илән фәннең гадәме тәнакызыны[5] беләсем вә исбат итәсем килә иде.

Мин шул вакытта Дарвинның кәшеф итдеке кануне тәкямел[6], яхуд «Истыйфаи табигый» нәзариясе хакында да ишеткән идем. Бу хакта бераз тәфсыйльле мәгълүмат аласым килә иде. Шуның өчен байтак мәшәкатьләнеп, Тимирязевнең китабыны алган идем. Миңа китапны биргәндә назыйр мөгаллим: «Бу китапны һәркемгә күрсәтмәңез, бераз яшереп укыңыз, чөнки бәгъзы яшьләр һәм сездән соң сорап укыр да, белер-белмәс нәтиҗәләр чыгарыр»,— дигән иде.

Шуның өчен бу китапны төнлә, кеше яткач, спальнянең юыну бүлмәсендә укый идем. Чөнки спальнядә лампалар кысылган була иде. Шулай итеп, бер яктан, иптәшләремнән качып укый идем, икенче яктан, чытаеп, игътикадыма зарар килмәсә ярар иде, дип, куркып укый идем. Бу китапны укып чыккач, эчендә һичбер төрле игътикадате исламиягә мөхалиф[7] нәрсә тапмагач, шатланганымны күрсәң!!

Бу үз мазыйым[8] хакында кайтып сөйләвемне гафу итүенезне үтенәм. Хатирате шәбабәт[9] бик газиздер. Каләм бер кереп киткәч, туктау бик читен. Нә исә, менә бүген Кембриджда докторлык алган Тимирязев шул китапның мосаннифы[10] иде. Мин бу урында Дарвин кәшеф иткән нәзарияи гыйльмия нидән гыйбарәт икәнене яза алмыйм. Бу хакта беләсе килгән укучыларга шул ук Тимирязев китабыны, яхуд Дарвинның русчага тәрҗемә ителгән китабыны тәүсыя итәм[11].

Чарльз Дарвин 1809 да туган вә 1882 дә вафат булган. Шулай итеп, бүген 24 июньдә аның вәладәтенә йөз сәнә буладыр. Дарвинның бөтен әхфады[12], угылының угыллары, Кембриджда торалар икән.

Өйләдән соң сәгать дүртләрдә Дарвин әхфады безне вә бөтен әтрафтан килгән профессорларны бер бакчада чәйгә чакырдылар. Дарвинның ике хафиденә вә ике килененә тәкъдим иттеләр. Буннан соң ватандашымыз Тимирязев илән һәм таныштык. Әллә кайчан тарихланып беткән Дарвинның киленнәре булуы, алар илән танышу мөмкин булуы вә минем фикеремдә әллә кайчандагы школа хатирәләре эчендә күмелгән Тимирязевнең исән булуы вә аның илән күрешү-сөйләшү мине бик кызык фикерләргә төшерә иде.

Бөтен галәмдә әбәдия[13] мәшһүр тотылачак Дарвинның һәм хәяте шәхсиясендә гади кеше булуы, шушы без йөргән коллежларда йөргән, без күргән бакчаларда гизгән булуы, Пушкинның «Бер инсанның голүви[14] куәте тәфәккериәдән башка бер нәрсә түгелдер» (Что составляет величие человека, если не мысль») дигән сүзе хәтеремә төшә иде. Хәкыйкатән, бөек адәмнәр, гали инсаннар иҗадат, фикерия вә димагыйәләре[15] нисбәтендә бөекләрдер.

---

[1] *Мәмнугъ* — тыелган.
[2] *Һәвәсе гыйльмем* — гыйлемгә һәвәслегем.
[3] *Халән* — хәзер дә.
[4] *Мәракъ (мәрам)* — теләк, максат, ният.
[5] *Гадәме тәнакызы* — бер-беренә каршылыгы.
[6] *Кануне тәкямел* — үсеш кануны.
[7] *Игътикадате исламиягә мөхалиф* — ислам ышану-өйрәтүләренә каршы килә торган.
[8] *Мазыйым* — үткәнем.
[9] *Хатирате шәбабәт* — яшьлек хатирәләре.
[10] *Мосанниф* — автор.
[11] *Тәүсыя итәм* — тәкъдим итәм.
[12] *Әхфад* — оныклар (хафид — онык).
[13] *Әбәдия* — мәңге, мәңгегә.
[14] *Голүви* — югары, бөек.
[15] *Димагыйәләре* — ми эшчәнлеге, акыл.

Бу чәйдән соң тимер юл илән Лондонга кайттык. Бу кич теләгән кеше «Дейли телеграф» дигән гәзитә идарәханәсене карарга бардылар. Мин өйдә калдым.

## XX

### Лондонда бишенче көн. Лорд Крумер өендә. Лорд Крумер илән сохбәт. Англия падишаһы тарафыннан кабул улыну. Кич нәзарияте хариҗия даирәсендә кабул һәм Лондонның иң мәшһүр ханәсендә кичке кабул

Өйлә тәгамына бүген мәшһүр Солсбери ханәсенә чакырылган идек. Ләкин мин бу ханәгә бармадым. Сәбәбе — мин үзем ялңыз мәшһүр Мисырда күп еллар хаким булып торган лорд Крумер тарафыннан чакырылган идем. Бу чакырылу бу рәвештә булган иде.

Дума әгъзалары шәрәфенә Русия сәфире граф Бенкендорф бөек бер мөсамәрә [1] ясады; бу дәгъвәт илчеханәгә Англиянең әксәр вөкәлясене [2] вә табәкаи галиясеннән [3] бик күп адәмне җәлеп иткән иде. Дәгъвәтлеләрнең микъдары меңнән зиядә иде. Әүвәлдә Мисырда Англиянең баш мәэмүре булып торган мәшһүр лорд Крумер мөсамәрәдә хазир булган, мине күрергә теләгән, фәкать мин ул көн аның илә күрешә алмадым. Соңра аңладыгыма күрә, лорд Крумер господин Стаховичка мөрәҗәгать итеп: «Араңызда Дума әгъзасы бер мөселман бар имеш; аның илә күрешергә теләр идем»,— дигән. Стахович лордка адресымны биргән.

Мөсамәрәдән ике көн соңра лорд Крумердан аеруча дәгъвәтнамә алдым. Егермесенә кадәр Мисыр валилегендә булган вә Мисырның әмир идарәсене ислях, өмүре икътисадиясене [4] тәрәккъый иттергән вә, бинаән галәйһи, галәме ислам [5] илә Шәрекъ әхваленә ашна бер сәяси кеше илә күрешәчәгемә шатланып, дәгъвәтенә күрә бардым. Кечкенә бер утада [6] тәгам сөфрәсе [7] башында бер сәгать ярым кадәр сохбәт иттек. Бөтен сохбәтемезне тәмам язмыйм.

Җитди вә кызыклы бәхәсләр галәме ислам вә буның истикъбале даирәсендә дулашты. Лорд Крумерның галәме исламның хәл хазиренә вә тарихына даир мәгълүмат васыйгасе [8] мине хәкыйкатән хәйран итте! Безнең Төркестандагы җирле мәхкәмәләр хакында миннән сораган сөальләре Төркестан идарәсенең бөтен тәфсыйлатене тәдкыйк иткән [9] булуыны күрсәтә иде. Бәрәкәт бирсенгә, мин бу сәнә дахилия нәзарәте бюджеты хакында сөйләгән нотыкны хәзерләгәндә Төркестан идарәсе вә әһалисе хакында байтак нәрсә укыган вә тәхкыйк иткән [10] идем ки, мәхҗүбияттә [11] калмадым.

Лорд Крумер мина диде:

— Галәме исламны белергә теләвемнең сәбәбе ялңыз мәэмүр вә сәясион нәзарыннан түгелдер; философ нәзарыннан дәхи тәхкыйк итмәк эстим.

Минем мөселманнарның истикъбале хакында сөйләдекем өмидләргә лорд җәнабләре муафәкать итми исә дә, әкъваме исламның истикъбалене чарасыз күрми; соң вакытларда Шәрекътә күрелгән хөррият вә тәрәккъый хәрәкәтләреннән зур нәтиҗәләр көтә, фәкать бу хили шартлар дахилендә; күстәрдеке шартлар махсус вә кызыклыдыр. Мәгаттәәссеф, сәяхәтнамәмдә озак тәхлил итә [12] алмыйм.

Әгәр лорд Крумерның бөтен дидекеләрене бер җөмлә тәгъбир итмәк лязем булса, болай дияр идем:

---

[1] *Мөсамәрә* — кичке аңгәмә, сөйләшеп утыру.
[2] *Әксәр вөкәлясене* — күп вәкилләрен.
[3] *Табәкаи галия* — югары катлау.
[4] *Өмүре икътисадиясене* — дәүләт экономикасын.
[5] *Галәме ислам* — ислам дөньясы.
[6] *Ута (ота, ода)* — өй.
[7] *Тәгам сөфрәсе* — аш табыны.
[8] *Мәгълүмат васыйгасе* — мәгълүмат киңлеге, иреклеге.
[9] *Тәдкыйк иткән* — дикъкатләп өйрәнгән.
[10] *Тәххыйк иткән* — дөреслеген тикшергән.
[11] *Мәхҗүбият* — оятка калу.
[12] *Тәхлил итү* — анализлау.

— Мөселманнар чабук [1], вакыт качырмаенча Аурупа мәдәниятенә кабул вә татбикъ итмәледер. Юкса агыр хәлләргә калачаклар; динебез илә бу мәдәният имтизаж итә [2] алмый дигән фикерләре батыйльдер [3], хәленез җәһәтеңездән нашидер [4]; коруне вөстада христиан галәме һәм буйлә фикерләрдә иде... Бакыныз Англиягә: мәдәниятсез дип әйтә алмассыңыз, гыйбадәт ханәләре шәһәрнең иң гүзәл мәйданнарындадыр; иң гүзәл биналарыдыр; якшәнбә көннәре кәлисаләр [5] халык илә тулыдыр; әгәр бетмәк, черемәк эстәми исәңез, тиз мәгарифкә, тәмәддеңгә [6] тырышыңыз; хәер-хуаһанә әйтәм, юкса мөселманнарның истикъбальләре дәһшәтледер.

Лорд Крумерның сохбәт заманында сөйләгән башка сүзләре дә гаять әһәмиятле дикъкатькә шаяндыр. Мәгаттәәссеф, бу сүзләр шул кадәр мөһим вә фәлсәфи ки, бер сәяхәтнамәдә бунларның тәфсыйлатене сыйдыру мөмкин түгелдер.

Буннан соң хосусый ханәләрне тәгъриф вә бунда булган хосусый сохбәтләрне тәфсыйль итмим. Буңа кадәр язудан максудым укучыга бу галәмдә йөргән фикер вә сохбәтләр хакында тәкърибән [7] бер фикер бирү иде. Буна кадәр язганым бу хакта кяфи [8] булса кирәк. Бу урында шуны да әйтим, мин сохбәтләрне язган вакытта һәрбер сүзләрне яза алмадым. Бунын сәбәбе — күрешкән кешеләрем һәрбере бик зур сәясәт әрбабы [9] булганга, һәрбер фикерләрне язу сәясәт вә әдәп җәһәтеннән мөмкин түгелдер. Бинаән галәйһи буннан соң күрешәчәк берничә министр илән булган сохбәтләрнең тәфсыйлатене яза алмаганым өчен гафу үтенәм.

## Падишаһ сараенда кабул

Сәгать өчтә бүген сарайда кабул ителәчәк булганымызга, сәгать икедә һәрберемез һотелгә кайтып, махсус бүлмәгә жыелган идек. Мөдәббирләр әүвәлдә безгә сарайда кабул адәбе буенча нинди киемнәрдә булу лязем булачагыны әйтеп куйганнар иде. Һәрберемез сюртюкта булу тиеш иде. Галстукларымыз чын карада, бөтенләй якты да булмаска тиеш иде, бертөрле соры галстуклар тәүсыя иткәннәр иде.

Куллар сары сымак пирчәткәдә булырга тиеш иде. Сарайга барып житкәч, падишаһ илән күрешкәндә уң кулларымызда пирчәткәләр салынган булып, сул кулларымыз пирчәткәле булырга тиеш иде. Табигый, штиблетләр лаклы булырга тиеш иде.

Сәгать өчкә чирек сәгать калганда автомобильләргә утырып Лондонда Англия падишаһы тора торган «Букингем» сараена юнәлдек. Кәефләремез яхшы иде. Бундай зур бер падишаһ тарафыннан кабул ителүгә бер җәһәтеннән бер нәүгъ шатлык вә, дигәр җәһәттән, кечкенә генә бер каушау хис итә идем. Күрә идем ки, тәкърибән гайн хисләр башка иптәшләремдә һәм бар иде.

Автомобильләр илән сарайга барып життек. Сарайның фасадының мәһабәтлекләрене тәгъриф итеп сезне борчымыйм. Ләкин фәүкыльгадә булганыны әйтим. Автомобильләрдән төшеп ишектән кергәч, беренче күзгә күренгән зур баскыч, баскыч буенда тезелгән әллә нә кадәр кызыл ливрейләр кигән, сачләрене ак пудра илән агарткан лакейлар өстемездән пальтоларымызны вә цилиндрларымызны алдылар. Югары менгәч үк безнең Русия посолы Бенкендорф вә аның мөгавиме вә сарайның мәрасим назыйры каршымызга килделәр, бер бүлмәдә бераз көтү лязем булганыны аңлаттылар. Бу бүлмә кабул бүлмәсеннән байтак ерак иде. Шуның өчен үзара сөйләшә идек. Мөдәббирләр падишаһ кабул итә торган бүлмәгә кем кем артыннан керәсене вә кем кем артыннан король вә королигә илән күрешәчәкне аңлаттылар. Мин Ефремов илән барон Крюднер арасында идем.

Керергә вакыт житте. Иң алдан сәфиремез керде, буннан соң Хомяков вә һакәза [10]. Нәүбәт миңа житте. Иң озын залның уртасыннан керелә иде. Ишектән

[1] *Чабук* — тиз (рәвештә).
[2] *Имтизаҗ итү* — ярашу, кушылу.
[3] *Батыйль* — ялган.
[4] *Нашидер* — барлыкка килгәндер.
[5] *Кәлисә* — чиркәү.
[6] *Тәмәдден* — мәдәниятләшү.
[7] *Тәкърибән* — якынча.
[8] *Кяфи* — җитәрлек.
[9] *Сәясәт әрбабы* — сәясәт әһелләре, кешеләре.
[10] *Вә һакәза* — һәм башкалар.

кердем. Миннән биш-алты адым җирдә уң ягы илән падишаһ вә аның сул тарафында короличә вә аннан ары падишаһның угылының балалары тора иде.

Якын барып, Европа гадәтенчә, аякларымызны тигез куеп, башымызны иеп сәлам бирдек.

Падишаһ кулыны сузганыны күреп, кулымны суздым. Сәфир падишаһга исемемне вә кем булганымны сөйләде: «Максудов, Думада мөселман мәбгуслары группасыннан»,— диде. Җиденче Эдуард кулымны яхшылап тотып кысып күреште, падишаһның мәргуб [1] йөзендә йөземә карап күрешкәндә хәер-хуаһанә бер тәбәссем [2] бар иде.

Падишаһ илән күрешкәч, короличенең кулыннан үптем. Короличенең нәзарыда гаять хәер-хуаһанә иде. Буннан соң миннән элек күрешкән иптәшләрем янына барып тезелдем. Иптәшләрем һәрберсе залның уң тарафында падишаһка каршы тезелгән иделәр.

Миннән соң кергән кешеләр күрешеп бетеп, һәркаюымыз бер җиргә тезелгәч, падишаһ безгә таба якын килеп, саф француз лисанында бер нотык сөйләде. Нотык озын булмаганга, бу җирдә гайнән [3] язу файдасыз булмаса кирәк. Нотык буннан гыйбарәт иде:

— Әфәнделәр, королева вә үземнең исемемнән сезгә хуш килдегез димен. Дума башланганнан бирле бик зур бер интерес илән мин сезнең Дума мәҗлесләрене укып килдем. Бүген сезне шәхсән тануымга вә сезне минем мәмләкәтемдә күрүгә зиядәсилә [4] мәмнүн булдым. Өмид итәм ки, сез минем мәмләкәтнең төрле тарафларыны вә төрле милли мөәссәләрене күрергә вә үгрәнергә өлгерерсеңез. Тәәссеф итәм ки, һава бик яхшы түгел, ләкин өмид итәм, сез киткәнче матур көннәр дә булыр әле. Хуш, сау булыңыз дигәнче шуны да әйтим: мин сезнең мәмләкәткә сәяхәтемнән бик яхшы хатирәләр сакладым. Мин сезнең мәмләкәткә ике бардым, киләчәктә дәхи барырга өмид итәм. Хуш, сау булыңыз, яхшы сәфәр итеңез.

Җиденче Эдуард бу нотыкны сөйләгәндә, бу падишаһның дөньяның иң зур падишаһларының берсе булуы, нинди зур бер милләтнең сөемле әмире икәне, нә кадәр мөстәмләкят [5] вә нә кадәр әкъваме шәттаның [6] императоры икәне һич хәтеремнән чыкмый иде. Бундай бер мәркәзе куәт, бөтен галәм тарафыннан тәсдикъ ителгән икътидар [7] алдында каушау белән катыш тирән бер хөрмәт хисе итә идем.

Падишаһ нотыгыннан соң Хомяков буңа бер җавап сөйләде. Рус милләте вә Думага хөсне тәвәҗҗеһе [8] өчен падишаһка рәхмәт укыды. Буннан соң падишаһ безнең илән баш селкеп күрешеп, үзенә махсус бер ишектән чыкты.

Сонра без дә бер-береннән зур, бер-береннән матур, мәһабәт заллардан узып, пальтоларымыз калган җиргә төштек. Киемнәрне киеп, сарайдан чыктык, автомобильләр илә өйгә кайттык. Һәрберемез кабул рәвешеннән, илтифаттан, падишаһның нотыгыннан гаять мәмнүн вә мөтәәссир идек.

Мин Ефремов вә Милюков илән бер автомобильдә идем. Милюков нотыкның холясасене тәкрар итә иде. Мин:

— Холясагә хаҗәт юк, мин бөтен тәгъбир вә җөмләләре илән ядыма алдым,— дидем. Вә шул сәгать тәкрар иттем. Бу нотыкның соңыннан әһәмияте зур булачагына, нотыкның бөтен сүзләрене хәтердә калдырырга тырышкан идем. Һәм нотык озын булмаганга муаффәкъ тә булган идем.

Милюков:

— Мадамки [9], һәр сүз хәтереңездә икән, кайткач ук яза күреңез,— диде.

Кайтып житәр-житмәс яздым да иптәшләремә күрсәттем. Аларның хәтерләрендә калган җөмләләргә татбикъ иттек[10]. Һәрбере вакыйган җөмләләр шушылар, диделәр. Вә шул сәгать рус гәзитәләренең мөхбирләре тәрҗемә итеп телеграм җибәрделәр.

---

[1] *Мәргуб* — сөйкемле.
[2] *Тәбәссем* — елмаю, көлемсерәү.
[3] *Гайнән* — үзгәртмичә, ничек бар, шулай.
[4] *Зиядәсилә (зиядәсе илә)* — артыгы белән.
[5] *Мөстәмләкят* — колонияләр.
[6] *Әкъваме шәтта* — төрле-төрле кавемнәр.
[7] *Икътидар* — көч, булдыклылык.
[8] *Хөсне тәвәҗҗеһе* — яхшы-хуш илтифаты.
[9] *Мадам ки* — әгәр шулай икән.
[10] *Татбикъ иттек* — чагыштырдык.

Бу нотыкның нә кадәр мөһим икәнене изахка[1] хаҗәт юк. Бу беренче дәфга[2] Русия мәҗлес мәбгусаны — депутатларыны башка бер мәмләкәтнең падишаһы рәсми сурәттә кабул итү иде. Бинаән галәйһи, Думаның игътибары вә Русиядә идарәи җәдидәнең урнашуы җәһәтеннән бу кабул вә нотыкның тарихи бер кабул вә нотык булачагында һич шөбһә юктыр.

Буннан соң кавус әскәлсендә, Англия короле безнең императорны кабул иткән вакытта, үзенең безне кабул иткәнене сөйләде вә безнең падишаһка диде:

— Мин сезнең мәмләкәтнең Думасының берничә вәкилләрене күрдем. Алар минем янымда берничә вакыт калдылар. Өмид итәм ки, анлар безнең мәмләкәтнең тәэсисат[3] вә хәятыны яхшы күрә алганнардыр. Аларның мөшаһәдәтләре[4] безнең ике мәмләкәтнең арасында мәүҗүд мәхәббәтне тагы да куәтләргә сәбәп булса иде,— диде.

Безнең император буңа каршы Англия падишаһына тәшәккер әйтте:

— Минем Думаның әгъзаларыны хөсне кабулыңыз өчен зур рәхмәт,— диде.

Мәнә, укучы, Англиягә сәяхәтемез вә аның падишаһы тарафыннан кабул ителүемез әһәмиятсез вакыйгаләрдән түгелдер. Безнең падишаһның Англия падишаһына безне яхшы кабул иткәне өчен тәшәккер итүләре Думаның дәрәҗәсе игътибары җәһәтеннән гаять зур бер вакыйгадер.

Бүген иң күп җиргә чакырылган көнемез иде. Кич иң әүвәл хариҗия министерствосының сараенда кабулга чакырылган идек.

Буннан башка Лондонның иң зур, иң бай, иң аристократ хисап ителгән ике йортында һәм кичке кабулга (мөсамәрәгә) чакырылган идек. Бу кич эчендә өч җирдә булу лязем иде. Иң әүвәл хариҗия нәзарәте сараена бардык. Бу сарайның зурлыгыны һич сөйләп аңлатыр хәл юк. Ул көн кабулга ун мең кеше чакырылган һәм хазир иделәр дисәм, бераз зал вә баскычларның зурлыгы хакында бер фикер биргән булырмын. Сарайга берничә чакрым әтрафка тезелгән арабаларның гына да хисабына чыгу мөмкин түгел кеби иде. Бу арабаларның бер-беренә юл бирергә, тәртип белән тезелергә бундай зур шәһәрләрдә махсус ысул бар имеш. Кунакны китереп төшергәч, бәлдия полисе[5] кешеләре күчергә бер номер бирәләр. Кире чыкканда нә кадәр арабалар күп булса да, ун минуттан лязем арабаны табып китерәләр имеш.

Хариҗия нәзарәте сараена барып төштек. Фәүкыльгадә зур баскыч халык белән тулган. Зур вә киң, тау кадәр баскычтан уң ягыннан бер агым төшә, сул тарафтан икенче агым акрынлап югары чыга иде. Югары менгәч, алдымызда күренгән ачык зал кеби бер җир дә кеше илән тулган иде. Ирләр һәрбере йә фрак кигән иде, йә гаскәри киемнән иде.

Мин инглизләрнең гаскәрләрене вә гаскәри әлбисәләрене[6] беренче дәфга күрә идем. Офицер әлбисәсе шактый матур. Озын буйлы, арык инглиз гаскәриләренә яхшук килешә. Ирләрдән соң дамаларга да дикъкать иттем. Һәрбере гаять нәфис, бу сәнә модасы — мөсамәрә робаларында иде. Һәрберенең муеннары ачык иде. Бриллиант, энҗе илә тулы иде. Дикъкать иттем: хатыннардагы энҗе-мәрҗән Франция вә Русиядә бу кеби мөсамәрәләрдә күренгәннән артыграк иде. Бу да инглизләрнең бу югары табәкаләренең фәүкыльгадә байлыгына шәһадәт бирә иде.

Баскычтан менеп җитүгә, безне бер танымаган кешеләр каршы алдылар. Кешеләр фәүкыльгадә күп булганга, иптәшләремнән аерылмага мәҗбүр булдым. Мине әллә никадәр саллардан, бүлмәләрдән үтеп, бер суык тәгам хәзерләнгән җиргә алып керделәр. Бундай хәзерләнгән өстәл берничә җирдә булса кирәк. Мин утырган җирдә миннән башка рус иптәшләрем юк иде. Һәркем кеше күплегеннән аерылып беткән иде. Бер өстәл янына барып утырдым; шул ук бүлмәдә өстәлнең ары башында ул көннәрдә Лондонга Солтан Мөхәммәд Хамеснең тәхеткә утырганыны игълан итәргә килгән Мохтар паша һәм утыра иде. Аның бәрабәрендә берничә фәсле төрекләр бар иде.

Бер-ике суык тәгамнәрдән капкалап, тизрәк бу бүлмәдән чыктым. Чыгып каранып йөрисем килә иде.

Чыгып барганда гаскәри әлбисәдә бер арык, озын кеше якын килеп русча:

— Ватандаш, сезнең илә танышырга эстим,— диде.

---

[1] *Изах* — җентекләп аңлату.
[2] *Дәфга* — тапкыр, мәртәбә.
[3] *Тәэсисат* — төзелеш.
[4] *Мөшаһәдәт* — шаһитлек.
[5] *Бәлдия полисе* — шәһәр полициясе.
[6] *Әлбисә* — киемнәр.

Бу зат Лондонда икамәт итә торган[1] бер великий кенәз икән, исемене сөйләде. Шул сәгать хатынына тәкъдим итте. Мин дә фамилиямне сөйләдем.

— Сезнең фамилияңез миңа мәгълүм,— диде.— Берничә көннән бирле Лондонны шаулаткан ватандашым депутатларның фамилиясене минем кеби рус түгел, бөтен Лондон әһалисе беләдер,— диде. Хатыны французча сөйли башлады.

Бу великий кенәз вә зәүҗәсе[2] илән байтак сөйләшеп тордык. Берничә мәсьәләдән байтак җитди бәхәс иттек. Великий кенәзнең үзене простой тотуы, миңа, простой бер депутатка илтифаты, фикерләре миңа гаять хуш тәэсир итте. Мадам ханәсенә дәгъвәт итте:

— Хариҗия нәзарәтендә бөтен кичә каласызмы? — диде.

— Юк,— дидем.— Бүген янә ике җирдә булырга тиешмез,— дидем.— Фәкать аркадашларымнан аерылдым, ничек барырга белмим,— дидем.

— Кая барасыз? — диде.

— Моннан Стаффордһаус дигән йортка, аннан Лансдаунһаус дигән йортка бару фаразында идек,— дидем.— Инде ялгыз барырга мәҗбүрмен. Фәкать ничек адрес илән барырга да белмим,— дидем.

Кенәз диде:

— Лондонда бу ханәләрне белмәгән кеше юк, шушылай ханә исемнәрене әйтсәңез, сезне теләсәңез кайсы арабачы илтер,— диде.— Без дә Стаффорд һауска барачакмыз, ләкин без әүвәл Лансдаунһауска барамыз,— диде.

Великий кенәзнең нәзакәт вә самимияте, бу кадәр илтифаты мине хәкыйкатән мөтәәссир итте.

Нәзарәттән чыгып, байтак урамнардан җәяү барып, бер арабачы табып Лансдаун ханәсенә юнәлдем. Байтак баргач, әллә никадәр арабалар арасыннан бара башладык. Бу арабалар арасыннан ун дәкыйка чамасында баргач, ниһаять, бер бакчалы ишек алды эчендәге сарай кеби бер ханәгә килеп җиттек.

Халыкның күбесе китә иде. Ләкин килүчеләр дә бар иде. Китүчеләрнең кучерләрене хуҗаларының исемене кычкырып чакыралар иде.

Ниһаять, барып кердем. Бер зур ханә, дәһа тугърысы — бер падишаһ сарае. Безнең кеби бер хосусый кеше ханәсе. Тәсаувыр иту[3] кабил түгел. Һичбер мәмләкәттә бер хосусый кешенең мәскәне[4] бу кадәр мөзәйян[5], бу кадәр зур булу ихтималы юк.

Ялгыз идем. Һич кешене танымый идем. Иптәшләрне эзли идем. Бара торгач, берничәсене таптым. Ханә сахибәсенә тәкъдим иттеләр. Ханә сахибәсенең кабулы бер падишаһ хатыны кабулына охшаш иде.

— Залларны карап йөрдеңезме? — диде.

— Йөрдем,— дидем. Картина вә рәсемнәрнең күплеге хакындагы хәйрәтемне[6] белдердем. Бундай, һәрвакыт һәркемнән ишеткән комплиментка исе китмәсә дә, залларны карадыңызмы дигәч, бер нәүгъ әһәмият биргәнлеккә шаһид бирәр сүз әйтмәсәң мәкъбүл күрмәячәге мәгълүм иде.

Лондонда бундай бай ханә биш-алты гына имеш, бунлардан без өчендә булдык. Болардан берсе шушы Лансдаун ханәседер. Икенчесе — моннан чыгып барачагымыз — Стаффорд ханәседер. Өченчесе — мәшһүр Веллингтон ханәседер. Бунда һәм берничә вакыт соңра булдык. Буннан соң язачакмын. Бу ханәләр, хәкыйкатән, эчендәге сәрвәт, хәзинә, алтын-көмеш вә фәүкыльгадә кыйммәтдар рәсемнәрнең күплеге, залларның зур вә матурлыгы, әтрафында бакча вә мәнзәрәләрнең гүзәллеге җәһәтеннән гаҗәпкә калмау мөмкин булмый торган җирләрдер.

Инсан сарайларны күргәндә бу кадәр гаҗәпсенмидер. Ләкин бу кадәр зур сәрвәтләрнең бер хосусый кешенеке икәнене күрү хәйран калдырадыр.

Бу Лансдаун ханәсеннән чыгып, тизрәк Стаффорд ханәсенә бардык. Бу ханә байлык җәһәтеннән югарыдагыдан ким түгел. Бу ханәдә бүген зур кабул булмай, безгә махсусрак ясалган кечкенә бер мәҗлес иде. Шуның өчен залларны, картиналарны тагы да тәфсыйльләп, озак карап йөри алдык. Ханә сахибәсе үзе күрсәтеп йөрде. Картиналарның кәсрәт вә нәфасәтенә[7] изһаре тәгаҗҗеб[8] итмәү

[1] *Икамәт итә торган* — яши торган.
[2] *Зәүҗәсе* — хатыны.
[3] *Тәсаувыр иту* — сурәтләп күз алдына китерү.
[4] *Мәскән* — тора торган урын.
[5] *Мөзәйян* — бизәлгән, зиннәтләнгән.
[6] *Хәйрәтемне* — соклануымны.
[7] *Кәсрәт вә нәфасәтенә* — күп булу һәм нәфисләкләренә.
[8] *Изһаре тәгаҗҗеб итмәү* — гаҗәпләнүне белдермәү.

мөмкин түгел иде. Вә бу изһаре тәгажжеб ханә сахибәсенең хушына китүе бик заһир[1] иде. Гаҗәп инсаннар, бәдиһи[2] булган хуш хәкыйкатьләрне нә кадәр тәкрар итсәң дә, кәефләре килә генә барадыр. Бу ханәнең нәфасәте хакында ханә сахибәсе нә кадәр изһаре тәгажжеб, ибраз тәхсиннәр[3] ишеткәндер, алай булса да, безнең илән булган иптәшләремездән Маклаков вә Стаховичның сөйләгән тәхсиннәренә кәефе килгәне заһир иде.

Кеше аз дисәң дә, зур залда ирдән-хатыннан илле кадәр кеше бар иде.

Танышкаладык. Арада мәшһүр Чемберлен угылы вә анын килене бар иде. Назик бер оркестр гаять хуш бер музыка һәвалары ишеттерәләр иде.

Бу сәрвәт, бу нәфасәт, хазирундагы[4] нәзакәт куәи хыялияне гаять тирән хәрәкәткә китергән иде.

Музыканың сәмави аһәңнәре рухның иң нечкә тамырларыны селкетә иде. Хыял булындыгымыз ханәдән дәһа мең кат нәфис, мең кат гали бер галәмдә җәүлан итә[5] идек.

Стаффордһаус дигән ханәнең сахибе Док Соутерленд дигән кеше Англиянең иң бай лордларыннандыр. Шотландиядәге ниһайәтсез күп җирләре фәүкыльгадә күп доход китерә имеш.

## XXI

## Лондонда алтынчы көн. Бер музәханә рәсме көшады[6]. Виндзорга бару.

Бүген иртә белән яңа ясалган бер музәханәнең ачылуыны карарга бардык. Бу бөтен Лондон өчен бер вакыйга булды. Музәханәгә якын бөтен урамнар халык илән тулган иде. Һәр җирдә флаг, һәр җирдә чәчәкләрдән гирләндәләр ясалган иде. Музәханәгә Англиянең хәзерге падишаһы Эдуардның анасы Виктория падишаһ илән атасы Альберт исеме бирeләчәк иде. Музәханәнең зур залларыннан берсе булачак җирдә һәр җиргә урындыклар хәзерләгәннәр иде. Падишаһ килеп нотык сөйләячәк җиргә якын уң тарафтан бөтен мәмләкәтләрнең посолларына, сул тарафта Англиянең зур кешеләре арасында безгә җирләр хәзерләгәннәр иде. Залга һәркем сыячак булмаганга, Англиянең иң зурлары гына хазир иде. Падишаһ залда биек итеп ясалган җиргә чыгып, музәханә ачылуга мөнәсәбәтле бер нотык сөйләде. Падишаһ залга чykканда һәм нотык соңында музыка Англия гимныны уйнады. Нотык соңында музәханә назыйрына Эдуард музә ачкычын бирде. Шул ачкычны бирү илән рәсме көшад тәмам булган хисап ителде. Рәсме көшад тәмам булганнан соң, падишаһ тәмам безнең янымыздан үтеп, чыгып барышлый безгә махсус бер сәлам бирде. Падишаһ артыннан вәли гаһед[7], анын зәүҗәсе вә аннан соң баш министр Асквит чыкты. Буннан соң без дә чыгып, көчкә автомобильләрне табып, өйгә кайттык. Рәсме көшадта Төркиядән Мохтар паша бар иде. Ул да безгә каршы посолларга махсус бер хөрмәтле урында иде.

Өйләдән соң Лондоннан өч-дүрт сәгатьлек җирдә Англия падишаһларының җәйлек сарае булган Виндзор сараен карарга бардык. Виндзор сарае дөньяның бик матур сарайларыннан берсе имеш. Без тимер юл илән бармый автомобильләр илә бардык. Үтеп киткән басуларымыз бик матур иде. Ләкин һичбер җирдә ашлык чәчелгән басу күрмәдем. Һәр җирдә болынлык, бәрәңге бакчасы гына очрый иде. Күреләә ки, Англиянең мин күргән җирләрендә иген игү бик аз мәкъбүл, авыл халкы болынлыклар ясап хәйван асрау илә мәшгуль. Кырлар матур, юллар яхшы, һәр җирдә чирәмлекләр. Ара-тирә вак күлләргә очрадык, байтак заман бер су буеннан бардык. Өч-дүрт сәгать автомобильләр илән чапканнан соң, ниһаять, Виндзор сараена килеп җиттек.

Сарай бер таулык өстендә, фәүкыльгадә зур. Тарыз мигъмарисы[8] готик стильдә. Бу сарай эчендәге мал-мөлкәт, картина, зиннәт[не] һичбер җирдә күрмәдем. Бөтен залларны карап йөрергә ике сәгать чамасында вакыт кирәк булды.

---

[1] *Заһир* — ачык, күренеп тора.
[2] *Бәдиһи* — ап-ачык билгеле.
[3] *Ибраз тәхсиннәр* — күрәләтә мактаулар.
[4] *Хазирун* — җыелган кешеләр, шунда булучылар.
[5] *Җәүлан (җәвәлән) итә* — әйләнеп йөри.
[6] *Музәханә рәсме көшады* — музей ачу тантанасы.
[7] *Вәли гаһед* — падишаһның үзе урынына тәхеткә утырачак варисы.
[8] *Тарыз мигъмарисы* — архитектурасы.

Залларны тәгъриф итүдән гаҗиз булганымны игътираф итәм [1]. Карап йөри торгач, көтебханәгә килеп чыктык. Бу көтебханә кадәр тыныч, күнелле бер көтебханә[не] тасвир итү бик читен. Мин Шәрекъ падишаһлары сарайларыны күргәнем юк. Бу сарайда бу кадәр күп китап булуы Англия падишаһларының мәгълүмат һәвәслекләрене күрсәтә иде. Китаплар арасында әллә никадәр ислам хоруфаты [2] илән язылган китаплар күрдем. Бунлар арасында әксәриясе [3] Һиндстан лисаны урду лисанында булырга кирәк. Бер дә карап, ни гарәп вә ни фарсы — белгән кәлимәләргә очрамадым. Күрсәтеп йөрүчеләр сарайлар нәзарияте министры вә аның мөгавиннәре иде. Карап йөреп арыгач, бер залга килеп чыктык. Бунда ике аерым өстәлгә чәй хәзерләнгән иде. Алдымызда — сарайның берничә чакырымнар сузылган парк вә бакчасы, зур юллар, фәүкыльгадә зур фонтаннар, чирәмлекләр, зур вә карт агачлар вә ниһайәтсез чәчәкләр күренә иде.

Сарайның тышындагы тәэсире зурлык вә мәһабәтлек булган кеби, эчендәге заллар да, бу чәй эчкән залымыздан күренгән бакчалар да һәм хәйрәтемезне муҗиб [4] булган ише зурлык иде.

Зур бер сарай, күз алдымызда зур «җәннәт» бакчасы, әле генә күреп йөргән чиксез бүлмәләрдәге чиксез алтын-көмеш, чиксез шкафлардагы кыйммәтле надир [5] чынаяк-касәләр, ниһайәтсез рәсемнәр, бу зур вә гайн заманда эченнән чыгасы килмәслек көтебханә инсанны төрле уйларга төшерә иде. «Әлфе ләйлә вә ләйлә» [6] хикәясене укыган вакытта башымнан үткән хыялый мәнзарә вә сарайлар хәтеремә төшә иде. «Әлфе ләйлә»дәге сарайлар хыял гына, хәкыйкатькә мөмкин түгел дип уйланадыр. Хәлбуки, монда хәкыйкатьтә бер «Әлфе ләйлә»дәге сарайлардан, бакчалардан дәхи дә зуррак бер сарай дия идем. Ник бу сарай мине артык бер һәйаҗанга китерми [7] дия идем. Ләкин, белмим, никтер, хыялдагыннан артык бу хәкыйкый сарай кувәи хыялиямне яндырмый иде, рухымны очырмый иде. Бу ник болай дип уйлый идем. Буңа бер ачык җавап таба алмасам да, кувәи хыялиянең очуына мәдәнияте хазирә [8] мохите мөсагыйд [9] түгелдер шикелле тоела иде.

Гүя, тимер юл, трамвайлар, заводлардан мөрәккәб[10] мәдәният эчендә бу сарай бер тәнакыз[11] кеби тоела иде.

Англиядә бу хәл, ягъни иң яңа мәдәният әхвале иң искедән калма коруне вөстага лаек осуле хәят вә шәүкәт илән катыш булуы Англия мәдәниятенең һәр җәһәтендә күренәдер.

Мисаллар: парламентта рабочийлардан депутатлар бар. Бу депутатлар партия тәшкил итәләр, хөкүмәтне теләсә ничек тәнкыйть итәләр, хөкүмәт бөтен запросларына җавап бирергә мәҗбүрдер. Бу җәһәттән караганда Англия нә кадәр демократик дияргә мөмкин. Шул ук парламентның Югары палатасында һич сайланмаган — нәселдән нәселгә палата әгъзасы булып килгән лордлар бар. Бу ике хәл бергә җыеладыр. Шул ук гамәлә[12] депутаты лордларның бу имтиязларына[13] каршы каты кычкырмый.

Икенче мисал: Һайд Парк. Буның бер башы — бөтен Лондон байларының мәйдане ифтихарыдыр[14]. Икенче тарафы — бөтен фәкыйрьләрнең, бөтен бичараларның куаныч җиредер.

Янә бер мисал: авылларда бер зур завод; бу заводта рабочийлар собраниеләр ясыйлар, мөсавате камиләдән[15] бәхәс итәләр. Шул заводтан ерак түгел бер лордның имениесе. Лорд имениесендә бер коруне вөста[16] патшасы кеби яшидер. Буңа һичкем ачуланмый, эче пошмый, шул лордны күргәндә бөтен рабочий тәгъзыйм илән сәлам бирәдер. Вә һакәза[17]...

---

[1] *Игътираф итү* — кимчелекне тану.
[2] *Ислам хоруфаты* — ислам (гарәп) хәрефләре.
[3] *Әксәриясе* — күпчелеге, иң күбе.
[4] *Хәйрәтемезне муҗиб* — сокlануыбызга сәбәп.
[5] *Надир* — сирәк очрый торган.
[6] *«Әлфе ләйлә вә ләйлә»* — «Мең дә бер кичә».
[7] *Һәйаҗанга китерми* — дулкынландырмый.
[8] *Мәдәнияте хазирә* — хәзерге мәдәният.
[9] *Мөсагыйд* — мөмкинлек бирүче.
[10] *Мөрәккәб* — кушылган, бергә җыелган.
[11] *Тәнакыз кеби* — каршы булып, ярашмый кебек.
[12] *Гамәлә* — эшче.
[13] *Имтияз* — өстенлек.
[14] *Мәйдане ифтихар* — горурлык, мактаныч мәйданы.
[15] *Мөсавате камилә* — тулы-камил тигезлек.
[16] *Коруне вөста* — Урта гасыр.
[17] *Вә һакәза* — һәм башкалар.

Виндзордан кайткач, кич, Англиягә сәяхәтемезнең мөдәббирләреннән профессор Перс (Mister Pares) шәрәфенә Лондонның зур рестораннарының берендә мәҗлес ясалган иде, шунда бардык. Мәҗлес күркәм булды. Байтак нотыклар сөйләнде. Миңа да сөйләргә туры килде. Үз кешеләремездән генә мөрәккәб булганга, рәсмият юк иде. Шуның өчен озын нотыклар сөйләргә лязем юк иде. Депутатлардан башка, дамалардан Звегинцев хатыны (мадам Звегинцева), Хомяков кызы (М. Н. Хомякова), профессор Перснең хатыны (Madame Pares) бар иде.

Мин нотыгымда дидем:

— Бу мәҗлес профессор шәрәфенә булганга, кешенең үз алдында мактау читен булса да, бер-ике сүз әйтми мөмкин түгел. Профессорга үзене генә мактаганны ишетү агыр булмасын өчен, мин бу мәдехкә иптәшләремне һәм катыштырырга телимен. Мактаганда һәркем үз ноктаи нәзарыннан мактыйдыр. Шуның өчен минем мактау тарафы миннән алдан сөйләгән иптәшләрем мәдехләре кадәр үк фәсыйх [1] булмавы өчен гафу үтенәм. Фәсахәт җәһәтеннән әүвәлге нотыклардан түбән икәнене алдан ук әйтеп куярга бер дә курыкмаган шикелле, сөйләгән сүзләрем саф, рыясыз булу җәһәтеннән әүвәлге сөйләгән иптәшләрем сүзләреннән бер дә калышмас диярге дә җәсарәт [2] итәм.

Мин, иң әүвәл, профессор Перс рус булмаса да, Русия әхваленә бер рус кадәр вакыйф [3] булуына тәгаҗҗеб итдем. Профессор бу сәяхәтне тәшкил итә башлагач ук, Англиядә рус мәҗлесе мәбгусаныннан Англиягә кунак барганда бунлар арасында мөселман да булырга тиешдер: чөнки Русиядә руслардан кала мәмләкәтнең иң күп әһалисе булган мөселманнарга дахили хәятта урын вә әһәмият биру иҗабәте халь вә икътизаи гадәләт [4] булган кеби, харижда һәм Русия вәкилләре күренгәндә, арада Русиядә мөселманнарның барлыгыны дал [5] вә шаһид булачак мөселман вәкилнең булуы ляземдер — бу хәкыйкатьне профессор Перснең аңлавы вә фәгаләгә чыгаруга ярдәме җәһәтеннән һәм тәбрик вә тәшәккер итәсем килә. Әлбәттә, бу фикернең вөҗүдкә чыгуы профессордан башка аркадашларымның һәм мөселманнарга хөсне тәвәҗҗеһләре [6] вә мөселманнарның ишгаль итәргә тиеш булган мәукыйфләрене [7] аңлаганлыклары аркасында булганга, аркадашларымны да тәбрик итәм һәм аларга тәшәккер итәм.

Юлдашлар, без Русиядә яңа бер хәят юлының башындамыз. Кирәк партияләр, кирәк Русиядә мәүҗүд милләтләр арасында яңа мөнәсәбәтләр ясала торган замандыр. Буннан соң сәяси хаталар булса, бюрократия өстенә аудару мөмкин булмас. Мәсъүлият [8] милләтләрнең үз өстенә төшәчәктер. Хосусән бу җәһәттән әксәрият булган рус гонсырының [9] әфгаль[10] вә хәрәкәте мөһимдер. Русиянең якты истикъбалене теләмәгән бер вәкил мәүҗүд булуыны мөхаль[11] саныймын. Русиянең якты, солыхлы истикъбалене теләүче вәкилләр тарихи хаталардан сакланган кеби, мөмкин булган кадәр киләчәктә милләтләр арасында суыклык ясаячак эшләрдән качарга тиешмез.

Әгәр мөселманнар бу сәяхәткә катышудан калдырылган булса иде, бу бик зур тарихи хата булган булыр иде дип уйлыйм. Бинаән галәһи бу кеби хата вә тәәссефле хәл булмаганына һәм мөселман булуым, һәм русияле бер гражданин булуым җәһәтеннән шатланам. Әле генә профессор Перснең Русия әхваленә вөкуфене[12] тәбрик вә тәхсин иттем. Хәлбуки, бу тәбригем профессорның үзенә генә кайтып бетә микән? Бу эшнең, бу сәяхәтнең фәгаләгә чыгуына ярдәм иткән профессордан башка бер кеше бар диясем киләдер.

Вакыйган[13], профессор Русиягә килеп, зур бер гайрәт вә җиддият илән бу сәяхәтне оештырып йөргәндә, мин профессорның гайрәтенә, сәбатына[14] хәйран калган идем.

---

[1] *Фәсыйх* — матур, килешле.
[2] *Җәсарәт* — кыюлык, батырчылык.
[3] *Вакыйф* — аңлаучы, эшнең төбенә төшүче.
[4] *Иҗабәте халь вә икътизаи гадәләт* — уңай хәл һәм гаделлек таләбе.
[5] *Дал* — дәлилләүче.
[6] *Хөсне тәвәҗҗеһләре* — яхшы караш-илтифатлары.
[7] *Ишгаль итәргә тиеш... мәукыйфләрене* — шөгыльләнергә тиеш эшләрне, урыннарны.
[8] *Мәсъүлият* — җаваплылык.
[9] *Гонсыр* — өлеш, токым.
[10] *Әфгаль* — эш-шөгыль.
[11] *Мөхаль* — мөмкин булмаган эш-хәл.
[12] *Әхваленә вөкуфене* — хәлләренә тукталуын.
[13] *Вакыйган* — чыннан да.
[14] *Сәбатына* — ныклыгына.

Англия халкында гайрәт, сәбат вә җиддият гам [1] сыйфатлары булса да, профессорның бу фәгалияте [2] мине хәкыйкатән тәгаҗҗеб иттерә иде. Профессорны бу кадәр фәгалияткә кем сәвекъ итәдер, профессор вә бу кадәр гайрәтне кайсы мәнбәгъдән [3] аладыр дия идем. Бунын сәбәбене мин Англиягә килеп җиткәч кенә азрак аңладым: профессор Персне фәгалияткә сәвекъ идән сәбәпләрдән бере — Сезсеңез, мадам; профессорның гайрәт вә сәбатының бер мәнбәгы, һич шөбһәсез, Сезсеңез, мадам. Профессорның Сезнең шикелле бер рәфикаи хәят вә мөгавинәсе [4] булгач, аның фәгалияте вә аның тәшәббескярлеге [5] минем тәгаҗҗебемне муҗиб [6] булмый. Бу миңа табигый хәл кеби күренәдер. Мадам, Сезне алдыңызда мәдех итәргә мәҗбүр булуым өчен гафуыңызны үтенәм, бу мәҗлеснең вә бу нотыкларның сәбәбе Сезнең иреңезнең кустәрдеге муаффәкыятьле тәшәббестер [7]. Вә бу муаффәкыятьләрнең иң зур тәрәге Сезсеңез; бинаән галәйһи минем бу нотыгыма сәбәп тә Сезсеңез! Әгәр алдыңызда мәдех өчен мин гаепле исәм, бунын гаебе миңа гына төшми, Сезгә дә кайтадыр. Бу кадәхемне иң әүвәл, мадам, Сезгә, буннан соң профессорга вә ахырдан бөтен аркадашларымның шәрәфенә күтәрәм.

## XXII

### Якшәнбә көн чиркәүләрдә вәгазьләр. Фәкыйрь гаиләләрне зиярәт. Һайд Паркта, ачык һавада җәмгыятьләр

Бүген якшәнбә көн Лондонның зур чиркәүләреннән берендә вәгазь сөйләүче поп вәгазендә Думаны катыштырып сөйләячәк иде. Мин чиркәүгә бармадым. Бүген бөтен көн иптәшләремнән аерылдым. Буны — мөселман булганга чиркәүләрдә вәгазьләр тыңламавымны һәркем аңлый иде. Буңа кадәр мин күп вакыт иптәшләремнән аерылып, Лондон хәятының икенче тарафыны күрәсем килә иде. Лондонның аристократлык, байлык дөньясыны гына күрү белән канәгатьләнмәй, простой халык тормышыны да, бичаралар, фәкыйрьләр дөньясыны да күрәсем килә иде. Әгәр Лондон хәятының бу тарафына күз салмай китсәм, мәхзүн [8] булачак, бер нәүгъ вөҗданән мөгаззәб [9] булачак идем.

Иң әүвәл, ике көпчәкле бер арба яллап, Лондонның иң фәкыйрь мәхәлләләре булган җир — Вай-Чапел дигән җиргә алып барырга куштым. Лондон хакында язылган һәр китапта бу фәкыйрь мәхәлләләр хакында берничә мәгълүмат булмый калмыйдыр. Хосусән бу мәхәллә хакында Англиянең мәшһүр әдипләреннән Диккенс дигән әдипнең «Оливер Твист» дигән хикәясендә бу мәхәллә хәяты гаять яхшы тасвир ителгәндер.

Искә төшкәндә әйтим, дөньяда мин белгән язучылар арасында Диккенс иң яхшы бәни адәм дусты язучылардандыр. Укып әхлак вә яхшылыгыны арттырасы килгән кешегә мин бу язучының әсәрләрене димләсем киләдер. Руссо, Толстой, Диккенс, Виктор Гюго... Хәкыйкатән, мин бу дүрт кеше кадәр бәни адәмгә тирән мәхәббәт, инсаннарның җафа вә хафаларыны вә изтыйрабларыны[10] чыннан кызганып язган кеше белмим. Бу дүрт кешенең берәр әсәрене укып бетергәндә инсан мотлакан үзендә бер инкыйлаб, рухани хис итәдер.

Нә исә, Вай-Чапелгә киттем. Бу җирләргә ялгыз барырга кушмыйлар. Хәзер, диләр, жуликлар, фахишәләр күп, талыйлар, диләр. Мин, алай булса да, ялгыз барырга уйладым. Күрсәтеп йөрүчеләрнең бәйанатыннан туйган идем. Үзем генә, кеше мөдахәләсеннән[11] башка күрәсем килә иде. Ул кадәр талыйлар дигәнгә дә ышанмый идем. Бу бер куркак буржуалар сүзедер кеби тоела иде. Алай булса да, янымда күп акча алмай, простой киемнәремне киеп киттем. Күчер: «Барып җиттек»,— диде.

---

[1] *Гам* — гомум (халык).
[2] *Фәгалият* — эшлеклелек.
[3] *Мәнбәгъ* — чыганак.
[4] *Рәфикаи хәят вә мөгавинәсе* — тормыш иптәше һәм ярдәмчесе.
[5] *Тәшәббескярлек* — тапкыр, инициативалы булу.
[6] *Тәгаҗҗебемне муҗиб* — гаҗәпләнүемә сәбәп.
[7] *Муаффәкыятьле тәшәббес* — уңышлы инициатива.
[8] *Мәхзүн* — көенечле.
[9] *Мөгаззәб* — газапланучы.
[10] *Изтыйраб* — борчылу-көенү.
[11] *Мөдахәлә* — катышу, арага керү.

Бер дә — барышлый да, барып житкәч тә — мәхәлләләрнең фәкыйрь булганы тиз генә беленмидер, чөнки арбачы зур урамнардан алып барадыр. Планнан карадым: «Барып життек» дигән жире Вай-Чапел исемендә бер зур урам икән. Урам бик үк матур булмаса да, ул кадәр фәкыйрьләргә махсус урын диярлек түгел.

Вак мәхәллә урамнарына керергә кирәк дип уйладым: арбачыга акча түләдем дә, җәяү, вак урамнарга кереп киттем. Бу урамнар көпә-көндез дә хәтәр дигәнгә азрак шикләнә идем. Бәреп җыгарлар кеби була иде. Шуның өчен батыр булып күренергә тырыша идем. Вак урамнарның кая барып чыгачагыны белмәсәм дә, туп-туры каушамый барган була идем.

Бу вак урамнар хәкыйкатән пычрак. Тәрәзәләр тузан белән капланган, йортларның кәрә торган җирләре кечкенә, караңгы, шакшы; кайсы урамнарда һич якты юк. Ике тау арасында кеби, ике араба сыймаслык җирләр бар. Урамнарда кеше аз иде. Бу вак урамнарда эчкеханәләр — кабаклар тулы иде. Бүген якшәнбә булганга, һәрбере ябык иде. Бер җирдә тар урам барып туктады. Кире әйләнеп чыгарга тугъры килде. Бу урам кадәр эссе, сасы урам күрмәдем. Гомуми сасылыктан башка бер махсус сасы, кызган май сипкән вә суган исләре килә иде. Һич бу урамнарга кояш керә алу ихтималы юк иде. Бүген якшәнбә булуына тәэссеф иттем. Кабак вә эчкеханәләр ябык иде. Бундагы сәфаләт вә рәзаләтләрне[1] күрә алмадым. Гади көннәрдә бу фәкыйрь кабаклардагы рәзаләт-сәфаләт, исереклекләр, сугышу-үлтерешүләр тәгърифтән хариҗ имеш.

Лондон эшчеләре арасында эчү-исереклеккә бирелү бик мәгъруф, ди. Якшәнбә булмаган көннәрдә монда урамнарга политсә кешеләре дә ялгыз керергә куркалар имеш. Исерекләр, рәзил фахишәләр кабак эчләрендә генә булмый, бундый вак урамнарда һәм тулып-быкырдап яталар имеш. Ләкин бүген, сасылыктан башка, бу хәлләр күренми иде. Кабаклар ябык. Гамәлә чиркәүләрдә булырга охшый иде. Күргән мәшһүдәтем[2] арасында артык тәэсир итәрлек нәрсәләр булмаса да, мин Вай-Чапелнең дәһшәтләрене бу хакта укыган хикәяләрем илән тасвир итә ала идем. Бу мәшъүм[3] урамнар кешесез күенчә бу кадәр куркыныч булса, исерек вә бичара фахишәләр илән тулганда тагы да мөдһиш булачагы шөбһәсез иде.

Бу рәвештә бер өч чирек сәгать чамасында йөргәч, бер зур урамга килеп чыктым. Иң элек күргән арабачыны яллап, яһүдиләр мәхәлләсеннән узып, Лондон пристаненә алып барырга куштым (ягъни язган адресны күрсәттем). Яһүдиләр тора торган җирләр әле генә күргән урамнар кеби кабәхәт, көнә сасы җирләр икәнс күренеп кала иде. Ләкин арабачы вак урамнарга кермәде. Мәгаттәәссеф, бу мәхәлләләрнең чын хәятыны күреп булмады. Мин бу яһүди мәхәлләләренең фәкыйрьлегене, бундагы дәһшәтле ачлык вә ялангачлыкларны бу җирдә яшәгән бер яһүди агызыннан ишеткәнем бар иде. Ләкин бу яһүди тасвир иткән хәлләрне күзем илән күрә алмадым. Лондон фәкыйрьләре кадәр фәкыйрь дөньяның һичбер җирендә юк имеш. Буның сәбәбе бер җәһәттән күп фәкыйрьләрнең эш таба алмавы булса да, иң зур сәбәбе инглиз гамәләсенең булган акчасыны тиз сарыф итеп бетерергә яратуыдыр. Англия эшчеләре арасында эчү бик шаигъ[4].

Инглизләрнең һәр табәкасында эчәргә ярату бар. Эчкән нәрсәләре французлар кеби вино (шәраб) түгел. Бик куәтле аракылар. Инглизләр куәтле аракыларны яраталар. Бөтен Англиядә исерткеч эчмәгән кеше аз имеш. Инглизләрнең сыралары да бүтән мәмләкәтләге кеби куәтсез сыралар түгел, бәлки әллә нинди спирт катыштырылган «Эль» вә «Стаувт» дигән сыралар. Бу сыра өйрәнмәгән кешене бер стакан илән хәлдән чыгара имеш.

Лондондагы фәкыйрьләр бөтен Англияне уйга калдырган бер мәсьәләдер. Бүтән зур шәһәрләрдә һәм һәрвакыт бичаралар булса да, бундагы кадәр даими сурәттә берничә йөз мең кешенең бу кадәр сасып-бызырдап яткан җирләре юк. Бу урамнарга охшашлы җирләр нә безнең Петербургта, нә Парижда бар. Инглиз халкы вә хөкүмәте акрынлап бу хәлне бетерергә, бу бичара вә фөкарәгә бераз ярдәм итәргә тырышадыр. Буңа Лондонда булган төрле җәмгыяте хәйрияләр шаһидтер. Бөтен Лондонда 2000 кадәр җәмгыяте хәйрия бар имеш.

Җәмгыяте хәйриядән морадым: төрле дарелгаҗизиннәр[5], кунып чыга торган йортлар, хәстәханәләр, ятимханәләр вә һакәза... Бу тәэсисате хәйриянең[6]

---

[1] *Сәфаләт вә рәзаләтләрне* — хурлык, түбәнлекләрне.
[2] *Мәшһүдәт* — күздән кичерелгән нәрсәләр.
[3] *Мәшъүк* — шомлы.
[4] *Шаигъ* — киң мәгълүм.
[5] *Дарелгаҗизин* — гаҗизләр йорты.
[6] *Тәэсисате хәйрия* — төзелгән ярдәм йортлары.

барысының сәнәви доходы 5.000.000 фунт стерлинг (ягъни илле миллион рубль кадәр) имеш. Буны Лондон кешеләренә бүлгән вакытта, һәр Лондон кешесе ун сум чамасында фәкыйрьләр файдасына сарыф иткән буладыр. Әлбәттә, буны әйтүгә дә хаҗәт юк, байлар бик күп ярдәм итә, фәкыйрьләр бер дә бирмидер. Буннан күренә: Лондон әһалисе фәкыйрьләрнең хәлене уйламый түгел. Ләкин нәтиҗәсендә генә әллә нә кадәр халык сәфаләт пычрагында ауныйдыр. Якшәнбә көн чиркәүләрдә җәмгыяте хәйрия файдасына җыйган акча 400.000 сум кадәр була имеш.

Буннан башка, фәкыйрьләргә ярдәм җәмгыятьләренә мәнсүб[1] дамалар вә башка кешеләр урамнарда шинбә көн акча җыялар имеш. Буннан килгән доход һәм 15.000 фунт стерлинг, ягъни 150 мең сум чамасында була имеш.

Бу фәкыйрьлек мәркәзеннән узып, эш-гамәл мәркәзе булган мәшһүр Лондон пристанена бардым. Якшәнбә булганга, пристаньдә һәм эш юк иде. Мәгаттәәсеф, бундагы чиксез, ниһайәтсез складлардагы малларны тәгъриф итә алмыйм. Кереп карый алмадым. Ләкин бу Лондон пристаненең, докларының зурлыгы ниһайәтсез икәнене бер-ике кәлимә илән белгертәсем килә. Махсус ясалган пристань җиренә дүрт зур караб килеп туктарга сыядыр.

Буннан башка әллә нә кадәр вак караблар, тулы доклар янындагы магазин вә складларда 220.000 тонна кадәр мал вә товарга җир хәзер имеш.

Тәмәкегә махсус складлар гына ике дисәтинәгә якын җир ишгаль итәдер. Бу пристаньнәрдә эш көннәрендә 30.000 кадәр рабочий эшли имеш.

Бу пристаньне идарә итүче компаниянең капиталы йөз утыз миллион чамасында имеш. Буннан Лондон пристанендәге тиҗарәте мал вә сәрвәт хакында бер фикер хасыйл итеп булса кирәк.

Буннан араба алып тугъры Һайд Паркка киттем. Якшәнбә көн Һайд Паркның чирәмлекләрендә, ачык һавада җәмгыятьләр булганыны белә идем. Бу собраниеләрне бер күрәсем бик килә иде.

Һайд Паркка барып җиткәч, арабадан төштем. Чирәмлекләр булган җиргә араба илән кертмиләр. Җәяү киттем. Зур чирәмлек, тигез болын фараз итегез. Барып җиткәндә иң әүвәл бер халык җыелган җиргә туктадым.

Биек бер нәрсәгә менгән бер яшь, арык хатын кычкырып-кычкырып бер нәрсә сөйли иде. Янында бер зур флаг. Бу флагка язылган сүзләренең нә икәнене бөтенләй аңламасам да, сайлаулар, хатыннар-фәлән дигән сүзләрнең мәгънәсене белә идем. Димәк, бу хатын хатыннарның сайлауга катнашуы лязем булуы хакында нотык сөйлидер. Яшь хатын, үзе бик арык, йөзе мәргуб[2], бик димагый[3]; уң кулыны бер дә селкетми, бер кулы зәгыйфь булырга кирәк. Сул кулы илән бәгъзан хәрәкәтләр, жестлар ясыйдыр. Менгән мөнбәре бер простой арба. Арбаның бер тарафына зур киндер җәймәне (брезент) таяклар илән җилкән кеби итеп куйган, таки тавыш бер генә якка китсен.

Хатын бик кызып-кызып сөйли. Тыңлаучылар байтак бар. Әксәрисе простой халыктан, якшәнбә көн ял итеп йөрүче гамәләдән булырга кирәк. Сирәк-сирәк кул да чабалар. Арада буржуалардан, укыган кешеләрдән һәм берничә тыңлаучы бар. Болар ихлас илән тыңламыйлар. Көлебрәк, истиһза итеп торган кеби.

Бу яшь хатынның сүзләрене байтак тыңлап торгач, чирәмлекнең икенче тарафына киттем. Анда янә башка бер халык җыелган җир күрдем. Халык арасында тыгызлана-тыгызлана барып карадым. Монда тагы бер хатын шулай ук арабага менеп баскан, шулай ук кычкырып сөйли. Арабасына шулай ук киндер тартып куйган. Ләкин бу хатын баягысыннан картрак, киемнәре дә баерак, сөйләү формасы әүвәлгедән гайрәтсезрәк күренәдер. Ләкин бунын да кул чабучылары бар. Бер инглиз минем бик дикъкать итеп карап торганымны күрде булырга тиеш, бу хатынның нинди кеше икәнене бәйан итәргә тотынды. Инглизләрнең таләффызы[4] бик читен. Буның өчен бу хатынның фамилиясене хәтердә тота алмадым. Ләкин дворянка икәнене белдем. Инглиз бу хатынның дворянка — принсли булуыны кат-кат әйтте.

Инглизләр дворян булуга фәүкыльгадә әһәмият бирәләр. Лондонга баручылар арасында дворян булмаган без бер-ике генә кеше идек.

Безнең һәрберемезнең тәрҗемәи хәлемез басылып өләшенгән иде. Шуннан минем дворян түгел икәнемне белгәннәр иде. Берничә җирдә сорап йөдәттеләр: «Сез нишләп дворян түгел? — диләр.— Әллә сездә татарларга дворянлыкны бирмиләрме?» — диләр.

[1] *Мәнсүб* — бәйле, мөнәсәбәте булган.
[2] *Мәргуб* — сөйкемле.
[3] *Димагый* — акыллы.
[4] *Таләффыз* — сүз әйтелеше.

— Русиядә нәселгә китә торган дворянлык бик сирәк бирелә,— дидем.— Искедән дворян булып килгән кеше безнең Русия мөселманнары арасында сирәк,— дидем.— Искедән килгән татар мирзалары һәрбере дворян булып тәсдыйк ителмәгән,— дидем.— Юкса безнең Казан мөселманнарының күбесе хан вә мирза нәселеннән,— дидем.

Дама, болай дигәч, бераз җуанды. Юкса сатхи[1] хатын мине ярыйсы гына кеше, дворян түгел дип бик кызгана иде.

Бу икенче араба өстендәге хатын әтрафындагы кешеләр баягыннан артыграк иде. Буның сөйләгән сүзләре дәхи дә җитди булырга кирәк, тыңлаучылар арасында истиһза илән көлүче юк кебидер. Бәлки буңа сәбәп бу хатынның дворянка — принсли булуыдыр. Аңладым, бу хатын хатыннарның ирләр илә хокукта мөсави[2] булуы хакында сөйлидер. Иртәгә Милләт мәҗлесенә җыелып барып, депутатларга мөсавате хокук законы ясарга кушыйк, көчлик, ди. Суффражисткалыкка дәгъва итә.

Суффражисткаларга бу ике хатынның вәгазьләре тәэсирсез калмады. Иртәгесен без Ливерпульгә киткәч, әллә ничә мең хатын җыелып килеп, Милләт мәҗлесенә керергә теләгәннәр дә, полисә кешеләре җибәрмәгәч, полисә илән сугышып керергә тырышканнар. Максудлары: кереп, депутатлар илән кычкырышып, мөсавәте хокук законы кирәклеге хакында сөйләшү вә петиция бирү булган икән.

Полисә әллә ни кадәрсене тотып, берничә сәгать ябып та тоткан.

Без бу вакыйга вакытында Лондонда түгел идек, Ливерпуль вә Шотландиягә киткән идек. Ләкин безнең иптәшләрдән Маклаков шул эшләрне күрер өчен Лондонда калган иде. Буның тәфсыйлатене ахырдан сүзгә оста Маклаков бик көлдереп сөйләде.

Хатын сөйләүчеләрдән башка Һайд Парк чирәмлегендә берничә дини вәгазь сөйләүчеләр дә бар иде. Кайсы Инҗилдән вәгазь сөйли. Кайсы үзенә бер кечкенә мәзһәб чыгарган, шуны аңлата. Һәрберенең үзенә җитәрлек тыңлаучысы бар, кайсы көлә, кайсы кабул итә.

Хуләсән, кямил хөррияте иҗтимагъ вә кямил хөррияте кәлям[3]. Теләсәң нә сөйлә, бары сөйләгән сүзләрең тәртипсезлеккә сәбәп булмасын!

## XXIII

## Англиядә сигезенче көн. Ливерпульгә сәяхәт. Анда безгә бирелгән мәҗлес вә нотыклар. Минем сөйләгән сүзләрем

Бүген иртә торып Ливерпульгә киттек. Ливерпуль шәһәре Лондоннан дүрт-биш сәгатьлек бер җирдер. Комитет тарафыннан безгә махсус бик уңгай вагоннар хәзерләнгән иде. Вагон махсус булса да, безгә аерым билетләр бастырганнар иде. Билетнең өстенә «Дума сәяхәте» дип язылган иде. Һәм поездда безгә генә махсус йимәк салоны да бар иде. Өйлә тәгамлары ашап, чәйләр эчеп, дүрт-биш сәгать бик тиз үтте, тоелмый да калды.

Ливерпульдә без һәммәбез бер җиргә, номерга төшмәй, һәрберемез аерым-аерым махсус йорт сахибләренә кунакка төшәчәк идек. Мин граф Бобринский илән икәү Боус (Mr. Boouth) дигән диңгез пароходлары хуҗасына төшәчәк идек.

Ливерпуль шәһәренә сәгать дүрт ярымнарда килеп җиттек. Вокзалга шәһәрнең головасы вә берничә гласный безне каршы алырга төшкән иде. Аннан башка фотографлар, газитәчеләр вә башка карарга килгән публика тулы иде. Безнең йорт хуҗамыз үзенең автомобиле илән, хатыны, үзе бергә каршы алырга төшкәннәр. Зур автомобильгә нәрсәләремезне куеп һәм үземез утырып киттек.

Боус үзе дә, хатыны да ярыйсы французча сөйләшәләр. Бусы минем өчен бик уңгай булды. Боус безне туры өенә алып бармады. Әүвәл диңгез пароходлары пристанена (портка) алып барып, үзенең бер пароходыны күрсәтәчәк булды. Портка барып җитеп, фәүкыльгадә бер зур пароходка алып керделәр. Пароход ярты сәгатьтән Бразилиягә китәчәк иде. Мин бу пароходның зурлыгыны яхшылап тәгъриф итә алмыйм. Әгәр хәтерем хыянәт итмәсә,

---

[1] *Сатхи* — беркатлы.
[2] *Мөсави* — тигез (хокуклы).
[3] *Кямил хөррияте иҗтимагъ вә кямил хөррияте кәлям* — җыелышлар ясарга һәм сүз сөйләргә тулы ирек.

пароходның озынлыгы җиде йөз фут чамасында, киңлеге 80 фут чамасында шикелле. Бу пароход түгел — бер дөнья, бер шәһәр. Пароходның йимәк бүлмәләре, язу бүлмәләре, уен бүлмәләре һәрбере аерым, һәрбере бик зур, һәрбере матур, чиста вә пакь. Бары мөһаҗирләргә махсус класс кына шакшырак. Америкага күчүче мөһаҗирләрне бу кадәр хайван кеби куруларенә эч пошарлык.

Пароходның буфет булган җиренә алып кереп чәй эчерделәр. Чәйне тиз-тиз генә эчтек тә, пароходны карарга тотындык. Пароходны күрсәтеп йөрүче хуҗаның үзе булганга, һәр җирдә гаять зур бер хөрмәт илән каршы алалар иде.

Пароход кычкырта башлады. Китәргә өч дәкыйка калган диделәр. Китүчеләр палубага чыгып, озатучылар пристаньгә чыгып беткән иде.

Боус әфәнде безгә диде:

— Югарыда берничә күрелмәгән бүлмә калды. Ләкин пароход китәргә өч дәкыйка калды, безгә чыгарга тугъры киләдер.

Бу аккуратностьны (тәкыйдьне) мин гаять тәхсин иттем. Бу кеше бу пароходның сахибе мотлакы[1], әгәр ул теләсә, пароход бер-ике дәкыйка түгел, берәр сәгать соңга калып китәчәк. Алай булса да, хуҗа ясалган расписаниегә тәгъзыйм итәдер, үзенең бер капризы өчен ярты гына дәкыйкагә булсын, кагыйдәгә хилаф эш күрәсе килмидер. Менә бу канун вә кагыйдәгә хөрмәт яурупалыларның һәрберендә гомуми бер сыйфаттыр. Буңа кайчан аккуратность, кайчан дисциплиналы булу диләр. Асылда һәрбере тәкърибән[2] бер гайн сыйфат мәмдухдыр[3]. «Вакытлы файда вә кәеф өчен кагыйдә вә мәслихәте гомумиягә хилаф хәрәкәт итмәү»дер.

Менә бу сыйфат, дисциплина, мәгаттәәссеф, безнең Русия кешеләрендә юк, һәркем үзенең ань кыйләтесе[4], бер минутлык капризы өчен кагыйдәгә, мәслихәте гомумиягә хилаф хәрәкәт итәргә хәзердер һәм итәдер. Безнең Русия халкының артта булуының нәтиҗәләренең берсе, яхуд хәтта сәбәпләренең берсе бу кагыйдәгә гадәм итагатьтер[5] дип уйлаучылар бар. Бу, русча әйткәндә, отсутствие дисциплины буладыр.

Бу урында бер рус бае, яхуд хосусән бер татар бае булса иде, кунакларына пароходыны күрсәтеп йөргәндә пароход китә башласа, һич шөбһәсез, капитанны чакырып, көтәргә кушар иде. Ләкин мистер Боус алай итмәде. Үзенең хуҗа икәнене аз гына да сиздермәде, тиз-тиз генә кунаклары илән чыкты.

Пароходтан чыгып, шулук автомобильләре илән безне Ливерпульнең тышындагы дачасына алып китте. Юлда пароходлардан бәхәс иттек. Боус аганың бу зур пароходы шикелле җиде пароходы бар имеш. Бу пароходлар тәкърибән безнең рус акчасы илән хисаплаганда унбер-унике миллион тора имеш. Боус аганың зур пароходларыннан башка егермеләп вак пароходы бар имеш. Болар да берничә миллион тора торгандыр.

Дачага барып җиттек. Дача бик матур. Тәмиз, пакь, ләкин бер дә әллә нинди кылангычлыклар юк. Безнең капиталы ярты миллионга да барып җитмәгән, аның да үзенеке булуы шөбһәле булган татар байларының дачасыннан артык җире юк. Бәлки бу мөсриф[6] татар баеның дачасындагы исрафлар бунда юк. Һәр шәйдә простойлык; әллә нинди фонтаннар әллә ничә түгел, әллә ничә төрле породадан этләр дә юк. Петербургтан (Лондоннан) китергән поварлар да юк. Бу миллионнар үзе тапмаган бер рус, яхуд татар яшь баенда булса иде, ниләр кыланыр иде? Ләкин безнең Русиядә дә малны үзе тапкан кешеләр исраф итмәй, угыллар, икенче буыннар, даимән дияргә мөмкин, исрафчы буладыр. Хәлбуки, мәдәниятле инглизләрдә икенче буын да исраф итмәй, арттырырга гына тырыша булырга кирәк. Боус карт кеше түгел, утыз сигезләрдә бер кеше. Малны, шөбһәсез, үзе табып өлгермәгән, әлбәттә атасыннан калган. Ләкин егет малны саклый белгәнгә охшыйдыр.

Дачага барып җиткәч, тиз генә җуынып, сакал-мыекларны тәртипкә куеп, ак күлмәк вә фракларымызны киеп, мәҗлескә барырга хәзерләндек. Бу мәҗлесне Ливерпуль шәһәренең төҗҗар[7] җәмгыяте, сәүдәгәрләр палатасы ясый иде. Мәҗлес сәгать җиде ярымда булачак иде. Йорт хуҗамыз Боус та бу шәһәрнең зур байларыннан булганга, ул да чакырылган иде. Бәлки үзе бу эшне оештыручылардан берéдер.

---

[1] *Сахибе мотлакы* — тулы хуҗасы.
[2] *Тәкърибән* — якынча.
[3] *Гайн сыйфат мәмдухдыр* — макталуга лаек шул сыйфаттыр.
[4] *Ань кыйләтесе* — кыска вакытлы, аз нәрсәсе.
[5] *Гадәм итагать* — итагать булмау.
[6] *Мөсриф* — әрәм-шәрәм итүче.
[7] *Төҗҗар* — сәүдәгәрләр.

Мәҗлес Аделфи — Adelphi Hotel — дигән бер гостинсаның зур залында хәзерләнгән иде. Гостинса зур. Зал һәм зур; бик матур итеп өстәлләр хәзерләнгән. Зал илән янәшә бер бүлмәдә хатын музыка уйнаучылардан мөрәккәб бер оркестр бар иде. Һәркем кайда утырасы алдан тәгаенләп куелган иде. Залга кергәндә кем кая утырасын күрсәткән баскан кәгазьне өләшәләр иде. Кәгазь буенча мин дә үземнең урынымны таптым. Музыка булуына минем бик кәефем килде. Бунын сәбәбе шул: мин бу мәҗлеснең ахырында нотык сөйләячәк идем. Нотык сөйләр өчен мәҗлес кешеләренең кәефе яхшы булганы кирәк буладыр. Кәефе яхшы булган халык алдында нотык сөйләү күңеллерәктер. Халык тыңлаучан була. Әйткән сүзләренә әһәмият бирүчән була. Музыка һәрвакыт яхшы кешеләрнең кәефене китерүгә тәҗрибә ителгәндер.

Бу мәҗлестә без дүрт кеше нотык сөйләячәк идек: Шидловский, мин, Лерхе вә Милюков, һәм шул язылган тәртиптә.

Инде бу урында бу нотык сөйләүләрнең ничек алдан тәгаен ителүе хакында бер-ике сүз әйтим.

Лондонга барган көннәрдә үк мөдәббирләр һәр каюымызны җыеп, нинди зур мәҗлесләр буласыны безгә бәян иттеләр. Һәр каюысында берничә кешегә нотык сөйләү лязем булачагыны аңлаттылар. Шуннан соң кемнәрнең нотык сөйләргә теләгәнене сорадылар. Арадан байтак кеше һичбер төрле нотык сөйләргә катышасы килмәгәнлекләрене белдерделәр. Сөйләве лязем булган яки сөйләргә ирадәсе[1] булган кешеләр унберләп булды: Хомяков, Гучков, Милюков, Ефремов, Шидловский, Лерхе, Звегинцев, Бобринский, Стахович, граф Патоцкий, Максудов. Сөйләргә теләгән кешеләр мәгълүм булгач, кем кайда сөйләүне тәгаен итүне мөдирләргә тапшырдылар.

Мөдирләр, бер сәгать киңәшеп, һәркем өчен сөйләү мәхәлләрене[2] тәгаен иттеләр. Башкалар арасында миннән дә сорадылар:

— Сезгә Ливерпуль шәһәрендә төҗҗарлар тарафыннан ясалган мәҗлестә сөйләргә яки Эдинбург шәһәрендә шәһәр управасы ясаячак мәҗлестә сөйләргә муафикъ күрдек, кайсыны тәрҗих итәсез[3]? — диделәр.

Мин тиз генә Ливерпульдә сөйләүне тәрҗих иттем. Бунын сәбәбе шул: Ливерпуль шәһәре Англиянең тәҗарәт җәһәтеннән бик мөһим шәһәредер. Ливерпуль байлары Англиянең хәятында мөһим бер роль уйныйлар. Бу шәһәр Англиянең бер Москвасыдыр. Аннан башка, бу Ливерпуль байларының Мисыр вә Һиндстан кеби мөселман булган мәмләкәтләргә мөнәсәбәте бар. Минем сөйләсе сүзләрем дә мөселманнарга хокук вә мөсавәт бирүгә даир булачак иде. Шуның өчен мин Эдинбург шәһәрендә сөйләүдән хәятлы, әһәмиятле Ливерпуль шәһәрендә сөйләүне әүлә[4] күрдем.

Менә нотыклар шушы рәвештә алдан тәгаен ителеп куелды. Миңа башта бу мәҗлестә генә сөйләргә тәгаен ителгән иде. Ләкин буннан башка, ахырында, ике җирдә сөйләргә тугъры килде. Берсе, югарыда укыгансыз, профессор Перс хөрмәтенә бирелгән мәҗлестә. Бу кечерәк бер нотык, бунда кеше аз иде. Һәм сөйләгән сүзләрем хосусыйрак иде. Икенче, матбугат җәмгыяте тарафыннан бирелгән мәҗелестә. Бусы минем занымда[5] әһәмиятсез түгел. Бусы хакында түбәндә бер-ике кәлимә сөйләрем.

Әле хәзергә Ливерпульдә сәүдәгәрләр тарафыннан безгә ясалган мәҗлесне тәгъриф итәргә башлаган идек. Онытмыйк. Шулай, без һәрберемез килеп, урыннарымызны табып җирләштек. Без урыннарга утырып беткәч үк музыка уйнарга тотынды.

Мәҗлес башлангач ук Англия композиторларыннан Кусыйк дигән кешенең «Гладиаторлар дөхуле»[6] дигән маршыны уйнадылар. Бу җиңел, күңелле, шатлыклы бер көйдер. Бу көй илән башланган мәҗлеснең күңелле булачагы бәдиһи[7] иде. Мин һаман, ашый-ашый, сөйләячәк фикерләремне уйлый идем. Мөселманнарның хокукта мөсавәте хакында да берәр сүз әйтми каласым килми иде.

Бу хакта бик күп сөйләп, кунакка чакырган кешеләрнең кәефене җибәрүдән һәм ихтираз[8] лязем булганыны сизә идем. Ләкин кунак итәләр дип кенә хәкый-

---

[1] *Ирадә* — омтылыш, теләк.
[2] *Мәхәл* — урын, йорт-җй.
[3] *Тәрҗих иту* — өстен күрү.
[4] *Әүлә* — артыграк, яхшырак.
[5] *Занымда* — уемда.
[6] *Дөхуль* — табыш, керем.
[7] *Бәдиһи* — ап-ачык.
[8] *Ихтираз* — саклану, сак булу.

катьне әйтми калырга да асла разый [1] түгел идем. Рус иптәшләрем дә, минем мөселман мәсьәләсеннән, хокуктан бәхәс итәчәгемне белгәнгә, бераз куркып торалар иде. Инглизләрнең Һиндстан халкына хокук бирмәүләре хакында күбрәк әйтеп җибәреп, алар да уңгайсыз хәлдә калудан куркалар иде. Хөласа [2], минем вазыйфам читен иде. Һәм бүре тук булырга һәм сарыклар исән калырга тиеш иде.

Йимәк тәмам булды. Нәүбәт нотыкларга килеп җитте. Иң әүвәл Англия короле вә безнең падишаһ сыйххәтенә касә күтәрделәр. Буннан соң Ливерпуль шәһәренең шәһәр рәисе лорд Мери бер нотык сөйләде. Буннан соң Шидловский сөйләде. Шидловский инглизчә яхшы сөйләсә дә, нотыгыны язган кәгазьгә карап сөйләде. Минем алай электән язып куйган кәгазем юк иде. Мин кәгазьгә карап сөйли белмим. Болай сөйләгәндә һәрвакыт начар буладыр. Һәрвакыт, сөйләгәндә, кирәк Думада булсын, кирәк башка җирдә, алдан бер план хәзерлим дә, шул план буенча бер кат алдан сөйләп карыйм. Нотык мөһимрәк, озынрак булса, берничә кат сөйләп карыйм.

Шидловский сөйләп бетерде. Өстәлгә таратылган нигъмәтләр тәртибе кәгазенең бер ягында нотыклар тәртибе язылган иде. Бу кәгазь буенча нәүбәт миңа килеп җиткән иде. Мәҗлеснең рәисе торып:

— Нәүбәт мистер Максудов, Думаның мөселман партиясенең әгъзасына,— диде.

Тордым. Мин өстәлнең югары очында бер урында идем. Алдымда ап-ак дәстәрхан [3] илә капланган өстәл стакан вә касәләр илә тулы. Ике өстәлнең ике тарафында йөз илледән артык кара фраклы, ак күлмәкле, сакалсыз-мыексыз инглизләр күзләрене миңа текәләгәннәр иде. Рус вә инглиз флагы матур, янәшә тезелгән иде. Сул тарафта музыка уйнаучы кызлар бүлмәсе күренә иде. Алар да, музыкаларыны туктатып, тыңлыйлар иде.

Сөйләргә башладым. Элекке җөмләләрдән үк кул чабып тәбрик итәргә башладылар. Шуның өчен фикремдә ясалган план буенча сөйлисе сүзләремнең берсен дә төшереп калдырмадым.

— Мөхтәрәм әфәнделәр, сездән сүземне үз лисаныңызда сөйли алмаганымны гафу кыйлуыңызны үтенәм. Мин французча сөйләячәкмен. Лисаныңызны лязем микъдарда белмәвемә тәәссеф итәм. Фәкать бер җуанычым бар: ул хәзер сөйләячәк лисаным сезнең гыйндеңездә мәнфур [4] бер тел булмавыдыр. Миннән мөкаддәм сөйләгән юлдашларым да ифадә кыйлдылар [5] ки, безнең Англиягә килүдән максудымыз китапларда укып тасвир кыйлган Англиямезне хәкыйкый Англиягә татбикъ вә чагыштырудыр.

Без әүвәлдә хыялымыздагы Англияне дә сөя идек. Аның мәдәниятене, сәрвәтене, куәт вә солтанәтене белә идек. Англия хакында һәр фикеремез мөстәхсәнанә [6] иде. Бу сәфәремез саясәндә [7] мәгълүм булды ки, хәкыйкый Англия безнең хыялдагы Англиядән кат-кат артык имеш.

Безләр — шәрекълеләрмез. Шәрекъ халкында хыял куәтле булуы мәшһүр. Алай булса да, безнең куәтле куәи хыялиямез дә Англиянең голү вә кәмалене кәма һуа хакъән [8] тасвир вә тәхлил [9] кыйла алмаган икән.

Англиягә тәслим[10] вә аның голү шәэнене тәсдыйк[11] Русия халкының һәр табәка вә һәр сыйныфында мәүҗүддер[12]. Аркадашларымнан Шидловский буны сезгә бик ачык сүрәттә аңлатты. Мин хәзер бу мәҗлестә сезгә Русиядә сакин[13] әһле исламның мәхәббәтене гарыз кыйлачакмын[14]. Мин алып килгән әманәт шулдыр.

Мин мөселман бер депутатмын. Русиянең шәрекъ тарафында сакин татар кавеменнән бер мәбгусмен. «Татар» дигәч, яурупалыларның күңеленә килешсез

---

[1] *Асла разый* — һич риза.
[2] *Хөласа* — озын сүзнең кыскасы.
[3] *Дәстәрхан* — ашъяулык, эскәтер.
[4] *Гыйндеңездә мәнфур* — каршыгызда нәфрәт ителгән.
[5] *Ифадә кыйлу* — аңлатып бирү.
[6] *Мөстәхсәнанә* — күркәм, яратулы.
[7] *Саясендә* — арасында.
[8] *Кәма һуа хакъән* — булганынча тулы һәм дөрес итеп.
[9] *Тәхлил* — анализ.
[10] *Тәслим* — сәламләү, саулык теләү.
[11] *Голү шәэнене тәсдыйк* — бөек, югары дәрәҗәсен тану.
[12] *Мәүҗүддер* — бардыр.
[13] *Сакин* — яшәүче.
[14] *Гарыз кыйлу* — ирештерү.

киемле, мәнфур сималы [1], кысык күзле, озын сөнгеле, уклы-җәяле, атка атланган мангул килә. Сәйяхләр сәяхәтнамәләрендә татарларның рәсемене теләсәләр ничек итеп күрсәтсеннәр. Тарихта һәр кавемнең баба вә әҗдады [2] төрле хәл вә кыяфәтләрне кичергәннәр.

Мәгълүмеңез булсын ки, Русиядәге төрек вә татар кавеме хәзер дә андый бер халык түгелдер. Гади мәдәниятне күптән кабул иткән вә мәдәнияте галиянең юлына кергән 20 миллионлык кабилиятле милләттер; дин мөбин исламда мөкайяд [3] улдыклары хәлдә, аның мәдәният илә иҗтимагыйәне белеп, мәдәниятне кямилән кабул итәргә хәзер бер кавемдер.

Ватандашларымыз руслар безгә бу хосусларда камил мөсагадә [4] бирәләр. Вә улдыкча ярдәм итәләр. Мөманәгә [5] итмиләр. Шул сайәдә без Русиянең камил гражданнарыннанмыз. Русиянең һәрбер эшләренә катышамсыз. Гаскәрдә булабыз. Хаким вә мәэмүр [6] дә була аламыз. Мәмләкәтемездә мәшрутият [7] игълан кыйлынганнан бирле низам чыгару эшләренә дә катыша башладык.

Мөселман, мөселман улдыгы хәлдә, гаять хәмиятле [8] бер ватанпәрвәр була аладыр. Әһле исламга өмуре миллияләрендә [9] мөсагадә никадәр артык күрсәтелсә, анларның хөббе ватаннары[10] шулкадәр артадыр. Тәдбир[11] өмуре дәүләттә никадәр катыштырылсалар, мөселманнарның сәдакатьләре[12] дә шул дәрәҗә артадыр. Тәбәгаи исламиясенә[13] бу илә мөсагадәләр бирү, анларны өмуре дәүләткә[14] катыштыру Русиягә махсус бер эш түгелдер. Тәхет химайәсендә мөселманнар күп булган һәр хөкүмәт вә һәр дәүләт бөйлә кыйлку ляземдер. (Һинд вә Мисыр мөселманнарына ишарә.)

Бу мәҗлес мөгътәбәран тоҗҗар тарафыннан ясалган мәҗлестер. Бәлки бунда хокук, мәдәният вә сәясәт бабларыннан күп сөйләү мөнасиб[15] булмас. Ләкин мин әһле тоҗҗаратның сәясәт вә мәдәнияттә күп дәхеле булуына каил[16] бер кешемен. Хосусән Англия тоҗҗары, сез мөхтәрәмнәр, важидадыңыз тарихе бәшәрияттә вә тарихе мәдәнияттә бик зур рольләр уйнадыңыз. Англия идарәсендәге бөтен җирләргә Англия гаскәрләреннән әүвәл сез аяк бастыңыз. Бөтен Американың вә җәзаире мөтәгаддидәнең[17] мәдәниятенә вә рәфаһы хәленә[18] сәбәп Англия тоҗҗарыдыр. Иске бер хәкыйкатьдер ки, бер мәмләкәтнең куәт вә шәүкәте ул мәмләкәтнең тоҗҗарының сәрвәте вә әһле сәнагатиянең рух мөхтәрганәсе[19] илә мөтәнасибдыр. Бу хәкыйкатьнең беренче мисалы вә нәмүнәсе Англиядер. Англиянең мәркәз тоҗҗариясе, ягъни гүйә[20] тоҗҗарат пайтәхете ошбу Ливерпуль шәһәредер.

Бу мәҗлес тә шул шәһәрнең тоҗҗар мөгътәбәраненнән гыйбарәттер. Бинаән галәйһи, Англиянең куәт вә шәүкәте, мал вә сәрвәте кыйсьмән[21] сез мөхтәрәмнәрдән гыйбарәт дисәм, артык мөбаләгә иткән булмасам кирәк. Мин сез мөхтәрәмнәрне Англиянең фагыйль шәүкәте вә мөдәббир сәрвәте булуыңыз җәһәтеннән һәм дә гайре мәдәни җирләргә мәдәният таратучы булуыңыз хәйсиятеннән[22] гомумән тәбрик итәм вә фикер тәхсинемне ифадә кыйлам. Каршымызда ике матур флаг тора (залда Русия вә Англия флагы янәшә куелган иде). Бу гүзәл шигар[23], дәүләтләр һәрвакыт ошбу мәҗлес кеби дустанә мәҗлесләрдә генә очрашсалар иде.

---

[1] *Мәнфур сималы* — җирәнгеч йөзле.
[2] *Әҗдад* — ата-бабалар.
[3] *Дин мөбин исламда мөкайяд* — «дин исламга нык бәйле, тугъры» мәгънәсендә.
[4] *Мөсагадә* — мөмкинлек.
[5] *Мөманәгә* — каршылык, тыю.
[6] *Мәэмүр* — дәүләт хезмәтендәге кеше, чиновник.
[7] *Мәшрутият* — конституция.
[8] *Хәмиятле* — тырыш, ярдәмчел.
[9] *Өмуре миллияләрендә* — милли эшләрендә.
[10] *Хөббе ватаннары* — ватанны сөюләре.
[11] *Тәдбир* — тиешенчә уйланылган эш, чара.
[12] *Сәдакать* — тугърылык.
[13] *Тәбәгаи исламиясенә* — мөселман гражданнарына.
[14] *Өмуре дәүләт* — дәүләт эшләре.
[15] *Мөнасиб* — яраклы, килешле.
[16] *Каил* — ышанып сөйләүче.
[17] *Җәзаире мөтәгаддидәнең* — күп санлы утраулар җыелмасының.
[18] *Рәфаһы хәленә* — иркен, мул яшәвенә.
[19] *Рух мөхтәрганәсе* — ирекле рухи ихтыяры.
[20] *Гүйә* — нәкъ.
[21] *Кыйсьмән* — өлешчә.
[22] *Хәйсиятеннән* — сәбәбеннән, уңаеннан.
[23] *Шигар* — билге, байрак.

Мин бу сәфәремезгә вә хосусән бу мәҗлесемезгә бик зур әһәмият бирәм. Бу мәҗлестә миңа кадәр һәр ике тарафтан дустанә сөйләнгән сүзләрдә һәр ике мәмләкәтнең дустлыгы вә һаман дуст булачагы бик ачык аңлашыла.

Бу дустлыкның һәр ике тарафның гражданнарыннан улан мөселманнарның хокукларына да яхшылык илә тәэсир итүенә өмид итәм. Кадәхәме Олугъ Англиянең истикъбале, гомумән Англиянең тәҗарәт вә сәнагатенең тәрәкъкыйсе вә хосусән бүген миһманы[1] улдыгымыз Ливерпуль шәһәренең төҗҗар мөгътәбәранәнең наме вә шәрәфенә күтәрәм.

Нотыкның башыннан ахырына кадәр кул чабулар туктамады. Моннан аңланды ки, нотык урынына муафикъ булып чыкты.

Миннән соң ике инглиз сөйләде. Болардан соң Милюков вә Лерхе сөйләде. Болар һәр икесе инглиз төҗҗарларының Русиядә күргән вә күрә беләчәк эшләре хакында сөйләделәр.

Мәҗлес шулай тәмам булып бара иде. Мәҗлес ахырында Чайковскийның «Чәчәкләр вальсы» дигән музыка парчасыны уйнадылар. Бу бик күңелле бер парча; мәҗлес бик матур тәмам булды. Һәркем хуш хатир[2] иде.

Кайтырга чыга башладык. Дума рәисе Хомяков килеп, кулымнан кысып тәбрик итте. Буннан башка иптәшләрем һәрбере тәбрик иттеләр. Гучков вә поляк вәкиле Свинтицкий:

— Әйтәсе фикерләреңезне инглизләрнең бик ачуларыны китермәй әйтү читен иде, сез буннан яхшы барып чыктыңыз,— диделәр.

Һәрбер аркадашларым нотыкны яратканлыкларыны белдерделәр, берничә төрле мәдехләр сөйләделәр. Ләкин мин инде аларны язып тормыйм.

Ләкин иптәшләр арасында бер кеше мөстәсна[3]. Бу кеше Государственный Совет әгъзаларыннан. Исеме лязем түгел. Бу кешенең бөтенләй кәефе китте. Бу кеше фикерене миңа әйтеп бирмәсә дә, аның кем икәнен белгәч, уйлап белүе читен түгел иде. Бу кеше Англия халкына: Русиядә егерме миллион кадәр мөселман булганыны һәм мөселманнарның аерым бер милләт булганыны белдергәнгә эче поша иде. Бу кеше шул һаман мөселманнарны күңдәм лакей, честный дворник итеп кенә күрсәтәсе килә иде. Хәтта үзенең барин табигате илән, кайда булганыны онытып: «Татар баласы, синең боларны сөйләргә ни хакың бар?» — дип кычкырырга кыҗраганга охшый иде. Ләкин татар баласы буны аннан сораячак түгел иде. Дөньялар үзгәргән, мәхәлләр[4] башка иде. Кем белсен, бәлки начальстводан рөхсәтсез французча белгәнгә дә эче пошкандыр. Эче пошарга да урын бар, әгәр төрле яктан татарлар шулай укыйгалап китсәләр, эчми торган лакей, яхшы кучер кайдар табарга кирәк булыр?

Өйгә кайттык. Боус аганың өендә бүлмәләремез хәзерләнеп куелган иде. Бүген кич соң булганга, ханәгә кайткач, тиз генә яттык. Иртәгесен торгач, ваннада юынгач, чәйгә чакырдылар. Бакча эчендә, бер балконда чәй эчтек.

Боус ага безне хатыны илән таныштырды, унбер яшьләрендә сабак укый торган кызыны алып килеп күрсәтте. Кыз рәсемле почта карталарыны җыя икән. Бездән матур карталар җибәрергә үтенде.

Чәйдән соң Ливерпуль дарелфөнүнендә инглиз телендә Милюков бер лекция укыячак иде. Шунда киттек. Иң әүвәл Ливерпуль дарелфөнүнене күрсәтеп йөрделәр. Бунда бер дәресханәгә кердек. Милюков батыр гына инглиз телендә байтак заман сөйләде. Хөләсасе — инглиз әдәбиятының рус әдәбиятына булган тәэсире хакында иде. Бик каты алкышладылар.

Буннан соң шәһәр идарәсе өйлә тәгамына кунакка чакырган иде. Анда бардык. Бунда һәм зур мәҗлес. Бунда һәм нотыклар сөйләделәр.

Буннан соң шәһәрне карап йөрдек. Шәһәр бер дә матур түгел. Бик ишлетыгыз шәһәр. Сәүдә шәһәре. Иң кызык җирләре — диңгез буе, порт. Бүген янә бер «Мавритания» дигән зур пароходны күреп-карап йөрдек. Ливерпульдәге Русия консулы һаман безнең илән бәрабәр[5] иде. Буннан соң сәүдә җире Биржага бардык. Биржада халык тулы иде. Без килеп керүгә, тиз генә тугъры Биржаның уртасына барырга юл ачылды. Бөтен халык бер тавыштан «Яшәсен Русия!», «Яшәсен Дума!» дип кычкыра башладылар. Урыннар хәзерләгәннәр. Биржаның мөдиренә тәкъдим иттеләр, ул үзе башкаларга таныштырды. Бу кадәр җыелган халыкка бер-ике тәшәккер сүзе әйтү кирәк булды. Лерхе дигән иптәшемез бер-ике сүз сөйләде.

---

[1] *Миһман* — кунак.
[2] *Хатир* — хәтергә алучы.
[3] *Мөстәсна* — үзенә аерым.
[4] *Мәхәлләр* — урыннар.
[5] *Бәрабәр* — бергә.

Буннан соң янә «урралар», кул чабулар. Буннан соң һәрберемез үз йортларымызга кайтып, нәрсәләремезне алып, сәгать дүртләрдә поездга утырып Шотландиягә — Эдинбург шәһәренә китәчәк идек. Боус ага илән кайтып киттек. Юлда өйләдән соң чыга торган гәзитәләрдә беренче сәхифәдә зур хәрефләр илә: «Ливерпульдә Дума кунаклары» дип язылган гәзитәләр саталар иде. Ул көн иртә белән чыккан гәзитәләрдә рәсемнәремез һәм кечкенә тәрҗемәи хәлләр вә нотыкларымызның холәсасе дә бар иде.

Кайтып, йорт хуҗасы илән күрешеп, нәрсәләрне алып вокзалга килдек. Йорт сахибе үзе дә вокзалга килде. Бу кешенең безнең багажларны автомобильдән алып вагонга кертергә күтәрүчеләр эзләве, кайсысыны-берсене үзе күтәрешүе һаман минем тәхсинемне муҗиб була иде.

Поезд кузгалды. Эдинбургка киттек.

## XXIV

## Шотландия. Эдинбург шәһәре. Вальтер Скотт. Шотландиялеләрнең Англиядә роле

Юл матур иде. Бу — Англиянең матур җирләреннән береdер. Зур болынлыклар. Ара-тирә зур, мәһабәт имениеләр. Яшел болыннар, матур чирәм вә яшеллекләрдә бик күп симез сыгырлар күренә.

Эдинбургта бер гостинсага төштек. Килгән көн бернәрсә дә булмады. Кундык. Иртәгесен өйләгә кадәр шәһәр карап йөрдек. Шәһәр бик матур. Шәһәрдә агачлык, чирәмлек бик күп, шәһәрнең уртасында, биек бер тау өстендә, искедән калган бик матур бер шату (замок). Аның әтрафы яшел чирәмле таулар. Шәһәрнең урамнары киң, бик пакъ. Шәһәр эчендә бер агым су да бар. Шәһәрнең уртасында бер бакча эчендә мәшһүр инглиз язучыларыннан Вольтер Скоттның (Walter Scott) бик матур, зур һәйкәле бар. Искедән Шотландия падишаһларының сараен да карап йөрдек. Бунда мәшһүр Мария Стюартның бүлмәләрене күрдек. Хәзер дә Эдинбургка килгән вакытта Англия падишаһлары бу сарайга төшә имеш. Буннан соң дарелфөнүнне карадык. Бунда граф Бобринскийга аерым илтифатлар булды. Чөнки граф Бобринский Эдинбург дарелфөнүнендә укыган, шуның өчен аны үзләренең шәкертләре күрәләр.

Буннан соң шәһәр идарәсе даирәсендә мәҗлес булды. Янә нотыклар. Монда, табигый, граф Бобринский сөйләде. Бик озак кул чаптылар. Аннан соң поляк граф Патоцкий сөйләде. Буңа да кул чапкаладылар.

Бу мәҗлеснең бер аермасы булды. Мәҗлес мөддәтендә Шотландиягә махсус бер музыка альты илән музыка уйнап мәҗлес ясалган өстәлләр әтрафыннан әйләнеп йөрделәр, бу альт музыкиянең исеме Шотландия истиляхендә[1] ничектер, белмим, французлар буңа корномуз диләр. Төрекләр тулум зурна диләр. Татарчасыны белмим. Бу нәрсә минем хушыма китте. Чыгарган тавышы бик моңлы, Шәрекъ музыка альтларыннан чыккан тавышка охшыйдыр. Әллә нинди бик коруне вөстави[2] бер тавыш.

Инде бу альтның ничек ясалганыны бераз сөйлик: бу бер нәүгъ балан сыбызгы кеби бер нәрсә, сыбызгының түбән башына куык китереп бәйләгәннәр. Шуның өчен тавышы гади сыбызгыдан чыкканнан артыграк. Безнең Себер вә Төркестанда һәм буңа охшашлы нәрсә бар шикелле.

Бу мәҗлестән соң Эдинбург әтрафында сахраларны карарга бардык. Сахралар матур, имениеләр гүзәл. Хосусән әүвәлдә Австралиядә вице король булып торган бер кешенең имениесе вә андагы сарайлар дикъкатемезне җәлеп итте. Бу йөрүләр, әлбәтә, һаман автомобильдә. Шуның өчен аз заманда бик күп мәсафә катгъ иделәдер[3].

Инглизлар бик мактанган бер тимер юл күперене дә карадык. Бу күпер чынлап та зур. Бундай озын күпер Америкада гына бар имеш.

Йөреп кайттык. Кич белән артык эш булмады. Без төшкән гостинсаның бер залында безне Эдинбургка чакырган комитет кешеләре илән бергә бер кечкенә мәҗлес ясадык, вак-төяк нотыклар сөйләдек.

Граф Бобринский нотыгында диде:

---

[1] *Истилях* — атама, термин.
[2] *Коруне вөстави* — урта гасырныкы кебек.
[3] *Күп мәсафә катгъ иделәдер* — күп ераклыклар (юллар) кичеләдер.

— Гәрчә Шотландияне заһирән[1] Англия алган булса да, асылда Англияне Шотландия кешеләре басты. Лондонда вә башка зур шәһәрләрдә ниндәй генә зур эшнең башындагы кешене карасаң, шотландияле булып чыгадыр. Мәсәлән, озак эзләргә дә юк, бу көндә ике зур сәяси партиянең башлыклары — һәм Бальфур, һәм Асквит һәр икесе дә шотландиялеләр түгелме,— диде.

Бу нотык шотландиялеләрнең хушына китте. Мин дә бер-ике сүз сөйләдем:

— Вальтер Скоттны уку илә бөтен дөнья халкы Шотландиягә мәхәббәт утырта,— дидем.

Мәҗлес тәмам булды. Бу көн кундык. Иртәгесен иртүк Лондонга юнәлдек.

Кайтырга чыккач ук мөдәббирләрдән Звегинцев без утырган вагонга килеп, диде:

— Господа, мин бүген Лондоннан бер телеграм алдым. Бүген кичкә безнең хөрмәткә Лондонның әҗнәби[2] матбугаты җәмгыяте бер мәҗлес бирәчәк икән. Мин кабул итеп җавап бирдем, чөнки бүген артык эшемез юк, барырга мөмкин булыр,— диде.— Ләкин бунда һәм нотык кирәк булачак. Кемнән үтенәмез?! — диде.

Безнең вагонда мин телим диюче булмады. Башкалар сөкүт иткәч[3], мин дә алга чыгып, мин сөйлим диясем килмәде.

Звегинцев:

— Уйлаштырыңыз, мин яңадан килеп сорармын,— диде.

Һәркем сәфәрдән соң арыган иде, Лондонга кайтыр-кайтмас мәҗлестә нотыклар сөйләргә иптәшләрдә дәрт күренми иде.

Звегинцев киткәч, безнең вагонда булган кешеләр киңәштек. Граф Бобринский:

— Нотык сөйләргә түгел, просто сөйләшеп утырырга да куәтем калмады,— диде.

Башкалар бүген төрле сылтаулар илән сөйләселәре килмәгәнене белдерделәр.

Арадан Челноков миңа диде:

— Садри Низамович, сез яшь кеше, арымагансыңыз, сез сөйләнез, как раз газета язучылар булганга, бунда булачак кешеләр һәркаюсы бик яхшы французча беләләр. Шөбһәсез, монда сезгә сөйләргә бик муафикъ,— диде.

Мин дидем:

— Анда, алдан хәзерләп куйган фикерең булмагач, ни сөйләмәк кирәк?

Челноков диде:

— Әле кайтырга биш-алты сәгать бар, бернәрсә хәзерләп өлгерерсеңез,— диде.

Болай дигәч, чынлап та миңа сөйләргә фикер төште. Чынлап та, урын бик мөһим, монда сөйләнгән сүзләр бер дәрәҗә бөтен дөнья кешеләренә сөйләгән кабиленнән булачак дип уйладым. Ул арада безнең янда булган Ефремов та димли башлады:

— Фикер таба алмасаңыз, Ливерпульдә сөйләгән сүзеңезне үзгәртеп сөйләрсез,— диде.

Буннан соң мин дә:

— Әгәр сез сөйләсәңез вә башка вагонда иптәшләрдән берәре сөйләргә теләсә, мин дә сөйләрмен,— дидем.

Ефремов:

— Мин бер-ике кәлимә сөйләргә күнәм,— диде.

Бу сүзләрдән соң мөдәббир Звегинцев яңадан килде вә диде:

— Башка вагоннарда халык арыган, сөйләргә теләүче юк, минем үземнән сөйләргә үтенделәр. Мин күндем. Ләкин бер-ике кеше житми, яңадан ике лязем,— диде.

Буннан соң Ефремов:

— Без монда Максудовны димлимез,— диде.— Ул һәркаюымыздан яшьрәк. Ул арымагандыр,— диде.

Мин дә:

— Әгәр һәркаюыңыз муафикъ тапсаңыз, мин сөйләргә риза,— дидем.— Ләкин господин Ефремовның һәм сөйләве шарты илә,— дидем.

Ефремов та күнде. Өч кеше сөйләячәк булдык.

---

[1] *Заһирән* — тыштан караганда.
[2] *Әҗнәби* — чит ил.
[3] *Сөкүт иткәч* — дәшмәгәч.

Ул арада Йорк шәһәренә килеп җиттек. Бунда һәм безне көтеп алдылар. Шәһәрне карап йөрдек. Бу шәһәрнең мәшһүр чиркәвене карадык. Ашадык, эчтек. Сәгать ике ярымнарда яңадан тимер юл илән Лондонга киттек.

Мин, поездга кереп утыргач, карандаш илән хатирә дәфтәремә сөйләсе сүзләремнең планыны яза башладым. Ләкин вагонда шау-шу бик күп иде. Уйныйлар, көләләр иде. Яхшылап язып булмады. Алай да бер нәрсә оештырдым. Планым бик кыска булса да, сөйләгәндә байтак булып чыкты.

Сәгать алты ярымда Лондонга кайтып җиттек. Җидедә гостинсага кайттык. Сәгать сигездә мәҗлескә барырга лязем булачак иде.

## XXV

### Әҗнәби матбугат җәмгыяте тарафыннан бирелгән мәҗлестә сөйләгән нотыгым. Ислам галәменең интибаһы[1]. Хөррият юлында матбугатның хезмәте

Һотелгә кайтып җитеп, тиз генә җыенып, киемнәрне алыштырып, фраклар киеп, мәҗлес булачак ресторанга килдек. Халык җыелып беткән иде. Халык күп иде. Йөз кадәр мәмләкәт гәзитә мөхбирләре, әллә ни кадәр Лондон гәзитәчеләре бар иде.

Бу урында бу җәмгыятьнең нидән гыйбарәт икәнен дә бераз әйтергә лязем булыр. Бу җәмгыять Лондонда торучы башка мәмләкәттән килгән гәзитә мөхбирләре җәмгыяте буладыр.

Мәгълүменез, һәр мәмләкәттә зур гәзитәләрнең башка мәмләкәтләрнең пайтәхет шәһәрләреннән бер хәбәр язып торучылары, мөхбирләре буладыр. Лондонда һәм башка мәмләкәтләрдән килгән зур гәзитәләрнең мөхбирләре бар. Лондон дөньяның иң зур шәһәрләреннән бере булганга, бу чит мәмләкәт мөхбирләре Лондонда башка шәһәрләрдәгедән дә күбрәк. Менә бүген безнең өчен мәҗлес ясаган җәмгыять шушы чит мәмләкәт мөхбирләренең җәмгыятедер, рәсми исеме «Әҗнәби матбугат җәмгыяте»дер. Бу җәмгыятьнең безгә бер мәҗлес бирергә уйлавы да бик кызык, мөһим. Боларга да безне Лондонда шау-шау илә кабул итү тәэсир иткән, боларда һәм кабулга катышу фикере туган. Боларның да Русиянең яңа парламентына хөрмәтләрене күрсәтәселәре килгән.

Һәр мәмләкәттән кешеләр бар иде: Америкадан, Русиядән, Франциядән, Германиядән, Болгариядән, Мисырдан, хәтта Кавказдан бер әрмәни гәзитәсенең мөхбиренә кадәр бар иде. Ләкин Төркиядән бер кеше юк. Төрекләр гәзитәчелектә мисырлылардан артта калган булырга кирәк, төрекләрнең мөхбирләре, Лондонда булмаган кеби, Петербургта һәм юк.

Төрекләрнең кечкенә генә ике миллионлык әрмәннәрдән дә артта булуы бик гаҗәп.

Мин үземезнең татар гәзитәләрене бу хакта гаеп итмим. Безнең әле Лондон, Парижларда мөхбир тотарлык бай гәзитәләремез дә юк, бәлки буңа ул кадәр лязем дә юктыр. Безнең өчен бу хакта ватандашымыз руслар язганнан икътибас кяфи[2] булырга мөмкиндер. Ләкин Төркия кеби зур бер мәмләкәттән Лондонда бер рәтле мөхбир булмавы гаҗәп.

Мәҗлес башланды. Минем янымда бер якта рус консулы, икенче якта бер болгарияле мөхбир иде. Мәҗлестә мөхбирләр арасында бик күп мөхбир хатыннар да бар иде.

Нотык сөйләү нәүбәте миңа килеп җитте. Сөйләргә аяк үзрә торгач ук, халык һәрбере миңа карады. Минем мөселман кунак икәнемне мәҗлестә булган гәзитә мөхбирләренең күбесе белә иде. Белмәгәннәренә белгәннәре әйтә иде. Якында колагыма: «Музульман, музульман»,— дигән сүз ишетелә иде. Мәҗлестә халыкның күплеге вә һәрбересенең журналист, язарга, тәнкыйтькә оста халык булуы куркыта иде. Алай булса да, сөйләргә кирәк. Поездда ясалган планым буенча шушы сүзләрне сөйләдем:

— Әфәнделәр, заманымызда һичбер коруне уля[3] халкы, кадим заман кавемнәре белмәгән бер сәнгать, бер мәһарәт мәйданга чыкты. Бу гәзитәчелек

[1] *Интибаһы* — уяну чоры.
[2] *Икътибас кяфи* — күчерү җитәрлек.
[3] *Коруне уля* — борынгы гасырлар.

сәнгатедер. Кадим заман халыкларыннан сәнгатьләр бабында иң алга киткән юнан халкы да гәзитәчелек нидер — белми иде. Һәйкәлтәрашлык [1], рәссамлык, шагыйрьлек, музыкачылык бабында никадәр тәрәкъкый иткән юнаннар да гәзитәчелектән хәбәрсез иде. Буны мин тәәссеф илә әйтәм, әгәр юнаныйларда гәзитәчелек булган булса, башка сәнаигъ өчен булган кеби, бу сәнгатьнең һәм мифләре, музалары, мәгъбәдләре [2] булган булыр иде. Хәтта мин уйлыйм, моның мәгъбәде (храм) башка сәнгатьләр намена ясалган мәгъбәдләрдән ким булмас иде. Мәгъбәд булгач, монда матбугаттан киная бер һәйкәл дә, шөбһәсез, булыр иде. Белмим, никтер, бу мәҗлестә матбугат нөмаиндәләре арасында дамалар булгангамы, бу матбугаттан киная булган һәйкәл миңа бер хатын һәйкәле булыр шикелле тоела; буны бу мәҗлестә дамалар булганга мөдаһәнә [3] итеп әйтүем түгел. Бу һәйкәлнең мөәннәс [4] булуыны ихтимал күрүемә сәбәп — матбугатчылыкка хөрмәтемдер. Матбугатчылык вазыйфасы бик назик [5] вазыйфадыр, нәфис бер сәнгатьтер. Назик вә нәфис бер нәрсәдән киная дә назик вә нәфис рәвештә булырга кирәк буладыр. Бу исә һәйкәлне бер хатын һәйкәле ясау илән генә мөмкин буладыр. Һәйкәл дигәч, нә рәвештә буласы да хыялга киләдер. Хыялымча, һәйкәлнең нәзари гыйнде, тәгъбир симасы [6] скепик булыр кеби тоела, ләкин шу заһире гыйндият [7] аркылы унтугызынчы гасыр фәлсәфәи сәясиясе мәйданга чыгарган фикер вә принципларга тирән бер икътикад [8] булганы күренәчәге дә шөбһәсез кеби тоеладыр. (Кул чабулар.) Бу сүзләрем матбугатның әһәмиятене тәгъбир итү өчен әйтелгән бер мөкаддимә [9] генәдер. Асыл максудым, кыска гына әйткәндә, матбугатның безнең заманда иң мөһим бер сәнгать икәнене, иң хөрмәткә лаек гамәлият икәнене әйтүдер.

Вакыйган[10] матбугатның вазыйфасы зурдыр. Тарих ясалуында гасырдымызда иң мөһим фагыйль[11] — гәзитәдер. Бу заманда министрләрне төшергән-мендергән, мәмләкәтләрне сугыштырган һәм килештергән — һәрбере гәзитәләрдер.

Мәмләкәтләрдә төрле фикерләрне тугъдырган һәм гәзитәләрдер. Ләкин матбугат ике яклы бер корал, аның илә тәрәкъкый вә хөррияткә дә хезмәт итеп буладыр, әсарәт[12] вә реакциягә дә ярдәм итеп буладыр. Ләкин Яурупа матбугатына шәрәф булсын, Яурупа гәзитәләре — әксәрият игътибары илә — җәһаләт, тәгассыб вә әсарәт ярдәмчесе булмай, хөррият, зыя вә тәрәкъкый чырагы булдылар. *(Кул чабулар.)* Унтугыз вә егерменче гасыр матбугатының шәрәфе тарихка сәбат улыначагы шөбһәсездер. Яурупа матбугаты тырыша-тырыша бөтен Яурупаны хөррият юлына кертеп бетерде. Инде бу көндә идарәи мәшрута Яурупаның һәрбер мәмләкәтендә гам булды. Яурупада христиан мәмләкәтләренең һәрберендә идарәи мәшрута урнашты. Инде нәүбәт ислам мәмләкәтләренә килеп җитте. Мәгълүменез, бүгенге көндә ике мөселман мәмләкәтенең халкы үзләренә хөррият вә тәрәкъкый урнаштырырга тырышып ятадыр. Бу читен бер эш. Төркия вә Иранда идарәи мәшрута тәмам урнашу өчен һич шөбһәсез үзләренең халкының иҗтиһады, гайрәте лязем булган кеби, Яурупаның мәхәббәт вә симпатиясе дә шарттыр. Бу исә язучылар — сезнең кулыңыздадыр. Хөррияткә сусаган бу ике мөселман мәмләкәтләрендә хөррият кертүгә һәм ярдәм итә аласыңыз, һәм зарар итә аласыңыз. Ләкин мин иминем ки[13], бу мәҗлестә хөррият вә мәшрутият дусты булмаган бер кеше юктыр. *(Кул чабулар.)* Бинаән галәйһи, һәр берегез каләмегез илә галәме исламның хөрриятләшүенә тырышачаныза имин булганга, мин сезне галәме исламда хөррият урнашуына, тәрәкъкыйнең тәмам җәелүенә хезмәт итүчеләр дип гадь итеп[14], сезнең шәрәфкә кадәхемне[15] күтәрәм. *(Озын кул чабулар.)*

Мәҗлестән соң бу ресторанның башка бүлмәләрендә байтак танышулар, сөйләшүләр булды. Мин үземнең беркөн Русия сәфарәтханәсендә очраган Барк-

---

[1] *Һәйкәлтәрашлык* — һәйкәлчелек, скульптура сәнгате.
[2] *Мәгъбәд* — гыйбадәт йорты, гыйбадәтханә.
[3] *Мөдаһәнә* — икейөзлелек, ялагайлану.
[4] *Мөәннәс* — хатын-кыз (җенесе).
[5] *Назик* — гүзәл, нәфис.
[6] *Нәзари гыйнде, тәгъбир симасы* — тышкы күренеше, йөзе-чырае.
[7] *Заһире гыйндият* — барлыкка килгән күренеш, образ.
[8] *Икътикад* — ышаныч.
[9] *Мөкаддимә* — кереш сүз.
[10] *Вакыйган* — чыннан да.
[11] *Фагыйль* — эш башкаручы, хезмәткәр.
[12] *Әсарәт* — коллык.
[13] *Иминем ки* — тынычмын ки.
[14] *Гадь (гъәд) итеп* — исәпләп, фараз итеп.
[15] *Кадәх* — рюмка, бокал.

лай әфәнде вә аның һәмширәсенә[1] очрадым. Бер әрмән гәзитә мөхбире илән таныштым. Үткен бер егет, гаять әрмән милләтчесе. Аннан башка мәшһүр, мөхтәрәм инсаниятпәрвәр инглиз журналисты Стеит белән таныштым. Җәйнең кызу вакыты булганга, мәҗлестән соң эчәсе килә иде. Иптәшләр илә бераз салкын кваслар эчкәннән соң, теге ике көпчәкле көлке арбаларга утырып өйгә кайттык.

## XXVI

### Англиядә уникенче көн. Лордмэр ханәсендә өйлә тәгамы. Рәгъбәтле[2] нотыклар. Милюковның мәшһүр сүзе

Бүген безне янәдән Лондонның буңа кадәр күрелмәгән җирләрене күрергә алып барачаклар иде. Мин бармадым. Ялгыз йөреп тагы да күп җир күреп буладыр. Буңа кадәр мин танышкан кешеләремә визит ясый алганым юк иде. Бүген унбердән өйләгә кадәр булган вакытымны визитләр ясарга хәсыр итәргә[3] тели идем. (Унбердән әүвәл визит ясау иртә буладыр.) Һәм шул ният илән чыгып, бер автомобиль алып, адресларым буенча йөреп, берничә кешегә карталарымны калдырдым. Ике кешене һәм өйдә тугъры китердем. Шул визиткә йөргәннән соң, тугъры сәгать унике ярымнарда Лондон шәһәр рәисе (лордмэр диләр) сараена бардым. Англиядә шәһәр рәисе бездәге шәһәр головасы кеби артык әһәмиятсез бер кеше түгел. Инглизләр бу мәнсабка[4] бик әһәмият биргәнгә охшыйдыр.

Лордмэрнең үзенә махсус бер сарае бар икән (Mansion House). Мәҗлес шул сарайда булачак иде. Барып җиттем. Халык җыелып җитә язган иде. Сарай мөкәммәл бер падишаһ сарае кебидер. Махсус киемнәрдә лакейлар, зур баскычлар, зур-зур таблолар илән зиннәтләнгән бүлмәләр. Югарыга менгәч, иптәшләрем янына китерделәр. Һәрбер иптәшләр бергә җыелган иде. Һәрберемез килеп җиткәч, лордмэргә безне илтеп күрештерәчәкләр иде.

Җыелып беттек. Бер зур-озын зал буенча безне алып киттеләр. Залның түрендә әллә нинди коруне вәста, яхуд оперетка падишаһларына лаек бер киемдә шәһәр рәислегеннән киная бер көмеш таяк (гаса) тоткан бер кешегә алып барып, һәрберемезне берәмләп күрештерделәр. Бу кеше лордмэр имеш. Бу кешенең әтрафында әллә нинди кешеләр. Болар да шулай ук оперетта падишаһсының гаскәренә муафикъ бер киемнәргә чорналган. Лордмэр, гаять вәкарь илә генә башыны селкеп, һәркаюымыз илән күреште. Бу кешенең бу кадәр вәкарьләре миңа гаҗәп, азрак артыграк, заманга муафикъ түгел кеби тоелды.

Мәҗлес башланды. Мәҗлестә иң урта урында лордмэр үзе утырган иде, аның уң кулында безнең Хомяков иде. Сул ягында Англиянең мәшһүр яһүди байларыннан Ротшильд иде. Ротшильднең иң хөрмәтле җиргә утыртылуы мине байтак уйларга төшерде.

Бу мәҗлестә безнең руслар тарафыннан берничә нотык сөйләнде. Бобринский, Гучков, Милюков вә Русия посолы граф Бенкендорф сөйләделәр. Нотыкларны иң әүвәл шәһәр рәисе башлады. Англия падишаһының саулыгына кадәх күтәргәннән соң, безнең падишаһ сыйххәтенә бер нотык сөйләп кадәх күтәрелде. Нотыгында шәһәр рәисе диде:

— Мин кадәхемне халкына идарәи мәшрута биргән Русия падишаһы саулыгына күтәрәм,— диде.— Әгәр царь Лондонга тәшриф боерса[5], гаять самими бер энтузиазм илән кабул ителәчәктер,— диде.

Лордмэр бу сүзләрне әйтеп бетергәндә, музыка безнең Русия гимны «Боже царя храни» уйный башлады. Руслардан тавышы булганнары музыкага ияреп бу гимнны җырладылар.

Бу ике падишаһ өчен булган нотык вә кадәхләрдән соң башка нотыклар башланды. Бобринский идарәи мәшрута хакында, Гучков Өченче Думаның эшләгән эшләре хакында сөйләделәр. Милюков та Русиянең хөррият юлына аяк басканыны сөйләде.

---

[1] *Һәмширә* — кыз туган (сеңел, апа, тута).
[2] *Рәгъбәтле* — кызыклы.
[3] *Хәсыр итәргә* — багышларга.
[4] *Мәнсаб* — дәүләт хезмәте урыны.
[5] *Тәшриф боерса* — килсә, рәхим итсә.

Милюковның бу нотыгындагы бер җөмләсе бөтен дөньяга мәшһүр булды.
П. Н. Милюков нотыгында диде:
— Сез, әлбәттә, миннән, оппозиция депутатыннан, Русиядәге хәзерге конституцияне мактауны, бу Өченче Думаны мәдехләүне көтмәсседез (аннан алда Думаны мәдехләп сөйләгән Гучков нотыгына ишарә). Мин тагы да яхшы, мөкәммәл бер конституция булуыны, хөрриятләрнең чынлап вөҗүдкә чыгуыны, исляхлар тиздән ясалуыны теләр идем. Ләкин алай булса да, шу кадәрене әйтергә тиешмен ки, Русия эчендә Дума булган мөддәттә без суллар, оппозиция, падишаһга каршы суллар оппозициясе булмамыз, бәлки падишаһымызның оппозициясе суллары булырмыз,— диде.

Бу җөмләдән соң бөтен мәҗлес бөтен залны шаулатып кул чаптылар. Бу сүз инглизләрнең бик кәефенә килгән кеби, русларга да бик охшады. Бу сүзеннән аны мәҗлес ахырында тәбрик итүчеләр дә күп булды. Ләкин Русия матбугатында бу сүзне һәм уңнан, һәм сулдан тәнкыйть итүчеләр булды бугай.

Мәҗлес тәмам булды. Мин мәҗлестән соң янә берничә кешегә визит ясадым. Бу көн сәгать дүрттә Лондонда торучы кенәз Долгорукий ханәсендә чәй вә концерт булачак иде. Анда бардым. Лондон эчендә бакчалы, зур, зиннәтле, бай бер кунак (особняк). Халык бик күп иде. Гаять матур музыка вә шигырь парчалары уйнадылар, җырладылар. Безнең сәфир дә бар иде. Лондонның кибарыннан бик күп кеше бар иде. Кенәзнең хатыны княгиня, русча белми булырга кирәк, безнең илән французча гына сөйләшә иде. Лондонда рус депутатларына зур кабул булганга бик мәмнүн булганыны сөйләде.

Миннән:
— Сез чынлап та татармы, йә исә нәселеңез генә татарданмы? Французларда бер мәкаль бар: русны актарып-тырнап карасаң, татар табарсың, диләр,— диде.
Мин дидем:
— Мин актаруга-тырнауга ихтыяҗсыз, туп-туры шул көенчә татар,— дидем.— Һәм шул татар булганыма бик һаваланам,— дидем.
Болай әйтүемә сәбәп: княгинянең әллә нинди, мине татар булганга кызганып җуатасы килеп сөйләгән шикелле сүзләр сөйләведер.
Бу сүземнең мәгънәсене княгиня аңламады булырга кирәк:
— Русиядә, белмәссең, шулкадәр халык бер-беренә кушылып беткән, поляк каны да күп, татар каны да күп, француз мәкале бик дөрес,— диде. Ул арада бүгенгә күчеп: — Әле сезгә чәй биргән кеше булдымы? — диде. Әллә нинди, Франциядә унсигезенче гасыр киеме төсле киенгән бер хадимгә миңа чәй бирергә кушты.

Кенәз белән таныштык. Кенәз үзе дә бик нәзакәтле, Лондонда сезон вакытының бик кызык булуыннан, кибар хәятының — Светская жизнь — һичбер шәһәрдә Лондон кадәр үк булмавыннан бәхәс итте.
Тагы берничә кеше илән сөйләшкәләдем. Мәҗлес бетте, кайттым.
Бүген кич дарелфөнүндә бер лекция тыңларга чакырылган идек. Мин анда бармадым. Беркөн сәфарәттә очраган Барклай әфәндегә акшам тәгамына бардым. Бунда акшам тәгамы заманында мисырлы бер егеткә очрадым.

## XXVII

## Англиядә унөченче көн. Оксфорд дарелфөнүненә зиярәт. Профессор Виноградов

Бүген Оксфордка бардык. Бу Лондонга якын дарелфөнүнле бер шәһәр. Ләкин Оксфордны тәгъриф итмим. Бу дарелфөнүн Кембридж дарелфөнүненә бик охшыйдыр. Гайн тәртип, гайн матурлык, гайн байлык дияргә мөмкиндер. Монда һәм дарелфөнүн тарафыннан мәҗлес ясалды. Янә нотыклар сөйләнде. Ләкин инде шулкадәр арыган идек, нотыкларны сөйләсе дә килми иде. Мәҗлес заманында мине гарәп әдәбияты профессоры Маргулуис янына утырттылар. Акрын гына итеп төрекчә дә сөйли белә. Мисырда һәм булган, Гөлнар ханым Лебедеваны белә икән. Казаннан дигәч, аны сорашты.

Мәҗлес тәмам булды. Мәҗлес соңыннан университетны карап йөргәннән соң, профессор Виноградовка чәйгә бардык. Профессор Виноградов үзе мәшһүр рус профессорларыннан, бу көндә Оксфорд дарелфөнүнендә Англия тарихы мөгаллимедер. Инглизчә һичбер инглиздән фәрекъсез[1] сөйли һәм яза имеш. Үзе

[1] *Фәрекъсез* — аергысыз.

әҗнәби бер кеше булып та Англия милләтенә үз тарихыны үгрәтерлек мәгълүмат сахибе булу зур бер кәмаләттер. Виноградов үзенең болай зур дарелфөнүнгә тәгаен ителүгә лаек булуыны, әлбәттә, тарихтагы хезмәте вә язган әсәрләре илә исбат иткәндер. Безнең Русия профессорлары арасында гыйлем вә фазыллары[1] бөтен Яурупа тарафыннан тәсдикъ ителгән байтак кеше бар. Бу хакта Русия ифтихар итәргә[2] дә хаклыдыр. Беркөн Кембридж дарелфөнүнендә профессор Тимирязевнең дәрәҗә алганыны күргән идек. Бүген бер рус профессорының инглизләргә мөгаллимлек иткәнене күрәмез.

Профессор Виноградовта чәй мәҗлесе дарелфөнүн бакчасында хәзерләнгән иде. Бакча матур, көн җылы, һава яхшы иде. Музыка уйный иде. Бездән башка да халык күп иде, бөтен дарелфөнүн профессорлар, хатыннары, кызлары илә тулы иде. Кунакка Мәскәүдән килгән профессор Виноградовның ике кардәш кызлары да бар иде. Бу ике кыз без Русиядән килгән кунакларга бик шатландылар, бик ачык кабул иттеләр.

Бу бакчада мәҗлес тәмам булгач, поездга утырып кайтырга чыктык.

## XXVIII

## Англиядә ундүртенче көн

Бүген якшәнбә иде. Арадан күбемез авылга, Норсклиф дигән «Таймс» гәзитәсе сахибенең имениесенә кунакка киттеләр. Мин бармадым, Лондонның буңа кадәр күрмәгән җирләрене карап йөрдем. Янә беркөн, үткән якшәнбә, күргән Һайд Паркның җәмгыятьләр, собраниеләр була торган җиренә бардым. Ләкин бүген һава яхшы түгел иде. Сөйләүчеләр булса да, беркөнге кадәр күп түгел иде. Буннан соң Русиягә берничә кешегә хат язасым бар иде. Гостинсага кайтып шуларны яздым; чемоданымда үзем илән алып килгән бер французча китап бар иде, шуны укыдым; чәй эчтем. Рәхәтләнеп ялгыз ял иттем. Бу унбиш көндә нотыклар, мәҗлесләр, бер туктамый яңа кешеләр илән сөйләшүләр, кунактан кунакка, автомобильдән поездга күчеп йөрүләр ардырган иде.

Кич булды. Иптәшләр авылдан кайттылар. Кайсылары гаҗәеп матур вә роскошь дип дачаны мактады. Кайсылары барасы калмаган, әллә ни юк диде. Кич белән без төшкән гостинсаның бер зур залында Һиндстан кешеләре вә студентлары бер собрание ясаячаклар иде. Англиядә төрле собрание ясау бик мәгъруф. Һәр гостинсаның собраниеләр ясарга махсус бер залы була имеш.

Йөзләп һиндстанлы укучы егетләр, берничә дистә Лондонда икамәт итүче[3] карт һиндиләр җыелдылар. Бу мәҗлестән максуд шушы иде: шул көннәрдә генә һиндстанлы бер студент әүвәлдә Һиндстанда мәэмүр булып торган бер кешене үлтергән иде. Бу һиндстанлы егетләр җыелып, бу хәрәкәткә каршы протест ясарга, үлтерүче егетнең бу эшеннән гаять хафага төшкәнлекләрене белгертергә җыелганнар иде. Болар Англиягә садыйк партиягә мәнсуб студентлар иде. Мин дә сорап кереп карап утырдым. Мәҗлес озакка бармады, тиз генә алдан хәзерләп куелган егеткә нәфрәт итә торган резолюцияне чыгарып, тавышка куйдылар.

Бер егет моңа каршы сүз сорап, кызып сөйләмәкче булган иде, аны тиз генә туктаттылар. Аңа каршы бер карт һинди байтак сөйләде. Сүзе арасында «мөселман» дигән сүзне дә тәкрар итә иде. Янымдагы Лондонда тора торган бер яһүди егет нотыкның хуләсәсене сөйләде.

Карт һинди Һиндстанның мәҗүс вә мөселманнары наменнән катыйль[4] егетнең хәрәкәтенә наразый[5] булганлыгыны сөйләгән имеш. Һиндстан халкының мәҗүс вә мөселманы Англия идарәсендә фәүкыльгадә разый имеш.

Мәҗлестә мөселман һиндиләр дә бармы дип сораштым. Юк булып чыкты. Берничә мөселман укучы Лондонда бар имеш. Ләкин мәҗлескә килеп өлгермәгәннәр имеш. Нотыклардан вә резолюциядән аңлана ки, бу собрание Англиягә садыйк[6] һиндлеләр собраниесе икән.

---

[1] *Фазыл* — өстен, абруйлы (кеше).
[2] *Ифтихар итәргә* — мактанырга, горурланырга.
[3] *Икамәт итүче* — төпләнеп яшәүче.
[4] *Катыйль* — үтерүче.
[5] *Наразый* — ризасыз.
[6] *Садыйк* — дус.

## XXIX

## Мисырлы егет илән өйлә тәгамы. Веллингтон сарае. Һайд Парк моназәрәсе[1]

Бүген иртә белән Лондон шәһәренең буңа кадәр күрелмәгән берничә җирләренә сәер иттек. Картиналар галериясенә бардык. Моннан соң мин, иптәшләремнән аерылып, «Сесил һотел» дигән һотелгә мисырлы бер егеткә өйлә тәгамына кунакка киттем. Бу егетне мин буннан ике көн мөкаддәм Барклай дигән кешедә күргән идем. Буннан соң визит[ка]лар да бирешкән идек, ул мине өйлә ашына чакырган иде. Бу мисырлы егет — мөселман, исеме Хәсән Сабри иде.

Хәсән Сабри бәк тәхсыйль җәһәтеннән юрист имеш. Ләкин бүгенге көндә җамигыльзәһргә тәгаллекъль[2] бер вазыйфасы бар имеш. Әгәр хәтеремдә ялгыш калган булмаса, җамигыльзәһрнең хөкүмәт тарафыннан куелган инспекторларыннан бере кеби. Сабри бәк бик яхшы французча сөйләшә. Буннан башка инглизчә һәм яхшы сөйли. Гарәпчәсе, әлбәттә, тагы да мөкәммәл, гарәпчә һәм яза имеш.

Тәүфикъ Нәсим исә Мисырның мәхкәмәи истинафиясендә[3] адвокат имеш. Нәсим бәк һәм французча вә инглизчә сөйләшә. Буннан күреләки, һәр икесе заман икътыязынча тәхсыйль күргән[4] Мисырның эштәге яшьләреннәндер.

Мәҗлес заманында һәр икесе Русия мөселманнары хакында бик күп төрле сөальләр ясадылар. Һәр икесе дә фәүкыльгадә ерак мәмләкәттәге диндәшләренең барышларына, әхваленә вакыйф[5] буласы килгәнләрене аңлаттылар.

Миңа ул хитабән[6] әйткән сөальләренә җаваплар биргәч, мин үзем Мисыр хакында, хәзерге Мисырда укыган яшьләр хакында байтак нәрсәләр сорадым. Һәрбер сөалемә яшь мисырлылар бик яхшы җаваплар бирделәр.

Сөальләрем бертөрле, үз фикеремдә, мөһим сөальләр иде. Икътисади, иҗтимагый вә хәятый сөальләр иде. Әгәр мәсьәләгә яхшы вакыйф булмаганда, өстән-өстән генә җавап биреп булачак түгел иде. Алай җавап бирелгәндә, мин дә мәгълүматның сайлыгыны сизәргә мөмкин булачак иде. Мин бу егетләрнең үз ватаннарының хәлене яхшы белүләренә чын күңелемнән тәхсин итәм.

Мин сәяхәттән соң Швейцариягә баргач, болардан башка берничә мисырлы егеткә очрадым; һәрберендә тирән бер ватанпәрвәрлек, җиддият вә ватан әхваленә вакыйфлек күрдем. Ләкин шул ук сәяхәт заманында берничә укучы вә укып бетергән төрек егетләрене күрдем, алар, мисырлыларга караганда үзләренең ватаннары хакында фикерләре бик югары булса да, ватаннарының хәяты, хәле, истикъбале хакында мәгълүматлары кяфи[7] булмаганы, мәмләкәт эчендә зоһур итеп яткан әхваль хакында бер ачык фикергә малик булмаганнары заһир иде.

Хәлбуки, мин күргән Мисыр егетләре һәрбере бу хакта төрекләрдән бик алда күренде. Женевада күргән мисырлы бер егет Мисыр хакында статистик цифрларны асат сөйләве мине хәйран калдырды. «Безнең Мисырны сәясәт җәһәтеннән тәхрирдән әүвәл икътисади тәхрир[8] кирәк»,— ди. Буның лязем вә мөһим икәнене цифрлар илән исбат итә. Буның икътисад канун вә истыйляхләренә[9] бик ашна икәнене һәр җөмләсе исбат итә иде. Һәрхәлдә, мин бу күргән Мисыр егетләреннән соң, бу гарәп мәмләкәтенең киләчәге якты булуына ышанам. Һәр мәмләкәт, һәр милләт өчен истикъбаль бары җидди мәгълүматлы, сәбатлы вә гайрәтле яшьләр мәйданга чыгу белән генә мөмкин буладыр.

Бу мисырлы диндәшләр илән мәҗлесемез бик озак дәвам итте. Әйтеп китмәгән мәсьәлә бик аз калды. Һотелдән Темза буенда Англия парламенты күренә иде. Аның өстендә Англия флагы җилберди иде.

Сабри бәй миңа карап:

— Парламентны күрәсеңезме? — диде.

---

[1] *Моназәрә* — бәхәс, дискуссия.
[2] *Җамигыльзәһргә тәгаллекъль* — җәмәгать җинатьчелегенә бәйле.
[3] *Мәхкәмәи истинафия* — апелляция суды, мәхкәмәсе.
[4] *Заман икътыязынча тәхсыйль күргән* — заман таләбенчә укыган.
[5] *Вакыйф* — аңлаучы, төшенүче.
[6] *Хитабән* — эндәшеп, сүзне юнәлтеп.
[7] *Кяфи* — җитәрлек, канәгатьләндерерлек.
[8] *Тәхрир* — язып аңлату.
[9] *Истыйлях* — атама, термин.

— Күрәм,— дидем.

— Әнә шул зур парламент Мисыр өчен бер кечкенә бала тугъдырса тугъдырыр,— диде.— Инсаннарның вә милләтләрнең талигасе[1] бик кызык: Мисыр кеби зур, шәэнле[2] бер мәмләкәтнең мөкаддәс мәелләренең вөҗүдкә чыгуы шул җилбердәгән флаг астындагы берничә дистә кешенең бер дәкыйкадә була торган карарыннан туарга мөмкиндер,— диде.

Мин көлеп:

— Туар, туар, бу инглиз палатасы кысыр түгел, әле бу көннәрдә генә Трансвааль өчен бер парламент тугъдырырга хәзерләнә,— дидем.

Мәҗлесемез тәмам булды. Миңа сәгать өчтә герцогиня Веллингтон сараена барырга тиеш иде. Бардым. Башка рус иптәшләрем һәм килә башлаганнар иде. Мин икенче булып килдем. Герцогиня Веллингтон (Duchesse de Wellington) кем булганын әйтү лязем булса кирәк. Уэлсли Веллингтон 1769 дан 1825 нче елга кадәр яшәгән Англиянең зур генералыдыр. Наполеонның башына җиткән. Ватерлоо сугышында Наполеонны җиңгән кеше шул Веллингтондыр. Англия тарихында бу кеше зур бер урын иштаь итәдер.

Бүген безне кабул иткән хатын шушы тарихи Веллингтонның йә угылының, йә хафиденең[3] хатыны булса кирәк.

Герцогиня Веллингтон безне түбән катта, кечкенә бер салонда кабул итте. Беркөн лорд Рай дигән кешедә очраган Маккинз Уоллес дигән инглиз дә һәрберемездән әүвәл килгән иде. Ул безне, һәркаюымызны, мадамга тәкъдим итте. Бераз торгач, герцогинянең кызы төште. Фәүкыльгадә матур бер кыз. Чын кибар инглиз җәмиләсенең нәмүнәсе. Озын буйлы, күп назик, куе сары сачле, тирән, мави[4] күзле, озын керпекле. Бөтен йөзендә бер ләтафәт җәелгән. Бик йомшак көлә, яңа чыккан Париж модасында киенгән, башында бик зур, үзенә бик килешкән эшләпә. Мин инглиз хатыннарының матурлары бик матур була, аларга бер дә [тиң] чыкмый дип ишеткәнем бар иде. Ләкин бер дә килгәннән бирле бундай матурны күргәнем юк иде. Беркөннәрдә Лондонның матур хатыннарыннан бере дип күрсәтелгән хатын, матур булса да, инглизләргә махсус бер матурлык илән матур түгел иде. Хәлбуки, Веллингтонның хафидәсе хакыйкатән инглиз матуры.

Мисс герцогиня һәркаюымыз илән берәм-берәм бераз сөйләште. Миннән: «Мин сез рус депутатларыны күрүдән бик мәмнүн булдым»,— дигән сүзне русча әйтергә үгрәнде. Русча үгрәнергә бик теләгәнене сөйләде. Агасы Петербург сәфарәтханәсендә[5] беренче секретарь икән. Бер сәнә Петербургка кунакка барырга уйлый икән. Русча җөмләне үгрәнгәч, аны барып Маклаковка вә тагы берничә депутатка сөйләде. Көлеп тәбрик иттеләр.

Буннан соң сарайның залларыны карарга башладык. Мондагы картиналарны, Веллингтонга бүләк булып төрле падишаһлардан килгән бүләкләрне тәгъриф итеп тормыйм, бунлар чиксез. Безнең рус падишаһларыннан да байтак бүләкләр алган икән. Заманында Веллингтон дөньяның иң зур кешеләреннән бере булган бит.

Зур залларына барып чыктык. Бу сарайның зур залыннан күрелгән мәнзарә кадәр матур бер мәнзарә һичбер җирдә күрмәдем. Бу тәрәзәләрдән Һайд Паркның иң матур җирләре күренәдер дисәм, бер дәрәҗә белдергән булырым дип уйлыйм. (Һайд Парк хакында алда бер-ике сүз сөйләгән идем.)

Ул арада чәй хәзер булган диделәр. Чәй бүлмәсенә чыктык. Бу бүлмәдән һәм Һайд Паркның бер кыйсеме һаман күренә иде. Бездән башка берничә кунаклар да килде. Зур, матур дивары таблоларга капланган. Йимәк бүлмәсендә чәй исе чыккан иде. Бу чәй исе, җәйнең матур вакыты булганга, Русияне, Русия хәятыны искә төшерде. Лимон илә исле чәй эчүләрне сагындырды. Һайд Паркның матур агачлар илән тулган ике зур аллеясе, бу аллеядә һәр көн булган кеби, матур экипажларда йөрүчеләр илә тулы иде. Һайд Паркның яшел болыны, чирәмлеге дә күренә, су да ялтырый иде. Ләкин никтер бүген боларны узып, фикерем Русия урманнарына, мөкаддәс балалык заманнары узган болыннарга, урманнарга вә бакчаларга сикерә иде. Шул дәкыйкадә, мөмкин булса иде, сикереп, Лондонны, Англиясене, матур сарайларыны калдырып, фракларыны, сюртюкларыны ташлап, үземнең балалык вакытым үткән

---

[1] *Талига* — алдынгы (өлеше).
[2] *Шәэнле* — дәрәҗәле.
[3] *Хафид* — оныҡ.
[4] *Мави* — зәңгәр.
[5] *Сәфарәтханә* — илчелек.

Ташсу авылының урманына, олугъ печәнлегенә очып кайтыр идем. Бу олугъ печәнлек искә төшкәч, нә бу сарайның байлыгы, нә картиналары, нә кунак дамаларның чиксез энҗе вә бриллиантлары һичберсе минем исемне китәрми иде.

Мәҗлес бетте. Кайттык. Кич Стрэши дигән бер журнал чыгаручыга барачак идек.

## XXX

### Лоу-Стрэши ханәсе. Хариҗия назыйре[1] илән сохбәт[2]. Мадам Асквит илән сохбәт. Француз теленең интишары

Стрэши — Лондонның игътибардагы сәяси бер журнал сахибедер, журналының исеме «Спектейтор»дыр (Spectator). Бу журнал сәяси булу җәһәтеннән булырга кирәк, Стрэшиның кунаклары арасында бик күп сәясион[3], депутатлар, министрлар бар иде. Без килеп җиткәндә халык тулган иде. Бу мөсамәрә[4] безнең өчен ясалганга, халык безне фикрән көтә булган булырга кирәк.

Бер зур залга килеп керү белән, халык һәркайсы безгә карыйлар иде. Кызык бит, әллә кайдагы, ерактагы Русия дигән мәмләкәтнең депутатлары. Күрәсе килерлек. Акрынлап һәркаюымызны берәр кешегә тәкъдим иттеләр. Минем илән әүвәл бер депутат сөйләште. Бу, бездән якын бер кеше илән сөйләшеп торган бер даманы күрсәтеп:

— Бу мадам Асквит,— диде.— Телисеңезме, таныштырыйм,— диде.

— Рижа итәм[5],— дидем.

Мадам Асквит сөйләшеп торган кешесеннән аерылгач, мине илтеп тәкъдим итте. Мадам Асквит — югарыда тәгъриф иткән баш министр Асквитның хатыны.

Мадам Асквит французча бих яхшы, хәтта оста сөйли, һәм сөйләргә бик ярата торган булырга кирәк. Әүвәлдә бездән һәр инглиз сорый торган гади сөальләрне сорады, соңыннан байтак җитди мәсьәләләргә кереп китте. Инглиз сәясәтенә, Англиянең Русиягә мөнәсәбәтенә даир байтак сүзләр сөйләде. Ләкин бу мәсьәләләрне мин бу урында яза алмыйм. Мадам Асквит сөйләгән сүз Асквит сөйләгәнгә мөсавидер[6]. (Чөнки Асквит, бөтен Лондон әйтүе буенча, бөтен эштә иренең мөгавинәсе[7].) Сәясәт башындагы кешеләр илән булган хосусый сохбәтләр һичбер вакыт язылып чыгарылмыйдыр. Ләкин шул кадәресене әйтәм, мин мадам Асквитның мәгълүмате сәясиясенә гаҗәпкә калдым. Мин буннан башка да инглиз хатыннарының бәгъзыларының дахили вә хариҗи[8] сәясәттәге хәбәрдарлыкларына хәйран булганымны сөйләгән идем.

Бераз сөйләшкәч, мадам Асквит киләсе көнгә өйлә тәгамына ашка чакырды. Кабул иттем. Баш министрнең дахили тормышыны күрәсем килә иде. Бу дәгъвәт[9] хосусый дәгъвәт иде.

Бераз сөйләшкәч, мадам Асквит:

— Сез безнең хариҗия министре сэр Эдуард Грей илән танышмысыз? — диде.

Мин:

— Беркөн Русия сәфарәтханәсендә күрешкән идек, ләкин яхшылап сөйләшкәнем юк. Яңадан тәкъдим итсәңез, бәлки бераз сөйләшер идем,— дидем.

Мадам:

— Сөйләшеңез, сөйләшеңез, ул минем ирем кабинетының иң гакыллы министрләреннән бередер,— диде. Мине сэр Эдуардка алып барып, французча: — Месьё министр, менә сезгә бер яшь рус депутаты, сөйләшергә димлим,— диде.

Сэр Эдуард Грей илә сөйләшкән сүзләремне бунда язарга лязем булмаса кирәк. Күбрәк сүземез Иран әхвале хакында булды.

Быел мин Төркия министре Рәфгат пашаны күргән идем, бүген сэр Эдуард Грейне күрдем. Аннан берничә вакыт соң Франциянең хариҗия министре Пишонны күрдем. Бөтен мәмләкәтләрнең хариҗия министрләрендә гомуми бер сыйфат

[1] *Хариҗия назыйре* — чит илләр министры.
[2] *Сохбәт* — әңгәмә.
[3] *Сәясион* — сәясәтчеләр.
[4] *Мөсамәрә* — кичке мәҗлес.
[5] *Рижа иту* — теләү, өмет итү.
[6] *Мөсави* — бәрабәр, бертөрле.
[7] *Мөгавинәсе* — ярдәмчесе.
[8] *Дахили вә хариҗи* — эчке һәм тышкы.
[9] *Дәгъвәт* — чакыру.

бар. Бу сыйфат — башка мәмләкәтләрдәге әхвальнең вак фактларына фәукыльгадә әһәмият бирү. Шулай һәм ляземдер. Чөнки вак фактлардан зур вакыйгаләр туадыр.

Министрдән аерылып бераз ялгыз йөргәч, беркөн сәфарәтханәдә танышкан «Дейли телеграф» гәзитәсе сахибенең хатынына очрадым. Бу хатын үзе — француз. Мин аларга карточка калдырган идем. Өйдә булмаганнарына тәәссеф итеп сөйләде. Янә Франциядән бәхәс иттек. Хатын диде:

— Дикъкать итәсенезме, бу мәҗлесне Лондонда дип белерлек түгел. Шулкадәр, һәркем французча сөйләшәдер. Лондонда югары табәкадә французча бик мәгъруф[1],— диде.— Бу табәкаләрдә бер дә инглизчә белмәенчә Лондонда торырга мөмкин,— диде.

Һәм чынлап та, Лондонда француз теле бик таралган. Буннан башка үткән сәнә Берлиндә булган вакытта Берлингә конгресска килгән бөтен дөнья депутатлары арасында французча белүче һәм яхшы белүче кешенең күплегенә исем киткән иде.

Германиянең ул вакыттагы баш министре Бюлоф конгресс ачылган көн Рейхстаг мәҗлесе залында француз телендә бер нотык сөйләгән иде. Бюлофның французча сөйләвендә һичбер косур[2] булмаганы һәркемне тәгаҗҗеб иттергән иде.

Бунларны язудан максудым — французчаның бүгенге Яурупа мәмләкәтләрендәге игътибарыны күрсәтүдер. Французча белгән кешегә Яурупаның, хәтта Американың һәрбер укыган, образованный кешесе илән күрешеп сөйләшергә мөмкин. Хәлбуки, нә инглизчә, нә алманча илән болай мөмкин түгел.

Алманиядә инглизчә белүче бик аз булган кеби, Франциядә һәм аз. Франциядә вә Англиядә алманча белүче бик сирәк. Буннан күрелә, Яурупа телләренең һәрберене үгрәнергә вакыты булмаган кешегә берне генә сайларга тиеш вә сайлаганда мотлакан французчаны сайларга тиеш дип уйлыйм.

Бу лисанның фәукыльгадәназик вә матурлыгыннан башка, гаять мөнтәширлеге[3] моны үгрәнергә сарыф иткән зәхмәтләрне һичбер вакыт үкендерәчәк түгелдер. Шуның өчен, яшь укучыларым, әгәр мөмкин булса, русчадан башка бердә французча үгрәнергә тырышыгыз. Бунсыз Яурупа мәдәниятенә чынлап интисаб[4] кәсеп итүе читен. Бу лисанның искедән җыелган хәзинәи әдәбияты бер бәхре гыйлемдер[5] ки, һичбер вакыт үкенмәсеңез.

Бу мөсамәрәдән кич бик соң кайттык. Иртәгесен Лондонда актык көнемез иде.

## XXX

Бу көн Темза нәһере өстендә каекъ узышыны карарга чакырылган идек. Бу узышны карагач һәм шунда мәҗлес булачак иде. Мин буңа бармадым. Чөнки Асквит йортына барасым бар иде. Миннән башка байтак кеше дә бармады бугай. Арыган идек. Каекъ узышыны күрергә дәртемез юк иде.

Мин сәгать бер ярымнарда автомобиль яллап Асквит ханәсенә бардым. Асквит баш министргә махсус, бик зур түгел, бик матур гына бер сарайда — дворецта торадыр. Югары мендем. Миннән башка берничә кунак вә безнең Маклаков бар иде. Мадам Асквит миннән башка руслардан Маклаковны чакырган икән. Бераз үткәч, мәҗлес башланды. Асквит сарае Веллингтон сараеннан соң бик мәһабәт күренмидер. Мәҗлес заманында Маклаков мадам Асквит илән сөйләште. Мин Асквитның җиткән кызы илән сөйләштем.

Бу кызның һәм даирәи мәгълүматына — развитиесенә хәйран калдым: унҗиде-унсигез яшьтәге бер кыз атасының тоткан сәясәтенең бөтен тәфсыйлатене, фәлсәфәсене аңлый вә бәян итә белә иде. Бүген дә бөтен Англияне шау китергән бер җир кануны хакында сөйләде. Бу шундай мөгъләкъ[6] бер мәсьәлә, эше шул булмаганда, буны бу яшьле ир кешегә дә белмәсә гаеп булачак түгел. Ләкин мисс Асквит һич шөбһәсез бу канунның бөтен рухыны вә тәфсыйлатене белә иде. Бундай хатыннар Англиядә сәяси ирләренең зур ярдәмчеләре булырга кирәк дип уйладым. Аннан башка бер гаҗәп нәрсә: мисс Асквитта һичбер төрле, күбесенчә

---

[1] *Мәгъруф* — билгеле, таралган.
[2] *Косур* — кимчелек, җитешмәгәнлек.
[3] *Мөнтәширлеге* — җәелгән, таралган булуы.
[4] *Интисаб* — мөнәсәбәтле булу.
[5] *Бәхре гыйлем* — гыйлем диңгезе.
[6] *Мөгъләкъ* — читен, четерекле.

кызларда була торган риялы, сонгый[1] оялчанлык (кокетлык) юк. Ир бала кеби, гаять батыр сөйләшә. Бу да минем фикеремдә бер фазыйләт[2].

Мәҗлестән соң Асквит белән бераз сөйләштек. Англия зур кешеләреннән Асквит французча читен сөйләшә. Һәм табигате чын инглиз. Күп сөйләшергә дә яратмый булырга кирәк. Эш кешесе. Дөньяда хикмәт — сөйләүдән бигрәк эштә бит.

Менә, укучы, мин дә сезнең илән сөйләшүем озагракка китте дип эчем поша. Ләкин яза башлаганда мин буны язарга бер сүз булсын дип кенә башламаган идем. Буннан укучыга бер фикер, бер файда өмид итеп башлаган идем. Ничек булгандыр, ул хакта хөкем итүне сезгә тапшырып, мин инде туктарга уйлыйм.

Асквиттан кайткач кич булды. Каекъ узышына барган кешеләр дә кайттылар. Арамыздан берничәсе шул көн кичке поезд илә иртүк киттеләр.

Без Франциягә барасы кешеләр ул көн китми калдык.

* * *

Бүген унжиденче көн иде. Иртүк торып, нәрсәләрне җыеп, чәй эчеп, Чаринг Круз дигән вокзалга бардык. Безне озатырга сәфарәтханәдән һәм төшкәннәр иде. Поезд, Лондонны калдырып, бик кызу Ла-Манш диңгезенә таба тәгәрәде.

Диңгезгә ике сәгатьтән барып җиттек. Поездан төшеп, диңгез пароходына утырдык. Диңгез тыныч иде. Тиз заманда Франция хөдүденә[3] җиттек. Диңгез пароходыннан төшеп, Парижга барачак поездга кереп утырдык. Дәкыйка соңра поезд Парижга таба тәгәрәде. Англия калды. Англиягә сәяхәтемез мазый булды[4].

*Тәмам*

## Сәяхәтнамә авторы турында берничә сүз

Җитмеш елдан артык исемен дә телгә алырга ярамаган Садри Максуди, ниһаять, туган халкына «кире кайта» башлады. Аның турында беренче сүзне академик Индус Таһиров башлап җибәрде (Парижда укыган Садри //Социалистик Татарстан.—1990.—27 май). 1991 елда вакытлы матбугатта С. Максудиның үз хезмәтләреннән III дәүләт Думасында урыс шовинистларының төрки-мөселман халыкларына юнәлтелгән, аларның азатлык өчен көрәшкә күтәрелә башлавын пантюркизм, панисламизм дип дөнья җәмәгатьчелеген алдауга корылган пропагандасын фаш иткән нотыгы дөнья күрде (Халык өскә чыгачак //Идел.—1991.— № 10—11.—78—86 бб.). Тоталитар система җимерелеп, демократизм өчен юллар ачыла, плюрализм принциплары алга чыга башлаган бу көннәрдә Садри Максудиның хезмәтләрен, аның тормышы һәм көрәше турындагы мәгълүматларны халыкка җиткерү галим-голәмәнең игътибар үзәгендә булырга тиеш иде кебек. Ләкин кызганыч, татар галимнәре һәм зыялылары бу юнәлештә иҗтиһад вә тырышлык күрсәтеп җиткермәделәр диясе килә. Дөрес, 1994 елда Садри Максудиның тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни кон-

[1] *Сонгый* — ясалма.
[2] *Фазыйләт* — өстенлек.
[3] *Хөдүд* — чик, дәүләт чиге.
[4] *Мазый булды* — үткәндә калды.

ференция үткәрүгә хәзерлек һәм шул конференцияне үткәрү уңае белән бу галим, җәмәгать эшлеклесе турында вакытлы матбугатта ара-тирә аерым мәкаләләр күренгәләде. Аларның авторлары Я. Абдуллин, М. Зәкиев, Ә. Кәримуллин, Ф. Гаффарова, Р. Даутов, М. Гайнетдин, С. Максудиның оныгы Г. Пултарлар булды. Нибары дистәгә якын мәкалә дөнья күрсә дә, татар укучысы шулар аркылы С. Максудиның тормышы, иҗаты турында азмы-күпме мәгълүмат алуга иреште. Ләкин югарыда искә алынган фәнни конференциянең материаллары әлегә кадәр басылып чыга алмый ята. Ә инде Садри Максудиның үз иҗатын татар мохитына кире кайтару мәсьәләсенә килсәң, хәлләр тагын да мөшкелрәк. Аның «Мәгыйшәт» исемле милли хикәясе (Казан утлары.—1994.—№ 7), «Миллият тойгысының социологик әсаслары» (Мирас.—1994.— №№ 10—12; 1995.—№№ 1—10), өстә күрсәтелгән нотыгыннан һәм гәзитә битләрендә күренгән берничә мәкаләсеннән башка хезмәтләре хәзерге заман укучысы өчен жиде йозак астында кала бирә. Ә бит ул — дистәләгән монографияләр, йөзләгән мәкаләләр авторы! Тагын шунысын искәртеп үтик: аның хезмәтләрен укучыга кайтару — татар халкының тарихы һәм милли аңын үстерү, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгыту, иҗтимагый фикеребез, милли азатлык хәрәкәте тарихындагы ак тапларны бетерү өчен дә гаять актуаль һәм әһәмиятле.

Даны дөньякүләм таралган, Сорбонна университетында, Төркия югары уку йортларында профессор, Русия Дәүләт Думалары, Төркиянең Милли мәҗлес депутатлары булып эшләгән, Милләтләр Лигасында Төркиянең вәкиле булып торган, юриспруденция өлкәсендә яңа сүз әйткән Садри Максуди 1880 елда (кайбер чыганакларда —1879) Казан артында Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала, аннан Казандагы Күлбуе мәдрәсәсендә укый. Аннан Кырымга барып чыга, И. Гаспралы белән таныша, аның яңа ысулга корылган мәктәбендә дә бераз белем ала. Аннан кире Казанга кайта, биредә 1872 елда ачылган «Русско-татарская школа»га укырга керә. Күлбуе мәдрәсәсендә бергә укыган Гаяз Исхакый да биредә икән. Алар татар матур әдәбияты белән кызыксыналар, икесе дә шәкертлек елларында ук иҗат өлкәсендә беренче тәҗрибәләрен ясыйлар. С. Максудиның өстә искә алынган «Мәгыйшәт» хикәясе шушы школада уку елларында языла.

Бу школа татар мәктәпләре өчен урыс теле укытучылары хәзерләсә дә, дипломлы белгечләр С. Максуди да, Г. Исхакый да бу юл белән китмиләр. С. Максуди үзенең белемен күтәрү өчен Төркиягә чыгып китә. Юл уңаенда ул Ясная Полянага туктый, Л. Н. Толстой белән очраша. Бер төн буе Л. Н. Толстой белән С. Максуди ниләр турында сөйләшкәннәрдер, бу безгә билгесез, ләкин бу әңгәмә эзсез үтмәгәндер. Төркиягә килеп чыккач, ул күп кенә әдипләр, зыялылар белән таныша. Алар арасында күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим Әхмәт Мидхәт тә була. Ә. Мидхәт аңа, белемен үстерү өчен, Европа югары уку йортларына укырга керергә киңәш бирә. Әнә шулай итеп, С. Максуди Парижга килеп чыга, биредә елга якын француз телен үзләштерү, башка фәннәрдән имтихан бирү өчен хәзерләнә һәм Сорбонна университетының Хокук факультетына керү өчен имтиханнарын уңышлы тапшыра. Ул Учительская школада укыган елларында ук француз әдәбияты, философлары, мәгърифәтчеләре хезмәтләрен өйрәнә. Күрәсең, Франциягә укырга бару нияте инде анда шул ук елларда тугандыр. Кырымда вакытта аңа бу киңәшне Сорбонна университетын тәмамлаган И. Гаспралы да биргән булуы ихтимал.

Сорбонна университетын С. Максуди дүрт ел эчендә уңышлы тәмамлый. Хокук факультетында уку белән бергә, университетның әдәбият факультетында да лекцияләр тыңлый. Параллель рәвештә Шәрекъ белгечләре хәзерли торган Коледж де Франже дигән югары уку йортында да укый.

Беренче урыс революциясе көннәрендә, ягъни 1906 елда Садри Максуди Париждан Казанга кайта. Югары юридик белемле яшь егет биредә барган сәяси, иҗтимагый хәрәкәт эшенә актив катнаша башлый, тиз арада ул зыялылар арасында үзенең белеме һәм прогрессив фикерләре белән танылу таба. Менә шуңа күрә ул II Дәүләт Думасына депутат итеп тә сайлана, аннан соң аны III Дәүләт Думасына да сайлыйлар. Дәүләт Думасында да Садри Максуди тиз арада актив, күренекле сәяси эшлекле булып танылa. Кыскасы, Думадагы мөселман фракциясе әгъзалары арасында Садри Максуди иң актив депутат була. Аны хәтта Думаның Эчке эшләр комиссиясенә дә әгъза итеп кертәләр, шул комиссия исеменнән Думада доклад белән дә чыгыш ясауны йөклиләр. Дәүләт Думасы трибунасын Садри Максуди патша Русиясе алып барган колониаль, милли изү сәясәтен фаш итү өчен дә оста файдалана. Аның Думада ясаган чыгышларының кайберләренең нинди темаларга багышланганын санап китик:

— Кыргыз-казакъ җирләрен талап алуга корылган сәясәтне фаш итү;
— Мөселманнар яши торган авылларда дәүләт тарафыннан аракы сатуны оештыруга протест;
— Русиянең Босфор һәм Дарданелл бугазларын басып алуга юнәлтелгән сәясәтен ачып бирү;
— Төрек — Болгария сугышында Төркиягә каршы Русиядәге төрки-мөселман халыклары катнашмаячагын күтәрү;
— Русия мәгариф министрлыгының бары урыс, христиан мәктәпләрен генә кайгыртуын, төрки мәгариф эшләренә бер тиен акча бирмәвен, ул гына да түгел, татар мәктәп-мәдрәсәләрен эзәрлекләвен фаш итү...

Хокук өлкәсендә Европа фәне мәктәбе дәрәҗәсенә ирешкән Садри Максудиның нотыклары үзләренең мантыйкый дәлиллеге белән шовинистик рухлы депутатлар арасында берәүләрнең — Пуришкевичларның җен ачуларын чыгарса, либераль карашлы депутатлар арасында исә яклау таба. Урыс шовинист депутатлары Садри Максуди чыгышларын өзәргә тырышып карыйлар, аңа сүз бирмәскә дип гауғалар күтәрәләр. (Бу нәрсәләр СССР Югары Советында Дм. Сахровка каршы коммунистлар оештырган провакацияләрне хәтерләтә.) «Поганый татарин» дип аталган Садри Максуди Дума трибунасыннан урыс шовинист депутатларына чиста француз телендә җаваплар бирергә дә мәҗбүр була. Шунысы кызык, Дума стенограммаларыннан күренгәнчә, тора-бара бу карагруһ депутатлар тешләрен кысып булса да Садри Максудиның талантлы юрист, оста оратор, күтәргән мәсьәләләрне тирән дәлилли белүен искә алып, эндәшми түзәргә мәҗбүр була башлыйлар. Думада каралган күп кенә башка мәсьәләләр буенча да Садри Максуди үзенең фикерен белдереп тора. Патша Думасында Садри Максудиның шундый активлыгы, «тыелган» мәсьәләләрне күтәреп чыгуы, царизмның милли-колониаль сәясәтен фаш итүе, аның империалистик чит ил сәясәтенең икейөзлелеген ачып бирүе — бу аның кыю, курку белмәс көрәшче икәнен дә күрсәтә. СССР Югары Советында, Россия Югары Советында исеме белән татар саналган ни хәтле депутатлар утырмады — аларның кайсысы, бу Совет трибунасына менеп, татар халкының хәзерге хәлен, аның мөстәкыйльлеген яклап чыкты соң? Андый «татар» депутатлары белән чагыштырганда, Садри Максудиның Дәүләт Думасындагы милләтләрнең азатлыгы, тигезлеге өчен көрәше, алда әйтелгәнчә, царизмның колониаль сәясәтен фаш итүе, кыюлыгы зур каһарманлык дип бәяләнергә тиеш.

Менә шуна күрә дә Садри Максудины конституцион демократлар — кадетлар үз партиясенә әгъза итеп алалар, аны Дума комиссияләренә сайлыйлар. Юкка гына Дума рәисләре О. Н. Хомяков һәм А. И. Гучковлар аның белән кул биреп күрешеп, юкка гына кадетлар партиясе лидеры, тарихчы, галим П. Милюков һәм башка күренекле урыс зыялылары Садри Максудига зур хөрмәт күрсәтмиләр.

1909 елда Англия Парламенты III Дәүләт Думасыннан егермеләп депутатын үзләренең Парламенты эшчәнлеге, Англиянең тормышы белән таныштыру өчен кунакка чакыра. Думаның 442 депутаты арасыннан Дума җитәкчеләре бу группага Садри Максудины да кертәләр. Бу делегация составында Садри Максуди бердәнбер мөселман депутаты була.

С. Максуди Дума депутатлары составында Англиягә баруын, анда күргәннәрен, үзенең төрле аудиторияләрдә нинди темаларга чыгышлар ясавын көндәлегенә терки барган һәм соңыннан аларны аерым китап итеп бастырып та чыгарган. Башта бу сәяхәтнамә абыйсы чыгара торган «Йолдыз» журналында 1909 елда басылып килә, аерым китап булып исә 1914 елда Казанда, «Өмид» типографиясендә дөнья күрә.

Бу сәяхәт Садри Максудины Англия Парламенты депутатлары арасында да абруйлы шәхес итеп таныта. Англия парламентының рәисе, Бөекбритания премьер-министры белән очрашулары да шуңа дәлил булып тора. Бу язмалардан без С. Максудиның югары дәрәҗәле дипломат, нәзакәтле һәм акыллы, Европа зәвегы ритуалларын тирән үзләштергән зыялы икәнен күрәбез. Кыскасы, Садри Максудиның Русия Думасы депутатлары арасында Англия парламентарийлары, җәмәгать эшлеклеләре, зыялылары игътибарын юкка гына җәлеп итмәгәнлеге аңлашыла.

Парламенттамы, яки башка урыннардагы очрашулардамы — кайда гына булмасын, кирәк урында ул үзенең мөселман, татар халкы улы булуын аерым бер горурлык белән сиздереп тора. Аның биредәге очрашулардагы чыгышларында татар, төрки, мөселман халыклары язмышы турында уйланулары, борчылулары, аларның киләчәге турында кайгыртуы ачык төсмерләнә.

Сәяхәтнамә Садри Максудиның эстетик, икътисади, сәяси карашларын да чагылдыра. Ул Германия, Бельгия, Англия кебек илләрнең икътисади яктан үсүенә соклана, Русиянең артка калган ил булып калуына борчыла. Европа әдәбияты, фәнен дә шактый яхшы белүе, Байрон, Дарвин турындагы фикерләре, Оксфорд университеты галимнәре турындагы күзәтүләре, биредә Тимерязев тантанасында катнашулары Садри Максудиның киң эрудицияле зыялы булуы хакында сөйлиләр. Безгә калса, бу сәяхәтнамәне татар укучысы өчен Англиягә ачкан тәрәзә дип тә бәяләргә кирәк.

1917 ел. Февраль революциясе. Яңа оештырылган революцион хөкүмәт «милли мәсьәләләр»не дә читләтеп үтә алмый. Шуннан чыгып, Урта Азияне Русия империясе составында саклап калу йөзеннән, «Төркестан комитеты» төзелә. Бу комиссиягә кадетлар партиясе исеменнән Садри Максуди да кертелә. Ләкин С. Максуди, тиз арада бу комиссияне ташлап, кире Петербургка кайта. 1917 елның маенда Мәскәүдә үткәрелгән Беренче Бөтенрусия мөселман корылтае С. Максудины Мәркәзи мөселман шурасының әгъзасы итеп сайлый. 1917 елның июлендә Казанда үткәрелгән Икенче Бөтенрусия мөселман корылтаена Садри Максуди төрки-татар халыклары өчен төзелгән «Милли-мәдәни мохтарият» программасын алып килә һәм ул Корылтайда кабул да ителә. 1917 елның 22 июлендә Казанда зур тантана белән «Эчке Русия һәм Көнбатыш себер төрек-татарлары»ның «Милли-мәдәни мохтарияте» игълан ителә, аның һәйәте дә оештырыла. Һәйәтнең рәисе итеп Садри Максуди сайлана. Аның эш урыны итеп Уфа шәһәре билгеләнә. 1917 елның 30 ноябрендә «Эчке Русия һәм Себер төрек-татарлары»ның Милли мәҗлесе чакырыла. Анда «өч нәзаралы» Милли идарә оештырыла, Милли идарәнең рәисе итеп Садри Максуди сайлана.

Ләкин Милли идарәнең, «Милли-мәдәни мохтарият»нең гомере бик кыска була. Урыннарда совет хакимияте ныгый башлагач, 1918 елның язында юкка чыгарыла, Милли идарә әгъзаларын эзәрлекләү, кулга алулар башлана.

Шушы шартларда С. Максуди белән Г. Исхакый совет хакимиятенең бу эшләренә протест белән чыгалар, Мәскәүгә барып совет хөкүмәтенә шикаять җиткерәләр... Үзләрен эзәрлекләү башланганнарын белгәч, Милли идарә әгъзаларының бер өлеше Кызылъяр аркылы Ерак Көнчыгышка юл ала, бер өлеше Финляндиягә китә...

Садри Максуди Финляндиягә барып чыга, биредә 9—10 ай буе яши, эшли, андагы татарлар белән аралаша, мөстәкыйльлек өчен көрәшүче фин эшлеклеләре белән очраша... Аннан ул Германиягә юл тота, соңрак үзенә якын Парижга барып чыга. Биредә Бөтендөнья сугышы буенча солых конференцияләре оештырыла. Версаль договоры кабул ителгәнче шундый дүрт конференция эшләп ала. Аларда Бөтендөнья сугышыннан соң Европада, дөньяда нинди тәртипләр булырга тиешлеге, сугыш нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа дәүләтләрне тану кебек мәсьәләләр дә карала. Шушы уңайдан Садри Максуди Русиядә хакимият башына килгән советларның «Эчке Русия һәм Себер төрек-татарлар милли-мәдәни мохтариятен» ябуларына, аның Милли идарәсе әгъзаларын эзәрлекләүләренә протест белдерә, конференциядән төрки-татар халкының мөстәкыйльлеген яклауны сорый. (Аның кайсы «Солых конференциясе»нә мөрәҗәгать итүе әле ачыкланмаган, ул мөрәҗәгатьнең текcты белән танышучы бер генә кешенең дә әле дә күренгәне юк.)

Тиздән С. Максудиның гаиләсе дә Финляндия аша Германиягә, аннан Франциягә килеп җитә. 1925 елларга хәтле С. Максуди Франциядә, Парижда яши. Хакимият башына коммунистлар килгәч, Русияне ташлап Франциягә качкан урыс зыялылары, элекке Дума депутатлары белән аралаша. Шул ук вакытта үзе укыган Сорбонна Университетында лекцияләр укый башлый. Германиядә башланган фәнни тикшеренү эшләрен дәвам итә. Кызы Адилә Аиданың истәлекләренә караганда, аның әтисе бу чорда көне-төне диярлек китапханәләрдә утыра. Аның төп эзләнүләре төрек-татар халыкларының тарихы, милли тел, тел һәм милләт мәсьәләләре була.

1924 елны Садри Максуди лекцияләр уку өчен Төркиягә килгәч, Мостафа Кәмал белән дә таныша. Төркия президенты аны Төркиягә күчеп килергә димли, һәм 1925 елда Садри Максуди гаиләсе белән Төркиягә күчеп килә, биредә үзенең икенче ватанын таба.

Ул илдә бара торган фәнни, иҗтимагый, мәдәни тормышта актив катнаша. Мостафа Кәмал үтенече буенча төрки халыкларның борынгы тарихын өйрәнү эшенә керешә, төрек телен камилләштерү буенча да эзләнүләр, тикшеренүләр алып бара, президентның киңәшчесе буларак та төрле рәсми очрашуларга чакырылып тора.

С. Максудиның Төркиядәге тормышы һәм эшчәнлегенә киңрәк тукталу биредә безнең максатка керми. Шулай да аның биредәге тормышы һәм эшләре турында бер-ике генә сүз булса да әйтеп үтү кирәктер. Биредә ул Ататөрек университеты Хокук факультетында, Истанбул университетында укыта, профессор исеме ала, төрле фәнни-тикшеренү оешмалары төзү буенча башлап йөрүче була, төрек телен гамәлгә кую, камилләштерү, үстерү буенча хезмәтләр яза... Ике тапкыр (1930—38) Төркиянең Милли мәҗлесенә депутат итеп сайлана... Төркия дәүләте исеменнән Милләтләр Лигасы ассамблеяләрендә катнаша, бу Лига кушуы буенча Чехословакиядә дә эшләп ала...

Садри Максуди 1957 елда Истанбул шәһәрендә вафат була. Инде алда әйтеп үтелгәнчә, Садри Максудиның бай фәнни мирасы хәзерге көнгә хәтле татар укучыларына гына түгел, хәтта аның галимнәренә дә билгеле түгел дияргә мөмкин. Аның Төркиядә аерым монография булып чыккан китаплары нигездә дүрт өлкәгә карый. Беренчесе — дәүләт һәм хокук һәм аларның тарихы: «Хокукның гомуми нигезләре» (1930), «Англиядә халык хокукы» (1937), «Хокук тарихы буенча дәресләр» (1941), «Хокук тарихы фәлсәфәсе» (1946), «Хокук фәлсәфәсе» (1946), «Гомуми хокук тарихы» (өч басма: 1944, 1946, 1948), «Төрек хокук тарихы») (1928), «Теоретик дәүләт вә лаеклы дәүләт» (1940), «Фарабинең хокук фәлсәфәсе» (1945).

Икенче өлкә: тарихи темаларга багышланган хезмәтләр. Болары «Искитләр вә сакалар» (1933), «Урта Азия төрек дәүләтләре» (1934).

Өченче өлкә: тел белеме һәм тел тарихы. Болары: «Төрек теле өчен» (1930) һ. б.

Аның аерым китап булып чыккан әсәрләре арасында өстә искә алынган «Миллият тойгысының социологик әсаслары» (1955) дигән монографиясе аерым басым ясап әйтүне сорый. Бу — дөнья әдәбиятында беренче тапкыр буларак милләтнең оешуы, яшәеше нигезен социологик яктылыкта тикшерә торган яңа сүз.

Китаплардан тыш С. Максудиның Франция гыйльми басмаларында дистәләгән фәнни мәкаләләре, татар, кырым-татар, төрек гәзитә-журналларында тарих, әдәбият, хокук вә дәүләт, тел, фәнне оештыруга караган йөзләгән фәнни-популяр, публицистик хезмәтләре басылуы билгеле. Без әлегә хәтта аларның тулы исемлеген дә белмибез.

Садри Максудиның хезмәтләрен татар укучысына кайтаруның ни хәтле әһәмияткә ия булуы турында ике төрле сүз булуы мөмкин түгел.

Садри Максудиның мирасы, беренчедән, татар-төрки юриспруденциясенең беренче, нигез ташлары. Моңа хәтле татар юридик фәне буенча бернинди хезмәт күренмәве безнең галимнәрнең ни хәтле битараф булуын күрсәтә. Дәүләте, законнары, юридик органнары булган, йөзләгән ел дәүләтчелеге булган болгар-татар халкының бу ягына игътибар итмәү — бу гафу ителмәслек күренеш, бу — безнең мөстәкыйльлек өчен көрәшебездә маяк булырга тиешле нәрсәләргә төкереп карауның үрнәге.

Садри Максудиның татар-төрки тарихы буенча, борынгы төркиләр, төрки телләр турындагы хезмәтләре гуманитар фәннәр өлкәсе өчен тарихи яктан гына түгел, фәнни-теоретик яктан да гаять әһәмиятле мирас.

«Англиягә сәяхәт»нең «Казан утлары» журналында басылып чыгуы Садри Максуди исемен торгызу өлкәсендә, аның тормышы һәм эшчәнлеген тирәнрәк аңлау өчен ярдәм итәр дип ышанасы килә. Киләчәктә, озакка сузмыйча, бу бөек милләттәшебезнең хезмәтләрен торгызу, халыкка житкерү эшенә галимнәребез, нәшриятлар да тиешле өлеш кертерләр диясе килә.

Садри Максуди — ул милләтебезнең горурлыгы. Алай гына да түгел, халкыбызның дәүләтчелек өчен көрәштә беренче органы булган Милли идарәнең рәисе дә. Хәзерге көндә милли азатлык, тигезлек өчен алып барыла торган көрәшнең чишмә башы да аның исеменә барып тоташа бит.

**Әбрар КӘРИМУЛЛИН,**
**Рәис ДАУТОВ.**

# Китапта телгә алынган кайбер шәхес һәм вакыйгаләргә кыскача белешмә-искәрмәләр[1]

*Аладьин А. Ф.* (1873—1927) — җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, 1—2 Дәүләт думалары депутаты, андагы трудовиклар фракциясен оештыручы һәм аның фактик лидеры. 1907—1916 елларда һәм Октябрьдән соң чит илдә яши. Вафаты Англиядә.

*Арсту* (Аристотель) (б. э. к. 384—322 еллар) — борынгы грек галиме һәм философы.

*Асквит* Герберт Генри (1852—1928) — инглиз дәүләт эшлеклесе, 1908—1916 елларда Англиянең премьер-министры.

*Ассурия (Ассирия)* — б. э. к. 14—7 гасырларда Азиянең көнбатыш өлешендә, Форат (Евфрат) һәм Дәҗлә (Тигр) елгалары буенда оешкан борынгы мәмләкәтләрнең берсе.

*«Әлфе ләйлә вә ләйлә»* («Мең дә бер кичә») — Урта гасыр гарәп әдәбияты ядкәре; мажаралы әкиятләр җыелмасы. Заманында бу әкиятләр Фатих Халиди тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, 1897—1899 елларда аерым-аерым алты китап булып Казанда басылып чыкканнар.

*Әфләтун (Платон)* (б. э. к. 427—347 еллар) — борынгы грек философы; фәлсәфә гыйлемендә идеализм юнәлешенә нигез салучыларның берсе.

*Байрон* (1788—1824) — мәшһүр инглиз шагыйре.

*Бальфур Артур Джеймс* (1848—1930) — инглиз дәүләт эшлеклесе, 1902—1905 елларда Англия хөкүмәте башлыгы, 1916—1919 елларда чит ил эшләре министры.

*«Биржевые ведомости»* — 1880—1917 елларда Петербургта чыккан иҗтимагый-сәяси, икътисади газета.

*Бобринский В. А.* (1867—1927) — граф, шикәр заводлары хуҗасы, 2—4 Дәүләт думалары депутаты; 1919 елда чит илгә китә.

*Бэкон Фрэнсис* (1561—1626) — инглиз философы, фәлсәфә гыйлемендә инглиз материализмы дип йөртелгән агымга нигез салучы.

*Бюлоф Бернһард* (1849—1929) — Германия дәүләт эшлеклесе, рейхсканцлер (1900—1909) һәм чит ил эшләре статс-секретаре (1897—1900).

*Веллингтон Артур Уэлсли* (1769—1852) — инглиз фельдмаршалы, Наполеонга каршы Ватерлоо сугышында союздаш илләр гаскәренә җитәкчелек иткән каһарман. 1828—1830 елларда Англиянең премьер-министры була.

*Виктория падишаһ* (1819—1901) — 1837 елдан Англия королевасы.

*Виноградов П. Г.* (1864—1925) — тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, академик (1914). 1903 елдан Англиядә Оксфорд университеты профессоры; Европа илләре, аерым алганда, Англия тарихына караган җитди фәнни хезмәтләр авторы.

*Волконский Н. С.* (1848—1910) — кенәз, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе, публицист; «17 октябрь союзы»н оештыручыларның берсе (1905), аның Үзәк комитеты әгъзасы, 1 һәм 3 нче Дәүләт думалары депутаты.

*Вольтер* (1694—1778) — француз философы һәм мәгърифәтчесе, күп санлы фәлсәфи һәм әдәби әсәрләр авторы.

*Гаспринский Исмәгыйль Мостафа улы* (1851—1914) — җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче һәм язучы; төрки халыклар арасында мәгълүм җәдитчелек хәрәкәтен башлап җибәрүче; төрки телдәге беренче (Россиядә) «Тәрҗеман» газетасенең (1883—1914) нашире һәм мөхәррире.

*Гладстон Уильям* (1809—1898) — Англиянең 1868—1874, 1880—1886 һәм 1892—1894 еллардагы премьер-министры, либераллар партиясе лидеры.

*Государственный совет* (Дәүләт советы) — 1906—1917 елларда Дәүләт думасының законнар тәкъдим һәм кабул итү хокукына ия булган югарыгы палатасы. Дәүләт советы әгъзаларының саны 180—200 тирәсендә булып, аларның яртысы өлеше патша тарафыннан билгеләнгән, ә яртысы губерна земстволары, дворян җәмгыятьләре, Синод, сәүдә, биржа, сәнагать һ. б. оешмаларның җыеннарында сайлап куелганнар.

*Грей Эдвар* (1862—1933) — Англиянең 1905—1916 еллардагы чит ил эшләре министры.

*Гөлнар ханым Лебедева* — Ольга Сергеевна Лебедева (1854—?), публицист, төрек-татар әдәбиятын русчага, рус әдәбиятын (Пушкин, Л. Толстой әсәрләрен) төрекчәгә тәрҗемә итүче.

*Гучков А. И.* (1862—1936) — җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, сәясәтче; «17 октябрь союзы» лидерларыннан берсе; 1907, 1915—1917 елларда Дәүләт советы әгъзасы, 1910—1911 елларда 3 нче Дәүләт думасы рәисе, 1917 елны исә Вакытлы хөкүмәтнең хәрби һәм диңгез флоты министры вазифаларын башкара. Октябрьдән соң Франциядә яши, вафаты да шунда.

*Гюго Виктор* (1802—1885) — мәшһүр француз язучысы.

*Дарвин Чарлз* (1809—1882) — инглиз галиме, дарвинизм тәгълиматына нигез салучы.

*Дәүләт Думасы* — 1905 елның 17 октябрь патша Манифесты нигезендә барлыкка килгән һәм законнар чыгару хокукына ия булган вәкаләтле орган. 1906—1917 еллар арасында дүрт Дума сайланып, 1 һәм 2 нче Думалар (1906—1907) патша тарафыннан, соңгы дүртенчесе 1917 елда Вакытлы хөкүмәт тарафыннан таратыла.

---

[1] «Англиягә сәяхәт» әсәре журналның ике санына бүлеп басылганлыктан, искәрмәләрне һәммәсен бергә алфавит тәртибендә ахырдан бирү кулайрак табылды.

*Дәүләт Думасында мөселман фракциясе* — Русиядәге мөселман халыкларыннан сайланган депутатлар һәр Думада үзләренә аерым фракция төзиләр. Фракция әгъзаларының саны 1 Думада — 22 кеше, 2 нче Думада — 36, өченчедә — 10, дүртенчедә — 7 кеше була.

*Диккенс Чарлз* (1812—1870) — инглиз язучысы.

*Елизавета* (1533—1603) — 1558 дән Англия королевасы. Аның идарәсе чорында Англия барлык өлкәләрдә зур үсеш кичерә һәм үзенең дөньякүләм колониаль экспансиясен башлап җибәрә.

*Ефремов И. Н.* (1866—?) — 1 нче, 3 нче һәм 4 нче Дәүләт Думалары депутаты, «Прогрессистлар партиясе» лидерларыннан берсе, 1917 елда Вакытлы хөкүмәт әгъзасы.

*Җиденче Эдуард (Эдуард VII)* (1841—1910) — 1901 елдан Англия короле.

*Җирсез Иван (Иоанн)* — 1199 елдан Англия короле. Аның заманында Европада беренче конституцияләрнең нигезе булган «Бөек хөрлек хартиясе» кабул ителә.

*Инҗил (Евангелие)* — христианнарның төп дини китабы.

*Кальвин Иоһанн* (1509—1564) — дин реформаторы.

*Католик кәлисәсе* — Германиянең Кельн шәһәрендәге тарихи собор,готик архитектура ядкәре (1248 елда төзелә башлаган).

*Кортоба (Кордова)* — X—XI йөзләрдә Пиреней ярымутравында оешкан Мөселман хәлифәлегенең башкаласы.

*Лавис Эрнест* (1842—1922) — француз тарихчысы, күптомлы «Бөтендөнья тарихы» исемле күмәк хезмәтнең мөхәррирләреннән берсе.

*Лиманов Исмәгыйль* (1870 тирәсе — 1917 дән соңрак) — җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм нашир; 1914 елда Петербургта чыккан һәм Думадагы Мөселман фракциясенең матбугат органы булган «Милләт» гәзитәсенең мөхәррире.

*Лютер Мартин* (1483—1546) — дин реформаторы, католик диненең лютеран мәзһәбенә нигез салучы.

*Маклаков В. А.* (1870—1957) —кадетлар партиясе җитәкчеләреннән, 2—4 Дәүләт Думалары депутаты, 1917 елда Вакытлы хөкүмәтнең Франциядәге илчесе.

*Мария Стюарт* (1542—1587) — Шотландия королевасы.

*Мәхмүдев Шәрәфетдин Җәләлетдин улы* (1859—1914 тән соңрак) — Эстәрлетамакта укытучы, Уфа губернасыннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты.

*Милюков П. Н.* (1859—1943) — тарихчы, публицист, кадетлар партиясе җитәкчеләреннән берсе; 3 нче һәм 4 нче Дәүләт Думалары депутаты; 1917 елда Вакытлы хөкүмәтнең чит ил эшләре министры.

*Нельсон Горацио* (1758—1805) — Франция-Испания флотына каршы диңгез сугышында җиңеп дан алган һәм шул сугышта һәлак булган инглиз адмиралы.

*Ниневия* — борынгы Ассирия мәмләкәтенең б. э. к. 8—7 гасырлардагы башкаласы.

*«Новое время»* — Петербургта 1868—1917 еллар арасында чыккан гәзитә.

*Ньютон Исаак* (1643—1727) — мәшһүр инглиз галиме.

*О'Коннол Даниэл* (1775—1847) — Ирландия милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе.

*Октябристлар* — патша хөкүмәтенең 1905 ел 17 октябрь Манифестына җавап рәвешендә оешкан эре җир биләүчеләр һәм капитал ияләре партиясе («Союз 17 октября»).

*Парнелл Чарлз-Стюарт* (1846—1891) — Ирландия милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, 1875 елдан Англия парламенты әгъзасы.

*Родичев Ф. И.* (1856—1932) — земство эшлеклесе, кадетлар партиясенең ҮК әгъзасы, 1—4 Дәүләт Думалары депутаты; 1917 елда Финляндия эшләре буенча Вакытлы хөкүмәт комиссары. Октябрьдән соң — эмигрант.

*Румнарның Төркиягә каршы истикъләл гыйсъяны...* — Сүз грекларның 1821—1929 еллар дәвамында госманлы төрекләренә каршы алып барган азатлык сугышы турында бара. Бу сугыш нәтиҗәсендә 1830 елда Греция үзенә мөстәкыйльлек яулый.

*Руссо Жан-Жак* (1712—1778) — француз философы һәм әдип.

*Сарданапал (Ашшурбанипал)* — б. э. к. 669—633 еллар арасында патшалык иткән борынгы Ассирия хөкемдары. Тарихта Мисыр, Вавилон, Элам кебек күрше мәмләкәтләргә ясаган уңышлы яулары һәм бигрәк тә чөй язулы плитә китаплар тупланган бай көтебханәсе белән данлыклы. Бу көтебханә 1849—1854 елларда Ассирия башкаласы Ниневия шәһәре хәрабәләре арасыннан табып алына.

*Сеньобос Шарль* (1854—?) — фрунцуз тарихчысы.

*Скотт Вальтер* (1771—1832) — инглиз язучысы, әдәбиятта тарихи роман жанрына нигез салучы.

*Сократ* (б. э. к. 470—399 еллар) — борынгы грек философы.

*Солсбери Роберт* (1830—1903) — Англиянең 1885—1892 һәм 1895—1902 еллардагы премьер-министры.

*Стахович М. А.* (1861—1928) — алпавыт, 1895—1907 елларда Орлов губернасы дворяннары башлыгы; «17 октябрь союзы»н оештыручыларның берсе. 1 нче һәм 2 нче Дәүләт Думалары депутаты, аннары Дәүләт Советы әгъзасы. 1917 елда — Финляндия генерал-губернаторы. Эмигрант.

*«Спектейтор»* (Күзәтче) — 1828 елдан Лондонда чыгып килә торган сәяси, икътисади, әдәби журнал.

*Суворин А. С.* (1834—1912) — журналист һәм нашир.

*Суффражисткалар* — 19 йөз ахыры һәм 20 йөз башында Англия һәм башка кайбер илләрдә хатын-кызларга сайлау хокукы даулау хәрәкәтендә катнашучыларны шулай атап йөрткәннәр. Суффраже — инглизчә сайлау хокукы дигәнне аңлата.

*Сыртланов Галиәсгар Шаһхәйдәр улы* (1847—?) — морза, адвокат, Уфа губернасыннан 1 нче һәм 2 нче Дәүләт думалары депутаты.

*«Таймс» (Замана)* — 1785 елдан Лондонда чыгып килә торган газитә.

*Тәфкилев Котлыгъмөхәммәд Батыргәрәй улы (1850—1917 дән соңрак)* — җәмәгать-сәясәт эшлеклесе, Уфа губернасында өяз дворяннары башлыгы; шул ук Уфа губернасыннан 1 нче, 2, 3 һәм 4 нче Дәүләт Думалары депутаты; андагы мөселман фракциясе җитәкчесе.

*Тимирязев К. А.* (1843—1920) — табигать белеме галиме, дарвинчы.

*Томас Мор* (1478—1535) — инглиз гуманисты һәм дәүләт эшлеклесе, «Утопия» исемле мәшһүр хыялый әсәр авторы.

*Төркия вакыйгаләре...* — Сүз 1908 елгы яшь төрекләр («Иттихад вә тәрәкъкый» оешмасы әгъзалары) революциясе һәм шуның нәтиҗәсендә 1909 елның апрелендә солтан Габделхәмиднең тәхеттән төшерелүенә бәйле вакыйгаләр турында бара.

*Трансвааль* — Көньяк Африкадагы өлкә, элекке Англия колониясе; хәзер Көньяк Африка Республикасы составына керә.

*Тукаев Мөхәммәтшакир Мөхәммәтхарис улы* (1862—1932) — дин һәм җәмәгать эшлеклесе; Эстәрлебаш мәдрәсәсе хуҗасы һәм мөдәррисе. Уфа губернасыннан 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думалары депутаты.

*Тупчыбашев Галимәрдән* (1862—1934) — җәмәгать эшлеклесе, юрист, «Иттифакъ-элмөслимин» җитәкчеләреннән; Бакудан 1 нче Дәүләт Думасы депутаты; «Каспий», «Хәят» газитәләре мөхәррире.

*Тэн Ипполит* (1828—1893) — француз философы, әдәбият белгече.

*Хәйдәрев (Гайдаров)* Ибраһим бәк Исабәк оглы (1879—?) — юл төзүче инженер, Дагъстаннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты.

*Хомяков Н. А.* (1850—1925) — «17 октябрь союзы» эшлеклеләреннән. 1886—1896 елларда Смоленск губернасы дворяннары башлыгы, 1896—1902 елларда Җир эшләре департаменты җитәкчесе; 2, 3, 4 нче Дәүләт Думалары депутаты, 1907—1910 елларда 3 нче Дәүләт Думасы рәисе.

*Хомяков А. С.* (1804—1860) — философ, язучы, шагыйрь, публицист; Петербург Фәннәр академиясе әгъзасы (1856). Н. А. Хомяковның әтисе.

*Чемберлен Джозеф* (1836—1914) — инглиз дәүләт эшлеклесе, 1895—1903 елларда Англиянең колонияләр министры.

*Шатобриан Франсуа* (1768—1848) — француз язучысы.

*Шидловский С. И.* (1861—?) — октябрист, земство эшлеклесе. 3 нче һәм 4 нче Дәүләт Думалары депутаты.



# ХУҖА НАСРЕТДИН ОНЫГЫ

Замандашларыбыз арасында төрки милләтләрдән халыкара аеруча киң танылган ике атаклы әдип бар иде. Икесенең дә тамыры татардан — берсе кырымлылардан, икенчесе казанлылардан. Әмма бик талантлы, бик мәшһүр булса, татар баласы нигәдер бик еш кына бүтән бер халыкның вәкиле һәм мактанычына әйләнеп китә. Ярый әле болары бөтенләй үк ят кавемгә сеңеп бетмәделәр, берсе — төрек, икенчесе кыргыз әдәбиятын үстерүгә хезмәт иттеләр. Быелның июле шушы ике мәшһүр каләмдәшебезнең беренчесен — Газиз Нәсинне арабыздан алып китте. Әмма аның кыйммәтле әсәрләре төрекнең һәм хәтта тулаем төркиләрнең генә түгел, егерменче йөз бөтендөнья әдәбиятының алтын хәзинәсендә дә мәртәбәле урын алды.

Соңгы дәвердә дөнья күргән белешмәләрнең берсендә (Б. Нәҗатигил. Әдәбиятыбызда исемләр сүзлеге. Истанбул. «Варлык», 1991) мин Г. Нәсиннең төрекчә басылган китапларын санап карадым: ун роман, тугыз пьеса, утыз жиде хикәя җыентыгы, жиде истәлек мәҗмугасе, дүрт әкият җыентыгы, бер памфлет китабы, алты мәзәк тупламы, ике сәяхәтнамә, дүрт шигырь мәҗмугасе, бер әңгәмәләр китабы, бер юмор анталогиясе — барысы сиксәнләп том! Шушы исемдәге китапларның беренче басмалары гына әле болар, аларга да авторның барлык әсәрләре кереп бетмәгән. Күпсанлы мәкаләләрен әйткән дә юк, хәтта байтак пьесалары да әле бу җыйнамада тупланмаган. Үзе тере чагында ук тәрҗемә ителеп, дистәләгән телдә дөнья күргән бүтән аерым басмаларын да (гарәпчәләре генә дә йөздән артык) китереп кушсак, Г. Нәсиннең укучыларына тулы бер китапханә бүләк иткәнлеге беленер.

Аның әсәрләре сыйфаты хакында исә Төркиядә казанган өч әдәби премиясе, Болгарстан, Италия, СССР, Филиппиндәге халыкара ярышларда алган беренчелеге — алты бүләге бик ачык сөйли. Кыскасы, зур иҗади байлык, чын мәгънәсендә кыйммәтле рухи хәзинә барлыкка китергән Г. Нәсин. Ничек моңа ирешкән ул? Кайсы тирәлектә туып-үскән, нинди тәрбия алган, ни рәвешле чыныккан? Язучылыктан тыш, тагын нәрсә белән шөгыльләнгән?

Шушы сорауларга җавап бирер өчен мин алтмышынчы еллардан бирле аның СССРда чыккан китапларын җыеп килдем, житмешенче елларда ун новелласын татарчага тәрҗемә иттем, киләчәктә Төркиягә барырга насыйп булса, беренче нәүбәттә Г. Нәсин белән күрешергә ниятләп куйдым. Әмма, үкенеч ки, аның иленә юлым төшсә дә, сөекле әдибем белән очрашу форсаты табылмады. Аның белән күрешүне гадәттән тыш вакыйга, үтә җаваплы эш санагангамы, Истанбулдан алтмыш чакрымдагы Чаталжага барып, мин аны иҗатыннан бүләргә базмадым. Уен-көлке, мыскыл тулы искиткеч әйбәт әсәрләр язганлыктан, ул миңа фани дөнья бәндәсе кебек тоелмый, күңелемдә һаман яшь, һаман дәртле-гайрәтле бер хикмәт иясе булып яши иде.

Нигә ашыгырга? Аның белән мәҗлес корырлык дәрәҗәдәге шәхескә әверелгәч тә өлгерермен әле, янәсе!

Бүген инде ул юк. Әмма Истанбул, Төркия турында сөйләгәндә һәм язганда, төрек халкының бер символына әйләнгән, егерменче йөз дөнья әдәбиятының иң күренекле юморчысы һәм сатиригы дәрәҗәсенә күтәрелгән бу мәшһүр затны телгә алмау гөнаһ булыр иде. Бу әле янә шуның өчен дә кирәк: фән һәм мәдәнияттәге европоцентризм Шәрекъ, шул исәптән, төрки халыклар казанышын тарихи үткәндә дә, бүген дә лаеклы рәвештә танырга, аңа тиешле бәяне бирергә бик атлыгып тормый. Тамырында яһүдилек булса... Г. Нәсин дә, Ч. Айтматов та, мөгаен, дөньядагы иң мәртәбәле әдәби бүләк — Нобель премиясен инде күптән алган булырлар иде. Г. Нәсин хаклы рәвештә белдергәнчә, аның югарылыгында иҗат итүче Европа һәм Америка язучылары турында гадәттә кычкырыбрак сөйләнә, алар күпертебрәк мактала, әсәрләре ешрак басыла җәмәгатьчелеккә кинрәк танытыла. Шулай икән, нигә әле без үзебез чын сәнгать барлыкка китерүче асыл затларыбызны лаеклы бәяләп, гаделлекне тергезергә тырышмаска тиеш?

Булачак язучы 1915 елда Истанбулдан ерак түгел бер авылда — Мәрмәрә диңгезендәге һәйбәли утравында туа. Ата-анасы аңа «ярдәм» мәгънәсен белдерә торган Мәхмәтносрәт[1] исемен куша, чөнки фәкыйрь гаилә, чыннан да, ярдәмгә бик мохтаҗ була. Ярлылыкта узачак тереклеккә Носрәтнең өч ир туганы ияләшә алмый — яшьли дөнья куялар. Носрәт исә кырыс шартларга бирешми, кытлыкка зур чыдамлык күрсәтә — исән кала. Анасы нибары 26 яшендә вафат булгач, аңа язмыш ачысын тагын да мулрак татырга туры килә. Атасы, рухы белән дәрвиш булганлыктан (соңрак шәех дәрәҗәсен казана), байлык артыннан кумый, улын заманына хас мөселманча әхлакта тәрбияләргә генә омтыла. Носрәт яшьли укырга һәвәсләнә, дини әдәбият белән бергә дөньяви әсәрләрне дә мул «йота» — Коръән аятләрен ятлый, намазларны калдырмый, гыйбадәт кыла, шул ук вакытта рәсем ясау белән дә мавыга, театр уеннары белән дә кызыксына, ун яшендә үк язучы булырга хыяллана башлый. Атасы аңа: «Тамагыңны туйдырырлык бер һөнәр үзләштер, юк белән башыңны катырма!» дип «төпле» киңәшен бирә.

Әдәбият-сәнгать белән кызыксынган малайга язмыш исә бүтән юлны әзерләп куйган була. Фәкыйрь балаларын бушлай киендереп, бушлай ашатып укыта торган уку йортлары Төркиядә бары хәрби тармакта гына булганлыктан, аякка басар өчен Носрәткә дә офицер һөнәрен сайларга туры килә — ул 1937 елда Хәрби-техник мәктәпне тәмамлый.

Яшь офицер әүвәл илнең Европа өлешендә (Тракия), аннары төньяк-көнчыгышында (Карс), соңрак Анкарада хезмәт итә. Буш вакыты табылды исә, әдәбиятка тартыла, шигырьләр һәм хикәяләр язарга һәвәсләнә. Гаскәрдә мондый эш хупланмаганлыктан, ул беренче әсәрләрен матбугатка атасы Газиз исеменнән тәкъдим итә. Төркиядә 1934 елда фамилияләр кулланышка кертелгәч, ул үзенә Нәсин, ягъни «син ни, кем?» мәгънәсендәге сүзне сайлап ала. Менә шулай Газиз Нәсин исеме пәйда була. 1944 елда ул инде үзен тулысынча әдәбиятка багышлый, әсәрләрен үз исеменнән бастырырга керешә.

Хәер, ул әле моннан соң да балачак хыялларыннан тиз генә арынып бетми — башта Нәфис сәнгать академиясенең нагыш бүлегенә укырга керә, аннары университетта белем ала башлый. Ләкин аларны ярты юлда ташларга туры килә — гаиләсен асрар өчен эшкә керергә мәҗбүр була.

Матбугат һәм азык-төлек сатучы, фотограф, хисапчы, укытучы — Г. Нәсин теләсә нинди хезмәткә алына. Әлбәттә, ул бер үк вакытта каләм кыштырдатуын да дәвам итә — гәзит-журналларда мәкалә, репортаж, фельетон, шигырь һәм хикәя, полиция һәм мәхәббәт романнары бастыра.

«Җиде көн» журналына, «Таң» гәзитенә язышып беркадәр тәҗрибә туплангач, күренекле каләмдәше С. Гали белән бергә, «Марко паша» журналын чыгарырга керешә һәм анда усал сәяси фельетоннар, памфлетлар нәшер итә. «Авылдан хатлар» башы астында үткен һәм тапкыр мәзәкче исеменнән илдәге мөһим вакыйгаларны гади кешегә аңлаешлы тел белән сурәтли, халык файдасын кайгырткан булып кыланучыларның чын йөзен ачып сала. Хакимнәр моңа озак чыдамый, «Марко паша»ны ябалар. Әмма бу басма «Мәгълүм паша», «Мәрхүм паша», «Безнең

[1] Кайбер басмаларда («Краткая литературная энциклопедия», 1 том. М., «СЭ», 1962. Бит 106; А. Несин. Эт койрыклары. Казан, Таткитнәшер, 1991. Бит 5; «Большой энциклопедический словарь», М., «СЭ», 1994. Бит 23 һ. б. /Г. Нәсиннең туган җире, чын исеме, фамилия алган елы дөрес күрсәтелмәгән.

паша» исемендә тагын терелә! Журнал чыгаручыларның икесен дә зинданга илтеп тыккач кына, «паша» тәмам җан бирә. Г. Нәсин Бурса шәһәренә сөрелә, тәүлегенә ике мәртәбә полиция бүлегендә билгеләнеп торырга тиеш була. Әмма язучы шуннан соң да «акылга утырмый», кат-кат хөкем ителеп, алты елга якын гомерен төрмә һәм сөргендә уздырып җәфалана.

Ничек кенә яхшы язмасын, мондый каләм иясе байтак нәширләрне өркетә, билгеле. Шуңа күрә Г. Нәсин шактый әсәрләрен бүтән исемнән бастырырга мәҗбүр була — аның әдәби кушаматлары бер заман ике йөздән артып китә. Шуның аркасында мәзәк хәлләр дә килеп чыккалый. Әйтик, кытайча имза куеп бастырган бер хикәясен күпмедер вакыттан соң икенче бер гәзит үз укучыларына «кытайчыдан тәрҗемә» дип тәкъдим итә. Француз исемен куеп бастырган икенче хикәясе исә «Дөнья юморы антологиясе»нә француз әдәбияты казанышы төсендә кертелә. Бары тик халыкара конкурсларда беренче урыннарны алгач кына, Г. Нәсин исеменә дә мәйдан бирелә башлый — нәшриятләр аның аерым китапларын бер-бер артлы басарга керешә.

Г. Нәсин белемен күтәрүгә, әдәби осталыгын үстерүгә даими игътибар бирә, ачлы-туклы яшәсә дә, иле тарихын, мәдәни мирасын тырышып өйрәнә, атаклы Хуҗа Насретдин һәм Бикташый мәзәкләре, Каракүз белән Хаҗи Әйват әңгәмәләре төрек халкында сатира-юморның тирән тамырлы сәнгать икәнлеген раслый. Гасырлар буе чарланып килгән көлкеле парчалар хәзерге заман мәдәнияте белән сугарылып, чәчәк атарга тиеш иде. Нәсин таланты менә шушы авыр эшне үз өстенә ала. М. Твен, Б. Шоу, Салтыков-Щедрин, Гоголь һәм бүтән язучыларның тәҗрибәсен үзләштерү аңа дөнья әдәбиятының иң югары казанышлары дәрәҗәсендә язарга ярдәм итә.

Укучылар Нәсин хикәяләрен мавыктыргыч һәм үткен телле булган өчен ошата. Автор аларда эшсезлек, җирсезлек, торак кытлыгы, идарәче даирәләрнең гади халык язмышына битарафлыгы, чит илләргә сукырларча табыну һәм башка күп мәсьәләләрне яктырта. «Фил Хәмди», «Яңа казан хөрмәтенә банкет», «Кайсы партия җиңәр?», «Үлгән ишәк», «Афәрин» һәм бүтән хикәяләрендә Төркия тормышының шыксыз яклары сатира утында көйдерелә, иҗтимагый һәм шәхси тормыш каршылыкларын чагылдыра.

Х. Туфан бервакыт безгә килгәч, шәхси китапханәмдәге төрки әдәбиятларның асыл нөсхә әсәрләре белән кызыксынып, Г. Нәсин, Ч. Айтматов, К. Кулиев китапларын актарып утырган иде.

— Карале, Тәүфикъ, бу Нәсин Төркияне, төрек халкын гел яманлап гәүдәләндерә. Безнең илдә аның китапларын шуның өчен генә еш-еш бастырмыйлармы икән? Нәсин әсәрләре укучыларда төрек халкы турында ялгыш фикер тудырмыймы? Төркияне кимсетү, аның дәрәҗәсен төшерүгә хезмәт итмиме икән алар? — дигән иде.

Мин ул чакта мәгълүм бер фикер иясенең сүзләрен кабатладым: «Һәр җитлеккән халык үз кимчелекләреннән көлә-көлә аерыла. Әдәбиятында юмор-сатира жанрының үсеше шул милләтнең җитлеккәнлеген дә күрсәтә», янәсе.

Шунысы кызык, Төркия хакимияте дә Г. Нәсинне заманында илнең һәм халыкның яманатын сатуда гаепләде, шуңа ышанучылар элек тә булды, хәзер дә бар әле!

Автор исә үзе шундый гаепләүләрне истә тотып, ахры, болай дигән иде: «Хикәяләремдә хәзерге Төркиянең иҗтимагый күренешен сурәтләргә тырышам. Бу эшкә алынганмын икән, төрек хезмәт ияләре вәкиле буларак, кешеләрнең һәм вакыйгаларның иҗтимагый бәлаләрен ачарга телим... Чөнки мине үстергән халкыма үземне һәмишә бурычлы саныйм. Халыкка якынлашуның һәм халык арасында танылуның иң тәэсирле чарасы булганлыктан, юморны бер халык сәнгате кебек кабул иттем. Халкымнан алганымны хикәяләрем төсендә янә халкыма кайтарам. Бары көлдерер өчен генә әсәр язмадым, кешеләрнең күзен ачарга теләдем... Күп кенә хикәяләрем — күз яшьләремнән тупланган ачы каһкаһәләрем. Кыскасы, хикәяләремне аңлап көлсеннәр, көлә-көлә аңласыннар» (Г. Нәсин. Кор дөйүшү. Бакы, «Әзәрнәшер», 1968. Бит 8.).

Чыннан да, төрек халык сатирасы кебек, Нәсин әсәрләре дә күпчелекне яклый, күпчелеккә хезмәт итә. Аның иҗтимагый кыйммәте менә шунлыктан да гаять зур. Язучының сатирасы гади кешеләргә хокук һәм ирек яулап алу, аны саклауга булыша. Аның әсәрләрендә югары әхлак оятсызлык белән көрәшә, хакыйкать ялганны мәсхәрәли, эчкерсезлек икейөзлелекне, киңлек тарлыкны җиңә, яңалык искелеккә һөҗүм итә. Менә шуңа күрә дә Нәсин иҗаты төрле милләт укучыларына якын һәм бик кадерле.

Нәсин әсәрләрендә, көлке белән янәшә, һәрчак фикер яши. Фикер йөртү

еш кына көлкедән калкурак та була. Чөнки язучы сатираны үтә житди һәм көчле бер корал дип исәпли. Тормыштагы гаделсезлек белән, төрле тискәре сыйфатлар, хорафатлар белән көрәшү өчен аны бар егәрлегенә эшкә жигәргә тырыша. Әйтергә кирәк, ул бу юлда байтак уңышларга ирешә. Төркиянең «Дус» журналы 1968 елгы дүрт санын Г. Нәсингә багышлап чыгару да шул хакта сөйли. Анда атаклы әдипләр, шагыйрьләр һәм драматурглар бертавыштан:

— Жәмгыятебез — сатирик һәм юморчы әдип өчен менә дигән лаборатория, Г. Нәсин ул лабораториядә бик әйбәт эшләп килә.

— Газиз Нәсин — үткен каләм остасы, аның әсәрләре бүгенге Төркия тормышындагы барлык күренешләрнең көзгесе,— дип белдерделәр.

Тәнкыйтьче Үнгәрән исә:

— Газиз Нәсин хикәяләре киләчәктә илебез тарихының билгеле бер дәверен өйрәнү өчен бәя биреп бетергесез әһәмияткә, Мисыр папируслары кебек кыйммәткә ия документ булачак,— дип раслый.

Болай укучылар ихтирамын казануның сере — осталыкта. Хикәяләрендә язучының үзенчәлекле таланты алмаз кебек бөтен кырлары белән ялтырый: әле мутланып елмая, әле үтергеч мыскыл нуры булып кабына. Үткен гротеск, реалистик сурәтләү, халыкчан наянлыкны Нәсин бик уңышлы куллана. Аның осталыгы елдан-ел арта, фәлсәфи фикере елдан-ел тирәнәя, каләм шомара, күзе жетерәк күрә, хыялы биек-биекләргә күтәрелә, сәнгать чаралары байый. Аның шулай ижади житлегүе, алдарак телгә алганымча, төрле жанрларда уңышлы эшләргә мөмкинлек бирә. «Хатынша ир», «Футбол короле Сәет Хупсәет», «Ирдәүкә Сәбәхәт», «Хәзерге балалар — даһи», «Язмышнамә», «Яшәр ни йөшәр, ни йөшәмәс», «Бер юл»...— бу романнарның һәркайсы туган илендә дә, чит мәмләкәтләрдә дә кат-кат басылды инде. Аның пьесалары исә Австрия, АКШ, Болгарстан, Венгрия, ГФР, Польша, Румыйния, Франция, Чехия, Югославия һәм бүтән илләрнең сәхнәләрендә уйнала. Тамашачылар бу пьесаларның психологик нечкәлегенә, тирән фәлсәфилегенә, форма ягыннан яңалыгына игътибар итә һәм кул чаба. Нәсиннең егерме бишкә житкән сәхнә әсәрләре радио-телевидение тапшыруларында да еш файдаланыла.

Нәсин, балачагында гарәп хәрефләренә күнеккәнлектән, башта әсәрләрен шул шрифттә яза, аннары аларны каткат төзәтә һәм бары шуннан соң гына машинкада латинга күчерә. Ижатының беренче дәверендә аңа ашыгырга туры килә, вакытлы матбугатта килешү буенча эшләгәнлектән — көн саен бер хикәя яки мәкалә язарга тиеш булганлыктан, «пешеп» житмәгән әсәрләрен дә бастырырга туры килә. Әмма соңрак, тамак ягы тәэмин ителгәч, нокта куйган әсәрен шундук укучыларга тәкъдим итәргә ашыкмый башлый, автор аларга яңа ижат ялкынын өстәгәнче, кайберләре еллар буе чиратын көтеп ята! Каторга хезмәте!

— Шагыйрь ялкау да була ала, илһам килгәндә генә каләмгә тотына ала, аның эше кайвакыт әнә шулай да пешергә мөмкин. Ләкин әдип, драматург язмышы бүтән. Алар күпләр белән аралашырга, өзлексез укырга һәм язарга, язганны төзәтергә, женләнергә, тагын-тагын жиң сызганып утырырга тиеш,— ди Г. Нәсин.

Төркиядә әдәби әсәрләр дә баса торган меңләгән гәзит һәм журнал чыга, кибет киштәләренә ел саен 1200 исемдә әдәби китап өстәлеп тора. Әдәби оешмаларга берләшкән язучыларның саны 400 дән аша, алардан тыш каләм тибрәтүчеләр дә аз түгел. Шуның өстенә халык күңелендә җуелмас урын ала торган классик мирасны, дөнья әдәбияты жәүһәрләрен дә онытмыйк. Менә шушы матбугат диңгезендә әсәрең югалып калмасын, бүтәннәр арасында исемең телдән төшмәсен өчен бөтен тырышлыгыңны һәм сәләтеңне бергә туплау һәм армый-талмый эшләү генә каләм иясенә уңыш китерергә мөмкин.

Нәсин моны бик яхшы белә һәм дистә еллар буе ял көннәре, бәйрәм көннәре барлыгын да онытып, ижатка бирелә. Тик ул һаман канәгать түгел: «Икенче тапкыр тусам, хәзергегә караганда шактый күбрәк һәм шактый әйбәтрәк эшләр идем» (А. Несин. Избранное. М., «Наука», 1974. Бит 278),— ди.

Әмма Г. Нәсин бары ижат эше белән генә чикләнә торган шәхес түгел. Ул үзе дә яңа журналларга нигез сала, хәтта китап нәшрияте дә оештыра. Каләмдәшләре белән очраша, Төркия язучылары синдикатын барлыкка китерә һәм аның беренче рәисе итеп сайлана, тынычлыкны саклау, халыкара хезмәттәшлекне үстерү хәрәкәтендә актив катнаша, төрле илләргә сәяхәтләргә чыга. Ләкин аны, әлбәттә, төрек мәдәнияте үсеше мәсьәләләре аеруча нык кызыксындыра, ул шушы өлкәне алга жибәрү өчен сәләтен дә, малын да кызганмый. Шуның бер мисалын 1972 елда «Нәсин вакыфы»н оештыруда күрәбез.

Әсәрләре зур тиражлар белән чит илләрдә басылу һәм күп кенә халыкара премияләр белән бүләкләнү әдипне ярлылыктан чыгара. Заманында фәкыйрьлекне мул татыган Нәсин кеременең бер өлешен ел саен дүрт ятимне үз карамагына алып, аларны берәр һөнәр үзләштергәнче яки югары белем алганчы тәрбияләргә карар бирә. Чаталжада жир сатып алып, анда дүрт катлы ташпулат кора, бакча утырта. Хәзер аның вакыфы карамагында 34 бала тәрбияләнә. «Нәсин вакыфы», моннан тыш, кайбер төрек язучыларының әсәрләрен бастыру, 1976 елдан бирле Төркия әдәбияты көзгесенә әйләнгән энциклопедик эчтәлектәге «Елнамә»ләр чыгаруга да көчен түгә. Бу эшне башкаруда үзе дә җиң сызганып катнаша, шуна җәмәгатьчелекне дә җәлеп итә. Ул үзенең ихтимал каләм хакының төп өлешен, туплаган малын алдан ук вакыфына васыять итеп куя. Хәләл тырышлыгы белән тупланган хәзинәсен! Мисалга, бары 1977 елда гына да АКШ, Албания, ГФР, Греция, Иран, Румыйния, Швеция, Югославиядә аның унбер китабы дөнья күрә, әнә шундыйлардан җыелган табышны халкына бүләк итә язучы.

Г. Нәсин сиксән елга сузылган озын гомерен киеренке халәттә яши. Табигый ки, дөньяга карашын да, заманына, белеме һәм тәҗрибәсе артуына бәйле рәвештә, байтак үзгәртә килә. Мәсәлән, ул утыз яшендә Коръән тәрҗемәсен укый һәм диннән, аерым алганда, исламнан шактый суына. Бер ара социализмның күпертелгән уңышлары, марксчылар пропагандасы тәэсирендә, Төркиянең алга килешен дә сыйнфый көрәштә хезмәт ияләре җиңүенә бәйләп карый башлый, иҗатында өстен сыйныфларны фаш итү белән мавыга. Сәлман Рөшдинең «Иблис аятьләре» әсәрен төрек телендә басуга катнашып, күп кенә ватандашларының бәддогасына дучар була. Г. Нәсин ике мәртәбә өйләнә, дүрт бала үстерә, шуларның берсе — ислам, берсе — христиан динен тота, икесе — аталары кебек, атеист, ягъни динсез («Аксиюн» ж., 1995. № 12. Бит 39. Истанбул). Соңгы дәвердә марксизм гамәле һәлакәткә очрады, социализм төзегән илләр исә кире капитализмга юл тота башлады, сыйнфый көрәшнең кешелекне бәхеткә илтмәвен таныды, алардагы һәр милләт үзенең элекке динен кайтарырга керешә. Төркиядә дә диннең көчәя баруы күзәтелә. Менә шушы шартларда Газиз Нәсин кешенең вөҗдан иреген, дин тоту яки тотмау хөрриятен яклаган хәлдә, диннәрнең кеше тормышындагы әһәмиятен, уңай ролен, ислам диненең исә, соңгы заманда барлыкка килгәнлектән, бүтән диннәрдән камилрәк булуын танып, европоцентристларның һәм АКШ ның «мөселман фундаментализмы» дип чаң кагуында милли, расачыл һәм христианлык фундаментализмы гәүдәләнүен игълан итте.

Нәсинне күреп белгәннәрнең сөйләвенчә, аның китап шүрлекләре төрле милләт язучыларының әсәрләре белән тулы. Кунакларын ул һинд, кытай, грузин, цейлон чәйләрен үзе катнаштырып ясаган эчемлек белән сыйларга ярата, аның өендә төрле ил, төрле раса, төрле дин кешеләре еш була. Ул теге яки бу фанатизмга каршы, халыкларның һәм дәүләтләрнең аңлашып, тату яшәүләрен тели, тигез хокуклылыкка, яхшы күңеллелекне яклый.

Истанбул белән танышып йөргәндә мин Азия белән Европаны тоташтырган асылма күпердән көньякка, кояшта ялтырап яткан Мәрмәрә диңгезенә карап хозурланып тордым. Шунда, зәңгәр офыклар артында, Г. Нәсин туган һәйбәли утравы да булырга тиеш иде. Ике кыйтга арасындагы утрау! Истанбулда йөргәндә мин ватанымдагыга охшамаган байтак күренешләрне, кешеләрне тамаша кылдым, әмма алар миңа һич тә ят тоелмады. Чөнки мин инде алар белән Г. Нәсин әсәрләре аша таныш идем. Ул әсәрләр элекке СССРның унбишләп телендә кырык мәртәбә чамасы басылган, шул исәптән, татар телендә дә аның «Эт койрыклары» исемле җыентыгы нәшер ителгән иде. Билгеле, Газиз Нәсинне татар укучысына таныту эше әле башлангыч баскычында гына. Замандашларыбызны матуррак һәм яхшырак яшәргә өйрәтә, намуслы һәм гадел булырга өнди торган сәнгатьчә камил әсәрләрнең кыйммәте беркайчан да җуелмас. Бөек төрек кардәшебезнең кайнар йөрәк тибешеннән барлыкка килгән тылсымлы дөнья безне тугандаш Төркия белән якыннанрак танышырга, аны яратырга булышыр, адәм баласының киң кырлы тереклеген танып-белергә, үз кимчелекләребезне тоярга ярдәм итәр. Нәсин иҗаты белән танышкан укучы акыллырак, зирәгрәк, хуш күңеллерәк кешегә әверелер. Чөнки без Хуҗа Насретдин мәзәкләрен нәкъ менә шуның өчен укып, сөйләп килдәбез. Газиз Нәсин исә шушы халык каһарманының оныгы гына түгел, заманыбызның Хуҗа Насретдины да иде.

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

## Газиз Нәсин

# Фил Хәмди

Истанбул хәвефсезлек идарәсеннән бер көнне барлык виләятләргә[1] менә мондый эчтәлектәге телеграммалар сугылды:

«Фил Хәмди» кушаматлы төзелмәслек ата карак качты. Утыз биш яшьтә, озын буйлы, авырлыгы ике йөз килограмм, коңгырт чәчле, өч теше төшкән, өске казнасында бер азау теше пломбаланган, аскы сул казык тешенә алтын коронка куйдырылган, костюмы коңгырт буй-буй, чәче сирәк, йөзе түгәрәк, күзләре коңгырт кара. Ике полицейскиебезнең каравылда өч көн, өч төн алмашсыз торуы аркасында аягүрә йокыга китүеннән файдаланып, җинаятьче юкка чыкты. Безнең тарафтан үткәрелгән сорау алу, тикшерү һәм тәфтишләү нәтиҗәсендә Фил Хәмдинең качуы тулысынча расланды. Әгәр ул виләятегезнең яки аңа карый торган өязнең берәр полиция участогына керсә яки нинди дә булса белешмә сорап полиция хезмәткәренә мөрәҗәгать итсә, аны түземсезлек белән көтүебезне һәм безне моннан соң зарыктырмавын, уңайлы буш вакытында Истанбул хәвефсезлек идарәсенә килүен һәм бирелүен үтенүебезне үзенә хәбәр итегез. Төзәлмәс ата карак Фил Хәмдинең фоторәсеме шушы телеграммага теркәп җибәрелә».

* * *

Бер виләятнең вокзалында ике полиция хезмәткәре басып тора иде.

— Рамазан, малай, әнә теге кесәл эчүче бәндә, мөгаен, Фил Хәмдидер әле,— диде аларның берсе.

— Һемм... Охшаган шул... Яле, фотосын карыйк әле.

Икенчесе кесәсеннән фоторәсем чыгарып, иптәшенә күрсәтте.

— Нәрсә баш катырасың, Рамазан? Үз сурәтең ич бу!

— Чынлап та! Мин аны бер бәйрәм көнне төшкән идем шул. Әйбәт чыкканмы?

— Әйбәт. Тик син Фил Хәмди фотосын да күрсәт инде.

Рамазан кесәсеннән бер төргәк фоторәсем чыгарып актара башлады.

— Менә бусы — улым картечкәсе... Әрме истәлегем... Ә менә бусын кем диярсең икән, Мәхмүт?

— Бусымы? Мөгаен... контрабандачы Думан Галидер!

— Ә менә монысы — Сөбхи кунакханәсендәге күсе... Бөтен картечкәләр буталып беткән.

— Рамазан, син әлеге Филне тизрәк тап инде!

Мәхмүт белән Рамазан икәүләшеп чаштыр-чоштыр Фил Хәмди фоторәсемен эзләргә керештеләр.

— Тизрәк кайнаш, Мәхмүт. Теге бәндә кесәлен эчеп бетерде инде, хәзер шылачак! Як-ягына карануын гына күр әле.

— Таптым, менә картечкәсе. Нәкъ үзе, суйган да каплаган!

Алар шикле күренгән кеше янына якынлаштылар.

— Әй, якташ, тукта әле!

Алар бер фоторәсемгә, бер әлеге кешегә карадылар.

— Яле, ян белән бас әле!

— Охшамаган бугай ла бу, Рамазан.

---

[1] Виләят — Төркиядә өлкә.

— Комиссар әфәнде дә бер күз төшереп алсын әле, бәлки ул таныр.
— Киттек, якташ, кузгал әйдә. Безнең белән участокка марш!

* * *

Икенче виләяттә ике полицейский базарда гәпләшеп тора иде.
— Ояты нинди бит, Шөкри агай-эне, ояты. Кичкә кадәр тарсылдап йөргүен йөрдек, әмма әлеге Фил Хәмдине тота алмадык.
— Ә бәлки менә бу бәндә шулдыр?
— Бәлки шулдыр да, әйдә, сорашыйк әле.
— Әфәндем, синең исемең кем?
— Мостафа.
Полицейскийлар үзара пышылдашты:
— «Мостафа», ди.
— Ул сиңа туп туры: «Мин — Фил Хәмди», — димәс инде.
— Әйе шул, мондый кеше бездәйләрне төп башына утыртып калдыруны нигә дә санамаска тиеш.
— Әфәндем, безнең белән бер җиргә кереп чыгыйк әле?

* * *

Ерак виләяттәге бер каһвәхәнәдә ике полицейский аһ-зарларын уртаклашып утыра иде:
— Мин кичә өч Фил Хәмдине эләктердем, ә комиссарга, күр әле син аны, берсе дә ошамады.
— Үз комиссарыбыз булса да, турысын әйтим, шундый вакчыл!
— Шыпырт! Чәй эчүче әнә теге бәндәгә күз сал әле.
— Булмас ла, чү... әйе, шул үзе ләбаса!
— Әйе, тик телеграммада «юан» диелгән, ә бу, кыяфәтсез, чыра кебек ябык.
— Ябыгырсың, агай-эне. Яшеренеп йөрү рәхәтме әллә?
— Анысы да дөрес... Тик... бу — кара чутыр. Фил Хәмдине «коңгырт чәчле» дигәннәр иде бугай.
— Тау-таш, чокыр-чакырлар арасында посып йөргәндер дә... каралгандыр.
— Анысы да хак. Тик аның чәчләре артык кара, җитмәсә, куе. Телеграммада Фил Хәмдинең «чәчләре коелган» дигәннәр иде бугай?
— Егет үзен танытмас өчен парик кигәндер әле.
— Нәрсә дип болай аптырадык соң әле без? Каптырыйк әйдә алдакчыны!
Алар елдам гына шул кеше янына килеп басты.
— Ни атлы син, егеткәй?
— Хәмди.
Полицейскилар бер-берсенә мәгънәле карашып, көлеп җибәрделәр.
— Хуп, киттек әйдә участокка. Мыштырдама!
— Нәрсә дисез? Миңа әйтәсезме сез?
— Сиңа инде, сиңа.
— Ни булды, нишләп әле мин анда барырга тиеш?
— Күп лыгырдама. Участокта белерсең, җәлт әйдә!

* * *

Барлык виләятләрдәге кебек, берничә чакрымга сузылган бер олы юлда ике полицейский бер юлаучыны туктатты.
— Авызыңны ач әле, илдәш!
— Авызымда берни дә юк минем.
— Булмагач, киреләнми генә ача бир инде!

Юлаучы авызын ачты. Аның тешләренә төбәлгән полицейскиләрнең берсе икенчесеннән:

— Яле, кәгазьгә кара әле, Филнең ничә теше җитми икән?— диде.

Тегесе укый башлады:

«Өч теше җитми, өске казнасында бер азау теше пломбаланган. Аскы сул казык тешенә алтын коронка куелган...»

Полицейский юлаучының тешләрен санарга тотынды:

— Бер, ике, өч, дүрт... Кыбырсымый гына тор әле! Тагын саташтым! Бер, ике, өч, дүрт, биш... егерме дүрт! Егерме дүрт теше бар икән.

— Егерме дүрт? Ничәсе җитми соң? Ничә тешең җитми, илдәш, беләсеңме?

— Сигезе.

— Суырткан! Танымасыннар өчен тешләрен суырткан бәндәкәем.

— Полицейский әфәнде, минем тешләрем ясалма ич. Берсе дә үземнеке түгел.

— Кара әле, кәгазьдә анда ни диелгән? Ясалма теш хакында берәр нәрсә әйтелгәнме?

— Язылмаган. Онытканнар. Шул, җаныкаем, шул! Нәкъ үзе, Фил! Күрәк тешен генә кара әле син аның, алтын коронкалы ич. Әйдәле, әфәндем, безнең белән.

— Кая?

— Участокка. Кыймылда җәтрәк!

* * *

Виләятләрнең хәвефсезлек идарәләреннән Истанбулга көне буе менә шушындый телеграммалар агылды:

— Фәләненче көнге фәләненче телеграммагызга җавап.

Безнең виләяттә ундүрт Хәмди тотылды, ундүрте дә буй-буй коңгырт костюмнан, сигезенең алгы теше алтын коронкалы. Шушы санның таләпләрегезне канәгатьләндерүе яки эзләвебезне дәвам итү кирәклеге хакында әмер бирүегезне түбәнчелек белән үтенәм».

«Фәләненче көнге фәләненче телеграммагызга җавап.

Безнең виләяттә 180 нән алып 220 килограммга кадәр авырлыктагы ике дистә Фил Хәмди тотылды. Авырлык аермасы үлчәүләрнең төгәлсезлеге аркасындадыр, дип уйлыйбыз. Барысының да күзләре коңгырт-кара, һәммәсенең дә Фил Хәмди булуына шикләнмибез. Тотылганнарны сак астында сезгә җибәрдек. Тотылмаганнарын җентекләп эзли һәм кулга төшкән берен сезгә озатачагыбыз турында ихтирам белән хәбәр итәбез»...

* * *

Истанбул хәвефсезлек идарәсенең виләятләргә җибәргән телеграммасы:

«Зиндан камералары шыгрым тулды, кулга алынган Фил Хәмдиләр саны җитәрлек дип табылды.

Сезгә рәхмәтләребезне белдерәбез һәм нәүбәттәге әмерне алганчы Фил Хәмдиләрне эзләү, кулга алуны туктатырга тәкъдим итәбез.

Искәрмә. Качкан Фил Хәмди тотылды».

## Казан кую тантанасы

Беренче кеше:

— Рәхим итегез, әфәндем, үтенәм, менә монда килеп басыгыз. Без журналистларны ифрат та хөрмәт итәбез. Әй-йе-е...

Икенче:

— Тәбрик итәм, бәй әфәндем.

Өченче:

— Рәхмәт. Тик мин аңламыйм әле, Сез мине ни өчен тәбрик итәсез?

— Яңа казан куелу уңаеннан...

— Ә-ә-ә, әйе-әйе. Бүген монда казан куялар ич әле. Казансыз булмый шул, бәй әфәндем. Казан үтә кирәкле шәйдер...

— Буфетка да рәхим итегез... Бер шешә шифалы су! Вилаять рәисе дә хөрмәт күрсәтергә булды әле, менә-менә килеп җитәр дип торабыз.

Дүртенче:

— Сезнең белән кайдадыр очрашкан идек сыман, тик кайда?

Бишенче:

— Сезнең йөзегез дә миңа таныш тоела. Кайдадыр күрешкән идек бугай. Туктагыз, тукта, сез мал сую ширкәтенең яңа корылган капкасын ачу тантанасында катнашмадыгызмы?

— Кызганыч ки, юк шул... Әфәндем, мәҗлесләрне бер үк көнне ясыйлар да, һәммәсенә өлгерә алмый калабыз. Мин ул көнне пыяла заводында яңа морҗа чыгарылу хөрмәтенә оештырылган тантанага барган идем.

— Аһ, бәй-әфәндем, мин ул банкетка эләгә алмадым шул. Иптәшләрем сөйләвенчә, анда кыздырылган чиркәс тавыгы белән сыйлаганнар икән. Кешенең берьюлы ике җиргә җитешә алмавы кызганыч.

— Ниһаять... исемә төште, Сез Япониядән сатып алынган кораб хөрмәтенә...

— Әйе шул, шуның тантанасына килгән идем. Мин дә Сезне хәтеремә төшердем. Ул көнне Сез кремлы торт кына ашавыгыз белән дикъкатемне тарткан идегез.

— Дөрес, дөрес... Бик ошаткан идем шуны. Әфәндем, аннан элекке тантанада чамадан тышрак сыйланганлыктан, яраткан итле ризыкларыма үрелә алмадым.

Алтынчы:

— Нинди казан куялар икән?

Җиденче:

— Валлаһи, белмим... Казан инде... Кер кайнату казаны түгел һәрхәлдә...

— Тәмле булсын! Мине ашказаным җәфалый әле, саруым кайный.

— Минем дә шулай, бәй әфәндем. Соңгы вакытта һәркем ашказаныннан зарлана. Йогышлы чирмени. Мин хәзер янымда һәрвакыт сода йөртәм, теләсәгез, Сезгә дә бер чеметем бирәм, йотып җибәрегез.

— Ай, рәхмәт! Моннан соң мин дә кесәмә сода салып йөрергә тырышыйм әле... У-у-уыэ...

— Җиңеләйттеме бераз, бәй әфәндем? Кикерү хәерлегә.

— У-у-уыэ! У-у-у-уыэ! Кыздырылган күркәләре бигрәк тәмле икән, авыз иттегезме? Боерыгыз!

— Рәхмәт! Мин бәлешне яратарак бирәм.

Сигезенче:

— Теге юан зат кем ул?

Тугызынчы:

— Кайсысы? Виски эчүчеме?

— Юк, башкасы.

— Банан ашаучымы?

— Юк ла инде, бүтәне.

— Салкын ит чәйнәүчеме?

— Аның янәшәсендә кулын сузганы...

— Ә-ә-ә... Белмим, үзен гел күргәлим дә бит...

Берәү:

— Эш тантана уздыруда гына түгел... Бу тантаналар бары сылтау гына...

Бүтән берәү:

— Моңа кем шөбһәләнә? Бу банкетлар да булмаса, күрешә дә алмас идек, валлаһи... Әфәндем, элек, балачагымда, әткә мәрхүм мине, кулымнан җитәкләп, һәр көнне берәр дәрвиш хөҗрәсенә алып бара иде. Дүшәмбедә — Өскедардагы Руфаи чатырына, сишәмбедә Касыймпашадагы Нәкъшибәндә куышына, чәршәмбедә — Чүреклектәге Кадыйри тәккәсенә, кече атна көнне — Мәүлана тавындагы ханәгә. Алланың һәр бирмеш көне — бер тәккәгә. Әйе-әйе. Нинди генә сыйлар татымый идек без анда. Җиз табаклар тулы тәм-том...

— Максат ашауда гына түгел, билгеле, мәхәббәт...

— Әлбәттә-ә-ә... Бавырга ни өчен бер дә сузылмыйсыз?

— Мин тулмага хиресрәк. Шәп, бик тәмле пешергәннәр.

— Нәрсә фабрикасы булачак икән бу, бәй әфәндем?

— Валлаһи, юньләп белмим. Машиналарына караганда, мөгаен, машина фабрикасыдыр.

— Сөбханалла, нинди зур корылма!

— Әфәндем, ничек кенә булмасын, мәдәният барыбер алга китә. Киңәш итеп әйтәм, фаршланган балыклары телеңне йотарлык...

— Бүтән банкеттагы сыйга да урын калдырам әле. Тагын бер тантанага барасым бар иде.

— Аңа кадәр сеңеп бетә ул, бәй әфәндем. Тантана дисезме? Миңа да ярар иде ул.

— Ә-ә-ә, ярый шул... Рәхим итегез!

— Әфәндем, кеше икегә ярыла алмый, кайбер банкетларга бармаска да туры килә инде.

— Шул шул. Күптән түгел гәзитләр, «АКШ безгә атом реакторы бирәчәк», дип язган иде. Бу корылма яңа атом фабрикабыз түгелме икән?

— Монда казан-мазан дип лаф органнар иде аны.

— Алга барырга, тәрәккый итәргә кирәк безгә, бәй әфәндем. Эшләргә һәм җиңәргә!

Бер кемсә:

— Тасманы кисәчәкләрме?

Бүтән бер кемсә:

— Галиҗәнап виләят рәисен көтәләр икән.

— Бу фабриканың хуҗасы кем икән, бәй әфәндем?

— Американ бугай.

— Булмас. Американнар мондый мәҗлес ясап ятмас. Бу фабриканың безнеке икәнлегенә шикләнмим. Тик кызык, монополияләр идарәсенекеме ул, әллә су хуҗалыгыныкымы?

— Әйттегез сүз. Суны фабрикаларда ясыйлармыни? Чыннан да, нәрсә фабрикасы булыр икән бу?

— Казан фабрикасы...

— Алайса монополияләр идарәсенеке инде. Димәк, аракы казаны икән... Әнә теге кешене һәр тантанада күрәм мин.

— Түр башындагылар кемнәр?

— Депутатлар... Сез әлеге ни... ачу тантанасына да киләчәксезме?

— Әлбәттә. Бармасаң уңайсыз. Бадам чикләвекләре күгәрчен икән, игътибар иттегезме?

Берәү:

— Мәмләкәтебезнең чәчәк атуы фабрикалар коруга бәйле, кардәшем.

Икенче берәү:

— Һәр көнне бер фабрика ачыла икән... Кыслалары искиткеч тәмле...

— Сез кичәге тантанада бирелгән кысланы ашап караган булсагыз икән! Бу кем баласы? Сезнекеме? Алланың рәхмәте төшкере!

— Шул исәптән, безгә дә.

— Ал, улым, ал, алма телисеңме, әфлисунмы? Әллә пирожныймы? Аша, балакай...

— Чү-ү-ү, әнә нинди мөхтәрәм бәй әфәнде килде.

— Кем соң ул?
— Белмим. Бәлки берәр фабриканың хуҗасыдыр, ә бәлки министрның үзедер?
— Баш директорга охшаган. Әйе, мин Сезне әллә кайчаннан бирле таныйм, һәр тантанада, һәр банкетта очрашабыз. Кызыксынуымны гаеп итә күрмәгез, ни белән шөгыльләнәсез Сез?
— Минме?.. Э-э-э... бәй әфәндем, тантананы ачалар, ахры, чыгышларына колак салыйк әле.
Нотыкчы:
— Хөрмәтле илдәшләр! Бүген мин сезне (чәнечке-пычаклар чыңлый), шушы тантанада катнашучы һәркайсыгызны, Тәзгәһтара электр станциясенең дүртенче казанын сафка бастыру уңае белән чын күңелемнән котлыйм. Бу казанны, АКШтан һичбер ярдәм алмастан, үз көчебез белән монтажладык. Мажар милли футбол командасын «өч:бер» исәбе белән җиңгән омтылышыбыз, гайрәтебез монда да үзен күрсәтте — казанны учак өстенә куйганда, америкалы өч конструктор, ике инженер, дүрт техниктан башка һичбер чит ил ярдәме кирәк булмады, мәзкүр казаныбыз тиешле урында үз көчебез белән урнаштырылды. Шуны да әйтеп китик, казан урынына куелганнан соң, эчендәге суның ни өчен кайнамау сәбәбен тикшергәч, мичнең казаннан алты метр кырыйдарак калуы беленде. Казан күчерергә авыр булганлыктан, белгечләр аның астына яңа мич чыгаруны отышлырак санады. Бу казан — Якын Көнчыгыш һәм Балкан илләренең иң олы казаны. Бакыр казаныбызга кургашын ямау салынган. Кургашын һәм бакырдан торуы өстенә, аның ике тишеге дә бар. Бу тишекләрне, һичбер АКШ ярдәменә таянмастан, үз көчебез белән чүбек, аптека мамыгы һәм сумала мүкләп томаладык. Тишекләреннән су саркып учактагы утны сүндермәслек бер хәлгә китерелде казан. Әгәр Тәркүз күле саекмаса, менә хәзер үз күзегез алдында тәҗрибә дә ясап күрсәткән булыр идек. Бу казан Кабакчы Мостафа баш күтәргән чакта яңачирүләр[1] ташлап калдырган мал булып, шул заманда баш вәзир Кырыкаяк Хәлил пашаның йортына килеп эләккән һәм шунда озак вакытлар гашура казаны буларак кулланылган. Соңыннан үзйөрешле баржаның пар казаны булып хезмәт иткән. Казанның тугыз тоткасы бар. Без аңа тагын бер тотка куеп, шушында китердек. Бу казанның...
Берәү:
— Туганкай, казан тарихы озынгарак сузылды, тайыйм әле мин.
Икенче берәү:
— Мин дә... Иртәгәге тантанада очрашырбыз, иншалла.
— Алла кушсын! Сау булыгыз.
— Исән-су йөрегез.
Нотыкчы:
— Бу казан...

## Хирурглар конгрессы

Хирургларның чираттагы бөтендөнья конгрессы Любликс шәһәрендә чакырылган иде.

Элекке еллар белән чагыштырганда, иң вәкаләтле бу корылтайга барлык илләрнең табиплары да бик зур әһәмият бирә иде. Монда дөньяның иң атаклы докторлары катнашты. Футбол ярышы, берәр житен чәчле яки кара чутыр кино йолдызының пресс-конференциясендә оештырылган эчке киемнәр күргәзмәсе кебек үк дулкынландыргыч вакыйга булмаса да, хирургларның унынчы корылтае эшен күзәтергә Любликс шәһәренә дөньяның барлык телеграф агентлыкларыннан да хәбәрчеләр килеп җитте. Егерме өч илнең иң күренекле докторлары конгресста гыйльми докладлар сөйләргә әзерләнә иде. Алар арасында, ватык сәгать

[1] Төркиядә XIX йөз башына чаклы тотылган гаскәр.

яки автоматик мылтык белән генә эш иткәндәй, күз йомып та кешене сүтеп-җыярга сәләтле үз эшенең тылсымчылары бар иде. Шуңа күрә бөтен дөнья газитләре, коену костюмы рекламасы, футбол ярышы һәм иң коточкыч җинаятьләр турындагы хәбәрләрдән соң, хирурглар конгрессына да берничә юл бирергә кирәк таба иде.

Беренче көнне корылтайны ачу тантанасы булды. Икенче көн гомуми фикер алышуларга багышланды. Аннары делегатлар гыйльми чыгышларын башлап җибәрделәр.

Трибунага, урта яшьләрдәге бер ир-атны ияртеп, мәгълүм АКШ хирургы доктор К. Клейзман күтәрелде. Телеграф агентлыклары хәбәрчеләре һәм газит репортерлары каләм-кәгазьләрен чыгарып, язарга әзерләнде. Делегатлар да радиоколакчаларын киеп, американның дүрт телгә тәрҗемә ителеп барылачак чыгышын тыңларга җыенды.

— Хөрмәтле хезмәттәшләрем!— дип башлады табиб К. Клейзман.— Шушы унынчы корылтаебызда утыз биш ел эчендә ясаган иң кызыклы бер операциям турында сөйләргә телим. Сезгә мәгълүм ки, әле бер генә хирургка да кешенең бармак тиресендәге сызыкларны үзгәртү насыйп булганы юк. Медицина тарихында гаҗәеп ак тап бу. Гыйльми әдәбиятта да бу хакта нидер язылганы юк. Бармак очларындагы тирене ничә мәртәбә һәм нинди генә ысул белән алсагыз да, яңа үскән тире нәкъ элекке рәсемен саклаячак. Менә шуңа таянып, полиция каракларны, сейф вату осталарын һәм явыз җан коючыларны шактый җиңел таба килә. Мин кешенең бармак тирәсендәге сызыкларын үзгәртә ала торган ысул табу бәхетенә ирештем. Соңгы казанышым менә шул. Хәзер янымда АКШның күренекле бае, ясалма аталандыру остасы Томас әфәнде басып тора. Аның Җик Дробос кулы дигән икенче исеме дә бар. Федераль бюроның җинаятьчеләр картотекасында аның нәкъ менә шушы кушаматы теркәлгән. Америка полициясе нәкъ менә ун ел инде аның эзенә төшәргә азаплана, әмма әле дә булса моңа ирешә алмады. Берәр банкны талаган саен мин хөрмәтле ясалма аталандыру остасы Томас әфәнденең, ягъни мистер Җик Дробос кулының тире сызыкларын үзгәртәм. Әфәнделәр, бу операция сезгә мәгълүм иң катлаулы операцияләргә караганда да табышны күбрәк китерә, дип ышандыра алам. Таланган сейфтәге хәзинәне иптәшләрчә уртаклашуның начар гонорар булмавын танырсыз шаять, дип уйлыйм. Хәзер мин сезгә, хөрмәтле хезмәттәшләрем, проекцион аппарат аркылы әлеге операциямнең серен ачармын.

Делегатлар бертавыштан доктор К. Клейзманны унынчы хирурглар конгрессының иң күренекле вәкиле итеп таныдылар. Әмма шуннан соң чыгыш ясаган инглиз хирургы мистер Б. Линс аларның ышанычын какшатты. Атаклы галим трибунага шулай ук ниндидер бер ир кешене ияртеп менде.

— Хөрмәтле коллегаларым!— диде ул.— Медицинаның бөтен дөнья елъязмасын бизәргә лаек булган, сугыш елларында үзем ясаган бер кызыклы операция турында сөйләмәкче булам. Минем янымда егерме алты дошман солдатын теге дөньяга озаткан Икенче Бөтендөнья сугышы батыры ефрейтор Мэтьюне күрәсез. Мәкерле снаряд бер заман аның башын өзеп аткан. Әмма мин үзем уйлап тапкан җилем белән башны кире гәүдәсенә ябыштырып, аны терелтүгә ирештем. Хәзер Мэтьюнең башы гәүдәсендә элеккедән дә ныграк утыра, аңа, атом бомбасы шартласа да, зыян килмәячәк. Хәзер мин сезгә әнә шул гаҗәеп җилемнең серен ачам.

Инглиз хирургы таң калган галим-табипларның күз алдында серле җилемне әзерли башлады. Барысы да моннан кызыклырак беллерүне бүтән ишетмәячәгенә иман китерде.

Әмма француз хирургы корылтай вәкилләрен үз фикерен үзгәртергә мәҗбүр итте. Ул трибунага оятлы җирләрен көчкә-көчкә генә капларлык коену костюмы кигән аксыл йөзле бер гүзәлкәй белән бергә менде. Чәчләренә бәс кунган гыйлем ияләре утырган урындыкларында кыбырсый башладылар.

— Галиҗәнәп коллегаларым!— диде француз.— Мин пластик операцияләр өлкәсендәге соңгы гаҗәеп казанышымны күрсәтергә телим. Сездә кайнар хисләр уяткан бу ярым шәрә сокландыргыч ханым — минем кайнанам. Аңа алтмыш яшь тулуын белгәч, минем тыйнак хезмәтемне лаеклы рәвештә бәяләрсез, дип ышанам.

Корылтай вәкилләре шаккатты. Француз хирургы саф фәнни эчкерсезлек белән, үзенә хыянәт иткән хатынына үч итеп, инде сәлперәйгән карчыкка әверелгән кайнанасына ничек итеп пластик операция ясавын һәм аны гашыйк итәрлек гүзәлгә әйләндерүен һәм үзенә сөяркә кылуын сөйләгәндә, аларның таң калуы үскәннән-үсә барды.

Конгресста көн саен берсеннән-берсе гаҗәбрәк, шаккатыргычрак фәнни ачышлар бәян ителде. Чират алман хирургына да килеп җитте.

— Кешенең үлеме аның бөтен әгъзалары да шунда ук яшәүдән туктый дигән сүз түгел. Мисалга, инфаркттан җан тәслим кылган авыруны алыйк. Әйе, аның йөрәге инде сафтан чыга, әмма аның бүтән әгъзалары тап-таза булырга мөмкин. Ютәлдән үлгән кешенең дә үпкәсе генә яраксызлана. Әле яшьнәп яшәрлек адәм баласының нинди дер бавыр, йөрәк яки ашказаны чиреннән тормыш белән саубуллашуы бик күптән күңелемне тырнап килә иде. Менә мин бер көнне мәетләрдән әле үлеп бетмәгән сәламәт әгъзаларны җыеп алдым да өр-яңа таза кеше ясап карадым. Күрегез! — дип алман хирургы сәхнәгә Алып батыр гәүдәле егетне чыгарды.— Аның аяклары сукыр эчәк чиреннән вафат баһадирныкы, гәүдәсе — куллары череп үлгән пәһлеваннныкы, башы — күкрәк чиреннән үлүченеке.

Конгресс делегатлары фикеренчә, әгәр иртәгә чыгыш ясавы көтелгән япон вәкиле тагын да искитәрлегрәк ачышын күрсәтмәсә, остаханәсендә урындык һәм өстәлләр ясаган сыман, мәет әгъзаларыннан тап-таза тере кеше барлыкка китерүче алман тылсымчысы доктор Гюнтер хирургик операциясен иң гаҗәеп һәм берәү дә узып китә алмаслык казаныш санарга кирәк иде.

Иртәгәсен япон хирургы Хими Шияма трибунага өлкән яшьләрдәге бер ирне алып менде.

— Сезнең алдыгызда торган япон абзые Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында аксаклыгы аркасында армиягә алынмагач, өметсезлеккә бирелеп, ватанчыл хисләре тәэсирендә үзенә харакири ясаган — бөтен эчәкләрын актарып аткан иде...

Конгрессны ябыр көн дә җитте. Анда катнашучылар берсеннән-берсе тамашарак булган казанышларын сөйләп бирде. Бер генә вәкил чыгыш ясамады. Ул, хезмәттәшләренә хөрмәт белән колак салып, иң арткы рәттә утыра иде. Конгрессны алып баручы аңа да мөрәҗәгать итте:

— Доктор әфәнде, Сезнең безгә сөйләрлек бер генә кызыклырак операциягез дә юкмыни соң?

— Бер очрак бар барын,— диде хирург,— әмма аны сөйләп, хөрмәтле корылтай вәкилләренең алтын вакытын алырлык түгел шикелле. Искитәрлек җире юк аның.

Залдагылар шаулаша башлады:

— Һәр вәкил чыгыш ясарга тиеш!

— Ни булса да, тыңлыйсыбыз килә!

Атаксыз хирург трибунага күтәрелде.

— Бик кыстагач, сөйлим алайса. Миңа аңкау бизен алу өчен бер операция кәмәше ясарга туры килде.

Залда хихылдаулар яңгырады. Хезмәттәшләренең санга сукмау галәмәте төрек докторының мин-минлегенә тиде.

— Сабыр!— диде ул үртәлеп.— Мин тыйнаклыгым аркасында гына аны «операция кәмәше» дип атадым. Әйе, гадәти генә аңкау бизе иде ул үзе.

Залда хихылдаулар көчәя төште.

— Аңкау бизен алу!.. Операциямени ул?

— Мин андыйга тотынмыйм да!

— Телгә алырга ничек оялмый?!

Хирургның күзләре ачулы ялтырый башлады.

— Ә сез аңкау бизен кистерүченең кем икәнлеген беләсезме соң?

— Безгә дисә ник БМОның баш секретаре булмый! Аннан ни үзгәрә? Аңкау бизе биз инде ул!

Мәсхәрәләнгән төрек хирургы бурлаттай кызарып чыгып:

— Мин операция ясаган кеше журналист иде!— дип кычкырды.

Делегатлар шаркылдавын дәвам итте.

— Булса соң!

— Безгә димәгәе, ник коммерсант булмый!

— Хезмәткәр булсын...

— Солдат булсын...

— Барыбер!

— Ялгышасыз, әфәнделәр. Ул вакытта безнең илдә матбугатка кагылышлы рәхимсез закон кабул ителгән иде. Журналистларга авызларын ачу тыелган иде, шунлыктан аның аңкау бизен арт тишеге аша «кереп» алырга туры килде.

Залда көлешүләр шып тукталды, делегатлар йөзендәге елмаюлар сүнде. Күзләрендә хөрмәт итү һәм соклану уты яна башлады. Алкышлар кабынып китте.

Барысы да бертавыштан әлеге аңкау бизен алу операциясен хирургларның унынчы бөтендөнья корылтае эшендә иң әһәмиятле белдерү дип санарга килештеләр.

Төрекчәдән **Тәүфикъ ӘЙДИ** тәрҗемәләре



Китап күзәтү




# ТАТАРСТАНДА СТАЛИННЫҢ КАНЛЫ ЭЗЛӘРЕ

(ГЫЙБРӘТЛЕ ЯҢА КИТАП УКЫГАЧ)

Төп сүзгә күчкәнче, 1995 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Сталин һәм «татарлар эзе» («Сталин и «татарский след») дигән китапның авторы Булат Солтанбәков турында кыска гына мәгълүмат бирү урынлы булыр. Булат Фәйзерахман улы 1928 елда Казанда, укытучылар гаиләсендә туган. Аның әнисен — Яңа Бистә балаларына аң-белем һәм тәрбия биргән Мәдинә апаны — бик күпләр әле дә сагынып искә ала.

Казан педагогия институтын тәмамлагач, Булат авыл мәктәбендә тарих укыта. Армия хезмәтеннән соң партия өлкә комитетының мәктәпләр бүлегендә эшли. 1961 елдан вуз укытучысы була.

Профессор Булат Солтанбәков хәзерге вакытта Татарстанның укытучылар белемен күтәрү институтында кафедра җитәкчесе. Бу галим шөгыльләнә торган төп проблемалар түбәндәгеләр: революция алдыннан һәм революциядән соң халык мәгарифе, мәдәният, сталинизмның республикада чагылышы, милли мәсьәләләр. Шул темаларга аның йөздән артык очерк, мәкаләсе басылды. Татарча белсә дә, ул рус телендә яза. Б. Солтанбәковның «Генсекның беренче корбаны», «Милли сәясәт серләре», «Татарстанның драматик тарихы», «Яшерен архив битләре» һ. б. китаплары киң җәмәгатьчелек тарафыннан җылы каршыланды, тиз вакыт эчендә таралып бетте.

«Сталин һәм «татарлар эзе» китабында 17 очерк тупланган. Аларның һәммәсе дә күп санлы архив материалларына, документларга таянып язылган. Автор фактларны шулкадәр оста итеп файдалана ки, әйтерсең лә очерк геройлары белән гомер буе эшләгән, яшәгән... Тагын шунысы бик әһәмиятле: Б. Солтанбәков, татар тарихчылары арасында беренче буларак, моңа кадәр җиде йозак астында сакланган («Сверх секретно» — «особо секретно») 558 нче фонд (Сталин кул куйган яки шуларга бәйләнешле документлар тупланмасы) материаллары белән таныша, өйрәнә.

Китапның төп геройларыннан берсе — Ильяс Алкинның тормышы, сәяси эшчәнлеге күп нәрсәләр хакында сөйли. Ильяснын бабасы — Шаһиәхмәт Алкин — заманасында Казан губернасының атаклы полицмейстеры була. Полковник дәрәҗәсендә пенсиягә чыга. Аның улы Сәиткәрәй Алкин университет тәмамлый, яхшы журналист була, 2 нче Дәүләт думасына депутат итеп сайлана. Сәиткәрәй улы Ильяс әнә шул мохиттә тәрбия, белем ала. Сүз уңаенда гына: Сәиткәрәй 4 баласына (Ильяс, Җиһангир, Даут, Әскәр) югары белем алырга мөмкинлек биргән. Алар башта Казандагы реаль училищены тәмамлыйлар, аннан соң төрле вузларда укыйлар. Ильяс ул чактагы иң атаклы вузларның берсе — Санкт-Петербург Политехник институтын сайлый. Шул елларда ул бик

күп революционерлар, җөмләдән, атаклы татар зыялылары Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, казах Алихан Букейханов белән таныша.

Офицерларга зур кытлык тугач, 1916 елда Ильяс Алкинны да армиягә алалар. Кыска сроклы училище тәмамлагач, аны Казандагы бер хәрби частька офицер итеп билгелиләр. Билгеле булганча, 1917 елда патша тәхетеннән ваз кичәргә мәҗбүр була. Шулай итеп Февраль революциясе сәяси көрәшнең яңа этабын башлап җибәрә. Казанда мөселманнар советы (социалистик комитет) оеша. Март уртасында мөселманнар комитеты төзелә һәм аның җитәкчесе итеп яшь, энергиясе ташып торган, төпле белемле Ильяс Алкин билгеләнә. Тиздән Петроградта Россия мөселманнарының 1 съезды ачыла. Съезд Ильясны Хәрби Шура җитәкчесе итеп куя.

Октябрь революциясен мөселманнар якты өметләр белән каршылыйлар. Вакытлы хөкүмәт безне алдады, большевиклар сүзләрендә торырлар, халыкка вөҗдан, сүз иреге, җир бирерләр дип уйлыйлар. Аларның да гадәти урыс шовинистлары икәнен белмиләр әле. Шул шартларда, 1917 елның 4 декабрендә, Уфа шәһәрендә, мөселманнарның Милли мәҗлесе җыела. Ул «Идел-Урал штаты» төзү турында карар кабул итә. Бу эшне практик тормышка ашыру өчен 8 кешедән махсус комиссия төзелә һәм аның җитәкчесе итеп Ильяс Алкин раслана. Озакламый, 1918 елның гыйнвар ахырында, Бөтенроссия мөселманнары хәрбиләренең съезды ачыла. Анда «Идел-Урал штаты» төзүнең И. Алкин тәкъдим иткән варианты өстенлек ала. Большевиклар бу тәкъдимгә теш-тырнаклары белән каршы төшәләр. Шуннан соң делегатларның Алкин яклылары шәһәрнең татарлар яши торган ягына күчә. 1 нче мартта «Идел-Урал штаты» төзелү хакында махсус белдерү ясалырга тиеш була. Шул хакта плакатлар басыла. Штатны төзүчеләр аның Россия составында булачагын әйтәләр. Әмма большевикларга бу да ошамый һәм 28 нче февраль төнендә хәрби революцион штаб (7 кешедән торган бу большевиклар штабы составында Солтангалиев, Якупов та була) Алкин кешеләрен кулга ала. Тарихка «Болак арты республикасы» исеме белән кереп калган бу якты омтылыш шуның белән юкка чыга...

Без бүген Татарстан республикасының суверенитет алуы турында сөйлибез, шул юлда беренче юл ярабыз дип уйлыйбыз. Бу йомшак итеп әйткәндә дә, дөреслеккә туры килми. Чөнки беренче мәртәбә рәсми төстә бәйсезлеккә омтылыш 1918 нче елда ясалган. Әмма, гадәттәгечә, юлыбызны күршеләр кискән... Шул елның августында И. Алкин Самарага күчә. Ул чакта чехлар Казанны алып өлгермәгән була. Аннан соң Ильяс Алкин Уфага бара һәм Зәки Вәлиди гаскәрләренең штаб начальнигы итеп билгеләнә.

Башта З. Вәлиди армиясе аклар ягында булса да, Колчакның шовинистик сәясәт үткәрүенә инангач, кызыллар ягына күчә. З. Вәлиди белән И. Алкинны Мәскәүдә Сталин кабул итә. Өметле вәгъдәләр бирә. Әмма һәммәсе ялган булып чыга... Башкортстан республикасы (1919 елның мартында төзелә) дигән бутафория — хокуксыз бер территория генә була. З. Вәлиди, тәҗрибәле сәясәтче буларак, моны бик тиз сизә. Мәскәү белән, вакытында араларны өзә һәм кулга алынудан котылып кала. Ә Алкинны, бер төркем иптәшләре белән бергә кулга алып, Мәскәүнең Бутырка төрмәсенә ябалар. Ул чакта, Ленин исән вакытта, Сталин хакимлеге чикләнгән була әле. Шуның өчен ул төрле чигенүләргә маневрлар ясый. Аның кушуы буенча, мәсәлән, И. Алкинны төрмәдән чыгаралар. Моннан соң ул фән белән шөгыльләнә, профессор дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма милли кадрларны юк итүнең яңа дулкыны И. Алкинны да эләктереп ала. Аны 1937 елның сентябрендә кулга алалар. Бер айдан соң, «халык дошманы» исемен тагып, аталар. И. Алкинның гаебе бер генә була: абруйлы, белемле милли зыялы. Шунысы хак: Ильяс Алкин, татар милли-азатлык хәрәкәтенең Мирсәит Солтангалиев, Мулланур Вахитов кебек үк, бөек, онытылмас шәхесе...

Милләтне бетерүнең «нәтиҗәле алымнарыннан» большевиклар шактый уңышлы файдалана. Шуларның аеруча мөһиме — милләтне, халыкны җитәкчеләрсез калдыру. Кем ни генә сөйләмәсен, җитәкчесез халык — толпа ул. Моны борынгылар да яхшы белгәннәр... Ә инде «пролетариат диктатурасы» дип аталган 7 башлы аждаһа хакимлек иткән чорда бик күп татар зыялылары аяусыз кырылган. Мәсәлән, 1938 елда Казанга Югары судның Матулевич җитәкчелегендәге күчмә хәрби коллегиясе килә. Аның карары белән бер көндә 120 кеше үлем җәзасына хөкем ителә һәм шундук атыла. Шуның аркасында Татарстан, Мари республикасы җитәкчеләрсез кала.

Кайчак «җәлладлар тегермәне», үзенең әйләнү көчен вакытлыча киметеп ала. «Ректор гомеренең 126 сәгате» (Г. Камай турында яңа мәгълүматлар) дигән очеркта шундый бик сирәк хәл тасвирлана. 34 яшьлек галимне, өстәвенә татар

кешесен — Гыйлем Камайны — Казан дәүләт университеты ректоры итеп билгеләделәр. Кыска гына вакыт эчендә ул укыту-тәрбия, фәнни-тикшеренү эшләрен юлга сала, яңа факультетләр ачу хыялы белән йөри. Бу нәрсә Мәгариф министры А. Бубновка бик ошый. Һәм партиянең XVII съездында ул Г. Камайны мактап телгә ала. Инде 1937 елда «халык дошманы» А. Бубнов кулга алынгач (атылгач), «ул үстергән кадрларны» чүпләү башлана. Шулай итеп Гыйлем Камай төрмәгә ябыла. Ул чактагы хәлләрен ректор кыска гына итеп болай аңлата: «Мондый хәлгә бер тәүлек түзәргә була әле. Бигрәк тә минем кебек кешегә — элекке Идел грузчигына. Ләкин 5 көн, 5 төн буе ял бирмәү, хәтта идәнгә утырырга, стенага сөяләргә рөхсәт итмәү, ач тоту, сусыз интектерү, туктаусыз кыйнауларга түзүе искиткеч авыр». 1937 елда Татарстан НКВДсы башында бер-бер артлы А. Алемасов, В. Михайлов дигән «чекистлар» тора. 1937 елда Г. Маленков Казанда өч көн булып, «халык дошманнарын тизрәк юк итү буенча» инструкция бирә. Шуны тыңлаганнан соң В. Михайлов болай ди: «Миңа 2-3 мең кешене генә кулга алырга (димәк, атарга) рөхсәт итәләр, ә мин 4-5 мең кешегә лимит алачакмын». Әнә шулай итеп, бу вәхшиләр кеше җанын чебен кадәре дә күрмиләр. Иң асыл ирләр, хатыннар меңәрләп кенә түгел, йөзәр меңләп юк ителә. Хәлбуки, тарихта моңа охшаш хәлләр юк... Революция турында сүз чыкса, инкыйлаб корбансыз булмый ул дип, Кромвель (Англия), Робеспьер (Франция) чорларын искә төшерергә яраталар. Ләкин ни генә булмасын, Октябрь революциясе янында алар — балалар уены гына...

Халыкны төрмәдә черетү, туктаусыз атулар аркасында (А. И. Солженицын «Аргументы и факты» газетасында ГУЛАГ та 67,4 миллион кеше юк ителгән дип язып чыкты), халык хуҗалыгы ике аякка аксый башлый. Шуңа күрә Сталин һәм аның баш җәллады Лаврентий Берия (дөресрәге, ул — баш җәлладның тыңлаучан ярдәмчесе) «кешене он итү тегерменең «әйләнешен вакытлыча акрынайтырга уйлыйлар. «Тимер нарком Ежов»ны, аның ярдәмчеләрен, шул җөмләдән Татарстан НКВДсының җитәкчеләрен, аталар. Янәсе, моңа кадәр булган корбаннар өчен алар гаепле. Шул чакта Казандагы 18 профессор һәм аспиранттан торган «дошманнар группасы» азат ителә. Алар арасында булачак бөек галим, академик Борис Арбузов һәм Гыйлем Камай да була. Ләкин Гыйлем ага физик яктан нык кеше булса да, 70 яше дә тулмый, дөнья куйды. Ике ел буена кыйналу, башка җәзаларга дучар ителү эзсез генә калмаган икән шул...

Югарыда әйтелгән китапта дин мәсьәләләренә, дин әһелләре язмышына да шактый урын бирелгән. Һәм бу, кайсы позициядән чыгып карасаң да, урынлы. Чөнки дин әһеле — шулай ук кеше, шәхес ул. Динче булган өчен генә кешене гаепләү, җәзаларга тарту бернинди халыкара законнарга, пактларга да сыймый. Икенчедән, шунсы бәхәссез: дин ул — көндәше булмаган иң көчле идеология. Динсез, дәһри җәмгыять эчтән череп таркала. Моны олы акыл ияләре бик яхшы белгән. Мәсәлән, бөек француз галиме, тарихчы һәм философ Вольтер үзенең бакчасында Аллага һәйкәл куйган (ул чыннан да алла барлыгына ышанган) һәм болай дигән: «Гади халыкны тәртиптә тоту өчен, булмаган тәкъдирдә дә Алланы уйлап табарга туры килер иде». Бу фикерне яклаучылар әле дә аз түгел.

Маркс, Энгельс исә бөтенләй башка юлдан киткәннәр, француз метафизикларына (ә алар дөньядагы бөтен начарлык дин әһелләреннән килә диләр) ияргәннәр. Ә инде Россиядә марксизм теориясенә нигезләнгән «пролетариат диктатурасы» җиңгәч», илдә дингә, динчеләргә каршы аяусыз көрәш башланды. Ун меннәрчә попларны, муллаларны, раввиннарны, ламаларны төрмәләргә яптылар, аттылар. Ә бит идеологик көрәштә андый хәл гомумән, булмаска тиеш. Мәчет, чиркәүләрне һ. б. яндырдылар, дуңгыз абзарларына әйләндерделәр. Мәдрәсә һәм монастырьларга да шундый язмыш килде... Моның нәтиҗәсе күз алдында: «бөек» Россия әхлаксызлар иленә әйләнде. Эчү, урлашу, еллар буе эшләмәү, кеше үтерү гадәти күренешкә әверелде.

Ислам кануннары хәмер эчүне катгый тыя. Тик шуның өчен генә дә, аңа олы хөрмәт белән карарга ярый. Революциягә кадәр мөселман татар авылына аракы, тәмәке кебек хәсисләр, гомумән, кертелмәгән. Шуңа халык чын мәгънәсендә пакь, итагатьле, физик яктан таза булган. Соңгы 2 ел эчендә Татарстанда 600 мәчет ачылды. Бу шатлыклы күренеш. Әмма шатланырга иртәрәк. Чөнки бик күпләр егылып эчә, ә исерек нигә мәчеткә барып сәҗдә кылсын ди? Бу үзе — искиткеч зур фаҗига. Әмма, ни генә булмасын, яшь буыннарны бу афәттән котылдыру чарасын күрергә кирәк. Ничек? Бу сорауга җавап табуы һич тә җиңел түгел. Чөнки сүз әбисе-бабасы, әтисе-әнисе денсезгә әйләнгән, хәмер белән дус-

лашкан балалар турында бара. Шулай да мона бөтен җәмгыять мәктәпләр, балалар бакчалары, вакытлы матбугат, башкаинформация чараларе тотынса, мөгаен без яшь буынны һәлакәттән саклап кала алырбыз. Сүз балаларыбызны халкыбызның гасырлардан килгән күркәм традицияләре үрнәгендә тәрбияләү турында бара. Һәм марксизм-ленинизмны мактап диссертация язганнар, галим булганнар ни генә сөйләмәсен, халкыбызның традицияләре ислам кануннары белән сугарылган. Балалар — хисле җан ияләре һәм әнә шуңа күрә тәрбия бирү өчен бу чор иң кулай санала... Булат Солтанбәков китабында болар турында сүз булмаса да (чөнки җыентыкның бурычы башка), автор объектив рәвештә дини мәсьәләләргә яңача карарга булыша. Шул уңайдан әлеге китаптагы «Мөфти һәм Совнарком: сөйләшергә тырышу» очеркын мисал итеп китерергә булыр иде.

Бу очеркның төп герое Риза Фәхретдиновны күпләр беренче чиратта энциклопедик белемле олы галим буларак беләләр. Ул үзе дә гомер буе фәнни эшләр, журналистика белән генә шөгыльләнергә уйлый. Әмма тормыш кануннары, чынбарлык һәммәсеннән дә өстен булып чыга. 1921 елда Галимҗан Баруди (Галиев) вафат булганнан соң, аның урынына мөфти итеп Риза Фәхретдиновны сайлыйлар. Ул Уфага күчеп, дини вазифаларын үти башлый. Фәнни-тикшеренү эшләрен дә туктатмый. 1924 елда Риза Фәхретдиновны Казанга чакыралар. Шунда ул җирле җитәкчеләр белән дингә кагылышлы сөйләшүләр алып бара. «Совет ягыннан» сөйләшүгә Совнарком рәисе Хаҗи Габидуллин, күренекле язучы, академүзәк җитәкчесе, күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов катнаша. Ул заман «гадәтләрен» истә тотсак, бу «акцияне» Мәскәү оештырган дип уйларга да урын бар... Мөфти урыннарда властьлар тарафыннан дин, вөҗдан ирегенең нык бозылуы турында әйтә. Әгәр властьлар безне аңласа, без дә үз чиратыбызда властьларга ярдәм итәрбез, ди. Шуннан соң бер ел үткәч, Риза Фәхретдинов Мәккәдә узган Бөтендөнья мөселманнары Конгрессында катнаша. Ул анда советлар сәясәтенә уңай бәя бирә... Бу, мөгаен, Казандагы сөйләшүләр нәтиҗәсе булгандыр һәм ул чакта мөфти тоталитар системаның чын асылын белмәгәндер.

Кызганыч, ике якның «аралашуы» шуның белән тәмамлана диярлек. Х. Габидуллинны Мәскәүгә чакырып алалар, университет профессоры, Мәгариф министрлыгының урынбасары итәләр. Ләкин бу үзенә күрә «мәче белән тычкан уены» гына булып чыга (шул ук алым И. Алкинга карата да кулланыла иң...) 1937 елда исә «халык дошманы» Хаҗи Габидуллинны аталар. Мөфтинең хәлләре дә яхшыдан булмый. Әмма ул җәлладларга эш калдырмый: 1936 елда үз үлеме белән бу фани дөньядан китеп бара. Ә 1937 елда мөфтинең 42 хезмәткәре кулга алына. Шулай итеп тоталитар система динне бетерүнең яңа этабына күчә.

«Изге китапның Россиядәге серләре» («Загадка священной книги в России»), «Генерал Дәүләтшинның хаҗга баруы» («Хадж генерала Давлетшина»), «Ай белән тәре өстендә кылыч» («Меч над крестом и полумесяцем»), «Казан протодьяконы — Сталинның дусты» (Казанский протодьякон — друг Сталина») очерклары да документларга бай булулары белән аерылып торалар. «Сталинның тимер наркомы» («Железный нарком Сталина») дигән очерк та бик үзенчәлекле.

«Төрек министры жандармерия күзәтүендә» очеркы патша заманында чит илләрдән килгән кунакларны күзәтү «механизмын» ачуга багышланган. Әмма, тоталитар системаның «кыланышлары» белән чагыштырганда, патша жандармериясенең «эшчәнлеге» җиңелчә шаяруны гына хәтерләтә икән. 1913 елда Төркиянең юридик һәм икътисади мәсьәләләр белән шөгыльләнүче министры Мәхмүт Әссад әфәнде Россия хөкүмәте рөхсәте белән, мөселманнар яши торган регионнарда: Кавказда, Оренбурда, Сәет бистәсендә, Уфада, Казанда, Нижгарда, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта була. Бу уңайдан шуны гына әйтәсе кала: илдә коммунистлар партиясе җитәкчелек иткәндә генә түгел, бүгенге «демократлар» вакытында да төрек министрының төрки халыклар белән очрашып, милли-азатлык хәрәкәте җитәкчеләре белән сөйләшеп йөрүләре төшкә керә торган нәрсә түгел. Инде совет чорына килгәндә, Төркия хакында җылы сүз әйтү түгел, уйлау да бик хәтәр фал иде, моның өчен аталар иде. Алай гына түгел: тоталитар система татарларның үзара аралашуына да юл куймады, халыкны «пантюркизм», «панисламизм», «Туран» дәүләте төзү идеясе» белән куркытты. Бөтен ил шымчылар белән тулды. Университетта укыганда (1945—1950), безнең группадагы 16 кешенең 2 се шымчы икәнлеге ачыкланды. Тагын бер мисал: Генштабта эшләгән татар генералы Рәфкать Әхмәтович Вәлиев Казанга эш белән килгәндә, аның артыннан ачыктан-ачык күзәтү алып барыла иде. Ул бу хакта үзе сөйләде...

Ә «Төрек министры...» очеркында сүз Казан жандармериясенең «эше» турында бара. Бу вакытта Казанда татар милли-азатлык хәрәкәте лидерлары Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Йосыф Акчура һ. б. күпкырлы эш алып баралар... Министрга алар белән очрашу мөмкинлеге бирәләр... Әмма һәр адымны күзәтәләр. Мәсәлән, Мәхмүд Әссад Уфадан «Амур» пароходы белән юлга чыккач та, Казанга министр турында тәфсилле телеграмма җибәрелә. Башка урыннардагы кебек, Казанда да М. Әссад артыннан яшерен күзәтчеләр йөри. Ләкин министрны ниндидер «йөрү-күрешү» программасы» белән чикләмиләр. Мәсәлән, ул Тукай кабере янында (Татар зыяратында), Мәрҗани мәчетендә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һ. б. бик күп урыннарда була, үзе кирәк дип тапкан һәркем белән сөйләшә. Моңа кадәр бик күп татар регионнарында булган төрек министры: «Объектив сәбәпләр аркасында, Казан Россия мөселманнарының мәдәни һәм иҗтимагый хәрәкәт үзәгенә әйләнә»,— ди. Бүгенге министрларның берсе дә мондый кыюлыкка бара алмаслар иде... Очеркның соңгы өлешендә Казанда төрек министрын каршылаган, аның белән очрашкан кешеләрнең ахыргы язмышы сурәтләнә. Мәсәлән, 30 нчы елларда КГБ, НКВД җәлладлары Ибраһим Әмирханов, Һади Максуди, Габдулла Гыйсмәти, Шәһәр Шәрәф, Фатих Кәрими һ. б. бик күп затлы татар зыялыларын юк итте. Аларга тузга язмаган гаепләр япсалар — таксалар да, сәбәп бөтенләй башкада була: илдә бер генә халыкны калдыру сәясәтен тормышка ашыру, «Вак милләтләргә» һөҗүм бик күп «фронтларда» алып барылды. «СССР тарихы» дип аталган нәрсә чынбарлыкта бер халыкның дөрес булмаган, күпертелгән тарихы» иде. Мәскәүдә Кызыл мәйдан белән рәттән урнашкан Үзәк тарих музее бар. Әмма ул ил тарихына багышланмаган. Бөтен экспонатлар да «гел генә җиңү яулаган» урыс полководецларына, патшаларына багышланган. 30 төрки халыкны сурәтләүче бердәнбер экспонат бар: ямьсез кыпчак кызларының таш сыны... Олжас Сөләймановның «АзиЯ» китабында исә бөтенләй башка хәлләр тасвирлана. Чибәр кыпчак кызларына бик күп славян егетләре өйләнгән. Үз чиратында, кыпчак егетләре дә славян кызларын алганнар. Өстәп тагын шуны әйтергә ярый: документларга таянып, О. Сөләйманов: «Игорь полкы турында җыр» поэмасының авторлары — кыпчаклар — төрки халык вәкилләре,— ди.

Сталинның чын йөзен һаман ачып бетерә алганнары юк әле. Һәм, мөгаен, бу мөмкин дә булмастыр. Дм. Волкогоновның Сталин турындагы китабы да айсберг бозының өске өлешен генә хәтерләтә. Чөнки бу явыз кешенең һәм ул төзегән системаның кешелеккә кылган начарлыкларын саный китсәң, кәгазь дә, вакыт та җитмәс иде. Әкиятләрдә үзенең балаларын ашый торган вәхшиләр турында сөйләнелә. Совет системасы явызлыгы белән әкиятләрне дә уздырды. Чит илләргә кагылышлы бер-ике мисал китерү дә күп нәрсәне ачыкларга ярдәм итәр кебек... 1937 елда СССРда яшәүче чит ил компартияләренең җитәкчеләрен дә юк итте бу система. Гаепсез булу өстенә, алар чит ил гражданнары иде дә бит әле. Адым саен ялган, вәхшилек... Күптән түгел «Үтә яшерен» тапшыруында Финляндиягә каршы сугыш башлау өчен, Сталин кушуы буенча, кеше ышанмаслык провокация оештырылуы хакында сөйләнде. Галимнәр, дипломатлар, кулларына документлар тотып, моның ничек эшләнүен дәлилләделәр. Мәскәүдән, Генштаб начальнигы Шапошниковтан, Ленинград хәрби округы командующие армия генералы Мерецков исеменә телеграмма килеп төшә. Эчтәлеге: янәсе, финнар безнең җирләргә ут ачып, совет кешеләрен үтергәннәр. «Бу телеграмманы алу белән, шул телеграмманы Генштабка сук»,— дигәннәр аңа. Ә ул: «Финляндия ягыннан һич бер атулар да, провокацияләр дә булганы юк»,— дип җавап бирә. Мәскәү болай ди: «Кушканны үтә, без хәлне яхшырак беләбез, сиңа да белергә кирәк иде». Ә бу инде — үзенә күрә янау — командующий өчен бик куркыныч нәрсә була. Ул шундук Мәскәү кушкан телеграмманы Генштабка суга. Шуннан соң сәгате белән ил буенча митинглар башлана, «халык ак финнарны, шюцкорфашистларны тар-мар итүне катгый рәвештә таләп итә». Хәер, андый «халык таләпләре» безгә бик таныш нәрсә инде... Әнә шулай итеп бик күп корбаннар таләп иткән гадел булмаган сугыш башланды. Шуңа охшаш провокацияне Гитлер 1939 елның август ахырында Польшага каршы оештырды һәм 1939 елның 1 сентябрендә Германиянең Польшага басып керүе белән уннарча миллион кешене корбан иткән икенче бөтендөнья сугыш башланып китте... Яисә яңарак мисал: 1994 елда Чечняга каршы сугышны аклау өчен Мәскәү шулай ук провокация юлына басты. Янәсе, Чечняда чеченнар белән чеченнар сугыша, урыслар шуларны аералар гына. Ләкин, рус армиясенең регуляр частьлары тар-мар ителгәч кенә, ачыктан-ачык олы бер армада Чечняга басып керде... Әмма теге чакта

финнарны, бу очракта чеченнарны тез чүктереп булмады. Сәбәбе: үзенең бәйсезлеге өчен көрәшкә баскан халыкны җиңеп булмый...

Сталин «язучыларны сатып алу, провокациягә тарту» алымыннан да еш файдалана. Язучылар кулында көчле идеологик корал булуын яхшы белә ул. Булат Солтанбәков 558 нче фонд материаллары белән танышканда, «партиянең язучыларга җитәкчелек итү» документларын да күз уңаеннан җибәрмәгән. («Партия җәзасын бирергә...» дигән очеркны кара.) Дөрес, сүз күренекле рус язучылары турында бара. Әмма Татарстанда да шуңа охшашлы хәлләр булмады мени?! Ничек кенә әле! Тау-тау китаплар яндыру, китапханәләрне китапсыз калдыру, теге яки бу әсәрнең дөнья күрү-күрмәве партия өлкә комитетында хәл ителү (монда төп принцип булып язманың сыйфаты түгел, аның «сыйнфый позициядән чыгып язылуы» торды) — гадәти бер күренешкә әйләнде. Әдәбият кануннарын белмәгән, «әдәби эшләнеш» дигәнгә көлеп караучылар ул чакта язучының да, әсәрләрнең дә язмышын хәл итәләр иде. Сталин, Хрущев, Суслов, Брежнев («бернечә мәртәбә дәүләт бүләге лауреаты»), Жданов, Щербаков кебек «әдәбият белгечләре» Мәскәүдә соңгы инстанция саналсалар, Казанда партия өлкә комитеты секретарьлары, бүлек мөдирләре шул рольне башкардылар. Әдәбиятчы профессорларның да үлчәме бер иде: «сыйнфый күзлектән карап иҗат итү». Алар шуның белән тамак туйдырдылар, көн иттеләр. Алай гына түгел, дөнья әдәбияты классикларына да шундый ук таләпләр куелды: әгәр аларның әсәрләре «эшчеләр сыйнфы интересларына хезмәт итмәсә», тәрҗемәсе булмады.

Ә югарыда әйтелгән очеркта сүз А. Чапыгин, Б. Пильняк турында бара. Алар икесе дә авыл тормышын сурәтлиләр. Дөресрәге, булган хәлне күрсәтергә омтылалар. Бәхете булган, ахрысы, «партия чыбыгын» күп ашаса да, Алексей Чапыгин үз үлеме белән үлә. Бәлки бу хәерлегә булгандыр, аңа да Галимҗан Ибраһимов язмышы килүе бик ихтимал булган иң... Язмыштан узмыш юк дигәндәй, 1922 елда Борис Пильняк үзенең «Иван да Марья» дигән китабын бастыра. Әдип нибары булган хәлне генә язган. Әмма аның китабы «пролетариатка хезмәт итмәгән» шул. Бу хакта Сталинның карары катгый: «Китап контрреволюцион характерда» (соңгы сүз астына ике сызык сызылган). Ут йоттырып, ачлы-туклы яшәтәләр Пильнякны. Җир йөзендә тәмуг газапларына күрсәтәләр андыйларга. Һәм, ниһаять, «троцкист террорист» (!). Борис Пильняк дөнья мәшәкатьләреннән котыла: аны аталар... Хәер, андыйларны саный китсәң, очына чыгып булмас иде... Атуга кадәр барып җитмәсә дә, А. Фадеев (татар әдипләренә аның мөнәсәбәте әйбәт була...), А. Твардовский кебек олы талантларны да, партия корбаннары итеп карау дөрес булачак...

Милли әдәбиятка һөҗүм күптән барса да, 1937—1938 елларны берни белән дә чагыштырып булмый. Нәкъ менә шул чорда Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Галәү, Г. Толымбайский, М. Крымов, Г. Нигъмәти, Җ. Вәлиди һ. б. бик күп татар зыялылары юк ителде. Соңыннан да бу эш дәвам итте. Сугыш вакытында рус язучылары Чистайда, украин язучылары Уфада иҗат эше белән шөгыльләнгәндә (моңа безнең бер каршылыгыбыз да юк), бик күп татар язучылары, шагыйрьләре фронтка киттеләр һәм шунда ятып калдылар. Аларның исемнәре киң җәмәгатьчелеккә билгеле. Ләкин моңа карап кына югалтулар фаҗигасеннән йөрәк сызлавы кимеми. Тагын бик тә үкенечлесе шул: сугыш алдыннан бер китап чыгарган, яки әсәрләре вакытлы матбугатта гына дөнья күргән шактый өметле яшь талантлар барлыгы — 20 кеше фронтка китә. Шуларның берсе дә туган илгә әйләнеп кайтмый! (Моны миңа татар әдәбиятын яхшы белүче кеше — халык язучысы Гариф Ахунов сөйләде.) Бөек Ватан сугышында татар халкы искиткеч батырлыклар күрсәтә. Иң күп югалтуларны да ул күрә. Һәм менә нәкъ шул чакта, 1944 елның августында, ВКП(б) Үзәк Комитеты, татар һәм башка төрки халыкларның «Идегәй» дастанын һәм шуңа бәйләнешле әдәби әсәрләрне гаепләп, аларга «халыкка каршылар» дигән тамга сугып, карар чыгара. Бу факт милли әдәбиятларга яңа һөҗүм башлануын раслый иде һәм ул шулай булып чыкты да.

Әйе, тоталитар система язучыларны үз кысасында тотты, кол итте. Шуның нәтиҗәсендә муллаларның, попларның, «ачкүз кулакларның» «пычрак битлеген ертып ташлар торган» примитив хикәяләр, юлбашчыларны күккә чөючә «талантлы әсәрләр» иҗат ителә башлады. Мәсәлән, кулак корткыч, күмәк хуҗалыкка зыян итү теләге белән, төнлә, качып-посып, арыш, бодай башакларын кисеп йөри, имеш. Ач мужик моны эшләсә, ышанырга булыр иде әле. Кулакка килгәндә, теләге булса, икмәкне юк итү өчен аңа шырпы җитәр иде... Сталинга нинди генә мактау сүзләре яудырмадылар. «Ул төн буена безнең хакта уйлый, шуңа күрә Кремльдә ут сүнми, бөек юлбашчы тәүлек буе эшли», дигән «бөек әсәрләр»

аз булмады. Сталин үлгәч тә, мондый шаукымнар тиз бетмәде. Партиянең XX съездыннан соң «Күңелебез Ленин белән сөйләште». Миллиард тонналаган нефтебезне бушлай алып китеп, җиребезне харап иткән чакта да, «нефтебез өчен Европа парламентлары безгә сәлам бирә» дип шапырындык. Кызларыбызның татар егетенә түгел, теләсә кемгә кияүгә чыгуын (ә бу милләтне бетерүгә китерә) интернационализм чагылышы бу дип, мактап җырлар яздык, шуны туктаусыз җырладык. Дөньяның иң атаклы галимнәре Коръән алдында баш игәндә, надан башыбыз белән, бу Бөек Китапны сүгү юлына бастык. Моның өчен мөселман дөньясы безгә бик нык үпкәләде... Тагын әйтмичә булмый: халык «суверенитет» дип «аһ» органда, кайбер язучыларыбыз: «Тукай да митингка йөрмәгән, шуңа без дә йөрмибез», дип көфер сүзләр сөйләүгә кадәр барып җиттеләр. Чынлыкта сәбәп бер генә: «Мәскәүләр тотса якаң» дигән уй куркытты аларны. Башка берни дә түгел...

«Татарстан башлыгына һөҗүм» очеркында сүз милли лидерларны юк итүдә большевиклар файдаланган алым турында бара. Бу милли кадрларны бер-беренә каршы кую, шул юл белән һәммәсен дә юк итү. «Лядов бакчасы янында... 1920 елның 9 октябрендә «ниндидер билгесез кешеләр» Татарстан хөкүмәтенең башлыгы Сәхибгәрәй Сәитгалиевка атканнар. Берничә пуля пальтосын тишсә дә, премьер үзе исән кала»... Газеталар шулай язалар.

Очеркның беренче өлешендә революциядән соң милли районнарда, шул җөмләдән булачак Башкортстан һәм Татарстандагы сәяси хәлләр тасвирлана. Мәскәүдә «Идел-Урал штаты» төзелүдән бик куркалар. Моны булдырмау өчен төрле провокацияләр эшлиләр. Сәитгалиевка атуны оештыру шуның бер үрнәге. Тикшерү фәлән үткәрмичә, «премьерга солтангалиевчылар аткан», дип, «Солтангалиев яклыларны»: Татарстанның күренекле дәүләт эшлеклеләрен — Янбаевны, Фирдәүсне, Ганиевны, Бикчәнтәевны, Маминны, җәмәгать эшлеклеләреннән врач Хәдичә Ямашева-Бадамшинаны, атаклы нәшриятчы Нәсих Мохтаровны, Казан заводларыннан 47 кешене (шуларның 13 е хатын-кызлар) кулга алалар. 1937 елда, Сәитгалиев үзе кулга алынгач кына, 1920 елда аңа «Һөҗүмне» Сталин кушуы буенча оештырылулары ачыклана.

«Сталин һәм «татарлар эзе» китабындагы соңгы очерк — «Чечен синдромы» — безнең республикага кагылмый кебек. Әмма беренче карашка гына, чынлыкта безнең өчен күп нәрсәләр уртак. Сталин безне «үз вакытында» Себергә озатып өлгерә алмаган икән, язмыш шулай кушкандыр. Әмма шундыйрак планнар булган... Болар үзе аерым карала торган олы бер проблема. Әлеге очеркның исә әһәмияте бик зур: ул совет тоталитар системасының явызлыгын тагын бер кат шик калдырмаслык итеп раслый. Гадәттә, немец фашистларының вәхшилеген күрсәтү өчен, Орадур (Франция), Лидице (Чехия), Хатынь (Белоруссия) авылларын юк итүләрен искә төшерәләр. Әйе, андый хәлләр булган. Ләкин, бу сугыш вакытында, партизаннарга үч итеп эшләнгән. Ә менә 1944 елның февралендә совет гаскәрләре (100 мең сугышчы) «күз ачып йомганчы» мал вагоннарына (алар ягылмый) ун меңнәрчә чеченнарны тыгызлап тутырганнар. Юлда бик күпләр: хатыннар, картлар, балалар үлгән. Бөтенләй йөри алмаган авыруларны, картларны, авыруларны, балаларны — 700 кешене тау башына урнашкан Хайбах авылына җыеп атканнар, яндырганнар. Моны совет сугышчылары эшләгән. Ә бит чеченнар да — совет кешеләре. Сталин белән Берия бу «эшне тәгәл үтәүче җитәкчеләргә», сугышчыларга кайнар котлап телеграмма сукканнар. Генераллар, офицерлар югары дәрәҗәле хәрби орденнар белән бүләкләнгәннәр. Мәсәлән, Беренче дәрәҗә Суворов ордены белән — 4, Беренче дәрәҗә Кутузов ордены белән — 3 кеше, барлыгы 111 генерал, офицер бүләкләнгән. Әйтерсең лә алар Курск шәһәре янында дошманның оборонасын өзеп, зур уңышларга ирешкәннәр! Сүз уңаенда тагын бер мөһим фактны искәртик: «Кавказ регионыннан» озатылган халыкларның һәммәсе дә мөселманнар: чеченнар, ингушлар, карачайлар, балкарлар, месхет төрекләре. Ә христианнарга Сталин тимәгән... Бәлки кемдер Урыс гаскәрләренең 1994 елның ноябрь аенда Чечняга басып керүен очраклы хәл дип уйлыйдыр. Әмма хакыйкать башкада: Мәскәү 1944 елда эшләп өлгерә алмаганны (чечен халкын физик юк итүне) ярты гасырдан соң хәл итмәкче иде. Ләкин азатлык өчен көрәшкә күтәрелгәннәрне җиңеп булмый, алар үзләре җиңә, ди тарих...

Һәм соңгысы. Йөзәр еллар буена татар халкының тарихы бозылып, кара буяуга буяп кына күрсәтелде. Хәзер исә чын тарихыбызны булдыру, язу өчен уңай шартлар туды. Булат Солтанбәковның «Сталин һәм «татарлар эзе» дигән китабы шуңа бер мисал.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

# САБЫР ТӨБЕ — САРЫ АЛТЫН

Кышкы эңгер бигрәк иртә иңүчән бит: гүя ул тора-сала синең өстеңә ишелә дә төшә. Көннең әнә шул халәтен олуг рәссамыбыз Морат ага Рахманкулов үзенең өр-яңа картинасында гаҗәеп зур осталык белән гәүдәләндерә.

Кояшның ахыргы елмаюы: нурлары чыршы-наратлар куелыгына юньләп яшеренергә өлгермәгән әле: сүрән генә яктылык болытларга да, каен ботакларына да эленеп калган, арткы тарафларда күкнең тигезле-тигезсез гөмбәзе алсуланып тора — анда гүя әкият дөньясы, олы-олы сәмруг кошлар саллы вә киң канатларын җилпи, урман аланы өстенә серле караңгылык чаршавын ябарга ашкына...

Алгы тарафта өч-дүрт бөртек каен үсеп утыра. Уң кулдагысының язмышы бик үк сөенечле булмаган, ахрысы, шуңа ул кәкре-бөкре булып үскән, кыз туганнарындагы зифалыкны җуйган, тик ул һич тә бирешергә уйламаган: ботакларын як-якка җәеп җибәргән, бертөрле горурлык-чаялык белән күккә, югарыга томырылган. Ялгыз башы үсеп утырган ул каен, әлбәттә, сиңа мәһабәт булып күренә, син аңардан күзеңне һич ала алмыйсың, уйланырга мәҗбүр буласың: чаялыгы-мәгърурлыгы белән ул кеше язмышын хәтерләтә, синең үз язмышыңны, син кичергән хәсрәт-михнәтләрне янә бер мәртәбә исеңә төшерә түгелме соң?

Ботакларына сарган кар ул каенның аклыгын тагын да арттыра. Кичке эңгердә ак төс зәңгәрсуланып күренә. Әмма һәр тарафта азмы-күпме үзгәрәк төсмерне шәйләп була.

Мәшһүр рәссам Репиннан бервакытны:

— Илья Ефимович, карның төсе нинди була соң? — дип сораганнар.

Нәкыш остасы уйлап-нитеп тормаган, шундук җавабын да биргән:

— Мәгәр ак булмый! — дигән, ди.

Татар рәссамы аландагы карны тасвирлау өчен зәңгәрсу төсне сайлап бик дөрес эшли: урман аланының кичке бер халәтенә әлеге төс бигрәк тәңгәл килә, автор сурәтләп биргән күренешне сәнгать әсәре итүдә хәйран зур роль уйный.

Картинада сәмруг кошларны хәтерләтүче болытлар да, каеннар да зур осталык белән язылган, аларның һәркайсы үзенең вазифасын җиренә җиткереп башкара. Әмма картинада автор игътибар үзәгенә алан түрендәге тәбәнәк кенә, курчак шикелле матур гына, җыйнак кына ялгыз өйне алган булырга охшый: ботакларына кар сарган карт каен да, аның зифа буйлы туганнары да, киртә димәсәң хәтере калырлык итеп кенә курадан корылган киртә дә, уентыграк җиргә әмәлләгән бәп-бәләкәй күперчек тә әнә шул өйгә илтүче сукмакны билгеләү, ялгыз йортның урманга сыенып, аланның түрендә үк утырганын тәгаенләү өчен хезмәт итүче детальләргә күбрәк тартым...

Менә хәзер инде Морат ага Рахманкуловның фотограф булмыйча, ягъни үзе күргән һәр нәрсәне төкми-чәчми киндерегә күчереп утырту белән канәгатьләнмичә, картина язуга чын-чыннан иҗат эше дип караучы кыл-каләм остасы икәненә ишарә ясарга вакыт җиткәндер. Һәм рәссамның бу сыйфатын нәкъ менә ялгыз өй мисалында исбатлау гадел булыр.

Хикмәт шунда ки, табигатьнең бер почмагында җәйрәп яткан иркен алан күпне күргән һәм матурлыкны таный белгән рәссамның күңеленә хуш килә, тик менә бер кырыйда җиргә сеңгән землянка гына бу аланның ямен җибәрәдер, бөтен бер гармониягә зыян-каза китерәдер сыман тоела. Башка рәссам землянканы кертмичә генә этюд язмакчы була. Этюдны язып бетергәч, үз хезмәтенә житдирәк күз белән карый да — нидер житмәгәнен, бөтен бер күренеш килеп чыкмаганын абайлап ала. Канәгатьсезлек хисе тудырган картонны вак-вак кисәкләргә ерткалап ташлый да, кулын селтәп, үз юлы белән китеп бара...

Әмма урман аланы сәнгатькяргә һич кенә дә тынгы бирми. Аланга яңадан килгәч исә, һәммә нәрсәне иҗатчы буларак күздән кичерә: нәрсәләрне шул хәлендә тасвирларга, кайсыларына ниндирәк үзгәреш кертергә, ниләр өстәргә икәнен чамалап ала. Бер кат кискәнче җиде кат үлчи-уйлый торгач, рәссам гаҗәеп кулай бер чара уйлап таба: җаны сөймәгән землянканы игътибар үзәгенә куеп, аны этюдның — юк, алай гына түгел, картинаның! — аеруча гүзәл бер өлешенә әйләндерергә, якты нур сирпеп торган күркәм генә өй итеп сурәтләргә ниятли.

Әгәр шунда автор алтын сарай «салып куйса», реаль чынбарлык югалып, әкияткә тартым бер күренеш пәйда булыр иде; заманчалыкны дәгъвалап, коттедж-мазар «корыштырса», тамашачы бик үк ышанып җитмәс, бераз ясалмарак килеп чыгар иде. Хәер, чынбарлыкны лаклы итеп, бизәп күрсәтү авторның максатына да, гомерлек иҗат ысулына да тәңгәл килми. Менә ни сәбәпле кыл-каләм остасы үзенең хыялында туган әлеге детальне гап-гади бер өй итеп сурәтли һәм композициясендә табигыйлеккә ирешә. Картинада әнә шул табигыйлекне күреп, өстәвенә әле беркадәр серлелек тә шәйләп, тамашачы әсәрне ышанып кабул кыла.

Автор үзенең әсәрендә чын мәгънәсендә сәнгатьчә дәреслеккә ирешкән ләбаса! Гүяки әлеге өч тәрәзәле, җыйнак кына өй, һич бәхәссез, урман аланының нәкъ түрендә, берән-сәрән үскән карт каеннардан бераз арырак, куе агачлыкка сыенып утырадыр. Аның урыны табигать кочагында, нәкъ шунда! Яз җитү белән, өй түрендәге киң аланда, әлбәттә, ямь-яшел булып үләннәр, чәчәкләр баш калкытадыр, озакламый алар бөтен аланны чуар бизәкле келәм белән каплап аладыр, аннары инде каен җиләге мул булып өлгерәдер, берәзлексез кошлар симфониясе яңгырап торадыр...

Ә хәзергә алан түрендәге әлеге өй, бөтен әйләнә-тирәгә хас булганча, калын кар катламы астында калган, кар колакчыннары өйнең түбәсеннән салынып тора, өй үзе, кышкы йокыга талган урман киегедәй, тәбәнәкләнеп калган сыман. Тик ул йокламый, ул уяу, аның морҗасыннан сыек кына булып төтен күтәрелә, өч тәрәзәсеннән дә күренгән якты ут аны тагын да җанландырып җибәрә — гүя ул өй тирә-юньгә җан җылысы бөркеп, үзенә дәшеп-чакырып тора.

Тәҗрибәгә бай кыл-каләм остасының хыялында туган җылы өйне әлеге урман күренешенә иплә генә, һәркем ышанырлык итеп кертеп утыртуы сокландыра, хәйран калдыра. Һәм әнә шул егетлек-тәвәккәллек, мәсьәләне иҗади хәл итү пейзажны җанландырып җибәрә, әсәргә серле матурлык бирә, ямь өсти.

Рәссамнан бервакытта да күргәнен кәгазьгә-картонга-киндергә төп-төгәл итеп күчереп утыртуны дәгъва кылмыйлар, таләп итмиләр. Фәкать автор үзе сурәтләгән күренештән, әлбәттә, хыялдагы образлар белән баетып, сәнгатьчә дөреслек китереп чыгарсын, фәкать ул үзенең таланты-кодрәте белән тамашачыны ышандыра алсын, фәкать ул милли сәнгатебезне яңа гүзәл әсәр исәбенә баетсын. Морат ага Рахманкуловның табигатьне тасвирлауда бу чаклы сәнгатьчә дөреслеккә вә табигыйлеккә ирешүе, әлбәттә, сокландыра һәм сөендерә. Әлеге әсәрне авторның олуг иҗади уңышы дип саңау урынлы булыр.

Морат ага Троицкида яшәүче зур төптән чыккан татар зыялысы Шәрип Рахманкулов гаиләсендә 1909 елның 20 маенда дөньяга килә. Бу нәсел-нәсәбәнең милләтебезгә янә нинди шәхесләр биргәнен раслау нияте белән, мәшһүр драматург Әхмәттаҗетдин, шулай ук җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм сәнгатькяр Шәриф Рахманкуловлар да Морат аганың якын кардәшләре икәнен искә алып үтү дә җитәдер.

Туган шәһәрендә җидене бетергәч тә, малайның төрле сурәтләр ясарга һәвәслеген күреп, Казан каласына укырга җибәрәләр. Хәзерге Сәнгать училищесы бервакытны Архумас (архитектурно-художественные мастерские, ягъни архитектура һәм сынлы сәнгать остаханәләре) дип атала, 1926 елны Морат исемле егет шунда укырга керә. Ул шунда нәкыш һәм графикага өйрәнеп кенә калмый, таштан уеп, балчыктан әвәләп сурәт ясау һөнәрен, ягъни скульптураны да ныклап үзләштерә. Әнә шул заманнан ул Бакый ага Урманчены үзенең остазы итеп таный.

Сәнгать училищесын 1930 елда тәмамлаганнан соң, Морат ага кайларда гына эшләми: Уфаның Сәнгать техникумында да укытып ала, Мәскәүнең киностудиясендә, Казанның киностудиясендә, телестудиясендә, газета-журнал редакциясендә, «Татхудожник»та, Чистайның рус драма театрында, Ульяновскиның худфонд бүлекчәсендә үзенең һөнәрен күрсәтә.

Аның иҗади колачы киңлеккә соклануын белдереп, сәнгать фәннәре докторы С. Червонная «Художники Советской Татарии» дигән китабында: «... ул инде сугышка чаклы ук кино-сценография өлкәсендә эшләүче беренче татар остасы булып җитлегә»,— дип бәяли (421 бит).

1938 елда Рахманкуловны Рәссамнар берлегенә (союзына) кабул итәләр. Илленче еллар башында ул «Татхудожник»та производство эшләрен оештыручы, ягъни мөдир була. Шунда кемнәргәдер ярый алмый гына бит! Бернинди җыелышка-мазар куеп тормыйча, берлекнең җитәкчеләре моны әләкләп Мәскәүгә хәбәр итәләр һәм 1952 елда Рахманкуловны союздан чыгарып ташлыйлар. Олаудан төшереп калдыру гына, яшәү чыганагы булган заказлардан мәхрүм итү генә бик аз тоелгандыр, ахры: аны өстәвенә бер картинадан копия алган чагында юлбашчының портретын бозып күрсәтүдә гаеплиләр. Абзаң — алтын куллы рәссам, Себер китүдән көч-хәл белән котылып кала шул...

20—25 елдан бирле күреп-күзәтеп киләмен Морат аганы. Шулчаклы да әдәпле вә инсафлы, шундый да тыйнак вә сабыр холыклы булса да булыр икән кеше дигәнең! Хәер, аның борчылган чаклары да булмый түгел, әмма ул анда да сер бирми, ягыравык тавышы белән акыллы гына бирәр сүз әйтеп куя — нәтиҗәдә син аны тынычландырасы урынга ул синең үзеңне һәйбәтләп кенә тынычландырып куя да ташлый. Кыенга килгәндә дә акылын җуймыйча, аһ-ваһ куймыйча, гыйбрәтле сүз, төпле фикер әйтергә сәләтле шәхес алдында башыңны имичә хәлең юк.

Гадәттә сәнгать һәм әдәбият өһелләренең көен көйләп, җаена барып кына яшәве аларның җәмәгатьләренә шактый зур кыенлык тудыра бугай. Мәгәр үзе дә шундый ук инсафлы, кече күңелле Суфия ханымга Морат абзый белән тату гомер кичерүләре алай ук кыен булмаганга охшый. Һәрхәлдә, аларның шулай чүкердәшеп яшәүләре әле бүген дә күпләрне сокландыра.

Морат ага, Урманченың арада бер уңган һәм талантлы шәкерте буларак, остазының күркәм холкын-гадәтен кабатлый: тугызынчы дистәнең уртасына җиткәч тә әле — иҗатын дәвам иттерә. Нәкыш өлкәсендә милли сәнгатебезнең аксакалы аеруча зур уңышларга ирешә. Бүгенге көндә дә кыл-каләм остасы әдәбият-сәнгать әһелләренең портретларын яза, Сөембикәнең сурәтен кабат-кабат язып камиллеккә ирешергә хыяллана.

Табигать күренешләрен мәңгеләштерү юлында Морат ага азмы-күпме импрессионистларга якынлаша (1992 елда иҗат иткән «Обсерватория янында» картинасы моның үрнәге). Шунысы кызык, рәссамның әле реалистик рухта язылган «Эңгер-меңгер» (1994) картинасында да импрессионистик чалымнар сизелә. Әйтик, әсәрен сабыр гына язып бетергәч, әллә әйбәт күренеш килеп чыкканга рухланып китеп, әллә инде сиксән бишкә җитеп тә үзендә иҗади дәрт сүнмәвенә сөенеп-канатланып, ак кар өстеннән каенның тамырларын җәеп җибәргәндәй, егетләрчә җитезлек белән саллы гына бер кәкре сызык ташлый да алгы тарафны куерак төс салып ныгыта. Әнә шул бәләкәй генә деталь картинаны тагын да баетып җибәрә, эмоциональ тәэссорат көчен арттыра. Яшьлек дәрте, җан җылысы бөркеп торган картинаны тамашачы яратып кабул итә, хыялга-уйга чума...

Әле күптән түгел генә Татарстан фәннәр Академиясенең «Татар энциклопедиясе» бүлегендә мондыйрак әңгәмә булып алды.

— Ул Рахманкуловның званиесе бармы соң? Заслуженныймы ул, народныймы? — дип кызыксындылар.

— Аңа исем бирергә тиешле заманда Морат аганы Рәссамнар союзыннан чыгарып ташлаганнар, 40 елдан соң гына яңадан алдылар. Мактаулы исем бирү мәсьәләсе әле бүген дә бик нык аксый. Иң милли рухтагы рәссамыбыз Х. Нәфыйковның да, әйтик, исем-дәрәҗәсе юк. Мәчет манараларын язган өчен, татарның чын тарихын сурәтләгән өчен кем бирсен икән аңа исем?! — диярга мәҗбүр булдым.

Ихтимал, моңа өстәп бераз тупасрак сүзләр дә әйтелгәндер. Әнә шул фикеремне үзебезнең ана телебездә укый белүчеләргә генә кабатлап әйтәмен: олуг талант ияләре Морат Рахманкулов белән Хәнәфи Нәфыйковлар — миңа карагаңда ныграк татар җанлы: әгәр дә мәгәр бөтен гомерләре буе миллә тебезгә фидакяр хезмәт күрсәткән шушы талантлы рәссамнарыбыз кертелми икән, әлеге энциклопедиядә үз исемемне күрү миңа оят булыр иде, мин үземне моңа алардан да лаеграк санамыйм.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

# ДИНИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ
# ҺӘМ
# ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1416—1417 ЕЛЛАР

**7 гыйнвар, якшәмбе көн. БӘРАӘТ КИЧӘСЕ.**
Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл — Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлыклар, изгелекләр иңә торган изге төн. Нәкъ менә шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**21 гыйнвар, якшәмбе. ИЗГЕ РАМАЗАН АЕ һәм УРАЗА БАШЛАНГАН КӨН.**

**11 февраль, якшәмбе. ФӘТХЕЛ-МӘККӘ КӨНЕ.**
Мөхәммәт пәйгамбәр тарафыннан Мәккә шәһәрен яулап алу — «Фәтхел-Мәккә» көне.

**17 февраль, шимбә көн. КАДЕР КИЧӘСЕ.**
Бу төндә язмышлар хәл ителә. Бу төндә Мөхәммәт пәйгамбәргә Коръән Кәрим иңә башлый.

**20 февраль, сишәмбе көн. УРАЗА БӘЙРӘМЕ.**
**ГАЙДЕЛ-ФИТР. УРАЗА БӘЙРӘМЕ.** Ураза тәмамлангач, авыз ачу бәйрәме башлану.

**27 апрель, шимбә. ГАРӘФӘ КӨНЕ.**
Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**28 апрель, якшәмбе көн.**
Гайдел-Адха, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Бу, ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**29, 30 апрель, 1 май — дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе. ТӘШРИК КӨННӘРЕ.**
Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**19 май, якшәмбе. МӨХӘРРӘМ АЕ башланган көн.**
1417 ел — Яңа мөселман елы башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зякят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**28 май, сишәмбе. ГАШУРӘ КӨНЕ.**
Сөнниләр тарафыннан Аллаһы Тәгалә үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы, Гали хәлифәнең улы — имам Хөсәенне (626—680) җәзалап үтерелүе көне хөрмәтенә билгеләп үтелә.

**3 июнь, дүшәмбе. Болгар татарларының ИСЛАМНЫ КАБУЛ ИТҮ КӨНЕ.**

**18 июнь, сишәмбе. СӘФӘР АЕ БАШЛАНГАН КӨН.**

Сәфәр аенын 27 көнендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм анын сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көне. Шушы төннән, ягъни 622 елның 16 июль төненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни Һиҗри ел исәбе башлана.

**27 июль, шимбә. МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ.**

Иң зур бәйрәмнәрнең берсе — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне — Мәүлид бәйрәме башланган көн. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, Мөхәммәд пәйгамбәр хөрмәтенә җәмәгать намазлары укыла, хәер-сәдака (Зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**15 октябрь, сишәмбе. ХӘТЕР КӨНЕ.**

Казанны саклап каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны искә алу көне.

**12 ноябрь, сишәмбе. РӘҖӘБ АЕНЫҢ БАШЫ.**

Дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаренең җиденче ае — Рәҗәбнең беренче көне. Нәкъ шушы көндә Мигъраҗ бәйрәме билгеләп үтелә, кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына, ә Мигъраҗ уразасы 60 ай яки 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**8 декабрь, якшәмбе көн. МИГЪРАҖ БӘЙРӘМЕ.**

Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәт көне.

**12 декабрь, пәнҗешәмбе. ШӘГЪБАН АЕ БАШЛАНУ КӨНЕ.**

Дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча сигезенче ай — Шәгъбан ае башлану көне.

Календарьны әзерләүче — хаҗи **Абдулла ДУБИН.**

# 1995 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Татарстан Республикасының 1995 елгы Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында. № 6.
«Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. № 7.

### Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул ителүгә 5 ел

Биш еллык гомердә (Татарстан Республикасының Премьер-министры Ф. Х. Мөхәммәтшин белән әңгәмә). № 8.

### ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ахунов Г., Гәрәев М. Арча җиренең ачык китабы. *Документаль повесть.* № 2.
Баянов Ә. Хыялда туган калам. *Автобиографик повесть.* № 12.
Гали Әсрар. Нәни хикәяләр. № 5.
Галиев Ш. Минем беренче гомерем. *«Хистәлек»ләр.* № 5, 6.
Галиуллин Т. Кияү. *Хикәя.* № 2.
Галиуллин Т. Сәмруг кош. *Хикәя.* № 8.
Гаффар Ә. Дәрья башы. *Повесть.* № 4.
Гыйләҗев А. Камыш бармак, көмеш тырнак. *Повесть.* № 7.
Донис З. Динозаврлар нигә беткән? *Хикәя.* № 7.
Закир Л. Инша. Кара хикәят. № 7.
Зәйнуллин З. Өч хикәя. № 7.
Зәйнашева Г. Менә шундый мәхәббәт. № 12.
Камалов Б. Яшьлеккә хыянәт. *Хикәя.* № 10.
Камалов Х. Түләнмәгән күз яше. *Роман.* №№ 1, 2, 3.
Кәрами Р. Авылдаш. *Хикәя.* № 11.
Латыйп К. Җиденче сәяркә. *Новелла.* № 9.
Маннап Ш. Моңсу хатирәләр. № 6.
Мөбарәков Т. Хәтер аланы. *Повесть-кыйсса.* № 4.
Рәшит Ә. Шомырт чәчәкләре. *Хикәя.* № 3.
Сибат Р. Ике гашыйк һәм җыр тыңлаучы ат. *Повесть.* № 5.
Сирматов И. Керәшен кызы. Моңсу повесть. № 8.
Фәизов Р. Телсез. *Хикәя.* № 1.
Фәизов Р. Ак каз. *Повесть.* № 11.
Фәйзи З. Сазлыкка ауган чәчәк. *Повесть.* № 8.
Хәлим А. Гомеремнең ун көне. Сәяси ачлык көндәлеге. № 6.
Яхин Ф. Август ае. *Роман.* №№ 10, 11.
Әйди Т. Кечкенә дә төш кенә. Эстониягә сәяхәт. № 9.

### ШИГЪРИЯТ

Афзал Г. Хәтер көне. *Шигырьләр.* № 2.
Биектаулы И. Соңгы оран. *Шигырьләр.* № 10.
Булатова К. Бу языклы дөньяда. *Шигырьләр.* № 8.
Булгакова Д. Күңел капкагызны шакыйм. *Шигырьләр.* № 3.
Вәлиева Р. Ник әрнетә һаман ул моңнар? *Шигырьләр.* № 3.
Габдрәхим Р. Бөек Иванга ачык хат. *Шигырь.* № 6.
Габиди Ә. Сагышлы хушлашу. *Шигырьләр.* № 12.
Гарифуллин Д. Минем уйлар сездә, робагыйлар. № 6.
Гаташ Р. Чулпан йолдыз калыкканда. *Шигырьләр.* № 2.
Гаташ Р. Кышкы робагыйлар. № 11.
Гатина Ф. Актарыла дәрьяларның суы. *Шигырьләр.* № 10.
Гыйззәтуллина Ф. Кыялар моңы. Поэма. № 10.
Гәрәева С. Өмет. *Шигырьләр.* № 11.
Закир М. Биеклек. *Шигырьләр.* № 7.
Зәйнашева Г. Су буенда тал бөгелә. *Шигырьләр.* № 3.
Ибраһим Х. Әүвәл миннән шалаш сорадың... *Шигырьләр.* № 11.
Латыйп К. Карт солдат уйлары. *Шигырьләр.* № 5.
Мансур З. Дүнү. *Шигырьләр.* № 5.
Миңлекәй. Кирәк түгел миңа... *Шигырьләр.* № 12.
Мортазин Ф. Бөек хакыйкатьне эзләп. *Шигырьләр.* № 10.
Мулла Гали С. Нишләр идек. *Шигырьләр.* № 12.
Мусин Ч. Сагыну. *Шигырьләр.* № 10.
Мәннан Р. Каләмле көз. *Шигырь.* № 10.

Мөслимова Ф. Рәссам истәлеге. *Шигырьләр.* № 3.
Низами. Исәнме, Сабантуй! *Шигырь.* № 5.
Низамиев Р. Татарстан турында моңсу җыр. *Шигырьләр.* № 9.
Нәҗми Н. Көтүчеләр. *Шигырьләр.* № 9.
Рафаил. Сандугачлар. *Шигырьләр.* № 4.
Рахман Р. Кояшлы җәй. *Шигырьләр.* № 9.
Садә Г. Ак бүре. *Шигырьләр.* № 8.
Саттар-Мулилле Г. Була алсам... *Шигырьләр.* № 10.
Сафина Н. Сиңа да, миңа да. *Шигырьләр.* № 3.
Сәгадәт К. Нигез. *Шигырьләр.* № 4.
Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. № 7.
Хәлим А. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 12.
Шагыйрьҗан Л. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 6.
Шиһап Р. Килер дәвергә сүзем. *Шигырьләр.* № 11.
Юзеев И. Сандугачның бишек җыры. *Шигырьләр.* № 7.
Яруллин Ф. Манаралар, айлы манаралар. *Шигырьләр.* № 2.
Әгъләм М. Күз яше без. *Шигырьләр.* № 12.
Әмәк Ф. Вакытында әйтелгән сүз. *Шигырьләр.* № 10.
Әхмәдиев Н. Үз бәхетем. *Шигырьләр.* № 11.
Әхмәтҗан Рәшит. Яңа шигырьләр. № 1.
Әхсәнов И. Баш иям — ияләргә. *Шигырьләр.* № 8.
Әхтәмова Р. Ай тулган төн. *Шигырьләр.* № 3.
Әюп Х. Кол Гали. *Шигырьләр.* № 3.
Җамал Р. Синең белән бергә чакта... *Шигырьләр.* № 10.

## ДРАМАТУРГИЯ

Мингалим Р., Хәмид Р. Идегәй. *Нәфис фильм өчен драма.* №№ 7, 8, 10.
Миңнуллин Т. Хушыгыз! *Ике пәрдәле драма.* № 1.
Салихов Д. Алла каргаган йорт. *Ике пәрдәле драма.* № 12.

## ОСТАХАНӘ

Зариф Ч. Зәңгәр кыялар. *Шигырьләр.* № 1.
Шаһиева Р. «Татар ретросы». *Шигырьләр.* № 3.
Әсән Г. Бала чакта... *Шигырьләр.* № 4.

## ӘДӘБИ МИРАС

Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты. № 7.
Габдессәлам. Илаһи бәетләр. № 6.
Гайнетдин М. Вакыйф Җәлалның гает шигырьләре. № 8.
Госманов М. Гаяз Исхакый: «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм патша цензурасы *(Иҗатының яңа сәхифәләре ачылу).* № 10.
Максуди С. Англиягә сәяхәт. №№ 11, 12.
Маннап Ш. Алтын бөртекләре югалмый. № 2.
Сүнчәләй С. Азан. *Шигырьләр.* № 2.
Шигырьле сулышлар *(Сибгат Хәкимнең Наҗар Нәҗмигә язган хатларыннан).* № 7.
Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Габдессәлам. № 6.

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Нәсин Г. Фил Хәмди. № 12.

## КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ ИҖАТЫ

Чавуш М. Ялгыш аңламагыз безне. *Шигырьләр.* № 6.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Ляпин И. Тауларга килсен иминлек. *Шигырьләр.* № 3.

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

### ХӘТЕР

Мостафин Ш. Байракчы Гази Заһитов. № 5.
Солтанбәков Ф. Үлем сәгатен көткәндә *(М. Җәлил һәм җәлилчеләр турында истәлекләр).* № 5.
Фронтовик шагыйрьләр иҗатыннан. № 5.
Шагыйрьләр, фронт һәм хатлар. № 5.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин М. «Колхоз тарала микән?» № 9.
Батулла. Төркиядә төрекләр яши. № 3.
Муллануров М. Тылсымлы кеше. № 11.
Низамиев Р. Без кая барабыз? № 6.
Хисаметдинов Р. Дусларымның васыятен үтәдем. № 9.
Юныс М. Гасабилы уйлар. № 10.

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Саттар-Мулилле Г. Татар телле Татарстан. № 7.
Әйди Т. Инкыйраз көзгесе. № 4.
Әхмәдулла Ш. Тарихи дөреслекне кайтарыйк. № 11.

## МӘДӘНИ МИРАС

Баттал Г. Казан төркиләре. №№ 3, 4, 5.
Әйди Т. Күренекле шәхесләребезнең берсе. № 3.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гыйззәт К. Таҗи Гыйззәтнең реализмы *(Тууына 100 ел тулу уңаеннан).* № 9.
Ибраһимова Ф. Гаяз Исхакый турында замандашлары. № 3.
Нуруллин И. Булган ул тәнкыйди реализм. № 2.
Сугышта җиңгәч — зинданга... *(70 яше*

*тулу уңаеннан күренекле язучы Гурий Тавлин белән әңгәмә).* № 12.

Хафизов С. Башкортстанда татар әдәбияты. № 1.

Әхмәдиева Л. Язмыш һәм иҗат. № 4.

## ШИГЪРИЯТ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Вәли М. Тәнкыйтьчеләр кая качкан? № 7.

Галиуллин Т. Шигырь кемгә кирәк? № 7.

Мостафин Р. Шигъри публицистика. № 7.

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Нурани Җ. Мәкерле көндәш. *Хикәя.* № 1.

Әмирхан М. Челлә бабай фатихасы. *Хикәя.* № 1.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Миңнегулов Х. Алтын Урда әдәбияты. № 1.

Әхмәтҗан Р. Тукай әкиятләрендә күчмә сюжетлар. № 8.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Бадыйков Х. Тау чишмәсе кебек. № 6.

Вәли М. Безнең урамнарның бәйрәме. № 3.

Галимуллин Ф. Шәркый рухыбыз тамырлары. № 1.

Ханзафаров Н. Заман дәреслеге. № 7.

Әхмәтҗанов М. Әдәбият — әхлак тоткасы. № 5.

Әхмәтҗанов М. Татарстанда Сталинның канлы эзләре. № 12.

## ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Кәримуллин Ә. Милли китабыбыз тарихы турында. № 2.

Михайлова С., Мөхәммәтҗанова Г. Тарихи һәм матур әдәбиятта Алтын Урда. № 7.

## ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Англиядә «Ислам энциклопедиясе» *(АКШ галиме Сирил Гласс әфәнде белән әңгәмә).* № 7.

## МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА

Гасырлар авазы. № 9.

Камал Т., Әмирхан Р. Фикри юл. *(Яхъя Абдуллин — фәлсәфә тарихчысы.)* № 1.

## ТЕЛЕБЕЗ ХӘЗИНӘСЕ

Саттар-Мулилле Г. Ономастика һәм энциклопедия. № 1.

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Низамов И. Татар рекламы: кичә һәм бүген. № 6.

Таиров Н. Сембердә Акчуриннар мәчетләре. № 6.

## СӘНГАТЬ

Татарның Туишевы. № 7.

Тургай картаямы? *(Илһам Шакировка 60 яшь.)* № 2.

Әхмәт Р. Фасилнең тормыш фасыллары *(Композитор Фасил Әхмәткә — 60 яшь).* № 5.

## ЮБИЛЕЙЛАР

### АБАЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Абай. Дөнья — салкын. *Шигырьләр.* № 8.

### ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Әгъләм М. Татарның танылмаган мәшһүр заты. № 1.

Зөлфәт. Бабичны юксыну. *Шигырьләр.* № 1.

Бабич Ш. Халкым өчен. *Шигырьләр.* № 1.

### М. БӨДӘЙЛИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Рухы сынмаган көрәшче. № 4.

Бөдәйли М. Тормыш төпчекләре. № 4.

### ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Олуг исемеңне зурлыйлар *(Г. Бәширов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Х. Камалов истәлекләре).* № 1.

### САЛИХ БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Баттал С. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 8.

### САФА САБИРОВКА 80 ЯШЬ

Низамиев Р. Ул һаман фарватерда. № 8.

Сабиров С. Бишбалта мөгаллиме. № 8.

### АТИЛЛА РАСИХКА 80 ЯШЬ

Зариф Р. Хакыйкатьне юлдаш итеп. № 8.

### «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 75 ЯШЬ

Яшьме, картмы? № 11.

### ГАРИФ АХУНОВКА 70 ЯШЬ

Ахунов Г. Йолдызлар калка. Автобиографик повестьның икенче китабыннан. № 9.

### МӘГЪСУМ НАСЫЙБУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Галимуллин Ф. Ак теләкне җилкән итеп. № 10.

### ҖӘМИТ РӘХИМОВКА 60 ЯШЬ

Төхфәтуллин Р. Кыядагы чәчәкләр. № 1.

Рәхимов Җ. Эскерттәге эзә. Эссе. № 1.

#### ӘДХӘТ СИНУГЫЛГА 60 ЯШЬ

Гаташ Р. Котлау сүзе. № 3.
Синугыл Ә. Күзгә бакча. *Шигырьләр.* № 3.

#### РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНГА 60 ЯШЬ

Гамбәр Н. Җәяүле күбәләк. № 4.
Әхмәтҗан Р. Төрле еллар дәфтәреннән. *Шигырьләр.* № 4.

#### ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Кама җилләре чыныктырган егет. № 8.
Миңнуллин Т. «Кызыл тышлы дәфтәр»дән. № 8.

#### ЭДУАРД МОСТАФИНГА 50 ЯШЬ

Мостафин Э. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 1.

#### ФИРАЯ ЗЫЯТДИНОВАГА 50 ЯШЬ

Зыятдинова Ф. Дулкыннар. *Шигырьләр.* № 9.

#### ҖӘҮДӘТ ДӘРЗАМАНГА 50 ЯШЬ

Дәрзаман Җ. Иң зур хикмәт. *Шигырьләр.* № 10.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Вакыйф Нуруллинга 60 яшь. № 5.
Наип Лаисовка 60 яшь. № 8.
Сарман сандугачларының бересе *(Мәдинә Маликовага 60 яшь)*. № 8.

### БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Каюм Насыйриның тууына 170 ел. № 2.
Абдулла Әхмәтнең тууына 90 ел. № 3.
Әбрар Сәгыйдинең тууына 100 ел. № 4.
Мәҗит Рафиковның тууына 70 ел. № 4.
Нур Баянның тууына 90 ел. № 5.
Әхмәт Исхакның тууына 90 ел. № 5.
Гали Халитның тууына 80 ел. № 6.
Муса Бигиевнең тууына 120 ел. № 9.
Заһидә Борнашеваның тууына 100 ел. № 10.

### КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Рахмани Р. Халкыбызның күрәшче галиме *(Әбрар Кәримуллинга 70 яшь тулу уңаеннан)*. № 7.

### ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Солтанбәк Б. Сталинның Бакудагы дусты. № 4.

Дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр № 12.

### КАРДӘШ ӘДӘБИЯТЛАР

Җәнгиз Дагҗыга 75 яшь. № 9.

### «КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН

Өч рәсем — өч мизгел. № 7

### ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Вәлиева Д. Дала — хәтер. № 1.
Шаһиева Р. Анының фатихасы. № 2.
Шаһиева Р. Камил Муллашевның «Герника»сы № 3.
Вәлиева Д. Галәмгә үрелгән учак уты. № 4.
Шаһиева Р. «Ханның халыкка анты». № 5.
Шаһиева Р. Түсләрдән — «Иртә яз». № 6.
Шаһиева Р. Курчак. № 7.
Гамбәр Н. Кояшлы тауга күтәрелү. № 11.
Миңлебаев К. Сабыр төбе — сары алтын. № 12.

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№ 1—12.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам М. Рахманкуловның «Эңгер-меңгер» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** тәнкыйтьче, «Идел» журналының баш мөхәррире Ф. Зөлкарнәев.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — КАЗАН КРЕМЛЕ

8 ноябрьдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Казан Кремлен реставрацияләү һәм реконструкцияләү мәсьәләләре буенча киңәйтелгән киңәшмә үткәрде. Анда ТР Архитекторлар берлеге рәисе Ф. Зәбирова, «Татинвестгражданпроект» фирмасы президенты И. Габдрахманов бу юнәлештә башкарылган эшләр турында җентекле мәгълүмат бирделәр. Халыкара кануннар нигезендә, Казан Кремлендәге бик тә кызыклы биналар ансамбле, мөмкин булганча, беренчел йөзен алырга тиеш, дип ассызыклап әйтеп үтелде киңәшмәдә.

Колшәриф мәчете архитектурасы буенча ТР Президенты республика конкурсы игълан итәргә тәкъдим кертте. Киләсе елда Татарстанда яшәүчеләр чын мәгънәсендә тарихи вакыйганың — кайчандыр Казанның серле рәвештә юкка чыккан төп мәчете архитектурасын яңадан торгызуның шаһитлары булырлар.

## АВСТРАЛИЯДӘ — ТАТАРСТАН ФЛАГЫ

19—22 ноябрь көннәрендә Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин җитәкчелегендә Татарстан Республикасы делегациясе рәсми визит белән Австралиядә булды. Ике ил җитәкчеләре арасында эшлекле һәм файдалы сөйләшүләр-килешүләрдән соң, Аделаида шәһәрендә Татарстанның Австралия берлегендәге вәкаләтле вәкиллеген (җитәкче — Р. Садри) рәсми төстә ачу тантанасы үткәрелде. Анда Көньяк Австралия Премьер-министры Д. Браун катнашты һәм чыгыш ясады. Җөмһүриятебез Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин исә бу тантанада катнашкан татар җәмгыяте вәкилләренә Татарстан Республикасы Флагын, Гербын һәм Гимн язмасын тапшырды, татар китапларын һәм милли музыкаль язмаларыбызны бүләк итте.

## КРЕМЛЬДӘ КАБУЛ ИТҮ

20 ноябрьдә Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Шәймиев Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнарының Үзәк Диния Нәзарәте Баш мөфтие Т. Таҗетдинны кабул итте. Әңгәмә барышында мөселман җәмгыятьләренең тынычлык сөю һәм татулык принципларында бердәмлеген ныгыту кирәклегенә бәйле мәсьәләләр күтәрелде. ТР Президенты, Үзәк Диния Нәзарәте Казан Кремле территориясендәге Колшәриф мәчетен торгызуда турыдан-туры катнашса иде, дигән теләк белдерде.

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНА — МАКТАУ ДИПЛОМЫ

Мәскәүдә «Сәламәт дөньяда балаларның сәламәтлеге өчен» дигән Беренче Бөтендөнья хәйрия сәнгать фестивален оештыру һәм үткәрүдә зур өлеш кертүчеләрне Мактау дипломнары белән бүләкләү тантанасы үткәрелде. Татарстан Президенты М. Шәймиев тә, ЮНЕСКОның Генераль директоры Ф. Майор, АКШ Президенты Б. Клинтон, Россия федерациясенең Дәүләт Думасы Рәисе И. Рыбкин кебек күренекле шәхесләр белән бергә, шушы дәрәҗәле халыкара бүләккә лаек булды.

## КИТАПКА — ДӘҮЛӘТ КАЙГЫРТУЫ

22 ноябрьдә ТР Дәүләт Советында «Татарстан Республикасында китап нәшер итүнең торышы турында» парламент тыңлавы үткәрелде. Анда китап нәшрияты, матбугат хезмәткәрләре, кайбер министрлыклар вәкилләре һәм халык депутатлары катнашты.

30 ноябрьдә исә шушы җитди мәсьәлә буенча Татарстан китап нәшриятында да эшлекле зур сөйләшү булды.

## ИҖАТ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев җитәкчелегендәге «Шигърият остаханәсе» тарафыннан ноябрь аенда гына да өч урында — «Сабантуй», «Ватаным Татарстан» газеталары редакцияләрендә һәм Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына караган кульязмалар һәм текстология бүлегендә кызыклы очрашулар уздырылды. Аның беренчесендә Башкортстан кунаклары — танылган язучылар Р. Сафин һәм М. Кәримовның иҗат лабораторияләре белән якыннан таныштыру булса, икенчесендә Зөлфәтнең «Ике урман арасы» дигән әр-яңа китабын тәгъдир итү булды. Өченче очрашуны исә «Шигърият остаханәсе», «Проза һәм драматургия остаханәсе», «Балалар әдәбияты остаханәсе» (җитәкчеләре — Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев иптәшләр) белән берлектә, «Мирасыбыз кемгә кала?» дигән мөһим мәсьәләгә багышлап үткәрде.

## АПАСТА — ӘДӘБИЯТ КӨННӘРЕ

23—25 ноябрь көннәрендә Апас районында әдәбият көннәре үткәрелде. Очрашулар район үзәгендә, Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиевның туган авылы Бакырчыда, Урта Балтайда, фронтовик шагыйрь

Г. Хужины дөньяга бүләк иткән Карамасарда оешканлык белән узды. Район хакимияте үзләренең якташы Ш. Галиевның иҗат итүенә 50 ел тулуны халык бәйрәме төсендә зурлап билгеләп үтте.

Әдәбият көннәрендә Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев, ТР Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары, шагыйрь Р. Харис, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, шагыйрьләр Р. Миңнуллин, М. Шиһапов, республика телевидениесе мөхәррире Э. Хамматова катнашты.

## ТУФАН УНКӨНЛЕГЕ

11 ноябрьдә Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры бинасында танылган драматург Туфан Миңнуллинның юбилей кичәсе зур уңыш белән узды. Әлеге тантана Туфан әсәрләре буенча куелган спектакльләр ункөнлегенең бер йомгагы иде.

Бәйрәм кичәсендә алтмышын тутырган ир-егетне ТР Президенты М. Шәймиев котлады, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы дипломын һәм истәлекле бүләк тапшырды. Юбилярны Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, драматургның туган ягы — Кама Тамагыннан район хакимияте башлыгы М. Шәмсетдинов, каләмдәшләре Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Вәлиев, күпсанлы сәнгать әһелләре кайнар тәбрикләделәр.

Кичәдә шулай ук Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев, Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин катнашты.

## ӘДИПНЕ ОЛЫЛАУ

Танылган юрист, юстиция өлкән киңәшчесе, язучы, ике дистәдән артык китап авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәгъсүм Насыйбуллинның 70 яшьлек юбилеен туган ягы Кукмара районында зурлап билгеләп үттеләр. Район типографиясендә юбилярның тормышын һәм иҗади эшчәнлеген яктырткан китап басылып чыкты, «Хезмәт даны» газетасында исә бер ай дәвамында аның турында кызыклы язмалар, истәлекләр биреп барылды. Кукмара районы мәктәпләрендә, мәдәният йортларында, китапханәләрдә юбилярга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр, китап укучылар конференцияләре үткәрелде.

Аннары тантана әдипнең туган авылы Байлангарда дәвам итте. Анда Казаннан килгән бер төркем язучылар, юстиция министрлыгы, прокуратура органнары вәкилләре, якын дуслары катнашты.

## ОЛЫ ШӘХЕСЛӘР ОНЫТЫЛМЫЙ

Язучы Шәйхи Маннурның тууына 90 ел тулу юбилеен якташлары олылап билгеләп үттеләр. Соңгы вакытта әлеге олуг шагыйрьнең һәм әдипнең Тулбай авылы (Мамадыш районы) зиратындагы каберe өстендәге мәрмәр ташка аның барельефы куелды һәм васыятендә әйтелгән:

Синең бар җиреҥ сөекле,
И Тулбаем — моң илем,
Бул бәхетле, бул ирекле —
Бар теләгем шул минем! —

дигән шигъри юллары язылды. Бу эшне күренекле скульптор Ә. Әбдерәшитов һәм җирле үзидарәнең Олыяз авыл Советы рәисе, һәвәскәр рәссам А. Һадиев башкарды. Татарстан йон эшкәртү акционерлык җәмгыяте һәм «Чулпан» күмәк хуҗалыгы (җитәкчеләре — Ә. Шәрәфетдинов, Ф. Хисмәтов иптәшләр) шушы чараларны башкарып чыгу өчен матди яктан ярдәм күрсәттеләр.

7 октябрьдә Ш. Маннурның яңартылган кабер ташы янында язучының иҗат мирасы комиссиясе рәисе И. Юзеев, комиссия сәркатибе — «Казан утлары» журналының бүлек мөдире Ш. Мостафин, җырчы М. Галиев, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры, шагыйрь Р. Корбанов һәм якташлары булды. Бирегә Шәйхелислам аганың һәм әти-әнисенең якты рухларына багышлап, Коръән Кәримнән аятьләр укылды, каберләренә чәчәк бәйләмнәре салынды.

Шул ук көнне Казан кунаклары Ш. Маннурның якын дусты — 37 ел буе «Чулпан» күмәк хуҗалыгына җитәкчелек иткән сугыш һәм хезмәт ветераны, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Г. Җиһаншинны искә алу, аның хөрмәтенә Дусай авылында мемориаль такта ачу, каберенә зыярәт кылу, яңа мәчеткә нигез салу чараларында да катнаштылар.

## ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ...

Моннан 31 ел элек, арабыздан бик иртә киткән шагыйрь һәм композитор Ләбиб Айтугановның тууына 60 ел уңаеннан аның туган җирендә — Әгерҗе районының Нарат авылы мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Әлеге искә алу кичәсендә шагыйрь Ә. Рәшитов, халкыбызның яраткан җырчылары В. Гыйззәтуллина, Р. Ильясов, М. Сөнгатуллин һ. б. чыгыш ясады. Шагыйрьнең кызы Миләүшә Айтуганова исә әтисенең тиздән дөнья күрәчәк шигырьләр җыентыгыннан (ул — аның төзүче-мөхәррире) кайбер әсәрләрен укыды, хатыны Луиза ханым, туганнары исә истәлекләр белән уртаклаштылар.

25 ноябрьдә Л. Айтугановка багышланган шундый ук кичә «Казан» милли-мәдәни үзәгендә дә үткәрелде. Анда Әгерҗе районыннан да күп кенә кунаклар килгән иде.

## ХӨРМӘТЛӘҮ КИЧӘЛӘРЕ

10 ноябрьдә «Казан» милли-мәдәни үзәгендә Татарстанның атказанган артисты, күренекле җырчы Сөләйман Йосыповның 70 яшьлек юбилеена багышланган иҗат кичәсе булды.

* * *

«Казан» милли-мәдәни үзәге 17 ноябрь — 7 декабрь көннәрендә татар халкының иң оста җырчылары катнашында «Сандугач-95» дип исемләнгән җыр бәйрәме уз-

дырды. Менә шул бәйрәм көннәренең берсе 30 ноябрьдә М. Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында үткәрелде. Ул Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, язучы Фәнис Яруллинга һәм аның хәләл җефете Нурсәя ханымга багышлап уздырылды. Көчле рухлы әдипне тамашачылар, килгән кунаклар алкышларга, чәчәк бәйләмнәренә күмделәр.

* * *

Тугандаш Башкортстан кызы — Татарстан Президентының милләтара мәсьәләләр буенча баш референты, шагыйрә Фирдәвес Бәшированың 50 яшьлек юбилеена багышлап, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Аннары шундый ук кичә юбилярның туган төбәгендә — Ишембай шәһәрендә дәвам иттерелде. Фирдәвес ханымны туган көне белән котларга Уфа, Стәрлетамак, Салават һ. б. шәһәрләрдән дә күп кенә кунаклар, әдәбият һәм сәнгать әһелләре килгән иде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — ВЕТАКАМЕДИЯДӘ КУНАКТА

9 ноябрьдә Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясендә «Казан утлары» журналын укучылар белән очрашу булды. Аны академия ректоры — академик Г. Идрисов ачып җибәрде. Аннары журналның баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, журналның даими авторы И. Юзеев, баш мөхәррир урынбасары Р. Низамиев, әлеге югары уку йорты профессоры, шагыйрь Р. Корбанов кебек иҗатчылар чыгыш ясады. Кичәдә Татарстанның халык артисты, җырчы Миңгол Галиев үзенең дүрт шәкерте — Р. Низамов, Р. Галиева, И. Мәгъсүмов, Р. Җаббаров белән чыгыш ясап, актлар залын дәртле дә, моңлы да булган җырларга күмделәр. Очрашу барышында ветакамедиядә яшь иҗатчылар өчен «Канатлы ат» дип исемләнгән студия оештыру зарурлыгы әйтелде.

## ЯКТАШЛАР ОЧРАШУЫ

17 ноябрьдә Кукмарада илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче якташлар очрашуы булып узды. Ул Кукмарага нигез салынуга 400 ел, район оешуга һәм район газетасы чыга башлауга 65 ел тулу уңаеннан үткәрелде. Әлеге очрашуда язучылардан М. Насыйбуллин, Ф. Галимуллин, Г. Морат, Р. Рахман, З. Мәхмүди, Х. Нигъмәтуллина, композитор Ф. Әхмәтов, җырчылардан Г. Ильясов, Р. Абдуллина, С. Әхмәтгалиева, Татарстан Журналистлар берлеге идарәсе рәисе Р. Ратникова, журналистлардан М. Авзалова, Г. Ризванов һ. б. катнашты. Тантаналы кичәдә район хакимияте башлыгы М. Гатиятуллин дүрт телдә — татар, урыс, удмурт, мари телләрендә чыгыш ясады һәм якташларга туган як туфрагы, истәлекле бүләкләр тапшырды. Шул ук көнне якташлар җәмгыяте оештырылып, аның рәисе итеп бертавыштан язучы-галим Ф. Галимуллин сайланды.

## БЕЗНЕКЕЛӘРНЕ БЕЛӘЛӘР

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры — Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев Төркия Республикасының Гуманитар академиясе академигы итеп сайланды.

* * *

Казан компрессорлар заводы директоры Әхмәт Мөхетдин улы Галиевның даны еракларга билгеле. Аның җитәкчелегендәге коллектив, заманнарның авыр булуына карамастан, тотрыклы эшли, алдынгы технологияне киң куллана. Американың Биография институты аны «Ел кешесе» дип игълан итте һәм истәлекле медаль тапшырды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Сынлы сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Указы белән, ТР Рәссамнәр берлеге идарәсе рәисе — рәссам Абрек Әмир улы Абзгильдинга, «Татарстан Республикасының халык рәссамы» дигән исем бирелде.

* * *

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе ректоры Рәис Кыям улы Беляев, РФ Президенты Б. Ельцин Указы нигезендә, «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

* * *

Сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен, «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясенең сәнгать тапшырулары программасы баш мөхәррире, шагыйрь Әхмәт Әхәт улы Рәшитовка, «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Рафаэль МУСТАФИН, Анас ХАСАНОВ. Первый Президент Татарстана Минтимер Шаймиев.**
Казан: Тат. кит. нәшр., 1995, 288 б. Тиражы — 10 мең данә.




Халкыбызның күренекле шәхесләре, аларның тормыш юлы һәм хезмәт эшчәнлекләре турында алар үзләре исән чакта махсус язылган китапларның бездә чыкканы юк диярлек. Ә Минтимер Шәрип улы Шаймиев — татар халкы, бигрәк тә Татарстан Республикасы язмышында тарихи шәхес. Соңгы дистә елларда республиканың сәяси һәм икътисадый тормышын аның эшчәнлегеннән тыш күз алдына китерү кыен. Китапның җәяләр эченә алынган исеме — «сәяси портретка штрихлар» дип атала. Сигез бүлектә тупланган материаллар бүгенге көндә күп халыклар таныган абруйлы Президентның тормыш юлын, шәхес һәм сәясәтче буларак кылган гамәлләрен шактый тулы тасвирлый. Китапта Президентның чыгышлары, журналистлар белән әңгәмәләре, аның үзе турында язылган мәкаләләр, шигырьләр тупланган. Китап заманча полиграфик ысулда басылган, Татарстан һәм Президент тормышын чагылдырган күпсанлы фоторәсемнәр белән бизәлгән.

**Рахмай ХИСМӘТУЛЛА. Тәүбә** *(Повесть, шигырьләр, публицистика).* Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995.—336 б. Тиражы — 2500 данә.




60 еллыгы уңае белән чыгарылган бу китапта Гаяз Исхакый бүләге лауреаты Рахмай Хисмәтуллинның иң яхшы әсәрләре тупланып бирелгән. Әсәрләрнең кайберләренә 1956 ел датасы куелса, кайберләре 1993 ел дип тамгаланган. Укучыга тәкъдим ителгән бу җыентыкка авторга хас хис кайнарлыгы, үткен тел белән язылган мәкаләләр, сайланма шигырьләр һәм «Тәүбә» исемле яңа повесть кергән. Китап Чаллы шәһәр хакимияте булышлыгы белән нәшер ителгән.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# QAZAN UTLARI
# ОГНИ КАЗАНИ

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**

Журнал включен в центральный каталог